Гөлфия Мөхәммәтгәрәева



Дөнья сүзе – бер бүләк



Казан
«Халкыбыз мирасы»
2021

ББК 26,59
УДК 908
М92

Гөлфия Мөхәммәтгәрәева

М92 Дөнья сүзе – бер бүләк. – Казан: «Халкыбыз мирасы» нәшрияты, 2021. – 368 б.

Бу китапка авторның 2014–2019 елларда «Тәртип-93.1 FM» радиосында яңгыраган тапшыруларының язма вариантлары кертелде.

ISBN 978-5-905160-20-2

© Гөлфия Мөхәммәтгәрәева, 2021

Дөнья сүзе – бер бүләк

Эшләгән вакытымда башымда бик кызыклы фикерләр, идеяләр туа иде, әмма аларны тормышка ашырырга һич кенә дә мөмкинлек булмады. Укытучы эше шундый бит ул: вакыт җитми, төнлә эшләрмен, язармын әле дип тә булмый, чөнки укытучының эше өйгә дә ияреп кайта... Лаеклы ялга чыккач, башымда йөргән фикерләремне туплап, киң катлау укучыларга газета-журналлар аша булса да җиткерермен әле, дип үземне өметләндердем. Чыннан да, андый вакыт җитте һәм мин җиң сызганып эшкә тотындым...

Укыткан вакытларда, «их, менә моны шулай итеп укытырга иде; менә шундый материал булсын иде; шушы урында менә мондый аудиоязмалар кулланылса, дәрес тагын да үтемлерәк булыр иде», кебек уй-фикерләр аз килмәде башыма... Белгәннәремне укытучылар, киләчәк буынны тәрбияләүчеләр белән уртаклашасым, аларга аз булса да ярдәм итәсем килде...

Үз гомеремдә бик күп гыйбрәтле хәлләрнең шаһиты булдым, ишеттем, тормышны күзәттем, катлаулы тормыш юлы узып, тормыш тәжрибәсе туплаган абый-апалар, әби-бабайларның сөйләгәннәрен күңелемә сеңдереп, үземчә нәтиҗәләр дә ясап бардым, күп укыдым... Һәм шуларны җыйнап, педагоглар, ата-аналар, яшь буын игътибарына тәкъдим итәргә теләдем...

Белгәннәремне халыкка җиткерүдә районыбыз газетасы «Авыл утлары», «Мөслим радиосы», «Татарстан яшьләре» газетасы, «Тәртип-93.1 FM» радиосы иң зур таянычларым булды.

Чыннан да, сүз – акыллы, гыйбрәтле, мәгънәле сүз – кеше өчен бер бүләк ул. Сүзләр аша җиткерелгән гыйбрәтле хәлләр – тормыш дәреслеге дә. Кабул итеп ал да күңеленә сеңдер, куллан. Әлеге җыентыкны «Дөнья сүзе – бер бүләк» дип атавым да юкка түгел. Дөнья сүзе – тормыш тәжрибәсе туплаган, акны карадан аеру яшенә җиткән картлар сүзе ул! Ташка баскан сүз – китап сүзе – киләчәк буыннар өчен дә бер бүләк!

Китап һәм аудиоязмаларымны укып, тыңлап, аз булса да уңай мәгълүмат, белем һәм тәрбия, гыйбрәт алсагыз, диңгездән бер тамчы дәрәҗәсендә булса да кешеләргә ярдәмем тиде бит, дип әйтә алыр идем, хөрмәтле укучыларым, тыңлаучыларым!

Автор

Туган телебез – татар теле!

Мөслим төбәге гүзәл табигате, ачык күңелле, бердәм, тырыш, хезмәт сөючән, талантлы халкы һәм үзенә генә хас гореф-гадәтләре, тарихы белән данлыклы.

Мөслим республикабызда татарлар иң күп яшәүче районнарның берсе булып тора. Татар телендә матур сөйләшүче, җор телле халык яши бездә! Сүз эзләп кеше кесәсенә керми мөслимлеләр!

Соңгы берничә елда Татарстан Язучылар берлеге, республикабызда яшәп иҗат итүче шагыйрьләр, язучылар Мөслимне үз итте. Юкка түгел, чөнки Мөслим – татар халкының милли хәзинәсен тәшкил иткән атаклы шәхесләрне, шагыйрьләрне һәм язучыларны биргән төбәк.

Һәр халык үз телен, яратып, «Ана теле» дип атый. Ана теле һәрвакыт беренче урында торырга тиеш, аның аша дөньяга, аңбелемгә юл ачыла.

Без, мөслимлеләр, яшь буынны гаиләдән, балалар бакчасыннан башлап туган телне яратырга, кадерен белергә, сакларга һәм үстерергә өйрәтәбез. Мәктәпләр, балалар бакчалары, мәктәптән тыш тәрбия үзәкләре, тел, милләт мәсьәләләренә зур игътибар биреп, күп төрле чаралар, бәйгеләр үткәрәләр.

Ел саен татар теле һәм әдәбияты буенча республика күләмендә үткәрелгән бәйгеләрдә Мөслим районы укучылары призлы урыннар алып кайталар. Хәтта башка телләрдә сөйләшүче, рус классларында белем алучы укучылар арасында да республика бәйгеләрендә җиңүчеләр шактый.

Җирле радио һәм телевидение тапшырулары татар телендә алып барыла. Районыбыз яңалыкларын, хезмәт алдынгылары, әдәбият, сәнгать, тел, әхлак турындагы тапшыруларны халык яратып карый, тыңлый.

2012 елдан башлап Мөслим радиосында лаеклы ялдагы татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлфия апа Мөхәммәтгәрәева тапшырулар алып бара. «Тел күрке – сүз» тапшырулар циклында автор туган телебезнең байлыгы, матурлыгы, аның тормышыбызда тоткан урыны, роле турында үтемле һәм образлы итеп халыкка җиткерә. Тапшыруларны район халкы гына түгел, ут-күршеләребез Азнакай, Сарман районнары халкы да яратып тыңлый. Бүген Гөлфия апаның тапшырулары «Тәртип» радиосыннан да яңгырый. Без моны

Мөслим төбәген тагын бер тапкыр бөтен Татарстанга таныту дип кабул итәбез. Гөлфия Мөхәммәтгәрәеваның тапшыру язмаларын бер җыентыкка туплап, халыкка җиткерергә уйладык. Бу язмалар мәктәпләр, анда эшләүче укытучы-тәрбиячеләр, балалар, ата-аналар өчен зур ярдәмлек, Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан райондашларыбызга бер бүләк булыр, дип уйлыйбыз.

Туган телебез – татар теле – бик бай һәм матур тел! Һәркем, кулыннан килгәнчә, телебез үсешенә өлеш кертсә, милләт тә, тел дә бетмәс! Киләчәк гасырларда да телебез саф, матур, кирәкле тел булып калсын иде!

Рамил Муллин,
Мөслим муниципаль район башлыгы

Туган тел сагында

Бөтен гомерен мәгариф эшенә багышлаган Мөслим районы, Түбән Табын урта мәктәбенең лаеклы ялдагы татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Россия Федерациясе гомумбелем бирү мәктәпләренең Мактаулы хезмәткәре, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләк иясе Гөлфия Мөхәммәтгәрәева 2011–2012 елларда җирле радио аша «Тел күрке – сүз» исемле тапшырулар сәхифәсе алып барды. Аннан соң автор аны укучылар, укытучылар һәм ата-аналарга ярдәм йөзеннән китап итеп тә чыгарды.

Берничә еллар элек Татарстан радиосы аша филология фәннәре докторы Вахит ага Хаков бик матур, эчтәлекле тапшырулар оештырган булса, шулай ук тел галиме Илдар абый Низамов төрле гәзит һәм журнал битләрендә шушы теманы яктыртып, милләтебез, туган телебез турында фәнни дә, шул ук вакытта киң катлам укучыларга аңлаешлы телдә үз фикерләре белән уртаклашкан иде. Гөлфия ханымның әйтергә теләгән фикере шул ук булса да, мәсьәләгә үзенчә якын килә. Ул татар телендә иҗат итүче төрле авторларга да, җирле халык сөйләменә дә мөрәҗәгать итә. Гөлфия ханымның күпьеллык педагогик тәжрибәсе, белеме, үз өстендә ныклап эшләгәне, башка галимнәрнең хезмәтләре белән танышлыгы ачык сизелә. Автор телебезнең байлыгы, аның төрле диалектлардан торуы һәм урта диалектка кереп, әдәби сөйләмнең үзәген тәшкил итүе турында бәян итә. Минзәлә сөйләшенең үзебез дә сизми торган төсмерләрен ул күп кенә мисалларда күрсәтеп бирә. Телебездәге кимчелекләрне фаш итә. Әдәби телдә дөрес, аңлаешлы һәм сәнгатьчә сөйләргә өйрәтә.

Гөлфия ханым гомере буе туган телебез, аның киләчәге, язмышы өчен борчылып яшәде. Ул – ихлас күңеленнән милләтпәрвәр кеше. Аның милләттәшләрен, яшь буынны туган телләрен яраткан, әдәби телдә дөрес һәм матур итеп сөйләшеп, туган телләре белән горурланып яшәүче күпкырлы шәхесләр итеп күрәсе килә. «Тел күрке – сүз» тапшыруларының дәвамы булган «Тел дигән дәрья бар» сәхифәсенең киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителүе районыбыз халкы, аның җитәкчелеге өчен бер горурлык, бәһале хезмәт.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов,
Татарстанның атказанган укытучысы, балалар шагыйре,
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

* * *

Кояш астында ятып кызган тузан-туфрактан эсселек бөркеп хәлне алган вакытта көтмәгәндә саф һава бөркүче җил исеп куя да тәнгә әл-хәл кереп китә. Шуның кебек, телебез, рухыбыз язмышы турында борчылып йөргән бер вакытта «Тәртип» радиосыннан Гөлфия Мөхәммәтгәрәева исемле ханымның ягымлы тавышы ишетелә башлады. Аның нәкъ үзебезчә гади, шул ук вакытта кайгыртучан хисләр кушып сөйләве генә түгел, нәрсә хакында гамьләнүе дә тансык иде. Гомер буе балаларга халкыбызның күңел байлыгын тапшырып яшәгән мөгаллимәбезнең белем бирү мәйданы нык киңәйде, аның нәкъ кирәк вакытта йөрәккә үткәреп әйткән сүзләре һәр тыңлаучының күңеленә барып җитә һәм урнашып кала. Ул беренче карашка билгеле нәрсәләрне дә өр-яңа яклары белән ялтыратып кую осталыгына ия. Бу инде талант дигән сүз, мөгаллимлек таланты. Күпләр кебек үк, мин дә Гөлфия ханымның сөйләвен буленмичә тыңлыйм. Бу, сүз дә юк, сөйләүченең осталыгы белән ирешелә.

Бу тавыш күп еллар яңгырап торсын иде дигән теләктә калам.

Фоат Галимуллин,
КФУ профессоры.
2 март, 2021 ел.

Әссәләмәгәләйкүм, хөрмәтле милләттәшләр!

Белгәнебезчә, 2021 ел – Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы.

2014 елдан бирле «Тәртип» радиосында чыгып килүче «Тел дигән дәрья бар» тапшырулары тупланган әлеге җыентык, милләттәшләребез өчен өстәл китабына әверелер дип ышанам. Тапшыруның авторы һәм алып баручысы – Мөслим районының лаеклы ялдагы укытучысы Гөлфия ханым Мөхәммәтгәрәева. Гөлфия ханым гасырлар буена формалашкан телебезнең бай хәзинәсен барлый һәм туган телебезгә карата сак булырга кирәклеген искәртә. «Тәртип» радиосындагы һәр тапшыруында, тел турындагы фикерләр белән берләштән, халыкчан мисаллар, әдәби әсәрләрдән өзекләр дә ишетерә тәжрибәле мөгаллимә.

«Кара әле син моны! Гап-гади бер авыл укытучысы, галимнәр авыз ачып тыңларлык тапшырулар алып бара «Тәртип» радиосында!» – дип сөйләде бер чыгышында Фоат абый Галимуллин.

Хак сүзгә җавап юк. «Тәртип» радиосының шигаре:

Үткән белән көткән арасында
Серле күпер килә саласы!
Түкми-чәчми милли хәзинәне
Чорлар аша озата барасы!

Менә шушы «серле күперне» салуда Гөлфия апа Мөхәммәтгәрәева тапшырулары төп басмаларны тәшкил итә дисәм дә дөрес булыр. Ә инде әлеге җыентыкның Мөслим районы җитәкчелеге ярдәме белән дөнья күрүе бу төбәкнең зыялылыгын раслый. Туган телебезгә, рухи кыйммәтләребезгә, гомумән, һәр кешесенә карата булган тирән ихтирам һәм хөрмәт билгесе булып та тора, дияр идем.

Тәртипле халык югалмый.
Татар тәртипсез була алмый!

Ихтирам белән,
Ризәлә Исмәгыйлева,
«Тәртип» радиосы баш мөхәррире.

I бүлек

«ТЕЛ ДИГӘН ДӘРЬЯ БАР»

(Радиотапшыру өчен материаллар)

I кисәк

1. «И газиз туган телем!»

Хәерле көн, хөрмәтле радио тыңлаучылар! **«Тел дигән дәрья бар»** тапшыруын башлыйбыз.

Тел дигән дәрья бар,
Дәрья төбендә мәрҗән бар.
Белгәннәр чумып алыр,
Белмәгәннәр карап калыр.

Тапшыруларыбызда менә шул тел дигән дәрьяның хәзинәләре, сүзнең тылсымлы көче белән якыннанрак танышырбыз, туган тел, сүз турындагы белемнәребезне баетырбыз, телебез, аның язмышы турында уйланырбыз.

«Без – татарлар, телебез татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул», – дигән татарның Ломоносовы Каюм Насыйри. «Тел ул буыннан-буынга ана сөте белән күчә килгән һәм күчәчәк иң мөкатдәс бер мирас булып, телен жуймаган милләтләрнең өстә ярылып яткан бердәнбер сыйфаты, билгеседер. Тел, ниһаять, – туган ил, туган җир ул», – ди язучы Хәсән Сарьян, образлы итеп. Мондый мисалларны бик күп китерергә мөмкин. Халкыбыз гомер-гомергә туган телгә битараф булмаган, аны хөрмәт иткән, аның бөеклегенә дан жырлаган. Туган телне зурлап, Ана теле дип атаган. Димәк, Ана – газиз, берәү генә булган кебек, Туган тел дә берәү генә була. «Туган тел ул була бер генә, туган телнең кадерен бел генә», – дип акыллы киңәшен дә бирә халык.

«Татар халык мәкальләре»нең икенче томында (Н. Исәнбәт) «Тел һәм сүз» дигән бүлек бар. Анда халкыбызның тел турында иң үткен, иң оста, иң тапкыр, иң мәгънәле мәкальләре туплан-

ган. Аларның һәркайсы үзе бер дөнья. Халык әйтсә, белеп әйтә инде ул.

Туган теленнән йөз чөерүчеләрне, маңкортларны иллә дә яратмаган инде халкыбыз.

Бер егет армия хезмәтен тутырып авылына кайткан. Бөтен кеше белән русча гына сөйләшкән була, ди. Имеш, гел урыс арасында хезмәт итә торгач, туган телен онытkан. Күрше егете белән мунчага киткәннәр болар. Күрше егет бик үткен, шаян кеше булган. Мунчага кереп, ләүкәгә утыруга, ташка бер чүмеч су җибәргән. Мунча бик эссе итеп ягылган булган. «Довольно!» – дигән тегесе. Күршесе аңламаганга салышып, тагын бер чүмеч су җибәргән ташка. «Довольно!» – ди икән тегесе. Шаян егет, башын җүләргә салып, тагын бер чүмеч суны тондырган. Мунчада чыдап булмаслык эссе икән. «Җитте, дип әйттем бит мин сиңа!» – дип кычкырып җибәргән солдат. «Күптән шулай дип әйтәләр аны, алайса «дәвүлне дә дәвүлне», – дигән ди күршесе. «Алтыда белгән Ана телең алтмышта да онытылмас», – дип, халык бик белеп әйтә.

Моннан берничә еллар элек, ТНВ каналыннан Муса Маликов турында ярты сәгатьлек тапшыру бирделәр. Муса Германиядә яши һәм укый иде ул вакытта. Немец телен өйрәнгән (Казаннан киткәненә 5–6 еллар тирәсе), рус телен камил белә. Шунысы гаҗәп: тапшыру барышында сөйләменә ник бер рус сүзен катыштырсын! Шәһәрдә туып-үскән егет бит әле ул! Шундый матур итеп саф татар телендә сөйләде ул. Киеме гади, үзе гади, сөйләме гади. Янына барып, аркаларыннан сөясем килде, хәтта. Аның урынында үзен «әллә кем» итеп тойган берәү булса, Германияләрдә укып йөргән башы белән татарча сөйләп тормаган да булыр иде, бәлкем. «Мин татар телен сагынып кайтам», – ди ул. Язучы М. Мәһдиевнең зыялы шәхесләр турында бик кызыклы фикере бар. Якынчасы болайрак: зыялы (интеллигент) кеше кимендә берничә чит тел белергә, туган телендә дөрес, матур, төзек җөмләләр белән сөйләшергә, Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбиятыннан мәгълүматлы, культуралы булырга тиеш, ди. Г. Тукайлар, Ф. Әмирханнар әнә шундый булган, ди. Муса Маликовны әнә шундый зыялы яшьләребезнең берсе, дип саныйсы килә.

Телгә искиткеч зур ихтирам тау халыкларында көчле.

Моның шулай икәненә бер мисал. Авар (Дагыстан) шагыйре Рәсүл Гамзатовның бер язмасы бар. Татарстан радиосыннан аны берничә мәртәбә диктор Камал Саттарова укуында ишеткәнем булды. Бик тә тәэсирле, мәгънәле язма. Мин аны үзем гаҗәпләнеп, сокланып тыңлаган идем. Узган гасырның алтмышынчы еллар уртасында бер төркем совет язучылары, сәнгать әһелләре Франциягә бара. Делегация составында Рәсүл Гамзатов та була. Франциядә ул үзенең якташын, милләттәшен, Франциядә зур танылу алган рәссамны очрата. Рәссам Бөек Ватан сугышы чорында пленга төшеп, Франциягә барып чыга. Шунда кала. Хәзер инде ул бай, мул тормышта яши. Француз кызына өйләнгән. Картиналары белән дәрәҗәле күргәзмәләрдә катнаша.

Туган илгә кайткач, Р. Гамзатов рәссамның туган авылын, туганнарын эзләп таба, алар белән очраша. Шундый зур, көтелмәгән хәбәрне ишетү өчен (аны һәлак булгандыр яки хәбәрсез югалган дип яшәгәннәр) барлык кардәш-ыру рәссамның туган йортына – саклясына җыела. Рәссамның әнисе дә исән булып чыга. Һәммәсе, тын да алмыйча, кунакны тыңлыйлар. Шагыйрь сөйләүдән туктагач, Ана: «Рәсүл, ул синең белән авар телендә сөйләштеме?» – дип сорый. «Юк, без тәрҗемәче аша аралаштык. Ул француз телендә сөйләште», – дип җавап бирә Р. Гамзатов. Шул вакыт Ана кара шәлен йөзенә кадәр тартып төшерә. «Бездә Аналар балаларын югалтканда шулай итәләр», – ди шагыйрь.

Бераздан Ана:

– Юк, Рәсүл, син күргән кеше минем улым булмаган. Ул күптән үлгән инде. Минем улым күкрәк сөтен имезеп үстергән газиз әнкәсенең телен онытырга тиеш түгел иде. Син ялгышкансың, – ди.

Үз туган теленнән йөз чөергән (әйе, йөз чөергән, онытмаган ул аны) баласын Ана гафу итә алмый, ул аны үзе өчен, бик авыр булса да, үлгәнгә саный.

Тел бетә, тел бетә, дип сөйләргә яратабыз. Аны кем бетерә соң? Патша заманында татар телен саклау, үстерү турында катлы-катлы законнар да чыгармаганнар, киресенчә, татар халкы изелүдә яшәгән. Ә халык иманын, телен саклаган! 1990 нчы елларда кабул ителгән «Тел турындагы» Закон, Программаны беркем дә сызып яки алып ташламады. Барысы да үзебездән

тора. Битарафлык – менә нәрсә харап итә безне. Милли үзаңы югары булган халыклар телне беренче планга куялар. Чөнки тел халыкны, милләтне берләштерүче төп корал. Дөньяда үтә милләтчел, бердәм, үзара ярдәмчел милләт бар. Алар – яһүдләр. Моннан 2000 еллар элек Рим легионерлары аларның дәүләтен җимерә. Таркалган дәүләтнең халкы дөньяның төрле ягына сибелә. Әмма алар халык, милләт буларак югалмыйлар. Бәлки, 2000 елдан соң кабат үз дәүләтләрен һәм онытыла барган борынгы яһүд телен – ивритны торгызалар, дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрәләр. Аларны берләштереп торучы көч нәрсә дисәгез – ана сөте белән сеңдерелгән тел, дин, гореф-гадәтләр һәм аларга хөрмәт, ихтирам.

Безнең туган телебез – татар теле дә бик матур, бай, аһәңле, бик борынгы бай тарихлы тел. Татар булуыбыз белән горурланыйк. «Без – татарлар», – дип башыбызны горур тотып, киләчәккә ышанычлы адымнар белән атлыйк. Тел язмышы халыкның үз кулында!

2. Сүз көче. Сүз артын сүз ачар

Сүз көчле ул, мәгънәле һәм сирәк булса,
Тыңлаучы да сүз аңлаучы зирәк булса.
С. Рәмиев.

Бүгенге тапшыруыбыз Сүз галиҗәнапләре хакында булыр. Тел сүзләрдән тора. Тел галимнәре тарафыннан сүзгә дистәләрчә билгеләмәләр бирелсә дә, аның төп үзлекләре ачыкланса да, тел белемендә кабул ителгән уртак билгеләмә юк икән әле. Беренче карашка искиткеч гади булып күренгән сүз проблемасы тел белемендә иң катлаулылардан булып кала бирә. Әмма без ул ягын тел галимнәренә калдырып торыйк та, телдә сүзнең кулланылышы, роле турында сөйләшик.

Сүзнең иң беренче чиратта мәгънәсе булырга тиеш. Халыкта мәгънәсез сүз сөйләүчегә, гомумән, игътибар бирмәгәннәр, андый кешене тыңлап та тормаганнар.

– Сүзенең атасы-анасы юк, тузга язмаганны сөйли, ни үзе, ни сүзе, – дип нәтиҗә ясаганнар андыйлар турында.

Сүзнең бизәге дә бар.

Башкорт шагыйре Йосыф Гәрәй сүз турында болай дип язган:

– Нинди генә сүзләр юк. Нәфисләре бар! Күңелсезләре. Мөлаемнары күп. Ачулылары. Хәтта, мәкерлеләре йөри телдәнтелгә.

Ачык күңелле сүзләр бик ишле. Моңлылар да аз түгел. Күңелсезләр, купшылар, шатлар, ямьсезләре дә җитәрлек.

Кайсыберләре ялтырап тора, гүя зөбәрҗәт. Икенчеләре дөм караңгы. Әйтерсең, мунча ташы.

Бер уйласаң, сүз җанлы кебек. Хәтта кеше кебек алар. Берсе ачык йөзле, берсе шыксыз чырайлы. Төрле төс ала сүз. Ачу белән әйтелсә, «зифа» да зифа түгел. Елмаеп туса, «юньсез» дә күркәм. Калын тавышлы «нәләт» каргыш икән, шаян «дөмеккере» дә «яшә»гә тиң.

Сөйләмдә, җөмләдә һәр сүзнең үз урыны булырга тиеш. Язучы Ф. Хөснинең «Урынындамы сүзләр – солдатлар?» дигән язмасы бар. Әйе, язучы сүзләрне солдатлар белән чагыштыра. Һәр солдат үз урынында икән, тәртип тә була. Сүз белән дә нәкъ шулай. «О, бик зур һәм кодрәтле нәрсә ул – сүз. Әлбәттә, нәкъ үз урынын табып, үз төсмерләрен салып әйткәндә», – ди Ф. Хөсни әлеге мәкаләсендә.

Берничә сүзгә тукталып алырбыз.

Татар телендә **матур** сүзенең 20дән артык синонимик вариантын табарга була: гүзәл, чибәр, күркәм, күрекле, ямьле, нәфис, зифа, сылу, күңелле, коеп куйган кургашын, күзнең явын алырлык, су сөлегеге кебек, урта бармак шикелле һ.б. Әмма сөйләмдә һәрберсенең үз урыны бар. Матурлык мәгънәсен белдерү өчен кайсын куллансаң да ярый түгел. Мәсәлән, **гүзәл** сүзен алыйк. Язучы Г. Бәширов «Гүзәл фәкать үз урынында гына гүзәл» дигән язмасында болай ди: «Матур синонимының бер варианты ул. Әмма ул гади матурлыкны гына белдерми. Гүзәл үз иптәшләренә караганда берникадәр аристократрак табигатьле, нәзберегрәк холыклы булу сәбәпле, ул матурлыкның иң югары дәрәҗәсе, иң нечкәсе, иң нәфисе, иң камиле белән генә эш итә. Гүзәл машина, гүзәл урман, гүзәл йорт һ.б. дип әйтү мөмкин түгел. Әгәр инде бу сүз кешенең төс-битенә карата кулланыла икән, ул кеше чиктән тыш матур, тиңсез, соклангыч матур булырга тиеш.

Гүзәлсең син, матурсың син, матурсың,
Матурларның-матурыннан матурсың, –

ди Г. Тукай.

Күрәсез, Г. Тукай да башта ук гүзәлсең, дип раслап куя. Аннан соң инде ул төшенчәне тагын да көчәйтә төшә, шул бер уңайдан аңлатып та бирә: гүзәл дигәнең «матурларның-матурыннан да матуррак икән».

Ямьле сүзе дә матурның бер варианты. Без, гадәттә, бу сүзне көн сүзе белән бәйләп кулланабыз: ямьле көн, көне бигрәк ямьле. Ләкин өйләре, бакчалары, ишек аллары ямьле дип тә әйтәбез (әмма ямьле кыз, ямьле егет түгел). ТНВ каналыннан **«Халкым минем»** тапшыруын бик яратып карыйм. Татарстаннан читтә яшәүче татарлар тормышын күбрәк яктырталар бу тапшыруда. Аеруча Чувашстанның Батыр һәм Комсомол районнарында яшәүче татарларга күбрәк тукталалар. Яшәп тә карый соң мондагы «мишәр агайлар» дип куям кайчагында. Тапшыру азагында, уңган-булган яшь киленнәр үзләренең бер «фирменный» ризыкларын тәкъдим итәләр. Менә шулар телендә **ямьле** сүзе ризык әзерләгәндә, аны бизәгәндә (аеруча камыр ризыклары) еш кулланыла. – Менә шулай итсәң, ямьлерәк була. – Ямьлерәк булсын өчен менә шулай итәргә кирәк. – Менә бит, ямьле генә килеп чыкты.

Кеше тормышында аеруча роль уйнаган төшенчәләрнең синонимнары, ягъни мәгънәдәш төрләре күбрәк була икән. Мәсәлән, **яшәү** сүзенең якынча 17 төрле варианты бар. Халкыбыз яшәү мәгънәсен әнә нинди матур сүзләр белән җиткерә белә: тору, гомер итү, көн итү, тормыш итү, тормыш көтү, тормыш кору, тереклек итү, дөнья куу һ.б. Һәр сүзендә тормыш итүнең нигезендә бары тик тырыш хезмәт ятканын аңлата кебек.

Бик матур яңгырамаса да, **үлү** сүзенә дә тукталыйк. Нишлисең, яшәү бар, үлем бар! Бу сүзнең 60ка якын варианты бар икән: бетү, сүнү, китү, өзелү, күчү, теге дөньяга китү һ.б.

Вафат булу белән **һәлак булу** дигән вариант та бар. Болар икесе ике очракта кулланыла.

Урын өстендә ятып авырып яки кинәт үлгән кешене вафат булды, диләр. Ә сугыш кырында, я нинди дә булса фаҗигагә юлыгып үлүчеләрне һәлак булды дип әйтү дөресрәк.

Әче телле кешеләр була. Болар синең белән вакланып

тормыйлар. Үлү сүзе урынына **катты, чукынды, дөмекте, тончыкты, кәкрәйде, кадалды, чукынып катты кебек** энәле-чәнечкеле сүзләрне сибәләр генә. Үлем – болай да иң ачы хәсрәт. Үлгән кеше кире кайтмый. Нигә аның артыннан шундый ямьсез, шыксыз сүзләр әйтеп калырга инде. Үзең дә бу дөньяга мәңгегә килмәгәнсең бит! Синең артыңнан да шул сүзне әйтмәсләр дисеңме?

Үлем белән бәйле тагын бер сүз.

Бер ир кеше сөйли: «Кайгылы чагым. Әни үлде, шуны **күмеп килдек».**

Язучы Рабит Батулла бер язмасында бу сүзгә тукталып, болай дигән иде: «Иң дөресе – **җирләү** булырга тиеш. Чокырны күмәләр, хайван үләксәсен күмәләр, ә кешене җирлиләр, җир куенына тапшыралар, җир куенына иңдерәләр. Адәм туфрактан яратылган, туфрак булырга тиеш».

Ярар, яшәү һәм үлем мәсьәләсен читкәрәк куеп, тагын берничә сүзгә күчик.

Алдарак, гүзәл сүзенә тукталган идек. Аристократ табигатьле сүз дип бәяләдек. Шундый сүзләрнең тагын берсе – **былбыл.** Бу сүз сандугач сүзенең синонимы. Сандугач – җырчы кош, гашыйклар кошы. Сандугач исеме кергән йөзләрчә җыр-такмаклар иҗат иткән халкыбыз. Халыкчан вариант дип атарга да була. Былбыл шагыйрьләр телендә активрак кулланыла, асыл кош дәрәҗәсенә күтәрелә. Былбыл атамасы аеруча Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбиятында еш очрый. Былбыл сүзе төрки халыклар, мәсәлән, әзәрбайҗан телендә **бюль-бюль (җырчы Палад Бюль-Бюль оглы)** булып яңгырый.

Р. Батулла **пешекче (повар)** сүзенең дә урынлы кулланылмавын әйткән иде. Пешекче нәрсәне дә булса пешекләүче мәгънәсенә ия. Тавык, үрдәк, казны пешеклиләр. Суйган малның телен, түбәтәен, кырык картасын, итек басучылар казанга салып итек пешеклиләр һ.б. Язучы бу сүз урынына **ашчы (**аш-су әзерләүче) сүзен тәкъдим итә. Н. Фәттах, Р. Батулла да тарихи әсәрләрендә бу сүзнең нәкъ шушы вариантын кулланалар.

«Туңгак алыпны ул (Туман каган) аучыларны юлга әзерләргә дип чыгарып җибәрде, ашчыларга иртәнге ашны тизрәк өлгертергә кушты». *(Н. Фәттах. «Сызгыра торган уклар»).*

Борынгы заманда бу сүзнең **бавырчы** варианты да кул-

ланылган. Күчмә тормыш белән яшәгән, аучылык белән шөгыльләнгән төркиләрдә малны сую белән иң әүвәл бавырын пешергәннәр. Бавыр пешерүне теләсә кемгә тапшырмаганнар. Бавыр пешерүче осталарны бавырчылар, дип йөрткәннәр. Тора-бара бу сүз ашчы мәгънәсендә кулланыла башлаган. Шул ук Р. Батулла үзенең «Сөембикә» романында бавырчы вариантын куллана. «Сөембикә барысын да алдан ук әзерләткән булып чыкты. Аръякка чыккач, ханга да, ханбикәгә дә, ахирәтләр белән җансакчылар, бавырчылар, җылкычыларга да аерым-аерым тирмәләр корып, хәйран гына зур бер авыл хасил иттеләр».

Мондый сүзләрне мисалга бик күпләп китерергә булыр иде.

Ул сүзләрне кая куясың, дип,
Сорасагыз миннән әгәр дә, –
Үз тәхетен эзлим һәрбер сүзгә
Язылачак яңа шигырьдә.

Шагыйрь М. Галиев әйткәнчә, һәр сүз үз тәхетендә булсын иде. Шулай булганда, телебез тагын да матуррак, баерак, аһәңлерәк яңгырар иде.

3. Сүзләрнең дә тарихы бар...

Тел белеменең этимология дигән тармагы бар. Сүзгә-сүз тәрҗемә иткәндә, ул «чынын өйрәнү», ягъни сүзнең тарихын, килеп чыгышын өйрәнү дигәнне аңлата. Ни өчен теге я бу предмет шулай аталган? Этимология үз алдына шундый сорауны куя.

Этимология – гаҗәеп бер дөнья ул. Аның эченә кереп китсәң, белер-белмәс башың белән тарих төпкеленә төшеп адашуың да мөмкин. Моның өчен телдәге тамырдаш сүзләрне җыеп бетерергә кирәк. Әдәби телдәге сүзләр генә җитми, диалектларны (җирле сөйләм) белү зарур. Халыкның мифологиясе, этнографиясе, рухи һәм мораль культурасы белән дә якыннан таныш булу таләп ителә. Сүз тарихы кардәш телләрдәге охшашлыкларга нигезләнеп тә өйрәнелә. Бу тармак турында тел галимнәре әнә шул фикердә. Киңкырлы эшчәнлек таләп ителгәнгә күрә, тел гыйлеменең бу тармагы белән шөгыльләнүчеләр әллә ни күп түгел.

«Сүз тарихын ачу җиңел түгел, билгеле. Шулай да ул бик мавыктыргыч шөгыль, үзе бер дөнья. Кайчагында беренче карашка бөтенләй мәгънәсез булып күренгән сүзләрнең дә гаять тирән мәгънәсе ачыла», – ди тел галимәсе Ф.С. Сафиуллина.

Этимологлар сүз тарихын эзләп ерак гасырларга сәяхәт итәләр. Без көн саен куллана торган, чып-чын татар сүзе дип инанган бик күп сүзләрнең берничә гасырлык тарихы бар икән. Үз гомерләрендә байтак үзгәрешләр кичереп, телебезгә яраклашып, бүгенге көндә актив кулланылышта йөргән бу сүзләрнең «аксакал сүзләр» булуына ышанасы да килми.

Татар теле – бик борынгы телләрнең берсе. Аның тамырлары көнчыгыш төркиләр (сөн, һуннар), шулай ук скиф-сармат кабиләләренә дә барып тоташа. Татар телендә кулланыла торган байтак сүзләрнең Көньяк Америкада яшәгән майа, инк, ацтеклар телендә очравы да гаҗәп түгелмени! Язучы Н. Фәттах әйткәндәй, телдәге курганнар, археологик катламнарының ачылуын көтә әле.

Берничә сүзнең килеп чыгышына тукталып китик. Мәсәлән, безгә бик якын булган авыл сүзе. Авыл – рус теле аша күп телләргә таралган татар-кыпчак сүзе. Борынгы төркиләр телендә «агыл» – киртәләп алынган урын, кура, табыр сүзеннән. Аг, аң – тамырыннан. Ә бу тамыр «ачык һавада мал-туарны туплап тоту өчен ясалган кура» дигәнне аңлаткан.

Үзебезнең төбәккә кагылышлы берничә атамага тукталып китик. Мәсәлән, Мөслим сүзе. Мөслим исемле авыллар берничә. Чистай районында да бар Мөслим авылы. Чиләбе өлкәсенә урнашкан Мөслим авылы бөтен илгә, дөньяга билгеле булды!

Мөслим – гарәпчәдән «мөселман динендәге ир кеше, мөселман» дигәнне аңлата (итагатьле, әдәпле, тәрбияле, буйсынучан дигән мәгънәдә). Ислам дине белән килеп кергән сүз. Риваятьләргә караганда, Мөслимебезгә нигез салучы Мөслим исемле кеше булган. Бу гаҗәп түгел: гадәттә авыл исемен авылга беренче нигез салган кеше яисә аның кушаматы, я шул тирәдәге табигатькә мөнәсәбәтле исемнәр белән атаганнар.

Мөслимгә терәлеп диярлек Ык елгасы ага. Башкортстанның Бәләбәй төбәгендәге калкулыклардан башланган бу елганың озынлыгы – 598 км. Шуның 48 километры Мөслим районына туры килә. Ык елгасының атамасына килгәндә, берничә караш

яши. Ык елгасы урманнар арасыннан, тауларга ышыкланып ага. Шуңа күрә беренче исеме Ышык булган, ди. Әкренләп, авазлар кыскару нәтиҗәсендә, Ык булып калган. Ык үзе турыдан-туры елга мәгънәсен белдерә дигән караш та бар. Тел галиме Ф.С. Сафиуллина Җаек (елга һәм шәһәр исеме) сүзенә биргән аңлатмасында җай, зәй, сай сүзләренең елга мәгънәсенә ия икәнлеген әйтә. «Халыкта, җайның күрке яр булыр, ярның күрке тел булыр, дигән мәкаль бар. Җай – елга икән. Җай+ык дигәндә елга+елга төзелеше күзәтелә», – ди ул.

Чынаяк, кашаяк сүзләре бар. Икесендә дә аяк дигән уртак кисәк бар. Бу сүз борынгы төрки, монгол, тунгус телләрендә булган. Савыт, касә, кечкенә табак мәгънәсендә йөри. Чынаяктагы чын сүзе – кытай сүзенең синонимы. Кытайларны чин дип, Кытай илен Чин иле дип тә атыйлар. Фарфорны уйлап табучылар кытайлар бит. Димәк, чынаяк – кытай савыты дигән сүз икән. Кашык аяк – кашык савыт була.

Узган гасырның 90 нчы елларында күп кенә атамаларның татарча вариантларын куллану модага кереп китте. Мәсәлән, татарча булсын диптер инде, магазин сүзе урынына кибет дип сөйләү, язуны мисалга алыйк. Магазин – үзе дә гарәп сүзе, амбар, склад сүзләренең күплек санын белдерә. Шунысы кызык: бу сүз безгә рус теле аша кергән. Кибет – борынгы татар телендә «кәбит, кәбәт», ягъни «йөреп сатучының көймәле арбасы (шуннан русларның «кибитка» – көймәле чана, тәрәзәсез өй сүзе). Бу сүз гарәпләрдә күббәт – үн – чатыр, палатка мәгънәсен аңлата икән. Чуваш телендә – кипет, типет; удмуртларда – кебит («тимерче алачыгы, лавка» мәгънәсендә).

Удмурт дигәннән, пилмән сүзе дә безгә удмуртлардан кергән. Удмурт телендә пель – колак, мән – икмәк төшенчәсен белдерә икән. Димәк, пилмән – колаклы икмәк була.

Кузгалак – кузы колак кушылмасыннан тора. Кузы – бәрән, ягъни бәрән колагына охшаган үсемлек икән.

Челпәрәмә сүзе фарсы телендәге чаһел парә – кырык кисәк дигән сүздән үзгәртеп ясалган.

Дәрес сүзе, мәсәлән, чабагач белән сугар өчен җәелгән ашлык җәемен (гарәпчә дәрәсә «җәю» тамырыннан) белдергән. Тәнәфес гарәпчәдән нибары «тын алу, сулыш» дигән сүз. («Нәфәсә» – сулыш алу). Гадәттә бер җәем ашлыкны сугып бетергәч,

бераз ял итәләр, сулыш алалар. Шуның шикелле, гарәп мәктәпләрендә бераз «ашлык сугып – укып алгач, тәнәфес – сулыш алу ясаганнар. Шаяртып әйтелгән дәрес (ашлык сугу – уку) һәм тәнәфес (сулыш алу – дәрес алмаштыру) сүзләре тирә-якка бик җитди терминнарга әверелгәннәр. Дөрестән дә, дәрес, уку – ашлык сугуга тиң, бик күп көч, энергия таләп итә.

Мондый мисалларны бик күпләп китерергә булыр иде. Әмма... Беренчедән, безнең вакытыбыз чикләнгән. Икенчедән, тыңлаучыларны ялыктырасы килми. Сүзләр тарихы белән кызыксынучыларга Рифкать Әхмәтҗановның Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге» (2001) дигән китабын тәкъдим итәм. Бу хезмәт татар теленең төп сүзлек фондын этимологик яктан яктыртуның беренче тәҗрибәсе булып тора. Әлеге китап белән танышканнан соң, чынлап та, этимологиянең үзе бер дөнья булуына ышанасың.

4. Дөрес сөйлибезме?

Кайбер радио һәм телевидение дикторларының, яшь артистларның, җырчыларның кирәкмәгән, тиешле-тиешсез урында «х» авазын авыз тутырып әйтүләрен ишеткәч, колакка мамык тыгып куярдай булам мин. Мәсәлән. дикторлар сөйләмендә **хәм, хава торышы, хәрвакыт, шәхәр, хәйкәл, әхәмият, мөхим, хәлак, хәлакәт** сүзләре аеруча еш кулланыла. Һәм, һава торышы, һәрвакыт, шәһәр, һәйкәл, әһәмият, мөһим, һәлак, һәлакәт бит дөресе һәм ничек нәфис, колакка ятышлы яңгырый. Һ авазы урынына х кулланып, телебезне чын-чынлап «хәлак итәбез», «хәлакәткә» юлыктырабыз бит.

Радио-телевидение «хам»лап торгангадыр инде, авыл балалары арасында да (теле русча ачылган яки рус классында белем алган шәһәр балалары турында әйтеп торасы да юк) бу авазларны дөрес кулланмаучылар арта бара. Язма эшләрдә дә иң күп хаталар х, һ авазы кергән сүзләрдә ясала.

Әдәбият, радио-телевидение, театр, матбугат – тел культурасын тәрбияләүчеләр алар. Әдәби тел үрнәкләрен алар бирергә тиеш. Ә бит әдәби, дөрес сөйләм авазларны дөрес әйтүдән башлана. Татар теле бик тә аһәңле тел бит ул! Авазларны дөрес

әйтмичә, телебезнең яңгырашына, сафлыгына, моңына никадәр зыян салабыз.

Азмы-күпме фонетика белән таныш кешеләр белә булыр: татар телендә «в» тартык авазы (ирен – теш) юк. Без аны рус теленнән һәм рус теле аша кергән сүзләрдә генә очратабыз: вагон, ваза, вертолёт, велосипед, телевизор, врач һ.б. Татар теленә «уау» авазы хас. Әмма ни гажәп: бик күпләр «уау» авазын кулланууны культурасызлык, «авыллык» (үзләре авылдан чыккан «агач культурныйлар») билгесе дип саный. Awыл сүзен авыл, wакыт сүзен вакыт, Wәлиев сүзен Вәлиев дип әйтү культурасызлык кына түгел, наданлык билгесе дә.

Шулай ук сөйләмдә **н**, **ң** авазларын дөрес кулланмау очраклары да күзәтелә: миңга, сиңга, минең (минем), анарга, аңгар. Сиңәргә әйттем дигәнне ишеткәч, артыма авып китә яздым хәтта.

Соңгы елларда сөйләмдә, радио-телевидениедә, матбугат битләрендә, хәтта, әдәби әсәрләрдә кайбер сүзләрне, мәгънәләренә игътибар итеп тормыйча, кайсы да ярар, дигән кебек куллану активлаша бара. Мәсәлән, ошый – охшый, әзер – хәзер, шаһит – шәһит, мәхәббәт – мәһабәт, мәкаль – мәкалә һ.б. Ә бит бу сүзләр бер-берсеннән аваз составлары ягыннан гына түгел, мәгънәләре белән дә бик нык аерылалар. Мондый сүзләрне мәгънә аермалыгын белүнең иң җайлы ысулы – русчага тәрҗемә итү. Мин укучыларыма шул алымны тәкъдим итә идем. Ошый – нравится, охшый – похож, әзер – готов, хәзер – сейчас, мәхәббәт – любовь, мәһабәт – великолепный, мәкаль – пословица, мәкалә – статья, шаһит – свидетель, шәһит – бу сүзнең мәгънәсе – Аллаһ юлында үзен корбан иткән, ислам дине өчен корбан булган, шул юлда һәлак булган; динен, илен яклап сугыш кырында һәлак булган, хак эш өчен сугышып үлгән яки гаепсез корбан булган кеше. Рус теленә турыдантуры тәрҗемәсе юк. Шахиды, – дип әйтәләр.

– Миңа ул язучының ижаты *охшый*. Кызның керфекләре ромашка тажларына *ошаган*. Авыл уртасындагы мәхәббәт мәчет тирә-юньгә нур чәчеп утыра. Сезгә тигез *мәһабәт* телим. Мин бер *мәкалә* әйтәм, кебек җөмләләрне укыгыз да нәтиҗә ясап карагыз инде.

Радиодан «Сабырлык» мөнәҗәтен әйтәләр:

Сабыр иткән бәндәләрне
Шахитлардан киткән, диләр.
Яки, Кол Шәриф, Кол Шәриф
Шахит китте яклап Казанны, –

дип җырлый берсе. Үзенең шәкертләре белән бергә, кулына кылыч тотып, урыс баскынчыларыннан туган шәһәрен саклап һәлак булган атаклы Сәетебез, Казанны яклап Мәскәүгә свидетель булып киткән буламыни инде?! Моның ише җырларны ишеткәннән соң, «Чүлнең ак кояшы» («Белое солнце пустыни») дигән мәшһүр фильм герое Верещагин әйтмешли, «за державу обидно!»

Тел байлыгы – халыкта. Халык теленә игътибар итик. Әдәби әсәрләрне күбрәк укысын иде балаларыбыз, яшьләребез. Соңгы елларда телевизор, компьютерлар ала аларның алтындай вакытын. Җанлы сүзне алыштыра аламы соң алар? Тукайлар, Әмирханнар, Дәрдемәндләр, Ибраһимовларның, Мәһдиевләрнең әсәрләрендә әдәби телнең, халык сөйләменең энциклопедиясе тупланган. Тукай әйткәнчә, «...эчем пошса, ...рухым төшсә»:

Шул вакытта мин кулыма китап алам,
Аның изге сәхифәләрен актарам.
Рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем,
Шуннан гына дәртләремә дәрман табам.

5–6. Җырның һәм сүзнең «ертыгы» буламы? «Ертык» сүзләр һәм «ертык» җырлар

Радиодан, телевизордан нинди генә җырлар агылмый көн дәвамында. И. Шакиров әйткәндәй, җырлаучылар күп, җырчылары гына бармак белән генә санарлык. Җырларны тыңлаганда, ничек ятлап бетерәләр микән бу сүзләрне, дигән иронияле сораулар да килә башка. Чөнки күпчелек җырларның башыннан азагына кадәр 5–6 сүздән торган тезмә кабатлана да кабатлана.

Элек (һаман да шул СССР заманында инде) халыкка чыгарганчы, һәр җырны, шигырьне, спектакльне, концерт программаларын энәсеннән җебенә кадәр тикшерә торган худсоветлар булган. Әдәби әсәрләр (хикәя, повесть, романнар) ничә цензор кулыннан үткән! Аның урынына халыкка әдәбият, сәнгать әсәрләренең иң-иңнәре генә җиткерелгән.

Хәзерге җырларның бөтенесе дә бер баудан ишелгән, дип әйтәсем килми. Әлбәттә, сүзе дә, көе дә, башкаручысы да тәңгәл килгән җырлар да шактый. Андый җырларны тыңлаган саен, тыңлыйсы гына килә. Ләкин сүзе белән колакны ерта торганнары да җитәрлек. Ә сүз бик зур роль уйный бит телдә!

Шәһәрдә туып-үскән, телләре күбесенең ярымтатарча, ярымрусча ачылган җырчылар (хәзер күбрәк сәхнәдә шулар) сүзгә артык әһәмият бирмиләр, көйне беренче планга куялар. Х, һ, ң, м, в, уау авазларын бөтенләй диярлек санламыйлар. Минен (минем), миңәргә (миңа), синен (синең), сина (сиңа), хава, авыл, гәм (гамь), нәк (нәкъ) дип сибәләр генә.

Сүзләрне сайлап кына, һәр сүзнең тәмен белеп язган язучы **М. Мәһдиев**нең **«Торналар төшкән җирдә»** повестеннән бер өзек:

«Ул арада радиодан концерт башланды.

Артистлар, дикторлар авыл йортларында үзләрен күпме тикшергәннәрен, күпме бәягә дучар булганнарын беләләрме икән? Мин гажәпләнеп тыңлап утырам: Энҗе белән Флүдә ике уйларга бер дә шик калдырмый торган «билгеләрне» чәпәп кенә баралар.

Флүдә. Менә тыңлагыз, Ренат Ибраһимов җырлый. Иллә дә чибәр, мөлаем ир инде. Мин шул кешегә гашыйк. Хәтта Ильясым да көнләшми, мине аңлый. Ходаем, тагын «Төсле җыр» икән. «Мәһабәт (мәхәббәт диясе урынга) шатлыктан тора ул!» – дип, яшел тавыш белән кычкырып харап итә инде үзен. Нинди зур талант!

Һәм Ренат нәкъ шул вакытта шулай кычкырып алды».

М. Мәһдиевтән тагын бер өзек:

«Радиодан Һ. Такташның «Урман кызы» җыры яңгырый:

Нигә, нигә синең шаян күзләр
Күзләремә болай багалар?
Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
Керфек очларыңнан тамалар?

Җырчы иптәш, Такташ абыең тамалар дими бит, агалар, ди. Тамалар дип язса, Такташ булмый инде ул!»

Шулай итеп, җырларның сүзләрен алыштырып җырлау да берни тормый җырчыларга!

Менә тагын берсе җырлый:

Кайдан килдегез безгә?
Батмаенча диңгезгә.
Менә икенчесе:
Әйдә, әйдә.
Кайда, кайда?
Әйдә барыйк урманга.

Ә И. Шакиров бу җырны болай дип җырлый: («Әйдә барыйк урманга» җыры).

Әйдә, әйдә.
Кая, кая?
Әйдә барыйк урманга.

Татар телендә юнәлеш килеш дигән килеш бар. Ул килешнең сораулары – кемгә? нәрсәгә? кая? Менә бу җырларда **кая?** сүзен куллану дөрес, чөнки юнәлеш мәгънәсе ята бу сүздә.

– Бер терлекче агай печән төяп фермага бара икән. Үзе йөк өстендә.

Каршысына бер егет очраган.

– Кайда барасың, Шәрифулла агай? – дигән.

– Йөк өстендә барам бит, күрмисеңмени! – дигән агай.

– Юк, син мине дөрес аңламадың. Кай тарафка юл тоттың, диюем иде, – дигән егет.

– Мин дөрес аңладым-аңлавын, син дөрес әйтмәдең. Менә хәзер җавап бирәм инде: фермага барам, – дигән дүрт класс тәмамлаган авыл агае.

Дүрт класс белеме булган авыл агае кадәр дә татар телендәге килешләрне куллана белмәгән башың белән ни дип сәхнәгә, бөтен галәмгә ишетерлек итеп радио-телевидениегә чыгарга инде!

Җырларда киләчәк заман хикәя фигыльләрнең дә башын әйләндерәләр. «Эссе» төркеме җырлый:

Киттек авылга,
Тынычлык **табырга.**

Үлергә, көлергә, сүнергә һ.б. шундый фигыльләрне дөрес куллану кагыйдәләренә бер-ике тапкыр күз төшерсәләр, алай итеп җырламаслар иде, бәлкем.

«Болар сиңа нигә кирәк соң? Худсовет члены булдыңмы әллә?» – дип, ризасызлык белдерүчеләр дә булыр. Бөек шагыйребез Г. Тукай әйткәнчә: «Җырлар – халкыбыз күңеленең

тутыкмас саф вә раушан көзгеседер». Шундый саф, якты көзгебезне тутыктырмыйк әле. Бүгенге көннәрдә радиодан иң еш яңгыраучы жанр – җырлар. Җыр конкурслары да, Аллага шөкер, үткәрелеп кенә тора. Радиога, сәхнәгә чыккансың икән, син инде, җырчы иптәш, бөек Туган телнең илчесе. Ә илчегә бик зур җаваплылык йөкләнә. Шулай булгач, Туган телеңнең дәрәҗәсен төшермә! Авыл сәхнәсендә җырлыйсыңмы, районныкындамы, әллә шәһәрнекендәме – моңың белән бергә һәр авазың, һәр сүзең тыңлаучы күңеленә үтеп керсен.

Инде «ертык сүзләр» турында да берничә сүз. 90 нчы елларда телебезгә без архаизмнар (иске сүзләр) дип атарга күнеккән сүзләр әйләнеп кайта башлады. Инкыйлаб, иттифак, җөмһүрият, икътисад, сәнәгать, мәдәният, мөхәррир, рәис, сәркатиб, корылтай, шигарь, тәгъбир, ижтиһад һ.б. сүзләр. Белеп һәм белмичә кулланучылар да шактый бу сүзләрне. Сәнгать белән сәнәгать (промышленность) сүзләрен бутап сөйләделәр һәм яздылар бер-ара. Шундый мәзәк тә йөрде әле. Имеш, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап авылга агроном булып килгән шәһәр егете сөйләмем татарча булсын дип, арттырыбрак җибәрә.

– Югары басуга бодай, Аралык басуга борчак мәдәнияте (культурасы диясе урынга) чәчтек, – дип отчет бирә.

Татар теле укытучысы буларак, аеруча соңгы егерме елда балалар, укучылар сөйләмендә «шаккатризм»нар барлыкка килүгә игътибар иттем. Фигыльнең юклык формасын кулланууда шактый «ачышлар» ясалды: укымасмын, бармасмын, әйтмәсмен, килмәсмен, хәтта укымармын, әйтмәрмен дигән вариант та бар. Нәмәчек (ничек) дигән сорау алмашлыгы да барлыкка килде. «Байый» телебез!

Матбугатта, радиода: «Фәлән районда яки шәһәрдә картлар йорты, балалар йорты ачу тантанасы булды», – дип сөйләүләр ишетелә. Бу тантаналы вакыйгамы инде!

Телдә «Вакыт күпме?», «Вакыт ничә?» дигән сорау җөмлә дә еш ишетелә. Вакытны беләсе килгәндә, сәгать ничә, дип сорау дөрес. Кайбер кеше болай дип сорасаң, әллә чын, әллә юри, Хәсән Сарьян әйтмешли, идиотларча, сәгатем бер генә, дип җавап бирә. «Вакытны бер, ике, өч дип санамыйлар, аннан соң вакыт ул бик күп – чиксез. «Биш вакыт унбиш минут», димиләр, ә «биш сәгать унбиш минут», диләр. «Алай да

була – булмасын» мәкаләсендә Х. Сарьян байтак «ертык» (ул аларны мәгънәсе бозык сүзләр дип атый) сүзләргә туктала. Шулардан берничәсе:

– Әдәби әсәрләребездә хәзер бик әдәпле егетләребез күренә башлады: сөйгән кызларының **кулын сорыйлар**. Әйтсәм – әйтим инде: элеккеләр яучы җибәреп кызның үзен сорагаккан.

– Янә **шигырьне уку бар, сөйләү бар**: карап укыса – укый була, яттан сөйләсә – сөйли була. Әмма бу ара шагыйрьләребез, ни сәбәптер, халык алдына чыкты исә, «Мин сезгә хәзер берничә шигырь укыйм», дияр дә, ике кулын селти-селти, яттан шигырь сөйләп җиппәрер.

Вакыт чыкты түгел, вакыт бетте; радиолардан яңгырый торган **аязучан болыт**, **алмашынучан болыт** та дөрес түгел – болыт алмашынмый, болыт аязмый.

– **Республика юлларында яңгыр ява, –** дип әйтә башладылар. Анысы тагын нинди яңгыр икән – юлга гына ява торган?..

Мондый мисаллар телебездә тулып ята. Юри генә, әгәр вакытыгыз булса, шундый сүзләрне теркәп, язып барып карагыз әле.

Чыгышымны Х. Сарьянның югарыда телгә алынган мәкаләсендәге өзек белән тәмамлыйм: «Табигать безгә күрергә күз, ишетергә колак, сөйләргә тел биргән. Болар һәркемнең яшәвен якты, моңлы, җырлы иткән өч гүзәл шәйдер. Тел – бер, ә без меңнәр! Шуңа күрә без аны меңебез мең яктан бозмыйк. Киресенчә, меңебез мең яктан үстерик, баетыйк!»

7. Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып...

(Татар телендә алынмалар һәм варваризмнар)

Безнең туган телебез – бай, яңгыравыклы, моңлы, аһәңле, борынгы тел. Моның шулай икәнен белү өчен тарихка, сүзлекләребезгә күз салу да җитә. 1958–64 нче елларда мәктәп укучылары, студентлар, укытучылар, телгә мәхәббәте, кызыксынуы зур булган аерым кешеләр ярдәме белән, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының тел секторында миллионлап, **игътибар итегез миллионлап,** сүздән тор-

ган картотека төзелә. Күңелгә үзеннән-үзе, **«әллә кем түгел без, әмма ким түгел без әллә кем булганнардан»**, дигән җыр юллары килә. Шулай итеп «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н төзү эше башлана һәм ул 1970 елга әзерләнеп бетә. Сүзлекнең беренче томы – 1977 елда, икенче томы – 1979 елда, өченче томы 1981 елда басылып чыга. Меңләгән сүзне үзенә туплаган бу өч томлы сүзлек – хәзинәбезне халыкка җиткерүче, телебезнең байлыгын дәлилләүче зур хезмәт.

Әмма бер генә халык та аерым, үзе генә яши алмаган кебек, бер генә тел дә үз байлыгы белән генә яши алмый. Телиме халык, теләмиме – үзе аралашып яшәгән халыклар, күршеләре белән тел, сүз, гадәт вә әхлак алмашып яши һәм яшәячәк. Татар халкы да шулай эшләгән.

Хәзерге татар әдәби теленең сүзлек составы бик борынгы чорга – төрки халыкларның барысы өчен дә уртак булган төрки телгә барып тоташа. Идел буена күченеп килгән бабаларыбыз алга таба фин-угор халыклары, урыслар белән аралашып яшәгән. Ислам дине кабул иткәннән соң, телебезгә бик күп гарәп-фарсы алынмалары үтеп кергән. Рус теле аша һинд-европа сүзләре килеп кергән. Татар телендә үзенең күплеге, кулланылыш ешлыгы ягыннан гарәп-фарсы һәм рус алынмалары аерылып тора.

Алынмалар телебездә ныклап урнашып калганнар, татарлашканнар, яңа сүзләр ясау өчен нигез булып хезмәт итә башлаганнар. Гарәп теленнән кергән **дөнья, җөмлә, галим, фикер**, **китап, рәсем, сәгать, җавап, гадәт, мисал** һ.б., фарсы теленнән кергән **сәүдә, рәвеш**, **начар, шәһәр, бәхет, һөнәр** һ.б. сүзләрнең алынмалар икәнен дә сизмибез. **Арыш, сука, мүк, салам, уҗым, буразна, эскерт, кәбестә, бүрәнә, мич, кәҗә** сүзләрен рус теленнән кергәндер дип уйлап та карамыйбыз. Менә бу сүзләр телебезгә монгол теленнән: **нарат, чаган, кияү, кодагый, мәңге;** ә **кәрәз, миләш, поши, пилмән, бүкән, лепкә, морж** сүзләре угро-фин телләреннән кергән. Руслар төрки һәм татар телләреннән һәм алар аша: **деньга (тәңкә), алмаз, алтын, амбар, аршин, башмак, богатырь (баһадир), буран, карандаш (кара таш, ягъни графит), книга (кенәгә), казна, кибитка, арбуз (карбыз), аркан, беркут (бөркет), колпак (калфак), ямщик (ямчы) һ.б.** сүзләрне кабул иткәннәр.

Татар теленә бик күп сүзләр, алда әйтелгәнчә, рус теле аша башка телләрдән дә кергән. Алар арасында немец, француз, инглиз, испан, итальян һ.б. телләрдән кергән сүзләр күп; грек, латин тамырларына барып тоташа торган сүзләр шактый һәм актив кулланылышта йөри.

Югарыда санап үтелгән чит ил сүзләрен дөньяның бик күп халыклары куллана. Аларны халыкара яки интернациональ сүзләр дип атыйлар. Телебездз киң кулланылышта йөрүче **биология, педагогика, партия, репертуар, абзац, вахта, спорт, фильм, ария, музей, вермишель, вымпел, катер, революция**, **томат, мотор, парад, гастроль, галстук, чемпион** һ.б. шундый меңләгән сүзне санарга булыр иде.

Заманында (20 гасырның башы һәм беренче яртысында да күзәтелә бу хәл), аерым телләр тарихында, интернациональ сүзләрдән ваз кичәргә тырышу, аларны үз сүзләре белән аралаштырырга теләү күренеше дә була. Чүлмәкчедән күрмәкче, дигәндәй, бу хәл татар телендә дә булып ала. Шул чорда (20 гасыр башы) журналда чыккан бер өзек: «Безнең ат белән барачак еремез тик утыз чакрым чамаларда гына улып, йитмеш чакрым бу йөрткеч берлә барылачак булдыкыннан, без бик тиз генә бу йөрткеч туктавына барып җиттек. Без килгәнче, бу йөрткеч күптән килеп, беренче кычкыртуы булган да икән, шунлыктан без тиз генә туктауга бардык та ике тәңкә егермешәр тиенгә күренгечләр алып утырдык» (йөрткеч – поезд яки пароход, туктау – вокзал яки пристань, күренгеч – билет). *Бу мисал Ф.С. Сафиуллина, М.З. Зәкиевнең «Хәзерге татар әдәби теле» (2002) дәреслегеннән алынды.*

1909 нчы елда «Шура» журналында, башка телләрдән алынган сүзләр кулланмыйча, саф татарча язылган материаллар бирүне сорап мәкалә басыла. Алынма сүзләр урынына нинди генә сүзләр кулланылмый ул язмаларда. Хәтта үзебезнең сүзләргә әйләнеп беткән гарәп-фарсы сүзләре **мәктәп, мәдрәсә** урынына **белек өе, белек йорты, белем урыны, белем йорты, уку йорты, уку өе, уку урыны, уку-язу урыны; каләм** сүзе урынына **бетәү, язгыч, язу карасы; дөнья – ачын, ачун; илче урынына – ялавыч; поезд – ут арбасы, пароход – ут көймәсе** кебек сүзләр тәкъдим ителә. Әмма бу сүзләр халык арасында яклау тапмый. Узган гасырның 90 нчы елларында да

бу күренеш кабатланды. Компьютер (санак, кампитр), вожатый (әйдәман), зонтик (кулчатыр), букет (гөлләмә) һ.б. сүзләрне мисал итеп китерергә булыр иде. Мин үзем бу сүзләрнең телебездә кулланылуына каршы түгел. Әмма иҗтимагый тормыш белән тыгыз бәйләнгән, халыклашкан һәм киң кулланылыш тапкан алынмаларны телдән тиз генә чыгарып ташлау мөмкин түгел.

Ана телендә сүз була торып башка тел сүзләрен куллану белән алынма сүзләр кулланышын бутамаска кирәк. Алынма сүз теге яки бу төшенчәне белдерү өчен телнең үзендә башка сүз булмаганлыктан кулланыла. Телнең үзендә кирәкле сүз була торып, аның урынына алынма сүз куллану урынсыз. Башка тел сүзләрен урынлы-урынсыз куллану – гади сөйләмнең үзенә бер төре – **варваризм** булып санала. «Катыштырма вә ләкин телгә телне» дигән тапшыруыбызда бу турыда сөйләгән идем инде.

Варваризм – латинча «чит илнеке» дигән мәгънәне белдерә. Борынгы заманнарда да сугышлар, яу чабулар булып торган. Яу белән килүче чит ил кешеләре үз телләррендә сугышка әйдәүче, дәртләндерүче сүзләрне кычкыра-кычкыра килгәннәр. Римлеләргә Европадан килүче кабилә-халыкларның сүзләре ерактан **вар – вар – вар** булып ишетелгән. Шунлыктан чит ил кешеләрен алар варварлар дип атаганнар. Сугыш, яуның максаты – җимерү, талау, үтерү. Кешелек иҗат иткән, корган, төзегән рухи һәм матди байлыкларны кыру, вәхшиләрчә җимерү дә варварлык дип атала.

Варваризмнар гади сөйләмдә генә түгел, әдәбиятта да очрый.

19 нчы гасыр һәм 20 нче гасыр башы татар әдәбиятында, галим-голәмә, дин әһелләре арасында гарәп-фарсы, төрек алынмалары, укымышлылыкны күрсәтү максатыннан булса кирәк, еш кулланылган. Мәсәлән, Г. Тукайның башлангыч чор иҗатына караган байтак шигырьләрен сүзлексез укып, аңлап та булмый. Төрекчелекнең йогынтысы аеруча көчле аның бу чор иҗатында. Әмма заманында Дәрдемәнд, Ф. Әмирхан, Г. Камал кебек шәхесләребез бу күренешкә каршы чыкканнар.

Әдәбиятта варваризмнар куллануның үз максатлары бар. Язучылар үз әсәрләрендә **персонажның тел үзенчәлекләре**

аша аның нинди образ икәнен, җәмгыятьтә тоткан урынын күрсәтү өчен дә варваризмнар кулланалар. Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романыннан Гайфул сөйләменә игътибар итик:

– Кичә «Байрак»тан кайтып җитү белән Паларусов миңа аягүрә генә докладовать итте. Мин аңа әйттем: «Син, дидем, неправильно поступать иткәнсең, дидем. Обвиняемыйга каршы меры пресечения принимать иткәндә, осторожно булырга кирәк, дидем. Беләсең, ул бит каты кеше. Миңа возражать итте: минем, ди, арестовать итәргә довольно ышанычлы основаниеләрем бар, ди.

Гайфул сөйләмендә, игътибар итсәгез, рус сүзләре кирәгеннән артык күп. Автор Гайфулның сәнәктән көрәк булып китү юлында рус сүзләрен кулланып, үзен тәҗрибәле, дәрәҗәле белгеч итеп күрсәтергә теләвен чеметеп ала.

Н. Фәттахның «Сезнеңчә ничек?» әсәреннән өзек.

– Алайса без икәү? – диде Бәхти, Ида белән икәү генә калгач. – Разрешите!

– Что же поделаешь с вами, – диде Ида, русча. Ул кайчакта Казанның татар кызлары кебек, үзенең яхшы тәрбия кешесе икәнлеген күрсәтү өчен, үз туган телен начар белүче булып кылана торган иде.

Матур әдәбиятта чит тел сүзләре **шул милләтнең тормыш-көнкүрешен, сөйләмен тасвирлау өчен дә кулланыла.** Мәсәлән, Н. Дәүлинең «Җимерелгән бастион» романында немец сүзләре күренгәли, чөнки вакыйга Германиядә бара. Г. Ибраһимов «Казакъ кызы» романында дала, казах халкының тормышын, гореф-гадәтләрен белеп тасвирлый. Әсәр казах сүзләре белән бик нык сугарылган. Персонажлар сөйләмендә генә түгел, автор сөйләмендә дә казах сүзләре тулып ята. Язучы казах халкының яшәешен тулысынча күз алдына бастыру өчен бара бу алымга. Аннан соң татар һәм казах телләренең тугандашлыгы, күп кенә казах сүзләренең татарларга аңлаешлы булуы белән дә аңлатыла бу алым.

Шулай ук **персонажның икенче бер халык вәкиле икәнен сиздерү өчен дә варваризмнар кулланыла.** К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» драмасында качкыннар тормышы белән бәйле күренешне искә төшерик. Питрәйнең сөйләм

рәвешеннән (кайсы милләт кешесе икәне әйтелми) аның чуаш кешесе икәне, Мишканың рус вәкиле булганлыгы сизелә. Яки Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ында Паларусов сөйләмендә дә чуаш акценты үзен нык сиздерә.

Варваризмнар кайчакта **чит илләр алдында баш июче персонажларның сөйләмен күрсәтү өчен дә кулланыла.** Рус язучысы Л.Н. Толстой «Сугыш һәм тынычлык» романында русча сөйләшкәндә француз сүзләре катнаштырып сөйләүче рус аристократларының сөйләмен күрсәтү өчен варваризмнар куллана. Заманында татар буржуаз милләтчеләре сөйләмендә арабизмнар (гарәп теленнән кергән сүзләр) тулып торган. Әдәби әсәрләрдә андыйлардан да көлгәннәр.

Фольклор әсәрләрендә, **аеруча җырларда, такмакларда юмористик, шаян аһәң бөркү нияте белән дә варваризмнар кулланыла.** Бу очракта алар җанлы сөйләмдәгечә, халык җырларындагыча бирелә:

Әнә килә автомобиль –
Төягәннәр дрова,
Яр өстенә яр сөяргә
Кемнәр бирде права?
Әнә килә автомобиль –
Төягәннәр семечка.
Яр өстенә яр сөясең –
Бу нинди привычка?
(М. Мәһдиев. «Торналар төшкән җирдә»).

Өстәлемнең уртасында
Бер йомарлам атланмай.
Ярым ташлый, дип курыкмыйм,
Яңалары гатавай.
Приходи к варатам, мин сине бик яратам.

Соңгы елларда, аеруча 21 нче гасыр башыннан, илебезгә, телебезгә Европа телләрендәге сүзләр ургылып керә башлады. Хәтта алар кайбер рус сүзләрен дә кысрыклыйлар. Тәкъдим итү (представление) – презентация, ил башлыгы – президент, предприниматель – менеджер, вступление в должность – инаугурация һ.б. Магазин, ларек, акционерлык җәмгыятьләре дә күбесенчә чит тел сүзләре белән атала. Үзебезнең Мөслимебездә дә «Эдельвейс», «Гарант», «Эльдорадо», «Феникс»,

«Аэлита», «Карина», «Самсон» кебек үтә яңгыравыклы исемнәргә ия сәүдә ноктaлары бар. «Чишмә», «Бәхетле», «Бәрәкәтле», «Мизгел», «Айсылу» ничек матур яңгырый!

Шәһәр җиренә барсаң, эченә кереп карамасаң, кайсы магазин, кайсы кафе, кайсы ни икәнен дә белеп булмый. Чөнки күбесенең исемнәре чит тел хәрефләре белән язылган. Телевизордан бирелә торган рекламаларны карасаң тагын! Рекламалар кararга ярата торган бер агай, магазинга барган да сатучыдан: «Миңа Солдаты дигән теш пастасы белән Сәмәй сабын бир әле, рекламада шуларны бик мактыйлар», – дигән. Солдаты, дигәне колгейт, сәмәй дигәне камей сабыны икән. Инглиз телендәге сүзләр язылганча гына укылмый икән ул.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: никадәр телебез сагында уяу торсак, аңа игътибарлы һәм ихтирамлы булсак, шуның кадәр телебезнең дәрәҗәсен дә күтәрербез, аның бер телдән дә ким түгел икәнен башкаларга да җиткерербез.

8. Катыштырма вә ләкин телгә телне...

Тел телне баета, дисәләр дә, чит сүзләрне кирәгеннән артык куллану, бутау телне чүпли генә. 20 нче гасыр башында ук атаклы шагыйрь Дәрдемәнд болай дигән:

Кил, өйрән, и туган бер башка телне,
Бүтән телләр белү яхшы һөнәрдер.
Катыштырма вәләкин телгә телне,
Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.

«Телнең сафлыгын, табигыйлеген, чисталыгын саклап сөйләү – һәркемнең намус эше. Ләкин без бу турыда кайчак онытып җибәрәбез», – ди тел галиме Ф. Сафиуллина.

Шагыйрь Ш. Галиев үзенең бер мәкаләсендә телне чүпләүчеләрне «телбасарлар», «сүз браконьерлары» дип атый.

«Ике телне бергә катыштырып сөйләүдән бара торгач, бер бозык, эшкә яраксыз тел генә туар», – дигән язучы М. Гафури. Моннан 80 еллар элек язылган ***«Чуар тел»*** мәкаләсендә ***М. Гафури*** базар сатучылары, авыл агайларының сөйләменнән мисаллар китерә дә:

– Әле югарыда мисал итеп күрсәтелгән агайлар русча укымаганнар. Инде русча укыган татарларның телне бозып

сөйләгәннәрен тыңлап торсаң – ис китәр! Алар, шөбһәсез, яртысыны русча, яртысыны татарча гына сөйлиләр. Эшләр шулай барса, үз телемез белән укуның базары да төшә башласа, 20–30 елдан соң саф татар теле белән язылган китапны аңлаучы да булмый башлар. Татар сүзенең нинди мәгънәдә икәнен лөгатьләрдән (ягьни сүзлекләрдән) генә карап белә башларбыз.

Никадәр алдан күреп, белеп язгансың, Мәҗит агай! Эшләр шуңа таба бара да инде!

Кайбер кешеләрнең сөйләшкәнен тыңлап торганнан соң, Дәрдемәнд сүзләре белән җаваплыйсы килә башлый:

Урысча күп сүзең, азы татарча,
Белалмыйм, кем син – урысмы, татармы?
Ничектер, белмәдек исем-шәрифең:
Хәсәнме, юкса, Иванмы, Макармы?

Безнең Мөслим төбәге халкының төп өлешен татарлар (89,1%) тәшкил итә *(Ә. Әхмәтгалиев. «Мөслим төбәге», 2003 ел).* Язучы, тәрҗемәче К. Миңлебаев бер мәкаләсендә, хәтта, менә кайда ул татарның әдәби теле, дип, Мөслим, Сарман төбәкләрен атаган иде. Юри генә, сынау рәвешендә, бер-беребезнең сөйләмен тыңлап карыйк әле. Һич икеләнми әйтә алам, саф татарча сөйләм килеп чыкмаячак! Татарчасы була торып, рус сүзенә барып ябышабыз инде. Ә яшьләребез телендә хәтта урта яшьтәгеләр дә аңлап бетерә алмаган «клёвый», «крутой» дигән сүзләр тулып ята. Үзләре аңлап, белеп куллана микән бу сүзләрне, дип, аптырап та куясың кайчак.

– Авылга кайтып киләсе бар иде. Астануфкыга чыксам, галасават итеп басып торасы булыр инде, пожалый.

– Мин дә бу субботада кайтырмын дигән идем дә, не получится. Мужикның одноклассникы өйләнә икән, на старости лет, пригласительный җибәргәннәр. Бармасаң, тоже нехорошо! Всё таки, воскресенье кич белән булса да әйләнеп килергә кирәк булыр авылдан.

47 сүзнең 18е рус теленнән алынган сүзләр!

Атна исемнәрен хәтта әбиләрнең дә күбесе русча вариантта гына куллана.

– Бу суббутыда Корьән ашына барасым бар.

– Дүшәмбе кайсы көн соң әле ул? Ә-ә, панидилник бит әле!

Халыкта, еракка китеп кара, дигән әйтем бар. Чит илләрдә яшәүче татарларның радио-телевидение аша чыгыш ясаганнарын тыңлап торам да хәйраннар калам. Финляндия, Америка, Австралия, Төркия, Германия, Швеция һ.б. илләрдә яшәүче милләттәшләребез кимендә 3–4 чит телне белә. Шуның өстәвенә сөйләмнәре саф татарча. Дөрес, азмы-күпме акцент сизелә, ул аларның сөйләменә бер бизәк кенә. Сөйләмнәренең акыллы, мәгънәле, тыйнак булуы сокландыра. Чып-чын зыялы кешеләр! Менә бер мисал.

Моннан берничә еллар элек Татарстан радиосыннан Фин илендә яшәүче бер ханым белән әңгәмә биргәннәр иде. Анда яшәүчеләр фин, швед, немец һәм халыкара телләрнең киң таралганы – инглиз телен дә беләләр. Татарлар үз туган телләрен беренче планга куялар.

– Сез ничек шулай 4–5 тел беләсез, татар телендә дә шундый чиста һәм дөрес сөйләшәсез? Без бер чит телне дә юньләп өйрәнә алмыйбыз, – дигәнгә ханым:

– Ә без балаларыбызга иң элек туган телебезне өйрәтәбез. Өйдә татарча гына сөйләшәбез. Милләттәшләребез белән дә фәкать туган телебездә генә аралашабыз, – дип җавап бирде.

«Башка телне өйрәнәсе булсаң, ул вакытта үз телеңнең кагыйдәләрен белү кирәк. Чөнки кеше үз туган телен яхшы белмәсә, башка телгә төшенә алмас, тик бик озак вакытлардан соң гына күнегә алыр», – дигән бит Каюм бабабыз да.

Бездә хәзер нихәлләр? Менә бу мәзәктәгечәме?

Хәйрулла агай оныгын мактап бетерә алмый:

– Бик башлы малай: теле русча ачылды, инглиз мәктәбендә укый! Хәзер татарчаны да төшенмә кели!

Туган телне өйрәнүне иң азакка калдырсак, мишәр агай әйтмешли, «келәп» кенә калмабызмы?

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: телгә игътибарсыз, саксыз карауга юл куелмаска тиеш, әлбәттә. Татарча сөйләшәсең икән, бик әйбәтләп татарча сөйләш, инде русча сөйләшсәң, рус сүзләрен ватма-җимермә!

9–10. Матурлык йөздә түгел – сүздә. Халык теле – чәчәкле болын

Безнең бүгенге телебез – әдәби сөйләм теленең нигезендә – гади сөйләм, халык теле ята. Кайчандыр, дөресрәге, 19 нчы гасырның соңгы чирегенә кадәр, җанлы сөйләм теленә якын халыкчан телдә язу әдәбиятта кире кагылган. Халык теле – урам теле, дип каралган. Бөек мәгърифәтчебез К. Насыйри моңа каршы чыга. «Ялган яла бу! Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул. Бүтән телләрдән бер дә ким түгел», – ди. Ул татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын, шуңа хакы һәм сәләте барлыгын исбат итте. Аның башка телләрдән артта торуын фәкать эшләнмәгәнлегеннән генә күрде. Аны практик һәм фәнни эшкәртү юлында зур, кыю эшчәнлек күрсәтте.

Татар әдәбиятында халык сөйләменә якын телдә язуны Габделҗаббар Кандалый башлап җибәрә. Шуңа күрә дә, аның шигырьләре халык арасына таралып, халыклашып китә. Габделҗаббар бабай шигырьләре буларак, гасырлар дәвамында халык күңелендә яши. Г. Кандалыйның шигырьләре китап булып, фәкать 20 нче гасыр урталарында гына чыга. Кандалыйның беренче җыентыгын әзерләгән Җәвид Алмаз халыктан җыеп туплый шагыйрьнең шигырьләрен. Онытмаган халык үз телендә, гади халык телендә язылган шигырьләрне. Күңел түрендә, йөрәк түрендә йөрткән байлыкны, әманәт итеп, буыннан-буынга тапшырган.

Халык теле алга таба матур әдәбиятка Я. Емельянов, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Коләхмәтов, Г. Камал, М. Гафури, Г. Ибраһимовлар ижаты аша килеп керә.

Әдәби телебезгә нигез булып торган гади халык сөйләме турында булыр алдагы сүзебез.

Гади халык сөйләме – болын кебек ул. Болында да бит төрле матур чәчәкләр, үләннәр, үсемлекләр генә үсми. Тигәнәгә дә, ара-тирә кычытканы да, билчәне дә, хәтта агулы үсемлеге дә очрый. Халык теле дә шулай төрле, бай! Матур, мәгънәле, үткен сүзләр белән бергә тупаслары, дорфалары да шактый. Халык теле җанлылыгы, тасвирлауга байлыгы белән аерылып тора. Җор һәм тапкыр сүзгә, сүз уйнатуга да урын җитәрлек

анда. Юмор һәм үтергеч сатирага да урын бар. Фразеологик әйтелмәләр дә, диалектизмнар да, үткен чагыштырулар да, мәкаль-әйтемнәр дә тулып ята халык сөйләмендә.

Чыгып шылу, чәлү, шәһәргә ычкыну, олагу, эш хөрти, быжгыту, уҗым бозавы, көзге чебеш, ызначит, мишәйт итү, эсвижи, дачурта, лутчы, гүпчим, самай, биштән төргән, түбәгә менеп төшү, ыржаю һ.б. кебек сүзләр көндәлек тормышта бүген дә актив кулланылышта йөри.

«Бер утыруда бер кирпеч ипи белән олы коштабакка салынган ботканы **сыпырып салды**».

«Котны алып, Батан бакчасындагы аюлар кебек **акырма әле», –** дип ачуланды тәмам батырайган Фәтихәттәй (Г. Ә.)

«Шул Сәйфи чулактыр әле, **оятсыз бәбәк**. Шул маташтыргандыр, **үләт ялагыры**!» (Г. Б.)

Мин язмаларымда халык язучысы М. Мәһдиевтән мисаллар китерергә яратам. Беренчедән, ул минем иң яраткан язучым. Икенчедән, М. Мәһдиев авыл тормышын, аның горефгадәтләрен, кешеләрен, телнең бөтен нечкәлекләрен белеп яза торган язучы иде. Үзенең бер герое әйткәндәй, «люби» очракка мисал китереп була аның әсәрләреннән. Геройлары – гапгади авыл кешеләре. Беркатлы, үтә ярдәмчел, эшчән, һөнәрле, сәләтле, сүзгә оста кешеләр алар. Автор һәр героен сөйләм теле аша ача, дисәк тә хата булмас. Һәрберсенең үзенә генә хас сөйләм үзенчәлеге бар. Япон Яһудин кушаматы йөрткән Исламгали агай («Бәхилләшү» повесте), «Каз канатлары»ндагы бераз сакаурак Фәхрелислам, искиткеч кунакчыл Галләмгали агайлар, «Кеше китә – җыры кала»дагы Шәйхи карт нәкъ менә сөйләмнәре аша ачылып, күз алдына тулы канлы образ булып килеп баса.

«Исламгали агай үзенең имәндәй таза, яшь килеш ике кулсыз калу фажигасен искә төшермәс өчен һәрвакыт көлкеле тема тудыра, эзләп таба, кыскасы, гел ялган сөйли иде.

– Танкка кадәр разведротада булдым мин. Мине фашистлардан белмәгән кеше юк иде. Гитлер әйткән ди әллә ничә тапкыр: Мәскәүдән – Левитанны, Беренче Украина фронтыннан Ягудинны тотып китерегез, һәр икесенең башына йөзәр мең марка акча түлим, дип әйткән ди. Шуларны пирвый усакка асам, дип әйткән ди.

Бервакыт урман аланында чолганышта калгач, 800 фашистны әсирлеккә алдым.

Ирләр елмаешты. Хатын-кыз таң калды.

– Ул тиклем халыкны нишләттең? – диде сугыш темасын аеруча яратучы Хәерниса.

– Нишләтим? Эш таптым. Бер колхозга алып бардым да атна буе чөгендер чүбе утаттым. Аннары ике көн буе бәрәңге басуында колоратурный жук чүпләттем. Эшләсеннәр. Талый белделәр бит.

– И ходаем, теге корткыч коңгыз шул вакытта ук булган икән...

– Булмыйни? Фашист-собакаларга ияреп килде инде ул безнең илгә». *(«Бәхилләшү»).*

Шәйхи карт, сугыш башланганнан бирле, Германия турында гына сөйли:

– Ярманда түлке машина күп инде анда, – ди. – Батырлыкка безнең солдатка чыкмый инде чыгуын, әмма ләкин тегеләр машина күп булу белән алдыралар. Аларның бит тегендә-монда барганда карты-карчыгы да бисәпилкегә генә утырып чаба *(«Кеше китә – җыры кала»).*

Гади сөйләм сүзләре гомумхалык сөйләм теленә карыйлар, сөйләмгә эмоциональ-экспрессив төсмер бирәләр. Гади сөйләм, халык сөйләме – ирекле сөйләм, интонацион сөйләм ул. Аны каләм әһелләре урынлы итеп матур әдәбиятта персонаж сөйләмендә кулланалар. Кискен, төксе әйтелүләре белән аерылып торсалар да, әдәби телне баетуда билгеле бер чыганак ролен үтиләр алар.

Гади сөйләм сүзләренең бер төре булган **вульгар сүзләргә** тукталып китик. Вульгаризм – латинча «**гади, тупас**» мәгънәсен аңлата. Әйтелеше ягыннан гаять тупас, дорфа, төксе, бозылган сүзләр һәм тәгъбирләр. Сүгенү сүзләре, аяусыз сөйләшү, кеше шәхесен тәмам түбәнсетү сүзләре керә вульгар сүзләргә.

Ш. Галиевнең «Котбетдин мәзәкләре»ннән берсе.

«Көтмәгәндә башланды сүз. Кибетче хатын бер егеткә:

– Кычкырма, тупас, – диде.

– Син үзең ахмак, – дип җавап бирде тегесе.

– Ник алай сөйләшәсез, паразитлар! – дип кычкырып

җибәрде чираттан бер хатын. Ире дә бу тәртипсезлеккә чыдый алмады:

– Һай, әшәке халык, туктыйсызмы, дуңгызлар! – дип өстәде.

Минем дә тел кычытты, ләкин дәшмәдем, сүземне эчтән генә әйтеп чыгып киттем: «Этләр белән эт булганчы, дәшмә, Котбетдин».

М. Мәһдиевтән бер өзек.

Сүгенү, дорфа сүз сөйләүне халык зур хурлык дип санаган.

Бер вакыйга хәтердә: кемгәдер кунак булып килгән яшь бер ир урамда тавыш чыгарган, сугыша башлаган. Сүз белән тыя алмагач, ирләр ат дилбегәсе алып чыгып аның аягын-кулын бәйләделәр дә урам уртасындагы чирәмгә сузып салдылар. Теге сүгенгән саен башына бер чиләк чишмә суы коеп тордылар. Кыйнашу-сугышу, алдашу, сүгенү – авылда бик хурлыклы эш исәпләнә иде.

– Фәлән кеше бик ямьсез сүз әйтте, шул авызлары белән ничек ризык кабар икән ул, – дип карчыклар сөйләнә иде. *(«Торналар төшкән җирдә»).*

Менә бит, элек авылда ничек булган! Ә хәзер! Артына утырганы, аягына басканы, ире-хатыны, әбисе-бабасы сүгенә, бер-берсенә нинди генә тупас сүзләр әйтми. Бала-чага, олы кеше бар дип тору юк – аяусыз сөйләм! Балаларның телен дә эшәке сүз белән ачтырабыз бит, җәмәгать! Аларның шул сүзләрне әйтүеннән рәхәтләнеп көләбез, кабатлатабыз. Дорфа, тупас җавап бирүләрен бер «егетлек» итеп күрше-күлән, таныш-белешкә җиткереп торабыз. Ананы телгә алып сүгенгән балалар, яшүсмерләр яныннан ишетмәгәнгә салынып, битараф кына үтеп китәбез. Әнә бит сугышка, яки 50–60 нчы елларга кадәр авылда сүгенүчеләрне ничек акылга утыртканнар бергәләп!

– Хәзер әйтеп кара син аларга, үзеңне пычракка коендырырга да күп сорамаслар. Измәңне дә изеп ташлар-лар хәтта, – диярләр күпләр. Шулай инде, ни чәчсәң, шуны урырсың, ди бит халык.

«Халыкның иң зур байлыгы, иң кадерле рухи хәзинәсе, һичшиксез, аның теле. Халык үзенең телен, оста бакчачы кебек, яман җилләрдән, рәхимсез салкыннар куырудан саклап,

мең еллар буена үстереп килгән, аны өзлексез баетып, матурлап, иң тирән фикерләрен, иң нечкә хисләрен дә аңлатып бирер дәрәҗәгә җиткергән», – ди язучы Г. Бәширов «Без кем идек...» мәкаләсендә. Мең еллар дәвамында безгә мирас булып калган телебезне чүп басуына әйләндерсәк, ата-бабаларыбыз рухы рәнҗемәсме?!

11. Ни башына ни кунган...

Бүгенге тапшыруыбызда сөйләм барышында очрый торган кайбер җитешсез күренешләргә тукталырбыз.

Халкыбыз сүзгә, сөйли белүгә, сөйләм оештыруга тәнкыйди карашта. Сөйли белү – сәнгать. Әлбәттә, буш сүз сөйләп, кешенең алтындай вакытын алу ягында түгел халкыбыз. Аз сөйлә, ләкин сүзең үтемле һәм мәгънәле булсын. Авыз эчендә ботка пешерүчеләрне, әйтәсе сүзен әйтә алмыйча, су буе җөмлә төзеп сөйләүчеләрне, сүз болгатучыларны, кирәкмәгән урында телен тыя белмәүчеләрне мәкаль-әйтемнәрендә, мәзәкләрендә утка тотарга да күп сорамый халык.

Кайберәүләр сүз табарга иренүдәнме, әллә шулай гадәткә алгангамы, сүз урынына **ни-ни** кыстырып сөйлиләр. Мондый кешеләрнең ни әйтмәкче булуларын да юньләп аңлап булмый. Бигрәк тә кабаланганда.

...Шулай, бер агайның күркәсе читән башына кунган икән. Агай аны куып төшермәкче булган. Күркә ялгыш читән казыгына кадалган. Агайга, күркәне үлгәнче суярга кирәк бит инде. Өйгә карап, кулларын болгый-болгый, кабаланып кычкыра башлаган:

– Ни башына ни кунган иде, ниткән идем, нитте дә китте. Ни китерегез әле нитәргә!

Ягъни:

– Читән башына күркә кунган иде. Куган идем, казыкка кадалды. Пычак китерегез әле суярга!

Беркем дә агайның ни әйтергә теләгәнен аңламаган. Шулай итеп, күркә дә үлеп әрәм булган.

...Ни-ни дип сөйләүче бер кеше үлем түшәгендә ята икән. Янына улы килеп:

– Әти, миңа нинди васыять сүзең бар? – дигән.

Бу кеше малаена болай дигән:

Ниеңдәге ниеңне нитә күрмә ниеңә,
Ниеңнең дә ние була, ул да нитәр ниенә.

Улы бу сүзләрне аңлый алмаган. Ә әтисенең болай дип әйтүе булган:

Эчеңдәге сереңне сөйли күрмә дусыңа,
Дусыңның да дусы булыр, ул да сөйләр дусына.

(Бу мисаллар Н. Исәнбәтнең «Балалар фольклоры» китабыннан алынды; Казан, 1984).

Ә бертөрле кешеләр сөйләшкәндә сүз тәртибенә бөтенләй дә игътибар итмиләр, кирәккә дә санамыйлар. Мондый очракта ни акыллы, ни тиле сүзләр килеп чыга. Яки кинәт кенә килеп туган киеренке хәлләрдә, курыкканда, кабаланганда, ашыккан-да да кеше сүз тәртибен чуалтырга мөмкин. Фольклорчы-галим Н. Исәнбәт сүз тәртибен бутап, чуалтып сөйләүне **матавыклар** дип атый. Халыкта матавык хәлләр, матавыкка юлыгу, матавыктан чыгу кебек гыйбарә нигезендә дә буталчык мәгънәсе ята.

Бер кеше сыерга печән салыйм, дип печәнлеккә менгән дә егылып төшкән. Ахылдап өйгә кергән дә малаена: «Хәсән балам, абзар түбәсеннән егылып төштем. **Уттан күзләр күренде.** Син бар, **печәнгә сыерны сал**», – дигән. *(Н. Исәнбәт «Балалар фольклоры»).*

Абзар түбәсеннән башың беләнрәк тә төшсәң, моның ише сүзләрне генә сөйләп калсаң ярый әле.

Менә берәү сөйли: «**Чәчен маңгай каплаган**» (маңгаен чәч каплаган, диярга тели булса кирәк). **Эттән арт** (арттан эт), **кулыңнан кесәңне ал** (кесәңнән кулыңны ал), **чәчеңне үреп тара** (чәчеңне тарап үр), **абзарны сарыкка ку** (сарыкны абзарга ку), **бер күкәең тавык салган (**бер тавыгың күкәй салган**)** кебек мисаллар көндәлек сөйләмдә очрап тора.

М. Мәһдиевтән бер өзек**: «**Кәшфи... Абдулның күлмәк җиңен тотты.

– Аның өчен чөнки... Аның өчен чөнки, – дип кабаланганда, Чулак Абдул аның кулына сугып җибәрде.

– Минем күлмәк җиңенә ябышырга **яшең баш** әле, – диде Абдул, кыза төшеп». *(«Исәнме, Кәшфи абзый»).*

Дулкынланудан, борчылудан, гажәпләнүдән дә кешеләр

иҗекләрне, авазларны бутарга, бер урыннан икенче урынга күчерергә мөмкин. Мондый күренеш телдә **метатеза** дип атала. Мәсәлән, укучылар арасында, **хаф сава (саф һава), ярымшарлар картасын – шарымярлар картасы дип,** рус теле дәресләрендә **задано на дом** урынына, **надано за дом, задано на ном, старастепенный член** дип сөйләү гадәти хәл.

М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романыннан тагын бер өзек:

«Сәхнәгә Тәлгать атылып чыкты. Әсәргән күзләре белән клубның түшәменә карады да кадалды да калды. Артта борчылдылар. «Мендәрем дә мендәрем, дип пышылдадылар. Берничә секундтан Тәлгать кычкырып әйтеп салды: «**Шилень**».

Халык гөр килеп көлде. Малай каушады. Ул **«Шинель»** дигән шигырь сөйләмәкче икән. Шулай да бер тын алгач, киртәсенә төште. Чатый-ботый китереп сөйләп китте».

Кайбер кешеләрнең сөйләмендә **инде, һәм, әйеме, әйе бит, шулай бит, шулаймы, димәк, чыннан да, значит (кайбер кеше нәчит дип кенә җиппәрә), действительно (**соңгы икесе ир-атлар сөйләмендә күбрәк очрый**)** сүзләре бик еш кабатлана. Мәктәптә ачык дәрес биргән укытучылар, җавап бирергә торып баскан укучылар аеруча «чирли» бу сүзләр белән. Җыелышларда ирекле чыгыш ясаучылар (алдан әзерләнеп килмичә, кәгазьгә карамыйча гына сөйләүчеләр), телдән интервью бирүчеләр сөйләмендә дә еш кулланыла әлеге сүзләр. Суга батучы саламга тотынган шикелле, сүз тапмый торганда бушлыкны тутыру яки сүз бәйләү өчен кулланыла бу сүзләр.

Тагын шундый күренешләрнең берсе – **сүз кабатлау, кабатлап сөйләү**.

М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романыннан бер мисал.

«Сабир Ишмуратович тамагын кырды.

– Моңа бары тик мин генә гаепле, иптәшләр, – дип, шактый ышанычсыз хәлдә башлап җибәрде ул сүзен. – Әйе, мин генә гаепле. Дөрес, бу класс безнең иң кыен коллектив. Яңа укытучылар – мин күз алдында тотам, әлбәттә, иптәш Сулимов белән иптәш Сәләхиевне – бу коллективны рәткә салу өлкәсендә бик энергично эш башладылар. Бик энергично эш башладылар. Инде килеп, инде килеп, шушы эш процессында, шушы эш процессында (борчылган вакытта директор һәрчак

шулай кабатлап сөйли) күңелсез картиналар чыккан икән, моңа, кәк директор, мин генә гаепле, мин генә гаепле. Иптәшләр, без бу мәсьәләне бик тирәнгә җибәрмик, үзара бетерик. Мин кәк директор, кәк директор, сүз бирәм, безнең коллективта моннан соң андый эшләр булмаячак, булмаячак...».

Ә бит гадәти шартларда, үзара аралашканда сөйләмнәрендәге әлеге кимчелекләрдән азат андый кешеләр. Чыннан да, кешенең психикасы белән бәйледер инде бу хәл.

Шулай да, мондый сөйләм тыңлаучылар өчен ялыктыргыч. Бер үк сүзне еш куллану, кабатлау чыгышның эффектын шактый киметә.

АКШ президенты Авраам Линкольн (1860–1865 елларда идарә итә) сенаторлар яки халык алдында ясаячак биш минутлык чыгышын да атналар буе әзерләгән. Бакчада, аллеялар буйлап йөри-йөри, үз-үзенә сөйләп караган. Хәзер дә АКШ президентларының чыгышларын телевизорлардан күрсәткәләп алалар бит. Президентның һәр җөмләсенә диярлек торып басып кул чабалар сенаторлар. Мәгьнәле, кирәкле сүз сөйләгәнгә бит ул. Сүз – ышандыру, тәэсир итү көченә ия булганда тыңлаучыларда әнә шундый көчле реакция күзәтелә. Сүзе эштән аерылмаган ораторның сөйләме дә әнә шундый зур көчкә ия. Атаклы педагог, психолог, язучы Дейл Карнеги (америкалы, 1888–1955 елларда яшәгән) үзенең «Публика алдында чыгыш ясаганда ничек итеп үзеңдә ышандыру көче тәрбияләргә һәм тыңлаучыга тәэсир итәргә?» дигән хезмәтендә бик кызыклы мисаллар китерә, ораторлык серләренә төшендерә. Публика, халык алдында еш чыгыш ясаучылар менә шушы хезмәткә ешрак мөрәҗәгать итсеннәр иде. Халкыбыз да ораторлык сәнгатенә битараф түгел.

- Булган оратор бар халыкны авызына каратыр,
  Булыр-булмас оратор болгатыр да таратыр;
- Йөрәктән чыкмаган сүз йөрәккә кермәс;
- Сүзең кыска булсын, кулың оста булсын.

Әлеге мәкальләр сөйләгән сүзләребезне, фикерләребезне тагын бер кат дәлилли кебек.

12–13. Кем син? Нәселең кем синең?

(Туганлык мөнәсәбәтен, нәсел-нәсәп, кардәш-ыруны белдерүче сүзләр)

Нәсел-нәсәп дигәннән, гарәпчәдән алынган бу ике сүз бер-берсенә якын, әмма бөтенләй үк бердәй булмаган ике төшенчәне белдерә. Нәсел-кан кардәшләреннән берәү булса, нәсәп-никях, кодалык мөнәсәбәтләрендә торган кеше.

Туган телебез нәсел-нәсәп атамаларына иң бай телләрнең берсе. Татар телендә 400гә якын шундый сүз – термин барлыгы билгеле икән. Бүгенге яшь буын бу турыда беләме? Белсә дә берничә төрен генә беләдер. Мәсәлән, ата-ана, әби-бабай, онык, җизни (җизнәй), апа, абый, ерак әби, ерак бабай, эне, сеңел һ.б. берничә сүз.

Еш кына балалардан, яшьләрдән: «Бу кеше безгә кем була соң? Ул безнең туганмыни?» – кебегрәк сорауларны ишетергә туры килә. Яки үзләренә: «Безнең туган дисең дә, ничек туган тия соң ул сиңа? – дисәң, – әй, двоюродный, троюродныймы шунда, – дип, русчалатып кына җавап бирәләр. – Двоюродный, троюродный дигәнне ничек аңлыйсың? – дисәң, аптыратма әле, дигәндәй, кул гына селтәп китеп баралар». Ул двоюродный, троюродный дигәннәре туган телебездә менә болай була икән.

1. Бер ата-ана балалары (ул-кыз) бер-берсенә карата җенесләрен аермыйча, **туганнар** була.

2. Туганнарның балалары бер-берсенә (двоюродный) **тудык** (ир заты), **тудыка** (хатын-кыз).

3. Бер ата-анадан соң өченче буын вәкилләре бер-берсенә **тума (**ир), **тумача (**кыз туган) дип әйтәләр.

4. Дүртенче буын **тора-ят, торачы** булалар. Ир-егет тармагыннан тора-ятларның бер-берсенә кыз бирергә, кыз алырга хаклары бар.

5. Бишенче буын **туа-ят**, моннан ары **җиде-ят** дип атала.

400 сүзне тикшерә китсәк, сүз бик озынга сузылыр, шуңа күрә нәсел-нәсәпне белдерүче берничә сүзгә тукталып китәрбез. Сүзне ата-анадан башлыйк.

Ата кеше – **ир** кеше, гомумтөркиэр сүзеннән. Ул «герой», «батыр», «киң күңелле» дигән сүз.

Ана сүзе дә гомумтөркихарактерда булса да, кардәш

телләрнең барысында да бар, дип әйтеп булмый. Мәсәлән, татар теленә иң якын телләрнең берсе – башкортларда **әсә** (монголча **әчә, әҗә, эҗе**). Татар телендә Ана сүзенең анакай, анай, әнәй, әни, әнкәй, инәй, инәкәй һ.б. төрләре еш очрый. Мөслим районының төньяк-көнчыгыш, көнчыгышына урнашкан авылларда **инәкәй, инәки** дип әйтү бар.

Әтинең, әнинең ата-анасы балаларга **әби, бабай** була. Сынаганым бар: Мөслим районының Яңа Усыга кадәр өлешендә сөйләм йомшаграк. Башкортстан татарларының сөйләменә хас үзенчәлекләр үзен сиздерә монда. Тат. Бүләр, Урәзмәт, Әмәкәй, Баек, Карамалы якларында әби-бабайны шундый матур итеп **әбкәй, бабкай** дип әйтәләр! Иске Карамалыдан соң тел катыланган кебек. Бу якта әти-әни (әткәй-әнкәй), әби-бабай китә. Әнинең ата-анасын **ерак әби, ерак бабай** дип атыйлар. Әби-бабайга **дәү әни, дәү әти** дип дәшү безнең якларга кереп кенә килә. Ләкин соңгы елларда шәһәр балалары телендә **давани, дават, хәтта дивани** (диванага да ерак калмаган), **«атика бабай», «атика ани», «атика эби»** кебек» «яңа атамалар» активлашты. Саф татарча яңгыраган, колакка ятышлы **әбкәй, бабакай, әбием, бабаем** кебек сүзләргә җитәме соң инде!

Без үскән чорларда, аңа кадәр бигрәк тә **дүрәнәй, дүрәтәй** (зур әни, зур әти) дигән сүз бар иде. Минзәлә төбәгенә хас булганча, «з» авазы «д»лаштырылганга күрә, үзгәреш кичергән бу сүзләр. Әтинең олы абыйсын һәм аның хатынын шулай дип атаганнар. Гаиләдә 3–4 малай булса да, бары тик яше буенча иң зурысына карата гына кулланылган бу сүз. Димәк, **дүрәтәй, дүрәнәй** титулы туганнарның берсенә генә – иң өлкәненә генә бирелгән. Хәзер бу сүзне өлкән яшьтәгеләр телендә генә ишетергә мөмкин. Бик матур, мәгънәле сүз, югыйсә.

Башкортстан татарлары телендә әтинең я әнинең әнисен **нәнәй, картый** дип атау киң таралган.

Безнең Мөслим төбәгенә (гомумән, көнчыгыш регионга) хас диалекталь (җирле) **апай, апаем** сүзе бар. Ул бездә үзеңнән кечкенәләргә эндәшү сүзе.

– Син аны, апай, болайрак эшләп кара әле.

– Апаем, сиңа шәһәрдән нәрсә алып кайтыйм?

Бу сүзнең **апа** сүзенә бернинди мөнәсәбәте дә юк икән. Борынгы заманнарда болай дип малайларга эндәшкәннәр. Ул «ал-

пай» (алып-батыр, баһадир), «алпаем» – батыркаем, үскәнем сүзеннән килә икән. Тора-бара үзеңнән кече кыз балаларга карата да әйтелә башлаган. Бу турыда Башкортстанда яшәүче тел галиме Рифгать Әхмәтҗановның бер язмасын табып укыгач, үземә зур бер ачыш ясаган кебек булдым.

Казан, Арча ягында бу сүз олы яшьтәге хатын-кызга карата **апа** мәгънәсендә кулланыла (Газизә апай, Хәдичә апай). Безнең **апай**, **апаем** дип үзеңнән кечеләрне атаганга, алар гажәпләнә торган иде.

Апа сүзе күбрәк очракта урта яшьләрдәге хөрмәтле ханымга эндәшү сүзе булып (бу мәгънә кардәшлеккә карамый) кулланыла. Үз апаң мәгънәсендә **тута, түтәй, түткәй**, **абыстай** һәм башка сүзләр килә. Әлбәттә, хәзерге яшь буын бу сүзләрне куллану ягында булмас, «кеше көлүдән» куркырлар.

Өйләнәсе егетләр алга таба кәләш (ярәшелгән кыз), бикәч (яңа төшкән килен), хатын (ханның җефете, ханбикә), хатынының эти-әнисе – каенатай-каенана (әмма бездә әби-бабай дип атау гадәткә кергән), каениш, балдыз, бажа, кода, кодагый, кодача кебек сүзләрнең нәрсә аңлатканын белсен иде һич булмаса.

Булачак килен исә, иренең ата-анасы, ир ягы туган-тумачасы турында да бераз мәгълүматлы булсын. Ирнең ата-анасы – каенана-каената; биана, биата. Соңгысы дөресрәк вариант. Чөнки борынгы гадәт буенча, килен ягы – хан ягы, ә кияү ягы – би ягы дип каралган. Би – эре хуҗа, җир-су, байлык иясе, баш кеше. Би – хатыны өчен дә хуҗа, баш кеше. Шуннан биемнең атасы, биемнең анасы атамасы килеп чыккан. Турыдантуры эндәшкәндә килен бианайга – әни, әнкәй, биатайга – әти, әткәй диярге тиеш.

Ирнең абыйсы – биага, апасы – бикәм, энесе (киленнән олырак булса) янагай, җанагай, кечерәк булса – каенэне, биэнем, сеңлесе – каенсеңел, бисеңел була.

Гаиләдәге ирләрнең хатыннары бер-беренә килендәш була.

Элек татар гаиләләрендә матур апа, мулла абзый, муллати, шәкерт абый, чибәр җиңги зур апа, алмапа, абыз түти, чибәр апа һ.б. шундый матур, мәгънәле сүзләр кулланылган. Мишәр халкында бу сакланган әле. Бездә дә кайбер гаиләләрдә әйтелә

торгандыр. Ләкин алга таба бу төшенчәләрне куллана белүчеләр булырмы?

Мулла абзый, муллатти, шәкерт абый, абыз түти, абзый сүзенең нигезендә укымышлылык, белем мәгънәсе ята. **Абыз –** гарәпчә хафиз – яттан сөйләүче шагыйрь дигәнне аңлата. Корьәнне яттан белүчеләрне «Корьән хафиз» дип атаганнар. Алга таба бу сүз туганлык термины булып киткән. Татар халкының күп гасырлык традициясе буенча, гаиләдә, ичмасам, бер кеше укырга, белем алырга тиеш булган. Һәм, гадәттә, гаиләдә икенче баланы абызлыкка әзерләгәннәр (чөнки беренче бала әти-әниләренә эшкә җигелгән). Шулай итеп абыз – икенче балага карата кулланылган. Беренче бала еш үлә торган заманнарда абыз иң өлкән туган булып кала килгән. Шуннан абзый – хөрмәтле, укымышлы ир кеше, **абыз тутай – абыстай –** укымышлы хатын атамалары килеп чыккан.

Нәсел-нәсәп атамаларында теге яки бу чорның әхлагы, рухи кыйммәтләре ачык чагылыш тапкан. Хәзер дә без аларны белеп һәм урынлы куллансак, бу атамалар кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне бизәп, матурлап торыр иде.

14. Ни хәлең бар, кеше туганым?

(Исәнләшү, хәл белешү).

Кешеләр бер-берсен нинди генә сүзләр белән сәламләмиләр: «Исәнмесез! Исәннәрмесез! Әссәләмәгаләйкүм! Сәлам! Салют! Привет! Чао! Хау ду ю ду!»

Бер-берсен сәламләгәндә төрле ил халыклары бик күптәннән бирле кулланган хәрәкәтләр, ишарәләр тагын да төрлерәк. Берәүләр бил тиңентен иелеп баш игәннәр, икенчеләре кулларын маңгай һәм йөрәк тирәсенә куйганнар, өченчеләре бер-берсенә телләрен күрсәткән, дүртенчеләре исә бер-берсенә борын очлары белән орынганнар. Аксөяк хатын-кызлар, боргалана-сыргалана, тез чүккәннәр, ә мәшһүр мушкетёрлар, гәүдәләрен иеп, эшләпәләрен селкеп торганнар. Король гвардиясе офицерлары үкчәләрен шартлатып, башларын күкрәкләренә салындырып сәламләгәннәр. Хәрбиләр әле хәзер дә бер-берсенә честь биреп китә. Берәүләр ерактан кул болгап сәламли,

икенчеләре кочаклашып ук ала. Әнә ике кыз бер-берсенә атылып килделәр дә, «пәп» итешеп алдылар, ни турындадыр тиз-тиз генә сөйләштеләр дә йөгереп китеп тә бардылар». *(«Үзең нинди – көзгең шундый»).*

Әйе, башка кеше белән очрашу вакыйгасын кешеләр төрлечә билгеләп үтәләр. Сәлам бирергә теләмәү яки бирелгән сәламне алмау – һәрчак һәм һәр халыкта да зур әдәпсезлек һәм тирә-юньдәге кешеләргә хөрмәт күрсәтмәү билгесе булып саналган. Чөнки баш иеп хәлеңне белүгә, сәлам биргәндә әйтелә торган кыска гына сүзләргә бик зур һәм бик мөһим эчтәлек салынган. Беренче карашка гади генә булган «исәнмесез» сүзе менә нинди мәгънәгә ия: «Мин сине күрәм, кеше. Син миңа ошыйсың. Белеп тор: мин сине хөрмәт итәм һәм синең дә миңа хөрмәт белән каравыңны телим. Мин сиңа иң кадерле нәрсәләр: исәнлек, тынычлык, шатлык, бәхет телим».

Бүгенге тапшыруыбызда халкыбызның исәнләшү, хәл белешү, шөкер итүгә бәйле берничә сүз – төшенчәгә тукталырбыз. Исәнләшүне белдерү өчен хәзерге көндә иң актив кулланылышта йөри торган сүз – **«исәнме», «исәнмесез»** сүзе. Кайбер кешеләр, уенын-чынын бергә кушып, бу сүзгә каршы:

– Исән булмасам, әллә духтыр булдыңмы? – дип җавап бирә. Яки, исән булмасам, каршыңда басып тормас идем бит, – ди.

– Үзең исән-саумы? Гаиләңдә тынычлыкмы? Йорт-җирең, мал-туарың иминме? – дигән мәгънә дә салынган бу сүзгә. – **Аллага шөкер**! – дип кенә җавап бирәсе, югыйсә. Гаеп итеп әйтүем түгел: тагын шундый кешеләр була, синең сәламеңне дә алып тормыйча, ah-bah килеп, үзенең чирләрен саный башлый. Тыңлап торасың да, шушы кадәр чир белән бу гомер ничек яшәгән икән бу кеше, дип уйлап куясың. Өеңдә, ихатаңда, урамда үз аягың белән йөрерлек хәлең, мөмкинлегең булганда, ашый-эчә алганда, үз йомышыңа йөри алганда, өстәл тулы ризыгың булганда, ике кулыңны күтәреп дога кыла алганда, мең тапкыр, Аллага шөкер, диясе генә!

Хәзер өлкәннәр, шулай ук дини-әхлакый тәрбия алган яшь-ләребез арасында да, **әссәләмәгаләйкүм,** дип сәлам бирү активлаша бара. Ислам дине тоткан ата-бабаларыбыз гомер-гомергә шушы сүз белән бер-берсен сәламләгәннәр. Ләкин со-

вет чорында тәрбияләнгән берничә буын өчен **әссәләмәгаләйкүм** сүзе «мәчет картлары» сүзе буларак кабул ителде.

«Әс Сәлам» сүзе Аллаһы Тәгаләнең исемнәреннән булып, сәлам бирү «Аллаһы Тәгаләнең исеме сезнең белән, сез Аллаһының саклавында», димәктер. Сәлам бирү «әс Сәламү галәйкүм», «Сәламүн галәйкүм», «Сәламүн галәйкә», «әс Сәламү галәйкә» кебек җөмләләрнең һәрберсе белән була ала. Сәлам кайтаручы «**вәгаләй күмүс Сәлам», «вә галәйкәс Сәлам**» рәвешендә әйтә. Сәлам бирүче» әс Сәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтуһү» дисә, бигрәк тә яхшы. Иң яхшы рәвеше «әс Сәламү галәйкүмдер». *(Бу юллар Идрис хәзрәт Галәветдиннең «Сәлам бирә беләсеңме?» дигән китабыннан алынды. Яр Чаллы, 5 нче бит, 2011 ел.)*

Сәлам бирү, ул сәламне ала белү – тәрбиялелек билгесе дә.

«Рәсүлебезгә бер төркем яһүдиләр: «Әссәәмү галәйкүм», – диделәр. (Әссәәмү – агу, үлем, дигән сүз). Яһүдиләр, Рәсүлебез бу сүзне Әссәләмү дип аңлар, дип уйладылар. Рәсүлебез, аларга **сезгә дә,** дип төртелмичә генә матур итеп җавап бирә. Рәсүлебезнең бу сүзе халкыбызның, **таш атсалар да, син аш ат**, дигән гыйбарәсенә туры килә». *(Илдар хәзрәт Хәйруллинның «Ислам дөньясында мең дә бер сорау» китабыннан, Уфа, 2009, 144–145 нче битләр).*

Халкыбызда өйгә кергәндә, кергәч сәламләшү, хәл-әхвәл сорашуның үзенчәлекле яклары бар. Язучы **М. Мәһдиев** бу турыда менә ничек искә ала:

– Тынычлык, иминлек бик кадерле. Ул безнең халыкның рухына сеңгән иде. Әнә шуңа күрә карчыклар кеше өенә килеп кереп түргә узгач, сәкегә әдәп белән генә янтаеп утырып, болай сүз башлыйлар иде:

– Хәерле бәрәкәт бирсен йортка, исән-сау торамсыз?

Безнең авылда «исәнмесез» дип түгел, әнә шулай мәгънәле, озын итеп сәламләшәләр иде. Ирләр исә урамда очрашканда, йортка кергәндә бик гади сүзләр белән болай исәнләшәләр:

– Ни хәлләрдә тагын? Яки, ни хәлләрдә ятасыз тагын?

Мондый исәнләшүдә ниндидер кайгыртучанлык, әдәп, әхлак нормалары чагыла, тынычлык, иминлек теләү сизелә иде». *(«Торналар төшкән җирдә» әсәреннән).*

Йортка дога кылып, хәл-әхвәл сорашу халкыбызның бик

матур гадәтләренең берсе. Шунысы куанычлы: әлеге гадәт хәзер дә дәвам итә.

Шулай ук аерылышканда кешеләр белән саубуллашырга кирәк. Бу алар арасында дошманлык юк, үзара яхшы мөнәсәбәтләр дәвам итәчәк, дигәнне аңлата. Гадәттә, **сау булып торыгыз, исәнлектә күрешергә язсын, күрешкәнчегә кадәр, исән булыгыз, сау бул, хуш** сүзләрен аерылышканда, чыгып киткәндә әйтәләр**. Хуш** сүзендә мәгънә аермалыгы бар. Мәңгелеккә аерылганда (үлем алдыннан), яңадан очрашмаслык, күрешмәслек булып аерылганда **хуш** сүзен кулланалар.

– Хуш дип әйтмим әле, күрешербез, бәлки, гомер көзләрендә булса да! – дигән шигырь юллары исемә төште әле. Мин дә сезгә хуш дип әйтмим әле. Күрешербез, иншаллаһ!

15. Алла боерса, хатын, ишек ач! (дәвамы).

Берәр эшкә керешер алдыннан, киләчәкне планлаштырганда **Аллаһ боерса, Алла бирсә, Аллаһы теләсә, Ходай кушса, Ходай насыйп итсә, Аллага тапшырып** кебек сүзләрне кулланабыз.

Элеккерәк заманда бер кеше йомыш белән калага барырга җыена икән. Хатыны:

– И синкәем, иртәгә бара алырсыңмы икән? Көн дә бозылырга тора. Әллә бүтән вакытка калдырып торасыңмы сәфәреңне? – дигән.

– Кичектергесез эшләрем бар. Барам булгач, барам, – дигән ире.

– Алла бирсә! – дип әйт дигән хатыны.

– Бирсә дә барам, бирмәсә дә барам! – дигән тегесе. Ярар, икенче көнне иртән үк ир юлга кузгалган. Ярты юлга җиткәч, бара торган җирдән, аты егылып үлгән моның. Тиресен булса да тунап алыйм, ичмасам, берәр файдага ярар, дип, атын тунап ятканда, моның янына стражниклар килеп чыккан. Үземнең атым, дигәнгә дә ышанмыйча, кулга алып, төрмәгә ябып куйганнар. Гаепсез икәнен ачыклаганчы, атна-ун көн үткән. Ярар, чыгарганнар моны. Авылына кайтып җиткән бу көч-хәл белән. Капка төбенә җитәр-җитмәстән үк: «Алла бирсә, хатын, ишек ач!» – дип кычкырып җибәргән ди. Монда инде аңлатма кирәк түгел!

Шулай ук, **иншаллаһ** сүзе дә – Аллаһ боерса сүзенең синонимы. Иншаллаһ, кайтырбыз. Иншаллаһ, башкарып чыгарбыз, эшләрмен, иншаллаһ.

Сөбханалла (Аллага – дан) – машалла. Соклану, гаҗәпләнү, хуплауны белдерү өчен кулланыла торган сүз. Шагыйребез ***Г. Тукай***ның ***«Сөбханалла, сөбханалла»*** дигән шигыре бар.

Сабый чакта укытканда мине хәлфә,
Рәхмәт аңар, өйрәтте бик яхшы нәрсә:
– Сөбханалла, диеп әйтү тиеш, – диде, –
Бер мән яңа гына тулган айны күрсә.

Шагыйрь сөйгәненең йөзен, башын тулган айга, кашларын яңа туган айга охшата да:

Укыйм чынлап: «Сөбханалла, сөбханалла!» – ди.
Әгәр күрсә шул матурны Гайнетдиннәр,
Гади генә Котбетдиннәр, Шәмсетдиннәр,
«Сөбханалла!» дию кая аларга соң!
Укымаган алар, бернәрсә белмиләр.
Әгәр, хәлфә, мин дә шулай надан булсам,
Синнән гыйлем алалмыйча калган булсам,
Әйтер идем, шулар кебек мин гыйрфансыз
(аң-белемсез, надан):
«Әй-йәй, бигрәк матур икән **чукынган кыз!»**

Кеше өстендә берәр матур кием яки өендә яхшы җиһаз күрсәк, иң башлап, каян алдың, ди күбебез. **Котлы булсын**, диясе бит, югыйсә. Ягъни, бәхетле язмыш (кот – бәхет дигән мәгънәне аңлата) телим. Киемең өстеңдә, җылы тәнеңдә тузсын. Тагын да матуррагын алырга язсын, яки алган җиһазыгызның да файдасын, куанычын күрегез, дигән мәгънәләр ята бу сүздә. Котлы булсын, дигәнгә, **рәхмәт,** диясе генә кала.

Еш кына, **рәхмәт белән тун тектереп булмый, коры рәхмәт, рәхмәткә генә эшләү, рәхмәтне кесәгә салып булмый, теге рәхмәтең дә бернәрсәгә дә ярамады** һ.б. шундый сүзләрне әйтеп, **рәхмәт** сүзенең дәрәҗәсен төшерәбез. Ә бит **рәхмәт** – Аллаһының 99 исеменең берсе. «Аллаһының 99 исеме бар. Боларны санаган кеше җәннәткә керер», – диелә. *(«Дога – и исми әгъзам», «Дәгъват» нәшрияты, 4 нче бит, 2011).* «Исми әгъзам» догасы менә болай башлана: «Һүәллааһу ләә иләәһә иллә hүә әр-Рәхмәнү әр Рәхимү» (шунда ук). Рәхман

һәм Рахим сүзләре **рәхмәт** тамырыннан барлыкка килгән икән бит. Ә **рәхмәт** сүзе шәфкать, мәрхәмәт, аяу, кичерү дигәнне аңлата. Аллаһ сиңа да мәрхәмәтле, шәфкатьле булсын; гаепгөнаһларыңны кичерсен, ягъни. **Коры рәхмәт, рәхмәткә генә йөрү** дип әйтеп, без Аллаһыны танымыйбыз, аның исеменнән йөз чөерәбез икән бит! Элек әби-бабайлар балаларга күбрәк рәхмәт җыярга кушалар иде. Рәхмәт үзеңә рәхмәт булып кайтыр, диләр иде. Ул вакытта бу сүзләрнең нинди тирән мәгънәгә ия икәнлеген аңламасак та, йөгерә-йөгерә суын да ташыдык, карын да көрәдек, утынын да керттек, сыер-сарыгын да көтүдән каршы алдык авыру яки карт-карчыкларның, әлбәттә, рәхмәт хисабына. Күрше-коланга да ярдәм итә идек. Хәзерге бала-чага акча өмет итә. Тәрбиясе шундыйдыр инде.

Элек бер бай кеше үзенә ярдәм иткән икенче берәүгә, рәхмәт әйтсәм күп була, дип, бер сыер биргән икән, дип сөйли иделәр безгә.

Урыс та бит, **спасибо,** ди. Спаси бог, сүзеннән. Аллаһ сакласын, Аллаһ ярлыкасын, диләр алар да.

Сәлам бирүдән башлаган идек, менә кая кадәр килдек! Гапгади генә күренгән сүзләр нинди тирән мәгънәләргә ия икән!

Кешеләр белән аралашу, сөйләм барышында тирә-яктагы вакыйгаларга үз мөнәсәбәтеңне белдерү өчен кулланыла торган сүзләр әле болар белән генә бетми. Күңелебездән аларны барлыйк һәм үз урыннарында матур итеп куллана да белик.

16–17. Исемнәр бакчасына сәяхәт

Кеше исемнәре, күренекле татар-башкорт шагыйре ***Шәехзадә Бабич*** әйткәнчә, гажәеп бер бакча. Аның байтак кына хатын-кыз исемнәренә карата күңел түрендә калырдай шигъри юллар тупланган **«Исемнәр бакчасында»** дигән әсәре бар.

Гөлнур туташ, гөлең бар бит, нурың бар бит,
Күзеңдә сур, күкрәгеңдә нурың бар бит,
Сигез ожмах каршысында синең белән
Җир мактанган: «Минем дә бер хурым бар», – дип.
Айзирәк кыз, ай зирәк кыз, үткер теле,
Изгеләрдән-изгерәктер, юктыр кере.
Әй Зөләйха, бер елмайсаң исертәсең,
Бер минутта биш туңдырып, биш эретәсең.

Җимеш бакчасында төрле агачлар үскән кебек, исемнәр бакчасында да төрле җимешләр – исемнәр бар. Безнең телебездә күркәм исемнәр бик күп. «Халкыбыз кеше исемнәре дөньясында мәгънәви матурлыкка омтылуның классик үрнәкләрен тудырган. Үзенең идеалларын һәм тарихын чагылдыра торган исемнәр хәзинәсен барлыкка китергән», – ди «Татар исемнәре сүзлеге»н (1981) төзеп бастырган тел галиме Г.Ф. Саттаров. Аның бу китабына – 10 мең, төрдәшләре белән 15 мең кеше исеме тупланган. Автор хәзерге татар исемнәре хәзинәсен җиде катламга аерып карый. Боларга борынгы заман исемнәреннән башлап, гарәп-фарсы алынмалары, рус теленнән һәм аның аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән интернационал исемнәрне һәм 1917 нче елдан соң барлыкка килгән яңа исемнәрне кертә.

Соңгы 10–15 ел дәвамында газета-журналларда исемнәр турында шактый гына язмалар, бәхәсләр урын алды. Төрле фикерләр бар. Яшьрәк буын яңача, заманча исемнәр кую ягында. Өлкән буын исә аларның ялгышларын кабатламаска, татарча, мәгънәле, аһәңле исемнәр сайларга чакыра. Чыннан да, 1930–40 нчы елларда, аеруча интеллигенция вәкилләре арасында тузга язмаган яки интернационал исемнәр кую модага кергән була. Бу уңайдан язучы ***Рабит (Роберт) Батулла*** менә нәрсә ди:

– Балага үз милләтеңнең исемен кушарга кирәк. Ул, әлбәттә, ата-ананың шәхси эше, әмма баланың шул исем белән гомер буе яшисе бар. Халыкның ул Европа исемнәренә авызы да көйләнмәгән. Миңа авылда Рабит дип эндәшәләр иде. Кечкенә энемә әти Эдуард дип кушарга теләгән иде. Миңа ул вакытта 16 яшь. Сугыша-талаша, аңа Рәсим дип куштырдым. Хәзер энем кунакка килгән саен: «Абый, миңа матур исем куштыргансың», – дип рәхмәтләр укый. Үз тәжрибәмнән чыгып, улларыма матур, чын татар исемнәре – Нурбәк һәм Байбулат дип куштым. Балага исем кушканда ата-аналар әдәбиятка да мөрәҗәгать итсеннәр иде. Анда Сөембикә, Тархан, Фәрһад кебек матур исемнәр бик күп».

1970–80 нче елларда исә бертөрлерәк исемнәр басып алды балалар дөньясын. Аларны бер урынга тупласаң, 20гә дә тулмас, мөгаен. Илнар, Илнур, Алмаз, Ленар, Динар, Айдар, Айрат, Рөстәм, Руслан, Ләйсән, Эльмира, Эльвира, Алсу, Гүзәл, Айгөл, Гөлнара, Лилия һ.б. исемнәр класс саен икешәр, өчәр очрый иде хәтта. Бер авыл мәктәбендә бит ул!

Балага исем сайлаганда, ул исемнең җыйнак төзелешле, бозылмый торган, җиңел әйтелешле һәм барыннан да бигрәк яхшы мәгънәле һәм аһәңле булуы зарур, ди акыл утырткан өлкәннәребез һәм дин әһелләребез. Авар шагыйре Рәсүл Гамзатовның исемнәр турында бик кызыклы фикере бар: «Хатын-кыз исеменнән наз, гүзәллек, ягымлылык, җылылык бөркелеп торсын. Ә ир-ат исемендә көч-куәт, гайрәтлелек, ныклык, батырлык, кыюлык кебек сыйфатлар чагылсын», – ди ул. Борынгы бабаларыбыз да нәкъ шулай уйлаган. Татар халкында кеше исемнәренең иң борынгы өлешен тәшкил иткән төрки исемнәр әнә шул турыда сөйли. Аларның күбесен әле хәзер дә яратып кушалар. Мәсәлән, Арыслан, Тансык, Булат, Тимер, Айсылу, Арзу, Таңсылу, Алтынчәч, Айгөл һ.б.

Телебездәге исемнәрдә иң зур катлам – гарәп-фарсы сүзләре. Сан ягыннан иң зур күпчелекне гарәп исемнәре тәшкил итә һәм алар бүгенге көндә дә актив кулланыла.

Кеше исемнәре коллекциясе яңа исемнәр белән байый тора. *«Шәһри Казан» газетасының 17 март (2011)* санында кеше исемнәре турында шактый бай материал бирелгән иде. 2010 елда яңа туган сабыйларга кушылган иң популяр исемнәр турында да мәгълүмат бар. Малайларга: Тимур, Әмир, Кәрим, Әскәр, Данияр, Ислам, Радмир, Камил, Гадел, Морат, Шамил, Тимерхан исемнәре кушылган икән. Кызларга исә Сафия, Камилла, Мәликә, Милана, Азалия, Амалия, Самира, Ралина, Диана, Ясминә исемнәре куелган. Малайларга татарча яңгырашлы исемнәр бирелсә дә, кызлар һаман «Европалашу» ягында.

Бер танышым оныгына нинди исем куярга микән дип киңәш сорый. Кыз балага матур, мәгънәле исемнәр күп инде ул, дим. Мәсәлән, Зәйнәп, Зөләйха исемнәрен куя башладылар, соңгы вакытларда, дим. «Һи, ул исемнәрне бездә Дәйнәп белән Дөлихага әйләндереп бетерәчәкләр», – ди бу. Хәзер инде без (Мөслим, Минзәлә, Актанышлар) дә әкренләп «з» авазын «д»ләштерүдән арына барабыз, бозмаслар иде әле (соңрак танышымның оныгына Милана исеме куйганнарын ишеттем). Татар халкы әйләндерергә ярата инде ул. Соңгы ун елда кызларга Алинә, Алисә, Камилә, Адилә, Газизә, Ясминә кебек исемнәр куя башладылар. Ләкин бу исемнәрне Алиса, Алина (хәтта Алена), Камилла, Аделя, Азиза, Жасминга әйләндерүне чүпкә дә санамыйбыз! «Шәһри Ка-

зан» газетасының алда әйтеп кителгән санында «Әти-әниләргә киңәшләр» бүлегендә мондый пункт бар:

– Мода артыннан кумагыз. Мода тиз бетәчәк, ә исем гомерлеккә калачак.

Шулай инде, яшьләр үзләренчә уйлый, картлар үзенчә. Әле узган гасырның 50 нче еллар азагында булган хәл. Мәүлет аенда бер яшь гаиләнең улы туа. «Улым, Мәүләветдин кушыйк балага», – ди икән яшь ирнең әнисе. «И әнкәй, ул этдин-метдиннәр күптән бетте инде», – дигән улы һәм балага заманча исем куйдырган. Шулай, һәр заманның үз законы, үз җыры. Ләкин өлкәннәр сүзендә акыл, тәҗрибә барлыгын да онытмаска кирәк.

Адәм баласының язмышы исеменнән билгеләнә, диләр бит. Гата, Һибәт, Нияз, Һәдия, Наил, Наилә исемнәре «бүләк» мәгънәсенә ия. Аллаһ бүләге, ягъни. Мондый исемнәр куелган кеше озын гомерле була, ди, чөнки бүләкне кире алмыйлар (әмма берәү дә мәңгегә килмәгән). Шул исемнәргә ия булган берничә кешене беләм. Әллә ничә үлемнән калып, озын гомер кичергәннәр күбесе. Габбас – кырыс, Сәгадәт – бәхет, уңыш, Гаяз – ярсу мәгънәләренә ия икән. Азат, Ирек, Илгиз, Илгизәр исеме кушылган малайлар башбирмәс булалар, ди. Чөнки ирекле, хөр, буйсынмас дигән мәгънә ята бу исемнәрнең нигезендә.

«Чит илгә баргач бер кыздан исемен сорадылар. Зания дигәч, гарәпләр аптырап китте. Зания ул – фахишә дигән сүз. Ишетүемчә, шуннан соң ул кыз исемен Санияга алыштырган», – дип яза Р. Батулла.

Кызлар өчен бик матур, мәгънәле исемнәр: Ләйлә, Хәят, Мәдинә, Мәликә, Газизә, Әминә, Мәрьям, Язилә, Диләрә, Дилбәр, Кадрия, Ширин. Һәр заманга яраклы исемнәр!

Малайлар өчен: Рәшит, Муса, Салават, Сөләйман, Сәйдәш, Искәндәр, Газиз, Хәйдәр, Хәсән, Газинур исемнәре бик муафикъ булыр иде.

Кеше исеме – шәхес турында вакыт чикләрен белми торган тарих хәбәрчесе, аның мәңгелек үлемсез ядкаре, хатирәсе.

Яхшы исем кыйммәт барсыннан да,
Аннан тугры дусны күрмисең;
Безнең хакта мәңге ядкарь саклап,
Картаймыйча яши һәр исем.

(Гамзат Цадаца)

II кисәк

СҮЗЛӘР ҺӘМ ГЫЙБАРӘЛӘР ДӨНЬЯСЫНДА

Телдәге сүзләр – алар халыкның сүз, тел байлыгы гына түгел, ә шул халыкның тарихы да. Сүзнең килеп чыгышын тикшерә башласаң, ничә гасырлык тарих төпкелләренә төшеп, заманнар, чорлар аша үзебезгә әйләнеп кайтырга була. Сүзләр, гыйбарәләр – тәрбия чарасы да. Аларга тирән мәгънә, фәһем салынган. «Тел күрке – сүз» тапшыруларының берсендә бу темага бераз тукталган идем («Сүзләрнең дә тарихы бар» язмасы). Алга таба телебездә урын алган, кулланылышта йөрүче яки ялга туктаган сүзләр һәм гыйбарәләр турында сөйләшербез, дөрес кулланылырга тиешле вариантлары белән танышырбыз.

Сүз турында беләбез инде. Ә нәрсә соң ул гыйбарә? Гыйбарә – сүз әйләнмәләре, әйтемнәр, телебездә гаять киң таралган тел күренешләре.

1. Маңкорт

Хайван дияр идең – аңы бар,
Мәет дияр идең – җаны бар,
Ярлы дияр идең – малы бар,
Ахмак дияр идең – саны бар.
...Һәммәсе, ләкин юне юк,
Кеше дип әйтерлек җире юк.

***(Илдус Гыйләҗев.** «Маңкорт»)*

Бу атама соңгы 25–30 ел эчендә телебездә киң кулланылышта йөри башлады. Кыргыз халык язучысы Чыңгыз Айтматовның «Гасырга сузылган көн» («Бер көн – бер гомер» дигән тәрҗемә варианты да бар) романы аша кереп китте. Милли хисләрен, тарихи хәтерен югалткан, туган телен һәм мәдәниятен онытkан, шәхси файда өчен үз халкы мәнфәгатьләрен корбан итә торган кешеләрне сыйфатлаучы төшенчә бу.

Борынгы заманнарда кыргыз далаларын басып алган жунжуаньнар үз кулларына төшкән әсирләр белән бик рәхимсез

кыланганнар. Аларның күбесен коллыкка сатканнар, ә үзләре янында каласы әсирләрнең башына **шри** дигән башлык кидереп, җәзалый-җәзалый, хәтерен җуйдырганнар. Шри башлыгы дөя тиресеннән ясалган. Кырып алынган башка шри кидереп, кол аны сала алмаслык итеп бәйләп куйганнар. Берничә көннән каты тирене тишеп чыга алмаган чәч эчкә – баш тиресенә таба үскән, колның миен томалаган. Нәтиҗәдә, җәзаланучының мие бутала, исе-акылы югала. Ис-акылсыз, аңсыз кол маңкорт була да инде, ягъни миен корт ашаган, мисез кеше. Татарча яңгырашы мәнкорт булырга тиеш.

Маңкорт үзенең кем икәнен, кайсы ыруг кешесе икәнен, туган җирен, хәтта үзенең исемен белми, балачагын, әтиәнисен хәтерләми – кыскасы, ул үзенең кеше затыннан булуын аңламый. Карусыз, күндәм, буйсынучан һәм зарарсыз була. Маңкорт, эт кебек хуҗаларын гына таный, башкалар белән аралашмый. Бар белгәне – тамагын туйдыру. Кушкан эшне сукырларча бирелгәнлек белән тырышып башкара. Маңкортларга иң пычрак, авыр эшләр эшләткәннәр. Алар, иясе ни кушса – шуны берсүзсез үтәгәннәр. Ч. Айтматов әсәрендәге маңкорт та, хуҗасы кушуы буенча, ук атып, үзенең газиз анасын үтерә.

Маңкортлык милләт, халык өчен куркыныч күренеш. Ул милләтне юкка чыгаруга китерә, коллык психологиясе тәрбияли. Ә дәүләт өчен коллар белән идарә итү җиңелрәк. Милләтпәрвәр затларыбыз маңкортлыкка каршы чыгалар.

Иң асыл ирләрең бүген нинди иман тапты?
Җылы урын, тамак, дан, диеп, денен, телен сатты.
Сатарга әзер сине дә – үз әнкәсен, халкым!
... Уйсыз, мәнсез маңкорт бүген
Милли бакчаң таптый, оялмый һич, халкым!

(Рәдиф Гаташ)

2. Тели белсәң – теләк...

Көндәлек проблемалар, тормыш-көнкүрештәге авыр хәл ителә торган мәсьәләләр, башка килгән кайгы-хәсрәтләр, борчумәшәкатьләр, авырлыклар турында сөйләшкәндә, еш кына, ярар, **исәнлек кирәк**, барысы да җайланыр, дигәннәрен ишетергә туры килә. Шул уңайдан бер гыйбрәтле мисал. Бервакыт, **исәнлек**

кирәк, дигәнгә, урта яшьләрдәге бер ир: «Мин исән булып, 5–6 ай, кеше күзенә карап, кеше ярдәмен көтеп, больницада ятып карадым инде. Элекке әби-бабайлар, **исәнлек-саулык кирәк**, дип, бик белеп, дөрес әйткәннәр. Саулыгың, сәламәтлегең булганда гына яшәү матур һәм мәгънәле икән», – диде.

Чыннан да, әби-бабаларыбыз һәр сүзнең хасиятен тоеп, үз урынында кулланган. Балаларга теләк теләгәндә дә, иң элек **исәнлек-саулык**, аннан, бәхет, тәүфыйк сораганнар.

Бәхетне кем ничек аңлый бит. Мәсәлән, исән-сау булу – үзе бәхет. Исән-сау кеше бәхетне үзе таба (минем белән килешмәүчеләр дә булыр). Ләкин бәхет тәүфыйк белән булганда гына озын гомерле. Тәүфыйксыз бәхет озакка бармый.

Радио-телевидениедән, газета-журнал битләрендә бирелгән котлауларда яки юбилейлар уңаеннан оештырылган мәҗлесләрдә бер күңелгә тия торган сүз шактый калыплашып китте. Теләкләр теләгәндә, ата-аналарга, **балаларыгызның рәхәтен күрергә язсын**, диләр. Мин үзем бу тезмәне аңлап бетерә алмыйм. Дөньяның, тормышның рәхәтен күреп, тоеп була. Ә ата-ана баласының **файдасын** күрергә тиештер, бәлки. Үстергән балаларыгызның куанычларын, файдасын, миһербан-шәфкатен күрергә язсын дию дөресрәк булмыймы икән?

Олыгая башлаган кешеләр авызыннан: «**Аз авыру – асат үлем»** яки «**аз авыру – җиңел үлем бир, Ходаем», –** дип теләк теләү еш ишетелә. Тели белсәң – теләк, тели белмәсәң – имгәк, дигәне дә бар бит әле аның. Асат, җиңел үлем нинди була соң ул? Минем аңлавымча, үлгәнеңне белми дә каласың, дигән сүз бу. Ә кайсы очракта белми-сизми калырга мөмкин? Нинди дә булса көчле катастрофага (машина, самолёт, корабль, теплоход), фаҗигагә очраса, шундый үлем көтә кешене. Көтмәгәндә башыңа каты әйбер белән сугып та теге дөньяга җибәрергә мөмкиннәр сине. Белми дә, сизми дә каласың! Күп инде мондый мисаллар. Ләкин болар берсе дә юньле үлем түгел, хәерле үлем түгел. Элекке әби-бабаларыбыз «аз авыру – хәерле үлем» дип теләгәннәр. Ягъни үз өеңдә, үз урыныңда, балаларың, якыннарың янында, барысы белән дә бәхилләшеп, әйтәсе сүзләреңне әйтеп, 1–2 көн булса да урын өстендә ятып үлүне күздә тота әлеге гыйбарә. Үлем бервакытта да җиңел була ал-

мыйдыр ул. Читтән карап торучыга җиңел кебек тоелса да, җан бирүче кеше үзе генә беләдер моны.

Райондашыбыз, язучы, Г. Тукай бүләге лауреаты Фоат абый Садриевның «Таң җиле» романын укымаган кеше сирәктер яки бөтенләй юктыр. Әсәрнең төп герое Нуриасманың хәле авырайгач, аның янына балалары, якыннары, ахирәт дуслары, күршеләре җыела. Ул аларга бәхиллеген биреп (каенсеңлесе Бәриядән кала), чиста урын-җир өстендә таң алдыннан бакый-лыкка күчә.

«Нуриасма түземсезлек белән таңны көтте. Ул гомере буе таң белән торды, таң белән ятты. Җир йөзендә таңнан да матур нәрсә юк. Таң атканда бөтен нәрсә – сулар-һавалар да, үләннәр, чәчәкләр, җиләк-җимешләр дә шифалы. Барлык тереклек ияләренең җан җылысы җир өстенә җәелгәндә, таң җиле булып исә...

Менә таңның ал нурлары өйгә керде.

– Килдеңме? – диде Нуриасма. – Рәхмәт... Мин сине көттем... Тагын күрдем... Нурыңны күзләремә алам...

Аның тавышы ишетелер-ишетелмәс кенә чыкты, сүзләрнең дә кайберләре генә аңлашыла иде.

– Әллә саташа инде? – дип пышылдады Маһинур.

– Тавышланмагыз, таң белән сөйләшә ул, – диде Мосаллия.

– Тиздән мин китәрмен... – диде Нуриасма. – Мине ямьсез итеп күрсәтмә... Мине юксынма, балаларны да үзең белән торырга күнектер...

Ул матур итеп елмайды».

(***Ф. Садриев.*** «Таң җиле»)

Яшь түкмәгез хушлашканда –
Җирдә бармы китми калган?!
Ай калыксын, сулар аксын,
Кош сайрасын, талга кунып,
Су сибегез бисмиллалап,
Рәнҗемәсен гөлләр сулып! –
Күзәтермен малай булып,
Чардуганнар арасыннан...

(Рим Идиятуллин,
Башкортстанда яшәп иҗат итүче шагыйрь.)

3. Хикмәтле гыйбарәләр. Сүзләрнең дә хикмәте бар...

Бүгенге тапшыруыбызда телебездә кулланыла торган тагын берничә гыйбарәгә тукталырбыз.

Кыз авырмы, тоз авырмы? Элек бу сорауны өйләнергә авырсынучы кешегә бирә торган булганнар. «Кыз алу авыр түгел, мәһәре авыр. Анысын да түләр идек, аннан да бигрәк, казнага түләү өчен тоз ташу авыр, димәктән калган сүз», – ди бу турыда галим Н. Исәнбәт.

Россиядә, 17 нче гасырда, ничәмә төрле салымнар өстенә, һәр өйләнгән кеше казнага бер пот тоз салымы да түләргә мәҗбүр ителгән. Ул тозны көньяк Тоз Түбә һәм Баскынчак (хәзерге Казахстан) күлләреннән арба белән ташыганннар. Татарлар өчен бу бик авыр һәм табигатькә ят, начар эш булып тоелган. Чөнки, алар уенча, тоз ул, су һәм һава кебек, табигатьтә буш һәм түләүсез яткан гомуми бер азык. Өйләнү чыгымнары тоту өстенә, никах салымы өчен, меңнәрчә чакрымнан тоз ташып йөрергә мәҗбүр ителүгә хөкүмәткә каршы бунтлар да («тоз бунтлары» – 1648 ел) күтәрелгән.

– Кайчан кайтыр – яз кайтыр. Яз кайтмаса – көз кайтыр. Йөге белән тоз кайтыр. Тоз артыннан кыз кайтыр.

Бу такмазада тозга яз китүченең көз көне генә әйләнеп кайта алуы әйтелә.

Менә бит, нинди заманнар булган, диярга генә кала. Бу безнең тарихыбыз да.

Элегрәк, совет чорында, менә бу әйтем популяр иде: «**Яхшылык эшлә дә суга сал – балык белер, балык белмәсә – халык белер»**. Без, укытучылар да, заманында, балаларга бу әйтемне аз кабатламаганбыздыр. Ә бит бу әйтем идеологиягә туры китереп җайлаштырылган булган. Әби-бабайлар аны болайрак әйткән: «**Яхшылык эшлә дә суга сал – балык белер, балык белмәсә – Халикъ белер, ягъни Аллаһы Тәгалә белер»**. Аллаһы Тәгаләнең 99 исеме бар, шуның берсе – Халикъ (йәә Халләку, йәә Аллаһу). Әйе, һәр кылган гамәлләребезне күрүче һәм белүче, дөрес итеп бәяләүче – бер Аллаһтыр.

Ахыры хәерле булсын. Без, хәзерге заманның сабырсыз, чәүчәләк бәндәләре, берәр авырлык, башка бәла килсә, ах-ух

киләбез, төшенкелеккә биреләбез, хәтта яшисе килмәс дәрәҗәгә җитәбез. Ә элекке әби-бабаларыбыз телендә бик мәгънәле һәм тынычландыра торган сүз булган: **ахыры хәерле булсын!**

Якташ шагыйребез, шулай ук Тукай премиясе лауреаты, Яңа Сәет егете **Зөлфәт**нең менә мондый дүрт юллы шигыре бар.

Кара кайгы була ак бәхеткә,
Ак сөюгә – кара хыянәт.
Ак яшәүне кара үлем кисә,
Ак-карадан тора бу хәят.

Элек заманда берәүнең бик яхшы аты булган. Атка кызыгучылар, яхшы гына бәягә сораучылар да булган, ләкин хуҗасы атны беркемгә дә сатмаган. Бервакыт утлап йөри торган җиреннән ат югалган. Күршеләре әйтә икән: «Менә, кешегә дә сатмадың, үзеңә дә булмады!» Ә ат хуҗасы исә: «Ахыры хәерле булсын», – диюдән башка сүз әйтмәгән. Бер атна-ун көннән теге югалган ат үзенә унлап ат ияртеп кайтып кергән.

Атларны өйрәткән вакытта, хуҗаның улы, ат өстеннән егылып төшеп имгәнгән.

– Ат-ат, дия торгач, улыңны имгәттең, – дип гаепләгәннәр тагын авылдашлары.

– Ахыры хәерле булсын, – дигән агай, сүз озайтып тормыйча.

Озакламый сугыш башланган. Авылның гренадердай ирегетләре сугышка китеп үлеп калганнар. Агайның улын, гарип булганга, сугышка алмаганнар. «Синең, ичмасам, гарип булса да, улың үз яныңда, безнекеләрнең сөякләре кайларда исраф булып ятадыр?» – дигәннәр авылдашлары, күз яшьләре белән.

Ата-баба гадәте буенча,
«Хәерле...» дип башлыйк эшләрне,
Хәерле таң, хәерле көн телик,
Хәерле дип телик кичләрне.

(Ш. Җиһангирова)

Ни булса да хәерлегә юрыйк! Шулай итсәк, эшләребез һәрчак уң булыр!

4. Үзеңнеке үзеңә кайтсын

Кемгәдер яхшылык, игелек кылсаң, чын күңелеңнән ярдәм итсәң, **үз изгелегең үзеңә кайтсын,** диләр. **Үзеңнеке үзеңә кайтсын** дигәне дә бар. Ике әйтем арасында, бер караганда, аерма юк та кебек. Ничек кенә бар әле? Алдагы хикәябез шуңа мисал. Галия исемле ханымның сөйләгәннәреннән:

«Мин гомерем буе икейөзле булдым. Үзем җиңел холыклы. Тиз аралашучан, гел җиңел эшләрдә генә эшләдем. Яшем 18 дә юк иде әле, чибәр генә егеткә кияүгә дә чыгып куйдым. Каенанам бик акыллы хатын иде. Бер генә бала тудырып өлгергән, ире асылынып үлгән. Нәрсә өчен икәнен дә белмәгәннәр. Мин, каенанам бик сабыр булганга, дус яшәгән булып кыландым. И яратмадым инде үзен. Үзе гел җайлап, бөтен эшне эшләп, тормышны үз җилкәсендә алып баргач, миңа талашырга җай юк кына бит. Ә минем өйгә хуҗа булып, ирем белән генә яшисем килә. Иремә охшаган бер малай, үземә охшаган бер кыз да табып куйдым. Балаларның ничек үскәнен дә белмим, каенанам үстерде, минем бер гаебемне дә иремә сөйләмәде. Яшьлек галәмәте булгандыр инде, эчкәли башладым. Бер чит ир белән йөреп алдым. Каенана өйдә юктыр, дип белеп, өйгә бер алып та кайткан идем, өстебезгә кайтып керде. Утырып елады гына. Бервакыт малаем үлем хәлендә кала. Каенанам, машина табып, баланы больницага алып китә. Ә мин ул вакытта сөяркәм белән идем. Кичкә генә кайттым. Балам турында ишеткәч, больницага йөгердем. Улыма операция ясаганнар, каенанам аны саклап утыра иде. Миңа шундый иттереп карады, ләкин авыр сүз әйтмәде. Шуннан соң эчүемне дә, йөрүемне дә ташладым.

Ул яхшы булган саен минем ачуым килә, гаебен эзлим. Иремә гел зарланам. Туйдым каенана белән яшәүдән, үзем хуҗа булып яшисем килә, дим. Балалар үсте бит инде, ялгыз ирләр күп, әниеңне берәрсенә кияүгә бирергә кирәк, дим. Ирем мине бик ярата, аерылып китүемнән курка. Юк гаепне бар итеп, миңа ярарга тырышып, әнисен рәнҗетә. Ураза вакытларында сәхәр ашаганда, кич намаз укый башласа, утны сүндереп, счётчиктан пробканы алып куя, өйдән куа. Ул табынга утырганчы, без өстәлдәге ризыкларны ашап куябыз.

Андый вакытларда да сүз әйтми, шыпырт кына догаларын укып, табында калганны ашый да, табынны җыештырып, аминын тотып китеп бара. Ә бер көнне ирем бер бабай иярtеп кайткан. «Әнине сиңа кияүгә бирәм, алып кит бүген үк», – ди. Әнисе бүлмәсенә кереп елады».

Галиянең каенанасы бик сабыр карчык булып чыга. Барлык әр-хурларга да түзә. Пышылдап кына Ходайдан үзенә сабырлык сорый. Үзе гел елмаеп, ап-ак яулыктан, чиста киенеп йөри, беркемгә зарланмый. Беркөнне Галия эшкә китәргә әзерләнеп йөри. Каенана иртәнге эшләрен бетереп бүлмәсенә кереп ята. Галия инде чыгып китәм дигәндә генә, ул аны үз янына чакырып ала. «Галия, бүген никтер хәлем юк. Сыерны да авырлык белән көтүгә кудым. Ятып торам бераз. Минем белән ул-бу була калса, бәхил барыгызга да. Балалар үсте инде, иреңне караштыргала, әтисе кебек була күрмәсен. Синең белән яхшы яшәдек, рәнҗемим. **Үзеңнеке үзеңә кайтсын,** балам», – ди.

Галия эштән кайтуга, каенана мәңгелеккә күчкән була инде.

– Каенанам үлгәч, кеше янында еласам да, эчемнән бик сөендем. Иркенәеп калдым, шундый рәхәт! – ди ул.

Әмма Галиягә шул рәхәттә озак яшәргә насыйп булмый. Каенананың ел ашын уздыруга, ире асылынып үлә. «Нигә икәнен дә белмәдем, язу да калдырмаган, ичмасам», – ди хатын. Шуннан тормышның бөтен нужасы аның җилкәсенә кала. 34 яшендә, хәтта өйләнергә дә өлгермәгән улы, бабасы һәм әтисе язмышын кабатлый. Кызы төрмәдән чыккан берәүне йортка кертә. Өйдәге бөтен әйберне сатып эчеп бетерәләр. Хәзер Галиягә үз өендә урын юк. Пенсия алганын саклап кына торалар. Кызы исә: «Хатыны үлгән берәр бабайга кияүгә чык, безне дә ашатырсың, үзең дә тук булырсың», – дип мыскыллый. «Күземне йомам да, каенанам, ирем белән яшәгән вакытларны уйлап сагынам. Шул вакытларны кире кайтарасым килә», – ди ул. Каенанасы каберенә барып елый. «Бир миңа бер киңәш. Гаебем нәрсәдә? Ничекләр яшим?» – ди, өзгәләнеп. Үзе җавабын да бирә: «Исән булса әйтер иде, Аллаһ бар ул, Галия. Барысы да үзеңә кайтты. Хәзер соң инде, дияр иде», – ди.

(«Татар мөселман календареннан», 2005 ел).

Үткән гомремнең әрнүе йөрәгемнән китмидер,
Зая үткән яшь гомерләр янә әйләнеп килмидер.
Бераз гомер сөрер өчен үстергән буйларымны,
Алданрак уйламадым хәзерге уйларымны.

(19 нчы гасыр шагыйрәсе
Газизә Сәмитова)

5. Байлыгыңа масайма, дәрәҗәңә таянма, саулыгыңа инанма!

Безнең халыкта **саран** сүзенең берничә синонимы кулланыла: саран, жмут (русларның жмот сүзеннән), кысмыр, куркүл, комсыз, карун... Саранлык – кеше тормышын күңелсезли, бәхетен киметә торган күренеш. Пәйгамбәребез дә үзенең бер хәдисендә: «Гөнаһлы кеше генә саранланыр», – дигән. Саран синонимының мәгънә ягыннан иң югары ноктасында торган **карун** сүзенә тукталып китик.

Карун – татар телендә саранлык символы. «Ул бит карун, аннан кыш көне бер уч кар да ала алмыйсың», – дигән сүзләрне телебездә шактый еш кулланабыз.

Карун сүзе безнең телебезгә «Корьән»нән кергән икән. Димәк, **Карун** – Корьәни шәхес, тарихи шәхес**. Карун (Карун әл-Абад) –** Муса пәйгамбәрнең кардәше икән. Ул бик бай булган. Риваятьләргә караганда, аның хәзинә ачкычларын берничә баһадир көчкә күтәреп йөргән. Ул алтын капкалы, алтынланган сарай төзеткән хәтта. Үзенең байлыгы белән бик масайган. Каверне аңа: «Байлыгың белән масайма, Аллаһы мактанчыкларны сөймәс», – дип тә карый. Әмма Карун, тәкәбберләнеп, кардәше Муса галәйһиссәләмнән көнләшә һәм аның дәрәҗәсен үзенә алырга тели.. Аллаһы Тәгалә Карунны кисәтеп әйтә: «Аллаһның сиңа биргән мөлкәтеннән зәкәт, сәдака биреп, ахирәт көненә әзерлән. Дөньядагы өлешеңне дә онытма. Аллаһы сиңа байлык биргән кебек, син дә кешеләргә юмарт бул». Карун Аллаһы Тәгаләнең бу үгет-нәсихәтенә каршы: «Бу байлыклар миңа бары тик гыйлемем аркасында гына килде», – ди.

Бу бәндәнең саранлыгы чиктән ашкан була. Үзенең кардәшләренә һәм кавеменә аз гына да өлеш чыгармый. Тәкәббер булганы өчен, Аллаһы Тәгалә әмере буенча, Карунны йорты-ние

белән җир йота. «Без Карунны зиннәтле сарайлары белән бергә җиргә уптырдык. Аллаһы каршында аны якларлык беркеме дә юк иде. Ул үзен-үзе якларлык хәлдә дә түгел иде», – диелә. Бу өзекләр *«Татар дини календаре»ннан» (2013 ел)* алынды.

Бу хакта **«Нәүрүз»** бәетенең борынгырак вариантында да телгә алынган.

Күрмәймесез Карунны,
Тотты кырык сарай алтынны,
Ахыр аны җир йотты,
Нәүрүз мөбарәкәбад.

*«Татар мөселман календаре»*ннан тагын бер өзек тәкъдим итәм: «Байлык гөнаһ түгелдер. Эшләп акча табу гыйбадәттер. Аллаһы Тәгалә «**нигъмәтләремне кулланганнарны сөярмен», «эшләгәнгә бирәмен**» ди. Хезмәт нәтиҗәсендә тупланган байлык хәләл вә мөбарәктер. Ә менә эш сөймәү, ялкаулык нәтиҗәсендә фәкыйрьлеккә төшү яки булган акчаңны хәрам максатларда сарыф итеп ярлы-ябагай булу хәрамдыр.

Аллаһы Тәгалә сабыр иткән фәкыйрьне сөйгән кебек, шөкер иткән байны да сөя. Ләкин шунысын да онытырга ярамый: байлык белән масаеп, тәкәбберләнеп йөрү хәрам була».

(«Татар мөселман календаре», 2011, 37 нче бит).

Халкыбызның бөек шагыйре Г. Тукайның **«Бәндәләр»** дигән шигыре бар. Байлык җыеп, зур дәүләткә ия булып та, халкына, кавеменә ярдәм итмәгән заман каруннары турында ачынып язган шигырендә мондый юллар бар:

Нинди күп бездә ятимнәрне талаучы бәндәләр!
Җантимерләрнең итек астын ялаучы бәндәләр.
Ярлыга ярты тиен артса, җылаучы бәндәләр,
Күзгә, ачларны аяп, төкрек сылаучы бәндәләр.
Бездә бар комган, читек, казылык сатучы бәндәләр,
Бармы ачларга сынык икмәк атучы бәндәләр!

Сәламәтлек, байлык, дәрәҗәнең безне сынар өчен бирелгәнен онытмасак иде!

6. Тырышлык бәхет китерер, ялкаулык ачтан үтерер

Телебездә сыйнфый катламнарны белдерүче сүзләр арасында фәкыйрьлек төшенчәсен аңлатучы берничә сүз бар: **фәкыйрь, мохтаҗ, ярлы-ябагай, гидай, былазау, хәерче**, **саилче, теләнче**. Болар синоним сүзләр булса да, мәгънә аерымлыклары бар. **Фәкыйрь** – гарәп сүзе булып, нәрсә салсаң да агып бетә торган тотрыксыз тишек чиләкне яки чокырга батып чыга алмый җәфалануны аңлата. **Ярлы –** үзебезнең төрки сүзе булып, чигенә чыгып, ярга килеп терәлеп, менә-менә ярдан төшеп китеп һәлак булу кебек төшенчәне аңлата.

Байлар, байлар бал эчә,
Урта байлар сыра эчә.
Ярлы мескен ни эшләсен,
Ярга ятып су эчә.

Фәкыйрьлек, ярлылык, хәерчелек – ислам диненең яратмаган, аңа каршы көрәшкән күренешедер. Шуның өчен мөселман, ризык һәм тормыш-көнкүрешен, яшәешен хәләл итү өчен көн-төн тырышырга тиеш, диелә. Ялкаулык, эш сөймәү, биргәнне көтеп яту, эчкечелек аркасында яки малыңны хәрам максатларда кулланып фәкыйрьлеккә төшүне дә халык та, дин дә мактамый. Кеше сәламәт икән, яшь һәм үз көчендә икән, һөнәре бар икән, үз алдына башкалардан ким-хур булмаска дигән максат куйган икән – ул ничек булса да фәкыйрьлек баткагына чуммаска тырыша.

Әйе, байлыкны, яхшы тормышны булдыру бик җиңел түгел, әмма аны туздыру, юкка чыгару өчен бик аз вакыт та җитә икән.

Кайчандыр бер хикәя укыган идем. Хикәянең исеме дә, авторы да хәтеремдә калмаган, әмма эчтәлеге, гыйбрәтлелеге белән күңелгә сеңеп калган ул.

Узган гасырның унсигезенче-унтугызынчы елларында булган хәл (комбедлар шул елларда төзелгән һәм эшләгән).

Бер авылда, тавык кетәге хәтле генә өендә, җиде баласы һәм пошмас, юбалгы, биләмче хатыны белән авылның ата ялкавы Кәтәнә Хәйрулла яшәгән. Җирен дә юньләп чәчмәгән, 5–6 тавыктан һәм бер кәҗәдән башка малы да булмаган. Революция булып, власть эшче-пролетариат кулына күчкәннән соң, авылда да шак-

тый үзгәрешләр була. Кәтәнә Хәйрулласын авылның иң ярлы, фәкыйрь кешесе буларак, комбед (комитет бедноты – ярлылар комитеты) рәисе итеп куялар. Комитет карары белән, рәисне авылның элекке бае яшәгән зур, матур йортка күчерәләр. Бай, гаиләсе-ние белән, Аклар армиясенә ияреп, качып киткән була. Иң беренче эш итеп, комбед рәисе, байдан калган яхшы атны җигеп, тарантаска җиде баласы һәм хатынын утыртып, үз карамагына кергән авыллар буйлап кунак булып, ашап-эчеп йөри. Бу эш бер айга сузыла. Көз, аның артыннан кыш җитә. Байдан калган утынны ягып бетергәннән соң, чират яхшы мебельләргә, аннан соң идән һәм түшәм сайгакларына җитә. Язга чыккан-да, өйдә бернәрсә калмый диярлек. Бары тик басып йөрер өчен берничә сайгак кала. Байдан калган кием-салымнар да озакка җитми. Чөнки хатын аларны юып мәшәкатьләнми, каралганнарын мичкә ташлап яндырып бара.

«Эшләргә өйрәнмәгән хуҗалык итә белмәс», «Ярлылыкка дару юк, ялкаулык белән кушылса», – дип халык белми әйтмәгән шул.

Байлыгы да бит аның өстәп торсаң гына арта. Шунысы да бар: үзең эшләп тапкан байлыкның гына кадере, бәрәкәте була.

Хәерче – бик ярлы кеше. Хәерчедән теләнчегә бер адым.

Бер карчык яшәгән ди. Җыйнак кына өе, тавык-чебеш, кәҗә асрый торган кечкенә генә булса да абзары булган. Өсте-башы да, ашау-эчүе дә үзенә күрә ярыйсы гына. Әмма үзе гел зарлана, мескенләнә икән.

– И мин хәерче бит, минем ише хәерчене кем тыңласын, минем ише хәерче кемгә кирәк? – ди икән, җае чыккан саен. Бервакыт, ут чыгып, әбинең бер әйберсе калмый янып беткән. Менә хәзер карчык әйтә икән: «И-и, элек мин бик бай булганмын икән! Менә хәзер мин чып-чын хәерче. Торыр җирем дә, ашар ризыгым да, кияр киемем дә калмады».

«Күпне өмет итсәң, аздан коры калырсың», дигәннәре шулдыр, мөгаен. Олыгайгач, булганына да шөкер итеп яшәү дә ярыйдыр.

Байлык – бер айлык, хәерчелек саклап тотсаң – гомерлек, дисәләр дә, кешелек һәрвакыт камиллеккә, яхшы яшәүгә омтылган. Чөнки ярлылык, фәкыйрьлек – милләт, җәмәгатьчелек һәм

дәүләт өчен дә куркыныч күренеш. Ә юньле дәүләт, үз чиратында, халкы, ватандашлары турында даими кайгыртырга тиеш.

7. Хикмәт әйтә белүдә

«Әйтә белгән авызда йомычка да йомры була, әйтә белмәгән авызда йомырка да дүрткырлы була», – ди халык мәкале.

Бер патша төшендә бөтен тешләре коелып беткәнне күрә. Бер төш юраучы моңа әйтә:

– Синең барча балаларың, кардәшләрең үзеңнән элек үләрләр.

Патшаның бик ачуы килеп, бу юраучыны төрмәгә яптырган.

Икенче көнне патша күрше шәһәрдән икенче бер төш юраучыны чакырткан. Анысы әйткән: «Син барча балаларыңнан һәм барча туганнарыңнан озынрак гомерле булырсың».

Патша бу юраучының сүзенә бик шатланган. Аңа бик күп бүләкләр һәм акча биреп, үз янына алдырган.

Бер галим янына төш юратырга дип ике кеше килгән. Аларның берсе: «Әллә нинди төш күрдем. Авыз-борынымнан кып-кызыл кан килә, имеш, – дип төшен сөйләгән. – Бу төшемнең тәкъдире ни булыр икән?» – дигән.

– Бәрәкалла, балам, гаять хасиятле төш күргәнсең. Бәхет сиңа көлеп баккан. Тиз көннәрдә дәүләтең тагын да артып, эшегез уңышлы булыр, – дигән галим.

– Карагыз инде, икебез дә бер үк төрле төш күргәнбез, – дигән икенчесе. – Минем дә авыз-борынымнан кисәк-кисәк кан китә, имеш.

Төш юраучының йөзе үзгәреп киткән: «Әй, балам, җитте, җитте. Зинһар, төшеңне сөйләмә. Сездән бәхет киткән. Тәңре синнән йөзен борган», – дигән.

– Менә сиңа, икебез дә бер үк төшне күрсәк тә, икебезгә ике төрле юрадың, – дигән тегесе, аптырап. – Моны ничек аңларга?

– Дөрес, икегез дә бер үк төш күргәнсез. Ләкин бу кеше «авыз-борынымнан кан килә», диде, ә син «кан китә», дидең.

Риваятьләргә караганда, өйдән бер җиргә чыкканда яки киткәндә өйдәгеләргә: «Мин киттем, – дип әйтергә яра-

мый. – Мин фәлән җиргә барып кайтыйм әле», – диярга кирәк икән.

Авыздан чыккан сүз – атылган ук. Аны кире кайтарып кире урынына куеп булмый. Шуңа күрә телгә килгән һәр нәрсәне сөйләү кирәк түгел. Кешенең әйткәне – ният итүдер. Ә ниятнең изгесе һәм яманы була. Изгесе тиз генә тормышка ашмаса да, яманының аягы кызурак атлаучан. Уйлап сөйләүгә ни җитә!

8. Яхшы сүз – җан азыгы, яман сүз – баш казыгы

«Яхшы эшкә эреп китәм, балавыз мин.
Мактап сөйлим изге эшне – бал авыз мин», –

ди бөек Тукаебыз үзенең бер шигырендә. Ләкин тормышта күбебезгә бал авызлы, тәмле телле булу җитеп бетми кебек. Шулай шул. Кайчакта кәефләр төшеп киткәндә, башка бер-бер кайгы-хәсрәт, борчу-мәшәкать килгәндә, берәрсе хәленә кереп, бер-ике җылы сүз, юату сүзе әйтсә, хәл бермә-бер җиңеләеп китә. Хәтта елыйсы килә, күздән берничә бөртек яшь чыксa, тынычланып ук каласың. Була шундый вакытлар: кәеф шәп, бөтен дөньяны кочарлык булып очынып йөрисең, кешеләргә, тирә-ягыңдагыларга гел яхшылык кына эшлисе килә. Шул вакытта бер тар фигыльлесе җаныңа тиярлек итеп бер-ике сүз әйтеп куя. Шул минутта җир әйләнүдән туктаган, кояш сүнгән кебек була, атылган кош кебек канатларың салынып төшә. «Бер сүз җитә җанны яраларга, бер сүз җитә сагышлардан араларга», – дип, бик дөрес әйтәләр. Бер уйламый әйтелгән сүз кеше язмышын әйләндереп капларга мөмкин. Хөсетлек, көнчелек белән әйтелгән берничә сүз төрмә һәм үлем белән тәмамланырга мөмкин. Заманында мондый очраклар йөзләрчә, меңнәрчә булган. Шәхес культы елларын искә төшерү дә җитә.

Җан азыгы булырлык яхшы сүз сөйләр өчен кешедә акыл, тәжрибә, мәгънә һәм сабырлык булырга тиештер.

Элегрәк заманда бер авылда бер егет өйләнергә булган. Сайлаган пары матур, бик акыллы, тыйнак, мәгънәле, ләкин ятим икән. Каената киленне ошаткан, хәер-фатихасын да биргән. Ә каенана ятим кызны үзләренә тиңсенмәгән. Бик тузынган, тик авырлык белән булса да ризалашкан. Туйлар узган. Кыз егет өенә күчеп килгән. Килен бик эшчән, олыны олы, кечене кече

итә, ирен ир итә белгән. Ләкин каенана киленгә, җае чыккан саен, төртмә сүз әйткәләп тора, гел кара көеп йөри икән. Килен каенананың төртмә сүзләренә пырлап китми, сабыр гына, матур гына итеп җавап бирә икән.

Беркөнне килен, кояш чыкканчы уянып, чыбылдык артыннан чыккан. Каенана аяк өстендә икән.

– Тордыңмы? – дигән ул киленә.

– Тордым, – дигән килен.

– Тордым, әнкәй, дип әйтсәң телең корыр идемени? – дигән каенана.

– Тордыңмы, кызым, дип әйтсәң, тордым, әнкәем, дип әйтермен, әнкәй, – дигән килен.

Икенче юлы килен ире куенында озаграк ятып, чыбылдык артыннан чыгарга соңлаган.

– Бик озак йоклыйсың, килен, – дигән каенана.

– Бигрәкләр дә тәмле малай үстергәнсең, әнкәй, яныннан һич торып китәсе килми, – дигән килен.

Өченчесендә, киленнең токмач кискәнен күзәтеп торган каенана:

– Озак мыштырдыйсың, килен, – дип әйткән ди.

– Синең кебек нечкә итеп кисәргә тырышам бит, әнкәем, – дигән ди килен. Ә каенананың токмачы, дөресен әйткәндә, бик үк нечкә булмаган, ди.

Менә шундый җаваплары белән килен акрын-акрын каенанасының ихтирамын яулаган. Каенана да киленең карашын яхшы якка үзгәрткән.

Бервакыт килен, бала табар көннәре якынлашкач, күңелсезләнеп йөри икән.

– Пошынма, кызым, – дигән каенана. – Ир бала туса, үсеп буйга җитәр дә синең кебек инсафлы кызга өйләнер; кыз туса, минем сыман каенана булгач, синдәй килен белән рәхәтләнеп яшәр, – дигән.

Менә шулай яши-яши атналар, айлар, еллар узган. Каенана картаеп, үлем түшәгенә егылган. Озакламый якты дөнья белән хушлашкан. Килен яулык чите белән күзләрен каплап елый да елый икән.

– Каенанаң өчен нигә шулкадәр өзгәләнәсең? – дигәннәр аңарга.

– Ул мине һәрвакыт елмаеп каршы алды, шуңа күрә мин аны елап озатам, – дигән килен.

(Бу мисал **Т. Миңнуллинның «Килен белән каенана»** язмасыннан бераз кыскартылып бирелде. *Т. Миңнуллин «Утырып уйлар уйладым», 1997 ел, 77–78 нче битләр*).

«Кешеләргә аш бирегез, аларга изгелек теләп, яхшы сүзләр әйтегез», – диелә пәйгамбәребез хәдисендә дә. Баш казыгы булырлык сүзләр түгел, җан азыгы булырлык сүзләр генә сөйләсәк иде!

9. Алай димә!

Мин бу чыгышымны әзерләгәндә, «Татар дини календаре», «Татар мөселман календарь»ларына мөрәҗәгать иттем. «Корьән»нән китерелгән сүрәләр, аятьләр, пәйгамбәребез хәдисләре дә әлеге басма чыганаклардан алынды.

Безнең татарларда әле хәзер дә: «**Уф, Аллаһ!» –** дип әйтүче кешеләр күп. Бигрәк тә берәр бәла-казага юлыкканда, курыкканда, алҗыганда, берәрсе бик аптыратканда, нәрсәгәдер ачу килгәндә һ.б. шундый очракларда бу сүз еш әйтелә. «Уф» дигән сүзнең мәгънәсе – «**туйдырдың инде**» дигәнне аңлата икән. Ягъни алай әйтү Аллаһы Тәгаләгә тел-теш тидерү булып санала. Кайбер тәфсирчеләр «уф» сүзен татарчага «тьфү», «төкерәм» дип тә бирәләр. Димәк, мәгънәсез, тиеш булмаган, гарык ителгән нәрсәгә гарәп телендә «уф» диелә икән. «Уф!» – канәгатьсезлек! Икенче мәгънәсе: тырнак астындагы кергә дә шулай әйтелә икән. Шулай булгач, бу сүзне урынлы-урынсыз телебездә кулланудан сакланырга кирәк.

Әле Аллаһы Тәгаләгә генә түгел, ата-анага да «уф» дип әйтергә ярамый. *«Әл-Исра» сүрәсенең 23 нче аятендә Аллаһы Тәгалә*: «Аларга (ягъни ата-анагызга) «уф» (туйдым сездән) дип тә әйтмәгез. Аларны битәрләмәгез, икесенә дә яхшы мөгамәләдә булыгыз», – ди.

«Әгәр дә ата белән анага «Уф!» дип әйтергә ярамаса, тыелса, Аллаһы Тәгаләгә бигрәк тә алай әйтү дөрес булмый!» – ди Идрис хәзрәт Галәветдин үзенең бер язмасында.

«Иртәгә эшлим!» – дип әйтмә. Иртәгә нәрсә буласын Аллаһы Тәгаләдән башка беркем дә белми. Болай дип әйтүне

Аллаһы Тәгалә тыйган. «Берәр эш башлар алдыннан һичбер вакытта да, **мин моны иртәгә, һичшиксез, эшләячәкмен, димә**, диелгән *(«Кәһеф» сүрәсе, 23 нче аять)*. Аллаһы шул ук аятьтән соң, дәвам итеп «иншәАллаһ» (Аллаһ теләсә) дип әйт дигән. Әгәр бер кеше «Аллаһ теләсә, иртәгә эшлим, дип әйтсә, аның сүзе дөрес һәм хәерле була». *(Идрис хәзрәт Галәветдин «Татар дини календаре», 2013 ел, 15 август бите).*

10. «Үзеңә үлем теләмә!»

«Дөньяда бер көн торасым килми» яки «үлсәм иде», «ник кенә үлмим икән» кебегрәк җөмләләрне күңелсезлекләргә юлыккан яки авыру кешеләрдән ишеткәнегез яки үзегезнең дә әйткәнегез бардыр. Аллаһының илчесе галәйһиссәлам әйткән: «Үзенә килгән зарар сәбәпле, берегез дә үзенә үлем теләмәсен. Әгәр дә кирәк булса: «Әй Аллаһ, яшәвем минем өчен хәерле булса, мине яшәт; үлемем минем өчен яхшырак булса, мине вафат ит!» – дип әйтсен».

Ягъни, бу хәдистән аңлашылганча, күңелсезлекләр сәбәпле, бәндәгә үз-үзенә үлем теләү тыела. Чөнки үлем теләү зарарлы нәтиҗәләргә китерә. Кешенең җаны зәгыйфьләнә, ул ярсый, өметсезлеккә бирелә. Үзеңә үлем теләү – наданлык галәмәте, диелә исламда. Чөнки кеше үлемнән соң нәрсә буласын белми. Бәлки, ул җәһәннәмгә ташланып, тагын да начар хәлдә калыр. Шуңа күрә сабырлык, сабырлык һәм тагын бер кат сабырлык сорала адәм баласыннан. Элекке әби-бабалар, үзенә үлем теләгән кешегә Ходай Тәгалә, өеп чир бирермен, дигән дип тә әйткәннәр.

Ислам галимнәре өметсезлеккә бирелгән, үзенә үлем теләүче бәндәләргә болай дип җавап бирә: «Кайгы-хәсрәтсез, борчуларсыз, авырлыкларсыз тормыш тулы, бөтен була алмый. Нәкъ менә шундый сынаулар адәм баласын тынычландыра, чистарта, сафландыра, саваплар язылуга бер шарт була».

Чыгышымны Пәйгамбәребезнең бер фикере белән тәмамлыйм. «Үлемне теләмәгез берүк. Яшәргә омтылыгыз. Хәятны (ягъни тормышны, яшәүне) үлемнән өстен күрегез. Әлбәттә, тормышыгыз гыйбадәт һәм Ислам диненә хезмәт белән үтсен». *(«Татар мөселман календаре», 2009 ел).*

11. Көнче көне көенеч

Халыкта **көнче, көнчелек, көнләшү** сүзе дә яши. Ак көнләшү, кара көнләшү дигәне дә бар. Кара көнләшүне, икенче төрле **хөсетлек –** дип әйтәләр. Бу сүз безгә гарәп теленнән кергән.

Хөсетлек – башка кешедә булган нигъмәтнең, ягъни муллык, байлык, дәрәҗә, бәхетнең юкка чыгуын теләү. Теләү генә дә түгел, сүзләре, кылган гамәлләре белән дә кешегә зыян салу. Хөсетле бәндә – үчлекле, үзеннән артыграк булган кешеләрне күрә алмас дәрәҗәгә җитүче; кешеләргә килгән бәла-казага, зыянга, авыруына, төрле бәхетсезлекләргә бәхет кошы тоткандай сөенүче. «Йөрәктә хөсетлек йөртү, кемнән булса да чынлап торып көнләшү – хәрам», – диелә Исламда. Ходай Тәгалә һәр бәндәсенә ризык һәм нигъмәтләрне бүлеп биргән. Син никадәр генә хөсетләнсәң дә, билеңнән югары сикерә алмыйсың, бәлки, үзеңә гөнаһ җыеп, ярык тагарак янында калуың да бар. Пәйгамбәребез дә көнчелекне яман сыйфатларның берсе дип атый. «Ут утыннарны яндырып, юкка чыгарган кебек, көнче кеше үзенең изге гамәлләрен юкка чыгара», – ди.

Кара көнләшү кешегә һәрьяктан зарарлы. Кемнеңдер хөсетлеге аркасында берәү күп төрле авырлыкларга дучар ителә, күңелсез хәлләрдә кала. Хөсетлек кылучыга аның җаны рәнҗи. Ә җан рәнҗеше бик көчле нәрсә ул! Хөсетле кешенең үзенең дә борчылып йөреп сәламәтлеге какшый, рухи көче дә кими, ул арый. Хөсетлек аны күңелсезлеккә өстери, гөнаһ кылдыра.

Адәм баласы тарафыннан Җир йөзендә беренче мәртәбә кылынган хөсетлек – Кабил белән Һабил вакыйгасын гына искә төшерик. Кара көнчелек аркасында, бер туган икенчесен һәлак итә! Әйе, хөсетлек бервакытта да юньлелеккә илтми. Телевизордан күрсәтелә торган фильмнарның кайсын гына алсаң да (аеруча сериалларда) хөсетлек күренеше белән очрашмый калмыйсың. Димәк, бу кешелекнең, җәмгыятьнең авыруы, рухның сәламәт булмавы.

Русларның Виктор Астафьев дигән язучысы бар иде. «Патша-балык» («Царь-рыба»), «Бәхилләшү» («Последний поклон») һ.б. бик күп әсәрләре белән таныш ул китап укучыларга. Үзе зур язучы булса да, олыгайган көнендә, ул мондый фикергә

килә. «Язучылар, – ди ул, – дөньяны болгатучылар. Язучылар язган әсәрләрне укыганчы, халык «Библия» укыса, күп мәртәбә тәртиплерәк, әдәплерәк, әхлаклырак булыр иде», – ди. Үзе рус кешесе, христиан динендәге кеше буларак, ул «Библия» ди. Мөселманннар Корьәнне, яһүдләр Тәүратны, гомумән, кем нинди дин тота, шул диннең тәгълиматын чагылдырган китапларын укыса, дип аңларга кирәк бу юлларны. Хаклык юк бу фикердә дип әйтеп кара!

Башка кешеләрнең яхшы эшләренә, уңышларына көнләшеп карау, аларга карата хөсетлек күрсәтү, яманлык кылырга тырышу халык әхлагында да кискен гаепләнә.

«Көнче көлмәс, хөсетле тынмас», «Хөсет кеше дус булмас, булса, күңеле хуш булмас», «Хөсет үзе кылалмый, кылган кешене күралмый» кебек мәкальләр халкыбызның мондый күренешне хупламавын күрсәтә. Халкыбыз шулай ук көнчелек хисен җиңә белергә, аны яманлыкка түгел, ә яхшылыкка хезмәт иттерергә кирәклеге турында да фикер йөртә. Моның өчен канәгатьлек күрсәтү зарур. Чөнки, халык әйткәнчә, **«канәгать кешедә көнчелек булмый, көнче кешедә канәгатьлек булмый».**

Әгәр дә кеше үзендә булмаган сыйфатка кызыгып, шуңа омтылса һәм шул ук вакытта башкаларның иминлегенә зарар теләмәсә, монысы **ак көнләшү** дип атала. Халкыбыз бу турыда менә болай ди: «Кешенең яхшы эшенә көнчелегең килсә, аннан уздырып эшлә». Ягъни башкаларның уңышына карап көнләшмим, гарьләнмим дисәң, үзең дә алар сыман булу өчен тырышырга, көч куярга кирәк.

... Ягымлырак булыйк кешеләргә,
Таш атканда, әйдә, аш атыйк.
Яман сүздән, каты бәгырьләрдән
Кешелекне саклыйк!

*(Шагыйрә **Лилия Садриева**.)*

12. Кешегә баз казыма...

Халык телендә «Кешегә баз яки чокыр казыма – үзең төшәрсең» дигән әйтем бар. «Явызлыкка – явызлык, яхшылыкка – яхшылык» (ягъни явызлык үзеңә явызлык булып, яхшылык исә яхшылык булып кайта) дигәне дә бар. Кайберәүләр телендә, явызлыкка явызлык белән, яхшылыкка яхшылык белән җавап бирергә кирәк, мәгънәсендә дә кулланыла. Рус телендәге «око за око, зуб за зуб»тан тәрҗемәгә охшаган. Татар телендә «үкегә үке» («око за око») варианты да очрый. Ә бит халкыбыз: «Таш атканга да аш ат», – ди. Якташ шагыйрәбез **Лилия Садриева**ның шул турыда бик мәгънәле шигыре бар.

Таш атканга аш ат, балам, – диеп
Өйрәттеләр безне әнкәйләр.
Таш атканга әле олырак ташны
Сайлый төсле хәзер үскәннәр.

– Үзеннән дә яманрак бул син,
Игелек юк хәзер кешедән...
Балаларын шулай тиргәгәнен
Күпме аналардан ишетәм.

Ташка каршы күпме таш атыла...
Әрнесә дә йөрәк,
Шул ташларга каршы тору өчен
Күпме түзем кирәк!

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмгә дошманлык итүче Әбү Ләхаб дигән кеше булган. Ул пәйгамбәребезне үтерү нияте белән үзенең ишек каршысына тирән генә бер чокыр казыта. Аны кеше күзенә күренмәслек итеп каплаттыра. Аның максаты – пәйгамбәребезне шушы чокырга төшереп күмеп кую була. Кояш батып, ахшам вакыты җиткәч: «Әбү Ләхаб каты авырып ята, ислам динен кабул итәргә тели», – дигән сүзне җиткерү өчен пәйгамбәр янына илче җибәрә. Илчедән шул сүзләрне ишеткәч, Мөхәммәд галәйһиссәләм Әбү Ләхабның өенә юл тота. Килеп җитеп, чокырга төшәргә бер адым кала, Җәбраил фәрештә пәйгамбәребезгә Әбү Ләхабның мәкерле

ниятен ачып сала. Пәйгамбәр, бу хәбәрне алгач, борылып өенә кайтып китә. Тәрәзәдән күзәтеп торучы Әбү Ләхаб Мөхәммәд галәйһиссәләмнең ишек яныннан кире борылып китүен күреп, чокыр казуын онытып, йөгереп чыга да үзе казыган чокырга егылып төшә. Чокыр бик тирән булганлыктан, никадәр азапланса да, аннан чыга алмый. Дуслары иртән генә аны күреп, озын баулар төшереп, чокырдан чыгарырга тырышып карыйлар. Әмма тырышулары бушка була. Әбү Ләхаб гафу сораганнан соң, Мөхәммәд галәйһиссәләм килеп, аны чокырдан кулы белән тартып чыгара. (*«Бәхетләләр календаре» 2013 ел, 244–245 нче битләр*).

Менә тагын халык арасында йөри торган бер риваять.

«Әүвәл заманда бер хатын яшәгән ди. Аның бик булдыклы, акыллы ире һәм дүрт улы булган. Уллары да әтиләренә охшап, уңган-булган, акыллы, матур булып үсеп җиткәннәр. Бервакыт әтиләре улларын дөнья күрергә алып чыгып киткән, әниләре озатып калган. Ялгыз кешенең башына ни генә килми?! Бу хатынның башына да бер бозык уй килгән.

– Тукта әле, юри генә сынап карыйм. Явызлык эшләсәң, явызлыгың үзеңә кире кайта, диләр. Хак микән. Хәзер бик уңайлы вакыт: ирем дә, балаларым да читтә. Үзем ничек тә саграк булырга тырышырмын, – дигән.

Бик уңдырып ипи салган бу. Берсенә агу кушкан. Ипиләрен мичтән чыгарып, сәкегә тезеп куйган. Ипиләрнең хуш исе тирә-юньгә таралган, тәрәзәдән урамга кадәр чыккан. Менә шул вакыт болар турыннан бер хәерче узып бара икән. Ул, икмәк исенә алданып, бу өйгә кергән, ашарга сораган. Хатын аңа юри агу кушылган ипине биргән. Хәерче сөенгән: «Менә әйбәт булды. Хатыным, балаларым белән бергә утырып ашарбыз», – дип, икмәкне капчыгына салган һәм рәхмәтен әйтеп, юлын дәвам иткән.

Кайту юлында бер имән төбендә ял итеп ятучы биш ирне күрә. Болар моннан, аз булса да икмәгең юкмы, дип сораганнар. Хәерче булса да, теге кеше юмарт булган. «Болар бишәү бит. Сынык-санык белән генә туймаслар. Теге бөтен ипине бирим әле. Берәр мәрхәмәтле бәндәсе очрап, тагын бербөтен ипи бирер», – дип, икмәкне теге кешеләргә бүлгәләп биргән дә китеп барган. Тегеләр ипине ашаганнар, бераздан тәгәрәшеп үлеп тә киткәннәр. Хатын яшәгән авылга да бу хәбәр килеп җиткән. Хатын, күңеле белән сизенеп, теге имән янына киткән. Имән

төбендә үлеп яткан ирен һәм улларын күргән. Ул шунда барысын да аңлаган, әмма соң булган шул инде».

Менә бу мисаллар явызлыкның бервакытта да ахыры хәерле булмавын тагын бер кат раслый түгелме?

Йөрәк урынында ташлар типсә,
Таш бәгырьләр булса күбебез,
Якты тормыш көткән бу заманның
Киләчәген ничек күрербез?

(Лилия Садриева.)

13. Нәүширвандай гадел...

Үтә гадел кешегә (андыйлар сирәк булса да очрап куя) «бигрәк гадел инде, әйтерсең, Нәүширван патша», диләр. Тарихта андый патша булган. Аны тарихи китапларда күбрәк Ануширван дип бирәләр. Татар халкы телендә Нәүширван яки Әнүширван рәвешендә кулланылган.

Әнүширванның фарсы (иран) теленнән турыдан-туры тәрҗемәсе – «үлемсез җан» дигән мәгънәне аңлата. Әнүширван – безнең эраның 5 нче гасырында идарә иткән Иран патшасы, диелә легендаларда.

Легендалар Әнүширван патшаның үтә акыллы, бик гадел булуы турында сөйли. Аның турында Фирдәүсинең «Шаһнәмә» поэмасында да сөйләнелә.

Менә аның гаделлеген раслаучы бер легенда.

«Гадел атамасына ия Нәүширван патша бервакыт ауга чыга. Ул бер җәнлек аткач, үзенә пешереп бирүләрен әмер итә. Әмма ауга чыгучыларның тозы булмый. Бер хезмәтче күрше авылга тоз алырга китә. Аны көткән арада патша әйтә:

– Хезмәтчем тоз өчен хакын түләсә иде.

– Патшабыз, тоз өчен түләмиләр. Сезнең патшалыкта яшәүче кешеләр үз патшаларына ярдәм итә алулары өчен шатланачак кына.

– Юк, әгәр дә патша бер уч тозны бушка ала икән, иртәгә аның ярдәмчеләре, вәзирләре йомырка, соңыннан тавык, бәрән һ.б. таптыра башлый... Һәм менә шундый начар гадәт әгәр дә бездән башлана икән, без гомер буе каргышта яшәрбез, – дигән Әнүширван патша». *(«Татар дини календаре», 2013).*

«Бервакыт, Әнүширван үз патшалыгындагы халыкның тормыш-көнкүреше, илнең баймы әллә хәерчелектә яшиме икәнен белергә теләгән. Моны белү өчен ялган хәбәр тараткан. Имеш, патша бик каты авырый. Дәва бер генә: җимерек бер бинаның ватык кирпече. Сөекле патшаларына дәва – ватык кирпеч кисәге эзләп, халык илнең төрле тарафына таралган. Ләкин патша сарае янындагы мәйданга барысы да буш кул белән әйләнеп кайтканнар. Чөнки патшалыкны әйләнеп чыгып та бер генә җимерек бина, бер генә җирдә дә аунап яткан кирпеч кисәге таба алмаганнар. Илдә шулкадәр тәртип, һәркемнең тормыш-көнкүреше уңайлы, бөтен җирдә төзеклек икән, байлык җирдә исраф булып ятмый икән!

Башларын иеп басып торган халкы каршына чыккан патша, барысын да гажәпкә калдырып, сөенеченнән кычкырып җибәргән:

– Аллага шөкер! Ходаем мине бервакытта да рәхмәтеннән һәм ярдәменнән ташламады. Аның ярдәме белән мин халкымны, илемне мохтаҗлыктан коткарганмын. Ә кирпеч ватыгы бер сәбәп кенә иде. Минем илемнең ни дәрәҗәдә төзек икәненә чын күңелемнән инанасым килде! – дигән».

Җир кешеләре гомер-гомергә гаделлек, гадел патша турында хыялланган. Үзенең идеалларын әкиятләрдә, дастаннарда, әдәби әсәрләрдә гәүдәләндергән. Әнүширван патша да халык идеалының бер чагылышы.

Әгәр дә мин фәләккә
(күк йөзенә, галәмгә) тәңре булсам,
Ватып аны яңа бер дөнья корсам, –
Кабул булып бөтен изге теләкләр,
Бәхеткә ирешер иде барлык инсан.

(Гомәр Хәйям)

14. Тартасыңмы, саласыңмы?

Телдә читләтеп әйтү, кинаяле сөйләм дигән төшенчә бар. Әдәбиятта бу төшенчә **аллегория** дип атала. Телдә кулланыла торган мәкальләр, мәсәлләр аллегориягә корылган. Изге «Корьән» китабын да аллегорик китап, диләр. Шуңа күрә аны теләсә кем шәрехли алмый, тәфсир яза алмый. Дин гыйлемендә

дә, дөньяви гыйлем диңгезендә дә «ат уйнатканнар» гына бу эшне башкара ала торгандыр.

Халкыбыз акыллы сүз сөйләүгә, кешенең фикерләү дәрәҗәсенә зур игътибар биргән:

«Акыллыга сүз әйттем: тыңлады да белде.
Тинтәккә әйттем: кычкырды да көлде».

Халык авыз иҗатында кинаяле сөйләмгә нигезләнгән мәзәкләр дә шактый.

Бер егетнең әтисе үлеп киткән. Шуннан соң егет, бер кешегә дә сәлам бирмичә, борынын чөеп йөри башлаган.

– Нинди акыллы егет иде, атасы үлгәч, бик әдәпсезләнде, масая башлады, – ди икән авыл картлары.

Беркөнне егет урамнан узып барганда, картлар моны туктатып: «Бу нинди әдәпсезлек! Нишләп сәлам бирми үтеп китәсең?» – дигәннәр.

Егет аптырап калган.

– Мин бит әтинең васыятен үтим. Үләр алдыннан ул миңа: «Улым, кешеләргә сәлам бирмә, үзләре сиңа сәлам бирсеннәр», диде бит, – дигән.

Картлар көлешкәннәр дә егеткә васыятьнең мәгънәсен төшендереп биргәннәр.

– Атаң сиңа: «Эшкә иртә бар, кешеләр синең эшләгәнеңне күреп, яныңнан узганда, сине зурлап, сәлам биреп китсеннәр, – дигән. – Әгәр соңга калсаң, ул вакытта синнән элек барган кешеләргә син үзең сәлам бирергә тиеш буласың бит, – дигәннәр.

Монысы хәзерге заманга рак карый торган мәзәк.

Бер егет үзенә кыз сорарга барган. Кыз йортында булачак кияүне әзерләнеп көтеп торалар.

Кызның әтисе бик акыллы һәм хәйләкәр кеше икән – егетне сынап карамакчы булган.

– Тартасыңмы? – дип сораган егеттән бабай буласы кеше. Кияү, әлбәттә, сорауны туры мәгънәдә аңлаган. Иптәшләре белән очрашканда, тәмәке суыргаласа да, суфыйланып, юк, дип җавап биргән.

– Саласыңмы? – дип, икенче соравын биргән бабай. Сыра хәмердән дә баш тартмаган кияү, бу сорауга да башын аска иеп кенә, юк, дип котылган.

Бабай буласы кеше кызына таба борылган да:

– Кызым, син бу егеткә барма, бер рәхәт тә күрмәссең, – дигән.

Мәҗлестәгеләр барысы да аптырап калганнар. Үзе тартмый, үзе салмый, үзе карап торуга да ару гына күренә. Мондый кияүне көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмассың! Моңа хәзерге заманда нинди кияү кирәк микән? – дип уйлаганнар кунаклар эчләреннән генә.

Бераздан бабай телгә килеп: «Тартасыңмы?» – дигән сүз, тормышны, дөньяны тарта алырсыңмы дигән сүз иде. Ир кеше үз гомерендә өй салырга тиеш. «Саласыңмы?» – дигәнем, әнә шуңа ишарә иде, – дигән. «Тормышны тарта алмаган, үз гомерендә бер өй дә сала алмаган кешегә ничек итеп ышанып кыз бирмәк кирәк!» – дигән бабай, сүзен йомгаклап. Бабай кеше, бу очракта, кияү буласы кешене төрле яклап сынап караган. Беренчедән, ул кияүнең фикер йөртүен, акыл ягын, сүз мәгънәсенә төшенүен, тапкырлыгын, чослыгын тикшергән. Икенчедән, кияү кеше икейөзле түгелме? Күңелендә – бер, телендә икенче фикер ятмыймы? Ялганчы түгелме? Өченчедән, кияү югалып кала торган кеше түгелме? Теләсә нинди ситуациядән чыга алырлыкмы? Ышанычлымы? Киләчәктә гаиләсенә терәк булырлыкмы?

Менә, егетләр, кияү буласы кешеләр. Бу фикерләрне колагыгызга киртләп куегыз. Сезгә дә шундый бабай туры килсә, бервакытта да югалып калырга тырышмагыз.

Сары сандугачлар тоттырмас, уяу егет үзен оттырмас!

15. Аллаһ ризалыгы өчен

Кешеләр белән сөйләшкәндә, аралашканда «шул кешегә күпме яхшылыклар эшләдем, ярдәм иттем – барыбер белми», дип гаҗизләнүчеләрне, яки «шуны эшләдем әле, моны эшләдем әле» дип өч тиенлек эшләре белән мактанучы, үзләрен рекламалаучыларны да ишетергә, күрергә туры килә. Алдагы чыгышларның берсендә «Яхшылык эшлә дә суга сал – балык белер, балык белмәсә – Халикъ, ягъни Ходай белер» дигән гыйбарәгә тукталган идек. Өлкән буын кешеләреннән дә «Аллаһ ризалыгы өчен», «Аллаһ белер» кебек сүзләрне ишетәбез. Ягъни эшләгән эшләреңне, кылган изгелекләреңне кеше күрсен, кеше

белсен, сине мактасыннар дип эшләмә. Болай итүнең бер сәбәбы да булмый. Киресенчә, синең кылган изге эш-гамәлләреңне беркем дә сизми-белми калсын.

Риваятьләрдә сөйләнгәнчә, бер падишаһ (аны Гомәр хәлифә дип тә бирәләр), караңгы төшүгә, өстенә җәймә каплап, арткы ишектән генә чыга да, каядыр китә икән. Шактый вакытлар узгач, кабат шул арткы ишектән кайтып, сараена кереп китә икән. Баш вәзире моны берничә көн күзәткән дә, бер дә бер көнне яшеренеп кенә патша артыннан киткән. Патша, караңгы аулак урамнар буйлап шактый баргач, шәһәр читенә чыгып, гади халык яши торган төбәктәге бик фәкыйрь генә өйнең ишегеннән кереп киткән. Вәзир патшаның чыкканын ике-өч сәгатьләп көткән. Патша чыгып, кайтыр юлына борылуга, вәзир теге өйгә кергән. Бәләкәй генә, әмма бик чиста-пөхтә өй эчендә, түрдәге ап-ак урын-җир өстендә, бик чиста киемле бер әби утыра икән. Әби – карт, авыру, җитмәсә, ике күзе дә сукыр икән. Вәзир әбинең хәл-әхвәлен белешкән. Әле генә чыгып киткән кешенең кем булуын сораган. Әби исә: «Мин бер ятим, авыру карчыкмын. Бер изге күңелле бәндә, байтактан мине тәрбияләп тора. Һәр көн килеп, өйләремне җыештыра, урын-җиремне, өсбашымны алыштыра, аларны юып китерә. Тамагымны туйдырып, ашарыма-эчәремә калдырып китә. Ул бәндәгә Аллаһының мең-мең рәхмәте яусын!» – ди.

Мондый мисалларны, никадәр генә бүгенге әхлактан зарлансак та, көндәлек тормышта да очратып була. Райондашыбыз, балалар шагыйре ***Мөҗәһит Әхмәтҗанов***ның ***«Матур кешеләр бар»*** шигыре әнә шул хакта:

Шундый матур кешеләр бар арабызда,
күңел күзен ачып карагыз ла.
Нурлар балкып тора йөргән юлларында,
ут уйната алар гади кулларында.
Телләрендә бары күркәм сүзләр генә,
күпне өмет итмәс алар үзләренә.
Вәгъдәләре иман булыр, ялган булмас,
беркайчан да алар яман гамәл кылмас.
Дәрәҗәгә омтылмаслар, тыйнак алар,
гаделлектә сине кат-кат сынар алар.

Туганнарга туганнарча мөнәсәбәт,
күрешергә чыгып торыр һәрчак сәбәп.
Шундый матур кешеләр бар, күрәсездер,
әле бергәләшеп гомер сөрәсездер.

Бер әбинең сөйләгәннәреннән: «Теге дөнья»га баргач, кайбер бәндәләр «мин фәлән кешегә шундый яхшылык эшләдем, төгән кешегә изгелек кылдым, миңа оҗмах тиеш», дияр ди. Андыйларга әйтерләр ди: «Кемгә яхшылык эшләгәнсең, оҗмахны шуңардан сора», – дип. Кешенең белгәне бар, белмәгәне чүл комыннан да күбрәк. Ни эшләсәң дә, Аллаһ ризалыгы өчен, дип, чын күңелеңнән эшләргә кирәк.

Картлар сүзендә хикмәт бар икәнен дә онытмыйк!

16. Беләсем килгән иде...

Берничә ай дәвамында радио аша **«Сүзләр һәм гыйбарәләр дөньясында»** тапшыруы барды. Радиодәресләрдә телебездә кулланыла торган байтак кына сүзләр, гыйбарәләргә тукталып, тел гыйлеме буенча белемнәребезне тулыландырдык. Радио тыңлаучыларыбыз телебезгә карата битараф түгел икән. Урамда очратып та, телефон аша да, таныш-белешләр аша да үзләренең рәхмәтләрен, фикерләрен белдерәләр, кайбер сүзләр һәм гыйбарәләрнең мәгънәсе, тарихы белән кызыксынуларын, белергә теләүләрен дә әйтәләр. Бүгенге йомгаклау чыгышы **«Тел дигән дәрья бар»** тапшыруларын даими тыңлап баручыларның берничә соравына нигезләп әзерләнде.

1. Шундый сүзләрнең берсе – **«мур кыргыры»** тезмәсе. Сөйләмдә бу тезмә сүз өлкән һәм урта яшьтәгеләр телендә кулланыла әле. Гадәттә, бу сүзне кәҗәләргә карата әйтәләр: **мур кыргыры кәҗә.** Күрше-тирәң, авылдашларың белән ызгышасың, дошманлашасың килмәсә, кәҗә яки күркә асрама, диләр бит. Чөнки бу ике җан иясе, файдалы яклары күп булуга карамастан, бакчаларга тынгы бирми. Күркә суган түтәлләрен үз күрсә, кәҗә ирек сөюче хайван буларак, бөтен дөньясын иңли, куганны да белми. «Җир дә йотмый, чир дә алмый, мур кыргыры кәҗәне», – дип, халык юкка гына әйтмәгәндер.

Мур сүзе безгә урыс теле аша латин теленнән кергән. Урыс һәм латин телендә яңгырашы – **мор**. Татар телендә киң

әйтелешле **о** авазы булмаганлыктан, халкыбыз телебезгә җайлаштырып, бу сүзне **мур**га әйләндергән булса кирәк. Тел галиме В.Х. Хаков фикеренчә: «Милли әдәби телдә кайбер сузыкларның тараюы һәм моның норма булып китүе, борын-борыннан кыпчак кабилә телләренә хас үзенчәлек булып санала. Мәсәлән**, о** авазының **у** га якын рәвештә әйтелә башлавы шуның ачык мисалы: **йок – йук, йол – йул, тон – тун, ток – тук һ.б.» (***В.Х. Хаков «Тел – тарих көзгесе», Казан. 2003, 127 нче бит*).

Мор – борынгы Римда үлем алласының исеме (**морг** сүзе дә шуннан ясалган). Телдә йогышлы авырулардан, эпидемияләрдән кешеләрнең һәм хайваннарның массовый рәвештә кырылуы мәгънәсендә йөри. Фәндә «**кара үлем»** дип атала торган **чума, холера** авырулары шундый куркыныч авырулардан санала. Безнең халык аларны «үләт чире», «мур» дип атаган. Димәк, «мур кыргыры» – «үләт кыргыры» мәгънәсен аңлата икән.

2. **Кәнитил, кәнитилле эш** нинди мәгънә аңлата? – дигән сорау булды.

Бу сүз (ягъни канитель) безгә рус теле аша **француз** теленнән кергән. Алтын яки көмеш йөгертелгән нечкә генә чыбыклардан үреп ясалган, тегү-чигү эшендә кулланыла торган җеп, укалы җеп. Кәнитил белән чигү бик мәшәкатьле, үрчемсез, катлаулы эш булган. Шуңа күрә вак, озакка сузыла торган, катлаулы, четерекле, мәшәкатьле эшләрне кәнитильле эш дип атаганнар.

Кәнитилле калфак, кәнитильле кәләпүш – кәнитил, ягъни, укалы җеп белән чигелгән калфак яки кәләпүш була.

3. **Хак, нахак, бинахак, бәнәхак** сүзләре нәрсәне аңлата һәм алар арасында нинди аерма бар?

Хак – гарәп теленнән кергән. Төп мәгънәсе – дөрес, чын, гадел.

Нахак – хак сүзенең антонимы, киресе. Ягъни, дөрес түгел, гадел булмаган, хаксызлык, яла, әләк. Нахактан ябышкан бәладән саклан, ди халык.

Сөйләмдә, «нахактан сакла, Ходаем» дигәнне ишеткән бар. Ә халык хак, нахакны бергә кушып, хагыннан-нахагыннан, ди. Шулай дөресрәк буладыр. Хагыннан да, нахактан да ераграк йөрергә язсын барыбызга да.

Бинахак, нахак сүзе кебек үк, хаксызга, урынсызга, гаепсезгә, дигәнне аңлата. **Би –** гарәп-фарсы алынмалары ал-

дыннан юклыкны белдереп килә торган алкушымча (татар телендәге – **сыз** – **сез** кушымчасы мәгънәсендә). Мәсәлән, бихисап (хисапсыз), бичара (чарасыз), биһуш (һушсыз) бигаять (чиксез, гадәттән тыш, искиткеч).

«Хәерле көн»! – дидем сандугачка –
Үзәкләрне өзеп сайрады
... Бинахакка мине рәнҗетүче
Берәүгә дә үпкәм калмады.

(Рим Идиятуллин)

Бәнәхак сүзе сүзлекләрдә бирелмәсә дә, диалекталь сүз буларак телдә **бинахак** мәгънәсендә кулланыла. Язучы Нәбирә Гыйматдинова иҗатында бу сүз очрый. «Бәнахакка яла ягылган Талип исемле бу малайны, билгеле, еллар үтә-үтә Акъяр хәтереннән сызды» *(«Син түгел бу, син түгел»... бәяны, «Идел», №3, 2013 ел).*

Хөрмәтле радио тыңлаучылар! Тапшыруларга карата битараф булмаганыгыз, игътибарыгыз, рәхмәтләрегез өчен үзегезгә дә рәхмәт!

Кадерле татар телем, сөекле туган телем!
Гомеремне Туган телгә багышладым – ялгышмадым!
«Телем», диеп җырлап торам, халкымны зурлап торам,
Былбыл кошлы гөлбакчада – сандугачлы телбакчамда –
алсу таңнар аттырам.
Татар теле – сандугачлы телбакчам, тургайлы
күңел бакчам!
Татар бәхете – туган телем! Аңлачы, шуны, халкым!

*(Тел галиме һәм шагыйрь **Гомәр Саттаров**.)*

III кисәк

НИ ӨЧЕН БОЛАЙ ӘЙТӘБЕЗ?

1. Кереш чыгыш. Картлар сүзен капчыкка

Хөрмәтле радиотыңлаучылар! Бүгеннән башлап **«Ни өчен болай әйтәбез?»** тапшырулар сәхифәсен башлап җибәрәбез.

Туган телебездә мәкаль һәм әйтемнәр, канатлы сүзләр дистә меңнәр белән исәпләнә. Алар күп гасырлар дәвамында төрле-төрле юллар белән иҗат ителгәннәр. Сөйләм барышында, ситуациягә карап, көндәлек тормышта да, әдәби әсәрләрдә дә халык телендә «картлар сүзе» дип аталган мәкаль-әйтемнәребез кулланылып тора. Мәкальләр нигезендә хикмәт, фәлсәфи фикер, тапкыр һәм үткен йомгак, нәтиҗә, тормыш тәҗрибәсе ята. Без мәкаль һәм әйтемнәрне, канатлы сүзләрне урынын белеп, аңлап кулланабызмы? Әлбәттә, өлкән яшьтәгеләр сөйләмендә алар үз урынында белеп кулланыла. Әмма яшьләр, балалардан еш кына: «Нигә алай дип әйтәләр? Бу сүз нәрсәне аңлата?» – кебек сорауларны еш ишетергә туры килә. Урта буын кешеләреннән дә: «Әби-бабай яки әти-әни шулай дип әйтә иде», – дигәнне ишетәбез, ә нәрсәне аңлата соң ул, ни өчен алай әйтәбез, дисәң, күбесе җилкәсен генә сикертә.

Мәкаль һәм әйтемнәр өчен төп җирлек: реаль тормыш хәлләре, халыкның әкият-мәзәкләре, кыйссалары, миф, ривәять-легендалар. Аеруча фольклор әсәрләреннең, гадәттә, «кыйссадан хиссасы», ягъни җыйнак, тапкыр әйтемгә салынган морале, сөземтәсе була. Тора-бара шулар төп тексттан аерылып, мәкаль яки әйтем булып китә.

«Татар халык мәкальләре»нең өч томлыгын төзеп, халыкка җиткергән атаклы галим-фольклорчы Н. Исәнбәт: «Нәрсә ул мәкаль?» – дигән сорауга болай дип җавап бирә:

«Сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт бирү өчен көнкүрештә күп сыналган дәлил яки шигъри бер мисал урынында әйтеп йөртелә торган кыска, ләкин бер тирән гомуми мәгънәне эченә алган төгәл җөмләле халык хикмәте әсәрләре мәкаль дип әйтелә». Ул **әйтем** сүзе турында да үз фикерен белдерә: «...бездә мәкаль белән берәттән, **әйтем** дигән бер сүз үзенә мәйдан

алды. Ул мәкаль дигән сүздән бер дә калмый. «Тәтәй бара, мин дә барам» дигән кебек, һәркайда «мәкаль һәм әйтемнәр» булып йөри. Хәтта хәзер болар икесе бер үк төрдән булган сүзләрме, бер үк жанрмы, мәгънәдәшме, түгелме – яхшылап белер хәл дә юк. Бу хәл мәкальнең бездә жанр буларак та әлегә хәтле яхшылап өйрәнелмәгән булуын күрсәтә, – ди». *(«Татар халык мәкальләре», 1 том, 2010 ел, 12 нче бит). «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә (Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2005 ел)* **әйтемгә** мондый бәяләмә бирелгән:

– Тотрыклы һәм гадәттә образлы тәгъбир – ягъни, нинди дә булса мәгънә, я фикер белдергән сүз тезмәсе, сүз әйләнмәсе.

Тапшыруларыбызда әнә шул «хикмәтле энҗеләр» булган мәкаль-әйтемнәребезнең телдә кулланылышы, мәгънәләре, килеп чыгышлары белән танышырбыз. Мин чыгышларымны әзерләгәндә, ***Н. Исәнбәт***нең *«Татар халык мәкальләре»* өч томлыгыннан, танылган фольклорчы ***Хуҗи ага Мәхмүтов***ның *«Язылмаган кануннар» (Казан, 1995 ел)* китабыннан, халык авыз иҗаты әсәрләреннән файдаландым. Бүген без тел өлкәсенә кагылган берничә мәкальгә тукталырбыз.

Дөньяда иң татлы нәрсә дә тел, иң ачы нәрсә дә тел, дигән мәкаль-әйтем бар. Күчмәлек чорында, Болгар дәүләте, Алтын Урда чорында да бездә **чичәннәр** мәйдан тоткан. Чичәннәр – шагыйрь-импровизаторлар, сүз осталары, оста бәхәсчеләр, җырчылар алар! **Телгә чичән телнең маен тамызып, сүзнең балын агызып сөйләр,** ди бер мәкаль. Татар дөньясында да атаклы Җирән чичән булган. Менә шул Җирән чичәнгә шул заманның ханы, чичәннең акылын, тапкырлыгын сынау йөзеннән, иң татлы нәрсә пешереп китерергә кушкан. Җирән чичән, аш өенә килеп, тәмләткечләр салып, тел пешереп китергән. Ханга тел бик ошаган. «Инде иң ачы нәрсәне китер», – дигән хан. Җирән чичән, аңа тозлап, борычлап тел китергән.

Әйе, тел белән иң матур, татлы һәм иң ямьсез, зәһәр, ачы сүзләрне дә әйтеп була.

Татарга тылмач кирәкми, дигән әйтем бар. Кирәкмәгәнгә сүзгә кысылып, сүз аңлатучыларга карата әйтәләр.

Татар ханлыклары чорында рус, Литва, Польша шикелле кенәзлекләрдә татар илчеләре белән аралашу өчен тәрҗемәчеләр тотканнар. Ханнан килгән илче, кенәзгә сүзен әйткәч, янындагы

тәрҗемәчегә «телем ач!» дип, үз әйткәнен тәрҗемә итеп бирергә кушканнан, «тылмач» сүзе ясалган. Бу сүз «толмач» рәвешендә ул телләргә дә кергән, ягъни **тәрҗемәче** мәгънәсендә.

Телдә, тузга язмаганны сөйләмә әйтелмәсе бар. Н. Исәнбәт мәкальләр җыентыгында аның «тозга язмаган» вариантын да китереп, болай ди: «Элек Болгар җирендә кәгазь ясый белмәс борын, каен тузына язудан калган сүз. Хәзер бу сүзне аңламыйча, тозга язмаганны сөйләмә, дип тә әйтәләр. Шуның белән **«тозсыз, мәгънәсез сүз сөйләмә»** дигәнне китерәләр *(«Татар халык мәкальләре», 2010, 364 нче бит).*

Хәзергә шулар, алдагы тапшыруларда шундый мәкаль-әйтемнәр белән танышуыбызны дәвам итәрбез. Бүгенгә сау булыгыз!

2. Әгәр Дәүләт сукыр булмаса....

Татар халык мәкальләре арасында бик үткеннәре, политик эчтәлеклеләре дә бар. Шундыйлардан берсе**: «Дәүләт сукыр булмаса, аксак кулына кермәс иде».**

Аксак Тимер Идел буйларына һөҗүм итеп, Болгар шәһәрен алганда, бик күп алтын-көмеш хәзинәләр һәм әсирләр кулга төшергән. Аннан соң ул: «Бу кулга төшкән кешеләр арасында хикмәт ияләре бармы?» – дип сораган. Аңа бу шәһәрдә бик хикмәт иясе сукыр бер шагыйрь булуын әйткәннәр. Аксак Тимер аны үз каршысына китерткән. Сукыр шагыйрь, думбрасын чалып, аңа Болгарның данлы батырлары, байлыклары турындагы хәлләрне хикәя кылып җырлаган. Аксак Тимер, гаҗәпләнеп тыңлап торганнан соң, аның исемен сораган.

– Минем исемем – Дәүләт, – дигән тегесе.

Аксак Тимер тапкыр телле кеше булган. Көлгән дә:

– Шулай итеп Дәүләт сукыр булдымыни? – дигән.

Сукыр шагыйрь аңа җавап кайтарып:

– Әгәр Дәүләт сукыр булмаса, аксак кулына кермәс иде, – дигән.

Мин дә беттем, патша да бетте

Татар фольклорында Мокыт атлы (тулы исеме Мөхәммәтҗан) аңсыз, аңгыра, үзе ярлы бер герой бар. Ул аңгыралыгы аркасында еш кына мәзәк хәлләргә кала. Әмма беркатлы

фикерләве аркасында кызык-кызык, мәзәк җөмләләре, Мокыт әйткәндәй, кереше белән халык телендә еш кулланылган.

Әлеге әйтемнең килеп чыгышының тарихы.

Бервакыт авылдагы халыктан имана салымы җыя башлаганнар. Түли алмаганнарның әйбер-карасын язалар да каравыл өенә алып китәләр икән. Мокыт агайның да мендәрен ала башлаганнар. Мендәрен бирмәскә була, барып ябышкан икән, мендәр ертылып, йон тузган. Алай да мендәрне алып киткәннәр. Мокыт агай урамның икенче ягыннан мендәрне озата бара, үзе бот чабып:

– Мин дә беттем, патша да бетте! – ди икән.

– Нишләп патша бетсен! – дигәч:

– Әнә бит, минем ертык мендәремә калган! – дип җавап биргән, имеш.

Патшалар, идарәчеләр темасына тагын бер әйтелмә: **Дамокл кылычы.** Әйтелмәнең төп чыгышы борынгы грекларның бер риваяте белән бәйләнгән.

Борынгы Грециядәге Сиракуз патшасы Өлкән Дионисий Беренченең (б.э.га кадәр 432–367 нче елларда яшәгән) якын кешеләре арасында Дамокл исемле бер вельможа булган. Ул патшаның бәхетеннән бик көнләшкән. Моны белгән Дионисий патша Дамоклны үз урынына тәхеткә утырткан, патшаларга күрсәтелә торган бөтен кадер-хөрмәтне күрсәттергән. Дамокл куанычыннан нишләргә дә белмәгән. Тик бер мәлдә ул, ничектер, түшәмгә күтәрелеп караган... Һәм куркудан катып калган: нәкъ аның баш өстендә нечкә генә кылга бәйләп куелган авыр кылыч асылынып тора икән. Имештер, шунда Дионисий әйткән: «Менә, Дамокл, син минем язмышыма кызыгасың. Тәхеттә утыруның нинди хәвефле булуын күрдеңме инде?» – дигән. «Дамокл кылычы астында яшәү», «Дамокл кылычы асылынып тору» – һәрвакыт куркыныч астында, хәвеф-хәтәр көтеп яшәү мәгънәсендә кулланыла.

Ил, дәүләт башында торучыларга камил акыл, тәүфыйк, сабырлык, тыйнаклык, ил-көннәргә тынычлык-иминлек теләп, саубуллашып торабыз. Киләсе очрашуга кадәр!

3. Һәр сүзнең мәгънәсе була. Картның васыяте

Мәкальләр күчерелмә мәгънәгә ия. Аларны аңлый белергә кирәк. Туры мәгънәдә аңлап көлкегә калучылар да күп булган элек. **Ай саен кыз ал, авыл саен өй сал, һәркөн саен бал да май,** дип васыять әйткән ди бер карт үләр алдыннан улын чакырып.

Карт дөньядан киткәч, улы уйлап-уйлап торган да: «Туктале, әти миңа бик яхшы васыять әйтте бит, тотарга кирәк моны», – дип, ай саен кыз алып аера, авыл саен өй салып, көн саен бал белән май гына ашап яши башлаган ди. Билгеле, эшне болай корып җибәргәч, ата байлыгы озакка җитәме? Бер ел да үтмәгән, тәмам бөлеп, хәерчегә калгач, беркөн авыл башына чыккан да, бер тиреслек башына менеп, түбәтәен учлап, башын тотып утырган ди бу. Шулай үз хәленә үзе шаккатып утырганда, моның яныннан бер карт үтеп бара икән. Сәлам биреп янына туктаган да, хәл-әхвәл сораша башлаган. Егет, артык хәл юк, дип ык-мык иткәч, карт әйткән:

– Сереңне яшермә, турысын әйт: нәрсәдән болай аптырадың? Бәлки, минем сиңа файдалы киңәшем тияр, – дигән. Шуннан соң егет тә чишелгән: «Шуңа аптырадым, бабай, әллә мин җүләр, әллә атам? Менә атамның өч васыятен тотыйм дип, шундый бер хәлгә калдым әле», – дип, картка әтисенең васыятьләрен сөйләп биргән.

Шунда карт егеткә әйткән: «Әй улым, улым! Син атаңның васыятен аңламагансың икән. Аның ай саен кыз ал, дигәне «өеңнән читкә китеп, кәсептә йөреп, аена бер генә кайтсаң, һәр мәртәбәсендә хатының сиңа яңа өйләнгән кәләшең кебек сөекле булып күренер» дигән сүз; «авыл саен йорт сал» дигәне, «авыл саен белеш-таныш яса, кешеләр белән яхшы белешләнсәң, һәрвакыт үз йортың кебек итеп барып керерсең; «ашаган саен бал да май» дигәне, «эшләп тамагың ачкан вакытта гына аша, шул вакыт сиңа икмәк белән тоз да бал белән май кебек булыр» дигән сүз ул. Хуш, улым, юлыма киттем әле мин», – дип, карт урыныннан торып киткән.

Бу егет карт күздән югалгач кына исенә килгән. Юк, бу тикмә карт түгел, дип, һәрбер әйткән сүзен зиһененә салып уйлап торган да, атасының васыятен яңача аңлап, яңача эш итә

башлаган. Шуның белән тормышы төзәлеп, бәхете алга китеп, егетебез яңадан аякка баскан ди.

Моржадан төтен чыгару әйтеменә тукталып китик. Бу әйтем, башкалар рәтеннән, башкалар кебек үк тереклек итү, тормыш алып барырга сәләтле булу дигән мәгънәдә йөри.

Өйнең моржасыннан төтен чыга икән, димәк, анда кемдер яши, тереклек итә, өй җылытыла, ризык пешерелә.

Бер кешенең типсә тимер өзәрдәй таза, ләкин бик ялкау улы булган. Беркөнне әтисе улының шундый булуына бик эче пошып, болай дигән: «Юк, улым, булмас синнән, моржадан төтен чыгара алмассың син», – дигән.

Егет әтисенең бу сүзләрен туры мәгънәдә аңлаган. Бик гарьләнеп, өй түбәсенә менгән дә, янар-янмас кына пыскыган мичнең моржасына тас каплап куйган. Өй эченә төтен тулган. Теге кеше төтеннән качып ишегалдына чыккан икән, моржа кырында басып торган улы:

– Әти, әллә төтен чыга башладымы? Менә мин дә төтен чыгара алам бит! – дип кычкырган, имеш.

– Үзе ахмакның – сүзе ахмак, – дип юкка әйтмәгән шул халык.

4. Алтын канат атаң бар, көмеш садак анаң бар

Мәкальләр арасында ата-ана, бала турындагылары да шактый.

Әни кулы йомшак була

Әүвәл заманда ике килен-килендәш булганнар. Берсе гел – ир бала, икенчесе гел кыз бала таба икән. Менә тагын болар икесе дә балага узганнар. Ир бала тапканы – кыз, кыз бала тапканы ир бала көтә икән. Шулай өметләнеп йөргәндә, беркөнне болар тагы элеккечә бериштән бала табып куйгач, үзара сөйләшкәннәр дә, шул көнне үк бәбиләрен алыштырып, берсе икенчесенекен бала итеп алып үстерергә булганнар. Билгеле инде, бу хакта балаларның үзләренә белдермәгәннәр, һәрберсе ят әнине үзенеке дип белеп үсә. Беркөнне шулай бу киленнәр, балаларын алып, каената йортына кунакка килгәннәр. Киленнәрнең берсе икечесенең кулындагы үз баласын кочаклап алып, сөйгән-сөйгән дә кире биргән. Шуннан бу бала үзен асрап үстергән

киленгә килгән дә, үз анасына таба карап: «Әни, нигә теге апаның кулы бик йомшак?» – дип сораган, имеш.

Әти, чуманыңны алып кайтырга онытма

Элек заманда бер юньсез кеше үзенең картаеп хәлдән тайган атасын, чуманга утыртып, каядыр илтеп ташларга җыенган ди. Аның шул тирәдә генә уйнап йөрүче малае бу хәлне күреп тора ди. Әтисенең янына килгән дә: «Әти, чуманыңны алып кайтырга онытма!» – дигән.

Атасы: – Нәрсәгә ул, улым? – дигән.

– Син дә Дәү әти кебек картайгач, мин дә сине шул чуманга утыртып илтеп ташлармын, – дип җавап биргән улы, имеш.

Үзең ата-анаңа ни күрсәтсәң, үзең дә шуны күрерсең, дигәнгә ишарә. Ата-анага кадер күрсәткән, бала-чагадан кадер күрер, – ди халык.

Бала булганы бала була, чага торганы чага була

Элек бер җирдә берничә кеше дөньядан зарланып утыралар икән. Берсе, авыр сулап: «Әйе шул, заманалар авыр, бала-чага күп, чыгымнар зураеп китте, бер дә җиткереп булмый», – дигән.

– Баласы бала, чага дигәне ни соң ул? – дип сораганнар аңардан.

Яннарында бала-чагадан күп җәфа күргән өченче карт бар икән. Ул әйткән: «Шул балалар арасында чага торганы була, шунысын чага дип әйтәләр», – дигән.

Бала өчен ананың – йөрәге, атаның беләге авырта; ата йөрәге таудан өлкән, ана йөрәге диңгездән тирән; ата-ана йөрәгенең тирәнлеген балалар белми; улның ояты – атага, кызның ояты – анага кебек мәкальләр ата-ана – бала мөнәсәбәтләренең никадәр тирән, катлаулы икәнлеген тагын бер кат раслый.

5. Үз өемдә үз көем

Татар халкында йорт салу, йорт тоту, йорт кадере кебек төшенчәләр алгы планда тора. Үз гомерендә бер йорт салып кермәгән ир кешенең халык арасында абруе булмаган. Хәлле хәленчә үз куышын булдырырга тырышкан. Үз өеңә җитәме, әйтеме әле хәзер дә киң кулланылышта.

«Ай-һай, минем үз өем, киң сараем, бүз өем» мәкале борынгы мәкальләрдән санала. Ул атаклы Җирән чичәннән калган сүз икән. Хан аның акылыннан һәм авторитетыннан файдалану өчен үз янында тотасы килсә дә, Җирән чичән хан таләбенә күнмәгән, һаман үз өенә кайтарырга сораган. Хан аны кайтарып җибәргән дә, шымчыларына: «Барыгыз, өем дә өем, дигән чичәннең өен күрегез, анда ни сөйләгәнен тыңлагыз», – дигән. Җирән чичән хан каласының тышында бик ярлы кечкенә генә алачыкта яши икән. Шул өенә кереп, сәкесенә сузылып яткан. Аягы сыймыйча ишектән чыгып тора, үзе кәефләнеп, нидер сөйләнә икән. Шымчылар, бу ни сөйли икән, дип тыштан колак салсалар, Җирән чичән: «Ай-һай, минем үз өем, киң сараем, бүз өем», – дип җырлап ята, имеш.

Һәркемгә үзенең кечкенә генә алачыгы да патша сарайларыннан да газиз дигән сүз.

Киез өем – бүз өем, керсәм-чыксам үз өем; карт булса да ир булсын, кыек булса да, өй булсын; начар булса да үз куышың булсын; өе барның – иле бар, иле барның – **көе бар** кебек мәкальләр алдагы фикерне раслый гына.

Халык йорт тотмас, тормыш итә белмәүчеләрне дә чеметкәләп тора.

«Тормышны көт – мәңге торам дип, үлемеңне көт – иртәгә үләм» дигән мәкаль безне тырышып эшләп көн күрергә, башкалар арасында ким-хур булып, мескен булып яшәмәскә өнди.

Хөрмеш дигән бер ялкау булган. Аның Иван дигән бер белеше булган. Бу бик еш Иванга барып кунак була, ашап-эчеп, тамагын шунда туйдырып кайта икән. Үзе: «Миңа да кил, кунак булырсың, минем тормышны күреп китәрсең», – дип белешен үзенә чакырып китә икән. Бервакыт Иван ат белән Хөрмешкә килгән. Хөрмешнең тормышы бик ярлы икән. Белешен ничек кунак иткәндер, анысы билгесез. Бераздан Иван китәргә әзерләнә башлаган. Киткәнче атын эчермәкче булып, чиләк сораган. Хөрмеш аңа бер ярык табак чыгарып биргән. Күрәсең, аның чиләге дә булмаган. Иван ярык табакны кулына алып карап торган да: «Әй Хөрмеш, Хөрмеш, шушымыни инде синең тормыш?» – дигән, имеш.

Халык юкка гына, тора белсәң тормыш, тора белмәсәң, ормыш, димәгән шул!

6. Карама түшенә, кара эшенә

Халкыбызның эш, хезмәт турындагы мәкальләре бик күп. Фольклорчы-галим Н. Исәнбәт «Татар халык мәкальәре» җыентыгының беренче томына әлеге темага 1446 мәкаль һәм әйтем урнаштырган. Халкыбыз гомер-гомергә эш сөйгән, һөнәрле, намуслы хезмәт белән көн күрүчеләрне, тәвәккәл, тырыш кешеләрне хөрмәт иткән; иренчәк-ялкауларны, булдыксызларны, кеше җилкәсенә салынып яшәүчеләрне, йокы ратучыларны тәнкыйть утына алган.

Эшләгән – үлмәс, эшләмәгән – көн күрмәс; эше юкның кадере юк, кадере юкның кабере юк; тәвәккәллек – ярты бәхет; эштән көлмә, көлке булырсың; һөнәрле үлмәс, ачлык күрмәс; эше юк – эт сугарыр; ялкауга көн дә ял; тәвәккәл таш ярыр, булдыксыз баш ярыр; эшләгәнгә эш язган, бәхетсезгә йокы язган, ди һ.б.

– Ай-вай, эшләгән кеше нидән бай? – дигән ди Мокыт агай да.

Мокыт агай һаман да байлык табарга хыялланып ята, тәрәзәдән карап, күршеләренең һаман тырышып эшләгәннәрен күрә, аларның кесәсендәге байлыкны санарга ярата икән. Шулай ятып, үз кесәсендә бер тиен акчасы да калмагач, беркөнне тәрәзәдән күрше йортларга карап башын селкеп торган да, әнә шулай дип кычкырган, имеш.

Күп сүз бозау имезер, артка таяк тигезер

Беркөнне такылдык Шәрифә сыер саварга чыккан җиреннән читән аркылы гына күрше хатын белән сөйләшеп тора икән. Бозавы муенчагын салып килгән дә сыерны имәргә тотынган. Шул вакыт ире арттан килеп җитеп, кинәт: «Бозавың имә!» – дип кычкырып, Шәрифәнең артына таяк белән китереп суккан. Шәрифә сүздән айныган, ләкин бозау да сөтне имеп бетергән булган шул инде.

Эшләгәндә сүзгә мавыкма, дигән мораль чыга әлеге мәкальдән.

«Кушканны эт эшләр, үзе белеп адәм эшләр» мәкален баласына аңлатмаган әти-әни, әби-бабай сирәк булгандыр заманында.

Элекке заманда бер картның үсеп буйга җиткән бер углы

булган. Угылны өйләндерергә кирәк бит инде. Карт улын ияртеп, күрше авылга кәләш сайларга киткән. Бер җирдә кызлар җыелышып тора икән. Шулар янынан үткәндә, карт улын кыйнарга тотынган.

– Ник улыңны кыйныйсың, бабай? – дигәннәр кызлар.

– Ничек кыйнамаска! Ни әйтсәм – шуны тыңлый, ни кушсам – шуны эшли, – дигән бабай.

Кызлар, бабайны җүләргә санап, шаркылдап көлгәннәр.

– Әйткәнне тыңлагач, улың бигрәк тә акыллы икән, бабай. Кыйнама улыңны, – дигәннәр.

Бабай улына: «Монда сиңа ярарлык кыз күренми, әйдә киттек», – дип, улын икенче авылга алып киткән.

Бу карт шулай авылдан авылга малаен кыйнап кыз эзләп йөрсә дә, һәркайда җүләр исеме алып, килен табудан тәмам өметен өзеп, кайту юлына борылган. Шулай бер авыл башында кер чайкарга төшеп баручы бер кызны күргәч, карт гайрәткә килеп, малаена салган да җибәргән.

– Чү, бабай, ник улыңны кыйныйсың? – дигән кыз.

– Әйткәнемне тыңлый, кушканымны эшли, шуңа кыйныйм, балам, – дигән карт.

– Бик дөрес итәсең, кыйна, бабай, кыйна! Аның инде тыңлап эшләр чагы үткән, үз эшен үзе белеп эшләр чагы җиткән. Кушканны эт эшли, үзе белеп адәм эшли, – дигән. Шуны ишеткәч, картның бердән йөзе ачылып киткән, көлеп җибәргән.

Улына: «Менә, улым, өйләнәм дисәң, син өйләнерлек кыз шул инде, син шуңа өйлән», – дип әйткән, имеш.

Инде шушы темага грекларның да бер легендасын китереп үтик.

Сизиф эше яки михнәте? – дигән әйтемне күпләрегезнең ишеткәне бардыр. Авыр, алҗыткыч, очсыз-кырыйсыз, ләкин нәтиҗәсез, әрәм хезмәт дигән мәгънәдә кулланыла ул. «Борынгы заман тарихын» укыган кешеләр белә булыр: грекларның легендар герое Гераклга соңгы – уникенче батырлыгын күрсәткәндә Тартарга – үлекләр патшалыгына төшәргә туры килә. Ул анда бик гыйбрәтле, куркыныч, сәер хәлләр күрә. Әнә бер кеше тырышып-тырмашып зур бер ташны текә тау башына тәгәрәтеп менеп бара. Инде менеп җитәргә бер адым гына калды дигәндә, таш аска тәгәрәп төшеп китә. Кеше таш артыннан тау итәгенә

төшә, кабат ташны югарыга күтәрә – тагы таш аска тәгәри. Бу хәл берөзлексез кабатлана. Бу кеше Коринф патшасы Сизиф була. Дөньяда чакта эшләмичә генә кеше милкен үзләштереп яшәгәне өчен, ул мәңгелеккә әнә шундый каты җәзага хөкем ителгән икән...

Халык әйтсә, хак әйтә, дип, бүгенгә сөйләшүне тәмамлыйбыз.

7. Авызын ачса, үпкәсе күренә

Бу әйтемнең өч төрле мәгънәсе бар. Берсе – артык ябык, арык булу. Икенче мәгънәсе – бик ярлы, хәерче тормышта яшәү. Тагын бер мәгънәсе – үзенең кимчелекләре яхшы билгеле булган мохитта урынсызга мактанучы кешедән көлеп әйтү.

Фольклорчы **Хуҗи Мәхмүтов «Язылмаган кануннар»** *китабында (1995, 90 нчы бит)* бу гыйбарә турында болай ди: «Борынгы заманда бу әйтем табышмак буларак әйтелгән. 1303 елда кыпчак телендә язылган «Коман мәҗмугасы»нда ул «Аузум ачсам өпкәм көрүнүр» формасында бирелгән. Җавабы да бар: «Ол – эшик ачса, от күрүнгәнидер», ягъни «ул – ишек ачкач, күренә торган ут» рәвешендә теркәлгән». Табышмакта элекке тирмә, ягъни, киез өй сурәтләнгән. Тирмәнең учагы ишек каршында булган. Ишекне ачуга, ярымкараңгы тирмә эчендә кызыл ялкын күзгә ташланган. Нигездә мал асраучылык белән көн күргән кыпчакларның тирмәне хайван образы аша сурәтләнүе, ялкынның терлек үпкәсенә охшатылуы табигый күренеш.

Атланма, билен сындырырсың!

Әле кулга кермәгән, керәчәге дә бөтенләй өметсез нәрсәләр турында инде булып җиткән кебек итеп хыялланырга яратучылардан көлеп әйтелә торган гыйбарә. Килеп чыгышы халык мәзәге белән бәйле.

Бер дә бер көнне бик фәкыйрь тормышлы бер кешенең малае бер тавык йомыркасы табып кайткан ди. Атасы улына: «Улым, бу йомырка безгә зур байлык китерә ала, – бит дигән. – Без бу йомырканы күрше әбинең тавыгы астына салып чебеш чыгарырбыз. Чебеш үсеп җитәр дә, киләсе елга шушындый матур-матур йомыркалар салыр. Без ул йомыркаларны сатарбыз да,

сарык бәрәне алырбыз. Бер-ике елдан сарыкларыбыз күбәер. Өч-дүртен сатып, кырыкмыш тай алырбыз. Ул ике елдан сабанга җигәрлек ат булыр, өченче елында бик матур бер колын да китерер...»

Атасы шулай дигәч, малае шатланып: «Ул матур колынга атланып, мин чабып китәрмен, әйеме, әти?» – дигән.

Атасы ачуланып: «Атланма, билен сындырырсың!» – дип, өстәлгә китереп суккан икән, учындагы йомырка ватылып, әллә кайларга чәчрәп киткән.

Халык телендә бу мәкальнең «булмаган бия, тумаган тай, атланып билен сындырма», «тумаган тайның билен сындырырсың», «алмаган ат, тумаган колын» вариантлары да киң таралган.

8. Атсыз авыруның аты корысын

Каюм Насыйри үзенең «Ләһҗәи татари» сүзлегендә татарларның томау, бизгәк кебек авыруларны «атсыз» дип йөртүләре турында язган. Чөнки, халыкның ышануынча, күп кенә чирләрнең исемнәрен телгә алмау аларны булдырмый калуда мөһим шарт булып саналган. Әгәр авыруның исемен әйтсәң, ул ишетә дә, кешегә авыру килә, дип шомланганнар. «Атсыз авыруның аты (исеме) корысын. Авыруның колагы сак. Атын атама – адашып китсен» кебек гыйбарәләр шул җирлектә барлыкка килгәннәр.

Мәсәлән, халыкта, **арпа дисәң – арта, бодай дисәң – бетә**, дигән әйтем бар. Күз кабагы читенә чыга торган эренле кечкенә шешне арпа, диләр. Күзгә арпа чыкса, аны юри «бодай» дип атаганнар, шулай итсәң, шеш бетә, имеш. Республикабызның көнчыгыш төбәгендә **арпа дисәң** – **арта, бетчә дисәң** – **бетә** варианты кулланыла. Бу гыйбарәләрнең килеп чыгышы борынгы **табу (тыю мәгънәсен аңлата)** күренеше, ягъни билгеле бер шартларда нинди дә булса сүзләрне яки эш-хәрәкәтне тыю йоласы белән дә бәйләнгән. Аерым сүзләргә **табу** салу һәм алар урынына алмаш сүзләр куллану ярдәмендә борынгы кешеләр сүзнең тылсым көченнән файдаланырга, үзләре өчен хәвефле затны, чирне сүз ярдәмендә буйсындырырга, яхшы якка үзгәртергә ом-

тылганнар. Мәсәлән, татар халкында елан күрсәң, елан дип оран салырга ярамый, камчы дияргә кирәк, дигән фикер бар. Елан дисәң – чага, елата, камчы дисәң, тик ята, я әкрен генә шуышып китеп бара еланың.

Еланны корт дип атау да бар. Елан дисәң – елышып килә, корт дисәң – корый. Йөрәгенә төшкән кандаланы да халык кибәк дигән. Шулай дисәң, теге кahәр, кибеп, кибәккә әйләнә икән (кандала, дисәң – кадала, кибәк дисәң – кибә). Бу күренешләр, шулай итеп, сүзнең тылсым көченә ышану белән бәйле.

9. Мифологик образларга бәйле мәкаль-әйтемнәр

Татар фольклорында мифологик образлар белән бәйле хикәятләр, әйтемнәр шактый. Шундыйларның берсе – «**Аңа бичуралары булыша, ахрысы**». Имештер, бичура хатын-кыз затыннан була. Башына өрпәк-өчпочмаклы яулык салып йөри: бәрәңге базларында, идән асларында, ташландык мунчаларда тора, имеш. Бичура төнлә өйгә кереп, юылмыйча калган савыт-сабаның барысын да ялап чыга. Әгәр савытта күңеленә ошамаган нәрсә очраса, кулына эләккән бар әйберне, төрлесен төрле якка ыргыткалап-бәреп, ватып-сындырып чыгып китә. Шуңа күрә төнгә савыт-сабаны юмыйча өеп калдырырга ярамый икән. Әгәр йортыңа бичура ияләнсә, бик сак булырга кирәк. Ара-тирә бичураларның яхшылары да очрый икән. Шундый бичура ияләшсә, өй хуҗасы байый ди. Ни кирәк булса, бичура барын да табып китерә икән. Бичура бар чагында бай гына торган кешеләр, яхшы бичура китсә, ярлыланалар икән.

Эше үрчемле кеше турында: «**Аңа бичуралары булыша, ахры**», – дип әйтү әнә шундый ышануга нигезләнгән.

Бичура белән бәйле тагын бер әйтелмә: **бичура урладымы әллә?** Бичураның тагын бер яраткан шөгыле – ул, еш кына, бер җиргә куелган нәрсәне икенче урынга яшерә ди. Шуңа күрә, өйдәге берәр әйберне эзләп-эзләп тә таба алмый аптырагач: «Кая гына китте соң? Бичура урладымы икән әллә?» – диләр. Кайчагында, **бичура, куй әйберне үз урынына**, диләр. Ни хикмәт, бераздан әйберне элек куйган урыннан табасың да.

Пәри башка, җен башка – берише әйбернең арасында аерма бар, дигәнне аңлата.

Пәри – Иран мифы, ә Җен – гарәпнеке. Шулай булуы белән дә, чыннан да, башка. Пәри – гүзәл кыз мәгънәсендә.

Пәри кызы! Ник чыктың да юлларыма,
Утлы кызыл гөлләр тотып кулларыңа?
Гөлләреңне ыргытып бер елмайдың да,
Ник яшерендең, төренеп таң нурларына?

***(Һ. Такташ.** «Таң кызы»)*

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын искә төшерик. Йосыф искиткеч чибәр, аңа тирә-якта тиңнәр юк. Барысы да аны күреп соклана, матурлыгы телдән-телгә сөйләнелә. Берара Йосыфта шушы сыйфаты белән горурлану, масаю булып ала. Шул чорда Ходай Тәгалә әмере белән Йосыфның юлы пәриләр шәһәре аша уза. Монда аңа игътибар итүче дә булмый, чөнки пәриләр гүзәллеге янында Йосыфыбыз урта матур дәрәҗәсендә генә икән!

«Халыкта пәри сүзе гарәпнең җен сүзенә тагылып, мөселман пәрие һәм мөселман түгелгә аерылып, икесе дә кешегә кагыла һәм саташтыра торган явыз мифлар булып киткән», – ди Н. Исәнбәт һәм «пәри туе, пәри алыштырган» кебек мисаллар китерә *(«Татар халык мәкальләре», 3 том, 764 нче бит).* Әкиятләребездә шулай ук **дию пәрие** мифологик образы да еш очрый.

Латинда, руста пәри – изге мәгънәсендә.

10. «Йөзек кем кулында булса, шул – Сөләйман»

Легендалар буенча, Сөләйман пәйгамбәр дөньядагы барлык патшалар өстеннән генә түгел, бәлки, кош-кортлар, җәнлекләр, җилләр, җен-пәриләр, диюләр өстеннән дә хакимлек иткән. Мондый чиксез кодрәткә ул тылсымлы йөзек ярдәмендә ирешкән. Аллаһы Тәгаләнең 99 исеме арасыннан иң бөек исеме язылганга күрә, бу йөзек хуҗасына җен-пәриләрне, кош-кортларны, җил-суларны үз ихтыярына буйсындырырлык кодрәт бирелгән. Әгәр йөзеге югала калса, аның бөтен көч-кодрәте юкка чыккан.

Бервакыт, Аллаһының рәхмәте белән, икенде намазына кадәр Сөләйманга гаиптән атлар бирелә. Сөләйман атларның матурлыгына соклана, аларны уйнатып, икенде намазын оны-

тып кичектерә. Шуның өчен Аллаһы Тәгалә аның патшалыгын алып, бәлага тарта. Бер кичне йөзеген хатыны янында калдырттыра. Сөләйман сурәтенә кергән бер җен йөзекне алып китә, шуның белән Сөләйманның кулыннан патшалык та китә. Аның тәхетенә, Аллаһының кодрәте белән, әлеге йөзекне алган җенне утырталар. Соңрак Сөләйман пәйгамбәр тәүбә итә, Аллаһыга кайта, йөзекне кулга төшереп, яңадан патша була.

«Власть хокукы кем кулында булса, шул көчле, шул хаким», дигән мәгънә ята әлеге әйтемдә. Сөләйман йөзеге – чикләнмәгән хакимлек, кодрәт, буйсындыру көче символы.

«Бар да үтә» дип язылган Сөләйман балдагына

Сөләйман патша никадәр акыллы, гыйлем булса да, аның тормышы бик тынгысыз икән. Бервакыт ул киңәш сорап акыл иясе янына барган. «Ярдәм ит, зинһар, акыл иясе. Чыгырымнан чыгарлык чакларым була. Нишлим?» – дигән. Акыл иясе аңа бер балдак биргән. «Ки шушы балдакны. Анда **бар да үтә**, дип язылган. Бик нык ачуың килгәндә яки бик нык шатланганда, шул язуга кара», – дигән. Сөләйман патша акыл иясенең сүзләрен тыңлаган һәм үзенә тынычлык тапкан. Бервакыт ул бик нык тузынган, ачуыннан шартлар дәрәҗәгә җиткән. Кулындагы балдак та ярдәм итмәгән. Ул, ачуыннан, балдакны бармагыннан суырып алган да суга ыргытырга уйлаган. Шул вакыт балдакның эчке ягына язылган язуга күзе төшкән. Анда, **монысы да үтәр**, дип язылган булган ди.

Сөләйман үлде, диюләр котылды

Бу мәкаль Н. Исәнбәтнең *«Татар халык мәкальләре»* җыентыгына теркәлгән *(3 том)*. «Диктатор үлеп, кемнең дә булса эшенә комачау калмауга мисал», – дигән искәрмә дә бирелгән. Белүебезчә, җеннәр Сөләйман пәйгамбәргә хезмәт итә. Алар Сөләйман пәйгамбәр теләгәнчә, биек-биек өйләр салганнар.

Сөләйман пәйгамбәрнең, Ходай Тәгалә билгеләгән гомере беткәч, мөнбәрдә басып торган хәлдә, җаны алына. Аның үлгәнен җеннәр дә, кешеләр дә белми. Үлгән хәлдә, таянып торган таягын кортлар ашап өзгәч кенә ул җиргә егыла. Шуңа кадәр җеннәр бу, безгә карап тора дип, һаман эшлиләр дә эшлиләр, егылгач кына, котылдык, дип качканнар ди.

11. Аю хезмәте күрсәтү

Бу әйтем «белмичә, урынсыз ярдәм күрсәтеп, күңелсезлек китереп чыгару» дигән мәгънәдә кулланыла. «Аю хезмәте күрсәтү» әйтелмәсе русчадан «оказать медвежью услугу»дан калькалаштырылган булырга тиеш», – ди фольклорчы Хуҗи Мәхмүтов. Ә рус теленә ул И.А. Крыловның «Пустынник и медведь» мәсәленнән кереп киткән. И.А. Крылов аны рус халык әкиятенә нигезләп язган булган. Бу әкият татар халкы арасында да таралган. Аны венгр галиме Габор Балинт 1870 елда ук Казан өязендә язып алган һәм 1875 елда Будапештта бастырып чыгарган. Менә ул әкият.

Әүвәле бер мужик белән аю дуслашканнар да урманга киткәннәр. Урманда мужикның йокысы килгән дә ятып йоклаган. Аю моны каравыллап тора икән. Бервакыт мужикның маңгаена бер чебен килеп кунган. Аю аны тырнагы белән куып караган, ләкин чебен селкенмәгән дә. Шуннан соң аю җирдә яткан бер ташны алгы тәпиләре белән күтәреп алган да чебенгә бәргән. Чебен очып киткән, ә мужик үлгән.

И. А. Крылов әйткәндәй, «услужливый дурак, опаснее врага!»

Башыңа төшсә, башмакчы булырсың

Нинди дә булса эшне теләмичә, аптыраудан, чарасызлыктан башкару мәгънәсендә кулланыла. Кайбер кешеләр бу әйтемне башмак тегүче яки башмаклар белән сату итүче дип аңлый. Алай түгел икән шул. Кайчандыр «башмакчы» дип мәчеткә килгән кешеләрнең башмакларын саклап һәм мәчеттән чыгучыларга биреп торучыны атаганнар. Авыр һәм дәрәҗәсез һөнәр дигәнгә дә туры килә.

12. Аты барның – канаты бар

Бик борынгы заманнардан башлап күп гасырлар буена хуҗалык эшләрендә, юл-сәфәр йөргәндә, гаскәри хезмәттә ир кешенең төп таянычы, булышчысы, юлдашы ат булган! Шуңа күрә телебездә атлар турында шактый гына мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, әкиятләр, җырлар бар. Н. Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» җыентыгында (1 том) атлар белән бәйле

757 мәкаль һәм әйтем теркәлгән. Ат – мәкальләрдә ирлек, егетлек, түземлек, дан билгесе. Шулай ук юлдаш һәм морадка җитү чарасы да. 11 гасырда Мәхмүд Кашгарый төзегән «Диване лөгат-эт-төрек» («Төрки сүзләр җыелмасы») сүзлегендә «Куш – канатын, эр – атын» мәкале теркәлгән икән. Бу – кош өчен канат ничек кирәк булса, ир өчен ат та шулай кирәк була, дигән мәгънәне аңлата**. «Ир канаты – ат**» әйтелмәсе әнә шуннан калган.

Габдулла биясе. Юньле хуҗа үзенең төп ярдәмчесе һәм терәге булган атны ничек тә тәрбияләргә тырышкан. Яхшы, таза, көчле ат хуҗаның горурлыгы булган. Начар ат шулай ук хуҗасының ниндилеген аңлаткан. Ат белән бәйле төрле мәзәк хәлләр дә була тормышта. Менә шуларның берсе. Кайдадыр һәм кайчандыр бер авылда Габдулла исемле кеше яшәгән. Бик ярлымы, әллә бик саран булганмы ул, ничек булса да булган, бер дә бер көнне моның биясе ачтан үлгән. Хуҗа бу хәлгә уңайсызланып, атының авызына бер учма печән тыгып куйган да, кешеләр чакырган. «Менә атым ашаганнан үлде», – дигән. «Тун сыпырганны, ат сыйлаганны ярата», – дип юкка әйтмиләр шул.

Табын янында назланып, нәзберекләнеп утыручыга да: «Аша-аша, ашаганнан кеше үлми, Габдулла биясе генә үлә», – диләр.

13. Безнең дә атабыз кияү, анабыз килен булган

Халыкта кияү-киленнәр белән бәйле бик күп мәкаль-әйтемнәр бар. «Яхшы килен – килен, яман килен – үлем; яхшы кыз килен булгач күренер; яхшы килен – өй күрке; киленне елсыз мактама; килен килбәтле булсын, сүзе ширбәтле булсын; килен сүз чыгара, тавык күз чыгара» һ.б. мәкальләрдә килен кешенең уңай һәм тискәре яклары сыйфатлана.

Кыз кеше килен булып төшкәндә үзе белән бирнәсен дә алып килгән. Әлбәттә, бае байча, урта хәллесе уртача, ярлысы ярлыча. К. Насыйри «Татар этнографиясе материаллары» исемле хезмәтендә татарларда килен төшерү гадәтен бик тәфсилләп бирә. «Кыз үзенә тиешле нәрсәләрне атасының өендә бер дә калдырмый», – ди**. «Киткән кыздан пумала курка»**, – дип

йомгаклап куя. Пумала почмакка посып: «Мине дә эләктереп китмәсә ярар иде», – дип, дер калтырап торыр ди. Төп йорттан аерылып башка чыгучыларга карата да кулланыла бу әйтем.

Кияү үзебезнеке. Бу шаян гыйбарә кешене артык басымчак итүгә, аның сабырлыгыннан, юашлыгыннан чама белми файдалануга карата кулланыла. Бер кияүне дә бабасы кунакка килгәч, аш-су вакытында, кияү үзебезнеке, гаеп итмәс, дип, түрдән ишек төбенә кадәр күчереп утырткан ди. Икенче юлы кияү дә бабасын җавапсыз калдырмаган. «Бабай үзебезнеке, гаеп итмәс», – дип, колак төбенә менеп төшкән ди.

Тай биреп сөйләткән идем, ат биреп туктата алмыйм.

Бу гыйбарә күбрәк тел-сүз культурасына бәйләп кулланыла. Ул башта тартынып яки әдәп саклап үз-үзен тыеп, тартынып торып, аннан сүзгә бер керешеп киткәч, чик-чаманы онытып җибәрүче, кирәгеннән артык сөйләшүче кешедән көлеп әйтелә.

Элек заманда бер карт улын өйләндергән. Ул чактагы гадәт буенча килен кеше каенатасыннан тел яшерә икән. Каената булган кешенең киленен бик тә сөйләштерәсе килә икән. Беркөнне киленең әйткән бу: «Килен, – дигән, – инде бер ел тордың, әйдә, сөйләшә башла. Сөйләшсәң. тай бирермен», – дигән.

Килен сөйләшә башлаган. Шуннан бер атна да узмаган, болар сөйләшү генә түгел, талаша ук башлаганнар. Инде каената ялына икән: «Килен, зинһар, сөйләшмәсәнә, ат бирер идем», – ди икән. Шулай, сөйләшмәсәң дә ярамый, сөйләшсәң дә ярамый!

14. Язганны күрерсең, чәчкәнне урырсың

Күлмәктән туган – эше уңа торган, бәхетле кеше турында әйтелә. Шулай ук телдә бу әйтелмәнең **карындыгы белән туу, йөзлек белән туу, сүрү белән туу** вариантлары да кулланыла. Мәхмүд Кашгарыйның мәгълүм «Төрки телләр сүзлегендә» («Диване лөгат-эт-төрек») «Каплыг огул» ягъни, кап, сүрү эчендә туган бала» дигән әйтелмә теркәлгән һәм аның «бәхетле» мәгънәсендә йөрүе күрсәтелгән.

Күлмәктән туган дип, шулай ук бәла-казалардан, фаҗигале хәлләрдән исән-имин калган кешегә карата да әйтәләр.

Маңгай йолдызлы булу. Бу гыйбарә дә бәхетле булу

дигән мәгънәгә ия. «Бәхетле язмыш иясе» мәгънәсе белән бергә бу әйтелмә кешенең тышкы күркәмлеген дә белдерә. «Бүрегемнең кондызына карама, маңгаемның йолдызына кара». Йолдызлы – бәхетле булу. Бүрегем кондыз тиресеннән булуы бәхетемнән, дигәнне аңлата.

Бер әкияттә патша кызы кияү сайлаганда мондый шарт куя: «Миңа кияү булачак егетнең кимендә 70 төрле һөнәре булсын; теше белән тешләп тимер өзсен, өреп пыяланы ватсын, ат менеп җилне чабып узсын, бер битендә – кояш, бер битендә – ай, маңгаенда йолдыз ялтырасын», – ди.

Маңгайга язылу. Кешенең һөнәрен, холык-фигылен тышкы кыяфәтеннән үк чамалап булса, бу кеше турында «аның кемлеге маңгаена язылган», диләр. Яки, киресенчә, кешене тышкы кыяфәтенә карап кына тану-бәяләү кыен булганда, «мин аны каян белим, маңгаена язып куелмаган бит», диләр. Бу гыйбарәнең барлыкка килүен элекке заманнарда кешеләрнең тәннәренә тамга-билге салу күренешләренә бәйләп карау бар. Мәсәлән, «у него на лбу написано» әйтелмәсе борынгы рус дәүләтендә җинаятьчеләрнең маңгайларына кыздырылган тимер белән келәймә сугудан килеп чыккан дип аңлатыла. Алексей Михайлович патшалык иткән чорда (17 гасыр) келәймә урынына яндырып, «б» дип, ягъни «бунтовщик» сүзенең беренче хәрефен яза башлаганнар. Шул рәвешле бичараларның кемлеге, чыннан да, аларның маңгайларына языла торган булган.

Татар телендә «маңгайга язылу» гыйбарәсе «кешенең язмышы алдан ук билгеләнеп куела» дигән мәгънәдә кулланыла күбрәк. Ислам дине өйрәтүенчә бу шулай. «Маңгайга язылган җуелмый; маңгайга язылган язмышны тир белән сыпырып ташлап булмый» кебек мәкальләр шуннан калган.

Халыкта кешенең төс-бит, буй-сынына карап юрау сүзләре шактый. Маңгай төзелешенә карап, сынауга нигезләнгәннәре дә бар: маңгае киң кешенең зиһене яхшы була; маңгае тарның акылы тар; маңгае ак – йөзе пакь.

Бу өзекләр Хуҗи Мәхмүтовның «Язылмаган кануннар» китабыннан алынды (1995).

15. Колакка киртеп кую

Телебездә **«колакка киртеп кую»** әйтелмәсе бар. Ул бик нык кисәтү, онытылмаслык итеп әйтү, истә тоту, хәтердә саклау мәгънәләрен аңлата.

Тамырындагы кирт сүзе киртләү, кирт ясау агачка яки башка нәрсәгә үткен әйбер белән сыр, тамга ясауны аңлата. Элекке заманда гади халык мондый кирт-тамгаларны исәп-хисап эшендә, алачак-бирәчәк бурычларны билгеләп бару өчен дә файдаланган. Шулай ук терлекләрнең колакларына кирт ясап, тамга салганнар. Менә шуннан күчерелмә мәгънәдә «колакка киртү» тезмәсе. Тора-бара образлы әйтелмә буларак телебезгә кереп киткәндер.

– «Колакка киртү» гыйбарәсенең нигезендә «киртләү» фигыле түгел, ә борынгы төрки телләрдәге **кирит** сүзе ятуы мөмкин, – ди фольклорчы Хужи Мәхмүтов һәм 11 йөз галиме Мәхмүд Кашгарыйның «Төрки телләр сүзлеге»ндә «киритләү» сүзенең **ябу, бикләү** мәгънәсен аңлатуын әйтә. Капуг киритләде – капканы бикләде, киритле капуг – бикле капка мисалларын китерә.

Элек кешегә бик җитди, әһәмиятле сүз әйткәндә «колагыңа киртлә», ягъни, колагыңа салып-бикләп куй, дип кисәтә торган булганнардыр. Хәзерге вакытта без аны колакка киртләү формасында кулланабыз. Ике вариант та дөрескә туры килә.

Нервыда уйнау. Төп чыгышы белән латин теленнән кергән әйтелмә, әмма татар телендә дә бик актив кулланылышта. Хәтта балалар да урынын белеп куллана! Мәгънәсе: кемнең дә булса ачуын китереп, озак вакыт ошамаган нәрсә эшләү, сөйләнү, кәеф җибәрерлек эш-гамәлләр кылу. Нервыда уйнау әйтелмәсенең чын мәгънәсендә музыкаль тарихы бар. Кешеләр бик борынгы заманнарда ук кыллы музыка кораллары ясарга өйрәнәләр. Латинча «кыл» сүзе «нервус» дип йөртелгән. Нервыда уйнау – кыллы музыка коралында уйнау дигәнне аңлаткан. Соңга таба врачлар кеше организмында да «кыллар» булуын ачыклаганнар һәм аларны да «нерв»лар дип атаганнар. Шулай итеп, нервыда уйнау тезмәсе күчерелмә мәгънә алып, кеше нервыларына карата кулланыла башлаган.

16. Питрау күкесе

Бу әйтелмәнең кулланылышы да сөйләм культурасы белән бәйле. Сүзнең вакытын белмичә, бигрәк тә эш узганнан соң сөйләнеп йөрүчеләргә **«Питрау күкесе»**, яки «вакытсыз сүз сөйләмә, Питрау күкесе булырсың», – дип әйтәләр.

Питрау (Петров день) – яңа стиль буенча 12 июльгә туры килә. Татар халык календарена руслардан кабул ителгән бу дата элек бездә үләннәр өлгереп җитү, печән өсте башлану вакыты булып исәпләнгән. Махсус симертеп, печәнгә төшкәндә суела торган яшь тәкәне «**Питрау тәкәсе**» дип йөрткәннәр. Телебездә тагын «**Питрау үләне**» дигән төшенчә дә яши. Шифалы, имдәва үләннәрен Питрау алдыннан җыйганнар. Сынамышларга караганда, Питрауга чаклы үләннең шифасы – чәчәктә, Питраудан соң – тамырда.

«Питраудан соң сандугачның теле бетә, үләннең тәме бетә», – сынамышыннан күренгәнчә, байтак кошларның үзүзләрен тотышында үзгәрешләр күренә. Алар хәзер таң белен-белен мәстән үк кошчыкларына азык эзләп чыгып китәләр, җырлап-сайрап утырырга вакытлары калмый. Хәтта, гаилә мәшәкатьләреннән азат булган күке дә Питрауга кадәр генә кычкыра, аннан соң ул да сакаулана. Питраудан соң кычкырып, сакаулыгын гына белдерә, имеш. Шуңа күрә вакытлы-вакытсыз, урынлы-урынсыз сөйләшеп, үзен уңайсыз хәлгә куючыны «Питрау күкесе» дип атау калган.

Алланың кашка тәкәсе. Борынгы заманнарда төрки халыклар, шулай ук татарлар маңгаенда кашкасы – ак табы, ак йон үскән төше булган терлекне изге дип санаганнар. Аеруча, маңгаенда кашкасы булган җирән-кызгылт-көрән ат, халыктагыча әйтсәк, җирән кашка бигрәк тә хөрмәт ителгән. «Җирән кашка аткаем, башын чайкый малкаем», – дип җырлыйлар да бит. Җирән кашканың ите һәм тиресе халык медицинасында да киң файдаланылган. Вак терлекләр арасында хөрмәтле урында кашкалы сарык тәкәсе торган. Башкалар алдында үзен һавалы, эре тотучан, үзенә аерым хөрмәт-игътибар таләп итүчегә карата: «Әллә син Алланың кашка тәкәсеме?» – әйтеме кулланыла. Яки, үзен Алланың кашка тәкәсе дип белә, харап кылланмышы, дип тә әйтәләр.

17. Сафура буранны

Телебездә кулланылучы бу әйтелмәнең берничә мәгънәсе бар. Тезмәдәге **буран** сүзе үк ниндидер стихияле бәла-казага ишарәли кебек. Әмма Сафура исеме белән буран икесе бергә нинди мәгънәгә ия икән? Аңлашылганча, Сафура – хатын-кыз исеме. Исемнәр сүзлегендә ул «кешенең игелекле эшләрен язып баручы, аның күңелен, холкын төзәтүче фәрештә» мәгънәсен аңлата.

Бәлки, шушы исемне йөрткән хатын-кыз, үз исеменә хилафлык китереп, гел буран туздырып, тавыш чыгарып яшәгәндер? Н. Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре»ндә бу исем берничә мәртәбә телгә алына һәм ул «җәнҗал остасы» Сафура буларак кулланыла. Бер мәзәктә сөйләнгәнчә, ул яшьтән үк усал телле, талаш остасы булган. Аның теленә берәү дә чыга алмаган. Бер мәзәктә ул хәтта дию пәриен дә җиңүче итеп сурәтләнә.

Сафура бураны әйтелмәсен дини риваятьләргә бәйләп карау да бар. Мәсәлән, Н. Исәнбәт язганча, ул Муса пәйгамбәрнең хатыны Сафураның, яһүдиләрне адаштыру өчен, ком чүлендә гаять каты буран чыгаруы турындагы хикәяткә барып тоташа.

Тел галиме Рифкать Әхмәтҗанов фикеренчә, гарәпләрдә «сафура» сүзенең ике төрле «С» белән язылучы варианты бар икән. Бер очракта ул «фәрештә» дигәнгә туры килсә, икенче очракта «сары ком бураны» – күчерелмә мәгънәдә – усаллык, гайрәт чәчүче хатынны белдерә.

«Сафура буранны» әйтелмәсе күбрәк йорт эчендә, хатын-кыз тарафыннан чыгарылган җәнҗалны аңлата. Шулай ук теләсә кайсы коллектив эчендә талаш, шау-шуны да белдерә ала. Язучыларыбыз да үз әсәрләрендә бу әйтелмәне кулланалар.

Аңа бар да кырыккан. Гаять тискәре, үзсүзле, үҗәт кешегә карата кулланыла торган әйтелмә. Кулланылышка кереп китүе бер мәзәк белән бәйле. Сафура кебек киребеткән, үзсүзле, усал бер хатын булган ди. Ире нәрсә әйтсә дә, гел киресен эшли икән. Эшлә дисәң – эшләми, сөйлә дисәң сөйләми, утырма дисәң – утыра, көлмә дисәң – көлә ди. Бервакыт болар агымсу буендагы печәнлекләрен кararга барганнар.

– Печәнне чапканнар! – дип әйтте ди ире.

– Нишләп чапсыннар аны, кырыкканнар бит, – дигән хатыны.

Ире хатынын куркытмакчы булып: «Чапканнар, диген. Юкса, суга төртеп төшерәм», – дигән.

Хатын һаман «кырыккан», ди. Ир хатынын суга башта тездән керткән, аннан соң муеныннан батырган, тегесе һаман «кырыккан» дип әйтә ди. «Чапкан, дип әйт, шулай дисәң чыгарам», – дигән ире. Тегесе «кырыккан да кырыккан»! Менә хатын суда бер бата, бер калка башлады ди. Калыккан арада «кырыккан», дип кычкыра ди. Актыгында кулын күтәреп, су өстендә ике бармагын кайчы белән кырыккандагы кебек күрсәтеп, агып китте ди.

18. Грек, Рим мифлары буенча таралган мәкаль-әйтемнәр

Татар телендә чит телләрдән кергән мәкаль-әйтемнәр дә шактый. Аларның күбесе тарихи вакыйгалар, әдәби әсәрләр, легендаларга бәйле рәвештә рус теле аша телебезгә килеп кергән. Мәсәлән, грек, Рим тарихы, легендаларындагы образлар, цитаталарны мисалга алырга була. Алар, башлыча, калькалаштыру юлы белән ясалганнар.

Калька – француз сүзе – үтә күренмәле, копия мәгънәсен аңлата; ягъни, сүзгә-сүз тәрҗемә.

Килдем, күрдем, җиңдем – еш кына мондый әйтелмә авыр бурычны җиңел генә хәл иттем дип, зур эш майтарган кебек кыланучы кешеләргә карата кулланыла.

Тарихта сөйләнелгәнчә, борынгы Римнең атаклы дәүләт һәм политик эшлеклесе, полководец Юлий Цезарь, имештер, үзенең бик тиз һәм бик җиңел яулаган җиңүеннән соң, Римга әнә шундый хәбәр җибәргән. «Пришел, увидел, победил!»дан сүзгә сүз тәрҗемә.

Котылырга теләп бу афәттән
Үксез манаралар күккә ашкан.
«Килдем. Күрдем. Җиңдем».
Тыныч кына
Имза куя турист изге ташка.

*(**Зөлфәт**. «Адашкан болыт», 1990).*

Барлык юллар Римга илтә – Все дороги ведут в Рим

«Бөтен юллар Римга илтә иде
Цицероннар исән чагында», – дип язган Х. Туфан «Әй» шигырендә.

Төрле чаралар, гамәлләр объектив рәвештә бер үк нәтиҗәгә китергәндә, бер үк максатка төрле юллар белән ирешеп булуга ишарә.

Борынгы Рим – зур сәяси, икътисади һәм мәдәни үзәк булган. Озак гасырлар дәвамында бик күп халыкара мәсьәләләрне бары тик Римга барып, Римның рөхсәте яисә булышлыгы белән генә хәл итәргә мөмкин булган. Туры мәгънәдә дә бу шулай, чөнки империягә буйсынган төрле ил-төбәкләрдән башлана, я уза торган күпсанлы юллар, барысы да шушы «мәңгелек шәһәр»гә килеп чыккан.

Аннибал анты – әйтелмәсенә тукталып китик. Төньяк Африкадагы борынгы Карфаген дәүләтенең генә түгел, ә борынгы заман тарихының атаклы полководецы, дәүләт эшлеклесе Ганнибал исеме белән бәйле әйтелмә бу. Ганнибал б.э.к. 247–183 елларда яшәгән. Ул ун яшьлек малай чагында ук үз илен коллыкка төшергән римлыларга каршы бөтен гомере буе килешмәүчән көрәш алып барырга ант итә. Соңыннан, полководец булгач, аның армиясе Рим гаскәрләрен күп тапкырлар җиңүгә ирешә, әмма Римны ала алмый. Зама шәһәре янында карфагенлылыр хәлиткеч җиңелүгә дучар булалар. Дошман кулына төшмәс өчен Ганнибал көнчыгышка кача һәм соңыннан үз-үзен агулап үтерә. Шулай итеп ул үзенең балалык антына ахыргача кадәр турылыклы булып кала. Аннибал анты – халык азатлыгы өчен ахыргача нык торып көрәшергә карар бирү мәгънәсендә кулланыла. Шулай ук яшьтән биргән антка тугры калучыларга карата да әйтелә.

19. Грек мифларыннан кергән әйтелмәләр

Грек мифларыннан кергән әйтелмәләр дә шактый икән телебездә. Алдагы тапшыруларыбызда икесенә – **Дамокл кылычы, Сизиф хезмәте** гыйбарәсенә тукталган идек инде. Бүгенге чыгышта тагын берничә әйтелмә, аларның телебездә кулланылуы турында мәгълүмат биреп китәрмен.

Ахиллес үкчәсе. Бу гыйбарәнең килеп чыгышы мифологиягә кайтып кала. Ахилл яки Ахиллес – борынгы грек легендаларының бик популяр курку, җиңелү белмәс герое. Дошман уклары күпме генә тисә дә, Ахиллга бернинди зыян китерә алмаганнар. Чөнки, имештер, Ахиллның әнисе – диңгез алиһәсе Фетида кечкенә чагында улын изге Стикс елгасына чумдырып алган була. Тик малайны чумдырганда әнисе аны үкчәсеннән тотып торган. Шул сәбәпле, изге су Ахиллның үкчәсенә тими калган. Бу хакта Ахиллның дошманы Парис белеп алган һәм аны үкчәсенә ук атып үтергән. Менә шушы легендага таянып, кемнең яки нәрсәнең дә булса кимчелекле, җитешсез, тиешенчә якланмаган, тиз зарарланучан, йомшак ягы турында «бу аның ахиллес үкчәсе» дип әйтә башлаганнар.

Гордий төене. Бу гыйбарә нинди дә булса катлаулы, буталчык эшне тиз арада һәм кыю рәвештә хәл итү мәгънәсендә кулланыла. Аның килеп чыгышы да борынгы грек легендасына барып тоташа.

Фригия дәүләте бервакыт патшасыз кала. Киләчәк турында хәбәр бирүче жрец-оракул – фригиялеләргә Зевс храмына барырга һәм юлда җигүле арба белән очраган беренче кешене патша итеп сайларга куша. Фригия кешеләре храмга таба юнәләләр һәм беренче итеп гади игенче Гордийны очраталар. Патша итеп сайлангач, Гордий үз язмышына шундый зур үзгәреш керткән арбаны Зевс храмына китертә һәм аның тәртәсенә гаять буталчык төен ясап, үгез камыты бәйләп куя. Оракул исә, кем дә кем шул төенне чишсә, ул кеше бөтен дөньяга хаким булачак, дип белдерә. Борынгы заманның бөек полководецы Александр Македонский Фригияне яулап алгач, әлеге хикмәтле төен турында ишетә. Ул храмга керә дә, төенгә бераз карап торгач, кинәт кылычын суырып чыгара да аны бер селтәнүдә чабып өзә.

20. Дөньяны сүз бизәр

Әйе, дөньяны сүз бизәр, сүз бозар. Сүзгә бик зур миссия йөкләнгән, дидек. Шушы сүз дигән бөек галиҗәнапне кулланып, сүзләрдән чәчәкләр ясаучы каләм әһелләре, аларны илһамландыручы шартлар турында берничә сүз.

Парнас тавы. Парнас – әдәбият-сәнгать өлкәсенә караган символик атама. Борынгы грек мифларында сөйләнгәнчә, Парнас – Фессалиядәге бер тау. Ул музалар, ягъни шигърият, сәнгать, фән алиһәләре һәм аларның башлыгы Аполлон яшәгән урын. Күчерелмә мәгънәсе – шагыйрьләр төркеме, шагыйрьләр берләшмәсе.

Татар халкының легендар герое Хуҗа Насретдин бер төнне, хатынын уятып: «Тиз бул, шәмне яндыр, илһам килде, шигырь язам, – дип ут кабыздырган да, – яшел яфрак арасына кызыл борынлы кара тавык кереп китте», – дип язып куйган ди. Дөрес, бу мәзәк кенә. Менә шул илһам дигәнең каян килә икән? Чыганагы кайда икән?

Пегас тоягы. Пегас – грек мифологиясе буенча Зевсның канатлы аты. Татарда канатлы атны – тулпар, толпар, диләр. Имештер, Геликон тавында Пегас тоягы белән типкән урында тылсымлы чишмә бәреп чыккан, ягъни илһам чишмәсе. Аның суын эчү шагыйрьләрне иҗатка рухландырган. Пегас исеме дөнья халыклары телләрендә поэзия, шигъри илһам символы буларак кулланыла башлаган.

Пегастырмы – канатлы аттырмы
Шагыйрьләрнең илһам юлдашы?
Укып беләм, ләкин күргәнем юк...
Мин шигырьдә үзем – эш аты!

(Марс Шабаев)

Шушының белән ***«Ни өчен болай әйтәбез?»*** сәхифәсен йомгаклыйбыз. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт.

Бу бүлек нигездә танылган фольклорчы Хуҗи Мәхмүтовның «Язылмаган кануннар» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1995) китабы буенча эшләнде, мисаллар да әлеге китаптан тупланды.

12.01.15.

IV кисәк

СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ

1. Тел, сөйләм – милләтнең визит карточкасы. Сөйли белү – сәнгать ул

«Тел дигән дәрья бар» тапшыруы берничә циклны үз эченә алды. Чираттагы циклны **сөйләм культурасына** багышларга булдым.

Сөйләм культурасы турында сөйләргә алыну юктан гына түгел. Кешене киеменә карап каршы алсалар, акылына карап озаталар, дигән әйтемгә, сөйләменә карап, дигәнне дә өстәргә була.

Элек заманда карап торуга матур гына, әмма тилемсәрәк бер егетне, киендереп, ясандырып, кыз күрсәтергә алып барганнар. Агалары, егетне юлда барганда бик кисәткәннәр: «Кыз катына кергәч, өйдәге кебек килде-китте сүз сөйләп утырма, йомры-йомры сүзләр генә сөйлә», – дигәннәр. Кыз егетне күрүгә аны ошаткан, әмма бераздан егетнең бик үк дөрес кеше булмавын абайлаган. Чөнки егет кыз янына кереп, бераз утыргач, сүзсез утыруны килештермичә, агалары өйрәткәнчә, йомры-йомры сүзләр сибәргә тотынган: «Коштабак, тәлинкә, ай, табак, иләк белән чиләк», – дип тезеп киткән ди. Шуннан соң кыз кияү сәләмәсеннән баш тарткан ди.

Сөйләм культурасы ул халыкның, милләтнең йөзен билгеләүче сыйфат та. Һәр кеше үз милләте, аның үзенчәлекле сыйфатлары белән горурланырга хаклы. Без, татарлар, аз сөйләвебез, күп эшләвебез, тырышлыгыбыз белән аерылып тора торган милләт.

«Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул», – дип, бөек Тукаебыз юкка гына язып калдырмаган. Халкыбызның сүз, сөйләшә белү осталыгына кагылышлы акыллы, алтыннан да кыйммәт фикерләре аеруча халык авыз иҗатында киң чагылыш таба.

Халкыбыз төп игътибарны сүзнең мәгънәви ягына, сөйләмнең эчтәлегенә юнәлтә. Мәкальләрдә бу аеруча ачык чагыла. – Авызыннан энҗеләр чәчә. – Сандугач күк сайрый. – Сүзләре ялкын кебек. – Авызына каратып тота.

Менә бит, халык сүзгә оста кешене мактау өчен нинди матур чагыштырулар, охшатулар тапкан. Чөнки ул телгә осталыкны, сөйли һәм сөйләшә белүне тормыш өчен бик кирәк булган җитди сыйфат итеп карый.

– **Сүз сөйләү – һөнәр**, – ди бер халык мәкале. «Сүз сөйли белсәң – ирмәк (кызык, күңел ачу), сөйли белмәгән – имгәк. – Йөзә белмәсәң суга кермә – батып үләрсең; сөйли белмәсәң сөйләмә – күп алдында бөләрсең. – Сөйли белгән адәмнең һәр сүзенә – киң кочак; сөйли белмәс адәмнең сүзе – үтмәс бер пычак» кебек мәкальләрдә әлеге фикерләр ассызыклана. **Сөйли, сөйләшә белү – сәнгать, дип юкка гына әйтмиләр шул!**

Халык сүзнең рәтен-чиратын белмичә, кабаланып сөйләүчеләрне дә, шулай ук авызын ачып бер сүз әйтә алмый торучыларны да һич хупламый.

Һаман да шул, элекке заманда, бер егет кияү булып кергән көнне бик сөйләшкән. Әй сөйләнгән, әй сөйләнгән, бер дә телгә эләкмәгән калмаган инде. Әби кешегә кияү бик тә ошаган.

– Карасана, киявебез сүзгә бик юмарт булып чыкты әле, – дигән. Әмма кияү икенче көнне, авызына су капкандай, бөтенләй тынып калган.

Кыз моңа сәерсенеп:

– Кичә бик сөйләшкән идең бит. Нишләп бүген телдән калдың? – дигән.

Егет әйткән:

– Бик сөйләшәсе иде дә, җиңги өйрәтеп җибәргәннәр бетте бит, – дигән.

Шулай инде, үзеңдә булмаса, җиңги өйрәткән белән генә әллә ни ерак китә алмассың!

Бүгенге чыгышымны шагыйрь ***Х. Туфанның «Талантлы син, Кеше, туганым!»*** шигыреннән өзек белән тәмамлыйм:

Талантлы син, Кеше, туганым,
Сәләтле син һәрбер ижатка.
Дөнья дигән бөек китапка
Языла бара хезмәт юлларың,
Талантлы син, Кеше, туганым!

2. Күп сүз – чүп сүз

Сөйли белү – күп, матур итеп сөйләү дигән сүз түгел әле ул. «Сүзе сүзгә охшамый, авызы сүздән бушамый», – ди халык, буш, чүп сүз сөйләүчеләр хакында. Әле: «Күп сүз – чүп сүз», – дип тә өсти. Үз фикереңне аз сүз белән, ачык һәм җыйнак итеп, тыңлаучыларны ялыктырмый гына әйтеп бирә белү, халык карашынча, телгә осталыкның гына түгел, хәтта **акыллылыкның да** мөһим бер билгесе булып санала. Шуның өстенә аз сөйләү кешене хата, гаеп сүз әйтүдән туа торган күп төрле бәлаләрдән дә саклый.

- Аргамак атның билгесе – аз утлар да күп ашар,
  Азамат ирнең билгесе – аз сөйләр дә күп тыңлар.
- Аз сөйләмәк – акыллылык билгесе.
- Күп белеп тә аз сөйләү – егетлек һөнәре.
- Аз сөйләгән – күп ишетер.

Юкка гына, кешегә, ишетер өчен ике колак, күрер өчен ике күз, ә сөйләр өчен тел бер генә итеп бирелмәгән шул!

Артык күп, озын сүзнең бер яктан тәме, ләззәте булмый. Икенчедән, күп сүзгә я хата сүз, я ялган сүз катнашып китүчән.

- Аз сөйләү – алтын, күп сөйләү – болтун.
- Күп йөргән – юл адаша, күп сөйләгән тел – ялгыша.
- Күп сөйләгән кеше ялганчы булыр.
- Чабу озын булса – тезеңә урала, сүз озын булса – үзеңә урала.

Бер табиб, бик күп сөйләшүче бер авыруга телен чыгарырга кушкан да үзе рецепт язарга утырган. Теге кешенең бераздан түземлеге беткән.

– Доктор! Ун минут буе телемне чыгарып торам. Ә сез борылып та карамыйсыз! – дигән.

Аңа каршы табиб:

– Зарар юк. Тагын бераз шулай телегезне чыгарып торыгыз. Чөнки миңа рецепт язган вакытта булса да сезнең сөйләшми торуыгыз кирәк! – дигән.

Күп сөйләү, урынсызга сүз арттыру белән бәйле тагын бер начар гадәт – бер сүзне, фикерне кат-кат кабатлау. Бу хәл хәтта яхшы, кирәкле сүзнең дә тәмен, кадерен, дәрәҗәсен төшерә, ни сабыр кешене дә чыгырыннан чыгарырга мөмкин. Гадәттә,

бәйләнчек, үзсүзле һәм дә исерекләргә хас сыйфат бу. – Һаман бер балык башын чәйнәмиләр. – Сөйләгән сүзең алтын булса да, күп сөйләгәч бакырга калыр. – Бер сүзне ике кайтара әйтсәң, чабата була, ди кебек мисаллар әнә шуны күрсәтә.

Сүзне уратып, болгатып сөйләү дә матур күренеш түгел. Кайбер кешенең җөмләсенең башы була, әмма азагына һич чыгып җитә алмый. Ни әйтергә теләгәнен тыңлаучы да аңышмый. Берәү исә кыска гына итеп әйтәсе урынга, әллә кайлардан уратып, тәмләп сөйли. Вакытың булса, мондыйларны тыңлавы рәхәт, ә вакытың тар чак булса... Ни китә алмыйсың, ни бүлдерә алмыйсың. Икенче берәү сүзен сөйләмнең уртасыннан башлап китә. Баштагы мәлдә сүзнең ни турында барганын аңышмый да торасың.

«Күп сөйләгән кешедә өмет юк» дигән мәкальне истә тотып, бүгенгә сезнең белән саубуллашып торырбыз.

Сөйлимен мин сүзләремне, халкым тыңласын өчен!
Игътибар белән тыңласын, сабаклар алсын өчен!

3. Сөйләмең ипле булсын

Әлбәттә, тормыш булгач, гел шатлыклы-куанычлы хәлләр генә булып тормый. Кешеләргә тәнкыйть сүзе дә әйтергә кирәк була, кайгылы, авыр хәбәрләр дә җиткерергә туры килә, әмма әйтәсе сүзеңнең эчтәлеге нинди булуга карамастан, халык сөйләмдә тупас, дорфа, авыр сүзләр кулланууны һич тә хупламый. Сүз белән сак эш итү, хәтта тыңлаучы өчен күңелсез нәрсәләр турында да ипләп-җайлап әйтә белү халык каршында сүз әдәбенең, сөйләм культурасының зарури бер шарты булып санала.

Халык язучысы **М. Мәһдиев** әсәрләрендә мондый мисалларны еш очратырга була. Менә аның ***«Каз канатлары»*** романыннан бер өзек.

«Тигезлек белән гомер иткән кешеләр, бер-берсен югалткач, тиз какшыйлар. Бибиәсма җиңги дә картын мәңгелек йортка озаткач, озак яшәмәде.

– Вәлиулла абый артыннан кайтып китәргә чамалый бу, – дип, Фәхрислам аны бер күрүдә диагноз куйды. Эченнән генә, әлбәттә.

– Авылда «үлде», «җан бирде» дигән ямьсез сүзне өлкәнрәкләр бөтенләй кулланмый иде. «Кайтып китте», – янәсе, адәм баласы бу җирдә, бу дөньяда кунак кына. «Агачлыкка илтеп куйдык», – дип тә сөйлиләр. Агачлык – зират, әдәп белән, сак кына әйтәләр.

Авыру янында исә: «Терел, – диләр. – Минем аягым җиңел булсын!»

– И-и-и, Ходайның рәхмәте бик киң аның, Әле менәтерәк йөгерә-йөгерә көтү куарсың, каз-тавык ашатып йөрерсең.

– Әнә безнең Күпербаштагы тәтә нинди хәлдә яткан иде. Җиде ясиннар чыгып, балаларын телеграм сугып кайтардылар. Газраилның килер сәгате җитмәгән булгач, әнә, хәзер тәтә йөгереп йөри. Йөгереп! Әле синнән-миннән калып йөз ел яшәр.

Бу инде, әлбәттә, халыкның күңел яхшылыгы, әдәбе». (М.М.)

Халкыбыз кычкырышу, әрләшү, талашу, тиргәшү кебек негатив күренешләрне кискен төстә гаепли. – Кычкырышка яхшы сүз керми. – Талаш эткә килешә. – Бер көн талашканның кырык көн ризыгы киселә, ди. – Ызгышканның зыяны – килгән бәхетне китәрер. – Бакыру ягымлы булса, ишәктән кадерле хайван булмас иде.

Кычкырышу, талашу, бер-береңә ямьсез сүзләр әйтешү күңелсезлекләр генә китерә: бер-береңнән гайрәт чигә, ара ерагая, күңел суына. Кызурак канлы кешеләр, хәтта, якалашып та ала, сугышып та китәләр. Гаиләдә булса, мондый хәлләр гаилә тынычлыгын ала, аның нигезен какшата, хәтта, гаилә таркалуга да китерә. Бу очракта халык акылга таянырга һәм сабыр булырга өнди.

Бер ир хатынын ачулана, ә хатын аңа һәрвакыт каршы әйтә икән. Шуңа күрә, ир хатынын тотып кыйный икән. Хатын багучыга барган: «Нишлим, ирем бик холыксыз», – дигән.

Багучы аңа бер зур гына сәдәф биргән. «Ирең ачулана башласа, менә шушы тылсымлы сәдәфне кап. Кара аны, сәдәфне капкач, авызыңны ачасы булма. Югыйсә, файдасы булмас», – дигән.

Шуннан бер көнне ире сүзгә килә башлагач, хатын, аңа күрсәтми генә, теге сәдәфне алып капкан. Ир ачулана да ачулана, ә хатын дәшми икән. Ир аптыраган инде, бу ни эш дип. Мондый хәл берничә тапкыр кабатланган.

Хатын, шуннан соң, багучы янына барган. «Рәхмәт яусын, сәдәфең бик килеште. Шуны каба башлаганнан бирле бик тату торабыз», – дигән.

Кадер дә, хөрмәт тә сиңа тик туган җирдә икән.
Оныклар үскәнче яшә, ятка сер бирмә икән.
Әйтсеннәр: күрче боларны! Сез һаман бергә икән,
Сез һаман бергә икән, бергә икән!

(Сибгат Хәким)

4. Кешесенә карап сүз сөйлә

Була шундый кешеләр: алар белән сөйләшкәннән соң рәхәт булып кала. Күңел тынычлана, җаның чистарынган кебек була, яшиселәр килә башлый. Психологларың бер якта торсын (кем белә, бәлки аларга Ходай психолог орлыклары да салгандыр). Болар – намуслы-гадел, акыллы, үзләре белән аралашучыларга чын мәгънәсендә яхшы ният тәге кешеләр.

Сөйләшүләре гамәлләре белән туры килә аларның.

– Биек тауга менсәң, күзең ачылыр; яхшы белән сөйләшсәң, күңелең ачылыр, – дип халык бик белеп әйткән.

Тагын була шундый кешеләр: алар белән сөйләшкәннән соң согын сыгып алган лимон кебек каласың. Эч пошыра, җанга тия торган сүз кирәкме, ирониями, сарказммы, төрттерүме – барысы да бар алар телендә. Әле сүзгә ике-өч төрле мәгънә салып сөйлиләр, җитмәсә. Моңа серле караш, ишарә, мимика да өстәлә. Ни уйларга да белми торасың! Кайберсенең һәр сүзе, ток бәргәндәй, чатырдатып аңга, җанга суга. Андыйлар яныннан ераграк йөргәнең хәерле.

Була шундый кешеләр: синең белән бик әдәпле сөйләшә, ләкин аның нияте, гамәлләре сөйләгәне белән туры килми. Сүзләре матур, ләкин матур сүзләр артына яшертен ният, хәйлә, мәкер поскан. Була сүз йөртүче кешеләр. Сөйләшү барышында, синең «һы» дигәнеңне, «әйе» дип әйтте, дип, үз сүзен синеке итеп, тиешле кешесенә җиткереп, ара болгатырга да күп сорамый андыйлар. Үрмәкүч авына эләккән чебен хәлендә каласың килмәсә, мондый «әңгәмәдәшләр» янында да озак тел чарлап тормавың яхшы, дөрес, сизенеп кала алсаң.

Кайбер кеше шаяртып сөйләүне аңламый. Башка фикер-

дәшләрең, дусларыңа, якыннарыңа яраган сүзләр икенче берәүгә ошамаска мөмкин. Хәтта аны-моны уйламыйча, үзеңчә шаяртып әйткән сүзең аркасында әңгәмәдәшең өчен син дошман булып та калырга да мөмкин. «Уен сүзне һәркем белмәс, кешесенә карап сөйлә», – ди халык мәкале дә.

Шуңа күрә дә, сүз әдәбе, сөйләм культурасы турында фикер йөрткәндә халык үз сүзеңне кемгә сөйләвеңә, әңгәмәдәшеңнең кем булуына зур игътибар бирергә кирәклеген искәртә.

– Сүз әйтәсең килсә, кем тыңлавын кара. – Ахмакка әйткән сүз агып яткан суга тиң, акыллыга әйткән сүз кулга тоткан туга (ту – байрак дигән сүз) тиң, – кебек мәкальләр әнә шул турыда.

Әңгәмәдәшең олы кеше, ягъни үзеңнән өлкән кеше икән, сүзең кыска, ачык, җитди булырга тиеш. – Олы кешеләргә озын сүз сөйләмә. – Олы сүзен бүлдермә. – Олы алдында телен тыймаган – теле авызына сыймаган.

Сүз сөйләгәндә кешенең холык-фигылен, акыл һәм белем дәрәҗәсен исәпкә алу да кирәк. – Нәсихәтеңне әтәчкә әрәм итмә, – дип, халык надан, ахмак кешеләр белән әңгәмә коруның, сүз алышуның файдасыз, кирәксез эш икәнен кат-кат искәртә.

– Ахмакка киңәш итмә, – дигәнгә бер мисал.

Берәүнең күзләре бик авырткач, икенче берәүдән киңәш сораган. Тегесе әйткән: – Белмим шул, туган, мин үзем тешләрем бик авырткач, алдырып файдасын тапкан идем. Бәлки син дә шулай итәрсең? – дигән. «Кешеләргә акылларына карап эндәшегез», – диелә бер хәдистә.

Татарның бөек мәгърифәтчесе **Каюм Насыйри** ***«Китаб – әт-тәрбия»*** җыентыгының ***«45нче тәрбия»*** бүлегендә мондый киңәшләр бирә: – Әй, угыл, җиде төрле кешегә киңәш итмә.

1. Әүвәл, надан кешегә киңәш итмә, чөнки надан кеше үзенең наданлыгына булышып, сине азгынлык юлына салыр.

2. Дошманыңа киңәш итмә, чөнки дошман кеше сине һәлакәткә тартыр.

3. Хөсетле вә көнче кешегә киңәш итмә, чөнки көнче кеше синең нигъмәтеңә зыян килүен теләр.

4. Икейөзле кешегә киңәш итмә, чөнки ул кеше һәркайчан адәмнең ризалыгын гына карап торыр.

5. Куркак кешегә киңәш итмә, чөнки куркак кеше сиңа һичбер киңәш бирергә җөрьәт итмәс.

6. Саран кешегә киңәш итмә, чөнки саран кеше мал җыярга хирыстыр, анда дөрес киңәш юктыр.

7. Малга комсыз кешегә киңәш итмә, чөнки нәфес арзуына иярген кеше нәфесенә каршылык кыйла алмас.

Әдәпле итеп сөйләшү күңелләргә рәхәтлек өсти, әдәпсез сөйләм исә йөрәккә таш булып утыра. Кешеләр белән сөйләшкәндә, кирәкле сүзне табып, матур итеп сөйләшә белү, әңгәмәдәшеңне хөрмәт итү – үзара аралашуның уңышлы чыганагы, кешеләрнең мораль һәм физик сәламәтлегенең нигезе дә булып тора.

5. Сүзне әйт сыяр җиргә, яки сүз вакытында һәм урында әйтелсә генә сүз

Сүзне тиешле урында һәм вакытын белеп сөйләү – үзара аралашуның мөһим шарты. Әлбәттә, сүз әдәбен белгән кеше, башкалар янына килеп сүзгә катышып киткәнче, башта сәлам биреп, хәл-әхвәл сорашып алырга тиеш. «Әүвәл саләм, аннан – кялам (сүз) дигән гыйбарә бар халык телендә. – Сүздән әүвәл сәламләш. – Элек күреш, соңыннан сөйләш, – дигәне дә бар. Язучы **Фаил Шәфигуллин**ның ***«Сиңа әйтергә кердем»*** юмористик әсәрендә Марат исемле егет күршесе Хажиәхмәт бабай янына керә дә, туп-туры, керешсез-нисез, мотоциклын биреп торуын сорый. Бабай замана яшьләрнең мондый әдәпсезлеге өчен әрнеп болай ди:

– Нинди халык бу, ә? Исәнләштем, хәл-әхвәл сораштым юк. Тоталар да кычкыра башлыйлар. Элек заманда болай түгел идек без. Олыны олы, кечене кече итеп белә идек. Әгәр олы кеше кем беләндер сөйләшсә, сабыр гына әңгәмәнең ахырын көтеп торыр идек. Ә болар синең колак төбенә киләләр дә кычкыралар. Кайда олыларга хөрмәт, кайда сабырлык? Юк ул синдә, юк! Ә, бәлкем минем кайгы-хәсрәтем бардыр! Ә, бәлкем, чирлимдер мин! Иң элек син әйбәт кенә килеп исәнләш, хәлемне сораш, мал-туарым белән кызыксын. Менә инде шуннан соң йомышыңны әйтсәң дә ярый.

Бабай сүзләрендә мең хаклык бар.

«Сүзне тиешле урында сөйләү» дигәнне ничек аңларга? Бу, барыннан да элек, әйтәсе сүзеңне гомуми әңгәмә барышына,

аның эчтәлегенә туры килерлек булуына һәм тыңлаучыларның игътибарын ни дәрәҗәдә җәлеп итүенә игътибар бирү, дигән сүз.

· Тыныч күлгә таш атма, тиешсез урында сүз катма.

· Суны сип сеңәр җиргә, сүзне әйт сыяр җиргә.

· Һәрбер сүзнең үз урыны бар.

Язучы, драматург **Т. Миңнуллин**ның ***«Кызыл тышлы дәфтәрдән»*** дип аталган язмаларында мондый вакыйга сөйләнелә. Бөек Ватан сугышы еллары: 1942 еллар булырга тиеш. Фронттан авылга бер-бер артлы похоронкалар килеп тора. Уракчы хатыннар, ялга туктагач, елаша-елаша кайгыларын уртаклашалар. Әнә кичә Сабирага да похоронка килгән. Итәк тулы бала, авыру каенанасы белән ятим калганнар. Алга таба нишләргә? Хәбирәгә дә кара кәгазьне бүген кулына тоттырдылар. Биш бала, гарип каенсеңел, 90га җитеп килүче карт белән карчык бер Хәбирәгә карап тора хәзер. Халисәнең дә (Туфан Миңнуллинның әнисе) Габдулласыннан күптәннән хәбәр юк. Хатыннар елаша, ах-ух киләләр. Фронтта бер кешесе дә булмаган, әнисе белән генә яшәүче Гөлчирә дә боларга кушылып елый башлый.

– Син нигә елыйсың? Синең бит сугышта беркемең дә юк, – дигәнгә, тегесе:

– И-и, сез шулай дисез дә, минем дә кайгым бар. Кичә юып, кибәргә элгән шәлъяулыгымны иртәнге якта, бозау чәйнәп, элә-танагын калдырмаган, – дип әйтте ди.

Сүзнең вакытын белеп сөйләүгә килсәк, бу – үзеңә нәүбәт, ягъни чират җиткәч яки сүзне үз вакытында сөйләү дигән сүз.

– Синнән сүз сорамас борын сөйләмә. – Арттан әйтергә теләгән сүзеңне алдан әйтергә ашыкма. – Сүз вакытында әйтелсә генә сүз. Вакытсыз сөйләмә – Питрау күкесе булырсың.

(Мәкальләр).

Бер кеше, базарга баргач, танышына керә. Моңа чәй әзерләргә ашыкмыйлар. Сөйләшеп утыра торгач, шактый вакыт уза. Чәй эчәргә кыстаучы һаман юк. Кунак китәргә әзерләнә башлый. Ишектән чыккач, хуҗа кунакка: «Чәй эчәр идек», – ди.

Хатыны иренең чабуыннан тартып: «Кая ашыгасың, капканы чыккач әйтерсең», – дип пышылдый.

Сүз вакытында әйтелсә генә тиешле тәэсирне тудыра, көтелгән нәтиҗәгә китерә. Әйткәләшкәннән соң, их, шулай дип

әйтәсем калган, болай дип әйтәсем калган, дип ухырудан файда юк. Әйтә алмый калган сүзеңне, икенче көнне барып әйтү, мәсьәләне тагын да катлауландырырга мөмкин. Бәлки, кайбер очракларда дәшми калу да кирәктер.

Халык мәкале болай ди бит: «Акыллы әйтер – сабыр иттем, дип; юләр әйтер – җиңдем, дип».

«Көрәштә иптәшләрен җиңгән кеше түгел, ә нык ачуланган хәлдә, сабыр итеп, ачуын җиңгән кеше көчле була».

(Мәгърифәтче **Риза Фәхретдин).**

6. Ике тыңла – бер сөйлә

Халык акылы югары тел культурасына ия булуны кешедәге иң күркәм рухи-әхлакый сыйфатлар рәтеннән бәяли. Сүз белән сак һәм уйлап эш итәргә, сүзнең урынын һәм вакытын белеп, матур һәм кыска итеп сөйләргә чакыра халкыбыз. Ипле, йомшак, җайлы сүзләр тупас, дорфа сүзләрдән һәрвакыт өстен куела. Телгә осталык югарыда санап кителгән һәм башка күп төрле сыйфатлар җыелмасыннан тора. Ләкин сөйли белү никадәр генә мактаулы сыйфат булса да, ул әле сөйләм культурасының бердәнбер билгесе түгел. Үзең оста сөйли белү белән бергә, башкалар сөйләгәнне тыңлый белү дә бик кирәкле сыйфат.

Сүзне тыңлый белүгә башкаларның сүзен бүлдермичә ахырына кадәр тыңлау, бирелгән киңәш-нәсихәтләргә колак салу, аларны үтәү, тәнкыйть сүзен күтәрә белү, аннан тиешле нәтиҗәләр ясау һәм башка билгеләр дә керә.

«Сөйли белсәң, тыңлый да бел; үзең сөйли башлаганчы, кеше сүзен тыңлап бетер; кеше авызын япма, кешенең сүзен өзмә», – дип, халык үз балаларына бик акыллы киңәшләрен бирә.

Ике кешенең берсеннән-берсе уздырып, бер-берсен тыңламыйча сөйләшкәнен күзәткәнегез бардыр. Икесе дә сөйли, ләкин бер-берсен аңламыйлар.

Телевизордан бара торган «Прямой эфир», «Пусть говорят» тапшыруларында бу хәл даими күзәтелә. Тапшырулар бака туен хәтерләтә кайчагында. Бар да сөйләгәндә берәү дә ишетми. Үз сүзен генә сөйләүче яки үз сүзен бирмәүчеләрне дә халык хөрмәт итми.

«Әйткәнне тыңла, тыңлаганны аңла», – диелә бер мәкальдә.

Бер тегермәнчедән патша сорый икән:

– Өчнеке тугызга җитәме? – дип. Ягъни өч ай эшләгән тугыз айга җитәме, дип, соравы булган патшаның.

– Җитә-җитүен, тик 32дән артмый (ягъни 32 тештән артмый), – дип җавап биргән тегермәнче. Монысы инде тапкырлык. Димәк, сөйләгәнне бик **игътибар** белән дә тыңлый белергә кирәк.

Каенда биш алма үсә иде. Шуның икесе җиргә өзелеп төшкән. Ничә алма калган? – кебек сорау-табышмак бар. Игътибарсыз тыңлаган кеше шунда ук куша-ала башлый. Ә игътибарлысы – каенда алма үсми, дип җавап бирә.

Кайбер җитәкчеләр, эшкә алганда, кандидатларны төрле яктан сынап, сөйләштереп фикерләү сәләтен тикшереп тә карый икән. «Сөйләгәннән тыңлаган зирәк булсын!» Менә халык ни ди!

Тыңлый белү һәркем өчен кирәк. Әмма укытучылар, җитәкчеләр, халык белән эшләүчеләр өчен бу сыйфат аеруча әһәмияткә ия. Дөрес, тыңлаганга салышып, сине тыңлаган кыяфәт чыгарып, бөтенләй башка нәрсә уйлап утыручылар да була. Бусы инде сансызлыкка керәдер, мөгаен. Ә сансызлык – халкыбызның иң хөрмәт итмәгән сыйфаты!

7. Кеше сөйләмдә ачыла

Алдагы чыгышларда кешенең кем икәнлеге, нинди икәнлеге сөйләмдә ачык чагылуы турында искәрткән идек. Галимнәр сөйләмгә карап кешенең тәрбиясен, әдәбен, холкын, социаль хәлен, яшен, профессиясен, хисси халәтен, һөнәрен, милләтен дә белеп булуын әйтәләр.

20 гасыр башы галиме **Җиһангир бине Абызгильдин *«Хөтбәт ысуллары»*** дигән хезмәтендә сөйләүченең әдәп тәрбиясе, сүз зәвыгы ничек, ни дәрәҗәдә икәнен сөйләменә карап белеп булуын түбәндәге мисалларда күрсәтә.

– **Тәкәббер** кешеләр һавалы, катгый, үз-үзләренә артык бер ышаныч белән, сүзләрен мөмкин кадәр зур, күтәренке, матур итеп сөйләргә яраталар, – ди. Аннан соң шунысы да бар: тәкәббер кеше теләсә кем белән сүз башламый. Башта ул сине

башыңнан аягыңа кадәр энә күзеннән үткәрә, үзенә тиң дип тапса гына сүзгә керешеп китәргә мөмкин. Булыр-булмас кеше аның өчен аралашу объекты түгел.

– **Әдәплеләр, –** ди, галим, – һәрвакыт садә, ләкин бик нык уйлап, тынычлык белән генә, табигатенә хас бер кәйфият белән сөйлиләр.

– **Мөнафыйклар** (икейөзлеләр) сүзләрен ике төрле итеп алып барырга тырышалар. Бер тарафтан тыңлаучыны сөйләме белән җәлеп итсә, икенче тарафтан аларны хәвеф тырнагына төшерергә тырышучан булалар.

– Ялганчылар кыска һәм мөмкин кадәр татлы, төрле яктан уратып, төрле тон белән сөйләүчән булалар. Сүзләренең барышыннан ук ялганлык күләгәләре күренеп тора.

– **Идиотлар** – тупас, дорфа, мәгънәсез, төпсез, озын сөйләүчеләр.

– Даһилар – сүзләрен куәтле, төпле, йөрәк вә күңелендә ташыган хисләргә бирелеп, ялкынлы рәвештә сөйлиләр.

– **Иң гакыллылар** карарсыз бер сүздән икенчегә сикереп, әле бер, әле икенче тонда сөйлиләр.

– **Эшчән кабилиятле** затлар сүзләрен аз гына сөйләрләр, – ди галим.

(Бу мәгълүмат Р.С. Абдуллинаның «Сөйләм культурасы» хезмәтеннән алынды. Казан, 2012, 40–41 нче битләр).

Тәрбияле, зыялы кешенең сөйләме әдәби югары стильдә була. Аның сөйләмендә тупас, вульгар сүзләр булмый. Рус язучысы А.П. Чехов әйткәндәй, **кешенең йөзе дә, киеме дә, күңеле дә, уйлары да – барысы да матур булырга тиеш.** Бу фикергә **сөйләме** дә дигәнне өстәсәк, һич ялгыш булмас.

Бер фильм героеның «Хорошие манеры вырабатываются не годами, а поколениями» дигән җөмләсе күңелемә кереп калды. Ягъни, үз-үзеңне тоту күнекмәләре, тәрбиялелек еллар дәвамында түгел, ә буыннар дәвамында үзләштерелә, буыннан буынга мирас булып күчә. Сөйләм дә тәрбиялелекнең бер тармагы.

Кешенең күрке йөз булыр, йөзнең күрке күз булыр;
Күзнең күрке тел булыр, телнең күрке яхшы сүз булыр.

(Борынгы халык мәкале.)

8. Кеше сүз пәрдәсе артында (сөйләүченең темпераменты сөйләмендә күренә)

Безнең эрага кадәр 5 нче гасырда яшәгән атаклы грек табибы Гиппократ темпераментның дүрт төрен билгеләгән: сангвиник, холерик, флегматик, меланхолик. Темперамент – кешенең индивидуаль, шәхси сыйфаты ул, ягъни, кешенең психологик эшчәнлек ягыннан үзенчәлекләренә, интенсивлыгына, тизлегенә, психологик процессларның темпына индивидуаль характеристика.

Флегматиклар характерлары буенча тыныч, ашыкмый, кабаланмый, тотрыклы, максатчан, тырыш. Нәтиҗәле эшчәнлек хас аларга.

Холериклар – кызу, хисчән, кискен, тотрыксыз, кәефләре тиз һәм кискен үзгәреп тора.

Сангвиниклар – бик тере, хәрәкәтчән, кайнар. Аларда мимика көчле. Үзенә ошаган эшне минутында эшләп ташлый, ошамаган эшенә тотынмый.

Меланхоликлар – бик хисле, күңелләре үтә тиз җәрәхәтләнә, тышкы факторларга реакциясе әкрен, үз эченә бикләнгәннәр.

Кешенең темпераментын сөйләменә карап та билгеләп була икән.

Көнчыгыш һәм Европа сөйләм культурасы казанышларын өйрәнеп, мәдрәсәләр өчен риторика дәреслеге язган Җиһангир бине Абызгильдин болай ди: «**Флегматиклар** тыныч, аз хисле, хисенә артык бирелмичә, сүзләрен акрынлык белән дәвам итеп, ип белән озак сөйлиләр».

Сангвиниклар сүзләрен тиз-тиз, ашыгычлык белән авызларыннан бертуктаусыз ыргытып торалар.

Холериклар ифрат ашыгычлык белән, **меланхоликлар** сүзләрен күңелсез, кабердән чыккан кеби, акрын сөйлиләр, ләкин сүзләре гаять төпле булучан, – ди. *(Бу мисаллар тел галиме Равия Самат кызы Абдуллинаның «Сөйләм культурасы» китабыннан алынды – 2012, 41 нче бит*).

Язучы Ә. Еники, шагыйрь С. Хәким характерлары буенча флегматиклар булырга охшый. Бу аларның сөйләмендә ачык чагыла. М. Мәһдиев, Р. Батулла язмаларында бу ике шәхес

турында күп мәртәбәләр искә алына һәм аларның үзнчәлекле сөйләме бик оста бирелә.

М. Мәһдиевнең *«Фронтовиклар»* романындагы Галиәхмәт карт – меланхолик.

«Карт, дөм үк булмаса да, шактый чукрак. Бөтенләй үк булмаса да, шактый телсез. Дөресе аз сүзле. Ул сүзләрнең дә араларында зур гына тәнәфес ясап сөйләшә. Рушад килгән көнне үк картның бу сыйфатына игътибар итте. Кичке караңгыда, малларын карап бетергәч, Галиәхмәт карт маңгаен тотып керде.

– Нәрсә булды тагын? – дип сорады карчыгы эш арасында гына.

– Башны... – диде карт һәм тынып калды. Бишмәтен салып элде, ак шарфын мич буена куйды, киез итекләрен мич башына урнаштырды һәм, түбәтәен дөресләп, ишек катындагы урындыкка утырды. Кытыршы, бирчәйгән дәү куллары белән авыз тирәләрен бер сөртеп алгач кына, башлаган җөмләсен тәмамлады:

– ... бәрдем». *(М. Мәһдиев «Фронтовиклар» романы, Казан, 1988, 31 нче бит).*

– Әкрен сөйләгән кешенең әмәле күп, – ди бит халык мәкале дә.

В. И. Ленин, Адольф Гитлер, Владимир Жириновскийны психологлар холериклар төренә кертә. Бу аларның сөйләмендә шулай ук ачык чагыла. Без В. И. Ленин, А. Гитлерның сөйләмен аудио яки видеоязмалар буенча ишеткәләп торсак, В. Жириновский чыгышын тыңламый калган көн сирәктер.

Шулай итеп, безнең арада төрле холыклы кешеләр яши. Шуңа күрә без аларны тыңлый белик һәм аңларга тырышыйк.

9. Сөйли белү – һөнәр ул

Тел гыйлемендә «Сөйләм культурасы» дигән фән бар. Бу фән үз фикерләреңне дөрес, төгәл, логик эзлеклелектә сөйли-яза белү, уй-тойгыларыңны күңелләргә үтеп керерлек итеп әйтү, туган телнең байлыгыннан иркен файдалана белү күнемәләре булдыруны максат итеп куя. Сөйләм культурасы – иң беренче чиратта, сөйләм нормаларын үзләштерү, авазларны дөрес итеп әйтү, лексик һәм грамматик чаралардан дөрес файдалану ул.

Сүз, сөйләм осталыгына ия булу кешегә җәмгыятьтә үз урынын табарга мөмкинлек бирә. Сөйләм осталыгына ия кеше аралашу осталыгына да ия була. Гадәттә, карьера ясау өчен сөйли белү, сөйләм осталыгына ия булу зур роль уйный. Юкка гына Наполеон Бонапарт: «Сөйли, сөйләшә белмәгән кеше карьера ясый алмый», – димәгән («Кто не умеет говорить, тот карьеры не сделает»).

Сөйли, кешеләр белән сөйләшә белү ил белән идарә итүчеләрдән башлап, эш башында утыручылар, җитәкчеләр, бизнесменнар, адвокатлар, прокурорлар, дин әһелләре, укытучылар, гомумән, кешеләр белән эшләүче һәммә һөнәр ияләре өчен мөһим.

Тыңлагыз, сез дин әһелләренең вәгазьләрен! Оста вәгазьче озак, күп сөйләмәс, әмма сөйләгән кадәре дә җаныңны сафландыра, күңелне тынычландыра, иманың яңара. Оста вәгазьчене тыңлаганнан соң, анадан кабат тугандай, сафланып каласың! Укытучы сөйли белми икән, бу инде ярты укытучы гына!

«Елмая белмәсәң, кибет ачма», – диелә бер кытай халык мәкалендә. Сатучы кеше елмаюы өстенә сөйли дә белсә, товары җыелып ятмый инде!

– Менә бу конфет бик тәмле. Әле үзем дә алдым. Өйдәгеләр дә бик яратты. Рәхәтләнеп чәй эчтек. Әле тагын алырга дип торам. Башкалар да бик яратып алалар. Шушы гына калды, соңгысы, – ди берсе.

– Менә бу кофта бик уңайлы, җылы, тәнгә рәхәт. Үзем гел шундый фасонны алам. Әле әнкәйгә алып биргән идем. Рәхмәт укып туя алмый. Әллә тагын йоклаганда да салмый, – ди икенче бер сатучы. Алай түгел икәнен дә белеп торасың, югыйсә. Әмма үзеннән-үзе кулың шул товарга сузыла. Теле бит, теле тарта! Элеккеге приказщиклар клиент алдында юкка гына тиен урынына бөтерелмәгән. Аршиннары кулларында уйнап торган, телләре телгә йокмаган. Шулай булмаса, товарны үткәреп булмый; товарың үтмәсә, бай абзаңның талканы коры!

Әгәр дә адвокат оста итеп, дәлилләп сөйли белмәсә, үзенең хаклыгына ышандыра алмаса, күпме кеше нахакка хөкем ителер иде.

Татар театр дөньясында атаклы трагик Мохтар Мутин дигән кеше булган. Ул бahадир гәүдәле, гайрәтле, кызу канлы,

әмма бик белемле, талантлы, сүзгә оста шәхес булган, диләр. Бер хезмәттәше аны судка бирә. Мутин судта адвокат яллап тормый, үз-үзенә яклаучы булып сөйли. Залдагы маржалар аның шундый оста, матур, логикалы итеп үзен яклавын-аклавын күреп, үкереп елый башлыйлар. М. Мутинны аклап, иреккә чыгаралар.

(Р. Батулланың «Сайланма әсәрләр»е буенча, 2008, 2 том, 73 нче бит).

М. Мәһдиевнең **«Каз канатлары»** романыннан бер өзек.

«Фәхрелисламны халык ярата иде. Туры, гадел сүзе өчен. Югыйсә, колхозның иң авыр елларында башка бригадирлар халыкка булмастайны вәгъдә итеп, үз дәрәҗәләрен төшерәләр иде. Эшкә әйткәндә:

– Давай, давай, быел хезмәт көненә кило ярымнан да ким булмый, – дип, җәй буе сөйләнәләр дә, көз көне өч йөз грамм белән калгач, берничә айга шым булалар. Аннан язга таба тагын кило ярым.

Фәхрелислам алай сөйләмәде. – Безгә, – дип әйтә иде ул, кешене эшкә кушканда, – эшләсәк тә өч йөз грамм, эшләмәсәк тә.... Ну инде колхоз үзебезнеке, гел болай булмас, рәтенә бер чыгарлар. Хөкүмәт рәтләми калмас. Эшләми яту ярап бетмәс.

– Ну, шушының теле! Эшләмәс җиреңнән эшләрсең, – диләр.

– Дөресен әйтә бит. Шул дөрес сүзе хакына гына тыңлыйсың да инде...

(М. Мәһдиев «Сайланма әсәрләр», 3 том, 1996, 428 нче бит).

Әлбәттә, сөйләм осталыгына ия булу өчен сүз байлыгына ия булу зарур. Моның өчен күп укырга, күп белергә, кешеләр белән даими аралашып торырга, оста психолог булырга, үз өлкәңдә генә түгел, башка өлкәләрдән дә мәгълүматлы булу кирәк.

10. Ораторлык сәнгате

10. 1. **Бүген без ораторлык сәнгате турында сөйләшербез**.

Оратор – латин теленнән кергән сүз, чыгыш ясаучы яки сөйләү осталыгына, ораторлык сәләтенә ия кеше. Рус телендә

элек бу сүз урынына **краснобай** сүзе кулланылган. Сурәтләү чараларыннан оста файдаланып, матур-матур җөмләләр белән күп һәм буш сүз сөйләүче мәгънәсендә.

Оратор язганны гына укучы түгел. Чын ораторлар бервакытта да язуга карап сөйләмиләр. Алдында яткан кәгазьгә карап сөйләгән кешене тыңлыйсы да килми. Рәхәтләнеп, залга, тыңлаучыларга карап, аларның реакциясен тоемлап, күреп сөйләү бөтенләй икенче нәтиҗә бирә. Тыңлаучы да кәгазь кыштырдатып, йокымсырап утырмый инде сөйләүче каршында.

Ораторлык осталыгы аеруча политик эшлеклеләр өчен әһәмиятле. Нәкъ менә шуның ярдәмендә алар халыкка үзләренең идеяләрен, максатларын, әһәмиятле мәсьәләләрне җиткерәләр.

Тарих бик атаклы ораторларны хәтерли. Борынгы Грециянең Демосфен, Аристотель, Сократ, Платон, Борынгы Римның Цицерон, Юлий Цезарь, Калидий, Ксенофонт кебек ораторлары турында ничә гасырлар буена сөйлиләр, аларның язмалары аша ораторлык осталыгына өйрәнәләр. Борынгы Грециядә һәм Римда ораторлык сәнгатенә өйрәтүче махсус мәктәпләр, махсус кешеләр булган. Аларны риторлар дип атаганнар. Бу илләрдә ораторлык сәнгате югары дәрәҗәдә үскән, ораторлар бик тә хөрмәткә лаек, дәрәҗәле кешеләр булган.

Оратор булу өчен берничә шартның булуы зарур. Беренчедән, талант! Алга таба – тавыш, дикция көчле булу. Белемлелек, эрудиция. Оратор намуслы, тыйнак, акыллы, тәвәккәл, алга карап эш итә белергә тиеш. Сөйләгән сүзләре өчен җавап бирерлек булырга, ягъни уйламыйча сөйләмәскә тиеш. «Яхшы оратор булу өчен яхшы кеше булырга кирәк», – дигән фикер яши. Димәк, сөйләмең, шулар нигезенә корылган эш-гамәлләреңә белән дә син тыңлаучылар өчен эталон булырга тиеш. Димәк, оратор булырга җыенган кешеләр өчен бик күп сыйфатларга ия булу сорала икән.

Безнең эрага кадәр 384–322 елларда Борынгы Грециядә яшәгән атаклы оратор – Демосфен турында берничә сүз. Аның укытучылары – Исей, Платон, Сократ. Ораторлык өстенә, Демосфен суд процессында чыгыш ясаучылар өчен речьләр дә яза. Мондый кешеләрне **логографлар** дип атаганнар.

Кечкенәдән үк Демосфен оратор булырга хыялланган. Ләкин аның шактый гына физик кимчелекләре булган. Сакау-

лык, зәгыйфь тавыш, тотлыгу, р авазын әйтә алмау, шуның өстенә сөйләгәндә җилкә сикертеп кую кебек сыйфатлар ораторлык карьерасы юлында төп киртәләр булып торган. Ләкин теләк көчле булганда һәммә нәрсәгә дә ирешергә мөмкин икән! Демосфен үзендәге кимчелекләрне бетерү өстендә күп эшли. Мәсәлән, р авазын әйтергә өйрәнү өчен, көчек сатып ала. Аңа кушылып, ырылдарга, р авазын әйтергә өйрәнә. Авызына чуерташ тутырып, авазларны дөрес әйтү күнекмәсен (произношение) ныгыта. Диңгез буена барып, дулкыннар шавын басарлык итеп кычкырып сөйли. Җилкә сикертү гадәтен бетерү өчен, уң ягына бауга бәйләнгән кылыч асып куя. Җилкә сикерткән саен, кылыч иңсәгә кадалып ала. Беренче мәлләрдә егетнең җилкәсе кара кангa бата. Әкренләп бу кимчелек тә бетә. Шуннан соң ул халык алдына чыга. Ләкин беренче чыгышларын халык кабул итми. Шулай да, булачак оратор күңелен төшерми. Бер артист дусты аның чыгышларына сәнгатьлелек, актерлык осталыгы җитмәвен әйтә һәм Демосфенга сәнгатьле сөйләм, актерлык дәресләре бирә.

Шулай итеп, Демосфенга атаклы оратор булу өчен күп киртәләрне үтәргә туры килә. Ул чыгышка төннәр буе ныклап әзерләнә, язган текстын ятлый, көзге каршына басып сөйләп карый торган була.

19 гасыр ораторларының берсе АКШның 16 нчы президенты Авраам Линкольн да (1860–1865 елларда идарә итә) – сенаторлар яки халык алдында ясаячак биш минутлык чыгышын да атналар буе әзерләгән. Бакчада, аллеялар буйлап йөри-йөри, үз-үзенә сөйләп караган.

Димәк, оратор буларак халык алдында чыгыш ясау, уңыш казану өчен җиде кат тиреңне салу кирәк икән. Алдагы чыгышыбызда 20–21 гасыр ораторлары, аларны оратор иткән сыйфатлар турында сөйләшүне дәвам итәрбез.

10. 2. 20 нче гасыр ораторлары

20 гасыр ораторлары дип, Столыпин, В. И. Ленин, Адольф Гитлер, Йозеф Геббельсны атыйлар. Шулай ук француз философы, тарихчы, француз һәм халыкара социалистик хәрәкәт эшлеклесе Жан Жорес; революционер, дәүләт эшлеклесе, язучы, тәнкыйтьче, тәрҗемәче, сәнгать белгече, хәзергечә әйтсәк, совет дәүләтенең беренче мәгариф министры – Анатолий Василье-

вич Луначарский, Италия ком. партиясенең генераль секретаре Пальмиро Тольятти да гасыр ораторлары исемлегендә.

В.И. Ленин публиканы үзенең көчле энергетикасы, оптимизмы, ышандыру көченә ия булуы, патриотик рухны күтәрә белү сәләте белән буйсындырган. Логика, бәхәскә урын калдырмаслык дөреслек, гадилек, жест (кул хәрәкәтләре) – аның төп ораторлык алымнары булган.

А. Гитлер гадәттән тыш ораторлык осталыгына, гадәттән тыш ихтыяр көченә, искиткеч ышандыру көченә ия булган. Гади халыкны гына түгел, укымышлы, зыялы кешеләрне дә үзенә ышандыра, буйсындыра алган. Хәрби көчләрнең төп штабында аңа каршы килерлек кеше булмаган. Ул кешенең күзенә карап сөйләгән, тыңлаучыны гипнозлаган. Властька килгәч, көненә 3–4 чыгыш ясаган. Тавышы күңелгә ятышлы түгел. Һәр сүзе кешегә ток бәргәндәй тәэсир иткән. Германиянең иң көчле ораторы дип әйтәләр. Юкка гына, нәрсә сөйләү мөһим түгел, ә ничек сөйләү мөһимрәк димиләр бит.

Бүгенге көн политикларына килгәндә, Россия президеты В.В. Путинның чыгышларына тыныч тон хас. Артык кискенлек, артык хәрәкәт, тавыш күтәрү юк. Тавышы көчле түгел. Аның чыгышларына юмор, хәйләле караш һәм елмаю, үзенчәлекле мимика хас. Путин үзен консерватив юнәлештәге прагматик дип саный. Ягъни үзенең эш-гамәлләре системасын, тормышка карашын практик һәм нәтиҗәле эшчәнлеккә таянып төзи.

Телевизор экраннарыннан даими күренеп торучы В.В. Жириновскийны оратор дип атап булмый әле, ди белгечләр. Ул артистлыгы белән алдыра. Популист. Тавышы уртача, пулеметтан аткандай кызу сөйли. Ә ораторлык сәнгате өчен бу зур минус икән! Ләкин В. В. Жириновский бик белемле кеше! Мәскәү дәүләт университетының Көнчыгыш телләр бүлеген (1964–70), шул ук уку йортының кичке бүлегендә юридик факультетны (1972–77) Кызыл дипломга тәмамлый. 1965–67 елларда – Марксизм-ленинизм университеты студенты.

1970–72 елларда Кавказ хәрби округында офицер булып хезмәт итә. Филология фәннәре докторы. Инглиз, француз, немец, төрек телләрен белә.

Тагын бер кызыклы мәгълүмат. Куба халык республикасының дәүләт башлыгы, Куба ком. партиясенең 1 секретаре Фидель

Кастро Гиннесның рекордлар китабына «иң ялкынлы оратор» буларак кертелгән. 1960 елның 29 сентябрендә БМОда ясаган чыгышы 4 сәгать 29 минутны тәшкил итә. Бәлки әле ул тарихка иң озын речь сөйләүче дә булып кереп калгандыр. Чөнки 1986 елда Куба ком. партиясенең 3 съездындагы чыгышы 7 сәгать 10 минут дәвам итә. Кайбер чыганакларга караганда 27 сәгатьлек чыгыш булган, имеш!

Атаклы педагог, психолог, язучы Дейл Карнеги (америкалы 1888–1955 елларда яшәгән) үзенең «Публика алдында чыгыш ясаганда ничек итеп үзеңдә ышандыру көче тәрбияләргә һәм тыңлаучыга тәэсир итәргә?» дигән хезмәтендә бик кызыклы мисаллар китерә, ораторлык серләренә төшендерә. Публика, халык алдында еш чыгыш ясаучылар менә шушы хезмәткә ешрак мөрәҗәгать итсеннәр иде.

10. 3. Халкым ораторлык сәнгате турында. Чичәннәр

Халкыбыз да ораторлык сәнгатенә битараф түгел.

- Йөрәктән чыкмаган сүз йөрәккә кермәс.
- Сүзең кыска булсын, кулың оста булсын.
- Начар оратор күп сөйләр.
- Булган оратор мең авызны каратыр,
- Булыр-булмас оратор болгатыр да таратыр.

Сүз уңаеннан: соңгы мәкаль *Н. Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» җыентыгының 3 томыннан (Казан, 2010, 333 нче бит)*. Галим бу мәкальнең язып алынган урыны итеп Мөслим районын күрсәткән. Димәк, бу – якташ мәкаль икән.

Әлеге мәкальләр сөйләгән сүзләребезне, фикерләребезне тагын бер кат дәлилли кебек.

Оратор безнең халык өчен яңа, алынма сүз. Әмма элек бездә бу сүз урынына **чичән телдәр, абыз** сүзләре кулланылган. **Абыз –** җитәкче-трибун, белем-тәжрибә иясе, укымышлы кеше мәгънәсендә. – **Абыз сөйләгәндә, авызың йом, колагың ач. –** Абыз атасыннан олырак (ягъни, укымышлылыгы өчен атасыннан олырак хөрмәткә лаек). **Телдәр аратыл булыр** (ягъни оратор).

Тагын да элгәрерәк, күчмәлек чорында, Болгар дәүләте, Алтын Урда чорында да бездә **чичәннәр (башкортта сәсәннәр)** мәйдан тоткан. Атаклы «Идегәй» дастанындагы Субра картны

искә төшерик. Алар – шагыйрь-импровизаторлар, сүз осталары, оста бәхәсчеләр, җырчылар! **Телгә чичән телнең маен тамызып, сүзнең балын агызып сөйләр, ди бер мәкаль.**

Борынгы вакытларда татар һәм башкортларда һәр ыруның үз чичәне, сәсәне булган. Алар кубыз, думбра чиртеп җыр әйткәннәр. Хәтта ырулар арасындагы бәхәсле мәсьәләләр җыеннарда чичәннәр ярышы белән хәл ителгән. Чичәннең җиңүе – ыруның җиңүе буларак кабул ителгән. Чын чичәннәр туры сүзле, куркусыз булганнар. Ханнарга, түрәләргә тел тидергәннәре өчен хәтта аларның телләрен кискәннәр. Нурихан Фәттахның «Ител суы ака торур» романында Бәкәч чичән әнә шундый җәзага дучар ителә дә инде.

Татар, башкорт, казахлар да үзләренеке дип исәпләгән, ягъни өч халыкның уртак шагыйре Мифтахетдин Акмулла атаклы чичән, сәсән, акын булган. Әче телле, туры сүзле Акмулланың дошманнары да күп була. Аларның котыртуы белән ялланган кешеләр 1895 елның 27 октябрендә Акмулланы үтереп китәләр.

Әмма шигырь дөньясында ул бәхетле була, дан казана. Аңа олы исем – Акмулла исемен халык үзе бирә.

– **Нәтиҗәдә Акмулла дип исем алдым, бу исем бүләк булсын тугрылыкка**, – ди ул.

«Акмулла үзе чыгарган җырларны, халык көйләрен берәр уен коралында уйнап, үзе җырлаган. Әмма башка берәүсе курай уйнаганда, ул бөтен эшен онытып тыңлаган һәм еш кына елый торган булган, дип сөйлиләр.

– Остазым, син курай тыңлаганда дөньяңны онытасың, бу ни-нәмәдән? – дип сораганнар шәкертләре.

Акмулла тирән көрсенеп әйткән:

– Курай тыңлаганда миңа еглау лазем. Чөнки курай туган туфрак теле белән сөйли ул. Курай телен аңлаган адәм, туган җыр моңын эчкән бәндә егламаенча һич түзә алмас, – дигән.

(Р. Батулла «Тузга язмаган хәлләр», 1997, 69–70 нче битләр).

Казах, кыргыз, каракалпакларда – **акын,** тау халыкларында (әзәрбайҗан, әрмән һ.б. Кавказ халыклары**) ашуг** сүзе дә **чичән** мәгънәсендә йөри**. Акын** да, чичән кебек, думбра уйнап үләң әйткән, сүз, җыр ярышында үзен, ыруын яклап дауга ташланган. Аларның теле үткен, акылга, гаделлеккә, образлы сөйләмгә өстенлек бирәләр.

Батыр яуда беленер, чичән дауда беленер, ди халык мәкале.

Казахларда шулай ук жыршылар да (җырчы) булган. Акыннардан аермалы буларак, алар – иҗат итүчеләр түгел, ә башкаручылар. Алар репертуарын фольклор әсәрләр – героик һәм социаль-көнкүреш эпосы, дастаннар тәшкил иткән.

Урта Азия халыкларында (төрекмән, үзбәк, кыргыз) **бахшилар** – халык җырчылары, фольклор әсәрләрен башкаручылар турында да берничә мәгълүмат. Төрекмәндә – багшы, үзбәкләрдә – багши, кыргызларда – бакшы. Алар дутар дигән музыка коралында уйнап җыр әйтә. Әле хәзер дә Төрекмәнстанда сентябрьнең икенче якшәмбесе Төрекмән багшые көне итеп үткәрелә икән.

Әзәрбайҗан ашуглары **сазда**, әрмән ашуглары **сантурида** уйнап җырлаган. Бу халыкларда **акын, ашуглар** аксакал дәрәҗәсендә йөргән, аларга тирән хөрмәт белән караганнар.

Татарларга караганда күчмә тормыш белән озаграк яшәгән казах, кыргызларда акыннар, башкортларда сәсәннәр 20 нче гасырда да булган. Казах халкы бүгенге көндә дә атаклы акыннары Жамбул Жабаев белән (1846–1945) хаклы рәвештә гоурлана. Тугандаш халык башкортлар Мәхмүт, Буранбай, Ишмөхәммәт, Мөхәммәтша Бурангулов кебек сәсәннәрен бүген дә телдән төшерми. Хәтта 1943 елны, БВС барган авыр чорда, Башкортстанның халык сәсәне исеме кертелә. Бу исемгә М. Бурангулов, Дәүләтшин, Исмәгыйлев кебек сәсәннәр лаек була.

Сәсәнлек башкортларда аеруча 16–18 гасырларда чәчәк ата. Бездә исә Казан ханлыгы белән бергә чичәнлек тә кабергә күмелгәндер!

Хәзерге көндә кулланыла торган **бард** атамасы да чичәннең синонимы. **Бард** – кельт теленнән кергән сүз, халык җырчысы мәгънәсендә. Үз җырын ялгыз башкаручы, икенче төрле әйткәндә автор-башкаручыларны да **бард** дип атыйлар. Булат Окуджава, Юрий Визбор, Владимир Высоцкий – танылган бардлар. Бардлар җырларын гитара белән башкаралар.

Югарыда санап үтелгән тел осталары – ораторлар, краснобай, чичән, сәсән, абыз, акын, ашуг, бахши, бардлар – барысы да сүз осталары. Сүзнең тәмен, асылын белеп, телнең нечкәлекләрен халыкка җиткерүче бу асыл затлар турында күпме

сөйләсәң дә аз булыр кебек. Ә халык җырчылары – чичән, сәсән, акын, ашуг, бахшилар – борын-борыннан килгән халык авыз иҗатын, тел байлыгын гасырлардан-гасырларга туган халкына әманәт итеп тапшыручы илчеләр алар. Бүгенге фән-техника заманының колы булып, рухи мирасыбызны чичәннәр кебек халыкка җиткерүчеләребез булмау, ah, кызганыч!

Хөрмәтле, радио тыңлаучылар. «Сөйләм культурасы» турындагы сөйләшүебезгә хәзергә нокта куеп торабыз, әмма туган телебез турында сөйләшү дәвам итәр, дигән ышанычта калам.

11. Бергә булыйк, бердәм булыйк

Хөрмәтле туган телне сөюче, хөрмәт итүче һәм ***«Тел дигән дәрья бар»*** тапшыруын даими тыңлап баручы милләттәшләрем! Сезнең хөкемгә тәкъдим ителгән дистәләрчә тапшыруларда мин сезгә туган телебез, аның сүз һәм тел байлыгы турында диңгездән бер тамчы дәрәҗәсендә генә булса да белем һәм мәгълүмат җиткерергә тырыштым. Сүзнең ни дәрәҗәдә бөек көч икәнен, аның тәрбияви әһәмиятен аңлатырга тырыштым. Сүз җебенең очына тотынып тарих төпкелләренә дә төшәргә була. Сүз, тел – безнең тормышыбыз, тарихыбыз, киләчәгебез!

Тел, туган тел турында уйлана башласаң, уйлар җитмәле түгел. «Тел – диңгез. Бер ясканып кына аның тирәнлегенә төшеп, киңлекләрен иңләп бетереп булмас. Күңелдә сызланып йөргән уй-зарларны бер читкәрәк куеп, «ниләр эшләргә?», «ни гамәлләр кылып була?» дигән сорауларга җавап эзләп карау дөресрәк булыр», – ди Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин. Бик дөрес фикер. Без, татарлар, җае килгән саен, җиде миллионлы халык без, дип мактанырга яратабыз. Җиде миллион кеше елына бер тапкыр булса да, милләт өчен, телебез өчен файдалы гамәл кылса, ничек яхшы булыр иде! Һәр татар эшне үзеннән башласын иде. Халык язучысы Нурихан Фәттах: «Әгәр тиздән минем телем бетә икән, озакламый тамырым корый икән, бу дөньяда ник яшәргә дә, нигә яратырга, балалар тудырырга, чәчәкләр үстерергә? Нигә җырлар, китаплар язарга?.. Икенең берсе – йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә! Мин көрәшергә булдым», – дип язган.

«Мәгарифебез, аеруча милли мәгарифебез һәм мәгърифәт

белән һәрчак бергә үрелеп баручы, гомер-гомергә әхлакны һәм телне саклап килгән дини тәгълимат, халкыбыз тарихында төп рухи роль уйнаган Китап – менә безнең киләчәгебезне билгеләүче төп нигез чаралар!» (Р.Ф.)

Милли мәгариф дигәннән... Мәктәпләрдә Туган телне укыту, аның дәрәҗәсен күтәрү, аны үз югарылыгына кую, тотуда туган тел укытучысының роле искиткеч зур.

– Татар теле бетәр инде ул. Кысалар инде татар телен! – дип сөйләнгән, зарланган татар теле укытучысын аңламыйм мин һәм аның мондый төшенкелеккә бирелүен хупламыйм да.

Г. Ахуновның «Хәзинә» романын бик күпләрнең укыганы бардыр. Узган гасырның илленче еллар уртасы, нефть чыккан Кәлимәт (Әлмәт) яклары тасвирлана әлеге әсәрдә. Роман геройларының берсе – Мөнәвәрә – татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Шул әсәрдән бер өзек: «Үзе укыта торган фән – ана теле белән дә эш шома гына бармады. Машина заманы, техника заманы, зур ачышлар һәм тетрәүләр заманы аның укучыларын, укучыларының ата-аналарын төрлечә уйлап карарга мәҗбүр итә. Алар: «Без татарча укып ерак китә алырбызмы икән соң? Институтларга керә алырбызмы?» – дип борчылалар иде. Моның өчен иң әүвәл туган телеңнең мәгънәсен, зурлыгын, газизлеген син үзең аңларга тиеш, аннары гына син аны бүтәннәргә аңлата аласың. Татарстанны нефть иле, химия иле, диләр. Әмма иген белән, нефть елгалары белән, дөнья күләменә чыккан машиналарың белән генә бөтен бер халыкны аңлатып буламы? Англияне Шекспир ватаны дип беләләр, Польша дип әйтү белән күз алдына Шопен килеп баса. Австрия кебек уч төбе чаклы гына илне дөньяга танытучы – Моцарт. Димәк, халыкны халык иткән, дөньяга таныткан сыйфат – аның күңел байлыгы, теле, сәнгате. Балаларга мисал итеп Мөнәвәрә – Тукайны, Муса Җәлилне китереп куйды. Татарстан дөнья өчен иң элек Тукай ватаны, Җәлил ватаны, Сәйдәш һәм Яруллин ватаны. Тукай да, Җәлил дә дөнья җәүһәрләренә килеп кушылган хәзинәләрен татар телендә ижат иткәннәр. Сәйдәш белән Яруллин татар халкының күңел байлыгын туплап, алмаз кебек эшкәртеп, зур дөньяга чыгарып җибәргәннәр. Шуларны аңлау Мөнәвәрәнең эшләгән эшен мәгънәлерәк итте». Менә шуларны аңларга, туган телнең бөеклегенә инанырга тиеш татар теле һәм әдәбияты укытучысы!

Милләтне, телне саклаучы, яшәтүче – Авыл турында да әйтми булмый. Авылларны бетерәләрмени?! Авыл – татар милләтенең генә түгел, һәр милләтнең җаны, рухы бит ул! Авыл милләтнең телен, традицияләрен, гореф-гадәтләрен, миллилеген саклаучы, туплаучы база бит ул! Авыл әдәбият-сәнгатебез өчен милли кадрлар әзерләп бирүче остаханә бит ул! Шәһәргә күчеп киткән авыл кешесе – туфрагыннан аерып, икенче түтәлгә күчереп утырткан гөл ул. Туфрагыннан аерылган гөл еш кына үсеп китә алмый яки акрынлык белән чит туфракка яраклаша, үзенең төп асылын, матурлыгын югалта бара, тоныклана.

Авыл һәм табигать бер-берсеннән аерылгысыз. Табигать кочагында үскән, яшәгән кеше моңсыз була алмый. Моң безнең күңелләребезне йомшарта, уйланырга мәҗбүр итә.

Берничә ел рәттән ил күләмендә (соңгы елларда дөньякүләм диярлек дә була) «Татар моңы» конкурсы үткәрелә. Бу конкурс күңелдә милләт, телнең киләчәгенә карата өмет, әле «дары базында дары бетмәгән икән» дигән ышаныч уята. Яшьләребез арасында искиткеч моң ияләренең шактый икәнен күргәч (аларның 90%ы авыл балалары) күңел бер сөенсә, башка милләт кешеләренең дә татар җырына тартылуы ниндидер горурлык та уята җанда.

Соңгы елларда халыкны куркыту модага кереп бара. Кризис дип куркыталар, инфляция, дефолт, төрле авырулар (тавык гриппы, дуңгыз гриппы), соңгы чиктә дөнья бетү белән... Милләт бетә, тел бетә, мәктәпләр бетә, авыллар бетә дип һаман бетү турында сөйләп, төшенкелеккә бирелеп барабыз түгелме? Бетмибез әле, Аллаһы боерса, яшибез әле. Өметне үтермик. Өмет яшәтә кешене. 1912 елны һәлакәткә очраган «Титаник» корабы турында ишетмәгән кеше юктыр. Югалтулар ул кадәр зур да булмас иде, кешеләрнең паникага бирелүе һәлакәтне тизләтте, дигән фикерне әйтә белгечләр. Куркуга, төшенкелеккә бирелү – үз-үзеңә кабер казуга тиң.

Һәр халыкның үз агачы була. Греклар зәйтүн дисә, гарәпләр хөрмә агачын үз итә. Японнарның сакурасы (чия) бар. Кырымлылар кипариска мөкиббән. Урысның үз каены... Ә татар халкының агачы – тал. Тал турында нинди генә җырлар, мәкальләр, әйтемнәр ижат итмәгән халык.

Талга басып, тал тибрәтеп, сайрый сары сандугач,
Җырлау түгел еларсың да, өзелеп-өзелеп сагынгач.

Татар халкы юкка гына тал агачын үзенә символ итеп алмаган. Ул аның язмышына туры килә. Тал никадәр генә бөгелсә дә, сыгылса да – сынмый. (Карт һәм коры ботакларны исәпкә алмаганда). Җиргә салып тапта син аны, җир белән тигезлә, өстеннән ат яки берәр техника белән үт – бераз вакыт үткәч карыйсың, яраларын төзәтеп, тал яңадан торып баскан. Кисеп бетер таллыкны – тамырлары бер-беренә нык береккән һәм үрчемле агач булганлыктан, икенче елга кабат үсеп китә алар. Игътибар иткәнегез бардыр: юллар төзегән, салган вакытта ике яктан да юлны күтәртәләр. Берничә елдан юлны ике яклап тал үсентеләре каплап ала. Талга дым гына кирәк икән.

Безнең милләт тә күпме сынаулар аша үткән. Гасырлар дәвамында күпме изелү, кимсетелүләр күргән, тамырына балта чапканнар, ләкин ул, барысына үч итеп дигәндәй, яшәвен дәвам иткән. Сыгылса да, егылса да торып баскан. Тегендә юк итсәләр, икенче җирдә баш калкыткан, тамырларын корытмаган, берегеп яшәргә тырышкан. Татар кайда гына юк! Дөньяның кайсы гына почмагына барып чыксаң да татарны очратмый калмыйсың, диләр бит илләр гизгән кешеләр. Татар халкын еш кына бер-берсенә ярдәм итмәүдә, таркаулыкта гаеплиләр. Татар башын татар ашар, диләр хәтта. Һәр милләттә бар инде андый баш ашаучылар, игътибар итсәң. Безнең халык өстенә төшкән сынауларны санап кына бетererлекме! Әмма ул яши, һаман яши! Бер-берсенең башын ашап торсалар, әллә кайчан кырылып беткән булыр иде инде халкым. Чит төбәкләрдә яшәүче татарлар, киресенчә, берләшеп, туганлашып, ярдәмләшеп яши беләләр. ТНВ каналыннан «Татарлар», «Халкым минем» тапшырулары әнә шундый милләттәшләребез турында күп сөйли. Димәк, тал ул – безнең милләтебез, сандугач – телебез! Басып сайрар талы булса, сандугач җырламый түзәрме?!

Талга дым кирәк, дидек. Милләтебезнең Каюм Насыйрилары, Шиһаб хәзрәтләре, Тукайлары, Әмирханнары, Дәрдемәндләре, Риза Фәхретдиннәре булган. Фәндәсләре, Маратлары (инде мәрхүм), Фәүзияләре, Разиллары, Туфаннары бар! Аларга алмаш та килми калмас, иншаллаһ!

Чыгышымны югары нотада тәмамлыйсым килә.

Киләчәкнең башы – бүгенгедә,
Нинди шатлык картлык көнеңдә –
Оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә,
Матур итеп туган телеңдә!

Бергә булыйк, бердәм булыйк! Кабат очрашканга кадәр сау булып торыгыз!

II бүлек

«САБЫЙГА». РАДИОТАПШЫРУ

I кисәк

1. Кереш

Һәр халыкның әдәбиятында «Балалар әдәбияты» дигән мөстәкыйль бер тармак бар. Шулай булмый мөмкин дә түгел, чөнки балалар безнең дәвам, милләтнең, халыкның, илнең киләчәге! Ә аларны киләчәк кешесе итеп тәрбияләүдә әдәбиятның өлеше һичшиксез зур! Ә әдәбият исә кешедә матурлык, әхлаклылык, хезмәткә мәхәббәт, кешелеклелек тәрбияли. Әдәбият тормышны аңларга, дөньяны танып-белергә өйрәтә. Әдәбият фикер һәм тел байлыгын үстерә. Җыеп кына әйткәндә, әдәбият кеше, милләт, халыклар тормышында бик зур роль уйный. Шуларны истә тотып, язучыларыбыз, шагыйрьләребез әдәбиятка мәхәббәтне кече яшьтән тәрбияләү максатыннан, балалар өчен берсеннән-берсе матур хикәяләр, шигырьләр, сәхнә әсәрләре иҗат итәләр. Кайсы гына язучы, шагыйрь балалар темасын читләтеп үткән икән? Классик язучылардан башлап, хәзерге чор иҗат әһелләре – һәммәсе балалар әдәбияты тармагына үз өлешен кертми калмаган. Чынлап та, «Без – барыбыз да балачак иленнән!» Балалар өчен дә иҗат итү – язучының иң зур бәхетедер ул. Шигырьләре, әкиятләре ана сөте белән бергә бала күңеленә сеңеп калган әдипләрнең әдәби язмышлары да күпкә баерак, кызыклырак, әдәби гомерләре дә күпкә озынрак, әсәрләре дә бермә-бер күбрәк укыла», – ди балалар шагыйре Роберт Миңнуллин.

Хәзерге заманда балаларыбыз әдәбияттан, әдәби китаплар укудан читләште, дип борчылабыз. Әти-әниләрнең, балаларыбыз компьютердан башларын да күтәрмиләр, көннәр буе шуңа капланып утыралар дигәннәрен еш ишетергә туры килә. Китап, азмы-күпме әдәби әсәрләр уку, өйрәнү әдәбият

дәресләрендә генә калып бара шикелле. Әле татар әдәбиятына килсәк, анысының да сәгатьләр санын күпкә кыскарттылар. Шуларны истә тотып, «Тәртип» радиосы дулкыннарында кече һәм урта яшьтәге балалар өчен «Сабыйга» тапшырулар сәхифәсен әзерләргә булдык. Бу тапшыруларда татар балалар әдәбияты турында сөйләрбез, язучы-шагыйрьләребезнең иҗатлары белән кыскача танышырбыз, аларның әсәрләрен тыңларбыз. Юк дигәндә дә, балаларыбыз радио тыңламый тормыйдыр. Әти-әниләр, әби-бабайлар, апа-абыйлар да әлеге сәхифәгә битараф калмаслар, дип уйлыйбыз. Бу сәхифә сезнең өчен дә!

Дәрдемәнд. «Сабый» *(нәсер)*

Бәхетле сабый! Карагыз, ниндәен рәхәт, никадәр дә татлы йокы эчендә!... Бөтен вөҗүден ниндәен матур тынычлык каплаган! Күкрәккәен бер кабартып, бер төшереп күркәм тын алышларын, күркәм йөзкәендә җилбер-җилбер уйнаган көлемсерәүләрен, тибенеп-тибенеп алган кечкенә тәпикәйләрен күргәнегездә, гүя бер фәрештә, күк йөзендә оча-оча канаткайлары талган да, җир йөзенә төшеп, бу бишекнең эчендә ятып калган дип әйтәсегез килмәсме?

Бәхетле сабый! Йокла! Синең һәрдаим тынычлык эчендә калуыңны теләгән шәфкатьле әнкәеңнең күзе алдында рәхәт, рәхәт йокла!

Син өлкән адәмнәр кебек, уянсаң – зәхмәтле эшләр, йоклысаң, имәнеч төшләр күрмисең. Уяныр-уянмас, әнкәеңнең йөзенә карап көлүдән башка һич эшең юк. Никадәр дә күркәм, татлы көләсең! Әнкәең никадәр арыган, никадәр талган булса да, янә шул матур көлүләреңаның бар мәшәкатьләрен оныттырадыр. Синең көләр йөзкәеңне күргән саен, әнкәеңнең дә йөзе көлеп, йөрәгендә бер шатлык, бер сөенеч пәйда буладыр. Шунда ук сине шәфкатьле кочагына ала, күкрәгенә баса да сиңа мәхәббәтен күрсәтә. Син дә аңа җавап урынына, күркәм-күркәм көләсең, һәм татлы-татлы имәргә башлап, туйганчы имәсең. Бу хәлдә янә әнкәеңнең йомшак кочагында сирпелеп йоклаудан башка эшең калмый.

И бәхетле сабый! Йокла! Синең һәрдаим тынычлык эчендә калуыңны теләгән шәфкатьле әнкәеңнең күзе алдында рәхәт – рәхәт йокла!

Җыр «Бәллү». (Дәрдемәнд сүзләре,
В. Ганиева башкаруында)

2. Каюм баба сабаклары

«Балалар әдәбияты мәйданы беркайчан да буш тормаган, поэзия, проза әсәрләре языла килгән. Әмма балалар әдәбиятының аеруча җанланып, тармакланып үсеп китүе 19 йөзгә туры килә. Ә татар балалар әдәбияты, нигездә, 19 йөзнең икенче яртысында ныклап формалаша», – дип яза татар балалар әдәбияты галимәсе Фатыйма ханым Ибраһимова. Бу гасырда «балалар өчен» дип күрсәтелгән әдәби китаплар чыга башлый. Әлеге тармакта аеруча зур хезмәт куйган кеше – татар халкының зур галиме, «татарның Ломоносовы» Каюм Насыйри! 1860 елда ул татар балалары өчен беренче энциклопедик уку китабы – «Буш вакыт»ны чыгара. Соңрак, 1881 елда «Әхлак рисаләсе» («Әхлак китабы»), 1891 елда «Тәрбия китабы» – җыентыклары дөнья күрә. Каюм баба балаларны гыйлем алырга, һөнәр үзләштерергә өнди. Әмма белемле, һөнәрле булу мәгърифәтле кешенең бер сыйфаты гына, кеше югары әхлаклы да булырга тиеш, дигән фикерне үткәрә.

«Тәрбия китабы» («Китаб-әт-тәрбия) 113 әдәби парчадан тора. Һәп парчада кеше өчен зарур булган күркәм холыкның бер сыйфаты турында сөйләнә. Беренче тәрбиядә галим болай яза». Бер хаким балаларга шундый нәсихәт бирде: «Әй җаннарым, угланнарым, нәсихәтемне ишетегез – һөнәр үгрәнегез. Дөньяның милкенә вә дәүләтенә ышанырга ярамас. Алтын-көмеш – сәфәр кешесенә хәтәрдер вә йорт-җир кешесенә дә хәтәре бар: я угры алып китәр яки утка янып китәр. Әмма һөнәр бер агым судыр вә ышанычлы дәүләттер. Һөнәр иясе, әгәр дәүләттән төшсә дә кайгы юк. И угыл, син дә һөнәр үгрән, тәрбия үгрән, гыйлем үгрән».

Каюм бабаның балалар да, өлкәннәр дә яратып укый торган әсәре – мәшһүр «Әбүгалисина кыйссасы»! Балачакта, бу кыйссаны бер-беребездән берничә сәгатькә генә алып торып, чиратлашып, ярыша-ярыша укый идек. Күп укыган, күп белгән

иптәшләребезне Әбүгалисина дип тә йөртә идек әле. Алар моңа ачуланмый, бәлки, горурланалар гына иде.

Каюм Насыйри бу әсәрне 1872 елда тәрҗемә итә. Әсәрдә акылның, зирәклекнең, гыйлемнең көченә дан җырлана.

Ә хәзер «Әбүгалисина кыйссасы»ннан бер өзек тыңлагыз.

Борын-борын заманда Бохара шәһәре янында Шәҗегъ дигән авылда бер ир белән хатын яшиләр иде. Алар бик тату торалар, матур гына гомер итәләр иде.

Көннәрдән беркөнне боларның игезәк ир балалары туды. Ата белән ана бик шатландылар. Балаларның берсенә Әбүгалисина, икенчесенә Әбелхарис дип исем бирделәр.

Көннәр, атналар үтте, айлар, еллар да үтеп киттеләр, балалар дүрт яшькә җиттеләр. Аларны мәктәпкә укырга бирделәр. «Укысыннар, белем алсыннар, кеше булсыннар», – диделәр.

Әбүгалисина үзенең үткенлеге, зирәклеге белән башка балалардан аерылып тора иде. Әбелхарис, Әбүгалисина белән игезәк булса да, бер ата, бер анадан туса да, зирәклек һәм булдыклылык ягыннан туганы шикелле үк түгел иде.

Әбүгалисина бик яхшы укый, укытучы ни генә әйтсә дә, бик тиз төшенеп ала, белгәнен бер дә онытмый иде. Шулай ук ул укытучы сөйләгән белән генә канәгатьләнеп калмыйча, яшьтән үк китаплар укуга бирелде. Шуңа күрә бик күп нәрсәләр белде. Халык сүзе белән әйткәндә, «кылны кырыкка яручы» бер бала иде.

Аның зирәклеге, сизгерлеге турында бик кызык сүзләр сөйлиләр. Ул вакытларда мәктәпләрдә, асларына киез салып, идәнгә тезләнеп укыйлар – парталар булмый. Әбүгалисинаның иптәшләре аның киезе астына бер бит кәгазь салып куялар, ә үзләре, Әбүгалисина нишләр икән дип, кызыксынып карап торалар. Әбүгалисина мәктәпкә килә, урынына кереп утыра, аннары бер югары, бер түбән карап тора. Аңа сорау бирәләр: «Нишләп алай карангалыйсың?» – диләр.

– Белмим, мәктәпнең түшәме төшкәнме, әллә идәне күтәрелгәнме? Ни булса да бар, элеккечә түгел, – ди. Шулай ул киез астына салынган бер бит кәгазьнең калынлыгын да сизгән, имеш, дип сөйлиләр.

Унике яшенә җиткәндә, Әбүгалисина бик күпне белүче гыйлем иясе булып җитешә, төрле фәннәрдән үзе дә башкаларга сабак укыта башлый. Үзеннән күп зур балалар аннан дәрес алалар.

Ул төшкә кадәр балаларга сабак укыта, төштән соң урамга чыгып, алар белән рәхәтләнеп уйнап йөри. Аның бу гадәте кайбер кешеләргә бер дә ошамый. Аңа: «Син шундый галим, акыл иясе кешесең, никадәр балаларга сабак өйрәтәсең, белем бирәсең. Ә үзең надан балалар белән уйнап йөрисең», – диләр. Әбүгалисинаның моңа бер дә исе китми. Ул: «Кешенең һәр яшендә үзенә күрә бер матурлыгы була, сабыйлыкның матурлыгы уен белән», – дип җавап бирә.

3. Г. Тукай һәм татар балалар әдәбияты

1905 ел революциясеннән соң балалар әдәбияты яңа күтәрелеш дәверенә керә. Бу чорда әдәбият тизләтелгән үсеш ала, күпләп мәктәп-мәдрәсәләр ачыла, аларда уку-укыту өчен яңа тип дәреслек-хрестоматияләр, программалар төзелә, татар теле һәм әдәбияты мөстәкыйль фән итеп укытыла башлый. Болар барысы да балалар әдәбияты үсешенә ныклы йогынты ясый. 20 гасыр башында кечкенәләргә атап язылган әсәрләр аеруча күбәя. Балалар өчен китаплар бастырыла, балалар матбугаты туа. Мәсәлән, балалар өчен «Тәрбиятел әтфаль» («Балалар тәрбиясе»), «Ак юл» исемле журналлар чыга башлый.

Реалистик татар балалар әдәбиятын үстерү юнәлешендә Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, М. Гафури кебек классикларыбыз зур хезмәт куйдылар. Балалар әдәбиятының кирәклеге, әһәмияте турында бөек Тукаебыз менә нәрсә дигән: «Балаларыбызның күзе гүзәл нәрсәләр күрергә вә борыннары да хуш вә татлы исләр иснәргә ияләшсен. Кечкенәдән үк гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күңелләре дә гүзәл һәм нәфис булып, анчак гүзәл вә мөкатдәс нәрсәләрне генә сөючән буладыр».

Шулай итеп, татар балалар әдәбиятын Тукаебыздан башка күз алдына китерүе дә кыен. Ул бу өлкәдә бик күп эшли. Шигырь-әкиятләр язу белән берлектә, мәктәпләрдә укыту өчен дәреслекләр, хрестоматияләр төзи, газета-журналларда уку-укыту мәсьәләсен яктырткан мәкаләләр бастыра.

Тукаебыз иҗатының буеннан-буена балаларны **хезмәттә** тәрбияләү юнәлешенә зур игътибар бирелә. Чөнки җир йөзендәге барлык материаль байлыклар кеше кулы белән тудырыла. Хезмәт сөйгән кеше генә уңышка ирешә ала. Үзе эш, хезмәт сөйгән кеше генә башкаларның хезмәтен дә бәяли һәм хөрмәтли белә! Эшләп кем баеган? – дигән заманда яшәсәк тә, җиңел юл белән табылган байлыкка караганда, гадел, намуслы хезмәт белән тапкан байлык бәрәкәтлерәк һәм файдалырак! Тукаебыз бала алдына идеал кеше итеп хезмәт кешесен куя. «И сабыйлар, эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә – эш! Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш!» – ди ***«Эшкә өндәү»*** шигырендә. Аныңча киләчәкнең бәхетле кешесе физик яктан сәламәт, рухи яктан камил булырга, туктаусыз иҗтиһад итәргә, ягъни тырышырга тиеш.

Тукаебыз шулай ук **уку, белем алу** мәсьәләсенә дә зур игътибар бирә. Белемле бала уңай герой итеп алына. «Белем – нур, наданлык – хур!» – менә Тукаебызның балаларга җиткерергә теләгән фикере.

«Өч наданга алмашынмас – бер язу белгән кеше», – ди ***«Ата илә бала»*** шигырендә. Баланың укуга булган мәхәббәте – гаилә бәхете дип бәяләнә.

Туган җиргә мәхәббәт, патриотизм, табигатьне җылы итеп, матур төсләр белән тасвирлау, кошлар, хайваннарга миһербанлы караш аша бала күңелендә бары тик матур хисләр, кешелеклелек, ярдәмчеллек, сизгерлек, нечкә күңеллелек тәрбияләүне максат итеп куя шагыйрь.

Тукайның балалар өчен язган шигырьләрен укыганда, күземә яшьләр килеп, күңелем тула минем. Фаҗигале балачак кешесенең балалар турында шулай яратып, үз итеп яза алуы үзе бер могҗиза! Күз алдына, өйләнмәгән, кулына бала алып, аны сөеп тә карый алмаган яшь егет түгел, ә тормыш тәҗрибәсе туплаган зур гаилә башлыгы булган олпат ир килеп баса!

Балаларыбызга, оныкларыбызга йоклар алдыннан, Көнбатышның тәрҗемә ителгән принцлар, принцессалар турындагы әкиятләрен генә укыганчы, Тукай шигырьләрен, Тукай әкиятләрен, татар балалар шагыйрьләре, язучыларының әсәрләрен дә уку отышлырак булмас микән?!

Тукайның берничә шигыре укыла. «Фатыйма һәм сандугач», «Эш», «Туган авыл», «Туган җиремә»...

4. Фатих Әмирхан һәм татар балалар әдәбияты

Бүген без классик язучы һәм драматург Ф. Әмирхан һәм аның балалар әдәбиятына керткән өлеше турында сөйләшербез.

Фатих Әмирхан дип әйтүгә, ни өчендер, тел очына Г. Тукай исеме, күз алдына Г. Тукай килеп баса. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Чөнки Ф. Әмирханны Г. Тукайның Фурмановы дип тә йөртәләр (Дмитрий Фурманов – Гражданнар сугышы герое В.И. Чапаевның комиссары). Г. Тукайга Ф. Әмирхан кебек ярдәм иткән, авыр вакытларда аңа зур таяныч булган башка берәү булдымы икән?! Үзе дә 21 яшендә зур фаҗига кичергән, башкалар ярдәменә мохтаҗ булган Фатих Әмирханның Тукайның Тукай дәрәҗәсенә күтәрелүендә роле бик зур, диләр галимнәребез дә.

Ф. Әмирхан – Тукайның яшьтәше. Алар икесе дә бер елны – 1886 елда туганнар. Фатих Әмирхан ел башында (гыйнварда), ә Тукаебыз апрель аенда. Икесе дә мулла гаиләсеннән. Тукаебыз яшьли ятим калып, кулдан-кулга йөрсә, Фатих Әмирхан Казанның Яңа бистәсендә Зариф мулла гаиләсендә кадерле, шукшаян, иркә, әмма үткен, зирәк, сәләтле бала булып үсә. Яңа бистә мәдрәсәсендә укыган җиреннән заманы өчен алдынгы булган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә күчә. Ул анда ун ел укый (1895–1905 еллар). Мәдрәсә каршындагы рус классында да белем ала. Югары белем алырга – Казан университетына укырга керергә хыяллана. Әмма 1907 елны аны паралич суга һәм искиткеч сәләтле, энергиясе ташып торган егет гомерлеккә аяксыз кала, креслода гына хәрәкәт итә. Тик ул югалып калмый. Барлык ихтыяр көчен җыеп, белемен туплап, журналистлык һәм әдәби иҗат эшенә чума. Хикәя-повестьлар, «Урталыкта» романын, драмалар, бик күп публицистик мәкаләләр иҗат итә. «Әльислах», «Кояш» газеталары чыгара. Башка газета-журналлар белән языша. Ф. Әмирхан 1926 елда каты авырудан вафат була. Бу вакытта аңа 40 яшь кенә була!

Язучы һәм драматург Фатих Әмирханны без өлкәннәр-зурлар өчен иҗат итүче буларак кына беләбез. Ләкин аның балалар өчен дә язылган берничә хикәясе бар. Әдипнең балалар яратып укый торган «Ул үксез бала шул!», «Нәҗип», «Корбан», «Балалар атавы», халык авыз иҗатына нигезләп иҗат ителгән «Ай өстендәге Зөһрә кыз», «Сөембикә» әсәрләре моңа мисал.

«Ай өстендәге Зөһрә кыз яки Сөембикә»дән берәр өзек.

5. Дәрдемәнд һәм татар балалар әдәбияты

Татар әдәбиятында Дәрдемәнд (хәсрәт чигеп яшәүче мәгънәсендә) псевдонимы белән иҗат иткән гаять үзенчәлекле, фәлсәфи, тирән мәгънәле шигырьләр язучы шагыйрь булган. Ул – Закир Рәмиев. Без мәктәптә белем алган чорларда, ягъни узган гасырның 60–70 нче елларында, бу шагыйрь, аның иҗаты әдәбият дәресләрендә өйрәнелмәде. Сәбәпләрнең берсе – аның революциягә кадәр зур фабрикант, алтын приискалары хуҗасы, миллионер, капиталист булуыдыр. Шулай да язучы Мәҗит Гафуриның «Шагыйрьнең алтын приискасы» әсәрендә бертуган Закир һәм Шакир Рәмиевләр приискасы турында сүз баруы турында бераз белә идек. Закир дигәненең шагыйрь булуын, Дәрдемәнд псевдонимы белән иҗат итүе турында укытучыбызның сөйләгәне хәтердә әле.

Бүгенге тапшыруда без Дәрдемәнднең балалар әдәбиятына керткән өлеше турында сөйләрбез. Дәрдемәнд – алтын промышленнигы, химаячы, шагыйрь генә түгел, зур гаилә башлыгы да булган. Хатыны Мәхүбҗамал белән җиде бала: 4 ул, 3 кыз үстерәләр. Ул балаларын бик яраткан, аларга ныклы белем һәм тәрбия биргән. Балалар өчен язган әсәрләрендә балаларны гыйлем алырга, тәрбияле, әхлаклы булырга өнди. Туган илгә, хезмәткә мәхәббәт, олыларга хөрмәт тәрбияләүне, ата-ана хакын хаклауны зур бурыч итеп куя. Менә аның **«Нәсихәт»** дип аталган дүртьюллык шигыре.

Гәрчә күрсәң ата-анаңнан җәфалар күп заман,
Син җәфа итмә аларга, бәлки – хөрмәт, и угълан!
Син нидер иттең исә атаң өчен, анаң өчен,
Син дә угланыңнан алырсың аны, әлбәт, и угълан!

Дәрдемәнд 1910 елда ***«Балалар өчен вак хикәяләр»*** исеме белән үз әсәрләрен дә кертеп, башка телләрдән күчереп, тәрҗемә итеп бер кечкенә китап та төзеп чыгара. Бу әсәрләр җиңел, аңлаешлы тел белән язылганнар. Әдипнең әлеге җыентыкка кергән берничә әсәрен тыңлап китәрбез.

Кояш нурлары

Матур кояш иртә белән кызарып күк йөзенә күтәрелде. Җир йөзен татлы йокысыннан уятыр өчен, алтын кебек сары якты нурларын таратып, төрле якларга җибәрде.

Башта бер нур очты. Барып-барып сабан тургаеның өстенә төшкән иде, сабан тургае йокысыннан уянып тирбәнде, чыгып күк йөзенә күтәрелде. Шуннан матур тавыш белән чырлап сайрап җибәрде.

Икенче нур очты. Монысы татлы йокыда яткан бер куян өстенә барып төште. Куян урыныннан торып озын колакларын селкетте. Шундан сикерә-сикерә яшел тугай эченә төшеп, йомшак үләннәрне керт-керт өзеп ашамага кереште.

Янә бер нур очып тавык кетәгенең эченә кергән иде, өлкән әтәч күзләрен ачып, канатларын язып, гайрәт белән тилпенде, «Кикри-и-и-и-ки-и-и-к!» дип кычкырып җибәрде. Тавыклар кунакчаларыннан очышып төштеләр. Кытыйклашып төрле якка таралды җим эзләргә.

Дүртенче нур килеп умарта өстенә төшкән иде, бал корты сараеннан чыгып канаткайларын төзәтте. Шундан «Без-з-з-з!» китте очып, хуш исле чәчәкләрдән бал җыйнарга.

Бишенче нур балаларның йокы бүлмәсенә кереп, бер кечкенә ялкауның түшәгенә, туп-туры күзкәенә төште. Я рабби, кыздыра! Әмма кечкенә ялкау әйләнеп икенче ягына ятты да тирән йокыгы талып та китте.

Гали

Бер кешенең өч углы бар иде. Иң кечкенәләре Гали атлы. Аталары базардан өчесенә дә берәр алма алып кайтты. Алмалар бик пешкән. Татлы, сулы җимешләр иде.

Берничә сәгатьтән соң аталары балаларын янына чакырып: «Алмаларыгызны нишләттегез?» – дип сорады. Өлкән углы әйтте:

– Әти! Мин алмамны ашадым. Эчендәге орлыкларны җыеп куйдым. Бакчабызга чәчеп алма агачы үстермәк буламын.

– Яхшы иткәнсең, углым! – диде атасы.

Уртанчы углы әйтте:

– Мин алмамны ашадым. Бик тәмле, татлы җимеш икән. Әтиемә хак тәгалә исәнлек бирсен дип дога кылдым.

Атасы янә: «Яхшы иткәнсең, углым!» – диде.

Өченче улы Гали атасына карап әйтте:

– Алманың яртысын ашадым...

Атасы әйтте: – Яртысын нишләттең?

Гали куркып кызарып әйтте: – Күршебезнең углы Вәли авырып ята. Барып яртысын аңа бирдем. Бик куанды, дога кылды.

– Бәрәк алла, углым! Син бигрәк тә яхшы иткәнсең! – дип атасы Галинең битеннән, күзләреннән үпте.

Богдай

Бер игенче, сигез яшендәге углы Хөсәенне янына алып, игеннәрнең ни хәлдә икәнен күрер өчен, басуга китте. Юлда бер игенлеккә очрадылар, богдайларның барысы да башакларын җиргә карап игәннәр, арада берничәсе генә башларын югары күтәреп, теп-текә торалар иде. Хөсәен бу хәлне искәрде. Әтисенә әйтте:

– Әти! Карачы бу богдайларны: мескиннәр! Ничек муеннары бөгелгән... Машалла, әнә тегеләре! Ниндәй, теп-текә, егет сыман торалар!

Атасы атны туктатты. Арбадан төшеп. Богдайларның ике төрлесеннән дә өзеп алды. Бөртекләрен чыгару өчен башакларын учлары эчендә угалады. Шуннан Хөсәенгә әйтте:

– Кара, углым! Боларның эчендә никадәр күп богдай бар! Менә шуның өчен дә боларның башлары иелгән... Инде шул текә торганнарын кара – эчләрендә бер әйбер дә юк! Болар бер тиен дә тормый. Моннан гыйбрәт ал, углым: текә башлы булу гакылсызлыктан килә.

Сукачы белән падишаһ

Көннәрдән беркөн бер падишаһ сунарга чыккан иде. Ау артыннан кырдан кырга узып йөргәндә, җир сөреп, иген игеп торган бер сукачыга очрады. Янына барып сәлам бирде. Сукачы сәлам алып: «Кыйдамәгезгә хәсәнат, солтаным!» – дип кул кушырып торды.

Падишаһ хәзрәте сорашмага башлады:

– Ни эшлисең?

– Гомерегезгә дога әйтеп, иген игәмен, тәкъсыйр!

– Елында никадәрлек ашлык сатасың?

– Бәгъзе ел йөз, бәгъзе елны биш йөз акчалык, солтаным!

– Ул акчаны ни урыннарга тотасың?

– Ходайга шөкерләр, хәзрәтегезгә догалар әйтеп, бер өлешен үз кирәкләремә тотамын. Бер өлешләре белән бурычларымны үтимен. Бер өлешен әүсемгә бирәмен, солтаным.

– Ни вакыт бурычландың? Бурыч алу ни өчен хаҗәт булды?

– Кечкенә бала көннәремдә, һичбер эшкә ярамасам да, атаманам мине киендереп асрап үстерделәр. Аларга бурычландым, тәкъсыйр! Инде алар картайды, бер эшкә дә ярамыйлар. Ашатып, эчертеп, бурычымны түлимен.

– Хуш... Акчаның бер өлешен әүсемгә бирәмен, дидең. Әүсемгә акча биреп файдалануның хәрам икәнлеген белмисеңме?

– Биш җан вак балаларым бар... Аларны ашатып-эчертеп торам, солтаным. Мин картайгач, алар да мине карарлар. Әүсемгә бирәмен дигәнем шул.

– Бәрәкалла! – дип, падишаһ хәзрәте ул кешегә йөз алтын һәдия биреп китте.

6. Дәрдемәнд. Балалар өчен кыска хикәяләр

Бер хәзинә

Карт бер игенче гомеренең актык көннәрендә балаларын янына чакырып әйтте:

– Балаларым! Басуыбызның эчендә бер хәзинә бар. Әмма кай җиренә күмелгән икәнен белә алмадым. Мин үлгәннән соң, озакка сузмыйча, басуыбызга барыгыз, һәр җирен яхшылап казып актарыгыз. Әгәр тапсагыз, ул хәзинә гомерегез буена тотсагыз да бетмәс һәм сезне берәүгә дә мохтаҗ итмәс, атадан балага мирас кала килгән бу басуны, сак булыгыз, сата күрмәгез. Чөнки бердән, киләчәктәге балаларыбызга хыянәт иткән булырсыз, икенчедән, эчендәге хәзинә кулыгыздан ычкыныр.

Карт игенче вафат иткәннән соң, ике кардәш, кем узардан басуга йөгерделәр. Казылмаган җир, чукылмаган урын калмады. Актардылар, эзләделәр – хәзинә юк!

Басуның өсте тоташ казылган, тупраклары тетелеп ватылган иде. Ике кардәш, бу кадәр имгәкләре бушка калмасын өчен, богдай чәчтеләр. Хәзинәнең табылмаганына бик кайгырыштылар.

Көннәр үтте. Игеннәр пешеп өлгерде. Кардәшләрнең игене күрше игеннәрдән кат-кат артык иде. Урак урылды. Ындыр басылды... Ике кардәш, ындыр табагында өем-өем яткан богдайны күргәч, аталары әйткән хәзинәнең «тырышып эшләү» икәнен менә шул вакытта гына аңладылар.

Бәли, тәҗрибә күргән гакыллы игенче, үзенең уллары алдында, тырышып эшләүнең төкәнмәс бер хәзинә хөкемендә икәнлеген балаларына киная белән аңлаткан иде.

Нури белән Зәйнәп

Нури белән Зәйнәп бер бүлмәнең эченә икәүсе генә иделәр. Зәйнәп урындык өстендә утырып бер яулыкның читен бөгә иде. Нури бүлмә эчендә әрле-бирле йөри, башында ниндидер бер уе бар кебек күренә иде. Кинәт бер читтә торган өстәлнең янына барды. Өстәлнең өстендә аналарының фарфордан ясалган кыйммәтле бер чүлмәге тора иде. Нури чүлмәкне карамак булды... Зәйнәп башын күтәрде дә әйтте:

– Абзый! Кара, чүлмәкне күтәрмә! Әнием ачуланыр!

Нури җавап биреп әйтте:

– Юк! Кулыма алмыйм, карыймын гына!

Нури чүлмәкне ике ягыннан тотып, эчен карар өчен, күтәрмәгә башлады. Әмма чүлмәк кинәт кулыннан ычкынды. Төшеп, биш-алты кисәк булды. Зәйнәп кычкырды:

– Я Рабби!... Нури! Нишләттең?

Нури башын иде, чүлмәкнең ватыкларына карады, кызарды, бузарды... Я инде әниләре? Ул да хәзер киләчәк иде түгелме? Нури Зәйнәпкә карап әйтте:

– Зәйнәп! Кара, чүлмәкне мин ватканны әниемә әйтмә!... Аңладыңмы?

Бер-ике минут үтмәде, әниләре бүлмәгә килеп керде. Чүлмәкнең ватыкларын күрде. Ачу белән: «Бу чүлмәкне кем ватты?!» – диде. Балаларына карады. Нури алгарак чыгып әйтте:

– Без бу бүлмәгә кергәндә чүлмәк ватык иде!..

Менә сиңа бер ялган.

Әниләре асрау кызны чакырды. Ачу белән әйтте:

– Хәдичә! Бу бүлмәгә балалар белән синнән башка беркем дә керми. Тугры сөйлә, бу чүлмәкне синме ваттың?

Бичара хезмәтче кыз, яулыгын күзләре өстендә тотып, еламага башлады. Нури бераз аяды. Әниләре Хәдичәгә әйтте:

– Я, Хәдичә! Елауның файдасы юк. Дөресен әйт!

Хәдичә үксеп-үксеп елый-елый җавап бирде:

– Юк, абыстай! Бу чүлмәкне мин ватмадым.

Зәйнәп әкертен генә Нуриның янына барды. «Туганым! Бакчы, Хәдичә ничек елый. Әнием аны куар бит. Өстенә яла япма, чынын әйт. Язык булыр, ич!» – диде.

Нури уйга калды. Шунда әнисенә якынлап әйтте: «Әнкәем! Хәдичәнең һич гөнаһысы юк. Ялган сөйләдем. Чүлмәкне мин ваттым».

Нури еламага башлады. Зәйнәп белән Нури бичара Хәдичәне шелтәдән коткардылар. Әниләре әйтте: «Бәрәкалла, углым! Менә яхшы иттең! Дөнья булгач, бәгъзе вакыт кеше кулыннан каза чыга. Аны танмый әйтергә тиеш. Хаталык белән бер эшне бозасың икән, аны кеше өстенә ябу бер дә ярамый. Үз гөнаһын башкалар өстенә аудару иң мордар, иң әшәке кешеләрнең эше... Ягез инде, балалар! Бу фәкыйрь хезмәтче кызның күңелен табарга тырышыгыз!

(Бу хикәятләр Дәрдемәнднең «Сайланма әсәрләр» җыентыгыннан алынды. Казан, 1959 ел)

7. Галимҗан Ибраһимов һәм балалар әдәбияты

Балалар, сезнең күбегезнең классик язучы Галимҗан Ибраһимов турында ишеткәнегез, әле бәлки аның атаклы «Алмачуар» хикәясен дә укыганыгыз бардыр. Мәктәп программасына аның «Яз башы» хикәясе дә кертелгән иде. Без мәктәп укучысы булганда, әдәбият дәресендә аның «Көтүчеләр» хикәясен өйрәнә идек. Шулай ук класстан тыш укуга аның «Карт ялчы» хикәясе тәкъдим ителә иде. Ә югары классларда аның «Тирән тамырлар», «Яшь йөрәкләр», «Казакъ кызы» романнарын укып, бәхәсләр оештыра идек. Нинди күңелле вакытлар булган икән ул мәктәп еллары!

Алда телгә алынган «Алмачуар» хикәясе ат турын-

да, ат яратучы Закир исемле авыл малаеның атларга булган мәхәббәте турында. Г. Ибраһимовка бу әсәрне язуга үзенең дә атлар яратуы этәргән. Аның әтисе Гыйрфан мулла бик тә атлар яраткан, чабышкылар тоткан. Аның турында аңа «ат җене» кагылган дип әйтә торган булганнар. «Атлар ярату миңа әтидән күчкән», – дип яза Г. Ибраһимов үзенең истәлекләрендә. Атлар ярату, атларга мәхәббәт – һәр авыл малаена хас сыйфат. Атлы булу – һәр авыл малаеның зур хыялы һәм бәхете булган заманында. Ә хәзер ***«Алмачуар»*** хикәясеннән бер өзек тыңлагыз**.**

VIII бүлек

Өйдә табак тутырып, бәрәңге пешергәннәр. Мин эттән яман ачыкканмын. Күземә ак-кара күренмәде, каз йомыркасы зурлыгындагы бәрәңгеләрне, тозлап-тозлап, арыш икмәге белән бөгәргә тотындым.

Үзем авыз тулы көенчә бурлы бия турында туктамый һаман сөйлим.

Әнкәй бер көлә, бер ачулана:

– Сиңа, ахры, ат җене кагылгандыр, торсаң – шул, ятсаң – шул, бер белгәнең шул булды, – ди.

Мин аның белән карулашырга уйлап авызымны гына ачкан идем, түбән оч Фәхринең зур улы Сәпәр урам як тәрәзәдән баш тыкты да, ут чыккан кебек, акырып җибәрде:

– Закир! Закир! Сөенче! Бурлы бияң колынлады, – ди.

Ни эшләгәнемне белмәдем, әни, аптырап:

– Ай, бу бала харап була инде шул мал өчен! – дип кычкырып калды, мин, ашъяулыклар, табаклы бәрәңгеләр өстеннән атылып, йортка чаптым.

Әткәй бакча буенда арба төзәтеп маташа иде. Туры аңа ташландым.

– Әткәй, әткәй, әйдә тизрәк, бия колынлаган, – дип акырам.

Гажәп яратам мин әткәйне! Ул әз генә дә ачуланмады, минем сүзне ишетү белән, урыныннан торды да коймага эленгән нуктаны алды:

– Кем әйтте, сөенче бирдеңме?

Ул арада капкадан Фәхри малае Сәпәр сөенче сорап килеп керде.

Минем, каз кавырсыннары, чүпрәкләр сатып, сөенчегә дип әзерләнгән алты тиен акчам бар иде. Карап та тормадым, яшергән җирдән тиз генә алдым да Фәхри малаена китереп тоттырдым.

Без әткәй белән Өзән елга буена колынны алырга киттек.

IX бүлек

Шәп маллар аякланып туа, диләр.

Ахрысы, бу сүз дөрестер.

Без барып җиткәндә, колын үзенең әле бик ныгып бетә алмаган нечкә аяклары белән саклана-саклана басып йөри башлаган иде инде.

Бичаракаем, бик ачыгып туган, күрәсең: әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып, әнкәсенең сөт белән тулып каткан имчәкләрен суырып азаплана.

Бу арада бурлы бия бик артык холыксызланып киткәнгә, мин аның янына барырга курыктым. Үзенең нуктасы белән аңа якын килә башлагач та, ул, баласын бирмәскә тырышкан ана арыслан кебек, әллә нинди яшел тавыш белән чинап, әткәй өстенә ташланмакчы булды. Йомылып тешләргә, чыелдап, колынының әле бер, әле икенче ягында йөгереп тибәргә итеп карады.

Ләкин безнең әткәй курку дигәннең нәрсә икәнен белми, маллар да аның болай икәнен аңлыйлар булса кирәк. Биянең дулавына – тешләргә, тибәргә омтылуына карамастан, әткәй туры барды да муенына нуктаны ташлады, алай-болай иткәнче, бурлы биянең башы калын нукта эченә кереп тә өлгерде. Мин аптырап, хәйран булып тик тордым. Шатландыммы, юкмы – белмим.

Тик өйгә алып кайтып, бияне кое баганасына бәйләп куйгач кына, мин үз-үземә исәп бирә алырлык булдым.

Колын чыннан гаҗәеп бер нәрсә иде: аның ботлары ничектер җиңел атлыйлар. Бәкәлләре озын, шундый нечкә озын ки, мондыйлар тик чабышкы атларда гына була, диләр. Әле яңа гына кибеп килә торган койрыгы белән ялы, әз генә, кыска гына булсалар да, озаклап үреп, кабартып ясаган ефәк бәйләме кебек, үзеннән-үзе дулкынланып торалар. Түм-түгәрәк сырты өстеннән, нәкъ арка үзәк турыннан, бармак калынлыгы кара

тасма кебек булып, койрыктан ялга җиткәнче, кара ефәк йон сузылган. Озынча, акыллы башның киң маңгаендагы озын яра кашка – бу колынны мең миллион иптәшләре арасыннан бөтенләй аерып, матурлыгы белән ялгыз дип күрсәтәләр. Бөтен гәүдәсе, әйтерсең, Ходайның үз кулы белән, фирештәләрнең ярдәме белән тигезләп, матур итеп, коелып ясалган. Шундый... сылу, шундый асыл сөяк булып яратылганнар.

Төсе хакында аптырап калдым. Кара түгел, күк дип тә булмый. Анасы кебек саф бурлы да түгел – ничектер, күгелҗем ак чәчәк төсе кебегрәк булып ялтырап тора.

8. Балалар язучысы Абдулла Алиш

Балалар язучысы диюгә, иң беренче булып Абдулла Алиш исеме телгә килә, аның «Сертотмас үрдәк» әкияте искә төшә! А. Алиш – балаларның яраткан язучысы, хикәяләр һәм әкиятләр остасы.

А. Алиш кечкенәдән зирәк һәм зиһенле бала булып үсә. Әтиәнисе дә – укымышлы кешеләр. Әнисе Газизә апа әдәбиятны бик яраткан, бәетләр һәм шигырьләр чыгарырга оста булган. Башлангыч белемне үз авылларында ала. Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, А. Алиш Казанга килә һәм Казан җир төзү техникумына укырга керә. Мәктәптә укыган елларында ук ижади сәләткә ия малай бик күп җәмәгать эшләре башкара, концерт-спектакльләр оештыруда башлап йөри, стена газеталары, кулъязма журналлар чыгара, шигырь-хикәяләр яза. Техникумда укый башлагач, аның әдәбият белән кызыксынуы тагын да көчәя. 1929 елда «Яшь ленинчы» газетасында аның беренче хикәясе басылып чыга. «Әти, эчмә!» дип атала ул хикәя. Алга таба пионерлар тормышы, аларның җәмгыятькә файдалы хезмәттә катнашулары, күңелле ял итүләре турында хикәяләр ижат итә. 1937 елдан 1941 елга кадәр «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналы редакциясендә һәм Татарстан радиокомитетында эшли. Бу еллар – язучы ижатының иң актив чоры. Ул балалар өчен хикәяләр җыентыгы чыгара, пьесалар яза (шагыйрь һәм язучы Әхмәт Фәйзи белән берлектә), «Якты күл буе» исемле повесть бастырып чыгара. Әмма аны балалар язучысы дәрәҗәсенә күтәргән жанр – әкиятләр икән! Беренче

әкияте «Капкорсак патша» дип атала. Ул 1934 елны «Пионер каләме» журналында басыла. Ул чор балалары әсәрне ябырылып укый. 1935–1940 елларда А. Алиш балалар өчен егермедән артык әкият иҗат итә. А. Алишның әкиятләре укырга рәхәт. Үзләре җыйнак, кызыклы, образлы тел белән язылган. Рифмалы җөмләләр әкиятләрне тизрәк истә калдырырга ярдәм итә, балаларның кызыксынуын көчәйтә. Менә аның «Нечкәбил» әкиятеннән бер өзек тыңлап карагыз әле: «Каршыгызда менә, күрәсезме, нәрсә соң ул, беләсезме? Шашка шакмаклары төсле тезелеп киткән йортлар. Ул йортларда яшиләр кортлар. Кортлар? Нинди кортлар? Татлыдан-татлы бал җыялар, шәмгә яраклы балавыз коялар. Ерак-ерак җирләргә очып китәләр. Укларын кадасалар, еларлык итәләр».

А. Алишның үзенең дә ике улы: Алмаз белән Айваз үсә. Ул улларын бик яраткан. Улларын, аның кебек башка балаларны да күздә тотып язган ул әкият-хикәяләрен.

Бөек Ватан сугышы башлангач, 1941 елның июль аенда А. Алиш фронтка китә. 1941 елның октябрендә Брянск шәһәре янында, Десна елгасы буенда чолганышта калып, фашистлар кулына әсирлеккә төшә. Берничә лагерьда булганнан соң, Алиш Берлин янындагы Вустрауга килеп эләгә. Монда Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән очраша, алар балән бергә антифашистик оешмада фашистларга каршы көрәшә. 1943 елда яшерен оешманың эше ачылып, А. Алиш һәм башка җәлилчеләр кулга алынып, үлем җәзасына хөкем ителә. 1944 елның 25 августында җәлилчеләр белән бергә җәзалап үтерелә. Бу вакытта аңа нибары 36 яшь була!

Ә хәзер балалар, Алиш абыегызның «Бик яхшы сабак алды ябалак» хикәясен тыңлагыз.

Бик яхшы сабак алды ябалак

Зәп-зәңгәр күк итәгенә барып тоташкан, очы-кырые күренмәгән бер кара урман бар. Ул урманда яшел киемле агачлар гөрләп үсәләр, тәмле-тәмле җиләкләр кызарып пешәләр. Анда ерткыч бүреләр, хәйләкәр төлкеләр, куркак куяннар, агулы еланнар яшиләр.

Усал ерткычлар, сайраучы кошлар белән бергә, бу урманда

ике ябалак та тора. Төскә алар тавык төсле матур, ә башлары аларның песи башына бик охшый. Күзләре коточкыч зур булсалар да, көндезләрен күрмиләр, шуңа күрә алар ауга да төннәрен генә йөриләр.

Кичләрен кошлар сайраудан тынгач, ерткычлар йоклагач, урман эчен мәче мыраулаган, бала елаган тавышлар каплап ала. Бу тавышка кошлар томшыкларын, ерткычлар борыннарын күтәреп йокыдан уяналар: «Рәхәтләнеп йокларга да ирек бирмиләр!» – дип, ябалаклардан зарланалар.

Бер төнне шулай ябалаклар, балаларын ияртеп, ауга киткәннәр.

Ана Ябалак балаларына шушы сүзләрне әйткән:

– Улларым, кызларым, берүк сүземне тыңлагыз. Бер-берегездән аерыласы булмагыз, көндезгә калмагыз! – дигән.

Балаларның арасында бик шугы: «Тукта әле, әни сүзен тыңламасам, ни булыр икән?» – дигән, туганнарыннан аерылып, бер якка карап очып киткән. Ә тегеләр моны югалткаННар, аның өчен бик кайгырышканнар. Эзли-эзли йөдәп беткәннәр, таң тугач, өйләренә кайтып киткәннәр. Кайтсалар, теге шаян өйләрендә дә юк икән. «Улым харап булды, улым харап булды», – дип, Ана Ябалак мескен өзгәләнә икән. Бала ябалаклар да бик кайгырышканнар, елашканнар.

Ә теге шаян бу вакыт аяк бармаклары белән агач ботагына ныК ябышкан, кая барырга белми аптырап тик утыра икән.

Беренче булып аны Тиен күргән:

– Минем агачымда нишләп болай кукраеп утырасың? – дигән.

– Тиенкәй – изгекәй, мине кума инде, бик азга булса да, чыда инде, кич булуга китәрмен, сиңа мең-мең рәхмәтләр әйтермен, – дигән Бала Ябалак.

Ләкин Тиен аның сүзләрен тыңламаган, ялваруларына колак салмаган.

– Әниең сүзен тыңламагансың, менә шушы хәлгә калгансың, үзеңә үпкәлә, андыйларга минем агачта кунак булырга рөхсәт юк, – дип, Ябалак кунаклаган ботакны селкеткән. Мескен Ябалак, ботакларны кабалап-кабалап, башка агачка күчкән. Ләкин кошлар аны бу агачтан да куганнар, хәзер үк күзләреннән югалырга кушканнар. Кайгысыннан Ябалак оны-

тып киткән. Төн дип белеп очып та киткән, канатларын ботакларга бәреп бетергән һәм җиргә килеп төшкән. Ә хәйләкәр төлкегә шул гына кирәк тә булган, ул аны байтактан бирле сагалап йөри икән.

Төлке аны әз генә эләктермәгән, теге шаян очып өлгергән, ләкин агач ботагына бик каты килеп бәрелгән. Төлкенең авызында каурыйлар гына калган.

Ябалак ничек кирәк алай көнне уздырган. Менә зарыгып көткән кич тә җиткән. Әнисенең әйткән сүзләре шаян Ябалакның исенә төшкән, ул, мескен, елый-елый арып беткән.

Әнисе белән әтисе шук баланы эзләп тапканнар. Ә адашкан Ябалак баласы өйгә кайтып керүе шатлыгыннан елап җибәргән: «Инде һәрвакыт әти-әни сүзен тыңлармын», – дигән.

Менә шулай шук Ябалак алган бик яхшы сабак.

9. Абдулла Алиш. «Куян кызы»

Бер соры куянның үзе төсле зур колаклы, бик иркә, бик кадерле бер кызы булган. Ул аны бик-бик ярата икән.

Көннәрдән бер көнне куян иркә кызына өр-яңа киез итекләр алып кайтып биргән.

– Мә, бәбкәм, аякларың туңмасын, сызламасын, – дигән.

Кызы бу бүләкне бик шатланып алган. Әнисенә рәхмәтләр укыган. Хәзер инде ул яңа киез итекләрне киеп, рәхәтләнеп йөри икән. Ләкин куян кызы җылы итекләргә өйрәнмәгән булган, ул алардан бик тиз туйган, салып ташлаган. Әнием тапмасын дип, аларны яшереп куйган. Әнисе аларны эзләп табып баласына кигезә, ә ул салып ташлый икән. Әнисе кигезсә – ул салган, әнисе тагын кигезгән, ә ул тагын салып ташлаган.

Кар өстеннән дә, боз өстеннән дә яланаяк йөгерә икән. Бер көн буе шулай йөгергән, икенче көнне дә шулай яланаяк йөргән, өченче көнне инде аксый-аксый әнисе янына килгән.

– Әни, әни, минем аягым бик авырта! – дигән. Әнисе аның аякларына караган да аптырап калган.

– Кызым, кызым, якты йолдызым, синең аягың шешкән ич, – дигән.

«Инде ни эшләргә?»– дип уйга баткан куян. «Бу баланы кая алып барырга, ничек дәваларга?» – дип кайгырган.

Шулвакыт нәрсәдер кычкырган. Куян агач башына күтәрелеп караган икән – тиенне күргән. Ул куянга болай дигән:

– Кайгырма, туганкай, йомшак куянкай, кызыңның аягын бик тиз төзәтеп була. Моның өчен «доктор Айболит»ка барырга, аңардан киңәш сорарга кирәк, – дигән.

Куянга чын-чынлап булышырга тотынган, «доктор Айболит»ның өенә үзе илтергә булган.

Куян кызын күтәргән дә «доктор Айболит»ка киткән, тиен, агачтан агачка сикереп, аңа юл өйрәткән.

Барып җитсәләр, «доктор Айболит»ның эше бик күп икән, аңа урманның төрле ерткычлары дәваланырга килгәннәр икән. «Балаларны чиратсыз карыйм мин», – дигән «доктор Айболит». Куян кызын доктор бүлмәсенә алып кергәннәр, нәрсә белән авыруын сөйләп биргәннәр. «Доктор Айболит» куян кызының аягына дарулар сөрткән һәм шул вакытта куян кызына әйткән:

– Аягың төзәлгәч, киез итекләрне инде салкын көннәрдә бер дә салма, сүзне тыңла, тагын начар хәлгә калма, – дигән.

«Доктор Айболит»ка алар бик зур рәхмәтләр әйткәннәр, саубуллашып өйләренә кайтып киткәннәр. Өч көн дигәндә, куян баласының аягы төзәлгән. Ул инде хәзер киез итеген бер дә салмый киеп йөри икән.

Ялкаулык – хурлык, тырышлык – зурлык

Чәчәкләр башлыгы бик зур ярыш үткәрергә булган. Шул турыда төрле якка хәбәр дә салган:

– Кем дә кем бал салырга яхшы савыт әзерләсә, ул савытта бал бер дә бозылмаса, әчемәсә, барлык чәчәктәге балны шуңа бирәчәкмен, – дигән.

Бөҗәкләр көнне-төнне белмәгәннәр, бар да тырышып савыт эшләгәннәр.

Күп тә үтмәгән, бөҗәкләр төрле яктан очып килгәннәр. Бар да үзләре эшләгән савытларны Чәчәк башлыгына китергәннәр.

– Менә дигән савыт, балны кара салып, – дигәннәр. Чәчәкләр башлыгы барысын да борып җибәргән:

– Ашыккансыз, ашыккансыз, бик начар ясагансыз. Мондый савытлар миңа кирәкми. Шуңа күрә бал да сезгә эләкми, – дигән.

Шөпшә белән Бал корты иң соңгылар булып эшкә керешкәннәр, беренчелекне алырга өмет иткәннәр.

Бал корты көне буе бертуктамый эшли дә эшли икән: ерак-ерак җирләргә очып бара, аллы-гөлле чәчәкләрдән бал суырып ала, аны алып кайтып, үзе әзерләгән матур күзәнәкләргә сала икән.

Шөпшә дә чәчәкләрдән бал җыйган. Ләкин ул бик-бик ялкау булган. Иртән әзрәк кенә эшли икән дә, кояш кыздыра башлагач, оясына кереп йоклый икән.

Көннәрнең берендә Шөпшә Бал кортына очраган һәм аны, өзелеп-өзелеп, кунакка чакырган:

– Кил әле, кил, мин әзерләгән бал савытын да күреп китәрсең, кайбер җирләрен төзәткәлисе бардыр, бераз ярдәм дә итәрсең, – дигән.

– Ярый, – дигән Бал корты, – барсам-барырмын, ләкин бүген миңа кереп чыгыйк, бераз күңел ачып утырыйк, – дип, Шөпшәне үз өенә алып киткән һәм бик шәпләп кунак иткән.

Шөпшә Бал корты эшләгән савытны кат-кат караган һәм аны бик-бик мактаган.

– Осталарның да остасы икәнсең, мондый шәп савытны ничек ясый алдың? – дигән.

– Серемне әйтсәм-әйтим, дус кеше бит, сиңа белгертим инде, – дигән Бал корты. – Көне-төне тырышып эшләгәч, бүгенгә эш торып торсын, ял итим әле димәгәч, бар авырлыкларны да җиңеп була икән, – дигән.

Көннәр үткән дә үткән. Бал кортының Шөпшәгә кунакка барыр вакыты да килеп җиткән.

Эштән кайтышлый, Бал корты Шөпшәнең өенә кергән, дустының хәлен белгән:

– Исәнме, Шөпшә дус, эштән соң ятып, бераз ял итәсеңме? Әллә юкса авырып торасыңмы? Бал савытларын илтер көн дә җитә бит, бик тырышып әзерләник, – дигән.

Шөпшә чалкан яткан, күзләрен акайткан. Аякларын югары сузган, мыекларын түбән салындырган. Ул:

– Сәламеңне дә алыр хәлем юк, дустым, – ди икән.

Кунакны сыйларлык түгел, туйганчы үзе ашарлык та балы юк икән. Ярты көн бал җыйса, шунда ук аны ашап бетерә дә барган. Башын шундый ялкаулыкка салган. Шуңа күрә бал савытын да эшли алмаган.

Ярыш көне килеп җиткән.

Бал корты балавыздан эшләнгән матур күзәнәкле бал савытын күтәреп очып киткән. Шөпшә дә үзенең аннан-моннан эшләнгән кәрәзен алып килгән.

Чәчәкләр башлыгы кәрәзләргә бал салып караган. Шөпшә кәрәзендә бал тормаган, ә Бал кортының кәрәзеннән акмаган.

– Тырышканнар, күп көч куйганнар, менә дигән кәрәз эшләп чыгарганнар. Шуңа күрә теләсә нинди чәчәктән теләсә никадәр бал җыярга бал кортларына рөхсәт бирәм, – дигән Чәчәкләр башлыгы.

Шул көннән башлап, бал кортлары чәчәкләрдән бал ташый башлаганнар, ә шөпшәләр ялкаулыклары аркасында хурлыкка калганнар.

10. Балалар язучысы Дәрҗия Аппакова

Татар совет балалар әдәбиятына сизелерлек өлеш керткән талантлы прозаик һәм драматург Дәрҗия Аппакова турында булыр алдагы тапшыруыбыз. Дәрҗия Сәйфулла кызы Аппакова 1898 елда Түбән Кама районының Байгол авылында ярлы крестьян гаиләсендә туган. 13 яшендә Казанга килеп, укытучылар мәктәбендә укый, балалар укыта. 1922–23 нче елларда Казан совет партия мәктәбендә укый, комсомолның Татарстан өлкә комитетында инструктор, гомумән алганда, партия-совет эшендә! 1928–43 нче елларда Д. Аппакова Урта Азиядә яши, укытучы. Хатын-кызлар арасында мәгариф-агарту эшләре белән шөгыльләнә. 1943 елны Казанга әйләнеп кайта һәм профессиональ язучы буларак иҗат эшчәнлеген дәвам итә.

Иҗат эше белән Урта Азиягә – Ташкентка киткәч ныклап шөгыльләнә башлый. 1940 елга кадәр берничә хикәя, пьеса, повесть, роман иҗат итә. 1937 елда язылган «Кечкенә Бануның тарихы» повесте аеруча нык таныла. Бу повесть тиз арада рус, татар, үзбәк, инглиз телләрендә басылып чыга.

Казанга кайткач, төп игътибарны балалар драматургиясенә юнәлтә: «Тапкыр егет», «Шүрәле», «Бишек җыры», «Илдус» пьесаларын иҗат итә. «Тапкыр егет» пьесасы 1944–46, 1974–75 нче елларда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уңыш белән бара.

Дәржия Аппакованың әсәрләре бүген дә актуальлекләрен югалтмый. Алар балаларны тәрбияле, кешелекле, әдәпле булырга өйрәтә. Ә хәзер Дәржия Аппакованың «Сөяк саплы пәке» хикәясен тәкъдим итәбез. Хикәядә бертуган өч бертуган Фәрит, Рөстәм, Заһид исемле малайлар турында сүз бара. Фәрит – беренче класста, Рөстәм икенче класста укый, ә кече энеләре Заһид балалар бакчасына йөри. Әниләре – укытучы, ә әтиләре ерак Боз диңгезендә капитан. Малайлар әтиләрен бик сагыналар, аның кайтуын көнләп түгел, сәгатьләп саныйлар. Менә беркөнне әтиләре кайтты. Малайлар аңа сорау арты сорау яудыралар – җавап биреп кенә өлгер! Көтмәгәндә әтиләре кесәсеннән бер пәке чыгара. Пәке дисәң дә пәке! Сабы фил сөягеннән көмеш белән бизәкләп эшләнгән. Озынлы-кыскалы биш корыч пычагы бар, үзе үткен. Өч малайның да теләге – их, бу пәке миңа булса иде! Элек бит пәкеле булу малайлар өчен бик зур дәрәҗә, хыял булган!

– Әйе-әйе, – ди әтиләре, – берегез бу пәкегә хуҗа булыр. Карандашларыгызны очларсыз, кораблькләр ясарсыз, планерлар. Тик урамга алып чыкмассыз пәкене. Анысы инде рөхсәт ителми, дусларым! Пәке, әтиләре юкта үзен әдәпле, гадел итеп күрсәткән малайга гына булачак. Бу турыда әниегез сөйләр, ди ул. Әниләре уллары турында өч хикәя сөйли. Беренче хикәя – Фәрит турында. Ул бер бабайга текә таудан әйберләрен аска төшерергә булыша, бабайның үзен дә чанасына утыртып алып төшә. Заһид исә балалар бакчасында бер кызның югалткан карандашын табып бирә. Ә өченче хикәя Рөстәм турында. Әнисенең сөйләве буенча, Рөстәм дә бик тәртипле, тәрбияле бала икәнен үз гамәлләре аша күрсәткән икән. Мәсәлән, әбиләренә кунакка баргач, үзен бик әдәпле тоткан. Алдына куйганны гына рәхмәт әйтеп, авызын чапылдатмыйча, карбыз суын ашъяулыкка агызмыйча гына ашаган. Әбиләреннән өйләренә кайтканда, трамвайда урындыкка җәелеп утырган һәм, җитмәсә, сызгырынып барган малайны күреп, аңа кисәтү ясый. Бер карт кешегә урын бирә.

Бүгенгә шул. Балалар, хикәянең калган өлешен киләсе тапшыруда тыңларсыз.

11. Дәржия Аппакова. «Сөяк саплы пәке»

(Ахыры)

Үзе турындагы хикәяне Рөстәм бик уңайсызланып тыңлады**.** Бер агарынды ул, бер кызарынды. Бер әнисенә карады, бер әтисенә. Әйе, әйе. Әнисе барысын да үзгәртеп сөйләде. Бөтенесен белеп торды Рөстәм, шулай да хикәяне бүлдермәде.

Әнисе бүлдермәскә кушкан иде бит.

Әнисе сөйләп бетергәч, Рөстәм нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачты... Шул вакытта кинәт әтисенең көр тавышы яңгырады.

– Бик-бик әдәпле малай булып үсәсең, Рөстәм. Шулай кирәк.

Әтисенең мактавы Рөстәм өчен тиргәгәннән дә авыр булды. Ачулансын иде, ичмасам! Җиңелрәк булыр иде. Ә мактавы...

Малайның күзләренә яшьләр тулды. Кинәт ул: «Дөрес түгел!.. Дөрес түгел!.. Түгел!» – дип кычкырды да елап җибәрде.

«Бу малайга ни булды?» дигән сыман, барысы да аңа карап аптырашып калдылар. Тик бер әниләре генә эшнең нәрсәдә икәнен аңлый иде. Ә Рөстәм һаман елый-елый сөйләвен дәвам иттерде:

– Әни! Ник син мине шулай яхшы, әдәпле итеп күрсәттең? Бабайга урын бирмәүче дә мин үзем идем бит! Мин бик зур әшәкелек эшләгәнмен бит. Мин гаепле, әнием!

Бүлмәдә тынлык урнашты. Барысы да әниләренең җавабын көттеләр. Әниләре акрын гына:

– Синең шул хикәядәге Рөстәм булуыңны күрәсем килә минем, – диде.

Әтиләре кулындагы пәкесен әйләндерә башлады. Нәрсә турында уйлана соң ул? Рөстәм бер урында басып тик тора. Башын игән. Битләре ут кебек яна. Ул да уйлана: «Начарлыкларымны кичерегез дип гафу үтенимме әллә? Ышанырлар микән? Пәкене эләктерер өчен генә димәсләр микән? Юк! Юк! Миңа тиеш түгел ул пәке!»

Кинәт әтисе сөяк саплы пәкене Рөстәмгә сузды. Малай моңа ышанырга да, ышанмаска да белмичә, аптырап калды. Аптырарсың! Әтиең синең бәхетең өчен армый-талмый эшләп йөрсен, синең турыңда көн-төн кайгыртсын, ә син монда әдәпсезләнеп йөр, әниеңне рәнҗет. Э-эх!

–

Әти, әти! Ник пәкене аңа бирдең? – диде Фәрит.

– Әйе, әйе, әти! – дип куйды Рөстәм дә. – Минем бит... Минем бит хакым юк.

– Әйе, – синең бүләк алырга хакың юк, – диде әтиләре. – Ләкин синең бер яхшылыгың өчен мин бу пәкене сиңа бирәм. Ягез әле, улларым, уйлап табыгыз! Мин Рөстәмгә нинди яхшылык өчен бүләк иттем бу пәкене?

Балалар, сез дә бу турыда уйлап карагыз әле.

12. Гадел Кутуй. «Рөстәм мажаралары»

Балалар, сез фантастик әсәрләр укырга яратасызмы? Аларны икенче төрле хыялый әсәрләр дип тә йөртәләр. Бу төргә караган «Әбүгалисина» кыйссасы» турында сәхифәбез башында әйтеп үткән идем инде. Безнең буын балалары ябырылып фантастик әсәрләр укый иде, бигрәк тә малайлар. Алар бигрәк тә фәнни-фантастик әсәрләрне яратып укыйлар иде. Кызлар да калышмый иде алардан. Чит ил язучыларыннан Жюль Верннның «Серле утрау», «Су астыннан 20 мең лье», «Капитан Грант балалары», Гэрберт Уэллсның «Вакыт машинасы», «Күзгә күренмәс кеше», Джонатан Свифтның «Гулливер мажаралары», Льюис Кэрролның «Алиса – могҗизалар илендә» һәм башка әсәрләр безнең балачак китаплары иде. Татар әдәбиятында фантастик жанрга караган әсәрләр аз дәрәҗәдә. Татар совет әдәбиятында фәнни-фантастик жанрны үстерүгә иң күп көч куйган кеше язучы Адлер Тимергалин булды. Аны «саф фантаст» язучы дип атыйлар. Сез аның әсәрләрен табып укырга тырышыгыз әле. Ә бүген без сезгә татар балалар әдәбиятына фантастик әсәр бүләк итеп калдырган фронтовик язучы Гадел Кутуй, аның атаклы «Рөстәм мажаралары» повесте турында бераз мәгълүмат биреп китәрбез. Иң әүвәл автор турында берничә сүз.

Гадел Кутуй (Гаделша Нурмөхәммәт улы) – татар совет язучысы, шагыйрь, атаклы «Тапшырылмаган хатлар» повестеның авторы. Яшәгән еллары: 1903–1945. Гадел Кутуй узган гасырның 20 нче елларында яза башлый. Шигырьләр, хикәяләр, пьесалар яза, татар илендә чыгып килүче байтак газета-журналларда мәкаләләр, фельетон, очерклары басыла. Бөек Ватан сугышы башлангач, 1942 елда фронтка китә. Авыр сугыш юллары үткән солдатка туган

якларына исән-сау кайтырга язмаган. Ул 1945 елның 15 июлендә Польшадагы Згеш шәһәре хәрби госпиталендә вафат була.

Язучы 1944 елда Казанга вакытлыча ижади командировкага кайта. Менә шул вакытта ул үзенең атаклы «Рөстәм мажаралары» повестен яза. Абага чәчәген ашап күзгә күренмәскә әйләнгән Рөстәм исемле малай, аның мажаралары турында әсәр. Ул фронтка китә, фашистларга каршы көрәшә. Расад (Рөстәм Асадуллин) исеме астында фашистларга күп зыян сала. Ә хәзер шул әсәрдән өзек тыңлагыз.

Г. Кутуй. «Рөстәм мажаралары»
(Өзек)

Кышкы кичләрнең берсе иде. Гайшә апа белән Һашим абый Академия театрына спектакль карарга киттеләр. Өйдә Рөстәм белән әби генә калдылар. Шул кичне Рөстәм яңа әкият тыңлады. Әби аны бик тәмләп, бик озын итеп сөйләде. Аның кыскача эчтәлеге менә болай иде.

Абага карап торырга бик гади үсемлек. Исе дисәң – хуш исе юк, яфрагы дисәң – яфрагы да әллә ни түгел. Ләкин шул абаганың искиткеч бер хикмәте бар. Абага чәчәк атмый, диләр. Ялганлыйлар! Ата икән! Мең вә миллион абагалар арасында бер абага очрый ди. Менә шунысы яз көне җиде төн уртасында ике-өч секундка чәчәк ата ди. Абага чәчәген өзеп, телләре астына кыстырырга өлгергән кешеләр, кеше күзенә күренмәс хәлгә киләләр ди.

Абага турындагы әкият Рөстәмнең холкын да, тормышын да бөтенләй үзгәртеп җибәрде. Ул элек тә күп укый иде, хәзер исә китапка тагын да ныграк ябышты. Укыганы – батырлар, табигать турындагы китаплар иде. Шул ук вакытта ул үзен курыкмаска да өйрәтте. Ул, өйдә япа-ялгыз калып, үзенчә күнегүләр ясады. Утларны сүндереп, сәгатьләр буе караңгыда утырды, төн карасында ишек алдына чыгып торды.

Көн артыннан көн үтте. Май ае уртасы иде. Рөстәм урманга китте. Аның кесәсендә кайралган үткен пәке, бер сызуда кабына торган чакма ташы, алдан ук агач төбенә илтеп күмелгән сохарилары һәм кружкасы бар.

Якында гына салкын чишмә бар иде. Рөстәм шунда барып, туйганчы су эчте, сохари ашады һәм агач башына менеп утырды.

Күзләре талганчы абагаларга карады. Рөстәм озак көтте, ләкин абага чәчәк атмады. Таң алдыннан ул кабат йокыга талды. Уянгач та, өйгә кайтып китәргә теләде. Абагаларны күрү аны бу уеннан туктатты. Алар аңа нидер әйтәләр, Рөстәмнән көләләр кебек тоелды. «Куркак ул, шүрләде, – диләр бугай, – курыксаң, бар, кайт, куркаклар безгә кирәкми. Бүген төнлә без чәчәк атачакбыз», – диләр сыман алар.

Рөстәм уйга калды. Ярый, кайтты, ди ул. «Ә кайда кундың?» – дип сорасалар, ничек җавап бирергә? Алдаргамы?

Төнне тыныч һәм тизрәк каршылау өчен Рөстәм йокларга ятты. Ләкин йоклыйсы килмәде. Әтисе аңа йокы алмаганда, күзләреңне йом да, йөзгә хәтле сана, дия иде. Рөстәм күзләрен йомды һәм, сузып-сузып, берәү, икәү, өчәү... дип санарга тотынды...

14. Әмирхан Еники (1909–2000)

Балалар, бүген мин сезне Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Әмирхан Еникинең тормыш һәм иҗат юлы белән кыскача гына таныштырып китәрмен. Язучының иҗат үрнәкләреннән өзекләр дә тыңларбыз.

Ә. Еники чыгышы белән Башкортстаннан. Благовар районы, Яңа Каргалы авылында туган. Балалык һәм мәктәп еллары Яңа Каргалыдан кырык чакрым ераклыктагы Дәүләкән авылында үтә. Яшьтән үк әдәбият, иҗат эше белән кызыксынган 16 яшьлек яшүсмер егет 1925 елда Казанга килә. Әкренләп, көндәлек матбугат битләрендә аның әдәби парчалары, хикәяләре күренә башлый. Әмма үзенчәлекле язучы-художник буларак, нигездә сугыш һәм сугыштан соңгы елларда формалаша. Бөек Ватан сугышының башыннан азагына кадәр катнашкан фронтовик буларак, сугыш темасы язучы иҗатында шактый урын ала. Аның «Бала», «Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә», «Ялгыз каз», «Мәк чәчәге», «Кем җырлады?» һәм тагын берничә хикәясендә дәһшәтле сугыш шартларында гади совет кешесенең рухи чыдамлыгы, ныклыгы, батырлыгы, тыйнаклыгы, туган ил өчен үзен аямыйча көрәшүе, тормышка, яшәүгә, җиңүгә, тыныч, матур киләчәккә тирән ышанычы сурәтләнә бу әсәрләрдә.

Ә. Еники 1953 елдан профессиональ язучы, ягъни әдәби иҗат белән генә шөгыльләнә башлый. Мәктәп программаларына язучының «Бала», «Кем җырлады?», «Әйтелмәгән васыять», «Матурлык», «Курай» кебек хикәя-повестьлары кертелә иде элек. Бу әсәрләр олылар күңелен генә түгел, балалар күңелен дә дулкынландыра торган әсәрләр. Үзем укыткан еллар исемә төшеп китте әле. Җиденче класста «Әйтелмәгән васыять»не укыган вакытта балаларның күбесе күз яшьләрен тыя алмыйлар иде. «Матурлык» хикәясеннән соң балалар уйчанланып калалар иде. Укучыны шундый халәткә китерү язучының зур, оста психолог булуын расламыймы?

Балалар, ә хәзер Ә. Еникинең «Матурлык» хикәясеннән бер өзек тыңлагыз.

...Аны күреп беренче чиркану һәм кызгану тойгысын кичергәч тә, күңелгә иң башлап шундый уй килде: ничек итеп Бәдретдин бу бәхетсез әнисен чакырып алырга һәм безгә күрсәтергә җөрьәт итте икән?.. Без бит, гадәттә, кешене куркытырлык ямьсез яки гарип туганнарыбызны ятлар күзенә күрсәтмәскә тырышабыз. Хәтта әниебезне дә, әгәр ул менә шушындый булса, үзебез чакырып алып күрсәтергә кыймас идек, уңайсызланыр идек, оялыр идек. Бәдретдин бу кыен хәлне бөтенләй күрми, аңламый микәнни? Әллә күрсә, аңласа да бик тирән яшерә беләме?

Ә җиңги шул арада чынаякларга чәй ясап, йөзен самовар артына яшерә төшеп, безгә сузды. Без башларны күтәрмичә генә, сүзсез генә чәебезне эчәргә тотындык. Бәдретдин безне кыстап:

– Йәгез әле, шәрикләр, ни бары белән ашап кына эчегез, ашап кына! – диде, һәм аның тавышында мин көткән уңайсызлану яки оялу ник кенә бер ишетелсә иде!

Йомырка тәбәсен капкалап, икешәр чынаяк чәй эчкәч, без чәшкеләребезне капладык. Бәдретдин, сыеның ярлылыгыннан булса кирәк, үзалдына, сиздермәскә тырышып кына, бер сулап куйды. Аннары кисәк кенә аягүрә басты да:

– Минем бит әле сезгә, шәрикләр, тагын бер күрсәтәсе нәрсәм бар, – диде Бәдретдин һәм, яңадан торып, шүрлектән кечкенә генә скрипкә алды. Бу кулдан гына ясалган, буялмаган, хөрти генә бер скрипкә иде.

Без гаҗәпләнеп сорадык:

– Кайдан бу синдә?

– Үзем мәтәштергән булдым инде, – диде Бәдретдин һәм скрипкәнең тоник кына тавыш чыгарган кылларын көйләргә тотынды. Аның кубыз уйнавын, мандолина чирткәләвен без белә идек. Әмма скрипкә!..

– Әй, Бәдри, нигә моңарчы яшердең? – дидек без. – Мәдрәсәдә Сәгыйть скрипкәсен алып, үзеңнән уйнаткан булыр идек бит!

– Оста барда кулың тый! – диде Бәдретдин, тыйнак кына елмаеп.

Ул айлар буе кул тимичә яткан скрипкәсен шактый озак азапланып көйләде. Шул чакта мин аның әнисенә күтәрелеп карадым: ана үзенең шәкерт улына шундый бер бәгырьгә төшәрлек тирән мәхәббәт белән, бәхет-сөенеч белән сихерләнеп, эреп, мөкиббән китеп карап утыра иде ки, мин хәтта йөрәгем-тәнем белән әллә ничек тетрәнеп куйгандай булдым. Аңлыйсызмы, күз алдыгызга китерә аласызмы – гүя бу зураеп ачылган сыңар күздәге өнсез карашта, бер адәм затына гына түгел, бөтен җан иясенә хас ниндидер менә үзе эшләгән могҗизага таң калу һәм шуңа чиксез куану, шуның белән әйтеп бетергесез горурлану ап-ачык чагылып тора иде: ул тапкан бит бу баланы! Ул имезгән бит аңа күкрәк сөтен! Ул шушы сөлек кебек егетнең әнисе бит! Шәкерт әнисе, гыйлем иясе булачак кешенең әнисе... Ихтыярсыздан йөрәгем үкси башлап, мин тизрәк башымны түбән идем.

Бәдретдин, маташа торгач, ахырда скрипкәсен көйләде, иңбашына терәде, җәя сыман смычогы белән сызгаларга тотынды. Скрипкәнең тавышы бик зәгыйфь иде, чеби тавышыдай көчсез-нечкә иде, ләкин бу минутта безнең күңелләргә ул да бик ягымлы, бик тансык иде. Бәдретдиннең уйнавын барыбыз да шылт та итмичә, тып-тын калып тыңлап утырдык. Бу ярлы өйнең һавасында ук ниндидер бер авыр сагышлы моң – мәңгелек моң йөзә кебек иде. Текә генә катып утырган ап-ак бабай ни уйлый, бүкәне өстеннән бер генә дә кузгалмаган абзый кеше ни кичерә – моны белүе һич мөмкин түгел иде. Тик шушы моң эчендә, томан аша караган тулы ай төсле, Бәдретдиннең әнисе үзенең сүзсез шатлыгы белән яктырып

утыра. Нинди язмышлар бәйләгән бу кешеләрне, нинди серләр саклана алар арасында?

Бер-ике көй уйнагач, Бәдретдин, ниһаять, әнисенә дәште:

– Әнкәй, сиңа нәрсә уйныйм?

Әнисе бер мәлгә балаларча кызарып, шул ук вакытта куанычыннан тагы да балкыбрак китте, ләкин кайтарып сүз әйтә алмады.

– Әнкәй, син шушы көйне ярата идең бит! – диде Бәдретдин һәм «Салкын чишмә»не уйный башлады. Аның сүзләре, сүзләреннән дә бигрәк, шулкадәр гади, табигый, җылы-якын итеп дәшүе минем соңгы шикләремне дә чәлпәрәмә китерде. Әнисе өчен уңайсызлану дигән нәрсәнең әсәре дә юк икән Бәдретдиндә!.. Кайда ул уңайсызлану! Берәүне дә күрмичә, бары әнисенә, әнисенең әнә шул башта безне чирканырга мәҗбүр иткән шадра, чалыш, акайган күзле йөзенә генә карап, ул скрипкәсен уйнады. Аның бу аз гына моңсу уйчанлык, яшерен генә кызгану белән өртелгән җитди-җылы карашында, әнисен өзелеп ярату гына түгел, аны беткәнче аңлау, кадерләү, юату сизелеп тора кебек иде. Белмим, болай карый алыр өчен күңелләрдә нинди генә тирән мәхәббәт дәрьясы ятарга тиештер инде?! Әллә бу шулай бик ямьсез ана белән бик матур бала яки, киресенчә, бик матур ана белән бик ямьсез бала арасында гына буламы икән? Соңгысы, ихтимал, еш очрый торгандыр, әмма беренчесен ишеткән дә, күргән дә юк иде.

Шулай да безгә кузгалырга вакыт иде инде. Бәдретдин уйнап туктагач, без хуҗалардан дога кылырга рөхсәт сорадык. Абзый кеше ямаулы тез бантларын ышкып куйды, ә Бәдретдин, бабасына үрелеп:

– Бабакай, шәкертләр бездән фатиха бирүебезне сорыйлар, – диде.

Бабай башын какты, һәм без кулларны күтәрдек.

...Күк алашаны җигеп, капкасыз-коймасыз, кыр үләне басып киткән «ишегалдыннан» урам уртасындагы тигез юлга чыктык. Бәдретдин һәм әтисе безне озатып, киртә буенда янәшә басып калдылар. Юк, алай гына түгел, алар белән бергә безнең артта авыл читендәге иң фәкыйрь йорт, бу йортның безгә билгесез ниндидер тирән сере – бәхетсезлегеме, фаҗигасеме, әллә без аңлаудан гаҗиз бөек бер өмете – бәхетеме – торып калды.

Кояш баюга таба борылган иде инде. Ә шулай да тургайлар, көн яктысыннан туя белмәгәндәй, тагын да биеккәрәк менеп, тагын да сузыбрак, ярсыбрак берөзлексез сайрыйлар да сайрыйлар. Дөнья киң, киң, киң, әләләләләүү! Җире-күге тын, буш, моңсу... бик моңсу миңа!.. Берни эшли алмыйм үзем белән: самовар артыннан гына улына карап утырган ана күз алдыма килә дә эчемнән тагын үкси башлыйм... Кемгәдер йодрык селкеп, кычкырасым килә: ямьсез түгел бит ул, матур бит ул, матур, матур Бәдретдиннең әнисе!

1964 ел

14. Әмирхан Еники. «Курай» хикәясе

Балалар, узган тапшыруда без ***Әмирхан Еники***нең «Матурлык» хикәясеннән өзек тыңлаган идек. Бүген мин сезгә аның ***«Курай»*** хикәясеннән бер өзек тәкъдим итәм.

Күптән түгел Сәгыйть дус миңа курай турында шушы риваятьне сөйләде:

«...Бик борынгы заманда бер хан, үсмер малайларны чакырткан һәм алардан чәчен кырдырган. Әмма чәч кырган малайларның берсен дә хан кире җибәрмәгән. Бөтенесен дә үтергән. Шулай итеп, ханның чәчен кырган күп кенә малайлар һәлак булганнар. Ни өчен хан аларны үтерткән? – моның сәбәбен берәү дә белмәгән. Менә көннәрдән беркөнне бер ялгыз хатынның бердәнбер улына да чират җиткән. Хан чәчен кырдырырга аны да чакырткан. Малай хан сараена китәр алдыннан әнисе аңа икмәк биргән: «Мә, улым, тамагың ачкач, утырып ашарсың», – дигән.

Малай сарайга киткән, хан янына кергән һәм ханның башын яхшылап кырган. Менә шул чакта ул гаҗәеп бер нәрсә күргән. Ханның башында имән бармак чаклы мөгезе бар, имеш!.. Хан шүрәле сыман мөгезле, имеш!..

Малай эшен бетергәч, хан аңа әйткән:

– Син инде минем мөгезне күрдең. Ханның мөгезе бар икән, дип сөйләрсең. Шуңа мин сине үтерәм, – дигән.

– Ярый, – дигән малай, бер дә курыкмыйча, – тик син миңа шушы икмәгемне генә ашарга рөхсәт ит, – дигән.

Хан рөхсәт иткән. Малай икмәген бик тәмләп ашаган. Аның ашавына хан бик кызыккан. Бер кисәген сораган. Малай

бераз сындырып биргән. Хан ашый башлаган. Икмәк аңа бик ошаган. Малайдан:

– Нигә бу икмәк шулхәтле тәмле? – дип сораган.

– Әнием аны үзенең күкрәк сөтенә изеп пешерде! – дип җавап биргән малай.

– Алайса без синең белән бер ананың сөтен капкан булып чыктык, без хәзер бертуганнар булабыз бит! – дигән. Малай дәшмәгән.

Ә хан уйланып:

– Бертуганны үтерергә ярамый бит әле! – дигән. – Ләкин үтертмичә дә булмый, чөнки син минем мөгезне күрдең, халыкка сөйләп йөрерсең... Инде нишләтергә сине?..

Малай бу юлы да дәшмәгән. Шуннан соң хан малайга әйткән:

– Ярар, мин сине үтертмим, – дигән. – Ләкин бер шартым бар. Кырда кура дигән бер көпшә үсә. Син аның кипкәнен чокыр башыннан табарсың. Менә шул көпшәне кисеп ал. Минем мөгез турында сөйлисең килгән саен шуңа өр... Аңладыңмы?..

Малай: «Ярый, риза», – дигән. Хан аны өенә җибәргән.

Малайның вакыт-вакыт мөгез турында бик сөйлисе килгән. Әмма ул вәгъдәсен бозмаган. Сөйлисе килгән саен шул көпшәгә өргән. Тора-бара ул көпшәнең астына тишекләр ясаган. Тишекләргә баскалап, көпшәдән нечкә-калын тавышлар чыгара башлаган. Шулай итеп, малай төрле көйләр уйнарга өйрәнгән. Хәзер ул ханның мөгезе турында сөйлисе килгәндә генә түгел, ә телдән әйтә алмаган берәр уе, хәсрәте булганда да көпшәсендә уйнаган. Искиткеч моңлы, матур уйнаган ул. Кешеләр аны таң калып тыңлаганнар. Кеше теле әйтә алмый торган хисләрне кузгатучы курай дигән гаҗәеп нәрсә әнә шулай туган, имеш!»

17. Әминә Бикчәнтәева (1913–1986)

Балалар, сезнең ***«Дәү әнием»*** шигырен ишеткәнегез яки балалар бакчасында кичәләр вакытында яттан сөйләгәнегез дә бардыр.

Әниемнең әнисе – әбием була минем.
Әби генә түгел ул, ул – минем дәү әнием.

Тәмле ашлар пешерә, матур гөлләр үстерә.
Барыбыздан олы ул, өебезнең нуры ул!

Бу шигырь юлларының авторы – балалар шагыйре Әминә апагыз Бикчәнтәева. Ул күбрәк кече яшьтәге балалар өчен язган. Шуңа күрәдер, аны «балаларның дәү әнисе» дип тә йөртәлр. 1940 елда басылып чыккан беренче җыентыгы «Бүләк» нәкъ менә кече яшьтәге балаларга адресланган була.

Ул 1913 елның 26 гыйнварында Казанда эшче гаиләсендә дөньяга килә. Урта мәктәптә җиде сыйныф һәм педагогия курсларын тәмамлый, аннан соң Казанның Бишбалта бистәсе мәктәбендә берничә ел балалар укыта. 1934–1938 елларда исә ул Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Укудан соң ул «Яшь ленинчы» газетасында әдәбият бүлеге хезмәткәре, Актаныш, Буа районы мәктәпләрендә укытучы, Татарстан радиокомитетында балалар тапшырулары мөхәррире һәм сугыштан соңгы елларда башта Яшел Үзәннең ФЗӨ мәктәбендә, аннары Казан химия заводы тулай торагында тәрбияче (1945–1947), шәһәр мәктәбендә китапханәче һәм Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә мөхәррир (1952–1955) булып эшли.

Язучы 1938 елда иҗат итә башлый. Үзе исән чагында аның 19 проза һәм шигырь китаплары басыла. Алар арасында «Шинель», «Бакча гөлләре», «Дәү әнием», «Дачада», «Беренче чәчәкләр», «Яз бүләкләре», «Әлфия алъяпкычлары», «Йөрим күл буйларында», «Фәридәкәй», «Бүген һәм иртәгә» кебек шигырьләр китаплары.

Әминә Бикчәнтәева «Ана йөрәге» (1959) һәм «Мин аңлыйм сине» (1966) повестьларын да яза. Аның кыска мәзәк хикәяләре дә бар (мәсәлән, «Хуҗа Насретдин балалар янында» (1956) хикәяләр циклы).

1983 елда аның иң уңышлы әсәрләре «Минем танышларым» җыентыгында урын ала.

Ә. Бикчәнтәева шигырьләре, җырлар.

II кисәк

1. Бари Рәхмәт (1897–1957)

Балалар, бүген мин сезне балалар шагыйре Бари Рәхмәтнең (Бари Сибгатулла улы Рәхмәтуллин) тормыш юлы, иҗаты белән таныштырып китәрмен. Тумышы белән, элекке Урал губернасы Гурьев өлкәсеннән булып, 1932 елдан гомеренең соңгы елларына кадәр, ягъни 1957 елга кадәр Казанда яшәп иҗат иткән ул.

Бөек Ватан сугышыннан соңгы татар балалар әдәбиятын Бари Рәхмәттән башка күз алдына китерүе дә кыен. Бөек Ватан сугышы әдәбият өлкәсенә дә зур югалтулар алып килде. Сугышка кадәр һәм сугыш елларында балалар өчен матур-матур шигырьләр, поэмалар, чәчмә әсәрләр иҗат иткән А. Алиш, М. Җәлил, Г. Кутуй, Ф. Кәрим, Ә. Айдар кебек язучы-шагыйрьләребез сугышта һәлак булдылар. Ә тормыш дәвам итә. Тормышыбыз дәвамчылары булган балалар турында да һич онытырга ярамый иде. Үзе дә Бөек Ватан сугышында катнашкан Бари Рәхмәт, сугыш тәмамлангач, җиң сызганып балалар әдәбиятына килә. Үзенең бай тормыш тәҗрибәсен һәм шигъри талантын яшь буынны – балаларны тәрбияләүгә багышлый. 1949 елда аның кече яшьтәге балалар өчен махсус язылган «Кем көчле?» һәм «Укыйсым килә» исемле ике китабы басылып чыга. Шуннан соң, кыска гына вакыт эчендә, ягъни 1950–57 елларда, шагыйрьнең алты җыентыгы дөнья күрә. Б. Рәхмәт тиз арада балаларның иң яратып укыла торган язучысына әверелә. «Балаларның яраткан шагыйре булып әверелү – иҗат кешесе өчен зур бәхет, – дип яза әдәбият галиме Фоат Галимуллин. – Бари Рәхмәт – бәхетле шагыйрь. Ул меңләгән укучыларның рәхмәтен тоеп яшәде һәм алар өчен иҗат итте. Ник дигәндә, ул балалар белән алар булып сөйләшә белә. Автор белән укучы арасында нинди дә булса киртә калмый, ягъни, Б. Рәхмәт – балалар өчен үз кеше», – ди галим.

Балачаклары, мәктәп еллары узган гасырның 50–60 нчы елларына туры килгән безнең буын балалары Б. Рәхмәт шигырьләрен укып, ятлап үсте. 8 нче Март кичәләрендә балалар аның «Бүген әнием бәйрәме» шигырен сөйләми калмый иде. Әнисенә чын күңеленнән булышып, аның кайтуына

өйләрен ялт итеп җыештырган, су китергән, керләр үтүкләгән, шуның өстенә яхшы укып әнисен сөендергән кыз балага сокланып карыйсың. Менә, кыз кеше шундый була ул, дип нәтиҗә дә чыгарасың. Сара, Әсма исемле кызлар да – яхшы үрнәк алырлык балалар.

Шагыйрь ялкау, вакытның кадерен белмәүче балаларны да чагып ала. Әнә – «Шундый ялкау ул» дигән шигырендәге Равил исемле малай! Йокысыннан тора алмый, үзе ялкау, ләкин ашар вакыт җиткәч: «Кая минем тәти кашыгым?» – диярга белә. Әмма ашарга утырыр алдыннан битен-кулын юарга, тешләрен чистартырга да иренә.

Песи үрти: – Мияу! Мияу! – ди. –
Һич булмаса миннән оял, – ди.
Менә мин дә юам битемне.
Ә син иренәсең, кит инде!
Актырнак та көлә: «Һау-һау!» – ди.
Их, син, Равил, Равил, ялкау ди.
Әбау, кыяфәтең, кит инде,
Ю битеңне, оят бит инде!

Сезнең арада да шундый малайлар юкмы? «Эш беткәч», «Ялкау, иренчәк һәм кире турындагы әкият» шигырьләрендә дә ялкау, гел йокы, уен турында гына уйлаган балаларның беркем тарафыннан да хөрмәтләнмәвен, ә тырыш, хезмәт сөючән балаларның, киресенчә, ихтирамга, игътибарга лаеклы икәнен, тырыш хезмәтнең яхшы нәтиҗәсен, дөньяда тик эш икән, кешене кеше иткән, дип, тормыш вакыйгалары аша күрсәтә.

Күп белергә, табигать серләрен төшенергә теләгән балаларга шагыйрь болай ди:

Сез табигатьнең серләрен, бик белергә теләсәгез,
Аны китап битләреннән, белем юлыннан эзләгез!

Телне бозып сөйләүчеләрне дә аямый шагыйрь. Мәктәп дәреслекләрендә аның «Маһирә» исемле шигыре бирелә иде элек. Х һәм һ авазларын дөрес әйтмәүче кыз турындагы шигырьне күпләр хәтерлидер әле.

– Ник алай сөйлисең, бозасың телеңне?
Нишләрсең Махирә дисәләр үзеңне? –

дип сорау да куя ул.

Илленче елларда ук телнең сафлыгы, аһәңе бозылуга бор-

чылу белдергән шагыйрь. Әмма бу күренеш хәзерге көндә дә дәвам итә.

Б. Рәхмәт балалар өчен күләмлерәк әсәрләр дә иҗат иткән. Шундыйларның берсе – «Сабан туенда» дип атала. Халкыбызның милли бәйрәме булган Сабантуй күренешләре бала хисләре аша тасвирлана.

Хөрмәтле әти-әниләр, әби-бабайлар, балалар! Б. Рәхмәт шигырьләрен эзләп табып укырга тырышыгыз әле. Ятларга, күңелдә калдырырга бик җиңел, мәгънәле һәм тәрбияви характердагы шигырьләр балаларның калебен дә чистартыр.

2. Әхмәт Фәйзи (1903–1958)

Балалар, менә бу табышмакның җавабын әйтә аласызмы? – Без-без итә, чәчәккә куна, чакса әгәр, еларлык итә. Әлбәттә, бал корты! Ә менә бу шигырь юлларын ишеткәнегез бармы? Авторы кем икән?

Чәй эчәбез бал белән, бала-чагалар белән.
Бала-чага алты җан: Әхмәт, Нәҗип, Закиржан,
Зәйнәп белән Галия, иң соңгысы Асия.
Бал, дисәң бер кими, кашык тыксаң, өч кими.
Алты кашык тыгылса, иртә тия, кич тими.
Кайвакытта һич тими.
Нигә дисәң, бал татлы, «юкәбал» дип атаклы,
Кәрәзләре сап-сары, саркып тора аслары.
Кашык белән аласың, тел өстенә саласың –
Эреп китә авызда, кара аны, сак кылан,
Ашъяулыкка тамызма!

Әйе инде, «Бал корты» шигыреннән бу юллар. Ә авторы – бөек Тукаебызга багышлап язылган атаклы «Тукай» романы авторы һәм шушы әсәре өчен, татар язучыларыннан беренче булып, 1958 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган танылган язучы, шагыйрь Әхмәт Фәйзи!

Ә. Фәйзи – күпкырлы талант иясе. Ул язучы, шагыйрь генә түгел! Берничә либретто авторы, драматург та, әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть, публицистика, киносценарийлар язу, әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә зур хезмәт куя. Юмор-сатира остасы да! Балалар әдәбиятын да читләми автор! Аның балалар өчен

язылган «Бал корты», «Ак аю», «Тискәре Ишми» кебек тезмә әсәрләре, «Аучы Мәргән белән Болан кыз әкиятен» балалар яратып укый иде. Ә аның сүзләренә иҗат ителгән «Умырзая» җыры халык күңелендә мәңгегә калыр.

Әхмәт Фәйзи 1903 елны Уфа шәһәрендә һөнәрче гаиләсендә туган. Әтисе заманы өчен шактый алдынгы карашлы кеше булган. Өенә газета-журналлар алдырган, китаплар укырга яраткан. Шулай бит ул: әти-әни китап укырга яратса, баласы да шуңа омтыла. Кечкенә Әхмәт тә китапларга тартыла. Мәдрәсәгә кергәнче үк укырга-язарга өйрәнә. Башта мәдрәсә, аннары Уфадагы рус-татар мәктәбендә һәм революциядән соң татар гимназиясендә белем ала.

Ул иҗат юлын 1916 елда Г. Тукай һәм М. Гафури поэзиясе тәэсирендә шигырьләр язудан башлаган. Мәктәптә һәм гимназиядә укыганда ук беренче өйрәнчек шигырьләрен һәм пьесалар яза. Урта мәктәпне тәмамлагач, Оренбургтагы Шәрекъ институтына укырга җибәрәләр аны. Шунда ук яшь татар язучыларының түгәрәге эшли, Ә. Фәйзи аның утырышларында актив катнаша. Шунда беренче тапкыр М. Җәлил белән очраша һәм дуслаша. 1921–22 еллардагы ачлык афәте аңа институтны тәмамларга ирек бирми. Шуннан соң аның «тормыш университетлары» башлана. Урта Азия, Донбасс, Мәскәү, Казан, Арча төбәгендә укытучы, һәвәскәр театр артисты, культура-агарту эшләрендә, матбугат һәм мәгариф системасында эшли. Ниһаять, 1931 елда Мәскәүгә килеп урнаша һәм шуннан соңгы гомерен профессиональ язучы сыйфатында башкалада яшәп уздыра. Бөек Ватан сугышы башлангач, Әдәбият институтының өченче курсында укыган җиреннән, үзе теләп фронтка китә. Волхов, Карелия, Дүртенче Украина фронтларында чыккан газеталарда хәрби корреспондент булып хезмәт итә. Ә. Фәйзи 1958 елның 11 августында вафат була.

Ә хәзер Ә. Фәйзинең «Аучы Мәргән белән Болан кыз» әкиятеннән бер өзек тыңлап китәрбез.

Көннәрдән беркөнне, Аучы Мәргән, ауда йөргәндә, кыя өстендә басып торучы бик матур болан күрә. Иңсәсендәге ук белән җәягә үрелгәнче, болан сикереп юк була. Икенче көнне дә Аучы Мәргән боланны аулый алмый. Бары тик өченче көнне генә болан белән очраша. Әмма боланны сары-чуар яшь юл-

барыс сагалап тора икән. Аучы юлбарыс белән көрәшеп, аны җиңә, боланны коткара. Ә болан дигәнең, искиткеч матур кыз булып чыга.

Шулвакыт Мәргәннең колагына җиңел генә дулкынлы көлү тавышы ишетелеп китте. «Кем көлдe?» – дип, Мәргән, аптырап, тирә-ягына карап алды. Көлү кабатланды. Һәм бу юлы Мәргән боланның көлү уңаена мөгезләре селкенгәнне күрде. Ул ихтыярсыз кулын суздыһәм чатланып үскән мөгезләрне тотып алды. Кинәт күз күрмәгән, колак ишетмәгән бер хәл булды. Мөгез боланнан җиңел генә аерылды да, Мәргәннең кулында калды. Ни күзләре белән күрсен, болан юк, аның урынында зифа буйлы, алтындай сары чәчле гүзәл бер кыз басып тора һәм әлеге сак кына ягымлы тавыш белән әкрен генә көлә иде.

– Нигә көләсең? – дип сорады, аптырап, Мәргән.

– Шатлыгымнан... – диде кыз, әллә нинди серле, ягымлы тавыш белән.

– Нинди шатлыгың бар синең?

– Мин бала вакытта, явыз Хан-баскак илебезне басып алгач, урманга качып киттем. Менә ун ел инде урманда, боланнар арасында йөреп, үзем боланга әйләндем. Мине алып кайтып, дәвалап та, өшкереп тә карадылар, файдасы булмады. Тик илебезнең иң карт кешесе, үләр алдыннан минем турыда шундый бер сүз әйтте: «Бу кыз бала яңадан адәм сыйфатына кайтсын өчен аны үзе яраткан батыр егет үлемнән коткарырга тиеш». Бүген менә шул хәл булды.

– Димәк, ул егет мин? Димәк, син мине яратасың?

– Әйе... – диде кыз, бит очлары кызарып янып китте, ул башын түбән иде. Мәргән аңа якынайды да, аның башын күкрәгенә кысып, күзләреннән үпте: «Безгә бу көннән алып, аерылу юк», – диде ул.

– Егет, син минем сөйләп бетергәнне көт. Карт, үләр алдыннан, тагын шуны әйтте: «Ләкин аларның тормышы гаять мәшәкатьле булачак. Бу мәшәкатьләрнең җимешен алар бик соң татыячаклар», – диде.

– Миндә бөтен авырлыкларны җиңәрлек көч тә, сәләт тә бар, боланым, курыкма... Шуның өстенә син миңа үзем кебек батыр ул бүләк итәрсең... Өчәүләп без әллә нинди авырлыкларны да җиңәрбез.

– Ярый ла улың үзеңә охшап батыр булса, әгәр ул миңа охшап өркәк туса?

– Юк, өркәк тумас. Өркәк булса да, мин аны батыр итеп тәрбияли белермен...

– Артын уйлап сөйлә, егет! Соңыннан миңа үпкәләмәс һәм ниятеңә үкенмәс бул!

– Үпкәләмәм һәм үкенмәм! – дип вәгъдә бирле Мәргән.

Шушы биек кыя өстендә алда булачак гаҗәеп һәм катлаулы, шатлыклы һәм зарлы тормышның чәчәге бөреләнә башлады.

3. Әхмәт Фәйзи. «Тукай» романыннан өзек

Балалар, «Тукай» романыннан «Кырлай» дип аталган икенче өлештән бер өзек тыңларбыз.

Яңа бистәдә читекче Мөхәммәтвәли абзый белән Газизә апа гаиләсендә күпмедер яшәгәч, язмыш кечкенә Габдулланы кабат Өчилегә – бабасы Зиннәтулла йортына кайтара. Зиннәтулла – Габдулланың әнисе Мәмдүдә апаның әтисе. Сигез кешедән торган, ачлы-туклы яшәүче гаиләдә Габдулланың кайтуына бик шатланмыйлар, әлбәттә. Бабасы аның кайтуына сөенми дә, көенми дә. Ә үги әби Латыйфа өчен бу хәл чүп өстенә чүмәлә була. Җае чыкса, ничек тә Габдулланы аткару уе белән яна башлый. Бераздан җай да чыга. Кырлай авылында яшәүче Сәгъди абзый яхшырак атадан калган берәр үксезне уллыкка алырга уйлый икән. Озакламый Сәгъди абзый Габдулланы Кырлайга алып китә.

Габдулла өйгә керү белән, өч олы кеше аның тирәсендә йөгереп дигәндәй йөрделәр. Зөһрә апа баздан салкын катык алып керде, каерып икмәк кисте. Нәфисә апа Габдулланы юындырып табынга утыртты. Сәгъди абзый аны, кыстый-кыстый, сыйлады.

Габдулла катыкны туйганчы ашады. Хәтта ярты телем икмәк белән җамаяк төбендә ике-өч кашыктай катыгы артып та калды. Ул ашыгып кына битен сыйпап алды да, бистәдәге гадәтенчә, калган сыныгын алып, тышка чыгып китмәкче булды. Ләкин аны кире урынына утырттылар.

– Сыныгыңны урынында ашап бетер, улым, аннан чыгарсың, – дип кисәтте аны Зөһрә апа.

– Басып ашап йөрергә ярамый, Габдулла, гөнаһ була, – диде ягымлы гына итеп Нәфисә апа.

Сәгъди абзый да икмәкне хөрмәт итәргә кирәклекне аңлатты һәм шул турыда гыйбрәтле бер хикәя дә сөйләп бирде:

– Менә мин сиңа сөйлим әле, син тыңлап тор! Әнә теге Зирекле башына өй салып утырган Күтәрмә Хәйберахман асылда Кырлай кешесе түгел. Ул монда Ябынчыдан килеп утырган. Аның бабасы Урәзмәт карт череп чыккан бай булган. Кинәт баеп киткән бу. Аны болай сөйлиләр:

– Бервакыт Урәзмәт җиргә икмәк валчыгын төшергән дә шуны эзләп-эзләп тә табалмагач, валчык тапталмасын дип, шул җирне киртәләп тора икән – ап-ак сакаллы бер карт килеп сәлам биргән. «Улым, нишлисең?» – дип сораган бу. Теге сөйләп биргән. Шуннан теге карт: «Ай, рәхмәт, улым, икмәкне бу хәтле кадерли белгәнең өчен, бай булырсың син», – дигән дә күздән югалган. Хозыр Ильяс үзе булган, күрәсең. Шуннан, син күр дә мин күр, Урәзмәт кинәт баеп киткән. Байлыгы җиде буынга җиткән. Без Хәйберахманнан сорыйбыз, кая соң ягъни, синең ата-бабадан калган дәүләтең? – Без ата бабабыздан калган байлыкның кадерен белмәдек, ди Хәйберахман, – икмәкне исраф иттек, – ди, – шуңа күрә хактәгалә безнең кулдан дәүләтне тартып алды, – ди. Менә терә сиңа! Күрдеңме?

Зөһрә апа өстәп куйды:

– Син, улым, кала җире белән үлчәмә. Анда икмәкнең кадере юк. Ашаган белми, тураган белә аны, – диде.

Бу – Габдулланың Кырлайда алган беренче сабагы булды.

Өзек: Әхмәт Фәйзи «Кечкенә Апуш», 83–85 нче битләр.

4. Ләбибә Ихсанова (1923–2010) (әдәбиятыбызның Ак апасы)

Без балачакта ярыша-ярыша әдәби китаплар укый идек. Ул вакытта телевизорлар, планшетлар, кәрәзле телефоннар юк иде шул әле. Ләкин китапларны да буш вакыт тигәндә генә укый идек. Ә авыл баласының буш вакыты да бик еш булмый иде. Мәктәптән кайтуга, сине йөз төрле хуҗалык эшләре көтеп тора. Ашыга-ашыга әти-әни кушып калдырган эшләрне, кушып кал-

дырмаганын да өстәп, эшләп куясың да, китапка капланасың. Ничек инде әле кичә генә бик көттереп синең кулыңа килеп кергән «Көмеш елга», «Җир астында җиде көн» дигән мәҗаралы китапларны укымыйча түзеп була! Элек китапның авторына бик игътибар бирми идек, нишләптер. Ни өчендер миңа бу әсәрләрне абый кеше язган кебек тоелды. Китапларны укып чыккач кына игътибар иттем: бу кыйссаларның авторы хатын-кыз икән! Ләбибә Ихсанова дип язып куелган китап тышына! Кит инде! Апа кеше шундый мәҗаралы китап язар икән!

Ләбибә Ихсанова дигән язучы апа белән читтән торып танышуым әнә шулай башланды. Алга таба мин аның «Сөйләнмәгән сер», «Космонавтлар урамы», «Тал бөгелә», «Робинзоннар лагеренда», «Саралан малайлары» кебек повесть-хикәяләрен дә кат-кат укыдым. Соңрак «Ана көндәлеге», «Гөлләр кояшка карый» повестьләрен дә яратып укыдым. Китап ахырында бирелә торган язучы турындагы кыскача мәгълүматларны укып, аның турында байтак әйбер белдем. Без яратып укыган «Көмеш елга», «Җир астында җиде көн» повестьлары буш җирдә генә барлыкка килмәгән икән! Киров өлкәсе, Нократ Аланы районының Түбән Шөн авылында туып-үскән Ләбибә исемле кыз, урта мәктәпне тәмамлагач, 1943–48 нче елларда Казан дәүләт университетының география факультетында укыган икән бит! «Үзем турында үзем» дигән истәлекләрендә язучы болай ди:

– Бу ел безгә, Казан дәүләт университетының география факультеты студентларына, шактый җитди эш йөкләтелгән иде. Сугыш беткән генә еллар, бөтен җирдә төзелешләр бара, электр энергиясе бик кирәк. Зур куәтле станцияләр салырга әле илнең көче юк, вакытлыча вак елгаларның көченнән файдалану көн тәртибенә куелган чак. Без дә 2–3 кешелек отрядларга бүленеп, Свердловск (хәзер кабат Екатеринбург) өлкәсенең төрле районнарына таралыштык. Безнең отряд Пермь өлкәсе белән чиктәш төньяк районында эшләргә тиеш булды... Бик гадел рәвештә, елганың агып чыккан чишмәсеннән башлап, койган җиренә кадәр, йөзләрчә чакрым җирне җәяүләп үтеп, аның киңлеген, тирәнлеген, агым тизлеген, елга төбенең һәм ярларының характерын, торымын торымга үлчәп, дәфтәрләребезгә теркәп бардык. Соңыннан, шул мәгълүматларга таянып, белгечләр

бу елгада электр станциясе салырга мөмкинме-юкмы икәнен тәгәенләр, ә без үзебезнең диплом эшен язарбыз.

Көннәр җылы, матур тора. Ачык һавада учак ягып пешергән ашны яшел үләнгә кырын ятып ашау, авылларга барып җитә алмаган көннәрдә черкиләр белән талаша-сугыша, урманда төн үткәрү кызык тоелды. Тирә-ягымда әле мин күрмәгән, күз алдыма да китереп карамаган, урманлы, чытырманлы, ят, күңелгә шом сала торган кыргый табигать!

Үзен романтик китаплардагы геройларның берсе кебек хис итеп, яшь кыз шигырь яза. Әмма хисләр, алган тәэсирләрнең шигырь юлларына гына сыймаячагын аңлаган кыз, проза язып карарга була. «Исеме дә телдән сикереп төшәргә тора бит хәерсезнең: Көмеш елга! Шулай дип атармын, шушы елга буенда йөрибез ләбаса!» – ди автор. Шулай итеп 1948 елда «Көмеш елга» повесте басылып та чыга. Туган табигать, аның байлыклары һәм шул байлыкларны өйрәнүче геологларга ияреп сәяхәткә чыккан Зөфәр исемле үсмер малайның мавыктыргыч маҗаралары турында сөйли бу повесть. Әсәр, басылып чыгу белән, балаларның кулдан төшерми укый торган китабына әйләнә. Әлеге повесте аны өметле язучы итеп таныта һәм Ләбибә апа Ихсанова алга таба үзен тулысынча әдәби иҗатка һәм журналистикага багышлый. Л. Ихсанова – өч дистәдән артык китап авторы. Алар һәммәсе дә диярлек яшь буынга багышланган.

«Л. Ихсанова – Гайдар һәм Алиш традицияләрен дәвам итүче язучыларның берсе. Ихсанова татар балалар әдәбиятына **сәяхәтләр жанры** алып килде», – дигән язучы Гариф Ахунов. Роберт Миңнуллин исә аны «әдәбиятыбызның Ак апасы» дип атый.

Л. Ихсанова – Татарстан һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге әдәби бүләге лауреаты.

Ә хәзер Ләбибә Ихсанованың «Көмеш елга» повестеннан бер өзек тыңлагыз. (Л. Ихсанова, 2 том, 10 нчы б., 2011).

5. Л. Ихсанова. «Җир астында җиде көн»

«Көмеш елга» повестеннан соң, озак та үтми, 1949 елда Л. Ихсанованың «Җир астында җиде көн» повесть-хикәясе дөнья күрә. Гөлбакчага тиң Текә яр авылы балалары үзләренең туган авыллары, аның искиткеч матур табигате, тирә-якка данлыклы Зәңгәр күлләре белән чиксез горурланалар һәм аларны бик яраталар. Үзе мул сулы, әмма серле Зәңгәр күл география түгәрәге членнары һәм түгәрәк җитәкчесе география укытучысы Кадыйр абыйларына һич тынгылык бирми. «Зәңгәр күлнең серенә төшенмичә ярамый безгә, – ди ул. – Укулар бетүгә, җир асты суларының юлларын эзләп карарга уйлыйм. Сез миңа булышырсызмы, укучылар?» – ди Кадыйр абыйлары түгәрәк членнарына. Мондый тәкъдимнән баш тартамы соң малайлар! Инде алар кыш буе түгәрәктә шөгыльләнеп, бик күп белем тупладылар. Җирлекнең планын сыза беләләр, күзләрен бәйләп, карурман уртасына илтеп ташласалар да, карта һәм компас ярдәмендә аннан чыга беләләр. Бу тирәдә җир асты куышлары да бар ди. Хәтта алар турында шактый гына кызыклы риваятьләр дә йөри халык телендә. Бер көнне Кадыйр абыйлары Казаннан таушалып беткән бер дәфтәр алып кайта.

Бу дәфтәр 20 нче гасыр башларында язылган була. Дәфтәр хуҗасы – Сергей Павлович Павлов дигән галим һәм революционер. Патша хөкүмәте аны бу якларга сөргенгә сөргән була. Менә шушы кеше Текә яр авылы тирәләрендә җир асты куышлыклары барлыгын белеп, шуларны өйрәнгән булган. Күргәннәрен дәфтәргә теркәп барган. Биредә җир асты куышлыкларының бик күп төрле формаларын очратырга мөмкин икәнлеген әйткән. Әлеге дәфтәрдәге язмалар түгәрәк членнары өчен зур ачыш-вакыйга була. Их, күрәсе иде шул җир асты куышлыкларын!

География түгәрәгенең иң актив членнары булган Шәүкәт белән Хәмиткә җир асты куышлыкларында җиде көн йөрергә, күп кенә мажараларга юлыгырга туры килә. Көчле ихтыяр, авырлыклар алдында югалып калмау аркасында, алган белемнәренең ярдәме белән чыгу юлын табалар алар. Чын дуслыкның әллә нинди авыр очракларны да жиңеп чыгарга ярдәм итүен дә аңлыйсың бу әсәрне укыгач.

Бу әсәрне укып, сез табигать белеме һәм география фәненнән белемнәрегезне тулыландырып кына калмассыз, бәлки,

узган гасыр урталарында яшәгән сезнең яшьтәге балаларның тормышларын, дөньяга карашларын, белемгә омтылышларын, нәрсә турында хыялланып яшәгәннәрен, чын дуслык, иптәшлекнең нинди булуын да белерсез. Укырга тырышыгыз бу повестьне! Гомумән, Ләбибә Ихсановның барлык әсәрләрен дә укырга тәкъдим итәм. Үкенмәссез!

Әсәрдән өзек.

6. Роза Хафизова (1929–2005)

Курай-малай, Кирлемәнле
Иттең әдәбиятны.
Ләбиб Лерон.

Балалар, бүгенге тапшыруыбыз балалар язучысы, 25 елга якын «Ялкын» журналы редакторы булган, балалар өчен генә түгел, олыларга атап язылган берничә хикәя-повестьлар авторы Роза Хафизова турында булыр. Заманында үзем дә аның «Тантаналы вәгъдә», «Кашкарыйлар озын гомерле», «Без әле кайтырбыз», «Мәхәббәт бар ул», «Киек каз юлы», «Карурманда ниләр булмас» кебек әсәрләрен яратып, кат-кат укыган идем. Шулай да, Роза Хафизова – үзенең әдәби иҗатын тулысынча балаларга багышлаган язучыларның берсе. Аның әсәрләре җиңел укыла, мавыктыргыч. Язучы әсәрләрендә балаларны хезмәт сөючән, эти-әни, өлкәннәргә карата ихтирамлы булырга, әхлаклы, гадел булырга өнди, тормышчан образлар белән бу төшенчәләрне укучы күңеленә сеңдерергә тырыша.

Р. Хафизова 1929 елның 6 февралендә Татарстан Республикасының Бөгелмә шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туган. Татарстанның хәзерге Лениногорск районы, Сарабиккол авылында 7 еллык, ә Иске Шөгер урта мәктәбендә унынчы классны тәмамлый. Алга таба укуын Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә дәвам итә. 1951–52 елда, югары белемле татар теле укытучысы буларак, эшчәнлеген Төмән өлкәсенең Тобол шәһәрендәге татар урта мәктәбендә дәвам итә. 1952 елда Казанга әйләнеп кайта һәм шуннан соң хезмәт юлын журналистика һәм язучылык эшчәнлеге белән бәйли. Аның кечкенәләр өчен әкиятләр һәм тәрбияви эчтәлекле хикәяләре тупланган «Кыңгыраулар җыры» исемле беренче китабы 1967 елда басылып чыга. Р. Хафизова – егермедән артык китап ав-

торы. Аның аерым хикәяләре элеккеге СССРда яшәгән милли телләргә дә тәрҗемә ителгән. «Курай – малай мажаралары» исә үзбәк, казак, украин телләрендә аерым китап булып чыккан.

Журналист Нәсимә Әхмәтҗанова язучы иҗаты турында болай ди: «Роза Хафизова чордашларының күңел бакчасына матурлыкка юл күрсәтүче китаплары белән килеп керде. Аның хыялы тудырган күпсанлы образлар балаларның да, яшьләрнең дә, өлкәннәрнең дә ышанычлы дусларына нинди булырга, ничек яшәргә өйрәтүче юмарт күңелле киңәшчеләренә әверелделәр».

Язучының 1969 елда иҗат ителгән «Курай-малай мажаралары» дигән әкият-повесте турында берничә сүз. Әкият берничә сәяхәттән тора. Курай-малай һәм Талсылу кыйссасы кече яшьтәге балалар өчен язылган. Бу геройлар нинди генә мажараларга юлыкмыйлар, кайларда гына булмыйлар! Әти-әниләр игътибарына! Роза Хафизованың 1991 елда басылып чыккан «Ак тәпи нигә моңая?» җыентыгына бу әсәр кергән.

Ә хәзер әлеге әкияттән бер өзек тыңлагыз.

Өзек: 4–6 нчы битләр.

7. Р. Хафизова. «Кирлемән»

Язучының бакча балалары һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен атап язылган тагын бер әкият-повесте бар. Ул «Кирлемән» дип атала.

Роза Хафизованың әлеге әсәре турында каләмдәшләренең фикерләрен тыңлап китик әле. Балалар язучысы Җәвад Тәрҗеманов менә нәрсә дигән: «Кирлемән» – язучының иң матур әкияте. Биредә аның әкият язу осталыгы күпкырлы булып һәм бөтен тулылыгы белән ачыла». Журналист Эльмира Закирова: «Астрид Линдгренның – Карлсоны, Алексей Толстойның – Буратиносы, Джим Барриның Питр Пэны булган кебек, Роза Хафизованың да Кирлемәне бар».

Киреләнергә яратучы балалар бармы сезнең арада? Менә шундыйларның дусты инде ул Кирлемән. Ул синең белән бер дуслашып алса, аннан тиз генә котыла алмыйсың. Ләкин котылу юллары бар. Нинди юллар икән ул? Монысын әсәрнең үзен укып белерсез. Әйдәгез әле шул әсәрдән бер өзек тыңлап китик.

«Актәпи нигә моңая?» – 111–116 нчы битләр.

8. Татар балалар әдәбиятының әйдәманы – Шәүкәт Галиев (1928–2011)

Бүген без сезнең белән Апас районының Олы Бакырчы авылында туып-үскән Татарстанның Халык шагыйре Шәүкәт Галиев иҗаты, аның татар балалар әдәбиятына керткән өлеше турында сөйләшербез.

Татар балалар әдәбияты дип әйтүгә, күз алдына үзеннән-үзе көләч йөзле, шат күңелле Шәүкәт Галиев килеп баса. Күңелгә бер-бер артлы аның шигырь юллары килә, күз алдыннан Камыршасы, Шәвәлие, Котбетдине йөгереп үтә.

Ш. Галиев – татар балалар әдәбияты үсешенә иң зур өлеш керткән, аның дәрәҗәсен күтәргән шагыйрь.

Ш. Галиевнең балалар әдәбияты өлкәсендәге эшчәнлеге югары бәяләнде. 1972 елда татар балалар язучыларыннан беренче буларак, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде. 1980 елда рус теленә тәрҗемәдә чыккан «Заяц на зарядке» («Куян күнегүләр ясый») китабы өчен, 1982 елгы Халыкара бүләк – Г.Х. Андерсен исемендәге дәрәҗәле диплом белән бүләкләнде. Шулай ук ул А.П. Гайдар билгесе (1984), Татарстан Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге әдәби бүләк иясе дә. Ә 1995 елда татар әдәбиятын үстерүдәге казанышлары өчен «Татарстан Республикасының Халык шагыйре» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Ш. Галиев исеме матбугатта беренче тапкыр 1948 елда күренә башлый. Беренче шигырьләр җыентыгы исә, узган гасырның илленче елларында басылып чыга. Шагыйрь алтмышынчы еллар башына кадәр зурлар өчен яза. Үзен юмор-сатира остасы итеп тә таныта. Аның шигырьләренә җырлар да иҗат ителә. «Раушаниям-бәгърем», «Тамчылар тамар чаклар», «Шалт, Мөхәммәтҗан», «Сөенечкә дисәм», «Утыр әле яннарыма», «Күпме күзләр күреп онытылган», «Көлегез» кебек җырлары халык күңеленә тирән үтеп кереп, бүген дә җырлана. «Кыңгыраулы мәктәп еллары» исә күпме буын чыгарылыш класс укучыларын зур тормыш юлына озатып калды.

1962 елда аның балаларга махсус атап язган шигырьләре тупланган «Камырша» исемле беренче җыентыгы басылып чыга. Шушы җыентык уңаеннан, әдәбиятыбызның аксакалы –

шагыйрь Сибгат Хәким болай дигән: «Тукайдан соң, Бари Рәхмәтләрдән соң туган бушлык бетте!»

Балалар шагыйре Р. Миңнуллинның да фикерен тыңлап китик әле: «Шәүкәт Галиев килүгә, безнең балалар әдәбияты шигърияте планкасы кинәт кенә югары күтәрелде. Шагыйрь татар әдәбиятының алтын хәзинәсен үзенең күпсанлы шигъри җәүһәрләре белән генә баетып калмады, балалар поэзиясендә үзенең шигъри мәктәбен дә тудырды».

«Камырша»дан соң, әдипнең балалар өчен өч дистәдән артык китабы дөнья күрә. Бу китапларда шагыйрь фантазиясе тудырган гаҗәеп дөнья – яңа теле ачылган нәниләрдән алып, мәктәп яшендәге кыз-малайларның күпкырлы һәм кызыклы тормышы сурәтләнә. Юмор катыш җор-йөгерек тел, шигъри тапкырлык һәм фантазия, балаларны ярату, аларга карата ышаныч һәм хөрмәт хас аның әсәрләренә. Аның шигырьләре кешелеклелек, туган халкына, туган теленә тугрылыклык, табигатькә һәм хезмәткә мәхәббәт хисләре белән сугарылган.

Ш. Галиевнең берничә шигырен тыңлыйк. «Камырша»...

9. Ш. Галиев иҗаты. Шәвәли кем малае?

«Сабыйга» тапшыруын яратып тыңлаучы дусларым, бүген дә балалар әдибе Ш. Галиев, аның иҗаты турында сөйләшүебезне дәвам итәрбез. Чөнки бер тапшыруда гына аның иҗаты турында сөйләп бетереп булмый, чөнки аның әдәби мирасы шактый. Аның иҗаты турында уннарча тапшыру әзерләргә мөмкин.

Ш. Галиев шигырьләрендә балалар теле белән сөйли. Аның геройлары, бигрәк тә нәниләр үтә кызыксынучан, күзәтүчән, күпне белергә телиләр. Туктаусыз «ник? нигә? ни өчен?» сораулары белән өлкәннәрне аптыраталар.

Безнең сыер көн дә кырдан чүлмәк-чүлмәк сөт ташый.
«Ул бит яшел үлән ашый, сөтне ничек ак ясый?» –

ди бер нәни бала.

Тавык фермасындагы апаларның, тавыкларга витаминлы азык бирүләрен күргән бала өчен тагын сорау туа:

Күкәйне мин дә яратам. Күкәй бит ул бик тәмле.
Тавык китап укымый ла! Ничек белә ул фәнне?
Туктаусыз сорау бирүнең дә хикмәте бар икән.
– Гел-гел улым, Шәвәли, сорау бирәсең нигә?
– Үсеп җиткәч, синең күк җавап бирәсем килә.

Әйе, балалар әдәбияты дигәндә – Ш. Галиев, ә Ш. Галиев дигәндә, башына кәләпүш кигән, бер күзен кысып елмайган шат күңелле малай – Шәвәли килеп баса. Әйе, Шәвәли – Шәүкәт бабайның дусты, оныгы! Әдәбиятка алып кергән образы.

Шәвәли – гади татар малае. «Ул кем?» дигән табышмак шигырендә үз героен автор менә болайрак тасвирлый:

Шаян малай, ди үзе.
Әллә таныш та инде.
Вәли төслерәк, диләр.
Әмма тешлерәк, диләр.
Лаеклы иптәш, дисәм
Исемен әйтмәс микән?

Шигырьнең һәр юлындагы хәрефләрне тезеп укысагыз, җавабын тиз белерсез. Ә Шәвәли үзе турында болай ди:

Мин – Шәвәли – шук малай. Үткен малай, ут малай.
Мин бик уңган, өлгер мин. Юк-бар белән көлдермим.
Бик тапкыр мин, җыйнак мин!
Мин, мин, мин – бик тыйнак мин!

Шулай итеп, Шәвәли – ут, мут, шук, үткен малай, бераз мактанчыграк. Малайлар бераз мактанчыграк була инде ул! Ләкин Шәвәлинең мактанчыклыгы ачуны китерми, чөнки аның мактанчыклыгы зыянлы түгел, ул шат күңелле, дөнья серләренә төшенергә омтылучы хыялый малай. Шәвәлине кечкенәләр дә, зурлар да ярата. Чөнки Шәвәли дә гел бер урында гына тормый, ул да үсә.

Шәвәли ничә яшьтә?

Бу сорауга заманында ул болай җавап биргән:

– Биш туларга унбиш минут, дөп-дөресе шул, – дигән.
Инде яңадан сорыйсы вакыт та җитте менә:
– Унбиш туларга биш минут, – ди хәзер җитди генә.

Әйдә, кемгә күпме кирәк, шул хәтле санасыннар.
Шәвәли яши берьюлы биш-унбиш арасында.

Шәвәли образының прототибы да булган икән. Ул шагыйрьнең авылдашы, балачак дусты – Шәвәли абзый! Чыннан да, балачакта ул бик мәзәкчән, тапкыр, шук, бик эшчән малай булган ди.

Балалар, шагыйрь абыегызның Шәвәлие белән тагын да якыннанрак танышасыгыз килсә, аның китапларын, җыентыкларын алып укырга тырышыгыз. Ш. Галиев аларны сез укысын, телләрен онытмасыннар, киләчәктә үз балаларына да өйрәтсеннәр дип, туган телебездә иҗат иткән. Чөнки:

Туган тел – иң татлы тел, туган тел – иң тәмле тел.
Тәмле дип телең йотма, туган телне онытма.

(«Туган тел»)

Чөнки, Халкым бер тумыш көнендә дә Тукаен онытмады.
Без – «Туган тел»дән туганнар. Без – Тукай оныклары!

(«Тукай оныклары»)

Шәвәли турындагы берничә шигырь.

10. Резедә Вәлиева (1930)

Бүген мин сезне Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе шагыйрә Резедә Вәлиева, аның кыскача иҗаты белән таныштырырмын. Р. Вәлиева – тумышы белән Башкортстаннан, Кыйгы районы, Дүшәмбикә авылыннан. Әти-әниләре – икесе дә укытучылар. Әтисе – Тәфкалүн Хәммәт улы кырык елдан артык укытучы, мәктәп директоры булып эшләгән. Хезмәте хөкүмәт тарафыннан югары бәяләнгән: ул – Россиянең атказанган укытучысы, ике Ленин ордены кавалеры, әниләре башлангыч класслар укытучысы. Гаиләдә өч бала үсә. Барысы да – уку алдынгылары, тырышлар, сәләтлеләр. Төпчек бала булган Резедә, мәктәпкә укырга кергәнче үк, апасы, абыйсының шигырь ятлаганнарын тыңлап, аларны күңеленә сеңдереп бара. Укырга барасы елны районның нәфис сүз сөйләүчеләр конкурсында үзе сөйләргә тиеш булган Тукай шигырьләре белән бергә, апасы-абыйсының тырышып-тырышып конкурска әзерләгән шигырьләрен дә сөйләп, бөтен залны шаккаттыра һәм кызга беренче урынны бирәләр.

Балачактан ук әдәби мохиттә кайнап үскән кыз, 1947 елда урта мәктәпне тәмамлагач, ике дә уйлап тормыйча, Казан дәүләт

университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга килә. Университетны тәмамлагач, 33 ел буе Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты бүлегендә мөхәррир хезмәтендә була.

Р. Вәлиева – нигездә, балалар язучысы. Шагыйрәнең беренче шигырьләре Республиканың көндәлек матбугатында илленче елларда күренә башлый. Алар нәниләр, балалар өчен язылган шигырьләр була. Беренче җыентыгы – «Минем дусларым» 1960 елда басылып чыга. Гомумән, 1960–2000 еллар арасында шагыйрәнең балалар өчен язылган шигырь, поэма, шигъри әкиятләр, хикәяләр, җырлар, табышмаклар тупланган утыздан артык китабы дөнья күрә. «Минем ижатымда кызыл җеп булып сузылып барган төп тема – Мәхәббәт, – ди шагыйрә. – Туган җиргә, табигатькә, туган халкыбызга, телебезгә, хезмәткә һәм ата-анабызга, өлкәннәргә, гомумән, кешеләргә ихтирам, миһербанлылык, игелеклек хисләре», – дип билгели үзенең кыйбласын.

Төмән шәһәреннән күп балалы ана – Әлфирә Айтбаева Р. Вәлиева ижаты турында менә нәрсә ди: «Резедә Вәлиеваның шигырьләре шундый аңлаешлы, гади, ягымлы тел, җиңел рифма белән язылган ки, тел белмәгән балаларыма тел ачкычы булдылар. Аның шигырьләрен укып-ятлап, балаларым туган телебезне яратып өйрәнәләр».

Укытучы Галия Гайнетдинова фикерен дә тыңлап китик әле. «Р. Вәлиева ижатының поэтик егәрлегенә сокланмый мөмкин түгел. Анда барысы да бар: тирән фикер дә, тәэсирле сурәт тә, ярсу характер да, үзәк өзгеч драма да, күңелгә уелып кала торган матурлык та. Шагыйрәнең язганнарын өлкәннәр дә, нәниләр дә бер дәрәҗәдә яратып, аңлап кабул итәләр».

Р. Вәлиева – тәрҗемәче дә. Берничә рус язучысы һәм шагыйрьләренең, аерым алганда, Агния Барто, Сергей Михалковның шигырь җыентыкларын татарчага тәрҗемә итә.

Р. Вәлиева – җырлар авторы да. Аның сүзләренә язылган җырларны җырчыларыбыз яратып башкара. «Яран гөл» җыры гына да ни тора!

Ә хәзер Резедә апабызның берничә шигырен тыңлап карыйк: «Язлар килә» – 9 бит, «Зоопарклы уйнадык» – 16 б., «Яле, кем әйтеп бирә? – 22 б., «Бу класска нәрсә булган?» – 26 б., «Күңелсез көн» – 18 б., «Укый беләм» – 43 б.

11. Резеда Вәлиева (дәвамы).

Кыңгырау чәчәк

Нинди була ул дуслык?

Яшел нарат урманында, аның иркен аланында бик нәфис, бик назлы бер Кыңгырау чәчәк үсеп чыккан.

– Абау ла, бигрәк матурсың! Исәнме, Кыңгырау чәчәк! Бик тә ошыйсың син миңа. Әйдә, икәү дус булабыз! – дигән Куян баласы.

– Дус булабыз? Ә ничек була соң ул дус булу? – дип сораган Кыңгырау чәчәк. Ул бит әле яңа гына туган булган, шуңа күрә дуслыкның нәрсә икәнен белмәгән.

Урман ягыннан бер Малай килеп чыккан.

Килеп чыгуга ук, ул: «Күр инде, нинди матур чәчәк!» – дип, Кыңгырау чәчәкне өзәргә кулын сузган. Әмма кулын сузуы булган, шунда ук ялт иттереп тартып алган. Кемдер авырттырып тешләп алган икән аның кулын. Караса, кечкенә генә Куян баласы.

– Тимә Кыңгырау чәчәккә! Ул – минем дустым! – дигән Куян баласы, Малайга ачу белән карап.

– Кит, кагылма аңа! Кыңгырау чәчәкне өзәргә ярамый.

– Ә! Мин белдем! Белдем дуслыкның нәрсә икәнен! – дип, шатланып чыңлап куйган шулчак Кыңгырау чәчәк һәм талгын җилдә әкрен генә зәңгәр башын чайкый-чайкый җырлап җибәргән:

Дуслык ул – яхшылык,
Дуслык ул – яктылык.
Дуслык ул кояштай нур чәчә.
Син мине саклаучы,
Яшәүне яклаучы,
Яшә син, Куян дус,
Мең яшә!

Иң зур мирас

Алтын җыйма, йортлар куйма,
Мираска дип балаңа,
Иң кадерле мирас итеп,
Туган телен бир аңа.

Иле белән, дине белән,
Туган җир белән бергә,
Туган телгә мәхәббәт сал
Күңеленә гомергә.
Аерса да хак язмышы
Туган йорттан, иленнән,
Күңеле мәңге аерылмасын
Газиз туган теленнән.

Кайда гына ишетсә дә
Аның татлы авазын,
Туган якка очсын күңеле,
Сагынып ана назын.
Онытмагыз, бу дөньяда
Из зур мирас бер генә:
Көмеш чыңлы, талгын моңлы
Газиз туган тел генә…

12. Роберт Миңнуллин – балалар шагыйре

Балалар, сезгә: «Роберт Миңнуллин кем ул?» – дип сорау бирсәң, бертавыштан, балалар шагыйре, дип җавап бирәчәгегезгә иманым камил.

Балалар шигъриятен популярлаштыруда Р. Миңнуллинның роле бик зур. Ул балалар өчен шигырьләр язып кына калмый, шулай ук балалар әдәбиятына, балалар язучыларына багышланган мәкаләләр яза, мәктәпләрдә очрашулар уздыра. Ун ел дәвамында Татарстан телевидениесендә «Шигъри тәлгәшләр» исемле тапшырулар сәхифәсен әзерләп алып бара. «Акбай цирк карый», «Җиде абый тай җигә», «Айга очтык» исемле балалар китаплары һәм телевидениедән әдәбиятны актив пропагандалаганы өчен 1982 елда Р. Миңнуллин Татарстан яшьләр оешмасының **М. Җәлил исемендәге** премиясенә лаек була. «Дөньядагы иң зур алма» исемле китабы өчен шагыйрь 1992 елда Халыкара әдәби бүләккә – **Г.Х. Андерсен** исемендәге Почетлы дипломга ия була. Татар балалар әдәбиятында бу бүләккә ия булучылар икәү генә: балалар шагыйре Ш. Галиев һәм Р. Миңнуллин! 1997 елда Р. Миңнуллинга балалар әдәбияты өлкәсендә ирешкән казаныш-

лары өчен Татарстан Язучылар берлегенең **А. Алиш** исемендәге премиясе бирелде. Ә 1998 елда «Күчтәнәч» дигән китабы өчен **Г. Тукай** исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. 2005 елда аңа Татарстан Республикасының **Халык шагыйре** исеме бирелде.

Әле Р. Миңнуллин – тәҗрибәле журналист, танылган җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе дә. Ул бик күп җырлар авторы да. «Әнкәмнең догалары», «Әнкәй», «Әни кирәк», «Әнкәйнең ак чәчләре» кебек дөньядагы иң газиз кешеләребез – әнкәйләргә багышланган җырларны белмәгән, ишетмәгән кеше юктыр, мөгаен. Заманында шагыйрь Сибгат Хәким Р. Миңнуллин иҗаты турында фикер йөртеп, болай дигән: «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан, Сөн суында юган иң элек». Популяр җыр. Актаныш якларынан, Сөннән, Агыйдел буйларыннан башланып китә ул җыр. Балалык күңеленнән, балалык моңсулыгыннан башлана. Балалар әдәбиятына Роберт шушы җырдан кереп китмәдеме икән? Очы шунда кебек».

Р. Миңнуллинның туган җире – Башкортстан Республикасы, Илеш районы. Илеш – Татарстан белән чиктәш район. Татарстан белән Башкортстанны Сөн елгасы гына аерып тора. Р. Миңнуллин Илеш районы, Нәҗәде авылында туа, әмма гаилә бераздан әтиләре Мөгаллим абыйның туган авылы Шәммәткә кайтып урнаша. Булачак шагыйрьнең балалык һәм үсмер еллары Сөн буенда, Актаныш районына терәлеп урнашкан шул матур авылда уза. 5 класстан 8 класска кадәр Актаныш районы, Аккүз авылына йөреп укый. Шуңа күрә аңа бу ике төбәк тә бик якын. Мөгаллим абый белән Гөлҗәүһәр апа гаиләсендә 4 малай, бер кыз үсә. Әмма Мөгаллим абый яшьли вафат була. Гөлҗәүһәр апа 5 бала белән тол, ялгыз кала. Үзенең истәлекләренең берсендә шагыйрь менә нәрсәләр турында сөйли.

Балачак истәлекләреннән

Мин еш кына балачагыма кайтып киләм. Үзебезнең кечкенә өебез сагындыра. Безнең авазлардан, шатлыклы көлүләребездән, әрнеп елауларыбыздан шау-гөр килеп торган өебез. Безне сыендырган, җылытып үстергән оябыз. Әле дә аптырыйм. Ничек сыйганбыздыр без анда? Хәзер инде хәллерәкләрнең дача йортлары да аңардан күпкә зуррак. Ә бит шунда биш бала үстек, барыбыз

да бериш, барыбыз да чорсызлар. Әткәбез вафат булгач, шул бәләкәй генә өебез дә бөтенләй бушап калды, хәтта зураебрак та киткәндәй тоелды. Дөньяның ачысы да, төчесе дә күрелде анда. Әле дә ярый әнкәебез булдыклы, акыллы, алдан күрүчән булып чыкты. Таратмады, ач итмәде, ялангач йөртмәде. Көнозын эштә була торган иде, ә төннәрен тегү текте. Хәзер бик текми инде. Үзе дә олыгайды, йомырка җыеп сатып алган тегү машинасы да тузды. Ул чакта исә тирә-якта бер оста иде. Күрше-тирәләрдән дә аңа килделәр. Чират иде хәтта. Әнкәйнең төннәр буе тегү белән шөгыльләнүе миңа да файдага булды. Шул лампа яктысында төнге икеләргә, өчләргәкадәр китап укып ята идем.

Хәзер менә уйлап йөрим: ай-һай авыр булгандыр әнкәйгә! Үзе генә беләдер ниләр күргәнен, ниләр кичергәнен. Ә безгә нәрсә? Якты өй, тәмле аш, җылы караш булса, шул җиткән. Калганы турында үскәчтен генә аңлый башлыйсың, олыгайгач кына уйланасың.

Туган нигез. Туган өй. Без барыбыз да шунда канат чыгарабыз, шунда очарга өйрәнәбез. Очып та китәбез... Китәбез шул, китәбез. Әмма туган өебез җылысы безне гомер буена җылытып тора, иң кыен чакларыбызда искә төшеп йөдәтә. Без туып-үскән өй күптән юк инде. Әмма мин аның һәрбер бүрәнәсен, бүрәнәләрендәге һәрбер ярыгын, һәрбер идән сайгагын, түшәм такталарындагы һәрбер сурәтне хәтерлим. Әнкәбезнең тәмле-тәмле ашларын кабат авыз итәсе килә, ул тегеп кидергән күлмәк-чалбарларны тагын бер киеп малайларның күзләрен кыздырасы килә. Ул чакта туган өйнең кадерен белеп бетермисең шул. Читтә, ераста, син булмаган җирләрдә рәхәтрәк, ямьлерәк шикелле тоела.

«**Балачак әдипләре», 1 нче китап, 120–121 нче битләр.**

13. Р. Миңнуллин ижаты (дәвамы)

Радио тыңлаучы яшь дусларым, бүген дә балалар шагыйре Р. Миңнуллин ижаты турында сөйләшүебезне дәвам итәбез. Аның берничә шигырен тыңлап китәрбез.

Р. Миңнуллин мәктәптә укыганда ук шигырьләр яза башлый. Хәтта аларның кайберләре район һәм республика көндәлек матбугатында басылып чыга. 1966 елда урта мәктәпне тәмамлагач, Илеш район газетасы «Маяк»та ике елга якын

әдәби хезмәткәр булып эшли. Менә шушында эшләгәндә Роберт Миңнуллин әдәбият белән чын-чынлап кызыксына башлый. Әдәбиятка мәхәббәт аны Казанга алып килә. 1968–1973 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укып югары белем ала. Университетта укыган елларында ук ул талантлы яшь шагыйрь булып өлгерә. Татарстанда чыгып килүче төп басмаларда аның шигырьләре еш басыла. 1973 елда, укуын тәмамлагач, аны республика пионер газетасы – «Яшь ленинчы» редакциясенә эшкә чакыралар. «Яшь ленинчы» газетасында эшләү эзсез калмый. Ул балалар дөньясы белән якыннан таныша, балалар өчен беренче шигырьләрен язып карый. Балалар матбугатында басылган ул шигырьләргә иң элек күренекле балалар шагыйре Шәүкәт Галиев игътибар итә. Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Фатих Хөсни кебек аксакаллар да яшь шагыйрьнең балалар өчен язуын хуплап каршы алалар.

Р. Миңнуллин татар балалар әдәбиятына өр-яңа образлар, шигъри табышлар, өр-яңа шигъри алымнар алып килде. Өлкәннәр һәм балалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, сабыйлар дөньясындагы четерекле проблемаларны калку итеп чагылдыра алды.

Шагыйрьнең үзе тудырган шигъри дөньясы, шаян балачагы, балаларча үз фәлсәфәсе бар. Балалар бит алар зурлар күрә алмаганны да күрә, үзенчә бәя бирә. Баланың дөньяга карашы да үзенчәлекле. Бала күңелендә дөнья, яшәеш, тормыш турында йөзләгән сорау яши. Үзеңне бала урынына куеп карый, аларча яши, уйлый алмасаң, укытучы да, балалар шагыйре дә була алмыйсың! Балалар шагыйре – педагог та, көчле психолог та ул! Р. Миңнуллин нәкъ шундый шагыйрь!

Шагыйрьнең шигырьләре җырлап тора, ятларга, истә калдырырга җайлы. Шуңа күрә аның шигырьләре балалар бакчаларында, мәктәпләрдә еш яңгырый. Хәзер сезгә шагыйрьнең берничә шигырен тәкъдим итәрбез.

3–4 шигырь.

14. Мөҗәһит (Мөҗәһит Әхмәтҗанов) иҗаты (1950)

Язучылар, шагыйрьләр авылда туалар, шәһәрдә яшиләр, шунда иҗат итәләр, дип уйлый күбебез. Алай түгел шул. Гомере буе авылда яшәп, матур-матур әсәрләр: хикәя-повестьлар, романнар, шигырь-поэмалар язып, әдәбият сөючеләр күңелендә якты эз калдырган Халык язучылары, республикабызның Г. Тукай премиясе һәм башка әдәби бүләк ияләре дә шакттый татар дөньясында! Мәсәлән, мин яшәгән Мөслим районында гына да берничә алар. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Әлмәт Язучылар берлегенең Р. Төхфәтуллин исемендәге әдәби премиясе лауреаты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Халык язучысы Фоат абый Садриевны белмәүчеләр, аның «Таң җиле», «Бәхетсезләр бәхете» романнарын укымаган кешеләр бик сирәктер. Татарстан Язучылар берлеге членнары – прозаик Роза апа Хәбибуллина, шагыйрә Лилия Садриева, шагыйрь Әхмәт Дусайлы, балалар шагыйре Мөҗәһит Әхмәтҗанов та гомерләре буе Мөслимдә яшәп иҗат иттеләр һәм итәләр.

Дуслар, бүген сүзебез балалар шагыйре Мөҗәһит (Мөҗәһит Әхмәтҗанов) турында булыр. М. Әхмәтҗанов Мөслим районының иң матур авылларының берсе – Түреш авылында туган.

«Мөҗәһитнең мин туган авылын яратам. Авылдашларын яратам. Ихлас кешеләр, ачык күңеллеләр. Урман кочагына сыенып утырган кечкенә авылда туып-үскәннәр шундый буладыр, ахры. Юкка гына Түрештә Татарстанның халык, Рәсәйнең атказанган артисты Наил Әюпов, шагыйрьләр Харрас Әюп белән Ләбиб Лерон туганмыни?! Алар арасында минем дустым, сабакташым, каләмдәшем Мөҗәһит Әхмәтҗанов та бар», – дип язган балалар шагыйре Роберт Миңнуллин.

М. Әхмәтҗанов, һөнәре буенча – укытучы. Күбәк урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1968–73 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Бу еллар университетта әдәби мохитнең киң колач алган еллары. Бунтарь йөрәкле шагыйрьләр Зөлфәт, М. Әгъләм, тирән лирик һәм моң иясе Х. Әюп, Ш. Җиһангирова, Р. Миңнуллиннарның җиң сызганып әдәбиятка килгән еллары. Шул казанда кайна-

ган кеше ничек шагыйрь булмасын! Университеттан соң, Ерак Көнчыгышта Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Аннан кайткач районның Урәзмәт урта мәктәбендә укыта. 1975–82 елларда комсомол һәм партия эшендә. 1982–95 елларда Мөслим урта мәктәбендә директор. 1986–2010 елларда шул ук мәктәптә татар теле һәм әдәбиятын укытты.

Уку-укыту эше белән берлектә, туктаусыз иҗат итте ул. Гомере буе диярлек балалар арасында кайнаган кеше балалар турында язмый, кем турында язсын?! Каләмдәше Р. Миңнуллин әйткәндәй, чын балалар шигыре балалар арасында гына туадыр ул! Язучы Галимҗан Гыйльманов аның иҗаты турында менә нәрсә ди: «Мөҗәһитнең шигырьләре, иң элек, авылчан гадилеге белән җәлеп итә. Беренче карашка аларда катлаулы сурәтләр, башваткыч вакыйгалар юк. Әмма һәр шигырь юлыннан ниндидер җылылык, ихласлык бөркелеп тора. Һәм һәр шигырьдә авыл дигән гаҗәеп дөнья өчен генә хас бер кызык яисә гыйбрәт бар. М. Әхмәтҗанов шигырьләренең тагын бер матур ягы – табигатькә үтә игътибарлылык, итагатьлелек, хөрмәт. Шагыйрь һәр ел фасылының үз ямен, тәмен таба белә, һәр агачның, бөҗәкләрнең, кошларның сулышын тоя белә.

Г. Гыйльманов Мөҗәһит Әхмәтҗановның шигырьләрен «тормыш дәресләре» дип атый.

Татарстан китап нәшриятында шагыйрьнең дистәләгән шигырь китаплары басылды. Булганнан бар да була, дигән әйтем Мөҗәһит абыегызга бик туры килә. Ул район тормышында бик актив катнаша. Мөслим үзешчәннәрен аннан башка күз алдына да китереп булмый. Ул – оста гармунчы; курай, кубыз, сорнай, сыбызгы, таш сыбызгыда бик матур уйный. Оста фотограф, кино төшерү сәнгате дә ят түгел аңа. Шәҗәрәләр төзү остасы да ул.

М. Әхмәтҗанов Татарстанның атказанган укытучысы, Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең А. Алиш премиясе лауреаты да.

Балалар, ә хәзер Мөҗәһит Әхмәтҗановның берничә шигырен тыңларбыз.

15. Дания Гайнетдинова (1952)

Хәзерге заманда да балалар өчен иҗат итә торган язучы-шагыйрьләребез шактый. Шуларның берсе – Дания Гайнетдинова турында булыр алдагы сүзебез. Д. Гайнетдинова – бүгенге көндә «Татарстан» радиосының әйдәп баручы мөхәррире.

Тумышы белән Татарстанның Теләче районы, Олы Тиләҗе авылы кызы Дания, Иске Җөри авылы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Чуашстанның башкаласы Чабаксар шәһәрендә планикътисад техникумында укый. Соңрак читтән торып Казан финанс-икътисад институтында һәм Казан дәүләт университетының журналистика факультетында укып, югары белем ала. Күңелендә әдәбиятка тирән мәхәббәт булган, иҗади сәләткә ия Дания Гайнетдинова алга таба үзен әдәбият-сәнгать, журналистикага багышлый. 1990 елда Татарстан китап нәшриятында аның «Күңел җылысы» дигән беренче китабы басылып чыга. 1991 елда Д. Гайнетдинова «Татарстан» телерадиотапшырулар кампаниясендә балалар редакциясенең өлкән мөхәррире булып эшли башлый. Шушында эшләгәндә, балалар өчен күп кенә радиоспектакльләр, радиопостановка сценарийлары төзи. Балалар өчен хикәяләр яза. Д. Гайнетдинова берничә китап авторы. Ул Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге премиясе лауреаты.

Балалар, ә хәзер Дания апагызның сезнең өчен атап язылган берничә кыска хикәясен тыңларбыз.

Изге сүз

Сәкинә быел беренче сыйныфны тәмамлады. Билгеләре дә гел «бишле» генә. Мәктәпкә кергәнче үк укый белә иде инде ул. Йөзгә кадәр санарга да өйрәнгән иде. Болар ярап куйды. Югыйсә, гел «бишле»гә генә укый алмаган булыр иде. Әтиәнисе дә кызларының тырыш булуына бик сөенделәр.

Җәйге каникул көннәренең берсендә Яңа бистәдә яшәүче дәү әнисе Сәкинәне үзенә кунакка алып китте. Трамвайда кайтканда, Сәкинә дәү әнисе яныннан читкәрәк китеп басты.

– Утыр, кызым, утыр, ник торасың? – дип сорады дәү әнисе.

– Өлкәннәр утырсын, – диде кыз.

– Шулай дисеңме? Менә рәхмәт, кызым! Дәү әнисе елмаеп куйды. Сәкинә дә көлемсерәде. Ул кондуктор апа янынарак барып басты. Аңа әле бер, әле икенче яктан билетка акча суза башладылар. Сәкинә аларны кондуктор апага сузды, аннан билетларны хуҗаларына кире кайтара торды. Апалар. абыйлар аңа татарча да, русча да рәхмәт әйттеләр.

– Рәхмәт, кызым!

– Спасибо, доченька!

– Рәхмәт, сеңлем!

Трамвайдан төшкәч, Сәкинә бик шатланды. Дәү әнисенә карап: «Егерме рәхмәт алдым», – диде.

Дәү әнисе кеткелдәп көлеп җибәрде: Шулаймыни, кызым?

– Ник көләсең, дәү әни? – дип сорап куйды Сәкинә. – Үзең әйтәсең бит, бер рәхмәт мең бәладан коткара, дип...

Дөрес, кызым, дөрес! Мин куанычымнан көләм. Синең тырыш, уңган булуыңа шатланам. Ярдәмчел булуыңа. Ә рәхмәт сүзе – изге сүз ул. Аның кадерен белергә кирәк...

Батыр Хәбир

Хәбир шук-шаян булса да, бик күзәтүчән малай**.** Быел беренче сыйныфка укырга керәчәк ул. Шуңа күрә үзен зур малай итеп күрсәтәсе килә бугай. Гел кечкенә булып йөреп булмый бит инде!

Ә беркөнне, чынлап та, батырлык эшләргә туры килде аңа. Болдырда йомшак талдан тырышып-тырышып сыбызгы ясап утыра иде. Яныннан мыштым гына үтеп баручы мәчегә күзе төште. Мәче авызында – кош баласы! Хәбир мизгел эчендә әйберләрен ташлады да песинең авызын ике яклап кулы белән шундый итеп кысты, тегесе никадәр тырышса да, кошны ычкындырырга мәҗбүр булды.

Кошчык, тәмам коты алынып, аңын җуйган. Хәбир аны болдыр култыксасына куйды һәм текәлеп карап тора башлады. Бераздан кошчык аякларына басты. Башын боргалап, тирәягына каранды. Аңына килде бугай...

Шактый вакыт узгач, әле ныгырга да өлгермәгән канатларын кыймылдатып алды. Ә тагын бераздан очарга тырышып

карады. – Чык-чырык! Чык-чырык! – дип аваз салды. Әнкә кош та Хәбирнең бу батырлыгына шаккатып, өзгәләнеп-өзгәләнеп, оча-куна бәргәләнә иде. Нәниен үлемнән коткаруы өчен рәхмәт белдерә сыман иде ул.

Бу хәлләрнең һәммәсен чоланнан Хәбирнең әбисе дә күреп торган икән. Ул Хәбир янына килде дә оныгының башыннан сыйпады. «Батыр икәнсең, улым! Кошчыкның гомерен саклап калдың бит. Әнә, әнкә кош та ничек шатлана. Ул да сиңа рәхмәт әйтеп чыркылдый», – диде.

Хәбиргә рәхәт булып китте.

16. Татарның Шолоховы – Фоат Садриев (1941)

Тормыш университетлары

Балалар, мин бүген сезне Республикабызның Г. Тукай исемендәге премия лауреаты, халык язучысы Фоат абый Садриевның кыскача иҗаты, аның балалар өчен язылган әсәрләре белән таныштырып китәрмен.

Фоат Садриев тумышы белән Мөслим районының Олы Чакмак авылыннан. 1941 елның 10 мартында туган малайның балачагы җиңел булмый. «Безнең балачак үтә дә авыр чорга туры килде, – дип искә ала язучы. – Минем әтием комбайнчы булган, Сталинград өчен барган сугышларда башын салган. Әнкәй бер караңгыдан икенче караңгыгача колхозда эшли. Яздан көзгәчә әнкәйләр утау утыйлармы, урак урып көлтә бәйлиләрме, ашлык сугалармы, салам эскертлиләрме – өйдә караучысы булмаган минем кебек бала-чага гел басуда. Шуңадыр инде мин гомерем буе табигатьнең бер генә күренешенә дә рәшәле иген басуларына сокланган кебек соклана алмадым», – ди язучы «Мин барыбер бәхетле» язмасында.

Бик яшьли «Тормыш университетларын» үткән егет әдәбиятка 1958 елда килә. Район газетасында 17 яшьлек егетнең «Алар җиңелделәр» дигән беренче хикәясе басылып чыга һәм конкурста беренче урынны ала. Бу вакыйга егеткә канатлар куя, иҗатка ныклы омтылыш уята. Ф. Садриев 1963–1970 елларда район газетасында әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире вазифаларын башкара. 1972–1981 елларда Мөслимдә чыга торган

«Авыл утлары» район газетасының редакторы булды. Бу еллар «Авыл утлары»ның иң якты янган, район тормышын һәрьяклап яктырткан еллары булып тарихка кереп калды.

Ф. Садриев – ике дистәгә якын сәхнә әсәрләре авторы, проза әсәрләре белән киң җәмәгатьчелеккә танылган каләм иясе дә. Язучыга аның 1992 елда иҗат ителгән «Таң җиле» романы аеруча зур танылу алып килде. Әсәр шулкадәр популярлыкка ия булды ки, 1993–94 елларда Татарстан китап нәшриятында зур тираж белән ике мәртәбә басылып чыкты. Бу әсәре өчен Ф. Садриев Әлмәт Язучылар союзының Рафаил Төхфәтуллин исемендәге әдәби бүләгенә лаек булды. «Бәхетсезләр бәхете» трилогиясе өчен язучы республикабызның Г. Тукай премиясе белән бүләкләнде.

Фоат Садриев – башлыча, өлкәннәр өчен яза, әмма әсәрләрендә балалар образлары да бик җылы итеп тасвирлана. Үзе дә гомере буе авылда яшәп иҗат иткән язучының геройлары да авыл кешеләре, хезмәт кешеләре, авыл балалары. Аның «Таң җиле» романындагы Марат исемле кечкенә шук малай шулкадәр чынбарлыктагыча итеп бирелә, аны кочагыңа алып кысып-кысып сөясе килә, хәтта! Романны укыган һәр кеше аңарда үзен, үзенең шат, бер кайгысыз балачагын яки балаларын күрә. Әле күптән түгел генә Фоат абыйның урта һәм өлкән яшьтәге балалар өчен «Тургай» дигән яңа китабы басылып чыкты. Китапта Тургай кушаматлы Ислам исемле малайның дөньяны танып-белү юлындагы тәүге адымнары сурәтләнә. Ул шук та, вакытында үтә җитди дә, авыл малайларына хас булган эчкерсезлек, гадилек тә хас аңар. Ислам сер дә саклый белә, дусларын үз артыннан ияртерлек көчкә ия бу малай башкаларда соклану хисе генә уята. Аның тормышы, мажаралары, кайвакыт хәл итеп булмас кебек тоелган проблемалары беркемне дә битараф калдырмас. Ике повестьтан торган әлеге китап инде сатуга чыкты. Ә аның өченче – соңгы кисәген автор шушы көннәрдә язып тәмамлады. Бу әсәр эти-әниләр өчен дә. Бүгенге балалар тормышының катлаулы яклары, алар алдында торган проблемалар тормышчан итеп тасвирлана әсәрдә. Бүгенге балалар, яшүсмерләр егерменче гасырда туып-үскән, шул чорларда формалашкан буыннан күпкә аерыла. Язучы әнә шул үзенчәлекләргә туктала. Бу әсәрне китап кибетләреннән алып укырга тырышсагыз иде.

Ә хәзер язучының «Мин барыбер бәхетле» язмасыннан үзенең балачагын тасвирлаган бер өзек тыңлагыз...

Үзенең авыр сугыш елларына һәм аннан соңгы елларга туры килгән балачагының бик авыр моментларын тасвирлаганнан соң, автор болай ди: «Бер карасаң, акырып елап утырмалы, шулай бит! Әмма ни гажәп, без борын салындырмадык. Әз генә буш вакытыбыз чыкса, тауга чана шуарга ашыктык. Менә шунда иде инде чын бәйрәм! Чаналарга әллә ничәшәр катлы булып төяләбез дә әллүр түбәнгә. Чаналар мәтәлеп китә, без чәчелеп очабыз, үзебез көлешәбез. Без фәкыйрь, ач, әтиләребез сугышта үлеп калган, ә күңелләребез шат, чөнки без бергә. Без тормышның үзебез оештырган шушы мизгеленнән искиткеч ләззәт алабыз.

Яз көне тау башы ачылуга, без тагын шунда. Анда яккан учаклар көлендә пешкән кабыклы бәрәңгенең тәмнәре, анда уйнаган уеннар безне тагын бәхетле итә... Җәй көне өстә күлмәкштан гына кала. Яланаяклар чебили, яланбаш йөреп чәчләребез кояшта уңып бетә. Инде без бергәләшеп Ыкка төшеп су коенабыз, кармак салабыз, төрле уеннар уйныйбыз, ихатада эшлибез, әнкәйләр янына басуга барып кайтабыз. Безнең гомер кырларда, басуларда, болыннарда, су буйларында, әрәмәләрдә, тау битләрендә уза. Бер сүз белән әйткәндә, без – табигать балалары идек. Әти-әни кочагын безгә табигать кочагы алыштырды. Барыбыз бергә булгач, ятимлекне, мохтаҗлыкны онытабыз. Күңелләребез көр, туктаусыз уйныйбыз, шаярышабыз. Шулай итеп без, бәхетне үзебезгә үзебез ясыйбыз. Балачакның иң олы бәхете – уенда бит ул! Сәгатьләр буе япа-ялгызы телевизорга багынып утыручы балалар безнең белән чагыштырганда ничек кызганыч!» Язучының бу истәлеге 2005 елда язылган. Ә хәзерге балаларга телевизордан тыш телефон, планшет, компьютерлар да өстәлде. Бүгенгә шулар. Икенче тапшыруда язучының «Таң җиле» әсәренә тукталырбыз.

17. «Таң җиле» романы – Аналарга мәдхия

Хөрмәтле ата-аналар, әби-бабайлар, балалар! Алдагы тапшыруда вәгъдә ителгәнчә, бүген мин сезне Фоат Садриевның «Таң җиле» романы һәм аннан алынган бер өзек белән таныштырырмын.

Язучының «Таң җиле» романы узган гасырның туксанынчы елларында ижат ителеп, иң яратып укылган әсәрләрнең берсе булды. Әсәрдә авыл тормышы, авыл кешеләренең эшләре, проблемалары, гыйбрәтле язмышлары тасвирлана. Әсәрнең төп герое – хатын-кыз, Нуриасма. Тормыш нужасының тәртәсенә җигелеп тартучы хатын-кыз, акыллы, сабыр, тормыш тәҗрибәсенә, ныклы ихтыяр көченә ия, балаларына, оныкларына үз үрнәгендә дөрес тәрбия биргән зур хәрефтән язылырлык Ана ул Нуриасма әби! Рафаэль Сибат бу роман турында менә нәрсә дигән: «Бер сүз белән әйткәндә, Фоат Садриевның «Таң җиле»ндәге Ана образы – чын мәгънәсендәге «татар хатыны» дигән зур төшенчәгә ия. Бу китап татар хатынына – Анага мәдхия һәм җыр! Прозаик Фоат Садри берүзе «Таң җиле» белән «Ана турындагы җыр»ны тудыручы шагыйрь, композитор, җырчы булды».

Нуриасманың бер улы – Фәрит – гаиләсе белән Донецк шәһәрендә яши, үзе шахтада эшли. Ике кызы, бер улы бар. Әмма көтеп алынган уллары Марат дүрт яшенә кадәр ун-унбиш сүз дә әйтә алмый, башы чирдән чыкмый. Кайларга гына алып барып, нинди генә табибларга күрсәтеп карасалар да, алга китеш булмый. Ахырдан врачлар урын, һава алыштырып карарга, мөмкин булса, баланы авылга кайтарырга тәкъдим итәләр. Шулай итеп, Маратны Фәритнең туган авылы Күкеледә әнисе Нуриасма янында калдырып китәләр. Бер ел гомер ата-ана өчен гасырга тиң була. Әти-әнисе малайны алырга кайткач, үз күзләренә үзләре ышанмый торалар. Чирләшкә малай урынына, алар алдында чуен кебек каралган, яланаяклы, авыл малайларыннан бернәрсә белән дә аерылмый торган Маратлары басып тора. Авазларны әйтеп бетермәсә дә, теттереп сөйләшергә өйрәнгән.

– Әни, Маратны ничек терелтә алдың син? Ничек шулай ныгып китте икән соң ул? – дигән сорауга, Нуриасма:

– Бала туфракта аунап, шуны ашап үссен ул. Туфракта нидер бар. Үзебез дә шуннан лабаса! – ди. Бу сүзләргә каршы берни дә әйтеп булмый шул!

Әти-әнисе янында бераз юанган бала, иптәшләре белән уенга чыгып китә һәм кичкырын гына кайтып керә.

– Без таудан тәәгәчле уйнадык! – диде ул, керә-керешкә. Өстендәге киеме буенча фикер йөрткәндә, аны ат койрыгына та-

гып берничә чакрым сөйрәгәннәрдер дип уйларлык иде. – Кепкаң кая, улым? – диде Нәсимә, ягымлы булырга тырышып.

Марат зур гына кружкага үзе сөт салып ипи белән ашый башлаган иде инде. Әнисенең соравы аның авызы ипи һәм сөт белән тулган, төелә-төелә чәйнәгән чакка туры килде. Марат ипине йоткач, бик җитди итеп: «Баш ичәнлеге кияк!» – дип куйды. Фәрит тынсыз булып бөгелеп төште. Нәсимә белән әнисе дә күзләреннән яшь чыкканчы көлделәр. Сөт белән ипи суккач, Марат: «Рәхмәт, Нуиәчмә әби», – диде дә, тагын чыгып йөгерде. Бераздан ул ишекне генә ачып кычкырды: «Әби, кажлал кайтты».

– Хәзер, улым, чыгам, – диде әбисе һәм алар барысы да ишегалдына юнәлделәр. Марат киң генә алюминий кәстрүл тотып сарайдан чыкты, аны чиләкләр киптерә торган тәбәнәк эскәмия өстенә куйды. Әбисе: «Җимне ныгытып болгат, улым», – диде. Марат олы кеше кебек җиңнәрен сызганды һәм, камыр баскандай, җимне ике куллап изә башлады. Аның бәрәңге, көрпә, атлык ябышкан бәләкәй йодрыкларының тиз-тиз хәрәкәтләнүен күргәч, Нәсимәнең кызганудан күзләре яшьләнде. «Кая, үзем», – дип Марат янына бара башлады. Ләкин Нуриасма аны туктатты һәм күз кысты: «Әнисе, син тимә, Марат улым үзе туйдыра ул казларны».

Казлар, ка-ка, килеп, Маратны сырып алдылар. Култык аларыннан кәстрүлгә башларын суздылар, үзләренең тәпиләре белән аның тәпиләренә бастылар, томшыклары белән беләкләренә, битләренә кагылдылар. Үзе каз буе малайның алардан курыкмыйча шулар уртасында калуы Нәсимәнең башына сыймады.

Марат әти-әнисенә үзенең зур булып үсүен күп эшләр белән дәлилли. Ул әбисенең иң якын булышчысы икән бит. Казларны ашату өстенә, көтүдән сыерны, кулына ипи кисәкләре тотып сарыкларны каршы алырга, бәрәннәрне ашатырга да җитешә ул. Үзен зурларча тотып, казлар, сарыклар, бәрәннәр белән сөйләшеп, аларны үз итеп яратып каравы бу балага карата соклану хисләре генә уята. Әйе, авыл үзенең саф һавасы, табигате, ризыклары белән генә түгел, хезмәт белән дә, халкыбызның гасырлар буе кулланылган тәрбия чаралары да белән дә кешене дәвалый ала. Марат менә шуның мисалы.

Бүгенгә менә шулар. Киләсе тапшыруда Фоат абый Садриевның «Аппакай» хикәясен тыңларсыз.

18. Ф. Садриев. «Аппакай».

Ф. Садриев балалар өчен язган әсәрләрендә алгы планга кешелеклелек, намуслылыкны куя, тирә-юньгә, кешеләргә, табигатькә, тереклеккә игътибар һәм ихтирам белән карарга өйрәтә. Сезнең игътибарга аның «Аппакай» хикәясенең кыскартылган вариантын тәкъдим итәм.

Булатның әнисе талдан үрелгән түгәрәк әйбер алып керде. Аның эченә сап-сары салам да салынган иде. Булат яшькелт талчыбыкларын тотып-тотып карагач: «Әни, бу нәрсә?» – дип сорады.

– Бу оя дип атала. Каз шуңа йомырка сала, – диде әнисе.

– Ник?

– Йомыркадан бәбкә чыгара.

Шулчак өйалдында каз каңгылдавы ишетелде. Әнисе ишекне ачуга, ул тупсаны атлап, өйгә керде. Муенын Булатка да, башка якка да сузгалап: – Ка-ка-ка, ка-ка-ка! – диде. Әнисе казны ояга утыртты да карават астына этте, карават җәймәсен идәнгә кадәр төшереп куйды.

– Казга анда караңгы бит, – диде Булат.

– Караңгы булмаса, ул йомырка да салмый, бәбкә дә чыгармый, – дип аңлатты әнисе. – Тешләп алмасын, бик якын килмә.

Әнисе маллар карарга абзарга чыгып киткәч, Булат эчтән генә көлеп куйды: «Җәймә артыннан берни дә күрмәгән килеш, ничек тешләсен инде ул?». Шулай уйлап карават янына килүе булды, каз томшыгы белән ике тапкыр тезенә китереп тә төртте. Ярый җәймә калын, тешли алмады. Күрмәсә дә, сизә икән.

Каз көн аралаш йомырка салды. Аннары йомыркалар өстенә утырды.

Бервакыт карават астыннан «пип-пип» дигән тавыш ишетелде. Әнисе ояны тартып чыгарды да каз астыннан йомырка алды. Аның бер башы әз генә тишелгән, ә шуннан туктаусыз «пип-пип» диюче сап-сары бәбкә борыны күренеп тора. Аңа тәлинкәдән су йоттырдылар да кире куйдылар. Ике көн үттеме-юкмы, идәндә сап-сары бәбкәләр йөгерешә башлады. Ләкин арада берсе чирле иде. Ул аксап кына йөри, юньләп ашый да алмый, борынын сары йоны арасына тыгып тик утыра. Булат

ул бәбкәне бик кызганды. Читтә калса, итәгенә алды, куллары белән җылытып утырды, су эчерде. Бәбкә акрынлап ныгый, терелә барды.

Җәй бик тиз үтте. Бәбкәләр акрынлап кара-кучкыл төскә керделәр, аларга канат-каурыйлар чыкты, чын каз булдылар. Теге бәбкә ап-ак иде. Шуңа күрә аңа Аппакай дип исем куштылар.

Агачларның яфраклары саргаеп коелды, яңгырлар ешайды, көннәр суытты. Инде казлар елгага йөрүдән туктадылар, сарайда җим ашадылар, ишегалдында йөреп керделәр.

Булат ял көнне иртән торуга бөтен җир ап-ак кар белән капланган иде. Ул чанасын тартып, тауга китте, туйганчы шуды. Кайтып керсә, өй тулы апалар, һәрберсе каз йолкый. Булат елап җибәрде һәм:

– Минем Аппакайны бирегез! – дип кычкырды.

– Аппакаең исән-сау, бар, чыгып кара, – дип әнисе аны тынычландырды.

Булат атылып ишегалдына чыкты. Аппакай сарайда ялгызы иде. Булат аның озын йомшак муенын сыпырды, сөйде, башка казларны кызганып елады.

Яз көне Аппакай ояга күп итеп йомыркалар салды, сап-сары бәбкәләр чыгарды. Аппакай үзе генә түгел, аның бәбкәләре дә Булатның аерылмас дусларына әверелделәр.

19. Фантаст язучы Адлер Тимергалин (1931–1913).

Әти үзе бер аерым планета!
Язучының кызы – рәссам Алсу Тимергалина.

Балалар, алдагы тапшыруларда мажаралы, фантастик әсәрләр турында аз гына булса да мәгълүмат биреп үткән идем. К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы», Гадел Кутуйның «Рөстәм мажаралары» повестьлары әнә шундыйлар. Әмма бүген мин сезне татар әдәбиятында бердәнбер «саф фантаст» язучы белән таныштырып үтәргә телим. Ул – Адлер Тимергалин! Дөнья әдәбиятында Жюль Верн башлаган юлны татарлар арасында дәвам итүче, диләр аның турында. «Татар совет әдәбиятында фәнни-фантастик жанрны үстерүгә күп көч

салган һәм бу жанрда нәтиҗәле эшләгән «саф фантаст» язучы, диләр. Адлер Тимергалинның төп өлкәсе – физика һәм астрономия. Укытучылар гаиләсендә туып-үскән Адлер Тимергалинга кечкенәдән үк «китап җене» кагыла. Әле башлангыч класста гына укыганда, ул 10 класста укучы апасының «Астрономия» дәреслеген ачып карый һәм аны азагына кадәр, рәсемнәрен карый-карый, берничә тапкыр укып чыга. Жюль Верннның «Капитант Грант балалары», «80 мең километр су астында» романнарын кат-кат укый. Физика белән кызыксына. Ул аның иң яраткан фәне була. Урта мәктәпне тәмамлагач, фән белән ныклап кызыксынган егет, Казан дәүләт университетына юл тота. 1948 елда физика-математика факультетының астрономия бүлегенә укырга керә. Әмма аерым сәбәпләр аркасында, аңа укуын монда дәвам итәргә мөмкинлек булмый һәм ул Ташкент шәһәренә китә. 1952 елда Ташкент дәүләт педагогия институтының физика-математика бүлеген тәмамлый. 1955 елга кадәр туган авылы Сарман районы, Иске Минзәләбаш җидееллык мәктәбендә физика-математика фәннәрен укыта. 1956 елда Казанга килә һәм гомеренең соңгы елларына кадәр шунда яши, эшли, ижат итә.

Беренче әсәре – «Роберт, уян, сөеклем!» 1959 елда «Идел» альманахында басыла. Ә бер елдан соң, ягъни 1960 елда, Татарстан китап нәшриятында, өч хикәяне үз эченә алган беренче китабы «Пәһлеван кабере» басылып чыга. Шуннан соң ике дистә ел эчендә аның сигез китабы дөнья күрә. Бәлки, бу китапларның кайберләре сезгә таныштыр да. Менә алар: «Ике хикәя, бер хыял», «Ерак планетада», «Мәңгелек хатирәләр», «Кохау ронго-ронго», «Космостан кунаклар», «Адашкан йолдыз», «Таш алиһә», «Кайтыр юллар». Исемнәре үк укырга чакырып тора бу китапларның. Нинди серләр яшеренгән икән аларда?! Фәнни-фантастик әсәрләр хыял дөньясында гына йөздерми, дөньяны танып-белергә дә өйрәтә, фәнни белемнәрне ныгыта, тулыландыра да.

Балалар, әлеге санап кителгән китаплар сатуда күптән юк икән инде. Чөнки алар узган гасырның 60-70-80 нче елларында басылган булган. Ул вакытта алар китап кибетләрендә озак ятмады. Бу Адлер Тимергалин әсәрләренең популярлыгы турында, ул чор балаларының фантастик әсәрләрне яратып укулары турында да сөйләмиме икән? Шулай да сез бу китапларны

китапханәләрдән эзләп карагыз әле, һичшиксез, таба алырсыз. Бәлки фантастик китаплар укырга яратучылар бәхетеннән, язучыбызның бу әсәрләре кабат басылыр.

Язучының барлыгы 17 китабы дөнья күргән. Үзенең дә бик бай китапханәсе булган. Кызы, рәссам Алсу Тимергалина «Татарстан яшьләре» газетасына биргән әңгәмәсендә, әтисенең китапханәсендә 5–6 мең китап булганлыгын әйтә. Үзе бер зур китапханә! Әтисенең гажәеп тирән белемле, зыялы, күпкырлы шәхес булуы турында горурланып сөйли. «Әти гомере буе физика, галәм, йолдызлар белән кызыксынды, – ди. – Әтинең теле искитмәле. Аның әсәрләрен укыганда мин рәхәтлек кичерәм. Әтинең тавышын, интонациясен ишеткәндәй булам», – ди.

А. Тимергалин – күпкырлы талант, дидек. Чыннан да, шулай. Ул берничә терминнар сүзлеге төзүдә һәм бастырып чыгаруда якыннан катнаша, тәрҗемәче дә. Берничә рус фантаст язучысының хикәя-повестьларын татар теленә тәрҗемә итә. Безнең чор һәм бездән соңгы балалар мәктәптә укыганда ул тәрҗемә иткән «Физика» дәреслегеннән гыйлем тупладылар. Аның тагын бер зур хезмәте – «Миллият сүзлеге»!

Балалар, Адлер Тимергалин дигән язучының китапларын уку сезне фән, хыял дөньясына гына алып кермәс, бәлки, кешелек дөньясын борчыган күптөрле фәлсәфи, әхлакый һәм тормыштагы күп төрле проблемаларны чишүдә фәнгә таянырга, аларны чишкәндә кешелеклелек принципларын алга куярга кирәклеген дә төшендерер.

20. Адлер Тимергалин. «Сәер планетада»

(Өзек)

Үземнең бу планетага каян килеп чыкканымны мин, ничек кенә тырышсам да, аңлата алмамдыр, чөнки ракетага ничек утырганымны да, коточкыч салкын галәм бушлыгы аша ничек очып үткәнемне дә – берсен дә хәтерләмим. Иң гажәбе шул: мин әле кичә генә «Фемиксо» дигән санау машинасында ялыктыргыч цифрлар белән мәш килеп утырган кече хисапчы – яңа гына мыек төртә башлаган егет идем. Ә бүген, бакчы, мин – астронавт, берьялгызым гына ифрат зур космопланны ерак дөньяларга алып барам...

Каршымдагы идарә панеле кырыкмаса-кырык төрле шкала, кнопка, яшелле-кызыллы сигнал лампалары белән тулган; менә бусы – җиргә кадәр ераклыкны, бусы – тизлекне, тегесе – тизләнешне... Шуңа исем китә: мин боларны каян беләм, каян өйрәнгәнмен соң? Нинди могҗиза бу? Хәер, бу турыда сүз куертмыйк. Кызыгы алда әле...

Тиздән мин ниндидер йолдыз системасына килеп чыктым. Йолдыз үзе яшькелт төстә булып, зурлыгы ягыннан безнең кояш чамасындарак иде. Аның тирәли биш зур планета әйләнеп йөри һәм шуларның берсендә генә атмосфера кеше сулау өчен яраклы иде. Мин моны лазер нурын планетага юнәлтеп һәм чагылган яктылыкны спектрограф белән тикшереп белдем.

Планета миңа ошап куйды. «Тотарга да шунда төшәргә!»– дигән уй күңелемне кытыклап җибәрде. Озак икеләнеп тормадым.

Сәер планета иде ул, валлаһи! Аны һич тә шар димәссең: формасы шакмаклырак булса да, кубтан бигрәк очы кисек Хеопс пирамидасына тартым, ягъни бу планетаның телгә алырлык формасы да юк иде.

Мин газ рульләрен искиткеч оста идарә итеп, планетаның аулак бер почмагына килеп кундым. Космопланнан скафандр кимичә генә чыктым, чөнки, инде әйткәнемчә, монда һава сулау өчен яраклы һәм ифрат саф иде.

Сәерлекләр көттереп тормады. Беренчедән, кинәт кенә суытып җибәрде һәм мин туңып калтырый башладым. Планетаның кояшы нәкъ баш өстендә тора иде ләбаса! Бер кыя ышыгына кереп күләгәгә утырган идем – җылынган кебек булдым. Әһә! Моның кояшы салкын нурлар тарата икән бит! Шушы гажәеп хәлне аңлаганнан соң мин кояш төшмәгән күләгә урыннардарак йөри башладым. Икенчедән, бу планетаның күчәр тирәли әйләнүе дә әкәмәт булып чыкты. Дөресрәге, ул бер күчәр тирәсендә генә түгел, алмаш-тилмәш дүрт-биш күчәр тирәсендә бөтерелә, шунлыктан тәүлек озынлыгын төгәл белеп булмый, хәтта планета киремә әйләнгән чакларда мин хронометр сәгатемнең киремә йөри башлавын да күрдем.

Өченчедән, планетаны сәйран кылып йөргәндә, мин гажәеп агачларга тап булдым. Алты ботаклы карсак кына бер агачны күз алдына китерә аласызмы? Аның астагы ботаклары

җиргә кадәр салынып төшкән. Ә өстәгеләре – дүртесе – төрле-төрле якка тырпайганнар. Яфраклары бик сирәк һәм тешкә тияр дәрәҗәдә шәмәхә. Мин әйбәтләбрәк карарга дип бер агачка якын килгән идем: сискәнеп киттем. Беләсезме, агач бөтен кәүсәсе белән кымшанып куйды һәм үзенең өске ботакларын миңа таба сузды. Мин кире чигендем, ә агач, аскы ботакларын җиргә терәп, алагаем озын кулларына таянган гиббон шикелле, минем өскә сикерде...

21. Рафис Корбан (1957)

Балачак калды ераста, калды еллар түрендә.
Р. Корбан.

Балалар, бүген мин сезне балалар шагыйре һәм драматург Рафис Корбан иҗаты белән таныштырып китәрмен.

«Рафис – иҗатының табигате белән балалар язучысы. Ихлас һәм мавыктыргыч әсәрләрендә баланың кызыксынып дөнья тануын үтемле итеп күрсәтә белә ул», – дип язган булган 1988 елда ук Татарстанның Халык шагыйре Шәүкәт Галиев.

Ә Галимҗан Гыйльманов аның иҗаты турында болай ди: «Яшь шагыйрьнең күпчелек парчалары эчке бер тәрбияви көчкә ияләр. Шат елмаю аша дөньяны танып-белергә өйрәтәләр». 1991 ел.

Роберт Миңнуллин исә шагыйрь иҗаты турында мондыйрак фикерләр әйтә: «Рафис Корбан балалар дөньясын яхшы төшенә, нәниләр күңелен аңлый, алар өчен яза белә. Язганнары – традицион, мөгезләр чыгармый. Бари Рәхмәт, Әхмәт Фәйзи, Шәүкәт Галиев кебек олы шагыйрьләрнең матур традицияләрен лаеклы рәвештә дәвам итә».

Рафис Корбан балалар өчен ике дистәгә якын шигырь китаплары чыгарган. Әле ул курчак театрлары өчен дә пьесалар яза. Казан Курчак театры аның «Куркуын җиңгән Куян» (1994), «Бардым күлгә, салдым кармак» (1995), «Ак күлмәктә кара елан» (1996) исемле пьесаларын сәхнәләштерә. Шулай ук аның пьесалары берничә театрда куела. Язучының сәхнә әсәрләре 2000 елда «Куркуын җиңгән Куян» җыентыгында урын алган.

Р. Корбан – Шәйхи Маннур һәм А. Алиш премияләре иясе дә.

1957 елда Биектау районы (ул чорда Дөбъяз), Кече Битаман авылында туган булачак шагыйрь башлангыч мәктәптә укыганда ук, тугыз яшьләрендә чакта, шигырьләр яза башлый. Җиденче сыйныфта укыган чакта «Яшь ленинчы» газетасында беренче шигыре басыла. Шуннан соң «Яшь ленинчы» газетасында, «Ялкын» журналында, үзләренең район газетасында бер-бер артлы шигырьләре, хәбәрләре, рәсемнәре басыла башлый.

1987 елда аның кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Буран кайда йоклый?» исемле беренче китабы басылып чыга.

«Шигырь язу сәләте миңа әниемнән күчкәндер, – ди шагыйрь «Син нинди бәхетле, әнием!» язмасында. – Ул да яшь чагында шигырьләр язган... Әйе, миңа шагыйрь җанын әнием биргән. Мин аның дәвамы. Аның күңелендә шигырь булып яралырга насыйп булмаган сүзләр минем йөрәгемдә шигырьләнәләр. Әгәр дә әдәбият сөючеләр Рафис Корбан атлы балалар шагыйре бар, дип таныйлар икән, аларны минем әниемә дә рәхмәтле дип саныйм. Менә күр, әнием, күпме кеше сиңа рәхмәт укый. Син нинди бәхетле!» Баласының чын йөрәктән әйткән шушы сүзләре, рәхмәте Ана өчен иң зур бәя!

Рафис Корбан 2012–2016 елларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе дигән бик җаваплы хезмәтне дә башкарды. Рафис Корбан лирик һәм публицистик шигырьләр, җыр текстлары авторы да. Узган гасырның туксанынчы елларында бик популяр булган «Уян, татар!» җырының авторы да ул.

Ә хәзер Рафис Корбанның берничә шигырен тыңларсыз.

21.09.19.

УЯН, ТАТАР!

Кояш чыкты, ул калыкты,
Тәрәзәдән нур балыкты.
Уян, татар, уян инде,
Уянырга вакыт җитте!

Ач күзеңне, күр үзеңне
Бу тормышның көзгесендә.
Инде кемгә калдың охшап?
Нинди кавем йөзе синдә?

Ана телен, туган телен
Гарипләрең каян белсен?
Үз җиреңдә, үз телеңдә
Сөйләшергә гаҗиз бит син!

Уян, татар, уян инде.
Шуны сорый үзе заман.
Милләтче дип аталудан
Куркасыңмы әллә һаман?

Милләтем дип әйтсә берәү,
Милләтче дип чыкты сүзе.
Татар өчен кем көрәшсен,
Көрәшмәсә татар үзе?!

Уян, татар, уян инде!
Уян, син дип кояш чыга.
Тор да кузгал изге эшкә!
Бу җыр шуңа булсын дога!

III кисәк

«САБЫЙГА» – БАЛАЛАР ФОЛЬКЛОРЫ

1. Балалар фольклорының әһәмияте

«Тәртип» радиосын яратып тыңлаучы хөрмәтле ата-аналар, әби-бабайлар, балалар! Радио тыңлаучыларның сорауларын истә тотып, «Сабыйга» тапшыруларын дәвам итәргә булдык. Алдагы тапшыруларыбыз татар балалар әдәбиятына багышланган иде, ә монысы исә балалар өчен бик тә зур әһәмияткә ия булган балалар фольклоры турында булыр.

Балалар фольклоры – башлыча, балалар арасында киң таралган үз традицион авыз иҗатлары, уенлы җыр-көй, биюләр, шулай ук аларга зурлар тарафыннан багышлап чыгарылган халык авыз иҗаты әсәрләре ул. Хәтта галим Нәкый ага Исәнбәт балалар фольклорын үзенә аерым жанр авыз иҗаты итеп караган һәм аны махсус җыю, системага салу эшен башлап җибәрүчеләрнең берсе. Ул шушы жанрга караган үрнәкләрне туплап, «Балалар фольклоры» исеме астында дүрт җыентык чыгара. Үземнең чыгышларымны Н. Исәнбәтнең 1984 елда чыккан «Балалар фольклоры» китабындагы язмаларга таянып эшләдем.

Тирәннәнрәк уйлап карасаң, балаларның телен, зиһенен ачуда, хәтерләрен баетуда, күңелләрен күтәрүдә, җитезлек, тапкырлык сәләтен үстерүдә әлеге жанрның бик зур әһәмияте бар. Шуны истә тотып, халкыбыз, элек-электән тәрбияне, туган телгә нигезне, мәхәббәтне бала тууга ук бишек җырларыннан башлаган. Бишек җырына, бала уянгач әйтелә торган назлы сүзтакмаклар, тел ачтыру такмаклары өстәлгән. Ә алга таба, бала үсә төшкәч, аның үз дөньясы башлана. Туганнары, дуслары арасына керүгә, аның репертуары тагын да баеган. Зиһенлеләр иҗат итсә, калганнары отып алып, бер-берсенә өйрәткәннәр.

Без үскән вакытларда, балалар фольклоры үз көчендә иде әле. Уеннар күп иде. Качышлы, әбәкле уеннары санамышларсыз, такмакларсыз булмый да булмый. Җәйге җылы кичләрдә, капка төбендәге бүрәнә өсләренә тезелешеп утырып табышмаклар әйтешү, әкият, алдавыч әкиятләр сөйләү, такмаклар,

такмазалар әйтешү үзе бер тел дәресләре булган. Мәктәп тәнәфесләрендә күмәк җырлы әйләп-бәйләп уеннары, каршы сафларга тезелеп җырлап уйнаулар бүгенгедәй күз алдында. Хәзерге заман балалары өчен бу уеннар тарих кына булып калмас микән? Балаларыбыз өчен зур мирас булган әлеге жанрны саклау, өйрәтү, тулыландыру – без-өлкәннәрнең, ягъни әти-әни, әби-бабаларыбызның төп бурычы икәнен онытмасак иде.

2. Бишек җырлары

Бүгенге чыгышымны «Бишек җырлары»на багышларга булдым.

Бишек җырлары – баланы йоклату өчен бик яхшы чара. Алар иркәләүче, тынычландыручы көй-моңнарга салып әйтелә. Әни-әбиләр әлеге көй-моңнарга салмак кына итеп рифмага, ритмга салып үз теләкләрен, фикерләрен җиткергәннәр. Бала сөйләшергә өйрәнгәнче үк, туган телендә иң назлы сүзләрне ишеткән, туган теленең аһәңен тойган. Бишек җырын күбрәк ана кеше җырлаган, көйләгән:

Әлли-бәлли итәр бу, йокыларга китәр бу.
Бәү-бәү итеп, күз йомып, изрәп кенә китәр бу.
Ал бишеге бар аның, гөл бишеге бар аның,
Өзгәләнеп тибрәтергә, үз әнкәсе бар аның.
Әлли-бәлли, бәбкәем, җан йөрәгем, нәнкәем,
Рәхәт кенә тыныч лап, йоклап китәр бәбкәем.

Малайга – бер, кызларга икенче төрле җыры булган әни кешенең. Малайларны тирбәткәндә, аларның батыр, укымышлы, эшчән, әтисенең ярдәмчесе, туганнарының таянычы, ил сакчысы булуына ишарә ясала.

Әлли-бәлли итә бу, йокыларга китә бу,
Йоклап торгач, зур үсеп, укуларга китә бу.
Әлли итәр бу бала, бәлли итәр бу бала,
Әткәсенә, әнкәсенә, хезмәт итәр бу бала.
Әллүк-әллүк итә ул, йоклап кына китә ул.
Үсеп буйга җиткәчтен, армиягә китә ул.

Кыз баланың матур, назлы, уңган-булган булуына басым ясала, яхшы кияү насыйп булсын иде дигән теләк тә теләнә.

Кызым-кызым кыз кеше, кызыма килгән йөз кеше.
Йөз кешенең арасыннан сайлап алыр бер кеше.
Йокла, кызым, йокла, кызым. Йокла кызым, йом күзең.
Үсеп матур кыз булганнан соң, кияү табарсың үзең.

Бала багу әбиләр өстенә дә төшкән, чөнки элек заманнарда ана кешегә озаклап бала багарга туры килмәгән. Гаиләдәге кимендә 6–7 баланы карау әбиләр өстендә булган. Бала карау бик четерекле, шул ук вакытта тынгысыз һәм бик җаваплы авыр хезмәт ул. Юкка гына, бер мәзәктәгечә, бер әби, ожмахка керер алдыннан куркып кына: «Анда да бала каратмыйлармы соң?» – дигән сорауны бирмәгәндер.

Әлли итәр бу бала, бәлли итәр бу бала.
Бу баланы бага-бага башым булды пумала, –

дигән бишек җырын да әбиләр ижат итмәдеме икән? Әмма, балам баласы балдан татлы, шул!

Әлли-бәлли итәргә ал бишеге бар аның,
Алдына алып йоклатырга үз әбкәсе бар аның.
Әлли-бәлли, күз нурым, сандугачым-былбылым.
Әниең кайтса, тук булырсың, сабыр итеп тор, улым.
Атаң кайтыр – бал бирер, анаң кайтыр – май бирер,
Ул майларга туярсың, җылавыңны куярсың.

Халкыбыз әнә шулай итеп баланы бишектән үк матур сүзләр әйтеп, изге теләкләр теләп, матур киләчәк юрап тәрбияләргә тырышкан. Ни чәчсәң, шуны урырсың, ди бит халык. Чәчкәнебез изгелек, яхшылык булсын иде.

«Бишек җыры».

3. Суы сарыксын, үзе калыксын!

Бүген мин сезне бала коендыру, бала юындыру вакытында нинди теләкләр теләнгәнен, нинди такмаклар әйтелгәне турында бераз сөйләп китәрмен. Элек баланы беренче булып кендек әбисе мунча керткән. Аның моңа җитәрлек тәжрибәсе дә, осталыгы да булган. Хәзерге вакытта яңа туган яшь баланы больницадан кайтуга ук мунча кертергә, чабындырырга кушмыйлар. Ә элек кендек әби беренче мунчада ук бәбине алдына салып себерке белән чапкан һәм болай дип такмаклаган:

«Атаң кискән утын түгел, анаң яккан мунча түгел. Аюдай ага бул, бүредәй бөгә бул. Аю баласы, бүре баласы, мунча ташы, бүрәнә башы. Картны күрсәң, бабай диген, яшьне күрсәң, абзый диген, җиңги диген. Тәмле-татлы телле бул!

Атаң ташы түгел, мунча ташы. Минем кулым түгел, Әйшә батманның кулы! Минем телем түгел, Идел кичкән инәкәләр теле. Кәбестәгә су салдым, суы сарыксын, үзе калыксын! Ят та йокла, тор да уйна!»

Гадәттә, бала чабындыру өчен каен себеркесен кулланганнар. Чөнки каен себеркесе иң шифалы себеркеләрдән санала. Ул тән тиресен шлак һәм токсиннардан арындыра, тирене нәфисләндерә, барыннан да бигрәк массаж ролен үти. Каен себеркесе шулай ук мунча һавасын чир таратучы бактерияләрдән дә чистарта.

Баланы юындырган саен үсә, диләр. Яшь баланы кимендә көнгә бер тапкыр таска салып юындыру, коендыру кирәклеген әйтәләр. Баланы юындырганда да теләк теләп такмаклаганнар.

Кәбестәгә су салдым, суы сарыксын, үзе калыксын.
Имәндәй таза булсын, җитендәй озын булсын.
Ябалактан йон ал, бүдәнәдән май ал.
Кәбестәдән аклык, судан пакълек.
Баламнан килер дөньяга шатлык.

Икенче берсе болай ди:

Үс-үс итә, балам үсеп тә җитә.
Бүдәнәдәй тулчыл бул, үр куяныдай күзле бул!
Адәм тапмас сүзле бул!
Коенганың Идел суы, йөрер юлың атаң юлы.
Торыр җирең бабаң җире.
Сайрар телең – анаң теле.
Карышма да, тибешмә дә.
Яңа кердең инешкә.
Киерелгәндә киртә буе,
Сузылганда солы буе бул. Үс, үс. үс!

Әнә шулай матур сүзләр белән, изге теләкләр, саф су белән пакъләнгән бала ничек начар булып үссен ди!

4. Үс, үс, балам!

Бүген мин сезне, хөрмәтле радио тыңлаучылар, баланы йокыдан уяту, уянгач такмаклар әйтеп баланы йокы дөньясыннан көндәлек тормышка кайтару өчен халкыбыз иҗат иткән мирас белән бераз таныштырып китәрмен.

Бишектәге бала йокысы туеп уянса, бераз тын ята әле. Ыгы-быгы килгән була, уянганын белгертеп, бишеген тибрәтеп ала. Шул вакытта аның янына әнисе яки әбисе килеп, аны киерелдереп, үс-үс иттерә, аяк-кулларын хәрәкәтләндерә.

Казлар канат бирсен, торналар аяк бирсен, бүдәнәләр май бирсен, ябалаклар йон бирсен, балам зур үссен! Үс-үс-үс!

Тор-тор, тургай, таң-таң ата бугай.

Тургай, кил, чыпчык, чык, чырык, чырык, чырык! –

дип такмаклап кулына ала сабыен. Шуннан соң үчтеки-үчтеки дип, баланы сикертеп ала. Болар, гади генә әйткәндә иртәнге гимнастика ролен үти.

Үчтеки-үчтеки, үсмәгәнгә кечтеки,

Үсә-үсә зур булыр, бигрәк матур кыз булыр, яки

Илдә-җирдә бер булыр, бер дип әйткән ул булыр.

Үчти-үчти сикерсен, каймак ашап кикерсен.

Әткәсе магазиннан бер шалтыравык (ягъни уенчык) китерсен.

Әнә шулай бераз бала белән аралашып алганнан соң, астын алыштырып, юындырып, тамагын туйдыралар. Бу эшләрне эшләгәндә әни яки әби кеше бала белән аралашуын, сөйләшүне дәвам иттерә, сүзсез процесс түгел бу. Бераздан баланы алга утыртып (монысы инде балага 6–7 айлар тулгач), чәбәкәй иттерү, деңки-деңки иттерү, ягъни тез өстенә утыртып сикертү кебек бала өчен күңелле уеннар да була.

Чәбәк-чәбәк чәбәкәй, минем кызым (яки улым) бәләкәй. Бәләкәй булса да ни кәләкәй (ягъни калека, үсми калган түгел, русчадан).

Чәбәк-чәбәк әткәсе, биетеп тора әнкәсе, такмак әйтә апасы, авызын-күзен мимылдатып карап тора әбкәсе.

Нәни кызым нәнкә күк, кечкенә генә тәңкә күк.

Алма, алма, алма күк, кечкенә генә салма күк.

Тез өстендә сикерткәндә, мондый такмаклар әйтелгән.

Деңки-деңки кызым бар, алты басма җебем бар.

Яучы килсә, миңа килсен, бөдрә чәчле кызым бар.
Деңки-деңки денләнсен, моны кызлар өндәсен.
Бу бармасын, назлансын, кызлар эче ут янсын.
Әтисенә ай кебек, әнисенә көн кебек,
апасына гөл кебек, әбисенә туп кебек, бабасына ут кебек.
Килеп киткән кешеләргә чүп кадәр дә юк кебек.

Бераз үсә төшкәч, «Күккү-чыпчык» уены, ике кулыннан тотып аякка бастырып тибрәтү кебек, ягъни таган атыну уеннарын әти кеше, бабай кеше өйрәткән һәм уйнаткан. Соңгысы баланың гәүдә тотрыклылыгын ныгыту өчен бик кулай булган.

Мәрьям Рахманкулова «Бала уйнатканда» җыры.

5. Топ-топ баса, туры китереп баса

Бүген без баланы тәпи йөрергә, биергә өйрәткәндә әйтелә торган такмакларга тукталырбыз.

Гадәттә, бала кешесе бер яше тулганда тәпи атлап китә. Кайбер балалар хәтта 8–9 айдан да йөри башлый. Халыкта баланың тәпи атлап китүе зур куаныч, сәламәтлек билгесе булган. Шуңа күрә беренче булып баланың тәпи атлап киткәнен, беренче теше чыкканын күргән кеше аңа бүләк алып бирергә тиеш булган. Бу хәзер дә шулай.

Гадәттә, бала гәүдәсен тота башлагач ук култык астыннан тотып бастырып карыйлар, аннан тәпи атлатып, әкренләп йөрергә өйрәтү башлана. Бу йөрергә өйрәтү күнекмәсе генә түгел, бәлки баланың сәламәтлеген, бигрәк тә аякларның ныклыгын тикшерү, аннан соң балада кечкенәдән үк ихтыяр көче тәрбияләнүенә дә йогынты ясый. Бала курыкмаска өйрәнә.

Элек баланы тәпи йөртергә өйрәткәндә, менә мондый такмаклар әйткәннәр.

Яле, кил әле, кил әле. Килә аласың микән әле.
Камыт аякларың белән баса аласың микән әле.
Текер-текер йөресен, тигәнәк моңар тимәсен.
Күп кешеләр моны сөйсен, күз дә моңар тимәсен.
Топ-топ атлап китә бу, ышкафларга җитә бу.
Тәп-тәп йөреп зур булгач, мәктәпләргә китә бу.

Озак вакыт тәпи йөри алмаган балага мондый такмак әйткәннәр.

Дүртаяк, камыт аяк, кыргаяк.

Тегәрҗеп муен, төймә баш, ник йөрмисең, карлыгач?

Тәпи китмәгән балага, язын торналар яки башка кошлар тәпи алып килер дип юрау, ышану, ә көзен йөреп китсә, торналар тәпиләрен калдырып китте, дип сөенүләр бар.

Бала тәпи йөри башлагач, аның мәшәкате дә арта, әмма бу күңелле мәшәкать! Ул актарына, теләсә кая үрмәли, көтелмәгән эшләр эшләп ташлый. Мондый вакытта баланың игътибарын башкага юнәлтү, аңа файдалы шөгыль табу кирәк. Баланы биетү – шуларның берсе. Такмак әйтеп, кул чабып торганга кайсы бала гына биеп китмәс.

Әттә түдер түдәме, гармунчыгыз өйдәме?

Өйдә булса, килсен әле, биетеп китсен әле.

Топый-топый топ баса, киндер куныч, йон табан.

Тыпыр-тыпыр биидер, аягы җиргә тимидер.

Очкан коштай талпынып, канатларын кагынып, һап-һап!

Биесен лә биесен лә, биек тауга менсен лә!

Нәзек итек кисен лә, кызлар моны сөйсен лә!

Балам бии багыгыз, кесәгезне кагыгыз.

Кәнфитегез булмаса, магазиннан алыгыз!

Хөрмәтле әти-әни, әби-бабайлар! Сез нинди такмаклар әйтеп биетәсез нәниләрегезне? Әллә алар телевизордагы заманча көйләргә генә боргаланалармы?

6. Тел ачтыру, тел шомарту

Бала кешесенең бер яше тулганда, сүзлек запасы шактыйга җыела. Бала белән күбрәк, ешрак аралашкан саен аның теле шулкадәр иртәрәк ачыла. Баланың беренче сүзләре мәммәм һәм әннә! Әмма кайбер балалар башлап әттә, баба, әббә сүзләрен дә әйтергә мөмкин. Шундый сынамыш та бар: бала әннә, әббә, апа сүзен башлап әйтсә, үзеннән соң кыз бала сорый, ә ир женесеннән булган кешеләрне атаса, алга таба ир бала туачак, имеш. Бала кешесенең беренче сүзләрен, аның сөйләмен якыннары – әти-әнисе, әби-бабасы, апа-абыйсы гына аңлый әле.

Сөйләшергә өйрәтүчеләр дә алар.

Әт, әт-тә дип әйт, әтәч койрыгын бирем.

Ән, ән-ннә дип әйт, әлбә бирем.

Ап, ап-апа дип әйт, ак алма бирем.

Әп, әп-әби дип әйт, әфлисун бирем.

Тешеңә йомшак булыр.

Егет, егет икәндер, бүрке бәрхет икәндер.

Бу егетнең һәрбер сүзе, шикәр-ширбәт икәндер.

Инде сөйләшә башлагач, кайбер балаларның авазларны, сүзләрне дөрес әйтмәве билгеле була. Хәзер андый балалар белән махсус белемле логопедлар шөгыльләнә. Ә элек, бигрәк тә авыл җирләрендә, логопед сүзен ишеткән кеше дә булмагандыр, мөгаен. Шунлыктан мондый балага халык үзе, халык авыз иҗаты ярдәмгә килә. Тел төзәткеч, тизәйткеч яки тел көрмәкләндергечләр ярдәмендә бала телен шомарткан.

Хәзерге заман балаларының шактые х, һ, къ, гъ, в авазларын дөрес әйтми. Бигрәк тә һ авазын х белән бутау еш. Һ – йоткылык авазы, ягъни йоткылыкта ясала. Фән телендә ул фарингаль (латинча – йоткылык) тартык дип йөртелә. Ә х авазы кече тел тартыгы, ягъни увуляр тартык. Ясалу урынына карап та аерманың зур икәне күренә, әмма балалар гына түгел, зурлар да бу авазны бутый. Халкыбыз бу авазларны дөрес әйтүгә игътибар иткән һәм менә мондый тел төзәткечләр иҗат иткән.

Хава (кыз исеме) чыкмый һавага, аңа һава алама.

Белмим һава гаепле, белмим Хава гаепле.

Һәммә ялкау гамәлсез һәм һөнәрсез, һәм гамьсез.

Мондый мисалларны күплән китерергә мөмкин.

Һ авазы татар теленә генә хас аваз түгел. Немец, инглиз, фарсы телләрендә дә бу аваз кулланыла.

Тизәйткечләр дә телне шомарта. Аларны кат-кат әйттерергә кирәк. Мәсәлән.

Такта какма, капка как. Капка какма, тотка как!

Бүрәнәгә басты бүдәнә. Бүдәнәне басты бүрәнә.

Гаеп бүрәнәдә дә бар, бүдәнәдә дә бар.

Балачакта **тел көрмәкләндергечләр** әйтеп ярышуыбыз истә әле. Кем бер ялгышмыйча әйтә ала: шул җиңүче. Биремнәр җиңелдән катлаулыга бара иде. 3–4 сүзлене кем дә әйтә, ә син менә озын көрмәкләндергечләр әйтеп кара! Ә тел

көрмәкләндергечләрне китаптан карап әйтми берсе дә, чөнки һәр баланың хәтер сандыгында берничә мисал була иде.

Иң киң таралганы – моны һәммәбез дә белә.

Мич башында биш мәче, биш мәченең биш башы.
Биш мәченең биш башына ишелмәсен мич ташы.

Ә менә монысын ялгышмыйча әйтеп кара!

Караңгыга каргандың ни, карганмадың ни! Караңгыда каргангаңа караганда, карганмаганың, карганмаганыңа караганда карманганың яхшы. Караңгыда каргангачы карганмыйча карманганың күп артык. Караңгыда карганырга, карманырга калдыңмы?

Бу әле зиһенне баету да. Монда өч сүзнең аермасын белергә кирәк: караңгы, каргану, карману. Шуларны аера алсаң, бер авырлыгы да юк. Әнә шулай тел һәм зиһенне үстерү, сүзлек запасын баету процессы алга таба балаларның үзара аралашуы нәтиҗәседә байый, тулылана бара иде.

7. Бала һәм әйләнә-тирә табигать

Бала кешесе тәпи атлап китүгә, табигать баласына әйләнә. Әле баштарак аның төп биләмәсе ишек алды, капка төбе булса, әкренләп бала урамга – иптәшләре, яшьтәшләре, гомумән, балалар коллективына барып кушыла. Балалар, бигрәк тә авыл балалары – алар табигать балалары. Бергәләп күмәк уеннар уйнау, елга яки күл буенда су коенулар, балык сөзүләр, әрәмә яки урманга барып ашарга яраклы үләннәр, җиләк-җимешләр җыю, әти-әнигә йорт эшләрендә ярдәм итү, печән, урак өсләрендә печән җыю, олыларга ашарга илтү, кич, көтү кайткач, болында сыер саклап ашату – болар барысы да авыл баласының даими шөгыле.

Авыл балалары фольклорны яхшы белә иде элек, белү генә түгел, ярата иделәр. Алар арасында оста такмакчылар, тапкыр сүзлеләр, әкият сөйләү осталары була иде. Җәй көне көтүләр кайтып, мал-туар абзарларга ябылгач, көне буе эшләп арыган өлкәннәр кыска җәйге төннең кадерен белеп, йокларга

ята, ә бала-чага, яшь-җилкенчәк өчен җәйге кичләр, төннәр – уен-көлке, җыр-бию, төрле «этлекләр» эшләү вакыты. Менә шушы вакытта 7–8, 10–12 яшьлек балалар төркемләшеп берәр капка төбенә яки аулаграк урынга җыелып, табышмак, такмаза әйтешә, укылган китапларның эчтәлеген яки куркыныч, шомлы әкиятләр сөйләү башлана. Язучы **М. Мәһдиев**нең **«Торналар төшкән җирдә»** повестен укымаган кеше сирәктер. Язучы үзенең балачагын искә алып, нәкъ шушы моментларны яратып тасвирлаган. Шуннан бер өзек китереп китәм.

«Безнең күрше Зөлфиягә дүрт класстан артык укырга туры килмәде. Менә ул укып күрсәткән булыр иде. Бу кызда, белмим, нинди генә талантлар ачыла алмыйча, сүнеп-күмелеп калды икән? Әгәр безнең авылда безнең буын балалары әдәбиятны, фольклорны яратып үскәннәр икән – моның белән без, беренче чиратта, Зөлфиягә бурычлы.

Һәр кичне (ул бигрәк тә көзге якътагы караңгы кичләрне ярата иде) Зөлфияләр капка төбенә җыелабыз. Шунда, караңгыда безнең өчен дөньяның иң серле, иң куркыныч, иң кызыксындыргыч капкалары ачыла... Зөлфия, каян тапкандыр, шул елларда ук (1938 еллар тирәсе) «Совет әдәбияты» журналын укып барган икән. Зөлфия караңгы кичләрдә безгә сөйләгән хикәяләр барысы да шул елларда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында басылганнар икән. Мондый реалистик әдәбият дәресләре көзге караңгы кичләрдә еш кына коточкыч фольклор әсәрләре белән чиратлаштырып алып барыла иде. Зөлфия сөйләгән әкиятләрдә әллә нинди куркыныч моментлар була иде һәм һәр кичне берничә бала шул куркыныч моментны сөйләгәндә дерелдәп урыннарыннан сикереп тора да, йомылып, өенә йөгерә иде. Әмма шул ук бала икенче кичне тагын Зөлфияләр капка төбенә килеп утыра һәм әкият көтә иде».

Һәр авылның әнә шундый Зөлфияләре була иде. Хәзер исә Зөлфияләрне телевизордагы күп сандагы ужастиклар, боевиклар, монстр, зомбилар белән шыплап тулган куркыныч фантастик фильмнар алыштыра. Гаҗәп, балалар шундый фильмнарны кәрарга гадәтләнеп баралар. Мин үзем, мәсәлән, андый фильмнарны бөтенләй карый алмыйм. Йөрәкне сандыкка тиңлиләр. Ул сандыкны кечкенәдән куркыныч вакыйгалар белән тутырмаска иде.

8. Чакырулар

Бала кешесенә һәр ел фасылы матур, рәхәт, күңелле! Һәрберсен сагынып көтеп аласың. Кышын чаңгыда шуасың, кардан төрле корылмалар төзисең, кар атышлы, кала алышлы уеннары үзе генә дә ни тора! Таудан чана шуу дисеңме тагын! Үз чанаңа утырып шуу гына җитми, ат чанасына төялеп аска шуып төшкәндә адреналин дигәнең үзеннән-үзе бүленеп чыга! Андагы чыр-чу, андагы рәхәтлек! Язы да, көзе дә шулай уен белән, эш белән, кызыклы ачышлар белән үтә иде. Иң рәхәте җәй булгандыр, мөгаен. Озын каникуллар, тәннәр күгәреп беткәнче су коенулар, урман-әрәмәдән кайтып кермәү, балык тотулар, печән өмәләрендә, басу-кыр эшләрендә ярдәм итеп, китап-дәфтәрлек акча эшләүләр... Матур, җылы, кояшлы көннәрдә бала-чага өйдә утырмый, аларның урыны – урамда. Кояш болыт арасына кереп качса, балалар шунда ук кояшны чакыра башлый:

«Кояш, чык-чык-чык. Майлы ботка бирермен. Майлы ботка казанда, тәти кашык базарда. Әти кайткач базардан, ботка төшәр казаннан.

Кояш, чык! Аяз, ач, болыт кач! Без уйнарбыз җылыткач.

Эт кояшы кит-кит, тәти кояш, кил-кил. Көмеш кашык бирермен. Көмеш кашык базарда, сыерыбыз абзарда. Сөтен савып алырбыз. Казаннарга салырбыз. Пешерербез ботка, калдырырбыз болытка! Каплама кояшны, кайт өеңә, яшә үз көеңә!»

Әнә шулай кояшны чакыра балалар хор белән. Кояш чыкса, сөенүнең чиге юк! Кайвакытта бик кыздыра башлый, яңгырлар яумый. Игеннәр, үләннәр яңгыр көтеп тилмерә. Авыл кешесе мондый вакытта пошаманда. Ачлык килмәсен, балаларыбыз, халык ачтан интекмәсен, ипекәйләр булсын иде ди. Авыл баласының да психологиясе зурларныкы кебек. Ул ипинең агачта үсмәгәнен белә!

Мондый вакытта өлкәннәр балаларга яңгыр теләргә куша. Бала кешесе гөнаһсыз, сезнең теләкләр тизрәк кабул булыр, диләр. Монда да һәр авыл баласының үз репертуары бар.

«Яңгыр яу, яу, яу! Сине көтә җир, җир! Безгә күмәч бир, бир!

Яңгыр яу, яу! Иләктән, чиләктән, пәрәмәчтән, коймактан, арпадан, бодайдан, эшләр китәр уңайдан!

Яңгыркаем яу, яу! Ачтан халык үлмәсен! Үләннәр дә күп булсын, сыерлар да тук булсын, безгә эчәргә сөт булсын!

Яңгыр яу. яу, яу! Ашлык уңсын ызанда, ботка пешсен казанда. Алтын кашык базарда, көмеш кашык болытта, нык яварга онытма!»

Кояш кыздыра башлауга, бала-чага су буена сибелә. Суга чумганда, мондый сүзләр әйтелә:

«Аруым, аруым, авызым тулы даруым. Арулыгым, пакълегем, исәнлегем, саулыгым. Тән керемне суга салдым, үзем судан пакъ калдым».

Су буенда, аулаграк урыннарда кармак салып балык тотучы малайлар утыра. Аларның да үз такмаклары, ырымнары бар:

«Балык кап-кап, яр буенда ялтырап ят.
Төкереп салдым, сикереп кап.
Яр башында ялтырап ят,
Ялтырамасаң, калтырап ят!
Әфсен-төфсен, балык капсын!
Яр буенда ялтырап ятсын!»

«Яки, чирт, чирт, чирттермә бирем. Батыр, батыр, батыргыч бирем. Эләк, эләк эләктермә бирем. Кап, кап, каптырма бирем».

Әнә шулай үтә җәйләр. Кызыклы, файдалы һәм күңелле!

(Җәй турында балалар җыры).

9. Камка, ала карга

Авыл баласы вакытын уен белән генә уздырган дисәк, бик ялгышабыз. Уенын да уйнаган, яшьтән үк эшкә дә тартылганнар алар. Яшенә карап һәр балага нинди дә булса эш йөкләтелә. Зурлар кечкенәләрен караган, өйдә, йорт-җирдә әти-әнигә булышкан. Кечкенәләр, кимендә 6–7 яшьтән башлап, бәбкә, чебеш саклаганнар. Каз бәбкәләрен, сап-сары йомгактай тәгәрәп йөргән чебиләрне ала карга, тилгән дигән мәнсезләр карап кына тора. Бераз гына уяулыгыңны югалтсаң да, бәбкә яки чебиеңнән колак кагасыңны көт тә тор. Ә моның өчен әти-әни алдында җавап тотасы да бар! Һавада тилегән күренсә, аны саклаучы бала кычкырып такмак әйтә:

«Тилегән, тилегән, бер аягы тимердән, бер аягы камырдан. Көш, көш, көш!

Тилегән, тилегән, атаң сиңа ни дигән? Бәбкә урлама, дигән. Бер күзеңә яфрак, бер күзеңә туфрак. Көш, көш, көш!

Ала карга күренсә дә такмак әзер.

Ала карга, ала карга, ни калган сиңа монда?! Ук-җәямне алырмын, канатыңа атармын, төшерсең кадалып, ятарсың кычкырып! Яхшы чакта кит! Көш, көш, көш!

Карга, тилгәннәр күренми торган арада, бала кешесенең игътибары канатларын җәеп үләнгә яки чәчәккә килеп кунган камкага юнәлә яки үзе үк кул сыртына килеп куна. Без балачакта камкага көйләп мондый такмак әйтә идек:

«Фатыйматтәй, киявең килгән, туныңны ки дә чыгып кач!

Яки, камка кач, камка, кач! Киявең кайта, капкаң ач! Капкаңны ач та үзең кач!»

Ни хикмәт, шул сүзләрне әйткәч, камка ике катлы һәм ике төстәге канатларын ачып очып китә иде.

Әнә әкрен генә үләп сабагы буйлап әкәм-төкәм шуыша. Үзенә куркыныч янавын сизсә, әкәм-төкәм мөгезләрен кабырчык эченә яшерә һәм туктап кала. Менә шул вакытта әкәм-төкәмгә якынрак киләсең дә, көйләп:

«Әкәм-төкәм, мөгезең чыгар, сөтле сыер бирермен. Сөтле сыер яратмасаң, ак төкерек бирермен, ак төкерек яратмасаң, мөгезеңә чыбык бирермен».

Чыбык очына төкерек саласың да әкәм-төкәмгә якын китерәсең, шулай иткәч, ул мөгезләрен чыгара.

Әнә сикерә-сикерә чикерткә килә. Баланың моңа да такмагы әзер:

«Чикерт-чикерт чикерткә, сине нәрсә сикертә? Сайрый белми сайрыйсың, бертуктамый кич-иртә. Бер сикердең – котылдың, ике сикердең – котылдың. Өченчесендә – тотылдың! Һап!»

Әмма әби-бабайлар, әти-әниләр җан ияләрен рәнҗетергә кушмыйлар. Тимәгез, җәфаламагыз, җибәрегез, диләр. Аларның да яшисе килә, диләр. Хәтта тик утырганда, үләнне йолкысаң да әрлиләр. Менә үзеңнең чәчеңне йолкысаң, рәхәт булырмы, диләр! Монысы да тәрбия!

10. Санамышлар, хәрәкәтле уеннар

Карлар эреп, тау башында җирләр ачыла башлауга, балачага шунда җыела. Малайларның үз уены. Алар кызып-кызып җир алышлы (пәке кадашлы дип тә атала) уйный. Кызлар сызыклы уйный (аны классики дип тә йөртәләр). Безнең Мөслим ягында сызыклы уены классики уеныннан шактый аерыла иде. Монда искиткеч төгәллек, сабырлык, гәүдә тотрыклылыгы зур роль уйный. Сызыклы уйнагычны (ул, гадәттә, «Любимый» кремыннан яки ваксадан бушаган савыт була иде) бер аякка аксаклап, сак кына икенче шакмакка күчерергә кирәк. Сызыкка тисә, беттең саналасың. Уенны икенче бала дәвам итә. Бер дә бетмичә соңгы шакмакка барып җитсәң, дама буласың, ягъни җиңүче. Ә дама буласы бик килә!

Скакалкада сикерүнең (бау сикерешле) нинди генә вариантлары кулланылмый иде. Аксаклап, кушаяклап сикерү, бии-бии сикерү – ничекләр генә сикерми идек. Хәзер мәктәптә укучы балалардан сорап карыйм да, физкультура дәресендә әзрәк сикереп караган бар, диләр! Нинди канәгатьлек хисе кичерүдән мәхрүм икәнсез, дип куям эчемнән генә.

«Чокыр туплы» уены бик яратып уйнала иде. Бу инглизләрнең гольф уеныныа охшаш уен. Тик тупны таяк белән түгел, кул белән тәгәрәтәсе. Ул чокырга керсә, сиңа бер очко. Монда да төгәллек, сабырлык, юнәлештән тайпылмау таләп ителә.

Әбәкле, качышлы уеннары санамышларсыз булмый. Нинди генә санамышлар юк иде безнең запаста. Балалар бигрәк тә уен-көлке, юморга бай санамышларны кулланырга ярата.

«Алдат, болдат, тәңкә чыңлат. Чыңлый-моңлый, тырт!

Аладан, боладан, песи бара колгадан. Койрыгын төйнәгән, балаларын төягән. Шул песине тотыгыз, көйрыгын кысыгыз. Койрыгы чишелде, балалары ишелде.

Бер, ике, өч, дүрт... ун, байлар кия каткан тун. Каткан тунның бәясе йөз дә кырык ике сум.

Берәм, икәм, өчәм, әкәм-төкәм, чикерткә, китеп тор син бер читкә. Камка, карга, чыпчык, син калып тор, ә син чык!»

Балалар уеннары гадел булырга тиеш. Хәрәмләшү бер дә хупланмый. Хәрәмләшергә яратучыны уенга катнаштырырга тырышмыйлар. Җиңелгәч елаган балага да такмак бар.

«Җылак-җылак, җылкы колак. Карама таяк, карт әтәч!

Җылак-җылак җылкыткан, җылап кеше куркыткан.

Уенда җиңелеп яки берәр сәбәп белән өенә кайтып әләкләшеп йөргәннәр дә өлешсез калмый.

Әллүкәй-бәллүкәй, безнең Шакир бәләкәй. Бармак белән тисәң дә, әтисенә әләкләй.

Әләкче-әләкче, әнә бара бер мәче. Мәчесе мияулый, елак яшьләрен ялый».

Әле соңгы җөмләне тупасрак итеп әйтүчеләр дә була. Шуннан соң елап, әләкләшеп кара инде.

Әнә шулай итеп балалар бер-берсен тәрбияли дә! Чынлап та, балалар уеннары – тәрбия чарасы дип юкка гына әйтмиләр шул!

11. Тап, табышмак!

Табышмак яратмаган бала бар микән? Кайсы аны әйтергә, икенчеләре табарга ярата. Балалар үзләре дә табышмаклар иҗат итәргә ярата. Бала гына дисәң дә, алар әйткән табышмакның җавабын өлкәннәр күп кенә очракта таба да алмый әле. Табышмаклар кечкенә булсалар да төш кенә! Алар зиһен байлыгын арттыра, ягъни уйларга, җитез фикер йөртергә өйрәтә. Табышмак текстында охшашлык һәм уртаклык төшенчәсе бергә килә. Җавапны шушы охшашлыклар һәм уртаклыкларга нигезләп табарга гына кирәк. Әмма табышмакның җавабы бер генә булырга тиеш.

Элек табышмаклар әйтешү бик популяр булган. Капка төбенә җыелган балалар арасында дисеңме, кич утырганда, аулак өйләрдә дисеңме... Чөнки табышмак, фольклорчы Нәкый Исәнбәт әйткәнчә, «күмәк эчендә берең әйткәннең мәгънәсен икенче кешедән таптыру өчен генә башкарыла торган фольклор (ягъни ул җыр кебек ялгыз гына үтәлми, көйләп тә әйтелми». Үз-үзеңә табышмак әйтеп, җавабын да үзең табып утырмыйсың бит инде. Димәк, табышмак әйтешү өчен кимендә ике-өч кеше кирәк. Табышмакларның күбесе авыл җирләрендә туып, авылда сакланган. Шуңа күрә табышмакларның эчтәлеге күбесе игенчелек, табигать, авылның тормыш-көнкүрешен чагылдыруга багышланган. Табышмакларның тагын бер әһәмиятле үзенчәлеге бар: алар сурәтләү чараларына, телбизәкләргә бик бай. Мәсәлән,

охшату – чагыштыру, омонимнар, метафоралар, гипербола, синекдоха һәм башкалар. Мәсәлән, омонимнар (адаш сүзләр) кулланылган табышмак.

Һәммә татарның өендә бар, үзе дөньяда бер генә. Ул нәрсә? Җавабы – Казан.

Үзе актай, корсагы каптай (кәҗә). Нигезендә охшату ята.

Үзе шардай, эче кандай, тәме балдай (карбыз) – чагыштыру.

Табышмакларның тапкыр җаваплы табышмаклар дигән төре дә бар.

Мәсәлән, сыер нигә ята? – Утыра алмаганга.

Табышмак сүзен ничек укырга кирәк? – Сулдан уңга таба.

Урманга нәрсә белән баралар? – Юл белән.

Табышмакларның логик фикерләүгә нигезләнгәннәре дә күп. Андыйларын хәзер башлангыч класс балаларының дәреслекләрендә күпләп күрергә мөмкин. Беркөнне үземә дә шундый табышмак әйттеләр әле. Ун йомырка булган. Шуның өчесен ватканнар, өчесен пешергәннәр, өчесен ашаганнар. Ничә йомырка калган? Сезнеңчә ничек?

Борынгы табышмаклар, җырлы-җаваплы табышмаклар дигән төрләрен дә китерә Нәкый Исәнбәт үзенең җыентыкларында.

Бер тирәк, унике ботак, һәр ботакта дүрт чыпчык, һәр чыпчыкта җиде яфрак, һәр яфракның бер ягы ак, бер ягы кара (ел, ай, атна, көн-төн).

Җанлыдан җансыз туа, җансыздан җанлы туа (тавык, күкәй, чебеш).

Алты аягы бар – Алып түгел. Дүрт күзе бар – дию түгел.

Аркасында кылдан җебе бар, эрләп суккан җебе түгел. (Үрмәкүч).

Заманга карап табышмакларның да эчтәлеге үзгәрә. Хәзер аларның җаваплары компьютер, телевизор, смартфон, планшет һ.б. ш. техника, үсеш белән бәйле.

Балаларның зиһеннәрен үстерү өчен табышмаклар бик файдалы. Балаларыгызга табышмаклар әйтергә тырышыгыз. Менә сезгә уйланырга бер табышмак.

Казанда пешми, табакка төшми, аны ашамаган үсми (күкрәк сөте).

12. Җиләк җыям, как коям

Җәй әле ул җиләк-җимеш җыю вакыты да. Кышка әзер витамин бит ул җиләк-җимеш. Әлбәттә, аны кышка киптереп куйганнар, кышын исә чәйгә салып эчкәннәр, җимеш суы ясаганнар. Әти-әниләр кыр, басу, печән эшендә булганлыктан, җиләк-җимеш җыю эше әбиләр һәм оныкларга, балаларга йөкләнгән. Каен һәм җир җиләге, карлыгын, кура җиләк, бөрлегән, шомырт, балан – җыярга гына өлгер. Әмма алган савытны тутырып кайтыр өчен җиләк-җимешнең шәплеген, урынын да белергә кирәк. Ә моны бик азлар белә. Әрәмә карчыгы, урман карчыгы дип даннары чыккан берничә әби була авылда. Әнә шуларга иярергә тырыша бала-чага. Үзләре белән иртәп барган кешеләрне, бу урынны белмәсеннәр өчен, адаштырып, саташтырып, әллә кайлардан алып кереп, икенче яктан алып чыгалар. Җиләк-җимешне җыярга осталык та кирәк. Кайбер балалар җыйган җиләкләрен ашап бетереп, савытларын башларына да киеп кайта иделәр.

Әпри кайта җиләктән, кая микән җиләге?

Башына кигән чиләген, талдымыни беләгең?

Кешедән ким буласы килми бит. Савытың тулмаса, аны бушатып, чиләккә үлән, әрекмән тутырып, өстенә җиләкне саласың да менә сиңа тулы савыт! Алай эшләүчеләр дә бар иде. Сизәләр иде инде андыйларны да.

Тулы икән чиләгең, эре икән җиләгең.

Өсте тулы, асты буш, чиләкнең эче куыш.

Җиләге чәйлек булыр, печәнеңне ашагач,

Кәҗәкәең тук булыр.

Әмма язылмаган закон бар: иң эреләрен, сусылларын, кызылларын гына сайлап җыеп, бер яки ике бәйләм сабаклы җиләкне әниләргә, әбиләргә яки өйдә калган кечкенә энесеңелләргә дип атап алып кайту.

Менә шушы урында язучы ***М. Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә»*** повестеннан тагын бер өзек тыңлап китик әле.

«Җиләк җыю буенча балалар арасында, Мәрфуга карчыктан кала иң зур абруй Зөлфиядә иде. Кичтән җиләк вакытында Зөлфияләр капка төбендә «оперативка» була: ничәдә торыр-

га, кемнәрне ияртергә, кемнәрне юк, нинди савыт алырга һәм урманның кайсы фарталына (ягъни кварталына) барырга... Башыңны иеп, кичтән Зөлфия янына киләсең. Куркып кына сорыйсың (ә иярмәсә?): «Иртәгә нишлибез? Барабызмы?»

Зөлфиянең бу вакытта телеграф стилендә кыска җөмләләре була. – Боерган булса. – Кая? – Кимпласага (киң полоса дигән сүздән, киселгән ачыклык). – Ничәдә?. – Көтү куганда. – Савытны ниндине? – Пласкати җитеп торыр. Артса, күлмәк итәгенә. – Кемнәр, кемнәр? – Шәйхулланы иярмибез. Зөләйха белән Рәшидә дә калып торыр. Гел ашыйлар, җыю турында уйламыйлар да.

Зыңгырт! Тимер келәле авыр капка ябылды. Зөлфия юк булды... Зыңгырт! Тимер келәле авыр капка ачылды. Зөлфияне ай күрде – кояш алды, көтү куалар икән. Артыннан торып йөгерәсең, авылны чыкканчы Зөлфия беркемгә бер сүз дәшми. Урман юлына чыккач, туктап барлау үткәрә. Әлбәттә, кичен исемлектән сызылган берәр бала булмый калмый. Зөлфия аңар авыр караш ташлый, теге бичара башын иеп басып тора. Әмма Зөлфия бик гуманлы, яхшы холыклы кеше иде.

Урман буена килеп җиткәч, Зөлфия әрекмән белән аягын урый да, кешедән калган иске чабатаны киеп, чыжылдатып куак арасына кереп китә. Кура җиләге җыйганда, чиләге тулмыйча кешегә эндәшми. Ә чиләк тиз тула. Аннан ул иптәшләренә җыеша.

Безнең авыл балаларының бик матур бер гадәте бар иде, савыт тулгач, өстенә сабагы-тәлгәше белән өзеп, сабаклы җиләк утырта идек. Анысы, кайтып кергәч тә, әнигә! Әни җиләге! Моны Зөлфия бик каты күзәтә иде. «Әйдәгез, әниләргә берәр сабак кадыйк та кузгалыйк».

Урман буена чыгабыз. Зөлфия әрекмән чабатасын салып ташлый, ягъни аны питомник киртәсенә элеп куя. Димәк, кирәк кеше файдалансын. Аннан питомник киртәсенеә юан баганасы башына бер-ике җиләк куясың. Монысы – урман иясенә. Шулай итсәң, ул иртәгә дә җиләкне күп таптыра. Шатланышып кайтып китәбез».

Хәзер җиләк-җимеш вакытында, бигрәк тә җиләк өстендә болында яки урманда бер баланы да күрмәссең! Әллә балалары калмады, әллә аларны жәллибез шунда, әллә үзләренең

кызу кояш астында янып-пешеп, черки-кигәвенгә талатып йөриселәре килми? Ә бит шушы гади генә тоелган чара да нинди зур тәрбиягә ия!

Җиләкле җәй турында берәр балалар җыры.

13. Алдавыч әкиятләр

Алдагы тапшыруларның берсендә әкиятләр турында сөйләшкән идек. Әйе, балалар арасында да оста әкиятчеләр булган, зурлар арасында да. Ә әкият тыңларга бөтен бала да ярата. Әти-әнисен, әби-бабасын, апа-абыйсын әкият сөйлә дип тинтерәтүче дә алар. Әкият сөйлә дип аптыратучы балалар өчен әкиятләрнең алдавыч әкиятләр дигән төре дә бар. «Алар чынлап та әкият сөйли башлаган шикелле башланып китәләр дә, кызыктырып, колакны торгызып җитүгә, берәр тапкыр сүз әйтеп яки рифмага туры китереп берәр сорау биреп кырт кисәләр дә куялар». *(Н. Исәнбәт. «Балалар фольклоры», 1984, 145–146 нчы битләр).* Алдавыч әкиятләр күбесенчә такмаза формасында була, хикәя формасындагылары да бар. Хәзер шуларның берничәсе белән танышып китәрбез**. 622. 627. 630. 633 нче әкиятләр**.

14. Имеш төбе – җимеш яки ни өчен алай?

Бала кешесе «ник, ни өчен алай» дигән сораулар белән зурларны аптыратып бетерә. Күбебез мондый сораулардан: «Аптыратма әле, вакытым юк! Үскәч үзең белерсең», – дип котылу ягын карый. Кайберләре иренмичә җавап бирергә тырыша, әкият формасын куллана яки кыска тапкыр җавап белән котыла. Кечерәк әкият сыман җаваплларны балалар бик яратып кабул итә. Әкият булгач – әкиятчә инде: аларда хайваннар да, кошлар да кешечә сөйләшә, кеше кебек киенәләр, кунакка йөриләр, җырлыйлар, биилəр... Әммамондафәнкитапларындаязылганның киресе килеп чыга. Әкиятчеклəр **ник?** дигән сорауга җавап сыман сөйләнсәләр дә, аларда фәнни җавап юк. Шулай булгач, аларны ник сөйлилəр? «Моңа җавап шул, – ди фольклорчы галим Н. Исәнбәт, – иң элек ялган булса да, алар, Тукай әйтмешли,

«сөйләве яхшы, күңелле, шагыйранә ялган»нар» *(«Балалар фольклоры», 154 нче бит).* Н. Исәнбәт мондый әкиятләрнең берничә әһәмиятен күрсәтә. «Беренчедән, – ди ул, – мондый әкиятләр балаларның уй-хыялларын киңәйтә. Чөнки хыял канатларыннан башка кешедә ижади хезмәт тә, белем дә, һөнәр дә, сәнгать тә була алмый. Икенче ягы да бар: алар холык төзәтү ягыннан берәр кызыклы, гыйбрәтле һәм характерлы мисал да булып торалар. Өченчедән, бер дә булмаганда, мондый әкиятләр балаларда уку дәрте уятыр».

Әйе, балалар мондый төр әкиятләрне яраталар һәм үзләре дә иҗат итеп газета-журналларга җибәрәләр. Ә хәзер халык авыз иҗатының бер жанры булган берничә әкияткә тукталырбыз. Бу әкиятләрне мин Нәкый ага Исәнбәтнең «Балалар фольклоры» китабыннан алдым.

Ни өчен тирәк агачы җимешсез булып калган?

15. Имеш төбе – җимеш

Ташбака, әвернәле үрмәкүч, бал корты каян булганнар? 166–168 нчы битләр.

Балалар, хәзер тыңланачак әкиятне сезнең бәлки ишеткәнегез дә бардыр. «Өч кыз» дигән татар халык әкиятен беләсезме? Менә хәзер шуңа охшаш әкият белән таныштырырмын.

Әкиятне уку.

III бүлек

«КЫЙССАДАН ХИССА»

Халыкта «кыйссадан хисса» дигән гыйбарә бар. **Кыйсса** – хикәя, тарихи эпизод, вакыйга, хәбәр дигән мәгънәләрне аңлата. «**Кыйссадан хисса**» – укыган хикәядән, тарихи эпизодлардан ишеткән, күргән вакыйга-хәбәрләрдән алынырга тиешле **гыйбрәт, мораль** ул! Әлеге тапшыру әнә шундый гыйбрәт алырлык кечкенә хикәя, вакыйгалардан тора. Язмаларның берничәсе «Татарстан яшьләре» газетасының «Замана кыйссасы» сәхифәсеннән алынды, тормыштан, язучыларыбызның әсәрләреннән, истәлек-язмаларыннан тупланды. Сөйләү – миннән, тыңлау – сездән.

1. Югалмас байлык

Бөек мәгърифәтче-галим Каюм Насыйриның «Китаб-әт-тәрбия», ягъни «Тәрбия китабы» дигән җыентыгы бар. «Ошбу китапта зикер кыйлыначак хикәятләр, вәгазьләр вә нәсихәтләр һәммәсе, вә бу рисаләнең һәрбер кәлимәсе – бер тәрбиядер. Шул җәһәттән: «Тәрбия китабы» дип ат бирдек», – дигән галим җыентыкка кереш сүзендә. Шул китаптан берничә кыйсса.

Беренче тәрбия. Бер хәким балаларга шундый нәсихәт бирде ки: «Әй, җаннарым, угланнарым, нәсихәтне ишетегез – һөнәр өйрәнегез. Дөньяның милкенә вә дәүләтенә ышанырга ярамас. Алтын-көмеш – сәфәр кешесенә хәтәрдер; вә йорт-җир кешесенә дәхи хәтәре бар: я угыры алып китәр яки утка янып китәр. Әмма һөнәр – бер агым судыр вә ышанычлы дәүләттер. Һөнәр иясе әгәр дәүләттән төшсә дә кайгы юк. Әй угыл, син дә шулай ук һөнәр үгрән, тәрбия үгрән, гыйлем үгрән».

Өченче тәрбия. Бер падишаһның берничә угылы булып, араларыннан берсе – зәгыйфь, кыска буйлы, кечкенә гәүдәле иде. Гайреләре озын буйлы, матур йөзле иделәр, әмма атала-

ры ул углына кимсетү һәм нәфрәт белән карар иде. Әмма бу угыл бер зиһен иясе вә мәгърифәтле бала иде. Әйтте: «Әй ата, гакыллы тәбәнәк надан озыннан яхшырак түгелме? Һәрнәрсәнең кыйммәте күләменә карап йөрмәйдер. Мунча ташы бик эре – йөге бер тәңкә. Энҗе бик вак, әмма мыскалы ун тәңкә», – диде. Аталары вә дәүләтнең зур кешеләре барчасы көлештеләр һәм угылның фикере белән килештеләр.

Бәс, әй угыл, гыйлем вә мәгърифәт дигән нәрсә буйга вә кыяфәткә карап булмыйдыр.

Егерменче тәрбия. Мисыр шәһәрендә ике әмирзадә бар иде. Берсе гыйлем үгрәнде, голәмә булды, икенчесе мал җыйды, бай булды, финанс министры булды. Бәс, бу бай булганы галим булганына кимсетү күзе белән карар иде вә әйтер иде:

– Мин солтанлыкка ирештем, син һаман бер ноктада торасың.

Галим әйтте:

– И, туганым, Аллаһ Тәгаләгә шөкер итмәк минем тарафымдыр, чөнки мин пәйгамбәр мирасын таптым, әмма син фиргавен мирасын алдың.

Әй угыл, бу кыйссадан сиңа тәрбия шулдыр ки, канәгать кирәк. Гыйлем, әлбәттә, пәйгамбәр мирасыдыр.

Әй угыл, ике төрле таифә (группа) бардыр ки, болар файдасызга вә мәгънәсезгә зәхмәт чигәрләр. Бере шулдыр ки, акча вә мал җыяр, үзе файдаланмас. Янә бере шул галимдер ки, гыйлем үгрәнде, гамәл кыйлмады. Бу ике таифә кешесеннән була күрмә.

Ә менә монысы хәзерге заман мәзәкчеләреннән.

Бер яшь егет каршында тылсымчы пәйда булган һәм аның алдына ике капчык китереп куйган.

– Менә шушы ике капчыкның берсен сайла, – дигән.

– Ә аларда нәрсә? – дип сораган егет.

– Берсендә – акча, икенчесендә – акыл, – дигән тылсымчы.

Егет, озак кына уйлап торганнан соң, акыл капчыгын сай-

лаган. Һәм шунда ук, Җир шарында яшәүче иң акыллы, иң зирәк кешегә әверелгән. Моның янына акыл эстәп дөньяның төрле почмакларыннан кешеләр агыла башлаган.

– И зирәкләрнең-зирәге, даһиларның-даһие, бу дөньяда иң әһәмиятлесе нәрсә? – дип сораганнар.

– Юк, егетләр... Теге вакытта тылсымчыдан акча капчыгын аласы калган! – дип җавап биргән акыл иясе.

Менә шулай, заман белән бергә дөньяга карашлар, тәрбия дә үзгәреп тора.

Бүгенгә шулар. Киләсе очрашуларга кадәр.

2. Изге холыкларның күркәме – дошманны дус итү

К. Насыйриның «Тәрбия китабыннан». 55 нче тәрбия.

Әй угыл, әгәр бер кеше сине явыз холкы белән рәнҗетсә, эчкерсезлегең белән аңа вәгазь кыл, ягъни аннан ачу алаем дип мәшәкать чикмә. Үч алырга вә җәза бирергә көч җитә торып гафу белән мөгамәлә кыйлмак, барча изге холыкларның күркәмерәгедер.

Шул ук «Тәрбия китабы»ннан.

Искәндәр Румидан сорадылар: «Мәшрикъ вә мәгриб илләрен ничек итеп алдың? Элеккеге падишаһлар никадәр гаскәр, акча вә хәзинә түгеп тә алалмаганнар иде», – диделәр. Искәндәр әйтте: «Һәр мәмләкәтне алдым, халкын рәнҗетмәдем. Вә элгәре падишаһларын изгелектән гайре нәрсә белән зикер кыйлмадым», – дигән.

Әй угыл, күрдең, ниндәен тәрбияле кешеләр бар, имеш. Киң күңеллелек вә йомшаклык белән бөтен мәмләкәтне яулап алалар. Гәрчә дошманың булса да, изгелектән гайре зекер кыйлма.

«Тар-мар!» кыйссасы

Бервакыт Кытай императорына ил төбәкләренең берсендә фетнә чыккан дигән хәбәр килеп ирешә. Император, тиз арада яраннарын җыя. «Кичекмәстән юлга кузгалабыз. Мин дошманнарымны бик тиз тар-мар итәчәкмен!» – ди. Гаскәре белән

фетнәчеләр янына барып җиткәч, император алар белән бик ипле һәм дустанә сөйләшә, эш нәрсәдә, дип кызыксына. Фетнәчеләр, императорның ачыклыгына, хәерхаклы мөнәсәбәтенә гаҗәпләнәләр һәм, нәтиҗәдә, барысы да аның ягына чыгалар. Хәзер, фетнәчеләрне җәзалый башларга дигән фәрман яңгырар, дип көткән яраннары аптырап кала. «Сез бит дошманнарны тар-мар итәм, дигән идегез. Ә үзегез, киресенчә, аларны гафу итеп, миһербанлылык, шәфкать күрсәттегез», – дигәннәр.

– Мин дошманнарымны тар-мар итәчәкмен, дидем һәм бу вәгъдәмне үтәдем, – дигән император. – Үзегез күреп торасыз, биредә дошманнар калмады, хәзер алар барысы да минем дуслар. Дошманны тар-мар итүне үтерү дип кенә аңларга кирәкми. Иң зур зирәклек – дошманны дуска әверелдерү!

К. Насыйриның «Тәрбия «китабыннан. Әй угыл, белеп тор ки, сиңа изгелек кылган кешегә яманлык кылма вә сиңа нигъмәт биргән кешене хурлама вә кимсетүле караш белән карама. Залимлыгы күп булган кеше тиз һәлак буладыр вә аның дошманнары күп буладыр. Залимлыктан сакланырга кирәк.

3. Туган тел – иң бөек тел

Бүгенге тапшыруыбыз тел, туган телгә багышланган кыйссалардан торыр.

Танылган философ, француз язучысы, мәгърифәтче Вольтер болай дигән: «Теләсә кайсы чит телне, үз алдыңа максат куйсаң, алты айда өйрәнергә була. Бер тел бар – аны гомерең буе өйрәнергә кирәк. Ул – туган тел!» – дигән.

Безнең туган телебез – татар теле. Бай мираслы, борынгы тел ул.

Бөек шагыйрь Кол Галидән сораганнар:

– И бөек остаз, – дигәннәр. – Шәрыкъ шагыйрьләре фарсыгарәп телләрендә язып дан казанды, син нигә төркичә язасың?

– И замандашлар, – дигән шагыйрь, – һәм фарсы, һәм гарәп телләре – дөньядагы бөек телләрдер. Мин – төрки адәм вә төркичә язу миңа рәхәт, – дигән.

Юл гизгәндә бер гарәп кешесе шагыйрь Мөхәммәдъярга әйткән, имеш:

– Хаҗи углы, и хаҗи Мөхәммәдъяр, китапларыңны гарәпчә язгыл! Бөтен голәмәи Ислам җиһанында шөһрәт вә дан алырсың!

Аңа каршы шагыйрь болай дигән:

– Төрки теленчә мәгънә сүзләрен ясап шаһ атыйын яздым мин ошбу китап, вә алда да төркичә назым итәем китапка хитаб.

Ягъни моңа кадәр дә төркичә яздым, алга таба да шулай итәчәкмен!

1462 ел.

Мәскәүнең бөек кенәзе Иван Өченче бу елны тәхеткә утыра. Аның исеменә В**а**лахиядән хат килеп төшә. Валахия – тарихи өлкә, хәзерге Румыниянең көньяк өлешендә – Карпат белән Дунай арасында урнашкан. Иван өченче бу хатны ача, әйләндереп-әйләндереп карый да тәрҗемәчеләргә бирә. Алар да бу хатны укый алмый, чөнки хат итальянчамы, румынчамы язылган була. Шуннан соң Иван Өченче хат яздыра да аны Валахия илчесенә тоттырып кайтарып җибәрә. Валахия патшасына язылган хатта мондый сүзләр була: «Урыс падишасы, илчелеге чит илләр белән бары тик урыс, латин һәм **татар** телләрендә генә языша!»

Татар теле Русиядә халыкара тел булган. Казан ханлыгы җимерелгәч тә татар теленең аралашу теле буларак әһәмияте югалмый.

– Беравык татар теле Русия һәм Персия (Иран) арасындагы илчелек мөнәсәбәтләре теле булды, – дип яза мәшһүр тарихчы Василий Барт**о**льд.

Бу мисаллар **Р. Батулланың** ***(«Тузга язмаган хәлләр», Казан. 1997)*** китабыннан алынды.

Газиз туган телем аһәңнәре
Канга, җанга сеңгән тумыштан.
Кеше диеп мине санамагыз,
Тапкан анам телен онытсам.
Бара-бара барып чыктык, ләгынь,
Тукайны укыйбыз урыстан.
Татармын мин, димә, газиз балаң
Бөек Тукай телен онытса.

Ояты ни: татар балалары
Урыс булып туа тумыштан;
Үз телеңне үзең акламасаң.
Үз телеңне үзең сакламасаң,
Рәхим-шәфкать көтмә язмыштан.

(Шәмсия Җиһангирова)

4. Кереңнән элек, чыгарыңны уйла

К. Насыйриның «Тәрбия» китабыннан. «Әй угыл, бер җиргә керсәң, әүвәл ничек итеп чыгасыңны уйларга кирәк. Бер ишекне ачсаң, ничек итеп ябармын дип уйламак кирәк. Ягъни бурычка керсәң, ничек итеп түләрмен, дип, әүвәл түләвеңне исеңә төшер. Вә дәхи бер эшкә керешсәң, ничек итеп тәмам кыйлырмын, дип, тәмам кыйласыңны исеңә төшер».

Һәр эшнең ахырын фикер кыйлып һәм уйлап эш кыйлган кеше бәла вә кайгыдан имин булыр вә сәламәт калыр. Уйламаенча ашыгып эш кыйлган кеше һичбер тәүбә вә үкенеч тартмай калмас.

Иң мөһиме

Бер фәкыйрь хатын кечкенә баласын күтәреп кабак яныннан узып барганда, мондый тавыш ишетә: «Кабакка кер дә, жаның ни тели шуны алып чык. Ләкин иң мөһиме турында онытма. Аң бул: син кабактан чыгуга, ишек мәңгегә ябылачак. Ә хәзер форсаттан файдаланып кал, ләкин иң мөһиме турында онытма!»

Хатын кабакка кергәч ни күрсен – өстәлләр алтын-көмештән, кыйммәтле ташлардан сыгылып тора! Ана баласын идәнгә төшерә дә, алъяпкычына ашыга-ашыга алтын акчалар, кыйммәтле ташлар тутыра башлый. Шул вакыт теге тавыш аны тагын кисәтә:

– Синең 9 минут вакытың калды!

Сулышы капкан, күзләре тонган хатын күтәрә алган кадәр байлык җыя да йөгереп чыгып китә. Аның артыннан шапылдап ишек ябыла. Мәңгегә! Шул чагында гына комсыз хатын эчтә баласын онытып калдырганлыгын исенә төшерә.

«Көмеш ваза хатирәсе»

Башкортстанның күренекле язучысы ***Мостай Кәрим***нең ***«Көмеш ваза хатирәсе»*** хикәясеннән бер өзек.

«1961 елның көзендә СССР Язучылар союзы безнең өчебезне – шагыйрь Михаил Луконинны, тәрҗемәче Мариан Ткачевны һәм мине Азия илләренә озак сәяхәткә җибәрделәр. Безнең максатыбыз – дөнья күреп, фәһем алу һәм төрле илләрдәге язучылар белән араларны якынайту, бәйләнешкә керү. Юлыбыз Кытай, Вьетнам, Бирма, Таиланд, Камбоджа аша үтәргә тиеш...

Камбоджадан кайтып китәргә тәүлек калгач, кичләтеп безне хөкүмәт башлыгы принц Нородом Сианук кабул итте. Әле көндез үк андагы илчебез безгә үгет-нәсихәт бирде:

– Ул мондый гына хөкүмәт башлыгы түгел, король улы – шаһзадә! Сарайның үз йолалары бар, бик иркен кыланып, әдәпне бозмагыз! Сез – совет кешеләре!

Монысын күбрәк Луконинга ымлады булыр. Чөнки ул илче белән очрашканда, үзен шактый иркен тота. Янә шуны аерым төшендерде илче: китәр чакта, шаһзадә белән хушлашып, ишек ягын уңайлаганда, артка чигенергә кирәк икән. Аңа аркаңны, җилкәңне күрсәтергә ярамый! Ике-өч тапкыр баш иеп, хөрмәт белдерсәң, бигрәк тә килешер: үз кул астындагы кешеләр аның белән күрешкәндә бер тезгә чүгәли, безгә монысын кылу мотлак түгел. Шушындый күрсәтмә алдык. Без ни, илче әйтмешли, горур совет кешеләре, туган илебезнең йөзенә кызыллык китермәс өчен, шаһзадә алдында өч түгел, биш тапкыр бөгелергә риза. Бу җәһәттән тәртип нык безнең».

Принц совет кунакларын бик ачык күңел белән кабул итә. Хуҗа үзен үтә гади тота. Җитмәсә, шигърият яратучы кеше дә икән.

«Байтак утырдык, – дип дәвам итә автор. – Мин юк-юкта «кереңнән әүвәл чыгарыңны уйла» дигән мәкальне искә төшереп алам. Ничегрәк итеп артка чигенербез икән?

Ниһаять, хушлашыр вакыт җитте. Хуҗа безгә бүләкләр тапшырды. Бөтенебез дә урыннарыбыздан тордык».

Принц горур совет кешеләренең артка таба йөри алмаслыгын аңлагандыр, яисә кунакларны авыр хәлгә калдырасы

килмәгәнме, тәрбияле кеше буларак, кунакларның уртасына кереп басып, билләреннән кочаклап, ишеккә кадәр озатып бара.

«Шулай итеп, илчебез биргән киңәшләр һәм күрсәтмәләр бушка булды. Хуҗаның «шигъриятне яратам» дигән сүзенең раслыгы, затлы токымның күңел зирәклеге, аңардагы патшалар тәрбиясе минем хәтеремә нык сеңде. Ә үз илебездә сәнәктән көрәк булган бәләкәй генә түрә кайсы вакыт өстәл артында утырган көе урыныннан тормыйча гына күрешергә сиңа кул суза. Сузса ярый да әле.

«Мин ифрат шигърият яратам. Хәтта хакимнәр дә шагыйрьләр белән исәпләшкән», – дигән фикерен гамәлдә раслады король улы».

Мостай Кәрим. «Гомер мизгелләре», Казан, 1996, 84–88 нче битләр.

5. Тәхет һәм бәхет

К. Насыйриның «Тәрбия китабы»ннан

Ике туган бар иде. Бере падишаһ хезмәтендә булып гомер кичерер иде. Бере үзенең кул көче белән табыш итеп, тереклек кыйлыр иде. Бервакытны падишаһ хезмәтендәге бай туганы әйтте: «Әй, туганым, ник падишаһ хезмәтенә кермәйсең? Бәлки, каты хезмәтләрдән котылыр идең», – диде.

Икенче туган әйтте: «Син ник кул көчең белән тереклек кыйлмайсың? Бәлки, хурлык вә кимсетелүләрдән котылыр идең. Хакимнәр әйткәннәрдер ки, үз икмәгең ашап өеңдә утыруың, кеше хезмәтендә алтын камәр (билбау) баглавыңнан артыграктыр».

Үз көчең белән тапкан бер тиенең кеше көче белән хасил булган мең тиеннән бәрәкәтлерәктер.

Габдулла Тукай. «Бәхет»

Бер шәһәрнең читендә генә өч агай-эне торалар иде. Боларның, ни сәбәптәндер, нинди генә эшкә тотынсалар да, эшләре уңга китми иде. Бу агай-энеләр, эшләре уңмавында үз-

үзләрен гаепләргә уйлап та карамыйча, һаман бәхет юклыгыннан гына күрәләр иде.

Берзаман, ничектер, күзгә күренмичә генә Бәхет үзе боларга кунакка килде дә, бу агай-эне нинди генә эш башласалар да, ярдәм итәргә сүз бирде. Бу вакытта өч агай-эненең берсе сәүдәгәрлеккә тотынган иде. Шулай итеп, Бәхетнең ярдәме илә, ни сатса аннан – файда, ни алса – аннан табыш итәр, берничә көндә малы вә хәзинәсенең хисабы булмаган зур бай булып китте.

Шул ук Бәхет килгән заманда икенче кардәш мәхкәмәдә (ягъни судта) писарь иде. Бу да Бәхет аркасында хакимлек дәрәҗәсенә күтәрелде, медальләр бирелде.

Сез инде өченчесенә Бәхет ярдәм иттеме диярсез? Ник итмәсен, итте: өченче кардәш чебен тота иде! Хәзер Бәхетнең булышлыгы илә, кулын селтәгән саен чебен тота, һичбер селтәнгәне бушка китми.

Бәхет кунакка гына килде дигән идек бит. Дөрес, Бәхет озакламый китте.

Ике кардәш бай вә дәүләтле булдылар. Өченчесе, һаман явыз Бәхетне яманлап, авылдан-авылга, сукрана-сукрана, капчык тотып, теләнергә китте.

Укучы! Ошбу хикәядә кем гаепле икәнен үзең табып хөкем ит!

Бүгенгә шулар. Киләсе очрашуга кадәр исән-имин торыгыз!

6. Нәрсә эшләсәң дә үзеңә әйләнеп кайта

Каюм Насыйриның «Тәрбия китабы»ннан. Әй угыл, сачкәнеңне урырсың, кылганыңны күрерсең. Ягъни изге эш кыйлсаң, изге җәза алырсың вә явыз эш кыйлсаң, михнәткә вә газапка лаек булырсың.

Әй угыл, яхшылыкның кадерен белмәгән кешедән ерак йөргәнең яхшы. Берәүгә бер яхшылыгың тисә, сөйләп йөрмә, берәүдән яхшылык күрсәң, фаш кыйл, онытма!

Әй угыл, берәүгә иткән игелегең вә ярдәмеңне вә аңар иткән яхшылыкларыңны әйтеп:

– Мин сиңа фәлән яхшылыклар кыйлдым, – дип сөйләп

йөрсәң, адәм тарафыннан рәхмәт вә Аллаһы Тәгалә тарафыннан савап өмид итмә. Син исенә төшермәсәң дә, ул кеше үзе дә белер.

* * *

Бу хәл, егерменче гасыр башында, Шотландиядә була.

Сазлык яныннан узганда, бер фермер җан ачысы белән кычкырган тавышлар ишетә. Ул тетрәвекле сазга батып баручы малайны күрә. Бәхеткә, фермерның кулында балтасы була һәм ул тиз генә юан ботак чабып алып, шуның ярдәмендә баланы тартып чыгара.

Икенче көнне фермерның өе янына зиннәтле экипаж килеп туктый. Каретадан чыккан джентельмен фермер коткарган малайның әтисе икән. Ул рәхмәт әйтергә килгәнлеген әйтә.

– Мин сезгә күпме акча тиеш? – ди ул.

– Мин сезнең улыгызны акча өчен коткармадым. Минем урында кем генә булса да, нәкъ шулай эшләр иде, – дип җавап биргән фермер. Шулвакыт болдырга бер малай йөгереп чыга.

– Бу сезнең улыгызмы? – дип сорый кунак.

– Әйе, – дип җавап бирә фермер.

– Болай булгач, мәсьәлә хәл ителде, – ди бай кунак. – Сез минем улымны үлемнән йолып калдыгыз, шуның өчен мин сезнең улыгызны үзем белән Лондонга алып китәм һәм аны яхшы урынга укырга урнаштырам. Мин шикләнмим: сезнең улыгыз да әтисе кебек игелекле баладыр һәм бу хөрмәткә лаек. Сезгә дә, миңа да үкенергә туры килмәс.

Һәм фермер малае Лондонга китә. Ул анда башта мәктәпне, аннан университетны тәмамлый. Озакламый ул пенициллин уйлап табучы буларак бөтен дөньяга таныла. Белмәгәннәр белеп калсын: аның исеме – **Александр Флемминг**.

Аны укырга урнаштырган кеше – **Рандольф Черчиль**. Ә аның фермер коткарып калган улының исеме – **Уинстон Черчиль** – соңыннан Англиянең премьер-министры.

Сүз уңаеннан: **Уинстон Черчиль** үпкә чиренең бик авыр формасы белән авырып урын өстенә егылгач, аны үлемнән яңа дару – **Александр Флемминг** ачкан пенициллин коткарып калган. Шушы хәлгә бәйле рәвештә микән, Уинстон Черчиль, җае чыккан саен:

– **Нәрсә генә эшләсәң дә, үзеңә әйләнеп кайта**, – дип кабатларга яраткан.

Бу мисал «Татарстан яшьләре» газетасының «Замана кыйссасы» сәхифәсеннән алынды (16 апрель, 2015 ел).

7. Беркайчан да зарланма

К. Насыйри «Тәрбия китабы»ннан

22 нче тәрбия. Ишеттем ки, бер фәкыйрь дәрвиш ачлык утында көйгән, берсе өстенә берсе ямалган кием кигән. Дусларыннан берсе әйтте: «Ник болай утырасың? Ошбу шәһәрдә фәлән кеше бар, мохтаҗларның хаҗәтен үтидер. Әгәр синең дә хәлеңне белсә, хәленә керер иде», – диде. Ул фәкыйрь әйтте: «Тик тор, фәкыйрьлектән үлмәк, кешегә хаҗәт белән бармактан хәерлерәктер», – диде.

Остаз киңәше

Бервакыт остазы шәкертенә әйтә: «Беркайчан да мин начар яшим», – дип зарланма. Ходай, бу сүзләреңне ишетеп, бу әле начар яшәүнең нинди булганын белми икән, дип язмышыңны үзгәртергә мөмкин.

Тормышында ни нәрсә килеп чыкса да: «Мин яхшы яшим», – диген. Ул чагында Ходай: «Бу әле яхшы тормышның нәрсә икәнен белми икән», – дип әйтәчәк һәм сиңа унлата яхшырак тормыш бүләк итәчәк.

Форсат

«Диңгез буенда өч катлы вилла сатыла. Бассейны һәм бакчасы бар. Бәясе – 1 доллар».

– Саташу, – дип уйлап куя бомж һәм газетаны чүп савытына ташлый. Ишек алларында ашарына ризык эзләп йөргәндә, ул тагын диварда зур игълан күрә: «Диңгез буенда өч катлы вилла сатыла. Бассейны һәм бакчасы бар. Бәясе – 1 доллар». «Ахмак шаярту!» – дип бомж юлын дәвам итә. Әмма киң урамда ат башы хәтле хәрефләр белән язылган галәмәт зур баннер (реклама характерындагы график сурәт) күргәч (анда да шул ук текст), бомж уйга кала. «Кайсы ахмагы бирде икән бу белдерүне? – дип уйлый

ул, – әллә барып тикшереп карыйм микән?» Кесәсендәге соңгы долларын капшап карагач, ул күрсәтелгән адрес буенча китә.

Вилланы эзләп тапкач, аңар ишекне бик чибәр хатын ача.

– Гафу итегез, мин белдерү буенча. Анда язылганнар берәр уен-муендыр инде, әйеме?

– Юк-юк! Барысы да дөреслеккә туры килә. Бернинди уен-муенсыз.

– Һәм бәясе дә бер доллармы?

– Әйе, бер доллар. Әгәр кызыксынсагыз, йортны карап чыга аласыз.

Йорт, билгеле, бомжга ошый һәм ул кесәсендәге бер долларны затлы виллага алыштыра. Бомжның: «Моны ничек аңларга?» – дигән соравына теге ханым болай ди: «Үләр алдыннан ирем язып калдырган васыять буенча, мин бу вилланы сатарга һәм акчасын аның сөяркәсенә тапшырырга тиеш. Тиеш икән – тиеш. Мин шулай эшләдем дә. Белдерү ярты ел эленеп торды, әмма беркем дә килмәде. Сез – кызыксынып килгән бердәнбер кеше. Уңышлар телим».

Шулай итеп, бу тормышта безнең барыбызга да шанс бирелә. Кайчагында хәтта кеше ышанмаслык нәрсәгә дә ышанырга һәм форсатны кулдан ычкындырмаска гына кирәк!

Бу мисал «Татарстан яшьләре» газетасының «Замана кыйссасы» сәхифәсеннән алынды (16 апрель, 2015 ел).

8. Әйткән сүз – аткан ук

К. Насыйриның «Тәрбия китабы»ннан. Әй угыл, әйткән сүз, аткан ук кебектер. Һәрбер сүзеңне уйлап сөйләшергә кирәк, авызыңнан чыккан кире кайтмас.

Г. Тукай «Бытбылдык»

.

Бытбылдык, диңгезгә кереп, барча җан-җанвар, кошкортка: «Мин хәзер бу диңгезне яндырам!» – диип мактанды.

Бу простой хәбәр түгел: шул ук сәгатьтә бөтен җир йөзенә, су төпләренә, урман араларына таралды. Барча су падишаһлыгының халкына зур хәвеф төште. Һавага карасаң, көтү-көтү кошлар килә; урманнан шулай ук көтү-көтү хайваннар

шәһәрдә пожар булганда җыелган халык шикелле җыелалар. Һәрберсе: «Диңгез ничек янар икән?» – дип уйлыйлар. Бу хәбәр авылдагы, шәһәрдәге кешеләргә дә таралган булырга кирәк. Кешеләр дә бер кулларына кашык, икенчесенә икмәк тотып, балык шулпасы ашарга дип, берсен-берсе егып, таптап, ашыгып чабалар.

Тамашачылар килеп бетте. Һәркем телсез кеше шикелле тавышсыз-тынсыз диңгезгә күзен текәп тора иде. Тик кайсы арада, чыш-пыш килеп: «Менә диңгез кайный башлар, менә янар», – дигән тавышлар ишетелә иде. Кешеләр, кошлар, хайваннар көтәләр; көтү уттан да эссерәк булып, эчләрен яндыра.

Аптырагач, бер-берсенә: «Ичмасам, кайный башламадымы?» – диләр иде. Диңгез исә янмый да, кайнамый да. Ахырда ни булды дисез? Бытбылдык, оятыннан, күзен йомып очып китте. Дөньяга даны чыкты, әмма диңгез янмады.

Бу урында һичкемнең йөзен ертмыйча гына бер сүз әйтергә мөмкин: бер эшнең очына чыкмыйча мактану кирәкмәс.

К. Насыйриның «Тәрбия китабы»ннан. Ялганчылык белән аты чыккан һәрникадәр туры сүз әйтсә дә, ышандырмыйдыр. Бер мәртәбә ялганчылыгың сизелсә, чын сүзеңә дә ышанмас булырлар.

Хуҗа Насретдин ялган сөйләп: «Мин кешеләрнең нәрсә уйлаганын белә алам», – дип мактанып йөри башлагач, аны казый янына өстерәп китергәннәр.

– Син кешенең ни уйлаганын беләсең дип сөйлиләр. Алайса әйт, менә мин хәзер нәрсә дип уйлыйм? – дигән казый.

– Син, бу хәзер миңа нәрсә дип ялганлар икән, дип уйлыйсың, – дип җавап биргән хуҗа.

Ялганчы кешенең ни әйтәсе болай да билгеле бит!

Хәзергә шулар. Киләсе очрашуга кадәр.

9. Изгелекнең кадерен бел!

К. Насыйриның «Тәрбия китабы»ннан. Адәмнең табигате шуйләдер ки, мәнфәгатен күргән кешегә мәхәббәт итәр вә зарарын күргән кешегә рәнҗер. Әй, угыл, кешегә мәнфәгать итәргә кулыңнан килмәй икән, зарарыңны ирештермә. Ачык йөзле, татлы сүзле бул, дустың күп булыр.

Игенче һәм язмыш

Бер игенче кырда җир сөргәндә хәзинә таба һәм шул хәлдән соң көн саен бу урынга килеп җиргә рәхмәтләр әйтеп, белгән догаларын укый торган була. Көннәрдән бер көнне игенче каршына Язмыш килеп чыга һәм болай ди: «Карале, дустым, нишләп син мин биргән бүләк өчен җиргә рәхмәт укыйсың? Ул хәзинәне баеп китсен дип, сиңа мин җибәрдем бит», – дигән. «Әгәр дә мәгәр, очраклы рәвештә хәлләрең үзгәреп китеп, фәкыйрьлеккә, мохтаҗлыкка төшсәң, син тагын сукранып, мине – Язмышны каргый башлаячаксың бит», – дигән.

Кеше үзенә кем игелек кылганын һәм кемгә рәхмәт укырга кирәклеген белергә тиеш.

Умартачы

Умартачы умарталыкта юк чакта берәү килә дә кәрәзләр һәм бал урлап китә. Хуҗа кайтып кергәч. таланган умарта ояларын күрә һәм аларны тәртипкә китерә башлый. Шулвакыт кырдан бал җыеп кайтып килүче бал кортлары өерләре белән аңа ташланалар. «Их, сезне! – дип кычкырып җибәрә умартачы. – Кәрәзләрне урлап китүчене сез күрмәгәнсез дә. белмәгәнсез дә. Ә мине, көне-төне сезне кайгырткан, сезне караган хуҗагызны өерегез белән чагасыз!»

Кайчагында кешеләр дә, мәсьәләнең асылына төшенеп җитмиләр дә, дошманнарыннан сакланасы урынга, дустларын читкә тибәрәләр.

Г. Тукай. «Яшь агач»

Мужикның урманда балта тотып барганын күреп, бер яшь агач: «И Агай! Хәлемә мәрхәмәт итеп минем тирә-ягымдагы

агачларны кисә күр. Мин, алар каплап торганга күрә, якты дөньяны күрә алмыйм. Тамырларым да, шушы карт агачлар тыгызлаганга күрә, кирәгенчә җәелә алмыйлар. Миңа җил дә, кояш нурлары да үтеп керә алмый. Әгәр син карт агачлардан мине коткарсаң, мин бер ел эчендә урманның беренче матур агачы була алыр идем. Бөтен сахра минем күләгә илә капланыр иде. Менә, күрәмсең, шул картлар зарарыннан минем калынлыгым һаман чыбык шикелле генә», – дип ялынды.

Мужик барлык карт агачларны кисеп аударды. Менә инде яшь агачның күңеле булды. Аңар дөнья иркен калды. Ләкин бу куанулар урынлымы?

Хәзер инде бичара яшь агачны кояш яндыра я бозлы яңгыр кәефен ала, я ком-туфрак бураны килеп, җиргә чаклы бөгеп, иелдереп китә. Көннәрдән бер көнне бик каты җилле давыл килде дә агачны шартлатып сындырып та китте. Бу хәлне күреп торган бер елан, җирдә сынып яткан яшь агачка карап: «И яшь бала! Инде кемгә үпкәләмәкче буласың? Бу бәла синең үзеңнән булды. Әгәр син карт агачларга тарланмаган булсаң, ул агачлар сине җилдән-яңгырдан саклаган булырлар иде. Син ышыкта тыныч кына рәхәтләнеп яшәр идең. Гакылсыз! Ул агачларга да мәңге суы сипмәгәннәр иде. Әгәр аларның гомере беткәнен көтсәң, аңарчы син дә үсеп, куәтләнер идең. Үз нәүбәтеңдә син дә зур агач булып, дөньяны күреп торыр идең һәм бу бәлаләр башыңа килмәгән булыр иде», – диде.

Бу кыйсса яшьләребез колагына кереп, гыйбрәт алсыннар иде.

10. Һөнәрле үлмәс

Дөньяда өч һөнәр иясе иң изге, кирәкле һөнәрләрдән санала икән. Болар – игенче, укытучы, сәүдәгәр. Әлеге кыйссаларыбыз бүгенге көндә дә иң популяр тармак – сату-алу, сәүдә өлкәсенә карый.

К. Насыйриның «Тәрбия китабы»ннан

Һөнәрле кол үлмәс. Әй угыл, һөнәрнең кайсы булса да, үзең яхшы булсаң, акча китерер. Әмма һөнәрләрнең яхшысы, әгәр

дә азрак сәрмәяң (акчаң) булса, сәүдә кыйлмак яхшы кәсептер. Ләкин хәләл сәүдә кыйлмак, бик читен эштер. Әмма иҗтиһад кыйл, әй угыл, хәләлдән сату ит. Хәләл сәүдә белән хасил иткән бер тиенең ун тиен хәрамыңны бәреп егар. Сәүдә малы алсаң, малның яхшысын ал, чөнки яхшы нәрсәдән файда өмиде бар. Ә начар нәрсәң сатылмый калса, зарар булыр.

Вә дәхи, әй угыл, бурыч итәргә һәвәс итмә. Вә файда белән алма вә заклад биреп акча алма. Чөнки бу эшләр адәмне хурлыкка төшерер. Кемгә бурычлы булсаң, аңар кол булырсың. Вә дәхи кешегә бурычка акча бирмә, хосусан, дустыңа бирмә. Чөнки дустың, вакытында үзе белеп бирмәсә, үзеңә сорарга туры килер, сорасаң рәнҗер, арагызда дуслык бетәр. Дустыңны дошман итмәк, җаһилләр, ягъни, наданнар, икейөзлеләр эшедер.

«Әйе, елмая белмәсәң, кибет ачма», – ди бит кытай халык мәкале. Сәүдә, сату-алу өлкәсендә эшләүчеләр ачык йөзле, тәмле телле, ихтирамлы, сатып алучыга карата итагатьле булмаса, аның янына беркем дә килмәс, товарын алмас.

1. Яратмый хәлең юк

Элек заманда кибеттәге өйрәнчек малай остазына мөрәҗәгать итә:

– Тәкъсир, кайбер сатып алучылар, ишектә күренү белән, гайрәтне чикерәләр. Андый чакта нишләргә икән?

– Ә аларның акчалары бармы соң? – дигән остаз.

– Бардыр инде. Булмаса, кибеткә кермәсләр иде.

– Синең акчадан гайрәтең чиккән чакларың булдымы?

– Юк, билгеле. Акчадан кемнең гайрәте чиксен инде!

– Акчаны яратасың алайса.

– Шулай дип әйтсәң дә була.

– Акчаны яраткач, сатып алучыны да яратасың инде. Яратмый хәлең юк, – дигән остазы.

2. Сатучыларның файдасы

Бервакыт шәкерте остазына әйтә:

– Әфәндем, мин беркөнне балачак дустымны очраттым. Минем сәүдә белән шөгыльләнүемне белгәч, ул авызын кый-

шайтты һәм сәүдәгәрләрнең барысы да жуликлар һәм спекулянтлар, чөнки алар арзанга алып, кыйммәткә саталар, гади кешеләрне талап симерәләр, – диде.

– Ә син аңар нәрсә дип җавап бирдең? – дигән остазы.

– Мин сүзне икенчегә бордым һәм без элекке дусларыбыз, сәясәт турында сөйләшә башладык.

– Аңлашылды. Син әйтер сүз таба алмагансың.

– Бәлки, сез миңа ул сүзләрне табарга ярдәм итәрсез.

– Яхшы, – остаз. – Синең урыныңда булсам, мин аннан: «Әгәр бөтен сатучылар кинәт кенә юкка чыксалар, син нишләр идең?» – дип сорар идем. Ул үзенә һәм гаиләсенә кием сатып алу өчен туку фабрикасына, ашарга алу өчен авылга йөри башлар иде. Ә бәдрәф кәгазе алу өчен кәгазь фабрикасына чабар иде. Шулай чаба торгач, аның эшләргә күпме генә вакыты калыр иде икән? Эш димәктән, синең дустың һөнәре буенча кем?

– Ул ниндидер сәясмәннең ярдәмчесе.

– Ә-ә, – ди остаз, – алайса аңлашылды.

(«Татарстан яшьләре». – 8 октябрь, 12 ноябрь, 2015).

Бүгенгә шулар. Хәзергә сау булып торыгыз. Киләсе очрашуга кадәр!

11. Яхшы гадәт – яхшы тәрбия җимеше

К. Насыйри «Тәрбия китабы»ннан

Локман хакимнән сорадылар: «Син хикмәтне кемнән үгрәндең?» – дип.

Әйтте: «Күзсез кешеләрдән үгрәндем, чөнки алар аяк басасы урынны күрмәенчә аяк басалар», – диде. Ягъни ул, күзсезләр аяк басасы урынны күрмәенчә я абыналар яки төртеләләр, яки егылалар. Шулай ук аңы юк кешеләр вә наданнар сүзнең урынын белмәй сөйләшәләр вә ахырын уйлап бетермичә сөйләшәләр. Аларның наданлыкларын күрдем дә хаким булдым, дигән, имеш.

Икенче бер кыйссада исә, Локман хаким бу сорауга, гадәтсезләрнең гадәтсезлеген күреп, гыйбрәт алып, хаким булдым, дигән.

Бүгенге кыйссабыз да гадәт һәм гадәтсезлек турында булыр.

Гадәтсезлек

Бер эш бирүче, реклама агентлыклары аша, фирмасының ачылуы турында хәбәр итә һәм тиздән бик күп гаризалар ала. Күпсанлы дәгъвачылар арасыннан ул ике кешене сайлый һәм аларны әңгәмәгә чакыра.

Беренче дәгъвачы бүлмәгә килеп кергәч, артыннан ишекне ачык калдыра. Эш бирүче аның белән унбиш минутлап сөйләшкәч, алгы бүлмәдә көтеп торуын сорый.

Икенче кандидат, бүлмәгә кергәндә, артыннан ишекне ябып керә. Бераз аралашкач, эш бирүче аңа да алгы бүлмәдә көтеп торырга куша һәм сәркатибен чакыра.

– Беренче дәгъвачы эш өчен кирәкле бөтен сыйфатларга да ия, – ди ул. – Әмма мин эшкә икенче дәгъвачыны алырга карар бирдем. Ник дигәндә, беренче дәгъвачы артыннан ишекне япмады, күрәсең, ул ялкау, таркау егеттер. Икенчесе япты. Шуңа күрә квалификациясе түбән булган очракта да ул эшкә бик тиз өйрәнәчәк.

Кеше бик белемле булса да, гадәтсез икән, аның күп белүеннән ни файда?

Әкрен кирәк, ипләп кирәк

Секретарь, менеджер һәм аларның боссы җәяүләп кенә әбәт ашарга баралар икән. Һич көтмәгәндә, алар юлда аунап яткан борынгы лампа күрәләр. Моның тышына нинди сурәт төшерелгән икән, дип лампаны сөртүләре була, аның эченнән гыйфрит килеп чыга һәм боларның һәркайсының берәр теләген үтәргә вәгдә бирә.

Беренче булып, секретарь алга чыга.

– Мине хәзер үк Багам утрауларына илт, – ди ул. – Минем, бөтен мәшәкатьләр турында онытып, зиннәтле катерда диңгезне айкыйсым килә! Секретарь шунда ук гаип була һәм гомере буе кәеф-сафа корып яшәргә китеп бара.

– Мине Гавай утрауларына илт, – ди менеджер. – Янымда массажчы кызлар йөгереп йөрсен, коктейльләр запасы бетмәстөкәнмәс булсын.

Ул да шул ук мизгелдә күздән югала.

– Хәзер синең чират. Нинди теләгең бар? – ди гыйфрит босска. Бераз уйлап торгач, теге җавап бирә:

– Әбәт вакыты тәмамлануга, теге ике хөрәсән кабат офиста пәйда булсын!

Моннан мораль шул: беркайчан да алдан чәчрәп чыкмагыз. Башта шефыгызның үз сүзен әйтүен көтегез.

12. Саран булма, юмарт бул!

К. Насыйри «Тәрбия китабы»ннан. Әй угыл! Халык каршында гыйззәтем вә хөрмәтем артык булсын дисәң, ачык куллы вә икмәкле-тозлы, җумард бул. Җумардлык белән дәүләт кимемәс, бәлки җумардлык дәүләтең артуына сәбәптер. Сәдака-хәер һичкайчан кешене бөлдермәс. Кешенең ярдәменә мохтаҗ булудан саклан. Әй угыл, кешенең миннәтен (берәүгә күрсәткән, эшләгән яхшылыгын, ярдәмен искә төшереп, аны битәрләү) һәрвакыт муеныңа йөкләмә, үзеңнең хәзинәңдә барына канәгать кыйл.

Берәүнең мохтаҗ икәнен беләсең икән, үзе сорамас борын тизрәк бирә күр.

Ипи

Авылда бик фәкыйрь бер карчык яшәгән. Шул дәрәҗәдә фәкыйрь булган, аена бер тапкыр булса да ипи салырлык оны да юк икән. Әбинең күршесендә бик көнче, кара эчле бер хатын яшәгән. Берзаман бу шуңа игътибар иткән: ул ипи пешергән көнне әбинең морҗасыннан да төтен чыга һәм пешкән ипи исе килгән кебек була икән. Бу хатын түзмәгән, әби янына кереп киткән.

– Әллә син дә ипи салдың инде? – дип сораган, исәнме-саумысын да әйтеп тормыйча.

– Кая инде..., – дигән әби. – Фәкыйрьлегемә хурланып, кешедән уңайсызланам. Шуңа күрә, син ипи пешергән көнне

мин дә мичемә кисәү башы тыгып, аңа ут тергезеп җибәрәм. Кешеләр, бу да ипи пешерә икән, дип уйласын, дим.

Әби мичтә кисәү башы яндырган көннәрнең берсендә аның ишеген шакыганнар. Әби ишекне ачып җибәрсә, сәләмәләргә төренгән теләнче карт басып тора икән. Ә әбинең өендә бер телем ипи дә юк икән. Бер пешкән бәрәңгесе булган, теләнчегә шуны биргән. Бәрәңгене ашап бетергәч, теге бабай ипи сораган.

– Юк бит ипи, каян алып бирим? – дигән әби.

– Мичеңнән ал, – дигән карт.

Әби мичен ачса, анда бер бөтен ипи ята икән.

– Менә могҗиза! Каян килгән монда ипи, бу миңа Ходайның рәхмәтедер инде..., – дип сөйләнә-сөйләнә ипине мичтән алганда, теге бабай әбигә әйткән:

– Ихлас күңелдән фәкыйрь-фокрага өлеш чыгарсаң, мичеңдә һәрвакыт ипи булыр! – дигән. Шул көннән башлап, игелекле әби ипи кытлыгы кичермәгән.

Суган кыягы

Бер бозык хатын, үлгәч, тәмугка эләгә. Гөнаһлары бик зур булганлыктан, аны сумалада кайната башлыйлар. Чыдар әмәле калмагач, ул, ярлыкавын сорап, Ходайга ялварырга тотына. Ходай аның янына фәрештәсен җибәрә һәм әйтә:

– Бизмәннең бер ягына хатынның кылган гөнаһларын, ә икенче ягына кылган яхшылыкларын сал. Яхшылыклары аска тартса, газаплардан азат ит, – ди.

Фәрештә бизмәннең бер ягына теге хатынның гөнаһларын өя, икенче ягына салырлык нәрсә тапмый.

– Исеңә төшереп кара әле, бәлки гомереңдә бер генә булса да яхшылык эшләгәнсеңдер? – ди фәрештә.

Хәтерендә актарына торгач, теге хатын, үләр алдыннан гына, урамдагы теләнчегә бер кыяк суган биреп китүен исенә төшерә. Шунда ук теге кыяк та пәйда була. Фәрештә әйтә хатынга: «Ябыш кыякның бер очына. Әгәр ул өзелмәсә, мин сине тәмугтан тартып чыгарам», – ди.

Бозык хатын кыякка ябыша һәм фәрештә аны, чыннан да, тәмугтан тартып чыгара. Шулай итеп, хәер итеп бирелгән су-

ган кыягы теге хатынның бөтен гөнаһларыннан да өстен булып чыга.

Яшьләр сүзен – янчыкка, картлар сүзен капчыкка сал, – ди халык мәкале. Өлкәннәр сүзендә хикмәт бар, шуны онытмасак иде.

13. Комсызлык – угрылыкның да юлдашы

К. Насыйри «Тәрбия китабы»ннан. Әй угыл! Кулга керүе мөмкин булмаган нәрсәне өмид итмә. Гамәлең микъдарынча гына өмид ит. Мәсәлән, ун тиенлек гамәл кылып, ун сум өмид итәргә урын юк. Сынамаган вә тәҗрибә кыйлмаган эшеңә тотынма. Һаман үзеңнең белгән эшеңне эшлә.

Әй угыл, угрыланган нәрсәне алмактан бик саклана күр. Кирәк үзең урла, кирәк белә торып угырланган нәрсәне ал, икесе бәрабәрдер. Аңсыздан урланган нәрсә кулыңа керсә, үзеңдә калдырма, иясенә тапшыра күр.

Комсыз хуҗабикә

Бер юлаучы сәүдәгәр авыл кунакханәсенә кунарга кергән. Моның тауар тутырылган зур-зур капчыкларын күреп, хуҗабикәнең күзе кызган.

– Их, моның тауарларын үзебезгә алып калырга иде, – дигән ул иренә.

– Моныңберавырлыгыдаюк, – дигәнире. – Бакчаданхәтерсезлек үләнен йолкып кер дә юлаучының чәенә сал. Шул чәйне эчкәч, сәүдәгәр барлык әйберсен бездә онытып калдырыр, – дигән.

Хәтерсезлек үләне салган чәйне эчкәч, юлаучы сәүдәгәр шунда ук йокыга киткән. Ә икенче көнне иртән үк торып, юлын дәвам иткән. Сәүдәгәр кунакханәдән чыгып китүгә, хуҗабикә онытып калдырылган әйберләрне тизрәк җыеп алырга дип бүлмәгә килеп керсә, анда бернәрсә дә юк икән. Шуннан бу хатын ире янына йөгереп чыккан.

– Синең үләнеңнең өч тиенлек тә файдасы булмады. Теге бөтен әйберләрен төяп алып киткән.

– Яхшылабрак кара әле, – дигән ире. – Ул, һичшиксез, берәр әйбersен булса да онытып калдырырга тиеш.

Хуҗабикә тагын кергән кунак бүлмәсенә һәм бераздан кычкырып җибәргән: «Онытkан! Онытkан!»

Тавышка ире йөгереп кергән.

– Нәрсәсен онытkан?

– Кунган өчен түләргә онытkан!

Комсызлык бәласе

Бөек Ватан сугышы тәмамлангач ук, бер генерал-майор Сталин янына керергә җан талаша. Ниһаять, офицерга Кремльдә очрашу билгеләнә.

– Минем сезгә шәхси үтенечем бар, иптәш Сталин, – дип мөрәҗәгать итә ул башкомандующийга. – Мин Германиядән үземә кирәкле кайбер әйберләрне алып кайтмакчы идем, әмма аларны чиктән чыкканда үткәрмәделәр, шуларны миңа кайтарып бирсеннәр иде.

Сталин рөхсәт итә, рапорт язарга куша. Аннары рапортны укый да резолюциясен сала. Сораучы рәхмәтләрен әйтә дә юлбашчының язганнарын укый. «Майорга аның таланган әйберләрен кайтарып бирегез. И. Сталин», – дип язылган була анда.

Генерал Сталинга кабат мөрәҗәгать итеп:

– Ялгыш майор дип язгансыз, ә мин бит генерал-майор, – ди.

– Юк, монда барысы да дөрес язылган, иптәш майор, – ди Сталин.

(Бу язма «Шәһри Казан» газетасының «Чуардан-чуар» дөнья сәхифәсеннән алынды, 2014 ел.)

Бер кермәдем түренә, кереп карыйм гүренә

Элек бер авылда Мәнди атлы бер тилемсәрәк кеше яшәгән. Мәнди авылында бик комсыз, саран бай да булган. Өенә кеше түгел, чебен дә керергә ярамый, малына тиярләр дип курка икән. Көннәрдән бер көнне бу бай үлгән. Аны күмәргә кабергә алып киткәннәр. Мәнди дә иярgән. Мәетне кабергә төшерер алдыннан, Мәнди, туктагыз, дип, кабергә төшеп киткән. Кабер

эчен, балчыкларын тоткалап карап бетергәч, анда башка әйбер күрмәгәч, кире менгән.

Кешеләр җүләрнең бу эшеннән гаҗәпләнеп: «Ник каберенә төштең, нәрсә карадың?» – дигәнгә Мәнди: «Бер кермәдем түренә, кереп карыйм гүренә», – дип җавап биргән, имеш.

Никадәр бай булсаң да, мал җыйсаң да, теге дөньяга берсен дә алып китә алмыйсың!

14. Күрмәгәннең күрәсе килә

Без рекламалар дөньясында яшибез. Радионы ачсак та, телевизорны кабызсак та, хәтта урамга йөрергә чыккач та алардан котыла алмыйбыз. Ниләр генә тәкъдим итми ул реклама дигәнең! Ышанмас җиреңнән ышанасың, алмас җиреңнән аласың. Әле бәясен киметеп тә бирәбез дисәләр, ябырылабыз инде очсыз товарга. Әмма бушлай сыр тычкан тәбесендә генә була дигәнне дә онытырга ярамый.

Бер ир үлә. Теге дөньяда аннан, кайсын сайлыйсың, дип тәмуг белән җәннәтне тасвирлаган видеороликлар күрсәтәләр. Теге кеше күрә: тәмугта казино утлары җемелди, аракы – күпме телисең, шуның кадәр. Хатын-кызларның ниндиләре генә юк! Бөтенесе типтерә, күңел ача... Ә җәннәттә шылт иткән тавыш та юк. Кешеләр тыныч кына, ашыкмый гына чәчәк җыеп йөриләр.

– Кайсын сайлыйсың? – дип кабат сорыйлар ирдән. – Әбәттә, тәмугны! – дип.

– Кайсын сайлыйсың? – дип кабат сорыйлар ирдән. Әлбәттә, тәмугны! – дип җавап бирә ир. Һәм аны тәмугка аткаралар.

Анда килеп керсә... Җеннәр кешеләрне газаплыйлар, зур казаннарда кайнаталар. Шунда теге ир җеннәрнең берсенә сүз ката: «Кайсын сайлыйсың?» – дигәнгә, миңа бөтенләй бүтән нәрсәләр күрсәткәннәр иде: казино, шәраб, хатын-кызлар...

– Ә-ә, аны әйтәсеңме? – дигән җен, – анысы бит аның реклама иде!

Менә шулай, һәр ялтыраган алтын түгел!

Җәннәт

Аксакал янына берәү ярдәм сорап килгән.

– Нишләргә дә аптыраган! Озакламый акылдан язармын, мөгаен. Без бөтенебез бер бүлмәдә яшибез: балалар, хатын, туган-тумачалар... Нервлар бетте. Өйдә ызгыш-талаш. Бу өй түгел, ә җәһәннәм!

– Мин сиңа ярдәм итәрмен, – дигән аксакал. – Ләкин моның өчен синең мин әйткәннәрне үтәвең кирәк.

– Үтим-үтим, валлаһи. Ни кушсагыз да үтим, – дигән ир.

– Бик әйбәт. Хуҗалыгыгызда мал-туар бармы?

– Бар. Сыер, кәҗә һәм алты тавык.

– Аларның барысын да шул үзегез яши торган бүлмәгә кертеп урнаштыр да тагын бар атнадан килерсең.

Бер атнадан теге кеше аксакал янына килә:

– Үләм инде мин! Өйдәге пычраклыкка, сасылыкка, тавышка чыдарлык түгел. Барыбыз да акылдан язу чигенә җиттек! – дигән, гаҗизләнеп.

– Бар, өеңә кайт та мал-туарыңны үз урыннарына чыгар.

Икенче көнне теге кеше, кояштай балкып, аксакал янына кабат килгән.

– Яшәү матур! Өйдә тынычлык, чисталык, киңлек! Бу өй түгел – җәннәт! – дигән ир, чиксез шатлык белән.

Шулай шул, һәр нәрсә чагыштырып караганнан соң беленә!

15. Хәерлегә булсын!

«Һәрнәрсәне дә яхшыга юрарга кирәк», ди акыл ияләре. Нәрсәгә юрасаң, шул килә, дигәнне дә ишеткәнегез бардыр.

Трамвайда, кулына пакет белән дарулар тоткан, гади генә киенгән ханым һәм өстенә кыйммәтле кайры тун кигән, бармагына калын алтын балдак таккан кызыл чырайлы таза ир бара.

Ханым уйлый: «Алла боерса, бу даруларны эчкәч, ирем савыгыр һәм барысы да әйбәт булыр. Улым эш тапты. Ул башлы бала, бер елдан, мөгаен, аны җитәкче итеп куярлар. Кызым тиздән бала табарга тиеш. Иншалла, оныгыбыз матур һәм сәламәт булыр».

Бу ханым артында фәрештә тора һәм аның уйлаганнарын язып бара.

Теге ир уйлый: «Нинди хәл соң бу! Машинамны ничә айдан бирле ремонтлап бетерә алмыйлар, аның хәзер эшкә яраклы җире дә калмагандыр инде. Көндәшләр үкчәгә басып килә – бизнесым үлә. Хатын яшь, билгеле, ул миңа хыянәт итәчәк».

Аның артында да фәрештә басып тора һәм барысын да язып бара.

Кич белән Ходай фәрештәләрнең язмача хисабын кабул итте һәм анда бәян ителгән теләкләрне үтәлешкә җибәрде.

Хәерлегә булсын

– Хәерле, – дип эш башлаган халкым,
Зур юлларга сәфәр чыкканда.
Кызу урак өсте башланганда,
Мәйданнарда бәйге тотканда.
Хәерле, дип бала битен юган,
Хәерле, дип туйлар уздырган.
Шуңа күрә йөзе иман нурлы,
Ә эшләре һәрчак уң булган.
Ата-баба гадәте буенча,
Хәерле дип башлыйк эшләрне.
Хәерле таң, хәерле көн телик,
Хәерле дип, көтик кичләрне.
Хәерле кич сезгә, кан-кардәшләр,
Хәерле ел, хәерле гамәл,
Гомерегез хәерлегә булсын,
Илтсен матур көннәргә кадәр.

(Ш. Җиһангирова)

16. Мәхәббәт сынаулары

100 көн

Бер патшаның гүзәл кызы үзенә кияү эзли. Аның игътибарын җәлеп итәр өчен бик күп гаярь бай дәгъвачылар килә кыз

катына. Алар арасында бер фәкыйрь егет тә була. Аның бөтен байлыгы – мәхәббәте һәм үҗәтлеге. Чираты җиткәч, ул патша кызына болай ди:

– Туташ! Мин сине бөтен гомерем буе яратырмын. Ләкин минем бернинди байлыгым да юк. Шуңа күрә, мәхәббәтемне раслап, үземне корбан итәргә әзермен. Мин ашамыйча-эчмичә, синең тәрәзәң каршында 100 көн утырырга вәгъдә бирәм. Бөтен бүләгем менә шул!

Егетнең бу сүзләреннән әсәрләнгән патша кызы риза була: «Мин сиңа форсат бирәм, – ди ул. – Әгәр, чыннан да, йөз көн ашамыйчә-эчмичә чыдасаң, мине хатынлыкка алырсың».

Шулай итеп, сынау вакыты башлана. Сәгатьләр, көннәр уза. Егет, күзләрен сөйгәненең балконына төбәп, тәрәзә астында утыра башлый. Кояш көйдерә дими, салкын җил исә дими, салкын яңгыр ява дими – барысына да түзә. Кайчагында балкон тәрәзәсе челтәре артында патша кызының йөзе шәйләнеп китә.

Ашау-эчүсез торуның 99 нчы көне җитә. Бу көнне бөтен халык булачак патшага көч бирергә мәйданга килә. Әмма билгеләнгән вакыт бетәргә бер сәгать кала, егет торып баса да, берни дәшми-нитми китеп бара. 99 көн һәм 23 сәгать утыргач була бу хәл.

Аны артыннан бер егет куып җитә һәм сорау бирә: «Нәрсә булды? Максатыңа ирешергә бер генә адым калган иде бит. Ни өчен мондый форсатны кулдан ычкындырдың? Ник китеп бардың?»

Дулкынланудан, күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып, егет болай дип җавап бирә: «Патша кызы минем газапларымны бер генә көнгә, һич булмаса, бер генә сәгатькә булса да киметәсе урында, минем интегүләремне пәрдә читеннән генә карап, тамаша кылды. Ул минем мәхәббәтемә лаек түгел!»

Кем дә кем гаеп итүләр, көлүләр, авырлыклардан курыкмыйча, үзенең хисләрен раслап тәвәккәл адым ясый – ул, һичьюгы хуплауга һәм яклауга лаек. Ә инде сөйгәне бу фидакарьлеккә битараф кала икән, димәк, аңа йөрәгеңне ачып, хисләреңне әрәм итәргә кирәкми!

Чын мәхәббәт

Иртәнге якта, тугызынчы яртылар тирәсендә, поликлиниканың хирургия кабинетына 80 яшьләр тирәсендәге бер бабай килеп керә. Бармагындагы ярасыннан җепләрен алдырырга килүе икән. Бабай бик ашыга, сәгать тугызда бик мөһим эше бар икән. Докторларның бер сәгатьсез булмаячакларын әйтеп, аңа утырып торырга кушалар. Әмма бабайның, күзләрен мөлдерәтеп, әледән-әле сәгатенә караштыргалап утыруын күргән шәфкать туташы, бабайны кызганып, аңа ярдәм итәргә була. Бәхеткә, аның ярасы инде төзәлгән була һәм шәфкать туташы тиешле коралларын алып эшкә керешә. «Кая ашыгасың шулкадәр, бабай?» – ди ул.

– Сырхауханәгә, авыру хатынымны ашатырга.

Баксаң, аның хатынында Альцгеймер чире тапканнар икән.

– Бераз соңга каласың инде, бабай. Карчыгың борчылыр инде, – ди шәфкать туташы.

– Борчылмый, – ди бабай. – Соңгы биш елда ул мине хәтта танымый да.

– Һәм сез, карчыгыгыз танымаса да, һәр иртәдә аны ашатырга йөрисезме?

Бабай елмаеп җибәрә.

– Ул минем кем икәнлегемне белми, әмма мин аның кем икәнлеген беләм!

Менә ул чын мәхәббәт нинди була!

(Бу мисаллар «Татарстан яшьләре» газетасыннан алынды. 2014–15 нче еллар.)

17. Аналар мәхәббәте – иң көчле мәхәббәт

Әни кулы йомшак була

Элек ике килен-килендәш булганнар. Берсе – гел ир бала, берсе гел кыз бала таба икән. Менә тагын болар икесе дә бер вакытта балага узганнар. Ир бала тапканы кыз көтә, кыз тапканы ир бала көтә икән. Шулай өметләнеп кенә торганда, беркөнне болар тагын элеккечә бериштән бала табып куйгач. үзара сөйләшкәннәр дә шул көнне үк бәбиләрен алыштырып, берсе икенчесенекен бала итеп алып үстерергә булганнар. Билгеле

инде, бу хакта балаларның үзләренә белдермәгәннәр. Һәр бала ят әнине үз әнисе дип белеп үскән.

Беркөнне бу киленнәр төп йортка кунакка килгәннәр, үзләре белән балаларын да алганнар. Киленнәрнең берсе икенчесенең кулындагы үз баласын кочаклап алып сөйгән-сөйгән дә кире биргән. Шуннан бу бала үзен асрап үстергән киленгә килгән дә, үз анасына таба карап алып: «Әни, нигә теге апаның кулы бик йомшак?» – дигән ди.

(Н. Исәнбәт «Татар халык мәкальләре», 2010, 2 том).

Әниләрнең хакы

Беркөн бер егет акыл иясе янына килеп: «Я акыл иясе! Әнием бик картайды, нәкъ сабый бала кебек булды. Яткан җиреннән тора алмый. Мин аны кулларым белән ашатам, чәй эчертәм. Тәһарәт алдырып, намазлыгы янына күтәреп илтеп куям. Һәр кушканын эшлим, һәр теләгән үтим. Я акыл иясе, әниемнең хакын үти алдыммы?» – дигән.

Ак сакаллы акыл иясе: «Тудырган әниең хакының йөздән бер өлешен дә үти алмадың», – ди.

Егет: «Ни өчен? Мин әниемнең бер әйткәнен ике тапкыр кабатлатмадым. Үзем шулкадәр хезмәт итәм, аңа һич кенә кыенлыклар китермим», – дигән.

Аксакал аңа: «Әниең сине, улым зур үссен, бөек кеше булсын, озак яшәсен», – дип аркасында күтәреп йөртте. Син исә, кайчан үләр, үлсә, котылыр идем, дип хезмәт итәсең. Монда таулар арасындагы кебек аермалык бар. Әниең сине бакканда, кайчан үсеп җитәрсең, балам, дия-дия, бары яхшылык теләп үстерде. Син исә, кайчан үләр, дисең! Шулай да бу ниятләрегез арасында булган аермалыкларның бер кыйммәте бар: син әниеңә никадәр хезмәт итсәң дә, аның хакын үти алмассың. Моны яхшы беләсең. Һичбер бала ата-анасының хакын үти алмас.

Фәкать шуны яхшы белегез: син әниеңә болай хезмәт итсәң, Аллаһы Тәгалә сиңа бөек саваплар бирер. Ата һәм ананың ризалыгына лаек булган кеше Аллаһы Тәгаләнең дә ризалыгына лаек булыр! – ди.

(«Иманлы гаилә» календареннан, 2016 ел, 30 декабрь саны.)

Ана мәхәббәте

Бу хәл Япониядә була. Көчле җир тетрәгәннән соң коткаручылар командасы чираттагы йорт хәрабәләре янына килә. Алар җимерекләр арасында бер яшь хатын гәүдәсен күрәләр. Хатын, намаз укыганда сәждәгә киткән кебек, алга иелгән, ә куллары нәрсәнедер кочаклаган сыман. Җимерекләр аның аркасына һәм башына зыян салган. Бәлки исәндер, дип өметләнеп, бер коткаручы тар гына ярыктан кулын тыгып, хатынның тәненә орына. Әмма гәүдә салкын була.

Коткаручылар, бу йортны калдырып, икенче җимерек йортны тикшерергә китәләр. Күңеле нидер сизенеп, коткаручылар башлыгы, кире теге йорт хәрабәләре янына әйләнеп килә. Тезләнеп, уңайлырак куышлыкны табып, башын эчкә суза. Яшь хатын астындагы урынны капшап карый һәм әсәренеп кычкырып җибәрә: бала! Хатынның гәүдәсе астында, чәчәкле юрганга төрелгән өч айлык бала була. Коткаручылар командасы, саклык белән, хатынның гәүдәсен һәм баланы алалар. Ана, күрәсең, улын коткарып калу өчен үзен корбан иткән. Йорт ишелә башлагач, баланы гәүдәсе белән каплаган. Тыныч кына йоклап яткан баланы команда башлыгы кулына ала. Тиз арада врач килеп җитә. Юрганны чишкәч, аның эченнән кәрәзле телефон килеп чыга. Экранда мондый текст була: «Әгәр исән калсаң, шуны бел: мин сине бик яратам!» Кәрәзле телефон кулдан-кулга күчә. Еламаган кеше калмый.

– Әгәр исән калсаң, шуны бел: мин сине бик яратам.

Ана мәхәббәте әнә шундый көчле!

(«Т. Я», 2015 ел. «Замана кыйссасы»ннан.)

18. Нәфес – шайтан!

К. Насыйриның «Тәрбия китабы»ннан

Әй угыл, өч нәрсә күңелне шатландырыр вә гакылны саф кыйлыр: гүзәл хатын, җитәрлек кадәр ризык вә якын дус, карендәш.

19 гасыр шагыйре Г. Кандалый исә кайгы-хәсрәт, борчу килгәндә күңелне бераз тынычландыручы өч нәрсә барлыгын искәртә:

– Күңелдән китәрүр өч нәрсә кайгу: яшел чирәм, гүзәл мәхбүб, акар су, – ди. Ягъни кайгыдан дәва өч нәрсәдә: яшел чирәмгә, гүзәл ярга һәм агымсуга карау.

Ләкин кеше тормышында аны һәлакәткә китерә торган сәбәпләр дә шактый. Әлеге 112 нче тәрбия бүлегендә мәгърифәтче-галим болай дип дәвам итә:

– Дәхи дүрт нәрсә бардыр ки, адәм аны ифрат вә чиктән тыш күп кыйлса, һәлак буладыр: әүвәл хатын-кыз белән артык маташса, адәм һәлак буладыр.

Янә явызлык артыннан күп йөри торгач, адәм һәлак буладыр.

Дәхи күп отыш уйнаса, адәмнең һәлакәте андадыр,

Дәхи дә күп хәмер эчсә, һәлак булмый калмыйдыр.

Риваятьләрдән билгеле булганча, Иблис бер суфи бәндәне юлдан яздыру максатыннан, гөнаһ эшләргә өнди: «Зина кылгыл!» – ди. «Зина кылмак явыз фигыль торыр, мин аны кыйлмаймын», – ди суфи.

«Кеше үтер!» – ди иблис. «Мондый гөнаһны да кылмыйм», – ди тегесе.

«Алайса хәмер эч!» – ди. «Хәмер эчмәк, боларына караганда ансатрак», – ди суфи һәм хәмер эчә.

Хәмер эчкәч, күңеле күтәрелде, хикмәт эзли башлады. Бер хатын белән зина кылды. Иблис тиз генә барып, теге хатынның ирен алып килде. Каны кызган, хәмер нәтиҗәсендә бәйдән ычкынган суфи теге хатынның ирен үтерде. Бу хәл падишаһка барып иреште. Падишаһ вәзирләре белән килгәндә, суфи теге зиначы хатын белән хәмер эчеп утыра иде. Суфыйны тотып дарга астылар.

Менә шулай итеп, хәмер кешедән күпме гөнаһ эшләтте. «Барча явызлыкның ачкычы хәмер булыр», – дигән 14 йөз шагыйре Мәхмүд Болгари. Уйланган кешегә уйланырлык урын бар.

Шушы темага халык ижат иткән бер мәзәк

Сыер кергән

Кибетче Ясәви көне-төне эчкән дә эчкән. Ревизия ясаганнан соң, кибетченең бик күп акча туздыруы билгеле булган. Моңа

бик күп нәрсәсен сатарга туры килгән. Шулар арасында сыер да «ычкынган». Танышларыннан берсе очрап: «Синең урынга кибеткә кем керде соң?» – дип сораган.

Ясәви исә: «Мин чыктым, сыер керде», – дигән.

Нәфес – шайтан, бик явыз ул –
Һәр адәмне аздыра.
Аздыра торгач, наданны
Юлыннан да яздыра.
Әмма аннан да явыз бар: ул – эчкечелек!
Ул халыкны йорт-җиреннән һәм дененнән яздыра.

*(20 гасыр башы шагыйре **Шәехзадә Бабич**.)*

19. Кешесенә карап...

К. Насыйриның «Тәрбия китабы»ннан

Әй угыл, белмәгән һәм тәҗрибә кылмаган танышларыңнан саклан. Кеше белән кеше арасында әхлак ягыннан аерма бик күп була.

Һәрбер сереңне дустыңа әйтмә, чөнки кайдан беләсең, бервакытны ул дошман булып китәр. Дошманыңа, кулыңнан килсә, зарар итмә, бәлки, берәр вакытны үзеңә дус булыр. Дустыңның дустына да ышаныч юк – аң бул!

Локман хәким ерак сәфәргә китәр алдыннан улына нәсихәт кылып әйткән: «Диңгез, ут, хатын-кыз бертөрле. Алардан башка яшәү дә авыр, әмма аларның нәрсә китереп чыгарасын да белеп булмый. Диңгезгә ышанычлы көймә белән кер, ут белән сак эш ит. Байлар, җитәкчеләр дә ут кебек. Аларга бик якынайма – янарсың, бик ерагайма – туңарсың. Сереңне хатыныңа сөйләмә».

Тормыш нужасы күрмичә, маңгай тирен түкмичә генә кисәк баеган яңа байдан әҗәткә алма. Ялагай һәм куштан кеше белән дуслашма.

Әтисе киткәч, улы аның сүзләрен сынап карамакчы була. Шәһәр башлыгының бер куштаны белән дуслаша, яңа байдан әҗәт ала. Бер сарык суеп пешереп, капчыгына тутырып өенә алып кайта. Хатыны капчыкта нәрсә барлыгы белән кызыксына.

– Әй минем сөекле хатыным. Сахрада берәү белән ачула-

ныштык. Үтереп котылдым, югыйсә, мине үтерә иде. Зинһар, берәүгә дә сөйләмә, сиңа гына әйтәм, – диде.

Көннәрдән бер көнне хатыны белән сүзгә киләләр болар. Хатыны әйтә:

– Үзеңне бел, мин дигәнчә булмаса, үзеңне зинданга яптырам.

Ире ачуланган булып, хатынына суга. Шуннан хатыны өйдән йөгереп чыгып, каравыл кычкыра:

– Минем ирем фәлән көнне берәүне үтерде, бүген мине үтермәкче була, коткарыгыз! – ди.

Халык җыела, бу хәбәр шәһәр башлыгына ирешә.

– Локман хәкимнең улын зинданга ябыйк. Кем алып килә? – диюгә, теге куштан дусты: – Үзем алып киләм, мин аны беләм, – дип сикереп тора. Сакчылар белән Локман хәким улы янына килә. – Син бит минем якын дустым. Бу бәладән качарга ярдәм ит, – ди Локман хәким улы. Дусты тыңламый, кулларын бәйләтеп алып китә. Моны ишеткән яңа бай да тиз генә килеп җитә: – Тизрәк минем алачагымны бир, – ди. – Хәлем авыр, күрмисеңмени, бераз көтеп тор, – ди тегесе. Әмма яңа бай көтеп торырга ризалашмый, өеңне ут төртеп яндырам, дип куркыта.

Шәһәр башлыгы янына алып килгәч, шәһәр башлыгы: – Әй хөрмәтле кешенең улы! Гаҗәеп эш кылдың. Сиңа килешми, хөкем итеп, җәзага тартабыз, – ди. Локман хәкимнең улы: – Үлгән кешенең никадәр җәрәхәте булса, мине дә аннан артык җәрәхәт кылмый үтерегез, – дип әйтә. Хатыны сөенәсөенә капчык яшерелгән урынны күрсәтә. Капчыкны шәһәр башлыгы янына алып киләләр. Ачып карасалар – пешкән сарык ите! – Бу ни хәл? – дип сорыйлар. Локман хәкимнең улы әтисенең нәсихәтләрен тәжрибә кылуын сөйләп күрсәтә. Бу – күпләр өчен сабак була.

(«Шура» дини альманахы, №7, 2015 ел, 144–145 нче битләр.)

20. Сүз йөртүдән олы гөнаһ юк!

Диндә дә, халыкта да сүз йөртү бик тәнкыйтьләнә. «Чагуның ни икәнен беләсеңме? Ул – кешеләр арасын бозу өчен берәүләр сүзен икенчегә йөртү», – диелә бер хәдистә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: «Минем өммәтемнән ун төркем, мөселманнардан аерылып, төрле сурәткә кереп кубарылырлар. Кыямәт көнендә кайберсе маймыл сурәтле булып кубар. Болар – сүз йөртүчеләр булыр».

Менә 19 гасыр уртасында ижат ителгән ***«Фазаилеш – шөһүр яки саваплы гамәлләр»*** китабыннан бер өзек (авторы – 19 гасыр имамы ***Җамалетдин Бикташи***).

Хәсән Басрыйга бер кеше килеп әйтте: «Әй Хәсән! Сине фәлән кеше яманлады һәм ярамас сүзләр әйтте», – диде.

Хәсән Басрый әйтте: «Кай вакытта, кай урында әйтте?» – диде.

– Бүген үз өендә яманлады, – диде теге кеше.

– Аның өендә ниләр эшлидер идең?

– Кунак булып, ризык ашый идем.

Хәсән Басрый әйтте:

– Ничә төрле ризык ашадың?!

– Сигез төрле ризык ашадым.

– И ахмак! Сигез төрле ризык эчеңә сыйган, бер сүз эчеңә сыймаган, шуны да миңа килеп әйтәсең! Тор, и бозык бәндә! Минем каршымнан чыгып кит! Синең сүзең белән аңа каршы бармам! Ант итеп әйтәмен: ул кешегә ярдәм итеп, минем белән бергә ожмахка кермичә, мин дә кермәм, – диде.

Әйе, сүз йөртүдән олы гөнаһ юк! Чөнки сүз йөртмәк, хәтта адәм үтерүгә сәбәп булырга мөмкин.

...Бер кеше бер колын сатты. Саткан чакта әйтте: «Бу колымның бер гаебе бар, риза булсаң ал. Ул – сүз йөртүчедер», – диде. Сатып алучы исә: «Аның миңа әллә ни зыяны булмас», – диде дә колны сатып алды. Көннәрдән бер көнне бу кол хуҗасының хатынына: «Синең ирең сине сөймидер. Сине аерып, икенче хатын алырга йөри», – диде.

Хатын әйтте: «Әй кол! Ни хәйлә бар икән иремне сөйдермәк өчен?» – диде.

Кол әйтте: «Иреңнең муенындагы төкләрен кисеп алсаң, сине сөяр», – диде.

Хатын колның бу сүзләрен күңеленә салып куйды. Кол исә хатынның ире янына барып:

– Әй хуҗам! Синең хатының сине сөйми, икенче кешегә күңел биргән. Хатының бу кичтә сине үтерергә ниятли, уяу бул! – дигән. Бәс, хуҗа йоклаган булып ята. Шул сәгать, хатыны кулына пычак тотып, төкләрен кисеп алыйм, дип иренә якынайды. Ире моны сизеп, сикереп торды һәм хатынын үтерде. Хатынның кардәшләре моңа хөкем чыгарып, үч алып, бу ирнең үзен дә үтерделәр. Шулай итеп, сүз йөртүче ике кешенең канына сәбәп булды. Моннан хисса шулдыр: сүз йөртмәк кеше үтерүдән дә олырак гөнаһ икән!

(Җамалетдин Бикташи «Фазаилеш – шөһүр» китабыннан, Казан, 1996, 93–94 нче битләр).

Хөрмәтле радио тыңлаучылар! «Кыйссадан хисса» тапшыруларын шуның белән тәмамлап торабыз. Әлеге тапшыру тыңлаучыларда аз гына булса да фикер уятса, файдалы гамәлләр кылырга этәрсә, без шат булырбыз. Сүземне 13 нче гасырның бөек шагыйре Кол Галинең түбәндәге шигырь юллары белән тәмамлыйм:

Гәүһәрне таш, дәю белән ул таш булмас.
Тикмә кеше гәүһәр кадерен белә алмас.
Бу назымның кадерен ахмак белмәс,
Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер имди.

27.10.16.

IV бүлек

«ТОРМЫШ ТӘРӘЗӘЛӘРЕ»

Ни өчен «тормыш тәрәзәләре?»

Адәм баласы, яши-яши, моңа кадәр бөтенләй игътибар ителмәгән күренешләр, тормыш ситуацияләренә, гомумән, тормышка бөтенләй башка күзлектән, фәлсәфи карый башлый. Гади генә булып күренгән, гади генә тоелган күренеш-вакыйгалар, уйлап карасаң, һәрберсе тормыш мәктәбе бит! Яшь вакытта болар турында уйлап та каралмый! Барысы да син теләгәнчә, син күз алдыңа китергәнчә барыр кебек. Алай түгел икән шул!

Сезгә тәкъдим ителәчәк сәхифәне **«Тормыш тәрәзәләре»** дип исемләргә булдым. Тәрәзә яктылык бирүче генә түгел, ул үтә күренмәле пыяла да! Ә тәрәзәдән барысы да күренә: яхшысы да, начары да! Тәрәзәнең теге ягында да, бу ягында да тормыш кайный. Әнә, тәрәзәнең тышкы ягындагы почмагына бер үрмәкүч пәрәвез ятьмәсе корган. Әллә ялгышып, әллә кызыксынып, бер чуар күбәләк туп-туры ятьмәгә очып килде дә тозакка эләкте. Тотынды бәргәләнергә! Бәргәләнгән саен ятьмәгә тирәнрәк керә. Болай да гомере кыска, аз булса да яшәп калсын дип, тиз генә чыгып, бер таяк алып, үрмәкүч ятьмәсеннән күбәләкне коткардым. Ятьмәдән ычкынгач, бер тын аңыша алмый торды күбәләгем. Бераздан очып китте. Кешеләр арасында да шушы күбәләк хәлендә калучылар азмы?

Бер чыккач, чәй эчәргә булыр дип, алгы бакчадан кура җиләге җыеп керергә булдым. Бакча өстәлендәге чүмечне алдым да кырыйдан гына, бик эчкә кермичә, җиләк җыя башладым. Ә иң эреләре, сусыл, кызарып пешкәннәре эчтәрәк. Кура арасында кычыткан булмый калмый. Өзеп торасың, үсә тора. Эре җиләкләр янына кычыткан җибәрми генә бит! Яланкул булганлыктан, кычытканны өзәргә батырчылык итми торам, чөнки аннан аллергия миңа. Саклана-саклана гына җиләк җыям. Шулай да, кура сабаклары арасына кысрыкланган

кычыткан омтылып карады берничә мәртәбә. Барыбер чагам, дигән кебек башын калкытып-калкытып ала, мин аның саен кураларны читкәрәк этәрәм. Савытым тулды бугай, чәй эчәргә җитәрлек булды инде, дип кураларны җибәрүем булды, теге кычыткан куралар арасыннан сикереп тә чыкты, беләгемне ялап та алды... Тормышта усаллык та шулай бит! Усаллыктан, усаллардан сакланасың, ләкин алар да кычыткан кебек, чагар өчен җаен, моментын гына көтеп торалар. Барыбер үзләренекен эшлиләр. Тормыштагы теге яки бу вакыйга-күренешләргә булган мөнәсәбәтемне хәзерге акыл-фикерләвем белән сезгә дә җиткерергә телим. Бәлки, минем фикерләрем кемнәрнедер уйланырга этәрер, үзенә аз булса да сабак алыр. Чыгышларым сезнең күңелгә барып җитсә иде дигән теләктә калам.

1. Сабыр төбе – сары алтын

Ире белән бергә 60 ел гомер иткән әбидән сорыйлар икән:

– И әби, бер ир белән ничекләр итеп тоташтан 60 ел яши алдың? Бабай да ару гына холыксыз, салгаларга да яраткан, күңеле дә чуар булган, дип ишеткәнебез бар. Ничекләр түздең?

– И балакайларым, баштагы 5–6 елына түзсәң, калган 50–60 елына гына түзәсең икән аны, – дигән әби, кеткелдәп. – Аның урынына, Ходай безгә тигез, бәхетле картлык насыйп итте.

Менә шул баштагы 5–6 елына түзә алмый шул күп кенә гаиләләр. Иң күп аерылышучылар да шушы чорга туры килә икән. Ә соңгы мәгълүматлар тагын да аянычрак: яңа оешкан гаиләләрнең күпчелеге ярты, бер ел эчендә үк таркала.

Бу – күпме бала тумас борын яки тугач та ятим кала; аталыдан – атасыз, аналыдан – анасыз үсә, дигән сүз бит. Бер канаты сынык кош оча аламы? Очса да, ерак китәме? Арбаның алды каян тәгәрәсә, арты да шуннан тәгәри, дигән сүз бар халыкта. Мондый балалар үсеп җитеп тулы канлы гаилә төзи, авырлыкларга түзеп тора алырмы? Күзәткәнем, игътибар иткәнем бар: ятим үскән кешенең баласы да ятим калучан. Язмышмы бу, тәкъдирме? Тормыш бик катлаулы бит ул. Аңламассың дөньясын!\

2. Маймыл гына димә...

Тере маймылны телевизордан гына күргәнем бар. Нихәл итәсең, шушы яшемә җитеп зоопаркта була алганым юк. Хәер, болай да дөньясы зоопарктан ким түгел. Кеше арасына гына чык: «маймылы» да, «дуңгызы» да, «эте» дә, «бете» дә җитәрлек. Артыңнан «бүре» сагаласа, алдыңа «төлкесе» йөгереп чыга. Икенче яктан фыр-фыр килеп, инәләрен тырпайтып «керпесе» уза, «хамелеоны» да шул тирәдә генә, «еланы» да ысылдарга гына тора.

Әмма чын маймылларның кешеләрдән аермалы бер бик әйбәт сыйфаты бар икән, дим: кулларына эләккән ризыкны (бананмы ул, әфлисунмы яки башка ризыкмы) кадерләп тотып, бер урынга җайлап утырып ашый. Сикерә-сикерә ашап йөргән маймылны күрмәссең. Ә кешеләр?

Район үзәге яки шәһәр урамнарында, базар тирәләрендә аягөсте туңдырма ялап, банан ашап, алма кимереп, көнбагыш чиртеп йөрүчеләрне еш очратырга була. Бала-чага булсалар, бер хәл! Үзләре балалар үстереп ятучы әти-әниләр, олы гына кешеләр, югыйсә. Ризыкны хөрмәт итү, олылау төшенчәсен онытып барабыз түгелме?!

3. Ожмахта дип белгән

Бер ата үзенең көчкә «3»легә укып баручы улын үгетли икән:

– Укы, улым, укы. Мужыт укытучы булса да булырсың, – дип.

Ни кызганыч: гомер-гомергә иң кирәкле, хөрмәтле, абруйлы булган, иң изге һөнәрләрнең берсе – укытучының дәрәҗәсе көннән-көн кими бара. Соңгы елларда бүтән уку йортларына керә алмаган яки конкурстан үтә алмаучылар, аптыраганнан, педагогик уку йортларына юл алды. Узган гасырның туксанынчы елларында алары да, яңгырдан соңгы гөмбәләр шикелле, үрчеде дә үрчеде. Кеше саны кимемәсен, уку йорты ябылмасын дип, кем килә – шуны да алдылар, ахрысы. Югыйсә, укытучы хезмәтенең никадәр җаваплы, авыр, тынгысыз икәнен, укытучының көндәлек төп эше – дәрес планы төзү, һәр дәрескә

җентекләп әзерләнергә тиешлекне дә күз алдына китерә алмаучылар каян чыгар иде. Эшләү дәверендә андый яшь кадрлар белән еш очрашырга туры килде. Шундый укытучылар кулына калган балаларны, илнең киләчәген ни көтә?

Укытучы һөнәре җиңел, теләсә кем булдыра ала, дип уйлаучылар өчен бер кыйсса.

Бер укытучы дәрес биргән җиреннән үлеп китә. Ярый, моны хөрмәтләп, соңгы юлга озатканнар. Теге дөньяда бу бәндәне оҗмахка җибәрәсе урынга, ялгышлык белән, тәмугка керткәннәр. Өч айдан соң, квартал ахырында, күк канцеляриясендә ялгышлык киткәнен белеп алганнар да фәрештәләр теге укытучы янына очып килгәннәр.

– И бәндәбез, зинһар, безне кичерә күр. Синең урының оҗмахта булырга тиеш иде бит. Нигә өч ай буе бер шикаять тә белдермәдең? – дигәннәр, өзгәләнеп.

Укытучы исә:

– И-и, туп-туры мәктәптән китергәч, мин монда оҗмах дип белдем, – ди икән, утлы күмердән аякларын алмаш-тилмәш күтәреп.

4. Болай да була

Укытучыларның август конференциясе. Пленар утырыш башланырга санаулы минутлар гына калып бара. Залда буш урыннар юк диярлек. Керүчеләрнең кайберләре, арткарак яки стена буена барып басалар. Шулар арасында бер кыз да бар. Өстендә күксел төстәге кофта, джинсы итәк. Чәчләрен дә матур гына итеп тарап куйган. Аякларында исә... тирән эчле резина галошлар, йөзендә сәер елмаю... Шуңа күрәме, үткән-сүткән, кырый урындыкларда утыручылар аңар гаҗәпсенеп карап-карап куялар. Әмма мин үзем аның кулындагы чәчәк бәйләменә игътибар иттем. Бик матур алсу розалар иде кызның кулында. Кыз чәчәк бәйләмен шулкадәр кадерләп беләгенә салган ки, яшь ана да үзенең беренче сабыен кулына алганда ул кадәр нәзакәтле була алмастыр, мөгаен. Ул чәчәкләргә вакыт-вакыт карап ала, буш кулы белән аларны сак кына сыйпап куя. Утырышның тантаналы өлешендә дә күзем әледән-әле кызга төшкәләп торды.

Лаеклы ялга китүче педагогларны котлау, озату барышын-

да аның күзләре моңсуланып китте. Әллә алар арасында аның берәр яраткан укытучысы бар идеме? Чәчәген шуңар бирергә җыенып та, сәхнәгә менәргә кыюлыгы җитмәдеме?

Сәхнәгә яшь алмаш – бу уку елында гына югары һәм урта педагогик уку йортларын тәмамлап кайткан егетләр-кызлар чыгып баскач, кыз кабат җанланып китте: күзләрендә очкыннар кабынгандай булды. Ул хәтта сәхнәгә таба талпынып та куйды. Бәлки, кыз укытучы булырга хыяллангандыр... Ниндидер сәбәп (авырып китүе аркасындадыр дигән уй килде башыма) белән укый алмый калгандыр... Бәлки, бүгенге көндә ул да шушы яшьләр арасында басып торырга, котлаулар кабул итәргә тиеш булгандыр... Бәлки, чәчәкләрен ул шуларның берсенә дип алып килгәндер...

Бераздан кыз юкка чыкты. Тәнәфес вакытында, фойега чыккач, күзем түрдәге өстәлгә куелган вазага төште. Анда тажларында су тамчылары ялтырап торган боек кына бер бәйләм алсу розалар иде...

«Алар нинди тамчылар икән?
Болыттанмы алар,
Әллә синең
Керфекләрдән тамдылар микән?»

(Х. Туфан)

4. Сез һәм без турында

Моннан берничә еллар элек, әле эшләгән вакытымда, иртә белән эш мәсьәләсендә районнан шалтыраттылар. Яшь кенә хезмәттәшем миңа, Сез, дип, исем-фамилиям белән мөрәҗәгать итә. Тавышыннан сизелеп тора: исемем янына рәхәтләнеп апа сүзен кушып, гади итеп кенә сөйләшәсе килә үзенең. Ләкин биләгән урыны буенча миннән өстенрәк булуы рәсми төстә сөйләшергә мәҗбүр итә булса кирәк аны. Ничек инде «начальство» башың белән мәктәп баласы яки авыл гыйбаты кебек «апа» дип турыдан ярасың...

Нәкъ шул вакытта Татарстан радиосыннан иртәнге тапшыру бара иде. Радиога шагыйрь Әхмәт Гаделне чакырганнар (урыны җәннәттә булсын). Ул бик оста итеп, әлеге дә баягы**, Сез, без** зат алмашлыкларын куллануга карата үзенең

карашын белдерде. Сез (Вы) дип мөрәҗәгать итү безгә руслардан кергән. Аеруча революциядән соң, татар халкы, аңлапмы-аңламыймы, бик күп гадәтләрне, сүзләрне руслардан алды бит. Русларда **Вы** – Ата (Отец), Ул (Сын) һәм Изге рух (Святой дух) мәгънәләрен үз эченә ала икән. Күплекне белдереп, зурлап эндәшү сүзе буларак кулланылышка кергән. Ә мөселманнарда бер Алла. Аллаһның барлыгына һәм берлегенә ышанган кеше генә мөселман була. Мөселман кешесе Аллаһка да Син дип мөрәҗәгать итә (и Ходаем, сорыйм синнән, рәхмәтеңнән, ярдәмеңнән ташлама, сиңа сыгынам, сәламәтлек, бәхет-тәүфикъ бир һ.б.). Мөселман кешесенең үзенә **Сез** дип әйттерүе үзен Аллаһтан да өстен итеп куюын аңлата булып чыга бит! Аннан, әбиләр сөйләве буенча, адәм баласы янында һәрвакыт шайтан йөрер, ди. Кешегә **Сез** дип әйтсәң, шайтан сөенер, ди, миңа да адәм рәтеннән эндәшәләр бит, дип.

Әмма ни хәл итәсең! Бу сүз шулкадәр калыплашкан ки, хәзер аны берничек тә кулланылыштан алып ташлап булмый. Хәтта бу алмашлыкны кулланыга татар телендә аерым кагыйдә дә бар.

«Сез» дигән – ыспай сүз,

«Син» дигән – якын сүз, – ди халык.

Халык белми әйтмәс.

5. Без капчыкта ятмый

Бер хатын яшь кенә көенә тол калган, имеш. Мәрхүм булган иренә тугрылыгын саклап, 2–3 ел буе беркемгә дә күтәрелеп карамый. И-и, яшь җан бит: сөясе, сөеләсе килә! Бер гаиләле ир белән яшерен генә очраша башлый бу. Берәү дә сизми, дип уйлый. Җир астыннан йөргән еланны да сизәләр. Күрше апа яшь хатынны кисәтә:

– Балакаем, ялгышасың. Синең кебек яшь, сылу, уңган-булган хатынга хуҗа табылмый калмас. Аты-чабуы чыккан кешенең беркем алдында да дәрәҗәсе булмый. Гаиләле ир барыбер сиңа булмас, булса да барыбер тормас, бәхетең дә булмас. Хатыныңның, балаларының рәнҗеше төшә күрмәсен үзеңә. Туктат бу эшеңне, – ди. Ә азгынлыктан аңы томаланган яшь хатын исә:

– Безнең очрашуыбызны синнән башка беркем дә белми бит. Хатыны да, башкалар да сизмәс әле, – ди.

Дөньяның ачысын-төчесен татыган, акыллы хатын була күрше апасы. Яшь хатынга каз канаты тоттыра һәм болай ди:

– Өеңә кайт та, менә шушы канат белән мичеңне агарт. Әгәр дә бер генә тамчы акшарың да идәнгә төшмәсә, стенага чәчрәмәсә, очрашуыңны дәвам итәрсең.

Яшь хатын өенә кайтып мич агарта башлый. Бер тамчы да тамызмаска тырышып, бик сакланып эшли бу. Өч көн тулганда, мичен агартып бетерә, Никадәр генә тырышмасын, сакланып эшләмесен – идәнгә өч-дүрт тамчы акшар тама...

Кыңгыр эшләребезне күпме генә яшерергә тырышсак та, барыбер сизелми калмый. Бәндә күрмәсә, Ходай күрә, ди торган иде минем бер таныш әби.

6. Хәлфә һәм аның шәкертләре

Элек заманда бер хәлфә, балаларның зирәклеген тикшерү максатыннан, өч шәкертенә мондый мәсьәлә биргән:

– Менә һәркайсыгызга берәр алма. Өегезгә кайтыгыз да алмагызны беркем таба, күрә алмаслык урынга җыеп куегыз. Иртәгә килгәч, минем колакка гына яшергән урыныгызны әйтерсез. Кемнең остарак яшергәнен шунда белербез, – дигән хәлфә.

Ярар, шәкертләр өйләренә кайтып киткәннәр. Икенче көнне килгәч, һәркайсы яшергән урынын хәлфәсенә әйткән. Берсе алмасын агач төбенә күмгән, икенчесе чормага яшергән, өченчесе исә алманы үзе белән алып килгән. «Аны барыбер Ходай күрә, шунлыктан, мин аны яшереп маташмадым», – дигән зирәк шәкерт.

Кыңгыр эшне эшләмә, эшләсәң, сизмәделәр, дип, һич тә тынычланма.

7. Бисмилласыз эш башланмас...

Җәйнең кызу бер көне. Бер төркем хатын-кыз җиләктән кайтып киләбез. Барыбыз да арыган, тамак та кипте. Шунысы куанычлы: һәммәбезнең дә чиләкләре мөлдерәмә тулы. Аз булса да

юлны кыскарту максатыннан, әрәмә эчләтеп, турыдан гына олы юлга бәреп чыгарга булдык. Адәм биеклеге кычытканнар, чытырманнар арасыннан җиләкле чиләкләрне түкмичә алып чыгасы да бар бит әле. Җитмәсә, кермәс борын чебен-черки сырып алды.

– Бөтен җиләкне түгеп бетерәбез икән болай булгач, – диде беребез.

– Бисмиллагызны әйтеп керегез. Абынсагыз да егылмассыз, – диде олы яшьтәге апаларның берсе. Чыннан да, чиләкләребезне дә, җиләкләребезне дә, үзебезне дә исән-сау алып чыктык чытырманлыктан.

Олы кешеләрнең сүзендә бер хикмәт булмый калмый. Теге апаның сүзләре кайта-кайта исемә төшә: «Бисмиллагызны әйтегез... Абынсагыз да егылмассыз...»

Бик тирән, фәлсәфи мәгънә салынган бит бу сүзләргә. Тормыш та бит урман-чытырман кебек. Абынасың да, егыласың да, кабат торып басасың. Ләкин торып басулары бик авыр. Шуңа күрә, абынып егылмас өчен, һәр адымны уйлап, Аллаһының ярдәменә таянып, бисмилла белән атларга кирәктер. Әнә бит әүлияләрнең-әүлиясе булган шагыйрь Акмулла ни дигән:

Һәр заман сүз башланыр «бисмилладан»,
Һәр вакыт эш башланыр «бисмилладан»,
Яхшылар «бисмилласыз» эш кылмаган,
Эш тәмам «бисмилласыз» һич булмаган.

8. Арадан берсе...

Хезмәт юлымны башлап җибәргән Татар Бүләре авылында эшләгәндә (1971–73) ике ел дәвамында Минсафа әбидә фатирда тордым. Минсафа әби авылның Ак әбие булган икән ул заманда. Бик чиста-пөхтә, һәрвакыт ак яулыктан булыр. Күп сөйләшми, биләмгә йөрми, гайбәт сөйләми. Кешенең сөйләгәнен сабыр гына тыңлап тора да, алай икән, ди яки берәр акыллы гына киңәшен биреп куя.

Без ана белән кыз шикелле яшәдек. Ул мине тормышның әле мин белеп-аңлап бетермәгән серләренә төшенергә ярдәм итте. Кешеләрне танырга, аралаша белергә, сабыр һәм итагатьле булырга өйрәтте.

Кичке ашны ашагач, чәй эчкәнче, әбинең ястыгын стенага сөйибез дә, аякларны сузып утырып, рәхәтләнеп, дөнья хәлләрен сөйләшәбез. Әби башыннан үткән гыйбрәтле хәлләрне дә искә ала, улым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла, дигәндәй, мине, үзенчә, ялгышлардан сакларга тырыша.

Берсендә шулай әби: «Кияү таптым дип, берүк шунда ук капланма! Әзрәк нәсел-нәсәбен дә кара, холкын да. Үзеңә тиң кешене сайларга тырыш! Хәер, насыйп дигәнең дә бар бит әле. Инде юньле бәндә туры килсен иде, дип телә», – ди.

Мин исә: «Юк, мин кияүгә чыкмыйм! Исерек белән (әйтерсең, дөнья исерек белән тулган) сугышып-талашып яшәгәнче, лучше, үзем генә яшим мин! – дим, кызып-кызып. – Бала да тапмыйм! Бала-чагадан кем файда күрә!» – дим.

Әби, сабыр гына елмаеп мине тыңлап торды да: «Алай димә, кияүгә чыгып, балалар үстерергә насыйп ит, Ходаем, дип телә. Ходай Тәгалә шуның өчен яраткан безне. Ялгыз калырга язмасын, диген. Исән булсак, ишетербез әле – Гөлфия дә кияүгә чыккан, бәбәйләр үстерә икән, дигән хәбәрләрне», – ди.

Ризык төшмәдеме, вакыт җитмәдеме, Минсафа әби белән яңадан нәкъ 25 елдан соң гына очраштык. Әби инде нык картайган, шулай да элекке мөлаемлыгын җуймаган. Башта танымый-чарак торса да, кем икәнне әйткәч, кочаклап ук алды. Чәйләр эчкәч, хәл-әхвәлләр сорашып, бераз сөйләшеп утырдык.

– Ничек соң, кияүгә чыктыңмы? Бәбәйләреңничәү? – ди әби, хәйләкәр генә елмаеп, төрттереп алуы инде. Онытмаган!

– Чыктым, дим. Өч малаем бар, зурлар инде, дим.

– Ничек соң малайлар? Тәртиплеме? Әйбәтләрме?

– Аллага шөкер, бик тәртиплеләр, акыллылар! – дим, горурланып (әле берсенең институтка кергән чагы гына, икесенең мәктәптә укып йөргән вакытлары).

– И-и, Гөлфиякәем, бала-чаганың арадан берсе ата-ананы көяләндерми калмый инде ул! – дип куйды әбием. Әбинең бу жөмләсе миңа бөтенләй ошамады. Бу олы кешеләр бигрәк мәзәк инде. Ничек алай булырга тиеш, ди. Бу фикер минекеләргә кагылмый, дим, эчемнән генә үртәлеп.

Минсафа әбинең вафатына да байтак еллар үтте. Ак әбинең урыны оҗмахтадыр, иншаллаһ. Әмма әбиемнең соңгы очрашуда әйткән фикере күңелемдә калды. Яши-яши әбинең хаклыгы-

на инандым. Чынлап та, кемгә генә карасаң да, балалар арасында, «арадан берәү» була икән. Күңелем белән өй борынча йөрим, танышларымны барлыйм, кешеләрнең сөйләшкәннәрен тыңлыйм. Һәркемдә бер проблемалы бала бар икән ул. Я ул була тәүфыйксыз, эчкече, юлдан язган... Я була ул авыру... Бер төрлесе, карап торуга акыллы, тәртипле, уңган, булган, чибәрлеге дә бар. Юк инде... гаилә тормышы барып чыкмый; я ирдән, я хатыннан уңмый! Бер төрлесе өйләнмичә яки кияүгә чыкмыйча тилмертә ата-анасын һ.б. Була тагын шундыйлары: үзенең дә башы проблемалардан чыкмый, гаиләсенә дә проблема тудырып кына тора. Нигә шулай икән?

Бервакыт, «Дини календарь»да мондый язма күргән идем. «Пәйгамбәребез сәхабәләреннән берсе: – Аллаһ Тәгалә әйтте ки, кем дә кем Аллаһыны танымый, гөнаһтан курыкмый, хәләл белән хәрамны аермый, шул бәндәмә бер тәүфыйксыз бала бирермен. Бәндәмнең гомере буе җыйган байлыгын таратырга, сәламәтлеген югалтырга, барлы-юклы дәрәҗәсен какшатырга шушы бер бала җитәр», – диде. Бу фани дөньяда, никадәр генә тырышсак та, саф, чиста, гөнаһсыз була алмыйбыз шул. Аллаһның барлыгына, берлегенә инанган хәлдә дә, үзе дә сизмәстән, гөнаһ арты гөнаһ җыя адәм баласы. Кылган гөнаһларыбызның җәзасын дөньялыкта ук күрсәтә Ходай Тәгалә! «Үзеңә бирмәсәм, балаларыңа бирермен», – дигәннәре хактыр!

Булмас димә... була икән... арадан берсе...

9. Сабый бала өчен Ана – нинди булса да ана!

Телевизордан Сабыйлар йортында (Дом малютки), интернат-мәктәпләрдә, балалар йортларында тәрбияләнүчеләр турында тапшыру бара. Берсеннән-берсе матур балалар! Ләкин күзләрендә моң, сагыш, ятимлек ачысы... Сагышлы күзләр ишек ачылган саен өмет белән шул якка текәлә. Менә ачылган ишектән әтисе яки әнисе керер дә кочагына алып, кысып-кысып сөяр. Аннан алар өйләренә кайтып китәрләр...

– Бүлмәгә чит кеше килеп керсә, әтисе-әнисе дип белеп, сырып алалар икән шуны, – ди үзара сөйләшеп утырганда бер танышым.

– Барысы да түгел, – дип бүлдерә аны, берничә ел интер-

нат-мәктәптә тәрбияләнгән икенче берсе. – Әти-әнисен бер тапкыр да күреп белмәгән балалар гына шулай итә. Ә син... барыбер исерек әниеңне көтәсең!...

10. Үги үз булмый...

Бу хәлгә байтак еллар үтте. Әмма кунакка кайткан балаларымны озатканда кабат-кабат исемә төшеп тора.

Юлда, Мөслимгә төшәр өчен, машина көтәбез. Бездән бераз читкәрәк яшь кенә ир дә килеп басты. Хәтсез зур, әмма буш юл сумкасын өчкә-дүрткә бөкләп, култык астына кыстырган. Бер ел чамасы элек әниләре вафат булган иде. Хатынының кырыгы тулуга, әти кеше яңага өйләнде. Аны да гаепләп булмый. Олыгайган ир кешегә ялгыз яшәве бер дә җиңел түгелдер.

– Әнисе исән булса, бу сумка шыплап тулган булыр иде! Шулай инде, анаң үги булса, атаң үзеңнеке булмас! – диде өлкән яшьтәге апа, пышылдап кына. Барыбыз да килешеп баш селкедек.

Ана кеше шулай инде: үзенә калмаса калмый, кеше арасында баласы ким-хур булмасын, ачлы-туклы йөрмәсен дип, төрлесеннән өлеш чыгарырга тырыша.

– Әни, сумканың замогы умырылып чыга бит инде! Тутырма ул кадәр, күтәреп йөртергә дә авыр була, – дип колак төбендә кычкырып тора малайлар, ә минем куллар, һаман бушрак урын табарга тырышып, сумканың эчен капшый... Җибәрә алганда җибәр әле, ди бит күңеле дә.

Һәрнәрсәнең дә кадере югалтканнан соң гына беленә шул...

11. Бер абынган ат

Көтү кайтыр алдыннан авыл агайлары, капка төбенә җыелып, дөнья, авыл хәлләре турында гәп куертучан. Менә бүген дә 4–5 агай Габдерәшит бабайларның коймасы буена өелгән бүрәнәләр өстенә кунаклаганнар да көн яңалыклары белән уртаклашалар.

– Безнең күршегә дә килен төште бит әле бүген, – ди Хәбир агай. – Хөснулланың төпчек улы өйләнгән.

– Бер дә пужар машинасы кебек акыртып машиналар үткәне ишетелмәде бит. Кай арада төште соң ул килен дигәне? – дип сүзгә кушылды икенче берсе.

– Алай машиналар белән маташмадылар. Иртәнге якта, көтү китәр алдыннан гына, матайга утыртып алып кайткан кияү киленне... Күрше авылның балыкчы Шәмси кызы, ди.

– Алай... Аны бик алак-шалак кыз диләр, түгелме соң? Кемнәргәдер ияреп китеп, тегеләре кызны пуезддан ташлап та калдырганнар икән, дип тә сөйләгәннәр иде бервакыт. Торуларының рәте-чираты булырмы икән? Егет, югыйсә, карап торуга, акыллы гына күренә иде. Нишләп ялгышты икән! Хәерле булсын! – ди берсе, хафаланып.

– Ат иясенә килгәч абынмасын, – дип, белдекле генә итеп, теманы йомгаклады өченчесе.

Шул вакытта дөньяның бар якларын – ачысын да, төчесен дә күргән 90 яшьлек Габдерәшит бабай салмак кына әйтеп куйды:

– Бер абынган ат барыбер абына ул, балалар! Абына...

12. Бер горурлык хисе

2006 нчы елны илкүләм «Мәгариф» милли проектында җиңеп чыккан укытучыларны Мәскәүгә җыйдылар. Кремльнең съездлар сараенда үтәчәк «Приоритетлы милли мәгариф проекты хәрәкәттә» дип аталган иҗтимагый-педагогик форумга чакырылучы Татарстан делегациясе составына мин фәкыйрегез дә кергән иде. Форум 22 нче ноябрьгә билгеләнгән. Йөздән артык Татарстан укытучысы 21 нче ноябрь көнне «Татарстан» поездына утырып башкалага юл тоттык. Кемнәр белән, ничек бардык – аларын сөйләп тормыйм. Поезддан төшкәч, башкалар төркем-төркем булып пансионатларга, кунак йортларына таралдылар. Мине бер танышым каршы алган иде. Мин, җитәкчебездән рөхсәт алып, шуларга киттем. Кичке сәгать алтыда башланачак чарага 1 сәгать 45 минутка алдан килеп куясы икән. Җыелу урыны – Мәскәү Кремленең Кутафьево манарасы (Кутафьево башнясы) янында. Танышым мине тиешле урынга китереп куйды да китеп барды. Андагы халык! Үзебезнекеләрне эзләп табарга кирәк бит! Делегация җитәкчеләредер инде:

компьютер кәгазенә язылган плакатларын югарыга күтәреп торалар. Менә «Самарская область», «Красноярский край», «Екатеринбург», «Краснодар» һ.б. исемнәр язылган плакатлар яныннан үтәм. «Ник үзебезнекеләрдән аерылдым инде! Хәзер аларны бу хәтле халык диңгезеннән ничекләр табыйм, кемнәрдән сорыйм!» – дип, эчтән үземне сүгәм. Бервакыт, башымны югарырак күтәреп карасам... күзләремә яшьләр килер дәрәҗәгә җиттем, хәтта! Миннән 40–50 адымнар чамасы гына арада калкурак урынга менеп баскан ике егет (татар егетләре) – берсе Татарстан флагы, икенчесе герб-барслы гербыбыз төшерелгән төсле плакатны югары күтәреп торалар! Халык ташкынын аралап, туп-туры шунда киттем. Башкалар да шул маякка карап килгәннәр икән! Хәтта урыс милләтеннән булганнар да: «Оказывается, наш герб, наш флаг – самый красивый!» – дип, горурлануларын белдерделәр. Үзебездә яшәгәндә боларга артык игътибар да ителми. Гади, гадәти бер атрибутлар кебек. Ләкин чит-ят җирдә, аеруча, илнең башкаласы Мәскәүдә, флаг белән герб күңелләрне кузгатыр дәрәҗәдә күңелгә һәм йөрәккә якын була икән. Еракка китеп кара, дигәннәренә тагын бер кат ышандым!

13. «Беренчесе – гармун, икенчесе – скрипкә»

Газеталарда еш кына статистик мәгълүматлар биреп барыла: күпме бала туган, күпме кеше фани дөнья белән хушлашкан, ничә пар язылышкан, ничәсе аерылышкан... Килүчесеннән китүчесе күп..., аерылышучылар да булып тора. Сүзем соңгылары турында. Зурлап никахлар укытып, туйлар ясап өйләнешкән парлар бит инде боларның күбесе дип куям эчемнән генә. Бер-берсенә соңгы көннәренә кадәр тугры калып, аңлашып, авырлыкларны бергәләп җиңәргә, шатлыкларны да уртак итәргә вәгъдәләр бирешкән булганнардыр... Әмма тормыш дигәнең син уйлаганча гына бармый шул! Тигез юлга караганда сикәлтәләре күбрәк була аның. Бер-береңә ныклап тотынмасаң, сикәлтәләрнең берсендә тормыш арбасыннан төшеп калуың да бар!

Хәзерге аерылышучыларның инициаторлары хатын-кызлар икән. Алар аерылу сәбәбе итеп беренче планга ирләренең

хыянәтен, аннан соң эчкечелекне, шуңа бәйле эшсезлек, акчасызлыкны күрсәтәләр. Әлбәттә, боларның берсе дә гаилә йөген тартып барырга тиешле ир-атны бизәми. Хатын-кыз ир ышыгында хәвеф-хәтәрләрдән сакланып, аны ныклы таянычы санап, аңа ышанып яшәргә дип чыга кияүгә. Гомер буе иренең сөеклесе, бердәнбере булырга, балалар табып үстереп, матур, үрнәк гаилә төзергә хыяллана... Шулай да, хатын-кызлар арасында да иренә хыянәт итүчеләр, исерткеч эчемлекләргә тартылып, бәйдән ычкынганнары да шактый! «Унга барам, уңганчы барам!» – дип, ирдән-иргә йөргәннәре дә бар. Барырсың да, алырсың да... Әмма...

Узган гасырның туксанынчы елларында «Татарстан яшьләре» газетасында Габдрахман Хәмиди дигән бик популяр автор бар иде. Мин аның язмаларын газетадан кисеп алып, бер папкага туплап та бардым әле. Дәресләрдә, тәрбия сәгатьләрендә файдалана идем. Бер язмасы бүген дә исемдә: «Беренчесе – гармун, икенчесе – скрипкә» дип атала иде ул. Габдрахман аганың әлеге язмасында гаилә, гаиләдә ир-хатын мөнәсәбәтләре турында бик үтемле һәм кызыклы фикерләр, тормыш мисаллары бирелгән иде. Беренче хатын, беренче ирне ул гармун белән чагыштыра. Әйе, гармун бик түзем һәм «хадавай» уен коралы. Аны теләсә кайчан уйнап була. Кая гына куйсаң да урын тәфсерләми. Шкаф өстенә куясыңмы, карават астынамы, чоланга чыгарасыңмы, әзрәк тузаннарын каккалагач, бакасына басып бераз кычкыртканалап алсаң, барыбер уйнап китә. Күрекләре өзелгәнче тартканга да чыдый мескен! Ә скрипкә исә бик көйле уен коралы! Аның урыны да коры булсын, тиешле шартларның барысы да үтәлсен. Уйнар алдыннан аны күпме көйләргә кирәк. Аннан соң да уйнаса әле! Икенче ир, икенче хатын да нәкъ скрипкә кебек! Гармуннарыгызның кадерен белегез!

14. Бәхет ачкычы кем кулында?

Безнең ерак бабабыз (әнинең әти-әнисен без ерак әби, ерак бабай, дидек) балаларына гел әйтә торган булган: «Яшь вакыттагы авырлыклар кул чапкан кебек үтә дә китә. Сабыр гына булыгыз. Картайган көнегезгә сорагыз бәхетне Ходайдан. Бәхетле картлык теләгез!»

– Һи, яшь вакытта, дөнья көткәндә, балалар үстергәндә булмагач ул бәхет дигәнең... Әллә картайганчы яшисең, әллә юк! – ди идек, ди әни.

– Аның картлыгы да кул чапкан ара кадәр тизлектә килеп җитә шул, сизми дә калырсыз әле картлык килгәнен, – ди торган булган бабай.

Әйе, юкка гына «иң зур бәхет – бәхетле картлык» дип җырламыйлар шул. Ә бәхетле картлык ул – тәүфыйклы балалар, диләр. Кеше гомере бик кыска дисәләр дә, аның картлыгы озын, диләр. Кеше гомере – табигать фасыллары белән тәңгәл килә бит!

Адәм баласының картлыгы гомер «языңны», «җәеңне», «көзеңне» ничек үткәрүеңә бәйле. Шул чорларда тырышып дөрес тормыш итсәң, үзеңә алмашка лаеклы, тәүфыйклы, акыллы-сәламәт балалар үстерсәң, гомер «кышың» да бәхетле булыр. Шулай бит (авыл мисалында), яздан башлап кара көзгә кадәр бакчаңда казынсаң, печәнеңне, ягарга утыныңны әзерләсәң, йорт-җиреңне ныгытсаң, кышлык ит, яшелчә запасын булдырсаң, кышны бер гамьсез чыгасың!

Гомер дә шулай!

15. Рәхмәт көне турында

Берләшкән Милләтләр Оешмасы һәм ЮНЕСКО карары белән 11 гыйнвар – Бөтендөня рәхмәтләр көне дип билгеләнгән икән. Максаты да изге: планетада яшәүчеләргә бер-береңә ихтирам, яхшы гадәт һәм күнекмәләр кебек төшенчәләрнең нинди зур әһәмияткә ия икәнен тагын бер кат исләренә төшерү, янәшә тирәндәгеләргә эшләгән яхшылыклары, изге гамәлләре өчен рәхмәт белдерү күнекмәләрен ныгыту.

Һәр халык, һәр милләт рәхмәт сүзен төрлечә белдерә. Мәсәлән, без – татарлар, рәхмәт, дибез. Гарәпләр – шүкрән, төрекләр, әзәрбайҗаннар – тәшәккүр, урыс халкы – спасибо, французлар – мерси, итальяннар – грацио, немецлар – данке, данке шон, инглизлар – сенк ю һ.б.

Рәхмәтне әйтүе дә, ишетүе дә бик рәхәт! «Әйтергә дә шулкадәрле рәхәт сүз ул! Сез ничектер? Яратам мин рәхмәт сүзен» (Х. Халиков). Әмма еш кына, рәхмәт белән тун текте-

реп булмый, коры рәхмәт, рәхмәткә генә эшләү, рәхмәтне кесәгә салып булмый яки ашап булмый, теге рәхмәтең дә бернәрсәгә дә ярамады, һ.б.ш. сүзләр белән рәхмәт сүзенең дәрәҗәсен төшерәбез. Урысларда да бит рәхмәт сүзе шәфкать, мәрхәмәт, аяу, кичерү дигәнне аңлата. Аллаһ сиңа да мәрхәмәтле, шәфкатьле булсын; гаеп-гөнаһларыңны кичерсен, ягъни! Урыс та бит «спасибо» ди! (Спаси, бог, сүзеннән). Аллаһ сакласын, Аллаһ ярлыкасын, ди алар да. Элек урысларда спасибо сүзе урынына благодарю, благодарствую сүзе йөргән. Спасибо сүзе беренче тапкыр 1586 елны Парижда чыккан телара сүзлектә теркәлгән икән.

Балаларны тәрбияләү гаиләдән башлана, дибез. Чыннан да, иң гади, әмма иң кирәкле сүзләрнең берсе булган рәхмәт сүзен бала кешесе бишектән үк ишетеп үсәргә тиеш. Үзен белә башлауга ук, ашап туйгач, һичшиксез, рәхмәт әйтергә өйрәнсен ул. Элек әби-бабайлар, ашаганнан соң, иң әүвәл балаларны әппәр итәргә, аш өстәле яныннан киткәндә, рәхмәт әйтергә өйрәтүне иң әһәмиятле һәм иң беренче тәрбия сабагы дип санаганнар. Минем каенанам оныкларына рәхмәтне әтигә, әнигә, әби белән бабайга аерым-аерым әйтергә куша иде (рәхмәт, әти; рәхмәт, әни; рәхмәт, әби; рәхмәт, бабай). «Әти белән әни өйдә булмаса да әйтергәме? – дип сораса балалар, – әйтегез, ата-анага рәхмәтне гомер буена әйтсәң дә таманга туры килер», – дия иде. Үзенә яңа кием, кеше кулыннан күчтәнәч һәм бүләк алгач та балалар рәхмәт әйтә белсен. Берәрсе аңа ярдәм күрсәтсә дә, рәхмәт әйтсен. Үзе дә рәхмәт җыйсын, чөнки рәхмәтнең савабы күп. Бу турыда алдагы чыгышларымның берсендә әйткән идем инде. Балаларыбызны, оныкларыбызны рәхмәтле, кешелекле итеп тәрбияләү бездән дә тора, хөрмәтле әти-әниләр, әби-бабайлар!

Без үскәндә суын эчкән чишмәләр кипкән инде,
Моңнарына уралдырган сандугач киткән инде.
Былбылларсыз гармуннар да моңнарын онытканнар,
Моңсыз, нурсыз яшәештән ни калыр оныкларга?
...Ни калыр оныкларга?

*(Шагыйрә **Лилия Садриева**.*
2016–2017.)

V бүлек

ТУКАЙ УКУЛАРЫ

1. «Без – Тукайлы халык»

Хөрмәтле радио тыңлаучыларыбыз! Сезнең игътибарга **«Тукай укулары»** дигән яңа сәхифә тәкъдим итәргә булдык. Әлеге сәхифәбездә Тукай, аның тормышы, биографиясендәге кызыклы моментлар, иҗаты турында сөйләрбез.

– Күпме сөйләргә була инде ул Тукай турында! – диярләр кайберәүләр.

– Кем соң инде ул Тукай?! Искитәрлек нәрсәсе бар соң аның! – диярләр икенче берәүләр.

– Тукай да Тукай! Әйтерсең, бүтән язучы-шагыйрьләре юк татарның! – дияр өченчеләр.

– Болай дип бары тик Тукайны белмәгәннәр генә әйтә ала! – ди язучы Рабит Батулла.

– Мин Такташның беренче чор иҗаты белән җенләнеп йөргән заманда (1969 ел) аны Тукайдан өскәрәк куеп сөйли идем, – дип дәвам итә Р. Батулла. – Бу сүзләрне ишеткәч, Фәрваз Миңнуллин, зиһенгә үткәзерлек итеп: «Син Тукайны яңадан өйрәнеп чык! Такташ – зур шагыйрь! Тукай исә – гасырлар шагыйре! – дигән иде», – ди.

– «Тукай» дигән фән булырга тиеш! – дигән мәрхүм галим Альберт Фәтхи. – Тукайның һәр сүзенә, һәр шөгыленә тарихигыйльми аңлатма, шәрех булырга тиеш киләчәктә.

Танылган эстрада җырчысы Алсуның (Алсу Сафина) газетага биргән бер әңгәмә язмасын укыган идем элегрәк. Шундагы бер-ике фикере күңелемә кереп калган. Ул бит Англиядә белем алган. «Англия мәктәпләрендә, – ди ул, – әдәбият дәресләрендә барлык сыйныфларда да Шекспир тормышы, иҗаты дәвамлы рәвештә энәсеннән җебенә кадәр өйрәнелә. Төп басым шуңа ясала. Ә тарих дәресләрендә исә Англия тарихы өйрәнелә. Россиягә кайткач, мин рус әдәбиятын һәм ил тарихын укыдым, өйрәндем,

ди. Димәк, инглизлар күптән инде мәктәпләрендә «Шекспир» дигән фән укыта икән! Һәм иң әүвәл үз тарихларын җентекләп өйрәнүгә игътибар биреп тә дөрес эшлиләр! Урысның Пушкины, инглизның Шекспиры булган кебек, безнең дә Тукаебыз бар бит! Нигә безгә дә шулай эшләмәскә!

«Татар галимнәренең вә чит илләрдәге фән эшлеклеләренең даими эзләнүләренә карамастан, Тукайның иҗаты һәм аның шәхси хәяты турында әле соңгы сүз әйтелмәгән, чөнки ул фән – чиксез дәвам», – ди язучы Рабит Батулла.

Без – Тукайлы халык! Тукайлар гасырга яки берничә гасырга бер генә туа! Тукайны белик, белмәсәк – укыйк, өйрәник! Тукай белән чын күңелдән горурланырлык булсын киләчәк буыннарыбыз. Ә бу безнең үзебездән тора.

Илаһи моң булып шагыйрь гомере
Яңгырап тора шушы көнгәчә.
Ак сакаллы картлар яшь Тукайга:
– Остазыбыз! – диеп эндәшә.
Бөеклекнең сере яшьтәмени?!
Сере нидә – сора халыктан:
Шагыйрьләре белән авырган ул,
Шигырьләрен укып савыккан!..

(Нур Әхмәдиев)

2. Тукай шагыйрьлек турында. Шагыйрь булу җиңелме?

– Тукай ни өчен шагыйрь булган? Ни өчен язучы яисә драматург булып китмәгән? Яки җырчы булмаган? Ә бит ул бик матур җырлаган, ди. Шундый сораулар күпләрнең башына килергә мөмкин. Мәктәп елларында, әле аннан соң да үземнең башыма да еш кына шундый фикерләр килә иде. Яши-яши, Тукай иҗатын өйрәнә һәм укыта торгач, бу сорауларга азмы-күпме җавап таба башладым.

Беренчедән, Тукайга туганчы ук **илаһи куәс (**сәләт, талант) салынган. Ходай Тәгалә аны дөньяга шагыйрь итеп яраткан. Шагыйрь үзе дә: «Бу шагыйрьлек миңа Алла тарафыннан бирелгән бер куәт. Шунлыктан аның берлән мактанырга хакым юк», – дия торган булган. **Геннарның роле дә зур**.

Тукай – ике яклап та муллалар, укымышлылар нәселеннән. Әтисе Мөхәммәтгариф – Кушлавыч авылының мулласы, җиде буыннан килә торган муллалар затыннан. Телгә-сүзгә бик оста, мәзәкчел кеше булган. Әнисе Бибимәмдүдәнең үзе өчен генә шигырьләр язуы билгеле.

Бибимәмдүдәнең әтисе Зиннәтулла хәзрәт тә шигырьләр язган. Яраткан беренче баласы, сөекле кызы Бибимәмдүдә вафатына багышлап язылган мәрсиясен (кайгылы шигырь, некролог) Өчиле халкының шактые күңелдән белгән.

Элек мәдрәсә шәкертләре шигырь дәфтәрләре тотканнар. Бер-берсенең дәфтәренә шигырьләр язганнар. Кайберсе үз шигырен, икенче берәүләр башка каләм әһелләренең мәгънәле шигырь юлларын истәлеккә калдырганнар. Тукайны күреп белүчеләрнең истәлекләренә караганда, ул **үз шигырьләрен** бүләк итеп урнаштырган. Рифмалы итеп тапкыр җавап бирүдә, такмак, җыр һәм сатирик куплетлар чыгару остасы булып танылган Габдуллага шигырь юллары яки куплетлар язу авыр булмагандыр. «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыганда «Әшгарь мәҗмугасы» («Шигырь җыентыгы») төзегәнлеге билгеле. Бу – 1902–03 еллар.

Аннан соң шунысы да мәгълүм булсын: элекке мәдрәсәләрдә Көнчыгыш әдәбиятының шактый әсәрләре (ә алар шигъри телдә язылган), Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбияты үрнәкләре өйрәнелгән, укылган. Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбияты исә – шигъри әдәбият. Бездә беренче повесть һәм романнар, драма әсәрләре 19 нчы гасырның икенче яртысында гына күренә башлый. Булгандыр элек тә проза жанрына караган әсәрләр (романнар, повестьлар), ләкин алар сакланмаганнар. Казан шәһәрендә Колшәриф хәзрәтләре туплаган зур китапханә язмышы бүгенгә кадәр билгеле түгел. Нинди генә китаплар булмагандыр анда! Әмма 1552 ел гарасаты аларны җир белән тигезләгән...

Мотыйгулла хәзрәт – «Мотыйгыя» мәдрәсәсенең хуҗасы – (атаклы җырчы Галия Кайбицкаяның әтисе) мәдрәсәдә гаруз дәресе, ягъни шигырь төзелеше фәнен укыта. Шәкерте Габдуллага гарәп, фарсы, төрек шигырьләре кануннарын ул өйрәткән.

1900 елда Уральскига Мирхәйдәр Чулпаный исемле шагыйрь килеп чыга. Габдулла үз гомерендә беренче мәртәбә тере шагыйрь күрә, хәтта аның белән якыннан таныша, дуслаша. 1902–1903 елларда, «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә Габделвәли

Әмрулла дигән бер төрек шәкерте укый. Ул шигырьләр язган, Габдулла белән дуслашкан. Шигырьләрен дусты Габдуллага матур итеп яттан укый торган булган. «Менә шул кешегә, миңа дөньяга кararга күземне ачкан өчен, гомерем барында рәхмәт укыйм», – дип яза соңрак Тукай.

19 нчы гасыр азагында Уральск шәһәрендә «Пушкин йорты» ачыла. Бу йорт киң җәмәгатьчелекне рус классикларының тормышы һәм эшчәнлеге белән таныштыру эшләре алып барган. 1899 елда Пушкин, 1902 елда Гоголь, Некрасов, Жуковский, Успенский юбилейларын үткәрәләр. Бу чаралардан Тукай читтә калмаган булырга тиеш.

Көнчыгыш әдәбияты һәм Борынгы, Урта гасыр татар әдәбиятының энҗе-мәрҗәннәре белән якыннан таныш булган Тукайга югарыда санап кителгән һәм башка сәбәпләр, шартлар аның шагыйрь булып китүенә нигез булып тора.

«Шагыйрь» шигыре

Әдәбиятчылар Г. Тукайның матбугатта басылып чыккан беренче шигыре итеп 1905 елда язылган «Гыйлемлек бакчасында күңел ачып йөрик» дип башланган исемсез шигырен атыйлар.

Татарларның бөеклеге, даны сигез кат күкләргә китсен;
Мәңге, һәрвакыт бу милләтне Ходаем бәхетле итсен.
Газеталар, журналларны көннән-көнгә, кат-кат күбәйтик,
Мәгариф мәйданында без, татарлар, ат уйнатыйк, –

дип, иң беренче басылган шигырендә үк халкыбызны фән, мәгариф өлкәләрендә уңышлар яуларга чакыра, туган милләтенә зур өметләр баглый. 19 яшьлек егет әле үзен шагыйрь дип исәпләми.

Шигырь бабында юк миндә мәһарәт,
Фәкать бу тугърыда кыйлдым җәсәрәт, ягъни,
Шигырь язарга миндә осталык юк,
Тик әле кыюлык итеп кенә яздым, –

ди икенче бер шигырендә.

Әлбәттә, Тукай 19 яшькә кадәр язмый тормаган. Тукайчылар аның 1900 ел башыннан әкренләп каләм тибрәтүе турында әйтәләр. 1905 елда аның унлап әсәре дөнья күрә. Шундый

җитди шигырьләр язу һәм матбугатка чыгару өчен байтак әзерлек кирәк.

Г. Тукай үзе шагыйрьлеккә югары бәя бирә, аны «Сәмави сүз» («Күк сүзен») сөйләүче итеп күз алдына китерә. Аның фикеренчә, чын шагыйрь, ихлас шагыйрь бары тик дөресен генә язарга тиеш. Ул куркып калмаска, тормыш ваклыкларыннан өстен торырга, ирекле булырга, халкының «ачы хәсрәт көен» көйләргә тиеш.

Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә,
Мәгълүмдер ки, курку белән өркү хәрам, –

дип, каләмне, каләм сүзен зур көчкә тиңли. Шагыйрь шигърияткә уен-көлке чарасы итеп түгел, бәлки, кешеләрне тәрбияләү, тормышны матурлау, җәмгыятькә тәэсир итүнең көчле коралы буларак карый.

Тукай шигърияткә тугры булып кала. Өстенә, үзе әйткәнчә, яла, нахак сүзләр, көнчелекләр яуса да, юлына һәр төрле киртәләр корылса да, ул яза, дөресен яза! Кемнәргәдер ярарга тырышу, ялагайлык, мескенләнү аңа хас сыйфатлар түгел. Уры-ны белән «әче телле», туры сүзле Тукай булып кала.

Очырмакчы булсам былбыл күкрәгемнән,
Әллә ничек! – мыр-мыр итеп мәче чыга! – ди.

– Шагыйрь үзе, тәне картайса да, күңеле япь-яшь, җаны көчле булып кала, ди «Шагыйрь» шигырендә. Ә бер шигырендә, шагыйрь икәнсең,

Баш имә, зур син, бу түбән җанлылар дөньясына;
Падишаһ син! Бик кирәксә баш исен дөнья сиңа! –

дип, шагыйрьне әдәбият дөньясының падишаһы, дип атый.

Тукай, гомере буе, туры Тукай булып кала. Ул тормышка җайлашмый, өстен катлаулар, бай түрәләр алдында баш ими. Нәрсә уйлаганын һич рияланмыйча әйтеп бирә. Ул үзенең шагыйрьлек вазифасын әнә шулай намусы кушканча башкара.

1913 нче елның мартында, гомеренә йомгак ясап, «Кыйтга» шигырен яза:

Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,
Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.
Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,
Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.
Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакъли алмадым.

3. Тукай иҗатында халык, аның язмышы, гражданлык лирикасы

Узган тапшыруда Тукайның матбугатта басылган беренче шигыре – «Гыйлемлек бакчасында күңел ачып йөрик» дип башланган исемсез шигырен телгә алган идек. Каләм тотып, әдәбият дөньясына атлаган яшь кеше, гадәттә, табигать күренешләрен тасвирлый, туган авыл, туган җир турында һәм мәхәббәт турында яза. Ә Тукайның матбугатта басылган беренче шигырьләрендә үк халык язмышы, аның киләчәге, киләчәген тәэмин итүче шартлар – мәгариф, фән өлкәсендә уңышлар яуларга чакыру, милләткә зур өметләр баглау төп урынны ала.

1905 елда язылган «Дустларга бер сүз» шигырендә, милләтнең хәлен җиңеләйтү өчен, кулга-кул тотынышып эшләргә, көрәшергә өнди. Алга киткән милләтләрдән үрнәк алып, «егла-тора алга таба атлыйк», ди. **Хөррият, азатлык**, ди шагыйрь, үсеш, алга китү юлыннан барырга мөмкинлек бирәчәк. Мәдәният мәйданында ат уйнату, безнең мәнфәгатьләрне кайгыртучы депутатлар сайлап, Петербургка җибәрү, башкалада үзебезгә кирәкләрне сорау тиеш. Без «дөнья оҗмахына» керергә тиеш. Ләкин бу эшне муллаларга йөкләргә ярамый, чөнки: «Дин эшендә башчы иттек без аларны».

«Яхшы булыр тапшырсак без дөньяларны
Абразауный егетләргә тәмам имди», –

ди.

«Иттифак хакында» (ягъни берләшү, 1905) шигырендә шагыйрь **халыкны иң зур көч** дип таный. Һәр көнне үзгәрә барган дөньяда йоклау тиеш түгел! Бердәнбер дөрес юл – **иттифак,** ягъни үзебезне һәм көчебезне берләштерү, ди. Шигырь берләшергә чакыру белән тәмамлана:

Ачыйк иттифакка юл,
Ушбудыр иң тугъры юл.

«И каләм» шигырендә шагыйрь, дөньядан артта калуыбызның төп сәбәпләреннән берсе итеп, **наданлыгыбызны** атый. Бәхет һәм якты киләчәгебез нигезе – **белем**, дигән фикерне әйтә.

Чакырып яз укырга, уку кыйммәтен тәкъдир ит;
Наданлыкның начарлыгын, аңлат агу икәнен, –

ди.

Г. Тукайның 1911 елның мартында шагыйрь С. Рәмиевкә язган бер хатында мондый юллар бар: «Мин поэт (шагыйрь) кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә...». Чын шагыйрь, халык шагыйре әнә шундый булырга тиештер, нәкъ Тукай кебек!

Тукайның «дипломат, политик, общественный деятель дә» икәнен раслый торган ике шигыренә тукталып китик.

1907 елны Петербургта Дәүләт Думасы утырышларының берсендә милли төбәкләрдән килгән мөселман депутатлары үз халыкларының авыр тормыш хәле, мәктәпләрнең мөшкеллеген әйтеп чыгыш ясыйлар. Ләкин уң депутатлар һәм реакцион матбугат мөселманнарның бу хәлен аңларга теләмиләр, киресенчә, «әгәр сезгә Россиядәге тәртипләр ошамаса, Төркиягә китегез» дип кычкырыналар. Г. Тукай моңа каршы «Китмибез» шигыре белән җавап бирә. Безнең хәлне Солтан җиренә, ягъни Төркиягә китү юлы белән генә яхшырту мөмкин түгел. Чөнки һәркем үз җирендә бәхетле тормыш төзергә тиеш. Ә безнең ата-бабаларыбыз күп гасырлардан бирле шушы җирләрдә яшәгән. Безне бу җиргә кодрәтле Тәңребез үзе бәйләгән, монда туганбыз, монда үскәнбез. Димәк, әҗәлебез дә монда булырга тиеш. Безнең бөек максатыбыз – ирекле мәмләкәт (дәүләт) булдыру. Шагыйрь сүзне Думада безне Төркиягә куарга теләгән депутатларга аларның үз телләрендә мөрәҗәгать итеп тәмамлый: «Если лучше вам, туда сами пожальте, господа!», ягъни, «анда яхшырак икән, үзегез шунда рәхим итегез, әфәнделәр!» – ди.

1913 елда Романовлар нәселенең Россия белән патшалык итә башлавына 300 ел тулуны бик зурлап бәйрәм итәргә әзерләнәләр. Зур юбилей бит! Әле хәзер дә нинди дә булса юбилей, дата алдыннан халык өметләнеп югарыдыгылардан нидер көтә. Ул вакытларда да шулай булгандыр. Г. Тукай шушы юбилей уңаеннан «Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык өмитләре» шигырен яза. Шагыйрь татар халкының тарихын һәм язмышын күз алдыннан уздыра. Төньяктан (шимальдән), ягъни Рус дәүләте башкаласы ягыннан ак болыт күренсә (бу очракта хәбәр килсә), без өметләндек, безгә бәхет китерүче хәбәр түгелме, «мәңге михнәт, мәңге рәнҗешләр бетәр» дип өметләндек, ди. 1552 елдан бирле узган 361 елны шагыйрь әнә шулай «мәңге

михнәт, рәнҗешләр чоры» дип атый, аның бетүенә өмет итә. Патша хәзрәтләре, олуг юбилей уңаеннан, бәлки, халыкка җиңеллек китерә торган, күз яшен киптерергә китерүче «Манифест» чыгармасмы, дип өмет итә. Ләкин өметләр акланмый. Ә бит татар халкы «рус җирендә әсәрле, эзле; тарихында бер дә тапсыз көзге».

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк?
Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук! –

дип, татар халкының да урыны түрдән булырга тиешлеген кискен итеп куя. Әмма патшаның җиңеллек китерүче әмерен көтү буш хыял гына шул!

Бу шигырь 1913 елның февралендә, шагыйрьнең үләренә ике ай калгач язылган. Бу аның гомер сәгатьләренең соңына кадәр туган халкы турында сызлануын күрсәтә. Президент тарафыннан чыгарылган Указ белән Халык шагыйре исеме бирелмәсә дә, Тукайны халык үз шагыйре итеп таныды! Чөнки аның шәхси тормышы да, туган халкының язмышы да бертөсле булды. Халык көен көйләде, халык җырын җырлады! Халык алманы шалканнан аера белә ул!

Мескен халык, мескен хаклык булмый,
Мескен шагыйрь була дисеңме?
Батыр дигән сүзгә рәттән куйыйк
Тукай дигән горур исемне!
Якты йолдыз булып атылган ул,
Зәгыйфь чәчәк булып сулмаган.
Туры Тукай, моңлы Тукай булган –
Бөек булган, боек булмаган!

(Ш. Гали)

4. Тукай иҗатында табигать, туган җир

Мәктәп елларында беренче тапкыр Тукайның «Туган авыл» шигыре белән танышканнан соң, Тукай безнең авыл кешесе түгелме икән, дигән үтә самими хис туган иде. Әнә бит ничек белеп язган ул:

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул...

Безнең авыл да тау башына салынган. Ә тау астында таллар, өянкеләр әйләндереп алган Салкын чишмә күле җәелеп ята. Күлнең төбеннән салкын чишмә бәреп тора, шуңа күрә күлне Салкын чишмә күле дип атыйлар, ди иде өлкәннәр.

Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңа күрә сөям җаным-тәнем белән.

Мин дә бит үз авылымны җаным-тәнем белән сөям. Кая гына барсам да, аның табигатен, кешеләрен, хәтта урамда чабулап йөргән кәкре койрыклы этләренә кадәр сагынып кайтам. «Шүрәле»се белән танышканнан соң, Тукай, һичшиксез, безнең авылныкы, дигән фикер ныклап урнашты күңелемдә. Үзеннән үзе хәтердә кала торган, бер караганда гади, әмма образлы шигырь юллары әнә ничек тезелеп китә.

Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк,
Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк!
Бик хозур! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;
Төпләрендә ятканым бар хәл җыеп күккә карап.

Нәкъ безнең авыл урманын язган бит! Күз ачып йомганчы безнең урманнарда гына җыеп була җиләкне! Нарат урманы эченә сыенып диярлек утырган авыл тагын кайда булсын безнең авылдан башка!

Мондый хисләр бер миндә генә тумагандыр ул вакытларда. Күпләр кичергәндер мондый халәтне. Меңләгән кешенең хистойгыларын уятып, аларның күңелендә йөргән сагыну, җирсү, ярату хисен болай итеп чын шагыйрь генә бирә ала. Менә бу инде шагыйрьнең осталыгы, шигъри сүзнең тәэсир көче, классика!

Рәссам табигать күренешләрен буяулар ярдәмендә җанландырса, каләм ияләренә бу очракта сүзләр ярдәмгә килә. Тукайның табигать турындагы шигырьләре сүзләр ярдәмендә

ясалган картиналар алар. Шул ук «Туган авыл», «Чыршы», «Җир йокысы», «Кышка бер сүз», «Яз галәмәтләре», «Җәй көнендә», «Җәйге таң хатирәсе» шигырьләренә буяу һәм пумалаларыңны ал да рәсем яса. Ләкин теләсә кем Тукай шигырьләрен рәсем итеп төшерә дә алмас, мөгаен.

Тукай шигырьләрендә туган ягыбызның табигате, матурлыгы, байлыгы һәркем горурланырлык итеп бирелә. Табигать тасвирлары аша шагыйрь халкын табигатьнең, туган җирнең кадерен белергә, сакларга өнди, горурлык хисләре, патриотизм хисләре тәрбияли. Чөнки Туган җир ул синең кендек каның тамган, тәпи атлап киткән җиреңнән башлана. Туган җир, Туган ил – ул син туган йорт, синең нигезең! Ярат син аны, сакла син аны! Синең авылыңны, синең төбәгеңне, синең шәһәреңне, синең илеңне читләр килеп күтәрмәс, ярдәм итмәс. Аларга бу җирләр һәм аның байлыгы гына кирәк! «Пар ат», «Туган җиремә», «Туган авыл» шигырьләре балаларыбызның дога урынына ятлый торган шигырьләре булса иде! Туган җирләреннән аерылып киткәннәр дә:

Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр Туган җирем, –

дип әйтерлек булсын иде!

5. Тукай һәм балалар әдәбияты

«Бәйрәм вә сабыйлык вакыты» шигырендә Тукаебыз болай ди:

Сабый вакытын сагынмакта һәр шагыйрь дә,
Ачы, тәмле хыялдыр бу һәр шагыйрьгә.

Шагыйрь һәм язучылар арасында балалар турында, балаларга багышлап язмаганнары юктыр яки бик сирәктер. «Без – барыбыз да балачак иленнән!» – дигән гыйбарә дә бар бит әле. Олыгайгач, һәммәбез дә балалык елларын сагынып искә алабыз. Иң рәхәт, ваемсыз, бәхетле чаклар булган бит ул еллар! Балачак шуклыклары, мажаралары һәркем күңелендә матур хатирәләр булып калган. Хәзер без аларны, уенын-чынын бергә кушып, бераз гына төрләндереп, арттырыбрак балаларыбызга, оныкларыбызга сөйлибез. Шулай итеп, истәлекләргә бирелеп булса да, балачак дөньясына экскурсия ясап алабыз. «Без

дә төшеп калганнардан түгел идек», – дигән кебек, балалар алдында бераз мактанып алабыз. Үзебезчә балаларыбызны тәрбияләргә тырышабыз, үгет-нәсихәт биргән булабыз, үзебез эшләгән ялгышлардан сакларга омтылабыз. Каләм әһелләре исә бала күңеленә әдәби, образлы сөйләм аша тәэсир итә. Аларның да төп максаты – балаларны тәрбияләү.

Г. Тукайның 1982 елда Татарстан китап нәшриятында басылган «Сабыйга» дигән җыентыгы бар. Әти-әниләр өчен дә, балалар бакчаларының тәрбиячеләре өчен дә, укытучылар өчен дә бик кирәкле ярдәмлек ул. Бишек җырларыннан башлап, шигырь белән язылган әкият-поэмалары да кертелгән һәм эчтәлеге белән саллы гына китап. Бала күңелен аңлап, балалар теле белән язылган, бала күңелендә кала торган, тиз хәтергә сеңә торган рифмалы тезмәләрне бүтән шагыйрьләрнең әсәрләре белән бутый алмыйсың. Алар үзләре үк: «Без – Тукайныкы!» – дип кычкырып торалар.

Тукайның балалар өчен язган шигырьләрендә **әдәп-әхлак** һәм **хезмәт тәрбиясе** беренче планда тора. Чөнки кечкенәдән әдәп-әхлакка ия бала ата-анасын, әби-бабасын, туганнарын ярата, хөрмәт итә, зурлый. Тәрбияле, тәртипле, тәүфыйклы бала – ата-ананың гамьсез киләчәге. Кечкенәдән хезмәт яратып, һөнәргә өйрәнеп үскән бала – ата-анасының да, милләтнең дә, җәмгыятьнең дә ышанычлы таянычы. Тырышлыктан, хезмәттән башка бернәрсәгә дә ирешеп булмый.

Шагыйрь «Эш» шигырендә балаларны Кояштан үрнәк алырга чакыра. Әнә бит Кояш иртә таңнан караңгыгача эшли: җир йөзен яктырта, җылыта, үсемлекләрне үстерә.

Син кояштан үрнәк алсаң, иҗтиһад итсәң һаман,
Күп арасында кояш күк ялтырарсың бер заман! –

ди шагыйрь.

Әмма һәр нәрсәгә дә яшьли өйрәнергә кирәк шул.
Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул,
Картаеп каткач буыннар эш белү уңайсыз ул!

(«Кызыклы шәкерт»).

Әле шунысы да бар:

Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел,
Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел!

(«Эшкә өндәү»).

Бу фикерләрне тыңлаганнан соң, бик күпләр: «Тукаең да, үзең дә белеп сөйләмисең! Эшләп, кем баеган да, кем рәхәт күргән? Әрсез, оятсыз, усал, хәйләкәр, ялагай булсаң, урлаша белсәң, эшләмичә дә яшәп була. Бәхетең булсын. Ялкаунык-ы, көчленеке замана!» – дип, бәхәскә керерләр. Балаларыбызга менә шундый тәрбия биреп, без, ата-аналар, әби-бабайлар үзебезгә баз гына казыйбыз. Менә шушы «киңәшләрне», «дәресләрне» (бу сүзләр куштырнаклар эчендә) тыңлап үскән балалардан киләчәктә иң әүвәл үзебез иза чигәчәкбез. Җиңел килгән бәхетнең, малның, тормышның гомере озын, ахыры хәерле булмый. Моны тормыш үзе әледән-әле раслап тора.

Авыр хезмәтләрнең берсе – уку. Әмма уку кирәк. Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә «Бишектән ләхеткәчә» диелгән бит, ягъни кеше гомер буе укырга, өйрәнергә, эзләнергә тиеш. Ленин бабайның мәшһүр «Укырга, укырга һәм укырга!» лозунгысы шушы хәдискә нигезләнгән дип язалар бит хәзер!

Өч наданга алмашынмас – бер язу белгән кеше,
Мәгърифәт эстәр, иренмәс һич – кеше булган кеше.

Шагыйрь, үзе әйткәнчә, ягъни татарларның бөеклеге, даны сигез кат күкләргә китсен өчен, белемле булырга, хезмәт ясатырга, эшләргә кирәк. Наданлык, хәерчелек кешене мескен хәлгә төшерә. Мескен, хәерче милләт кемгә кирәк тә аның нинди дәрәҗәсе булсын!

Менә аның ***«Бәхетле бала»*** шигыре.

Бәхетле шул баладыр, кайсы дәресенә күңел бирсә,
Мөгаллимне олуг күрсә, белергә кушканны белсә.
Сабакка калмаса соңга, борылмый барса уң-сулга,
Уенга салмаса ихлас – менә бәхете аның шунда!
Кечеләргә итеп шәфкать, үзеннән зурларга юл бирсә,
Бәхетсезләрне кимсетми, егылганнарга кул бирсә.

Алты юллык шигырьгә әдәп-әхлак тәрбиясе дә, хезмәт тәрбиясе дә сыйган. Алда китерелгән шигырь юллары, әлеге шигырьнең һәр юлы мәкаль булып та йөри ала. Гомумән, Тукай иҗаты афоризмнарга (хикмәтле сүз) искиткеч бай! Аларны җыеп тупласаң, бер җыентык чыгарырга була.

6. Тукай һәм балалар әдәбияты (дәвамы)

Балаларның Тукай иҗаты белән танышуы аның атаклы «Туган тел» шигыре белән башланадыр дип уйлыйм. Үземнең дә беренче тапкыр ятлаган шигырем «Туган тел» булды. Әле дә хәтерлим: беренче класска барасы елның җәендә әни ятлатты бу шигырьне.

– Укырга баргач, укытучы апаң, берәр шигырь беләсеңме, дип сораса, чатлатып сөйләп бирерсең шушы шигырьне, – дигән иде. Әле шунысы да хәтеремдә: без укыячак «Туган тел» китабының иң беренче битендә иде бу шигырь!

Туган тел турындагы иң матур шигырь, иң җылы, гади дә, шул ук вакытта үлемсез шигырь дә ул. Һәр татарның күңел түрендә, йөрәгендә сакланырга тиешле шигырь.

«Туган тел» шигыренең дүртенче строфасын күп еллар китапларда, дәреслекләрдә бастырмадылар. Имеш анда, Ходай турында искә алына:

И туган тел, синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

Казакъ әдибе Мохтар Ауэзов Тукай иҗатын бик яхшы белгән һәм яраткан. Дүртенче строфаның бирелмәвен белгәч, ачуланып: «Нишлисез сез? Мин ул шигырьне бала чагымнан ук яттан беләм. Ничек инде соңгы ике юлны кисәсез?» – дигән.

Бала – ата-ананың догачысы да бит әле! Балаларның теләкләре тизрәк кабул була. Ата-анасы исән чакта да, бакыйлыкка күчкәч тә, аларның гөнаһларын ярлыкауны сорап теләк теләүче, искә алып, хәер-сәдакасын бирүче, дога кылучы да бала булырга тиеш. Тукай әнә шундый искиткеч гуманлы караш үткәргән әлеге дүртьюллыкта. Ләкин атеизм тарафдарларына бу юллар ошап бетмәгән булса кирәк. Шөкер, хәзер һәр бала, һәр татар бу юлларны курыкмыйча сөйли ала!

Тукайның балалар өчен язылган шигырьләре – үзләре бер тәрбия мәктәбе! Тукай шигырьләрендә табигатьтәге, тормыштагы һәр нәрсә җанлана. Һәр җан иясе дә кешеләр кебек: уйный, көлә, шатлана һәм кайгыра. Аларның да үз тормышлары бар. Һәммәсе яшәү өчен, тормышта үз урынын табу өчен көрәшә. «Бала белән күбәләк», «Бичара куян», «Карлыгач», «Фатыйма

белән Сандугач» һәм башка шигырьләре аша шагыйрь һәр җан иясенә хөрмәт белән карарга өйрәтә.

1912 елны Тукай Петербург шәһәренә килә. Ике атналап була ул анда. Мәктәптә укучы татар балалары белән дә очраша. Язучы, тукайчы-галим И. Нуруллинның шул вакыйганы чагылдырган «Ирек тәме» хикәясе бар. Шагыйрь белән очрашуга килгән балаларның берсе «Фатыйма белән Сандугач» шигырен бик матур итеп яттан сөйли. Шигырьдә Фатыйма исемле бер кыз бала читлектәге Сандугач янына килеп: «Читлегең дә әйбәт, ашарыңа-эчәреңә дә бар, бүлмәң дә җылы. Ә син сайрамыйсың», – ди. Сандугач балага җавабында:

Ah, минем сайрар җирем урман иде,
Анда һәртөрле кызык тулган иде.
Мин бу җирдә нигә шатлык күрсәтим?
Анда өч баш кошчыгым калды ятим.
Һәм мине анда тагын дустым көтә,
Сагына ул, саргая ул, ут йота.
Белмисеңме, син, читен мәхбүслек (ягъни тоткынлык) ул,
Булса да алтын, һаман да читлек ул, –

ди.

Бала, кошчыкны кызганып, аны иреккә очыра: сөйгәне, балалары янына озата.

Шигырь укылып бетүгә, бер малай мышык-мышык елый башлый.

– Нигә елыйсың? – дигәч:

– Минем дә читлектә ике песнәгем бар иде. Читлек ишеге ачык калган да, мәче аларны тотып ашаган... Мин аларны азат итәргә өлгерә алмадым...

Тукай яшен сөртеп маташучы Хәсән янына килеп, малайның иңбашына кулын салды.

– «Өч хакыйкать»не хәтерлисеңме, мелла Хәсән? «Үткән эш кире кайтмый, хет үкен син, ул, ела. Киләчәккә сабак булыр. Гомерең алда әле. Меңне азат итәрсең. Кошларны гына да түгел...», – ди.

«Кошларга» шигыре

Тукайның алты куплетлы «Кышкы кич» шигыре бар. Баштагы өч строфада җылы өйдә рәт-рәт тезелеп утырган бер кай-

гы-хәсрәтсез балалар, кышкы кичнең озынлыгын да сизмичә, әниләре сөйләгән әкиятне авызларын ачып тыңлыйлар. Ә тышта ачы җилләр исә, өй түбәсендәге саламнарны тар-мар китерә. Суыклыктан, очар кошлар оча алмый. Ә җылы өйдә, мич каршында утырган балаларга рәхәт! Алга таба шагыйрь абый болай ди:

Төшсен ләкин исегезгә кайсы вакыт:
Һәркемгә дә бирелмәгән мондый бәхет;
Ятим калган сабыйлар бар, бәхетсезләр,
Ата-анасы вафат, җирсез һәм йортсызлар.

Үзегез рәхәттә яшәгәч, бөтен кеше дә шулайдыр дип уйламагыз. Дөнья бу! Бәхетсезләр турында да онытмагыз, алардан көлмәгез, кимсетмәгез. Ярдәм итегез, һич булмаса, җылы сүзләр әйтеп юатыгыз, ди. Кеше хәленә керә белү, кешеләргә ярдәмчел булу сыйфатлары да кечкенәдән тәрбияләнергә тиеш, ди шагыйрь.

Тукай балаларда милләтнең киләчәген күргән. Әле Уральскида вакытта ук (1906–07) «Әлгасрелҗәдит» журналында балалар өчен проза белән язылган 76 мәсәле басыла. 1909 елда 77 мәсәлне эченә алган «Энҗе бөртекләре» (Казан) җыентыгын чыгара. Мәсәлләрнең нигезендә исә әхлак тәрбиясе, үгет-нәсихәт ята.

Тукайның иң яратып аралаша торган даирәсе дә балалар булган. Бары алар белән ачылып сөйләшкән. Инде танылган шагыйрь «Әльислах» (Казан) газетасы редакциясе урнашкан йортның ишегалдында малайлар белән кузна уйнарга яраткан. Гәүдәсе белән үсмеррәк балалардан күп аерылмый торган Габдулла бу вакытта бөтенләй бер балага әверелә. Пиджагын салып ташлап, изүен чишеп, кайвакыт исә яланаяк калып, ихлас күңелдән хәрәмләшә-хәрәмләшә уйный.

– Хәрәмләшәсең бит, дисәләр: «Аның бөтен кызыгы да шунда!» – дип көлеп җавап кайтара торган булган. Кызып китеп, урамга да чыгып уйныйлар икән. Откан кузналарын, кочагына төяп кереп, иптәшләре алдында мактана.

Ташаяк ярминкәсенә барып, бала-чага белән бергә, агач атка атланып, карусельдә әйләнүе дә хак. Бу шуклыгы исә балачакта калган күңел җәрәхәте белән бәйле булырга тиеш.

Шагыйрь үзе, балачагы никадәр авыр булса да, шул чорларын сагынып искә ала.

Тәңре! Чигерче яшемне, синнән сорыйм;
Теләгемне синнән сорамый кемнән сорыйм;
Бәйрәм көнне генә сабый булып торыйм,
Рәхәтләнеп, сикереп, көлеп, уйнап йөрим, –

ди ***«Бәйрәм вә сабыйлык вакыты»*** шигырендә.

Нигә, дим, изге мәктәптән, сабый чаклардан айрылдым?
Нигә мин кечкенә Апуш түгел, зуп-зур Тукай булдым? –

ди ***«Гомер юлына керүчеләргә»*** шигырендә.

Һәр татарның китап шүрлегендә Тукайның башка китаплары белән бергә, аның балалар өчен җыентыклары да урын алса (ә андый җыентыклар дистәләрчә), ата-аналар, әби-бабайлардан балаларына зур бүләк, мирас булыр иде.

7. Тукай иҗатында дин

«Бөтенләй сафлана күңлем; укыйм иман, булам мөэмин»

Совет чорында Тукайдан атеист ясап бетерделәр. Имеш, ул дингә каршы булган, динчеләрне, муллаларны яратмаган, алардан ачы итеп көлгән. Мисал итеп «Ишан» шигыре китерелә.

Күзен йомган, муен бөккән, башына чалма чорналган;
Кибән чалма кибәк башта; ишан булган имеш хайван!

Мәктәп дәреслекләрендә аның ***«Сорыкортларга»*** шигыре дә бирелә.

Һөҗүм кирәк ишаннарга – сорыкорт, гөмбә башларга;
Бетер, сындыр, кырып ташла, мәгальурра вә билбанзай!
Ашап яткан сорыкортка кадалдым мисле хәнҗәр мин;
Боларның мәсләге – безне талау бит, бер дә коткармай.

Публицистик язмаларында, сатирик әсәрләрендә дә дин әһелләренә агулы укларын кадап-кадап ала; Ишми ишан, Зәйни ишан кебекләргә дә ару гына элэгә (соңгылары турында хәзер уңай фикерләр шактый әйтелә һәм языла). Шагыйрьнең 1912 елда язылган ***«Дин вә гавам» («Дин вә халык»)*** шигырендәге беренче ике юлы да Тукайны дингә ышанмаучы итеп күрсәтүгә мисал итеп китерелә.

Дин хәзер иске, аварга торгучы чергән дивар,
Аз гына, уйнап кына бармак белән төртсәң – авар.

Ә бит алга таба Тукай болай дип дәвам итә:

Билгеле: һәрбер агачлар да корырга башлыйлар,
Былбыл урнына оя тоткач башында каргалар!

Тукай – җиде буын муллалар затыннан. Ул бер дә атеист булмаган! Ул ислам динен, Корьәнне бик яхшы белгән. Гарәп, фарсы, төрек телләрен камил белгән. Намазын укыган. Намаз дигәннән... 1988 елны укучылар белән Тукай-Кырлайга бардык. Тукай музеенда булдык. Экскурсовод ханым безне бүлмәләр буйлап йөртеп, байтак мәгълүмат бирде. Стенага Тукайның Газизә апасы киемнәре янына чигүле ашъяулык та эленгән. Чигүле ашъяулык дигәнебез намазлык булып чыкты. Газизә апасы аны энесенә бүләк иткән булган. Шунда бер укучыбыз: «Тукай намаз да укыганмыни?» – дип куйды. Экскурсовод ханым авыз кырые белән генә елмайды да бик җәелеп китмичә: «Әйе», – дип кенә җавап бирде һәм экскурсияне дәвам итте. Әле ул вакытта, үзгәртеп корулар чоры башланса да, Совет, партия заманы иде бит.

Тукай, дини мәсьәләдә теләсә кем белән бәхәскә кереп, Корьәннән аятьләр китерә. Үзара сөйләшкәндә дә фикерен Корьән аятьләре белән раслый торган булган.

Тукай динсез-дәһри булмаган**; ул надан муллаларны, динне үзенә калкан итеп, пәрдә итеп файдаланган динчеләрне, динне кәсеп итүчеләрне яратмаган, агулы укларын шуларга аткан.**

Татарда Шәһер Шәрәф (атаклы Шәрәфләрнең берсе) дигән гарәп мәдәнияте тарихы белгече булган. Ул Тукай белән еш очрашкан, аралашкан. Әңгәмәләренең берсендә шагыйрь мондыйрак фикерләр әйтә**: «Яшьлек берлә әллә нәрсәләр язылган, кайсыбер шигырьләремне күрәсем дә килми. Халыкның дини яки милли хис-тойгы ларына тукына торган нәрсәләрне бер дә яратмыйм».**

Аңарга каршы мин: «Син милли шагыйрь бит, дини хисләргә дә шулкадәр әһәмият бирәсеңме?» – дип сорагач, Тукай: «**Дөньяда динсез бер милләт тә юк. Бөтен милләтләр динле булганда, без генә динсез булып кала алмабыз. Мин һәрвакыт дин берлән миллиятнең һәр икесенә дә тигез әһәмият бирү тарафдарымын»**, – дип җавап бирә. *(«Тукай турында истәлекләр», 1986, 105 нче бит).*

Прозабызның Тукае (бу метафора хәзер еш очрый) Гаяз Исхакыйның мондый фикере бар: «Әүвәл әхлак бозыла, икенче дин бетә, өченчедән ул халык үзе бетә». Билгеле: әхлак бозылмасын өчен дин кирәк. Ә дини тәрбия кеше күңеленә кече яшьтән, хәтта туганчы ук салынырга тиеш. Бала кешесе Аллаһның барлыгын, берлеген белеп үсәргә тиеш. Тукай ***«Таян Аллага»*** шигырен балаларга атап яза.

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдаим таян син Аллага!
Йә, Ходай, күрсәт, диген, ошбу җиһанда якты юл;
Ул – рәхимле; әткәң-әнкәңнән дә күп шәфкатьле ул!

Тукайның «Алла гыйшкына», «Васыятем», «Иһтида» (туры юлга керү), «Шиһаб хәзрәт» шигырьләре дә дини темага язылган.

Шагыйрьнең «Ана догасы» әсәрен укыган саен күңелем тула. Аналарның бөеклеген раслаучы әсәр. Төн. Авыл тып-тын. Хәтта этләр дә өрми. Халык йоклый. Фәкать авыл кырыендагы бер өйдә генә сүнми тора бер ут.

Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык,
Намазлыкка утырган бар җиһаннан күңлен арчып.
Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз угълын:
Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым!
Тамадыр мискинәмнең күзләреннән тамчы-тамчы яшь;
Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас!

Менә шулай итеп ялгыз ана кайдадыр бәхет эзләп зимагурлыкта йөргән баласы өчен өзелеп-өзелеп Ходайга ялвара. Аның исән-сау булуын, бәхетле булуын, бәла-казалардан имин булуын тели. Әле зимагур малай, газиз угыл бу вакытларда кайларда, нишләп йөридер, карт анасы турында уйлап карый микән?!

Үзе өчен түгел, баласы өчен исәнлек-саулык, бәхет, тәүфыйк теләп Ходайга күз яшьләре белән бары Ана гына ялвара ала. Телевизор экраннары аша, 10 кешенең башына җиткән маньяк улын кичерүләрен сорап, идәнгә тезләнеп, башын бәрәбәрә ил халкына күз яшьләре белән бары Ана гына ялвара ала! Аналар теләге, аналар догасы гына безне бәла-казалардан саклый. Ана – бөек. «Анаң, аннары анаң, аннары тагын анаң; соңыннан гына атаң; «Җәннәт аналарның аяк астында» кебек

хәдисләр үзләре үк Аналарның бөеклеген раслый. Тукаебыз гади генә авыл карчыгын да ана буларак бөеклеккә күтәрә.

«Васыятем» шигыре мондый юллар белән тәмамлана:

Әһле тәкфир (ягъни мине кяфер, динсез дип әйтүчеләр) бер гажәпләнсен, күреп актык сүзем: Күр, нә рәсмә тулган иман берлә Корьән садремә! (күңелемә).

Харис хәзрәт Салихҗанның Тукай һәм аның иҗатында дин мәсьәләләре турында бик эчтәлекле китабы бар. Кызыксынган кешеләргә шул китапны алып укырга тәкъдим итәм.

«Таян Аллага» шигыре.

8. Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы... (Тукай иҗатында мәхәббәт)

1. Ф. Әмирхан бер мәкаләсендә болай дип язган: «Тукайның бөтен мәҗмугаи әшгарен (шигырь җыентыкларын) күздән кичергәндә, андагы **лирикага** фәкыйрьлек күзгә бәрелми кала алмый».

«Бу очракта, **лирика** дигәндә, Ф. Әмирхан **мәхәббәт лирикасын** күздә тота һәм әлеге ярлылыкны Тукайның хатын-кыздан качуы, бер кызны эчтән сөеп тә, мәхәббәтен белдерми йөрүе белән аңлата», – ди Ибраһим Нуруллин.

Тукайны күреп белгән, аның белән аралашкан кешеләр, чыннан да, шагыйрьнең хатын-кызлардан качуын, алар булган җирдә үзен бик киеренке тотуын, аларга күтәрелеп тә карамыйча, кайчан чыгып китәрләр инде болар, дигән кебек утыруын яки берәр хатын-кыз заты бүлмәгә килеп керсә, ашыгып чыгып китүе турында язып калдырганнар. Ф. Әмирхан истәлекләренең берсендә мондый хәл искә алына. Бервакыт Тукай «Әльислах» газетасы идарәсенә Ф. Әмирхан янына йомыш белән килә. Дустының хатын-кызлар белән утырганын белеп, керми китә. Күпмедер вакыттан соң яңадан килә. Кызлар һаман чырык-чырык көлешәләр. Фатих Әмирханның да тавышы ишетелгәли. Өченче баруында да керми киткән һәм иртәгесен Әмирханны битәрләп алган. «Хатын-кыз белән ни сөйләп утырмак кирәк? Көненә өч мәртәбә сәгатьләп-сәгатьләп кирәксез, мәгънәсез сүз сөйләп утырудан ничек туймаска кирәк!» – ди. Ә Ф. Әмирхан хатын-кыз белән арала-

шырга яраткан, җиңелчә флирттан да качмаган. Шунлыктан аның янында кызлар еш кунак булган.

Оялчанлыкмы, хатын-кыз таифәсен яратмыйча тарсынуымы, кыюсызлыкмы, сәерлегеме бу шагыйрьнең? Сәбәп бүтәндә булырга тиеш. Бу турыда язучы-галим И. Нуруллин менә нәрсә ди:

– Тукай бик яхшы белә: аның шигырьләрен бик яратып укыйлар. Шигырьләреннән чыгып, үзен зур итеп, мәһабәт итеп, чибәр итеп күз алдына китерәләр. Шагыйрь белән күзгә-күз очрашкач исә, яшь кызның яисә чибәр ханымның йөзендә ихтыярсыз алдану, көткәнен таба алмау тойгысы чагылып үтми калмый. Сизгер һәм горур Тукайга ул карашлар пычак кебек кадала. Ә инде хатын-кызлар йөзендәге әлеге кимсетүле кыяфәтне күргәләгәч, ул, билгеле, үзенең «мин»леген саклау йөзеннән, танышудан кача башлаган, – ди.

Замандашларының истәлекләренә караганда, Тукайның портреты болайрак: кечкенә гәүдә, үзе ябык, аксыл чырай, җитмәсә, бер күзенә ак төшкән. Казанга шагыйрь булып әйләнеп кайтканда (бу 1907 ел), аңар инде 21 яшь. Ләкин үсмер малай кыяфәтле кешене шагыйрь Тукай булыр дип берсе дә башына китерми. Г. Камалның Тукай белән беренче очрашуы вакытында алган тәэсире болайрак: «Солидный гәүдәле Тукай турында исәпләп йөргәндә, шәкерт кыяфәтле бер малайның, ул Апуш мин булам, дигән сүзләре миңа бик начар тәэсир итте», – ди.

Ф. Әмирхан янына Тукайны Борһан Шәрәф алып килә. «Кыскарак буйлы, чандыр гәүдәле бу кунакның йөзе әүвәл карашта аны баласымак итеп күрсәтә», – дип яза әдип. Ул да аны бер шәкерт кисәге дип уйлый. С. Рәмиев тә беренче очрашуда аны «шыксыз гына бер малай» дип тасвирлый. Алга таба боларга тагын Казанга кайткач көчәя башлаган үпкә авыруы да өстәлә. Үзенең тышкы кыяфәтеннән, авыру булуыннан Тукайда, хәзергечә әйтсәк, комплекслылык, ягъни тышкы кыяфәте ягыннан үз-үзен түбән бәяләү, читенсенү, кимсенү сыйфатлары да булган.

Ә төскә-биткә ул үзе болай ямьсез булмаган. Шул ук С. Рәмиев истәлекләрендә мондый юллар да бар: «Мәрхүмнең йөзе коңгырт иде. Бәдәне зәгыйфь кенә булса да, әгъзалары бер-

берсенә бик туры килеп тора. Бер күзенә ак төшкән булса да, йөзенең килешләре белән ямьсез түгел, бәлки, уртача матур, биек маңгайлы; борыны килешле вә һәрдаим тулы булып ачылып торган зур күзле иде...

Бу көнгәчә сатылып йөри торган открыткалардагы рәсеме бер дә Тукайның үзе түгел, – ди *(С. Рәмиев. «Беренче очрашулар»).*

Тукай гыйшык утында янганмы? Сөйгәнме? Сөйсә кемне сөйгән?

Габдуллада беренче «гыйшык уты» Уральскида кабынган булса кирәк. Аның, мәсәлән, мәдрәсә күршесендәге бер карчыкның үзеннән ике-өч яшькә олы кызына күз тотып йөргәнлеген ихтимал итеп сөйлиләр. Бу мәхәббәт артык җитди булмаган, күрәсең, сизелерлек эз калдырмаган.

Шулай да бу чорда шагыйрьнең хатын-кыз таифәсенә карата мөнәсәбәтен белдергән берничә шигыре бар.

«Хур кызына» шигыре

Тукайны Мәҗнүн (мәхәббәттән тилергән) дәрәҗәсенә җиткергән гыйшкы турында Галимҗан Шәрәф, Тукай вафатыннан соң бер ел үткәч язып чыга. Тукайның мәгъшукасын (сөеклесен) З. туташ дип бирә.

З. туташ – Чистай шәһәрендә тәрбияле гаиләдә туып-үскән Зәйтүнә Мәүлүдова. Аларның гаиләсе 1907 елда Казанга күчеп килә. 14 яшьлек бу кыз ярыйсы гына укымышлы, матур әдәбият белән яхшы таныш. Тукайның язганнарын яратып өлгергән. Билгеле, Казанга килеп тә, Тукай хәтле Тукайны күрми йөрү яшь кыз өчен гафу ителмәслек бер эш булып тоела. З. Мәүлүдова үзенең истәлекләрендә Тукай белән беренче очрашып-танышуы турында бик кызыклы гына итеп язып калдырган. Очрашу 1908 елның март аенда (бу вакытта кызга 15 яшь) «Әльислах» газетасы идарәсендә була. Берничә кыз, бөтен кыюлыкларын җыеп, Ф. Әмирханның энесе Ибраһим Әмирханга ияреп, идарәгә керәләр.

– Мин иң элек Фатих абый белән күрештем. Фатих абый: «Кызлар, шагыйрь Габдулла Тукаев белән таныш булыгыз», – диде.

Тукай кара пинжәк, юллы ак күлмәк, кара галстуктан, үзе яланбаш иде. Чәче озын да, артык кыска да түгел. Ул күрешкәндә безгә бер генә караш ташлады, аннан кулларыбызга текәлеп кенә:

– Исән-сау йөрисезме? – дип куйды. Соңыннан күзләрен дә күтәреп карамады.

(А. Расих »Ишан оныгы» роман-истәлегеннән).

Халыкта, бер күрүдә гашыйк булу, дигән сүз бар. Тукай кызга бер күрүдә гашыйк булган. Шул утырыштан соң бер зур үзгәреш, Зәйтүнә туташның исеменә кадәр бер ихтирам күренә. Хәтта ул башкаларның аңарга аз гына ихтирамсызлыкларын да күтәрә алмый.

Зәйтүнә Мәүлүдованың истәлекләренә караганда, Казанда яшәгәндә Зәйтүнә Тукай белән берничә тапкыр очраша. Мәдрәсә ташлап чыккан шәкертләр файдасына ясалган әдәбият кичәсендә кыз белән шагыйрь арасында җылы гына әңгәмә, аралашу була. Тукай хәтта кыз алдында ачылып китә.

Әлбәттә, шагыйрь кеше үзенең мәхәббәт хисләрен белдерми кала алмый. Ф. Әмирхан, Тукайның шигъри җыентыкларында лирикага фәкыйрьлек күзгә бәрелми калмый, дигән иде. Ә 1908 ел – Тукай иҗатында мәхәббәт шигырьләре сан ягыннан һич тә фәкыйрь түгел икәнен раслый. «Әльислах» газетасында Тукайның мәхәббәт темасына берничә шигыре басыла. Әмма шигырьләрен я «Шүрәле», я «Мәҗнүн» имзасы белән чыгара.

«Тукай белән икенче очрашуыбыз Екатеринская урамында булды. Безнең яннан гөрләп трамвай узды. Олы апам Рабига: «Трамвай тәрәзәсеннән бер урыс башын селкеп узды, – диде. – Сезгә түгелме?» Бәдриҗиһан апамның күзләре үткен, ул карау белән: «Тукай, – диде. – Мин аны күрмәсәм дә, сәламләп баш идем», – дип яза З. Мәүлүдова истәлекләрендә. Озак та үтми, шагыйрьнең «...гә» (Зәйтүнә) дигән шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылып та чыга. Бу шагыйрьнең сөйгәненә, ягъни Зәйтүнәгә багышланган беренче шигыре.

1908 елның җәй башында Зәйтүнәләрнең гаиләсе кабат Чистайга кайтып китә. Китәсе көнне кызлар (Зәйтүнә һәм аның апасы) «Әльислах» редакциясенә барып, Тукайны үзләре янына чакырып чыгаралар. Китү хәбәрен ишеткәч, шагыйрь башын

аска иеп: «Бик жәл», – ди. Саубуллашырга пристаньга төшәргә вәгъдә биреп калса да, Тукай сүзендә тормый.

«Әльислах»ның 34 нче санында (1908 ел, 17 июнь) Мәҗнүн имзасы белән (бу имзаны Тукай тик шушы шигырьгә генә куя) «Кызык гыйшык» шигыре басылып чыга.

Ф. Әмирханга язган хатында (Ф.Ә. бу вакытта Серноводскида ял итә) мондый юллар бар:

– «Әльислах»та «Кызык гыйшык» шигырен яраттыгызмы? Керпе үзенең кабыгына кереп яшеренгән төсле, мин дә сөю хакында берәр нәрсә язсам, ялган имзалар астына сыгынам («Бер шигырь язсам да, ялган кул куям»).

Монда да Тукай юморга таяна. Коенырга карар иткән берәү, чирканчык алудан куркып, чиләк белән суны җилкә аркылы гына түгеп җибәрә дә «әл дә тәнгә тимәде» дип шатлана.

Мин моны яздым, бу – гыйшкым миследер;
Чөнки гыйшкым минем нәкъ шуның төследер.

Шагыйрь акылыннан шашар дәрәҗәдә сөя, ләкин хисләрен тышка чыгармый. Сөйгәненнән шүрәле төсле кача, юлда очраса да, күрмәгәнгә салыша; ут йотып янса да, сер бирми; очрашканда да, күкрәк тулы ялкын булса да, сүз сөйли салкын гына.

«Мәхәббәт» шигырендәге:

«Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну!
Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы! –

дигән юлларын акыл белән генә түгел, йөрәк белән дә аңлыйсың.

«Мәхәббәт» шигыре

Зәйтүнә Казаннан киткәч, Тукайга кинәт кояш сүнгән, дөньяның яме киткән кебек тоелган. Бу мәхәббәтен күпләрдән яшерсә дә, 1912 елның көзендә дусларының берсенә Зәйтүнәне һаман яратуы, оныта алмавы турында сөйләгәне билгеле.

Шул ук вакытта ул канәгать тә: ярый әле китте, белми китте! Ул шәһәрдә яшәгән чакта, үзен күргәндә эчтә янган ялкынны тышка чыгармый асрау гаять кыен иде.

Дуслары сизәләр: шагыйрь борчыла, кичерә. Шәхси тормышында тәртипсезлекләр дә арта төшә. Болай ярамый, берәр чара күрергә кирәк. Чара дигәннәре – Тукайның кемлеген

аңлый торган һәм тормышын тәртипкә салырлык бер кызга өйләндерү. Андый кыз табыла. Сөйләшәләр, ризалыгын алалар. Ф. Әмирханның анасы Рабига абыстай ярдәмендә кызның анасын да ризалаталар. Яшәр өчен фатир да табыла. Дуслары җыелышып кыскач, Тукай күнгәндәй була. Ничә күнеп, ничә кирели Тукай. Нәтиҗәдә, Тукайны өйләндерү барып чыкмый.

Шагыйрь бер ханымнан немец теле дәресләре ала башлый. Максаты: яраткан шагыйре Гейнены оригиналда укырга өйрәнү. Бу ханым да Тукайны үз кулына алырга теләге барлыгын шактый ачык сиздерә. Моны белеп алган Тукай, әлеге ханымның күзенә бөтенләй күренмәс була, хәтта укуын ташлый. Озакламый шагыйрьнең «...га» дигән исем белән бер шигыре басыла. «Син шагыйрьгә барма, син аңа әрәм. Шагыйрь җырлый, дисең. Җыр тыңлау күңелле дисең.. Кош кибетенә барып, бер былбыл сатып ал да, читлеккә куеп сайрат», – дигән мәгънә салынган шигырьгә.

Тукай өйләнү, гаилә коруны инкарь иткәнме? Юк! «Һәркемгә өйләнү тиеш, яратышсаң, әгәр гаиләңне тәэмин итә алсаң», – ди ул бер киңәш сораган танышына. Һәммә кешегә тиеш... әмма Тукайга түгел! Чөнки Тукай бар нәрсәдән дә **хөрлекне** өстен күргән. Беренче планга үзен, гаиләне түгел, милләт, халык, әдәбият, шигъриятне куйган. Шигърият күгендә йөзгән мәгърур бөркет койма өстенә көч-хәл белән очып менә торган өй тавыгы хәлендә калырга теләрме?!

Инде тагын берничә сорау туа. Ни өчен шагыйрь үзенең көчле мәхәббәтен Зәйтүнәгә аңлатырга теләмәгән? Ул бит Тукайга кияүгә чыгарга ризалык биргән теге кыз да, немец теле укытучысы да түгел. Ул бит аның мәхәббәте! Ни өчен сөйгәненнән качкан? Үзе әйткәндәй, «печать проклятия» – бер күзенә төшкән ак яки төс-кыяфәтенең, буй-сынының, үзе уйлаганча, бик шәптән булмавы сөйгәне белән аңлашырга комачау иткәнме? Шундый сораулардан соң, тукайчы И. Нуруллин бу мәсьәләгә үзенең карашын белдереп:

– Еш авырый торган Габдулланың... чәче агарганчы яшәмәячәгенә, гомеренең үзе уйлаганга караганда кыскарак булачагына күзе җиткән. Эш бу рәвешле тора икән, ни өчен гөнаһсыз яшь кызны (җитмәсә, җандай сөйгән кешеңне!)

үзеңә бәйләп, тормышын, киләчәген харап итеп ташларга! Тәрбиясе, холкы, җәмгыятьтә һәм әдәбиятта тоткан урыны аны бик күп гадәти кешеләргә насыйп була торган шәхси бәхеттән баш тартырга, үз кулы белән читкә тибәрергә мәҗбүр итте.

(И. Нуруллин «Габдулла Тукай», Казан, 1979, 156 нчы бит).

Ah, ничек! Без яр идек: син мин идең, мин син идем;
Тик хәзер берсе дә юк – калды истәлек кенә!

Г. Тукай. «Сөеклемнең кабер ташында»

9. И матур! Мин янмас идем – яндыручы булмасаң; Таммас иде җиргә яшьләр – тамдыручы булмасаң!

Шагыйрьне мәхәббәт утларына салган, беренче һәм соңгы мәхәббәте булган Зәйтүнә Мәүлүдова турында тулырак мәгълүмат бирәсем килә. Бик күп еллар З. Мәүлүдова турында төпле, тулы мәгълүмат булмый. Ә ул бердәнбер улы өчен истәлекләр язып калдырган икән. Зәйтүнәнең улы – галим, берничә роман, повестьлар, хикәяләре белән танылу алган язучы, Г. Тукай премиясе лауреаты Атилла Расих. Әнисенең язмаларын да кулланып, «Ишан оныгы» дигән роман-истәлек язды. Ул әсәр китап булып Татарстан китап нәшриятында 1996 елда басылып чыкты. А. Расихның кызы, Зәйтүнәнең оныгы Фәридә (ул да шагыйрә икән) әбисенең шәхси әйберләрен һәм кулъязма истәлекләрен Казандагы Тукай музеена тапшыра.

Алда әйтелгәнчә, З. Мәүлүдова – Чистай кызы. Кайбер чыганакларда Зәйтүнәне бай сәүдәгәр яки заманы өчен шактый культуралы гаиләдә туып-үскән кыз дип бирсәләр дә, З. Мәүлүдова истәлекләрендә үзенең фәкыйрь генә вак һөнәрче гаиләсендә тууы турында яза. Әтисе Хәйдәр, вакытында мәдрәсәдә укыган, шактый белемле булган. Ләкин кул хезмәте белән яшәүне артык күрә. Куллары һәр эшкә ятышлы була. Шулай да күбрәк пыяла кую белән шөгыльләнә. Шуңа күрә аны Пыялачы Хәйдәр дип йөрткәннәр. Ул көзге дә коя белгән, мич тә чыгарган.

Кызганычка каршы, кызның әтисе бик иртә үлеп китә.

Биш бала әниләре Шәмсеҗиһан кулында кала. Иң олысы Шакирга 14–15 яшь, төпчекләре Зәйтүнәгә алты яшьләр тирәсе була. Әниләре ике улын малайлыкка, олы кызы Рабиганы бер бай туганнарына асраулыкка бирә. Ике кызы: Бәдриҗиһан белән Зәйтүнә генә әнисе янында кала. Шәмсеҗиһан апа яшьтән кул эшләре белән шөгыльләнгән: бүрекләр, кәләпүшләр теккән, калфаклар, намазлыклар, эскәтерләр чиккән, кызларын да шул һөнәрләргә өйрәткән. Шәмсеҗиһан бай туганнарына барып, аларның керләрен, идәннәрен юудан да тайчанмаган, кунак килгәндә, аш-су әзерләү эшләрен дә башкара торган булган.

Зәйтүнә бик зиһенле бала булып үсә. Белемгә тартыла. Казанга килгәч, апасы Бәдриҗиһан белән русский-татарский школага укырга йөриләр. Казаннан киткәч, ике кыш Югары Курса авылында туган апасының кызлар мәктәбендә (тамак хакына) дәресләр бирә. Абыйларының ярдәме һәм үзенең тырышлыгы, зирәклеге аркасында Иж-Бубый мәдәрәсәсендә укып, өчьеллык программаны бер кышта үзләштереп, таныклык алуга ирешә.

Казанга килгән елны аңа – 14, ә Тукай белән танышканда 15 яшь була. Зәйтүнәдә кыюлык та бар, чибәрлеге дә сөбханалла! Куе кара чәчле, матур йөзле, уртача буйлы бер туташ булган ул.

«Татар матбугатында Тукайның берәр шигырен ләззәтләнеп укуга, түземсезләнеп, икенчеләрен көтә идем, – дип яза Зәйтүнә үз хатирәләрендә. – Шундый тирән мәгънәле, гадел һәм күркәм юлларны язган кешенең үзен күрәсем килде, аның үз шигырьләрен ничек укуын ишетәсем килде... Миндә аның белән танышу теләге туды. Һәм мин апам белән шундый мөмкинлекне эзли башладык».

Истәлекләрендә Тукай белән биш тапкыр очрашуы турында яза. Чистайга кайтып киткәч тә, бәйләнешләр берара өзелми. 1908 елның августында шәһәргә «Сәйяр» труппасы килә. Тукай Габдулла Кариев аша Зәйтүнәгә һәм Бәдриҗиһанга контрамаркалар (билет) җибәрә. 1910 елны «Сәйяр» труппасы кабат Чистайга килә. Тукай Г. Кариев аша Зәйтүнәгә күп сәламнар җибәрә, үзе дә Чистайга килеп чыгарга уйлый. Ләкин бу эш булмый кала. Шул килүендә Г. Кариев Зәйтүнәгә Тукайның фоторәсемен бүләк итә.

Бервакыт Курсада укыткан кышында Зәйтүнәгә бер якын

танышыннан хат килә. Анда: «Фатих абый (Ф. Ә.) сине язучы Тукаевка димләп хат язган. Без, үзенә яз, дип, синең адресыңны җибәрдек», – диелгән була. Шуннан соң озак та үтми, Зәйтүнә Ф.Ә.нан хат ала. Ләкин Ф. Әмирхан хатында Вафа Бәхтияров дигән кешенең («Әльислах»ның рәсми редакторы) кызны үзенә соратуын әйткән. Хатның бер почмагына «Тукай да сине онытмый» дип язып куйган. Бу хатны укыганнан соң кызның кәефе кырыла, хатка да җавап бирми.

Тукай хәтле Тукай үзенә багышлап шигырьләр язар дип яшь кыз уйлап та карамый. «...гә» дип исемләнгән шигырен дә, «Кызык гашыйк» шигырен дә апасы Бәдриҗиһан белән газетадан табып укыйлар. «Әнием ул вакытларда шигырьләрнең үзенә карата язылганлыгын башына да китерми. Тукайның әниемә булган мәхәббәте кайнар һәм сәер, әмма яшерен була», – дип яза Зәйтүнәнең улы, язучы Атилла Расих. Чөнки Зәйтүнә Тукай аңа Мәҗнүннәрчә гашыйк булыр дип уйлый да алмый. «Үземчә, ул миңа, укуга дәртле, шат күңелле милләттәшем, дип, агаларча, дусларча гына карады. Мин бик яшь идем шул ул чак», – ди.

Хатирәләренә караганда, Зәйтүнә үзе дә Тукайга битараф булмаган. Баштарак, ул миңа абыем кебек кеше, аның миңа карау ихтималы юк, бары аның белән якыннан таныш буласым килә, дип кенә йөрсә дә, кыз күңелендә дә өмет чаткылары, мәхәббәт очкыннары кабына. Моны сизеп алган иптәш кызлары, болай да дөрләп торган күңел ялкыннарына**, бик исе китәдер инде сиңа Тукайның,** дип керосин сибәләр. «Мин тиле үземне лаеклы кешегә исәпләп йөрим тагын. Тукай минем кебек ярлы мишәр кызына карамаса, монда гимназистка яки курсисткалар беткәнмени?» – дип уйлый кыз.

Хатирәләреннән тагын бер өзек: «Бик дустанә сөйләшкәндә, апам эчке серләрен әйтеп, үзенең Фатих абый (Ф. Ә.) белән бергә булуын, минем Тукай белән бергә булуымны хыялланып куя иде. Андый чакларда, үзебезнең хыялдан үзебез оялып, кеше сизмәсен тагын, дигәндәй як-ягыбызга карана идек. Аннары – тагын:

Бүген күргән өч егетнең җем-җем итә кигәне,
Фатих алма, Ибрай хөрмә, Тукай кура җиләге, –

дип тә җибәрә идек», – ди.

(А. Расих «Ишан оныгы», 1996, 100 нче бит).

2. 1913 ел җитә. Әлегә Зәйтүнә әнисе белән Чистайда яши. Белемен арттыру өстендә эшли, кул эшләре белән шөгыльләнә. Аны инде берничә мәртәбә кияүгә дә сорап киләләр. Ләкин кыз, укыйсым бар, дип аяк терәп карыша. Әнисе дә, кыз яшь әле, ул да китсә, мин бөтенләй ялгыз калам, дип яучыларны кире җибәреп тора.

Табигать уянган, яз шатлыгы кичергән бер мәлдә, Казаннан «Тукай вафат» дигән дәһшәтле хәбәр килеп төшә. Хатирәләрендә Зәйтүнә болай яза: «Тукай үлгәнен ишеткәч, бик еладым, бик борчылдым. Әкрен генә йөткерә башладым, бик ябыктым. Әни мине Гөлсем апага ияртеп, профессорга күренеп кайт, дип Казанга җибәрде. Иң элек, килгәч тә зиярәткә чаптым. Тукайның кабере кергәч тә капканың уңъягында. Зур гына бер калайга «Шагыйрь Габдулла Тукаев» дип язылган. Мин кабер янында Корьән укып бик озак елап утырдым».

Шуннан соң озак та тормый, абыйсы Шакирның чакыруы буенча, Зәйтүнә һәм әнисе бөтенләйгә Чистайны калдырып, Троицк шәһәренә күчеп китәләр. Зәйтүнә монда килгәч, «Сөембикә» кызлар мәктәбендә укыта, ул вакытта Троицкида яшәгән тел галиме Гыйбад Алпаровтан дәресләр дә ала. Кыз шәһәрнең алдынгы карашлы яшьләре белән таныша, спектакльләргә йөри. Шундый спектакль кичәләренең берсендә, танышларыннан берәү кызга, синең белән Зәйни ишанның уртанчы улы танышырга тели, дип килеп әйтә. Танышып, сөйләшеп китәләр. Егет кызга үлеп гашыйк була һәм озакламый аңа үзенә кияүгә чыгарга тәкъдим ясый. Әлбәттә, атаклы Зәйни ишан улын чистайлы ятимә карчыкның гүзәл кызына өйләндерү ягында түгел. Гаилә үз ишләре белән туганлашу ягында. Әмма егетнең таләбе катгый: я шул кызны алып бирәсез, я беркемне дә алмыйм, башымны алам да өйдән чыгып китәм! Зәйтүнә дә яратмаган, күңеле тартмаган кешегә кияүгә чыгу ягында түгел. Кыз никадәр генә каршы торса да, насыйбы булгандыр, ахыр чиктә ишан килене булырга ризалык бирә. Никях, туй 1914 елның кышында була. Зәйтүнә истәлекләрендә, туй алды вакытларын болай сурәтли: «Мин хәзер үз теләгем белән яшәүдән өмет өзгән, мәңгелек каторгага хөкем ителгән кеше кебек һәрнәрсәгә илтифатсыз карый торган кешегә әйләндем. Ул кеше белән ничек яшәрмен, аны сөя алырмынмы? Юк, юк, миңа тизрәк үләргә дә

Тукай белән бергә булырга, бары шул гына, – ди *(А. Расих «Ишан оныгы», 1996, 139 нчы бит).*

Ләкин тормыш дәвам итә. Күрәчәкне күрми, гүргә кереп булмый, диләр бит. Зәйтүнә ишан улы Кадыйр белән яшәп китә, язмышына күнә. Тормышта күп авырлыклар күрә, аеруча революциядән соң. Бер угыл таба. Ул, алда әйтелгәнчә, язучы, галим – Атилла Расих.

Ишан улы, ишан килене, ишан оныгы булу бу гаиләне әле утка, әле суга сала, бик күп сынауларга дучар итә. Ләкин Зәйтүнәнең тырышлыгы, үҗәтлеге, максатчанлыгы, тәвәккәллеге аркасында гаилә авырлыкларны җиңә. Зәйтүнә аркасында, диелде, чөнки ишан улы Кадыйр бик тормыш итүгә, дөнья көтәргә яраклы, русча әйткәндә, «практичный» кеше булмый.

Бөек Ватан сугышына кадәр Кадыйр Зәйнулла улы Рәсүлов Мөслим районы, Симәк авылында укытучы булып эшләп ала. «...Әти француз теле курсларына керде. Аны тәмамлап, Мөслим районында Симәк дигән авылда француз теле укытты, шул ук вакытта чит телләр институтында читтән торып укырга тотынды», – ди язучы *«Ишан оныгы» китабында (255 нче бит).*

Зәйтүнә Мәүлүдова укытучы булып эшли. 1950 елда Казан шәһәрендә вафат була.

«Бер рәсемгә» шигыре.

10. Г. Тукай – фәлсәфәче

– Татар шагыйрьләре, сәнгатьчеләре иҗатына, тормышына хас биш сыйфатның берсе – фәлсәфә, – ди «Нурга төренгән Тукай» язмасында Р. Батулла. Һәм бу төшенчәгә мондыйрак аңлатма бирә.

«Фәлсәфә – акыл ияләренә хас, бөек суфиларча фикерләү; моңа кадәр без күргәннәрне иҗатта күрсәтә белү; моңа кадәр башыбызга да килмәгән төшенчәләрне ачып салу; моңа кадәр канун-кагыйдә дип йөргәннәребезнең хата икәнлеген исбатлау куәсе» *(«Урыннары җәннәттә булсын», 2007, 9 нчы бит).*

Бу тема – студентлар яки аспирантлар өчен зур фәнни эш темасы була ала. Ләкин минем максатым – Тукайның берничә шигырен генә алып, аларның фәлсәфи һәм тәрбияви үзенчәлекләренә бераз тукталу.

Менә аның «Баскыч» шигыре (1910). Шигырь, махсус балалар өчен язылмаса да, мәктәп дәреслекләренә дә кертелә иде. Чөнки анда кеше бала вакытыннан ук аңлап үсәргә тиешле тормыш закончалыгы бирелгән.

Өй буена кырыклап басмасы булган гаять зур, авыр һәм озын баскыч сөялгән. Басманың һәр рәте кирәк, һәммәсе дә бер хезмәт башкара. Ләкин «югары басма тиңләшми түбәнге басмалар берлә».

Югары басма мәгърур: «Мин югары, сез түбән», – ди.
Ничек гали (бөек) минем урным, түбәнгеләр күрәмсез?» – ди.
Бер адәм килде дә шул чакта әйләндерде баскычны:
Түбәнге басмалар менде, югарысы түбән төште.

Тормышның үзе бит бу! Тормыш та баскыч кебек! Астыөскә әйләнеп тора. Шуңа күрә, бервакытта да мактанма, үзеңне зурга куйма, бүтәннәрне түбәнсетмә. Дөнья бу! Ходай Тәгалә, бәндәмә сәламәтлекне, дәрәҗәне, байлыкны аны сынар өчен бирермен, дигән, ди.

Шуңа күрә бу нәрсәләрне күтәрә белергә кирәк! Күтәрә белмәсәң, баскыч яки «Теләнче» шигырендәге карт хәлендә калу озак түгел.

Кыш, буран, салкын һава. Сызгыра җил, ыжгыра. Шул вакыт мәсҗет катында дөм-сукыр бер карт тора. Кулында капчык. Җәй дими, кыш дими – урыны мәчет капка төбе. Үткән бер кешедән, бер тиен булса да бирегез, дип теләнә. Бу юлларны укыганда күңел тетрәнә, картны кызгану хисләре көчәя. Бу бит кемнеңдер кадерләп үстергән газиз баласы булган, кемнеңдер әтисе булгандыр. Кая аның балалары? Ни өчен әтиләрен шушы көнгә калдырганнар? Ходайдан да курыкмыйлар микән! Шулай тетрәнеп укыганда, түбәндәге юлларга килеп төртеләсең.

Әйтсәм әйтим инде сезгә: бу кеше бик бай иде;
Эчкәне балдан, шикәрдән, ашлары тик май иде.

Менә ничек икән! Заманында бу карт теләнчебезнең данышөһрәтләре Казан, Ханкирмән, Әстерханга кадәр таралган булган икән. Ул кибетләр, мин сиңа әйтим, андагы хисапсыз маллар! Ул тройка атлары, фәйтуннар! Төлке толыплар, тунарга төренеп тройка атларда выжылдап кына узып китәр иде! Хәзрәтләр, үзеннән түбән бай дуслары аның янында юргалап кына йөриләр иде! Һәр сүзе закон иде! Ә хәзер?

Кайда бай хәлендәге җаннан сөекле дуслары –
Кайда качкан барчасы: Гайнүкләре, Әхмүшләре?

Ул көн саен хәер сорашып басып тора торган мәчетнең имамы, кайчандыр картның якын дусларыннан берсе булган. Әмма «күрми хәзрәт бу картны, тик кырын күзне сала».

Ә шулаймы? «Акча барда бар да дуст шул, бар да яр;
Акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр!»

Шулай, акчаң, дәрәҗәң, сәламәтлегең булганда барысы да була. Ярлар да муеныңа сарылырга гына тора. Байлыгың гына булсын! Хәзерге көндә телевизорны ачсаң, шундый бай абзыйларның ниләр кыланганын күрсәтәләр ярты программа буена. Фильмнары да бер калыптан сугылган.

Яшь гомерләр үтеп китәр, артыннан картлыгы да бастырып килә бит аның. Кеше тормышында иң нык игътибар, кайгырту, хөрмәт кирәк чор – картлык чоры. Син гаиләңә, якыннарыңа гына кирәк. Картайган көнеңдә кадер-хөрмәттә яшисең килсә, моңа үзеңне яшьтән үк әзерлә, теләнче бабай көненә каласың килмәсә, тормышның кадерен бел, авырын да, җиңелен дә күтәрә бел, адәм баласы! «Бу дөньяда иң зур бәхет – бәхетле картлык», – дип юкка гына җырламыйлар шул!

Шигырь 1907 елда язылган. Мәңге искерми торган, һәр заманга туры килә торган шигырь. 21 яшьлек егет гомер иткән аксакаллар нәтиҗәсен ясап куя!

2. Тормыш, яшәеш турындагы фикерләрен Тукаебыз ***«Нәсихәт»*** шигырендә дәвам иттерә.

Әйләнә көпчәк кеби байлык вә шөһрәт, мәртәбә:
Син бүген бай, бәлки шайтаннан да ярлы иртәгә.

Ләкин хәерчеләр, теләнчеләр, мескеннәр, мохтаҗлар яныннан битараф кына үтеп китмәгез. Капкаңа килсә, ачуланып кире борып җибәрмәгез.

Күрмәгез бер яклы дип сез бу вафасыз дөньяны;
Ул ике яклы: аның бардыр иләк һәм күн ягы.

Шуңа күрә аларга ярдәм итегез. «Булса бир, булмас исә, җайлап сөйлә булмаганын», – ди шагыйрь. Ләкин ак сакаллы Хозыр Ильяс барын да онытмагыз, ди. Бәндәләрне сынар өчен, юлчы яки хәерче кыяфәтендә күренүче пәйгамбәр барын белегез, ди. Бәлки сезгә, хәер сорашып яки хәл алырга, җылынып, чәй эчеп чыгарга дип Хозыр Ильяс кергәндер...

Кайчагында дөньяда яшисе килмәгән чаклар була. Кая барып бәрелергә, ни эшләргә белмисең. Эчең тулы борчу, сагыш! Әйләнә-тирәң тулы проблема! Кемгәдер эч-зарыңны бушатасың килә. Әти-әниеңне борчыйсың килми. Туганың, кардәшең янына бару кирәк тә бит! Җан тартмаса да, кан тарта, диләр. Ләкин, ни гажәп, бу очракта без таныш, дус дип исәпләгән кешегә ачылабыз. Якын дуслар бик сирәк, йөзгә-меңгә бер генә очрый, диләр, югыйсә! Бераздан, ник ачылдым көненә төшеп, үкенәбез. Яңадан бу ялгышны кабатламам, дип, үз-үзебезгә сүз дә бирәбез. Тик... Тукайның менә шул турыда фәлсәфә иткән «Ачы тәҗрибә авазы» дигән шигыре бар.

Сөям кайчакта бер-бер иптәшемне,
Аңар мин күрсәтәм күздә яшемне.
Кыйлам аңа изһар
(ачып салам, күрсәтәм) кайгы-моңымны.
Сөйлим бер-бер барымны һәм югымны.
Күренә ул мәхәббәтле күземә,
Куяр төсле бәһа һәрбер сүземә.

Менә шул вакытта шагыйрь колагына бер аваз килә: «Ышанма, дөньяда һәркемдә ялган!»

Аның тик тышкы ягын син күрәсең,
Мәхәббәтле әһәмият бирәсең.
Тышыннан кызгану күрсәтсә дә ул,
Эчендә нәрсәләр ятканы мәҗһүл (билгесез).
Кара йөз ул, кара эч ул һаман да,
Мәхәббәт һәм кешелек юктыр анда.

Авазның чын хакыйкатьне төшендерүен аңлаган шагыйрь:

«Аваз!» дим, ишетеләсең әйтче, кайдан?
Фәрештә кычкырамы яки шайтан?
Җавабында аваз: «Син рәнҗемә, ди,
Минем исемем – ачы, карт тәҗрибә, ди.

Ачы, карт тәҗрибә авазында никадәр хаклык барына күңеле белән 100% ышанса да, һаман аны тыңламый адәм баласы!

Бу дөньяда, табигыйдер, кеше буш булмый дошманнан;
Шулай анысы: вәләкин, и Ходаем, сакла дуслардан.

(Г.Т. «Вак-төяк»)

Минем үземә Тукайның «Тормыш» шигыре бик ошый. Бу шигырь минем өчен «юл күрсәтүче йолдыз» булды дисәм дә хата булмас. Тормыш – юлбарыс кебек канэчкеч, ди шагыйрь. Ләкин син шул юлбарыска каршы тора бел, көрәш. Бергә-бер булганда көрәшергә була. «Көрәшмәк куркыныч, күп хәлләре бар, вәли, җиңгәч, ганимәт маллары бар». Ягъни, яхшы нәтиҗәсе була. Кемнән дә, кайдан да булса ярдәм булыр әле, дип ышанып ятма, үзең тырыш: «Өмет итмә булышмакны лаимнән», ягъни саран, түбән җанлы кешеләрдән, шәйтаннан ярдәм көтеп ятма. Бәхет тавына үзең мен (әмма кемнәрнедер таптап, сытып, изеп, кемнәргәдер тәлинкә тотып, алдап-йолдап түгел). Менә, минем аркада кеше булды, аңа мин ярдәм итмәсәм, бу дәрәҗәләргә, бу бәхеткә ирешә алмый иде, дип артыңнан сөйләп йөрмәсләр, ди. Тагын да саллырак яңгырасын өчен шагыйрьнең үз сүзләрен китерәм:

Димәс һичкем: «Минем аркамда менде,
Хәзер юньләп сәлам дә бирми инде!»

3. Тукайны тиз ышанучан кеше булган, диләр. Еш кына, беркатлыланып, үзе әле ныклап белеп тә бетермәгән кешеләргә ачылып китә. Шуның аркасында, «чиле-пешле» кешеләр кругына да эләгеп ала. Мондый ситуацияләргә бигрәк тә Казанга килгәч юлыга. Адым саен очрап торган ялган, гаделсезлекләр, тормыштагы каршылыклар, җәмгыятьтәге тигезсезлекләрне күргән шагыйрь төшенкелеккә дә бирелә. Кайда хаклык? Кайда дөреслек? Бармы ул? «Чын вә ялган» шигыре шулай бәргәләнгән вакытларында язылгандыр.

«Әүвәл дөньяда җир юк, су гына булган, ди. Чын белән Ялганга Тәңредән бирелгән бер көймә. Бер-берсенә кара-каршы утырып йөзәләр, ди болар шул көймәдә. Бервакыт болар ызгышып, сугышып киткәннәр.

Көчле кулы берлә Ялган Чынны бер суккан, ди дә:
Чын батып киткән, ди чыкмаска җиһанга мәңгегә.

Игътибар итегез, шагыйрь Ялганны **көчле куллы**, ди. Чыннан да, ялганның кулы көчле. Ул кешеләрне, туганнарны ыгы-зыгы китерә, язмышларны чәлпәрәмә итә, кешене төрмәләргә һәм кабергә кертә, хәтта илләр арасында сугышлар чыгара.

Фәлсәфи тирәнлеккә ия, уйлануларга этәрә торган шигырь-

ләре бик күп шагыйрьнең. Укыйсың да, яшь кенә егеткә каян килде икән шул кадәр акыллы фикерләр, дип куясың. Бик яшьли тормыш юлына кереп киткән, үзе әйткәндәй, «тормыш белән көрәшә-көрәшә» үзенә-үзе юл салган, мөстәкыйльлекне сөйгән кеше булган ул. Халык тормышын, Корьәнне, хәдисләрне бик яхшы белгән. Дөньяви белемгә дә, логик фикерләү сәләтенә дә ия булуы, әдәбият-сәнгать әһелләренә бик кирәк булган **күзәтүчәнлек** кебек сыйфатлар Тукайны аксакалларча фикер йөртүгә китергәндер.

Еш кына кылган гамәлләребез өчен үкенеп, үз-үзебезне ашыйбыз. Үкенүдән файда юк икәнен дә беләбез, югыйсә. Тукай бу турыда ни ди икән? Моңа җавап «Киңәш» шигырендә бирелә.

Шуңа күрә, чыгышымны шагыйрьнең ***«Киңәш»*** шигыре белән тәмамлыйм.

Чикмә гамь шул нәрсәгә: синнән гомернең еллары
Алган аны бер дә бирмәскә – очырган җилләре.
Тормышыңның агымында инде ул киткән агып;
Кайгырудан файда юктыр – булмый инде кайтарып.
Түкмә күз яшь: ярдәмендә һәр заманда Алла бар;
Ал җәсәрәт (кыюлык), алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!

«Өмид» шигыре.

11. Тукай – әүлия шагыйрь

Иҗат әһелләренә хас тагын бер сыйфат – ул әүлиялык. «Әгәр дә шәхес иҗаты белән үз кавеменнән сизгеррәк, акыллырак булып, алда халыкны ни көткәнен юрый алса, әсәрләрендә шуңарга ишарәләр ясаса, һич югында болай барсагыз, сезне алда һәлакәт көтә», – диеп кисәтә алса, ул әүлиялар рәтендә булыр» (Р. Батулла).

Алдагы чыгышларда Тукайның әүлия шагыйрь икәнлеген раслаган мисаллар китергән идек инде. Шагыйрь хөррият, азатлык, иттифак (берләшү), гыйлемле, культуралы булу – милләт өчен, аның яшәве, үсүе, киләчәге өчен төп шартлар дигән иде. Менә аның ***«Ике юл»*** шигыре:

Ике юл бар бу дөньяда: бере будыр – бәхет эстәү;
Икенче шул: гыйлем гыйшкында булмак – мәгърифәт эстәү.

Синең кулда: теләрсәң, мәгърифәтле бул, бәхетсез бул;
Вә яки бик бәхетле бул**, ишәк** бул, мәгърифәтсез бул.

Шагыйрь белемне, гыйлемне иң зур байлыкларның берсе дип атый. Матди байлык бүген бар, иртәгә юк. Байлык тоткан саен кими, ә гыйлем, киресенчә, арта гына бара. Аны хәтта карак та урлый алмый. «Адәм баласы көмеш, гыйлеме булса, алтын», – ди халык.

Шул ук фикерләр «Хиссияте миллия» (милли тойгылар) публицистик язмасында дәвам иттерелә. Шагыйрь үз заманындагы мәдрәсәләрнең уку-укыту системасын тәнкыйть итә. Ул яңача укыта торган, дөньяви, ныклы белемнәр бирә торган милли мәктәпләр булдыру ягында. Укуның ни өчен кирәклеген кат-кат әйтә.

«Укымак – дөреснең ялганны, яктының караңгыны, турының кәкрене, сафлыкның бозыклыкны җиңүләренә иң үткен, иң кирәкле коралдыр».

«Укымак – фикерләрне күктән җиргә җибәрмәк».

«Укымак – үткәннәрдән кичеп, якты киләчәк тугрысында пәйгамбәрлек итмәк».

«Укымак – үзеңне һәр нәрсәне белергә һәм һәр теләгеңә ирешергә вә бөтен дөньяга солтан булырга лаек дип танымактыр».

Ләкин уку «утызар ел мәдрәсәдә ятып, бер татар баеның эштән чыккан кызына өйләнеп, соңра шул байның асрау малае булып тору» дигән сүз түгел, ди. Укуыңның үзең өчен дә, милләтең, халкың өчен дә файдасы тиярлек булсын, ди.

«Милләт абразауный кешеләргә... мохтаҗ. Милләт аталарга, аналарга, мөгаллимнәргә һәм мөгаллимәләргә, мөрәббиләргә, мөрәббияләргә (тәрбиячеләр), талантлы, сәләтле, булдыклы кешеләргә мохтаж. Безнең милләт тә Пушкиннарга, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ», – ди шагыйрь. Шуңа күрә укырга, алга киткән милләтләрдән, халыклардан үрнәк алырга чакыра. Милләтне алга чыгаруда шагыйрь яшьләргә ышана.

Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек, –
Без аның бик зур фәхерле (мактанычлы),
чын бриллиант кашлары! –

ди ***«Татар яшьләре»*** шигырендә. «Тырышыңыз, карендәшләр, шәкертләр, тырышыңыз! Бөтен өмидебез, бөтен үтенеч һәм со-

рауларыбыз тик сезгә генә юнәлгән», – дип тәмамлый «Милли хисләр» язмасын.

2. Г. Тукайның әле тагын ***«Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?»*** дигән публицистик язмасы бар. «Һәртөрле мөхәррирләр вә ярты мөхәррирләр милләтемез үлгән вә яки йоклаган дип язалар», – ди ул. – Йокының да чиге була. Әгәр милләтебез үлгән икән, аның баш очында кәгазь кисәге булган газеталар чыштырдатып кына аны уята, аңа җан кертә алырбызмы? Милләтебез үлмәгән дә, йокламаган да. Башка милләтләрнең кисәктән генә югары күтәрелеп китүләренә тәкать тота алмаган хәлдә һуштан язган. Аны һушка китерү өчен милләткә әдәбият гөл сулары сибик; авызына берләшү сулары салыйк; музыка, рәсем сәнгатен үстерик, милләтнең күзен ачыйк; тырышыйк, тырмашыйк – алга барыйк. Халыкның аңын томалап ятучы надан, карагруһчы дин әһелләрен куып җибәрик, ди.

Тукайның иң зур, көчле фикере **тел, туган тел** мәсьәләсенә карый. «Туган тел» шигыре телгә мәдхия, туган тел, ана теленә гимн булып яңгырый.

Г. Тукай 1910 елның 15 апрелендә Казанның Шәрык клубында «Халык әдәбияты» лекциясен укый. Шагыйрь халык иҗаты, аеруча җырлар турында шәхси фикерләрен сөйли. Халык бу чыгышны бик яратып кабул итә. Чыгышын ул түбәндәге юллар белән тәмамлый: «Кечкенәдән күңелемә урнашкан җырулар сөюемнән миндә туган телемезне сөю тугъды. Әгәр миңа җырулар ярдәм итмәсә, мин туган телемезне сөймәк кеби бер олугъ нигъмәткә, байлыкка ия була алыр идеммени! Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен Туган тел!» Һәм шуннан соң Тукай «Туган тел» шигырен укый. Милләтнең, халыкның иң зур рухи байлыгы халык авыз иҗаты һәм тел булуын, аларның буыннардан буыннарга тапшырылырга тиешле мирас икәнлегенә каткат басым ясаган.

Шушы ук язмасында газета-журналлар теленең чуарлыгын, төрекләшү процессын тәнкыйть итә, «үзара төрекчә сөйләшеп маймылланучы шәкертләр»не дә чагып ала; әкренләп газеталарның татарча языла, китапларның татарча чыга башлавына куануын да белдерә. «Без татарлар һаман да татарлар булып калдык. Төрекләр – Истамбулда, без – монда!» – ди.

«Туган телем бабамнардан –
Иң бай мирас, васыять.
Тарихына язылмаган
«Үлем» дигән әкият».

*(Шагыйрь **Әмир Мәхмүдов**.)*

12. «Җандай күрәм мин искеләрнең җырларын»

(Тукай һәм җыр сәнгате)

«Мин кечкенәдән үк җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем. Мәдрәсәдә хәлфәләр, кече атна кичләрдә, бер кадак симәнкә, ярты кадак чикләвек алып ясаган мәҗлесләрендә дә мине онытмыйлар иде. Мин самавыр артына утырып, алар кушкан көйләрне җырлап бирә идем... Мәдрәсәдә үк мине җырчы диләр иде», – дип язган Г. Тукай.

«Мотыйгыя» (Уральск) мәдрәсәсе шәкертләре, ел саен, яз көннәрендә Чаган елгасы белән Урал елгасы кушылган җиргә пикникка чыга торган булалар. Мондый чараларда Габдулла бик актив. Утырышыр өчен матур урын табып, самавыр куеп, ашъяулык җәеп чәйләр эчкәннән соң, күңел ачу башлана. Уен-көлке, җырлашу... Габдулла иптәшләренә кушылып та, үзе генә дә җырлаган. Гадәттә, көлкеле, шаян җырлар җырлап, иптәшләренең күңелен күтәрә, көлдерә торган булган. Шагыйрьнең сабакташы Шәриф Каюмов үзенең истәлегендә яшь Тукайның менә бу куплетны яратып җырлавын әйтә:

Скрипкам тари-тари, тари булса да ярый,
Безгә кызлар ләкмәс инде, карчык булса да ярый.

«Тукай укудан, эштән бушаган арада мәдрәсә идәне буйлап йөреп, көйләп, «Мөхәммәдия»не укырга ярата. Ашханәгә юынырга төшкәндә, ашханә буенча җырлап йөри. Биредә ул татарның милли көйләрен – «Кара урман», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү» көйләрен җырлый иде. Дөрестән дә, җырны ул сөеп башкара иде», – дип дәвам итә Ш. Каюмов.

Ул кубызда да бик матур уйнаган. Шул ук Шәриф Каюмов болай дип искә ала: «Чыннан да, Тукай кубызда матур итеп уйный иде. Башкорт халкының курай тавышларын чыгарып, Урал

елгасының агышына, ак мамык кебек агарып торган сирәк болытларга карап уйный».

Замандашларының истәлекләренә караганда, «зуп-зур-Тукай» булгач та җырдан аерылмаган ул. Шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй Казанга килгәч, Тукай белән берничә тапкыр очраша. «Күп кеше белән тыныша алмаган Тукай белән без иптәш идек. Төннәрендә күбесенчә сөйләшми-лыкылдамый утыра идек. Тик утыра идек. «Сөйләшмик, ди торган иде яки җырлый иде», – ди «Тукай турында истәлек» язмасында.

Җаек мәдрәсәсендә укыганда ук дәртләнеп халык җырларын җыя башлый ул. Җәйге ялга киткән иптәшләренә дә «өй эше», ягъни үз төбәкләрендәге әкиятләр, җырлар, гомумән, халык авыз иҗаты әсәрләрен язып алып килүләрен сорый. Җырлар гына тупланган «Җырлар дәфтәре» барлыкка килә. Бу дәфтәр 1946 елда гына табыла һәм шул ук елда басылып та чыга. Анда утызга якын саф татар телендәге җырлар теркәлгән була. Бу җырлар киләчәктә шагыйрь өчен шигъри мәктәп булгандыр. Фольклорга мәхәббәт аның иҗатын, телен халык сөйләменә якынайта. Аның иҗатына чын мәгънәсендә халыкчанлык хас.

Г. Тукай иң беренче чиратта халык авыз иҗатына, аеруча җыр сәнгатенә нигезләнеп иҗат иткән. «Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятыбызга, бер дә шөбһәсез нигез булачак», – дип ышанып әйткән.

Әйе, Тукайның шигырьләре җырлап тора. Тукай үзе исән чагында ук аның «Тәфтиләү», «Әллүки», «Зиләйлүк», «Туган тел» җырлары халык арасында тарала, җырлана. Тукай вафатыннан соң, бигрәк тә совет власте елларында шагыйрь сүзләренә байтак җырлар иҗат ителә. Композиторлардан Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллин, Алмаз Монасыйпов, Р. Яхин, М. Имашев һ.б. иҗат иткән җырлар халык арасында популярлык казана. «Шүрәле», «Су анасы», «Кисекбаш» балетлары Тукай исемен, татар исемен дөньяга таныттылар. Ә композитор Заһидулла Яруллинның «Тукай маршы» – Тукай шәхесенә карата иң зур һәйкәлләрнең берсе.

Г. Тукай сүзләренә берәр җыр.

«Кем белер кадереңне?» – М. Рахманкулова башкаруында.

13. Театр яктылыкка, нурга илтә (Г. Тукай һәм театр)

1905–1907 еллар революцион күтәрелешендә татарларның оешкан төстә катнашуларының бер төп сәбәбе – форсатны милли азатлыкка ирешү өчен файдалану була. Бу еллардагы халык күтәрелеше идарә машинасын җимерүгә ирешә алмаса да, аны шактый какшата. Шуның нәтиҗәсендә, күпмедер дәрәҗәдә ирек бирелү белән үк, татарлар яши торган барлык төбәкләрдә дә шактый үзгәрешләр, яңалыклар күзәтелә. Мәсәлән, Петербург, Казан, Оренбург, Уральск, Уфа шәһәрләрендә татар телендә дистәләгән газета-журналлар чыга башлый. Мәктәп-мәдрәсәләр яңача укытуга юнәлеш ала башлыйлар.

Татар яшьләре, зыялылар театр булдыру уе белән яна. Татарча театр куелуга омтылышлар элегрәк тә була. Мәсәлән, Касим (хәзерге Рязань өлкәсе) шәһәрендә 1900 елда ук ике көн рәттән театр уйнала. Казанда беренче татарча спектакльне 1903 елның 30 декабрендә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе яшьләре уйный. Ул Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасының беренче варианты була. Аны бик яшерен уйныйлар. 1906 елның 21 апрелендә Уфа яшьләре Гаяз Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» әсәрен клубта куярга рөхсәт алалар. Моны җәмәгатьчелек алдында яшеренмичә куелган беренче спектакль дип санарга мөмкин.

1906 елның 22 декабре татар профессиональ татар театрына нигез салынган көн дип тарихка кереп кала. Бу көнне Г. Камалның төрекчәдән тәрҗемә ителгән «Кызганыч бала» спектакле уйнала. Ни өчен татар драматургларының әсәрләре уйналмаган бу көнне? Югыйсә, Г. Ильяси, Ф. Халиди, Г. Камал, Г. Исхакый һ.б.ларның дистәләгән сәхнә әсәрләре бар. Ләкин губернатор тәрҗемә әсәрләр генә уйнарга (бу очракта рус яки чит ил драматургларының әсәрләре) рөхсәт бирә. Безнең яшьләребез монысына да шатланып риза. Әкренләп татар драматургларының әсәрләрен дә репертуарга кертеп җибәрәләр. Рөхсәт алынган бит инде!

Баштарак «Яшьләр» исемле труппа төзелә. 1907 елда Оренбургта оешкан «Сәйяр» исемле артистлар төркеме 1910 елны Казанга бөтенләй күчеп килә. Шуннан соң профессиональ татар театры тарихы башлана. Бу хәл татар мәдәнияте тормышында бик әһәмиятле вакыйга булып әверелә.

Театр һәм Тукай арасында нинди бәйләнеш бар соң? Театр – Тукай уйлавынча, зур бер милли казаныш. Театрга, аның киләчәгенә зур өметләр баглаган ул. Театрның искиткеч тәрбияви роль уйнавын әйткән. Үзенең мәшһүр «Театр» шигырендә: «Халыкка дәресе гыйбрәттер театр, күңелдә йоклаган дәртне уятыр», – ди.

Тукайның яратып, ачылып аралаша торган даирәсе балалар һәм артистлар булган. «Тукай артистларны якын күрә һәм сәхнәне ярата иде», – дип искә ала беренче татар артисткасы С. Гыйззәтуллина-Волжская. Ул замандагы татар артистлары ачлы-туклы килеш **театр** дип яшиләр. Барысы да гадиләр, җитмәсә, патриотлар. Бары-югы уртак. Шау-гөр килеп аралашалар, барысы да бертигез, гаеп итеш юк! Тукай аристократлар, байлар арасында үзен бик киеренке тота торган була, андыйлар белән аралашырга яратмаган, диләр. Ә артистлар – үз кешеләр!

Тукайның дуслары да театр дип җан ата. Мәсәлән, «Сәйяр» труппасын оештыручы Г. Кариев белән Тукай Уральскида «Мотыйгия» мәдрәсәсендә укыган, якын дуслар булганнар. Ф. Әмирхан, Г. Камал, С. Рәмиев татар театрына нигез салуда зур эш башкарганнар.

Казанга килгәч, труппа Тукай яшәгән «Болгар» номерларына урнаша. Тукай яшәгән 40 нчы бүлмә «Сәйяр» номеры белән бер коридорда. Тукай кичләрен «Сәйяр» номерына керә. Анда Г. Камал һәм артистлар белән бергә шаяртып, төрле көлкеле сүзләр сөйләп вакытын үткәрә. Татар театр труппасына «Сәйяр» исемен дә Тукай кушкан, диләр. Бервакыт артистлар бүлмәсенә кергәч, Тукай труппаның белдерүләрен укый. «Кырым-Кавказ мөселманнарының мәхәббәтен үзенә җәлеп иткән мөселман артистлары ширкәте», – дип укый да, тыны беткән кыяфәттә: «Уф-ф-ф! Сузсаң, Мәскәүләргә җитә ишаннарның чалмасы, дигәндәй, дилбегә буйлык театрыгызның исеме», – ди. Берәр кыскарак исем кирәклеге турында сүз була. Г. Кариевтан Тукай: «Театрыгызда ничә кеше?» – дип сорый.

Г. Кариев, минем белән җиде, дип җавап бирә. Тукай: «Алайса сез әнә теге, күк йөзендәге Җидегән йолдыз кебек туктаусыз хәрәкәттәге сәйярларга тиң икәнсез. Әллә сезгә дә Сәйяр дип әйтәбезме?» – ди. Барысы да бу исемне күтәреп алалар һәм театр «Сәйяр» исеме белән яши башлый.

Тигез күрә бөтен җанны театр, кирәк кол бул,
кирәксә император.
Мөкатдәс ул, бөек ул, гали зат ул, тәмам хөр ул,
вә бик киң ул, азат ул.
Вә ул дәрел голүм (белем йорты) дарел әдәптер
(әдәп йорты),
Холыкларны төзәтмәккә сәбәптер, –

ди ***«Театр»*** шигырендә шагыйрь.

Аның бу сүзләре очраклы гына язылмаган. Ул аларны тирән кичереш белән, бик уйлап язган. Инде Тукайлар театр дип янып йөргән заманнар артта калды. Бүгенге көндә татар илендә һәм аннан читтә дә дистәләгән театрларыбыз эшләп килә. Үткәнебезне, бүгенгебезне күрсәтеп, халыкны тәрбияли, көлдерә, уйлата, елата. Дөрес, бүгенге көндә театрларга да артистларга да бик җиңел түгел. «Сәхнә җене» кагылганнар гына мондый авырлыкларга түзә ала, киләчәккә ышаныч белән, өмет белән карый ала торгандыр, нәкъ «Сәйяр»чылар кебек.

«Театр» – җыр (М. Имашев көе).

14. Г. Тукай – социаль контрастлар шагыйре

1. Тукай иҗаты турында сөйләгәндә, аның социаль контрастларны оста һәм белеп бирүен әйтмичә һич булмый. Тукай индивидуалист шагыйрь түгел, ул чын мәгънәсендә халык улы.

Шагыйрьнең 1909–1910 еллар лирикасында шәхси һәм интим кичерешләр өстенлек алса да, ул соц. контрастлар темасына да урын бирә башлый. Менә аның ***«Яратырга ярый»*** исемле шигыре.

Яратырга ярый кышны, вәләкин зәмһәрире бар,
Киемсез калтырап торган мескене, фәкыйре бар.
Яратырга ярый җәйне: матур ул, анда зур ямь бар.
Вәләкин таш бинасы юк фәкыйрьләргә җәһәннәм бар.
Яратырга ярый дөнья: матур кырлар, матур таулар;
Яратмыйм мин вәләкин һич, сәбәп шул: ибне адәм бар.

Дөньяны яратмыйм, ди шагыйрь, чөнки анда адәм бар. Беренче карашка сәер тоелган бу сүзләрнең мәгънәсен алдагы ике строфа ачып бирә. Кыш матур, ләкин төлке толып киеп, рысак-

ларда выжлап узып китүче байлар өчен. Җәй тагы да матуррак, әмма бөкрәеп йөк ташучы яисә кәкре урак белән әлсерәп иген уручылар өчен түгел. Тигезлек булмаганга, берәүләр икенчеләр хисабына яшәгәнгә, җәбер-золымга тулы ирек бирелгәнгә шагыйрь дөньяны сөйми. ***«Күгәрчен»*** шигырендә ярлы, хокуксыз халык – күгәрчен, ә залимнәр – лачын сыйфатында бирелә.

Көче күп, тырнагы үткен, явыз ул,
Зәгыйфьләрне ашар, канлы авыз ул.

«Кярханәдә» (завод-фабрика, һөнәрханә) шигырендә эшче халкының бик авыр хезмәте сурәтләнә. Авыр хезмәт эшченең җелеген суырган.

Аргайгандыр үзе, саргайгандыр йөзе,
Бөкрәйгәндер биле, нурсызланган күзе.

Тукай соц. контрастлар темасына 1911–1913 елларда, моңарчы булмаганча, зур игътибар бирә. Менә аның «Сайфия» (1911) шигыре. Сайфия – дача дигән сүз. Шигырь «Иделдә сәяхәтем хатирәсе» дигән аңлатма белән башлана. Тукай 1911 елның апрелендә пароходка утырып Идел буйлап сәяхәткә чыга. Максаты: су юлы буйлап Әстерханга төшү һәм Сәгыйть Рәмиевтә кунак булу, кыргыз арасына кымызга бару.

Пристаньнарның берсендә тәкәббер бай пароходтан төшә. Багажын күтәргән носильщикларны иярткән килеш, шундый ук вәкарь, шундый ук олысымак кыяфәтен саклап, як-якка күз дә салмыйча, ярга чыга да, каршыларга килгән фаэтонга менеп утыра.

Ярда торган ач халыкка йөз дә бормый, туп-туры,
Юргалый ул шунда тиз-тиз, кайда бай сайфиясе.

Байның дачасы экологик чиста урында – авылда. Ләкин авыл ач, хәерче, мохтаж. Җимерек өйләр арасында кукраеп бер «кәйфия», ягъни байның күңел ача, ял итә торган зур йорты тора. Мескен, изелгән мужиклар, бу мәһабәтне күреп, җан ачысы белән, «во как!» диләр.

«Золым» шигыре.

2. 1911 елда ил өстенә яңа афәт – дәһшәтле ачлык килә. Крестьяннар чәчкән орлыкларын да җыеп ала алмаганнар. Таза ирләр, яшь егетләр эш эзләп читкә агылалар. Кайберләре тәрәзәләренә аркылы-торкылы такта кадаклап, гаиләләре белән кузгалалар.

Шәһәр урамнары, базар тулы хәер сорашучылар. Кешеләр урамда очраштымы, ике сүзнең берсе – ачлык турында. Әле бит кыш керде генә. Яңа өлгергәнче халык нишләр? Тукаебыз халык өстенә төшкән бу афәткә әрнеп, ***«Көзге җилләр»*** шигырен яза.

Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил елый.
Җил еламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый.
– Иң сөекле эшче әүладым бу ел ач калды, дип, –
Изге, шәфкатьле анабыз – мәрхәмәтле җир елый.

«Көзге җилләр» шигырендә шагыйрь ачлыктан тилмергән халыкны кызгану һәм кызгандыру максатын гына куймаган. Ул шушы афәтнең социаль сәбәпләренә ымлый торган контрастларга да укучының игътибарын юнәлтә.

Куйса монда корткалар төшкән тешен алтын белән,
Бер телем икмәк дип, анда назлы нечкә бил җылый.

Әйе, Җир балалары арасында да тигезлек юк. Шушы дәһшәтле ачлыкта берәүләр төшкән тешен алтын белән куйдырса, икенче берәүләр ачка тилмерә. Никадәр контрастлык!

Үзенә эш чыкканга куанып, чираттагы корбаны янына ашкынып килеп җитә торган Газраил дә, «бер сынык юктан гына үлгән таза ирләр күреп» хәтта тетрәнеп калган.

«Җан алырга кызганудан анда Газраил елый», – ди шагыйрь.

Кайвакыт гап-гади пейзаж шигырендә дә соц. контрастка ымлый торган юллар килеп керә. Мәсәлән, «Буран» шигыре. Табигать күренеше булган буранны бөтен төгәллеге белән тасвирлый шагыйрь.

Тик кенә торганда капланды томанга бар һава;
Кар оча, кар себерелә, кар котырына һәм кар ява.
Кар бәрә йөзгә рәхимсез, күз ачып булмый карап;
Һәр кара нәрсә бүре һәм һәр маяк булды карак.

Шагыйрь шаяртып, әллә Каф тау арты җеннәре ычкындымы икән, әллә Ходайның бихисап зур мендәре тишелдеме икән, ди, буранның ни дәрәҗәдә көчле икәнен күрсәтеп. Ләкин соңгы ике юлдагы көтелмәгән чагыштыру белән шигырен йомгаклап куя.

Сукранам мин, кар арасыннан карый да ай көлә.
Мин фәкыйрь, михнәттә гүя, – чарлагыннан бай көлә.

1909 елда язылган ***«Сәрләүхәсез»*** (исемсез шигырь) шигырендә:

Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,
Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын –
Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,
Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен.

Шагыйрь икәнсең, халык өстенә, гади халык өлешенә төшкән тарихи-иҗтимагый авырлык драмасын аңла, әдәбиятта шуны беренче булып күрсәт, ди. Аның үз ижаты да шул чакыруына тулы җавап бирүне изге максат итеп куйды.

15. Тукай мөтәрҗим (тәрҗемәче) шагыйрь генәме?

Г. Тукайның шигырь җыентыкларына күз йөртеп чыксаң, шактый гына тәрҗемә һәм ияреп язылган шигырьләр очратасың. Шагыйрь үзе дә аларның тәрҗемә шигырьләр икәнен җәяләр эчендә бирә, кем шигыреннән тәрҗемә иткәнен дә күрсәтә. Әлбәттә, болар турыдан-туры, сүзгә-сүз, юлга-юл тәрҗемәләр түгел, ә ирекле тәрҗемәләр.

«Фикер» газетасының 1905 елның 26 ноябрь санында «Мөтәрҗим Габдулла Тукаев» имзасы белән «Мужик йокысы» шигыре басыла. Әсәр рус шагыйре А. В. Кольцовның «Что ты спишь, мужичок?» дигән шигыреннән ирекле тәрҗемә. Татарда матбугат туганчы ук, байтак әсәрләр язса да, Тукай үзенең «Мужик йокысы» шигырен беренче әсәре итеп күрсәтә. Моның сере шул: шигырь саф татар телендә ижат ителгән. Чөнки «Фикер» газетасы баштан ук: «...газета халис казанча, урам вә гавам теленә дә язылачактыр», – дип белдерә, бөтен илгә шундый игълан тарата. Шунлыктан шагыйрь дә казанча, халык телендә яза. Болай язу аның үзенә дә ошый. Моңа кадәр корама телдә язылган, басылган шигырьләрен хәтта «онытырга» да риза.

Рус әдипләреннән аеруча А.С. Пушкин, М.Ю. Лермонтов, П. Майков. И.А. Крылов, Плещеев, В. Жуковский, Иванов-Классик, Позняков, Л.Н. Толстой, Көнбатыш Европа әдәбиятыннан Шекспир, Гёте, Гейне, Байрон, Кнут Гамсун һ.б. исемнәре, алардан тәрҗемәләр Тукайның шигырь җыентыкларында, мәкаләләрендә шактый очрый. Бу мисал үзе генә дә Тукайның ни дәрәҗәдә рус һәм Көнбатыш әдәбияты белән дә якыннан таныш булуын күрсәтә. Әле В.Г. Белинский, Писарев, Добролюбов мәкаләләрен дә укып үзләштерә ул.

Ф. Әмирхан тәкъдиме белән яки яраткан шагыйре Гейнены оригиналда укырга кызыкканмы – Тукаебыз Мария Карловна исемле немец хатынына тел өйрәнергә дә йөри башлый.

Моңарчы исеме дә ишетелмәгән Уральск каласыннан килеп, ике ел да үтми, татар шигъриятендә беренчелекне дәгъва итә башлаган шагыйрьгә, әдәбият мәйданына аңардан алдарак аяк баскан бик күпләрнең ачуы, көнчелекләре килә. Гадәттә, сәләтсез яки урта кул исәпләнгән бәндәләр шундый юлга баса.

Ачу килмәслекме? Китап арты китабы чыга, күз ачып йомганчы сатылып та бетә, нәширләр аны үзләре эзләп килә, гонорар мәсьәләсендә дә алга чыга. Тукайның исеме – һәркемнең авызында. Авыл мужикларына чаклы шигырьләрен ятлыйлар...

«Ичмаса, кыяфәте булса икән! Язганы да ah итәрлек түгел бит. Күбесе Пушкин яисә Лермонтовтан тәрҗемә», – дип төкерек чәчә дошманнар. Алар бик астыртын эш йөрткәннәр, аның турында гайбәтләр таратканнар, шәхесен кимсетә торган имеш-мимешләр җибәргәннәр, арада сүз йөртеп дуслары белән бозылыштырырга тырышканнар. Дошманнарның аеруча яратып кулланган тактик алымнарының берсе, әлеге дә баягы, Тукайның шагыйрьлеген инкарь итеп, мөтәрҗим, ягъни гади бер тәрҗемәче итеп калдыру. Шагыйрьнең Пушкин, Лермонтов һәм башка шагыйрьләрне тәрҗемә итүен, ияреп язуын, алдынгы рус культурасына мәхәббәт белдерүен – үз милләтенә мәхәббәт юклык итеп, руска сатылу, халкына хыянәт итеп күрсәтергә тырышалар. Шагыйрьнең шәхесен кимсетә торган уйдырмаларын мең данә тиражлы газета-журналларда тараталар. 1908 елда Оренбургта чыгып килүче «Чүкеч» журналының бер санында Тукайга атап икенче бер шагыйрьнең «Мөтәрҗим шагыйрьгә» исемле шигыре басыла.

Син дә Пушкин, Лермонтовның, бозгалап шигырьләрен,
Шатланамсың түшне киереп, мин дә бит шагыйрь, диеп.

Тукай горур булып кала, бу шигырьгә җавап бирми. Бераздан, кыюланып китеп, шул ук автор тагын бер шигырен бастыра. Тукайны ниләр генә дип мыскылламый ул! Бу юлы инде Тукай түзеп кала алмый – «Җавап» исемле шигырен язып ташлый.

Шигъре Лермонтов вә Пушкин – олуг саф диңгез ул,
Хәзрәте Пушкин вә Лермонтов, Тукай – өч йолдыз ул.

Син дә шул диңгез ярында, и агу йоткан көчек!
Телләреңә сузган буласың – җитми, җитми, кит күчеп.
Кит хәзер, ләкин китәрдә, сал колак бу сүзгә бер:
Барчы, эт, гомреңә буе шул күктә өч йолдызга өр.

Әмма шигырь революциядән соң гына Тукайның кулъязмалары арасыннан табылып басыла башлый. Ник аны шагыйрь дөньяга чыгармаган? Бу сорауга шагыйрьнең «Сәфилгә» каршы язарга теләгән каләмгә» (сәфил – түбән, вөҗдансыз кеше) шигыре җавап бирә.

Юк, маташма, и каләм! – калсынчы шундый юк белән;
Борча атмак көлкедер тау-таш ватарлык туп белән.
Сипмә конфетти аның төсле сәфилләр өстенә:
Ул хәзерләнгән атарга йөзгә каршы чүп белән.

Каршы җавап белән чыгу Сафил өчен, русча әйткәндә, «с лишком большая честь» булачак. Шунлыктан, Тукай җавап сүзе белән чыкмаган булса кирәк.

Язмамны ***И. Нуруллинның «Габдулла Тукай»*** китабыннан өзек белән йомгаклыйм.

«...түбән җаннарның бәйләнүләренә Тукайның бер дә исе китми башлаган, күңеле тәмам тынычланган дисәк, әлбәттә, хата булыр. Ул бит кеше җанлы кеше, җитмәсә, гаять юка тирелеле. «Сафил»ләрнең һаман дәвам иткән һөҗүмнәре аны барыбер борчыган... Ләкин Тукай милләткә хыянәт итүдә гаепләүчеләргә аз гына да исе китмәгән кыяфәт биреп, рус халкының бөек улларына мәхәббәтен һаман белдерә, тәрҗемә итә, файдалана. «Кыйтга» исемле шигырендә болай дип белдерә:

Аузын эт япмас, фәкать уйнар гариб (үз иленнән
аерылган) сазым минем,
Мокътәсиблектә (ияреп язуда)
Жуковский – зур остазым минем», – ди.

16. Шат яратса да җиһанга ят яраткан Раббысы!

1907 елны Уральскидан Казанга килеп төшкәндә Тукай күңелендә бәйрәмчә хисләр өстенлек итә. Ул бит хәзер туган ягында, татарның мәркәзе Казанда. Солдатка барудан да котылды. Инде Казанда төпләнеп калсаң да була. Иҗат итәргә, аралашырга дуслар күп булачак. Аннан соң монда әдәби мохит бөтенләй икенче! Ф. Әмирхан, Г. Камал, С. Рәмиевләр үзләре генә дә ни тора! Татар телендә чыгучы газета-журналлар күпме! Татар театры эшен башлап җибәрде. Казан кайный, Казан гөрли. Әмма Казан шагыйрьне ничек каршы ала соң? Кочак җәеп түгел. Әлбәттә, Уральскида һәм Казанда чыгучы газета-журналларда басылган шигырьләре буенча аны беләләр. Иҗаты белән таныш-лык яхшы. Хәтта үз сүзен әйтә ала торган талантлы шагыйрь килә әдәбиятка дигән сүзләр дә йөри. Р. Фәхретдин, Тукайның вакытлы матбугатта басылган шигырьләре белән танышып бара торгач, «татарның Мәгаррие булачак егет бу» дигән фикер әйткән (Әл-Мәгарри – гарәпнең борынгы бөек шагыйре). Ә үзен... хәтта танымыйлар да. Бер шәкерт яки мәхдүм дип кенә уйлыйлар.

Ә Уральскида аның дәрәҗәсе зур була.. Мәдрәсәдә яхшы укучы. Гарәп, фарсы һәм төрек телләрен бик яхшы белә. Хәтта, дәрестә хәлфәләрнең, хәзрәтнең дә хаталарын төзәтеп утыра. «Без урамда хәзрәт, хәлфәләрне очратсак, кулларыбызны күкрәккә куеп, сәлам биреп үтәбез. Ә алар Тукайның үзенә «Габдулла әфәндегә сәлам!» дип исәнләшеп китәләр. Тукайның шундый дәрәҗәле булуына без, шәкертләр, бик соклана идек», – ди истәлекләренең берсендә Гали Хикмәтуллин исемле сабакташы. Шагыйрь буларак та дәрәҗәсе зур. Аны укыйлар, аны танып та, болай да беләләр. 1906 ел урталарыннан башлап 1907 елның көзенә кадәр, ягъни бер елдан артык вакыт эчендә, 50ләп шигъри әсәр, «Шүрәле» поэмасы, 50гә якын мәкалә һәм фельетон язылган. Тукай һәрьяктан караганда да беренче скрипканы уйный. Яшә дә яшә инде шушы Уральскиеңда! Әмма «рәхәт булса да торган җир, сагындыра Туган ил!»

Габдулла Казанда кала. «Болгар» номерларыннан бер бүлмә ала. Эш тә таба. «Әльислах»ка хезмәт итә, «Китап» исемле кечкенә нәшриятка экспедитор булып урнаша... һәм каләмен дә ташламый.

Тукай кешеләргә авыр якыная, аның белән чын дуслык мөнәсәбәтенә керү җиңел булмаган. Әмма Тукай белән Ф. Әмирхан арасында дуслык чагыштырмача тиз урнаша. Казанга килгәч, беренче тапкыр күңел капчыгын да Тукай Әмирханга чишә. 1908 елның язында була бу. «Мин үзем килеп эләккән кругымнан разый түгел. Мин Казанга килгәннән бирле соң дәрәҗәдә эшлексезләндем. Минем бүлмәдә көне-төне вакытларын кая куярга белмәгән кешеләр җыелып яталар...», – ди. Казанга килүенә бер ел тулгач, Ф. Әмирханга язган хатында (Ф. Ә. бу вакытта Серноводскида дәваланып ята) мондый юллар бар: «Торам-торам да: «Ярабби! Ятимлекләр, фәкыйрьлекләр, ачлыклар, авылдан-авылга сатылып йөрүләр, рәхимсез татар байларында хезмәт итүләр, татар мәдрәсәсендә черүләр арасында да саклап килдекем талант очкыны шушы исрекләр, исрек иптәшләр арасында бер дә кабынмаслык булып сүнәрмени инде?» – дим.

Тукай үзе килеп эләккән чиле-пешле яшьләр кругыннан ризасызлыгын әнә шулай белдерә. Баштарак, заманы өчен шактый билгеле булган кешеләр белән аралашу Тукайга ошый. Алар шагыйрьгә Казанның алдынгы яшьләре булып күренә. Күп беләләр, эрелек юк, күңелләрендәге – телләрендә. Бүлмәгә шаулашып килеп керәләр дә өстәлдәге кәгазьләрне, китапларны идәнгә себереп төшереп табын әзерлиләр. Өстәлгә шапылдатып шешә утыртып куялар. Китә кызып мәҗлес. Кечкенә бүлмә балта эләрлек төтен белән тула. Аннары тотыналар карта уйнарга. Килгән мәлгә Тукайның да күңелендә бәйрәм настроениесе. Үзләрен эре тота торган затлар җыелган мәҗлесләрне җаны-тәне белән сөйми торган Тукайга бу компания кулай булып тоела. Әмма... Тора-бара мондый «бәйрәмнәр»нең җайсыз яклары да үзен сиздерә башлый. Укыйсы, өйрәнәсе, язасы бар... ә мөмкинлек юк. Тукайның киң күңеллелегеннән, беркатлылыгыннан, юмартлыгыннан файдалана әлеге компания. Тукай өйдә булмаса да аптырап тормыйлар. Керәләр, утыралар, тагын мәҗлес, тагын кәеф-сафа. Тукай номерын бервакытта да бикләп йөрмәгән. Кем тели – шул керә, кирәк әйбер булса (кәгазь, каләм, кара савыты, савыт-саба) алып чыгалар да кертергә оныталар. Шулай итеп, мәҗлес яратучылардан качып та котылып булмый. Мондый тормыш Тукайның саулыгы,

фикри үсеше һәм иҗаты өчен тулаем алганда зарарлы була. Ф. Әмирхан һәм тагын берничә иптәше Тукайга сүз белән дә, эш белән дә ярдәмгә киләләр. Ф. Әмирхан аны үз араларына алырга тырыша. Ә Әмирханның тирәлеге Казанның милли аристократиясе, яңа карашлы байлар, университет тәмамлаган интеллигенция, галимнәр дә юк түгел. Әмма Тукай ул даирәгә сыя алмый. Чөнки Тукай бу даирәнең кыланмышларын кабул итә алмый; фәлсәфәсен, йөзгә ясалма елмаю чыгарып, тыныч кына тыңлап тора алмый. Фатих, Галиәсгар, Сәгыйть дуслары янында да кайвакыт үзен хөр сизә алмый. Кала һаман шул үзе котылырга теләп тә котыла алмаган круг. Чөнки болар янында сүзне үлчәп сөйлисе юк, ни әйтсәң дә бата, хәтерләре калса да, зарар юк.

Шулай да шушы бер ел эчендә (1907–1908) Тукай каләме тик ятмый. Эштән соң, «дус»ларыннан арынып торган арада, алар калдырып киткән төтен эчендә Шагыйрь алтмышка якын шигырь, ике әкият-поэма чыгара. Ике җыентыгы, «Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш» сатирик поэмасы, ике дистәгә якын мәкалә һәм фельетоны дөнья күрә.

Каршылыклар белән көрәшә-көрәшә яза Тукай! Теле дә ачы, туры сүзле! Аның талантыннан көнләшүчеләр арта. Тукай теленең ачысын татыганнар да өстәлә болар сафына. Җитмәсә, тәрҗемәче шагыйрь генә бит ул, дип җанына тияләр.

Күп җыланнар сызгырып читтән карыйлар бәхтемә.
Борыла-сырыла бәдбәхетләр үрмәлиләр тәхтемә.
Аз кеби баскан бу золмәт тормышым йортын минем,
Түзмиләр бит бер генә яктан ачылган яктыма,
Үзләре... сүздән түбәннәр, күзләре тездән түбән;
Эт кебек һаулап яманым, күз йомалар яхшыма, –

дип яза әрнеп, ***«Дошманнар»*** шигырендә.

Әйтелгәннәргә доносла, цензура кысуы һәм охранканың бармак янавы да өстәлә. Язганнарыннан гаеп эзләү, китапларына арест салу, үзен җавапка тартуга кагылышлы эшләр баш калкыта. Аеруча бу хәлләр 1911 елдан башлана. Ләкин доносла нәтиҗәсендә, охранканың Тукай шәхесенә һәм иҗатына сагаеп каравы 1908 елдан ук күзәтелә. Шагыйрьнең сәламәтлеге дә көннән-көн какшый бара. Иптәшләре докторларга күренергә кушсалар да, Тукай аларны тыңламый. Шулай да, бервакыт докторга

барып карый һәм аннан үлеп бетеп кайта. Доктор дигәне бик тупас, мәгънәсез кеше булып чыга, күрәсең. Җүнләп тикшереп тә тормастан, Тукайның киләчәген ямьсез сурәттә күрсәтә торган диагноз куя. Үтә дә вәсвәсәчел Тукайга бу җитә кала. Бүлмәсенә кайтып ава да бикләнеп ята. Замандашларының истәлекләренә караганда, муенына элмәк салу фикеренә килә, хәтта, бу ниятен тормышка ашыруга омтылыш та ясаган. «Шул төнне мин җитмеш мәртәбә үземне-үзем үтерергә уйладым... Көчем җитмәде... Ләкин үлмәгән белән дә сау калмадым. Өмет бетте, кан бозылды, кеше җылытырга түгел, үземне җылытырлык та кан калмады. Хәятка өмет беткәч, барысы да бетте. Менә шуннан соң мин акрынлап үз-үземне үтерү юлына керештем. Өч ел булды, менә шул хәл дәвам итә...», – ди үзенең бер язмасында шагыйрь. Бу хәл 1910 елның март ахырларында булырга охшаган дигән фикер әйтә тукайчы-галим И. Нуруллин.

Ә 15 апрельдә Тукайның ***«Катиле нәфескә»*** (үз-үзен үтерүчегә) шигыре басыла. Үз-үзен үтергән кешегә мөрәҗәгать итеп, бәхәсләшеп, бу эшнең төзәтелмәслек зур ялгыш, хәтта җинаять икәнлеген исбат итәргә тырыша һәм шигырен болай дип тәмамлый:

Газап китми кабердә тән черүдән;
Бүрек ташлап котылмыйлар бүредән.

Бүлмәдә бикләнеп ята торгач, Тукаебыз әкренләп суынган, баштагы фикереннән арынган булса кирәк. Тукай әкренләп үзен кулга алган. Аның бит милләткә хезмәт итәргә дигән вәгъдәсе бар. Барлы-юклы гомерен үз кулы белән өзсә, халкы ни әйтер!

«Тукайның шәхси тормышы булмады. Ул халкы өчен яшәде, ул – халыкның бары тик бер кечкенә кисәкчәсе. Ул үлү белән дөнья бетми. Халык кала, халык яшәячәк. Халык белән бергә аның уйлары, борчулары, кайгы-сөенечләре, изге теләкләре яшәячәк. Язганнары кешеләрдә азмы-күпме изге тойгылар уята икән, шул тойгылар буыннан-буынга күчәчәк, әсәрләре яңадан-яңа буыннарга тураерга, яхшырырга, кеше булырга ярдәм итәчәк». (*И. Нуруллин «Габдулла Тукай», 1979, 292 нче бит).*

Менә шушы уйлар Тукайга яңадан тормышка кайтырга көч биргәндер.

...Тел яшергән Тарих кына белә
Бар кыйлганын аның, күргәнен.

Ә шулай да булгалаган бит илгә
Игелеклелек кылу үрнәге.
Бу Тарихта мәшһүрләрне куйсаң,
Ул яшәгән хәлгә, урынга, –
Байтагының шаулы даны түгел,
Чыкмас иде, бәлки, тыны да!
Яшәрен һәм үлемсезлеген
Дәлилләүгә мохтаҗмы халык?
Шикләнүче булса, кара, тикшер,
Бер бәгырен – Тукаен алып!...

(Р. Фәйзуллин)

17. Ваксынмау

Тукайның 1912 елда язылган ***«Ваксынмыйм»*** дигән шигыре бар.

Син үзеңчә изге эш эшлим дигәндә халкыңа,
Әллә нинди былчырык баулар салалар гаклыңа.
– Бу заман шундый заман, дип, бу вакыт мондый вакыт,
Син үзеңне дөньяда безнеңчә йөрт, безнеңчә тот.
Мин сыялмыйм андый шартлар, фани дөнья вактына,

Бүгенге чыгышымда Тукаебызның кайбер үзенә кенә хас сыйфатларына да тукталып китәргә телим. Әдәбият-сәнгать әһелләре, аеруча шагыйрьләр, бераз сәеррәк, дөньяга икенче күзлектән карый торган кешеләр алар.

Тукайның да шундый сәер гадәтләре, иптәшләрен гаҗәпләндерә торган яклары булган. **Менә аның кием-салымга мөнәсәбәте**. Ни эләкте, шуны киеп йөри. Галстук, ак яка, манжетларны җене сөйми. Иптәшләре, кием-салымга игътибар ит, син бит билгеле шәхес, шагыйрь, дип әйткәләп торалар, ләкин Тукай колагына да элми.

И. Нуруллин Тукайның кием-салымга тәкәллефсез булуын болай аңлата: «Бу аның, барыннан да элек, тормышның көндәлек ыбыр-чыбырына аз игътибар итеп, рухи яшәеш белән яшәвеннән килә. Икенчедән, хөрлек сөюче шагыйрьнең кешене кол итә, вакландыра ямьсезли торган тәртипләргә, гадәтләргә, йола һәм тәкәллефләргә, шул исәптән модага иярүчәнлеккә каршы үзенә күрә бер баш күтәрүе бу».

Тукай мода белән киенергә яратучы, тыштан ялтыраучы «кием калыплары»на нәфрәт белән караган, хәтта. Бервакыт «Әльислах» редакциясенә европача фырт киенгән бер егет килеп керә. Үзен шактый эре тотып, фәлсәфә сата башлый. Тукай, чыраен сытып, тыңлап тора да, әче сүз әйтеп куя. Тегесе дә җавапсыз калмый. Шагыйрь чыгып китә һәм бераздан әйләнеп тә керә. Иптәшләре шаркылдап көлеп җибәрәләр. Көлмәслекме? Тукай җиңенә, газетадан кисеп, ярты аршин киңлегендә «манжет» таккан, муенында – шул ук газетадан кисеп алынган киң «ак яка» һәм мунчала галстук. Гәүдәсен уклау йоткандай туры тотып, юк таягын уйнаткан булып, бер йөреп күрсәтә дә: «Я, мин фәлән фәләнов (теге егетнең исемен атый) булдыммы инде?» – ди. ***«Улмы? Ул...»*** дигән эпиграммасында мондый сүзләр бар:

Ул зыялыдыр, беләмсез, мәгърифәт, хикмәт сата,
Манжет алган ун тиенгә, биш тиенгә ак яка.

Тукайның тагын бер гадәте **– мәчеләр, этләр белән булашу**. Ул «Әльислах» урнашкан йортның зур, мәһабәт мәчесе белән сәгатьләр буе мәшгуль була. Мәче, эт балаларын номерына алып кайтып ипи-сөт белән сыйлый. Иҗатында, шигырьләрендә этмәчеләрнең еш очравы бу төр хайваннарга мәхәббәте белән аңлатыла булса кирәк. Хәтта балалар өчен «Мияубикә» исемле поэма да яза.

Нинаять, акча һәм байлык дигән нәрсәгә мөнәсәбәте.

Уральскидан Казанга килгәч, яңа танышларыннан берсе, аның Уральскида күпме эш хакы алганлыгы белән кызыксына.

– 20–25 сум чамасы, – ди Тукай.

– Казанда андагы кадәр эш башкарсагыз, ике-өч өлеш вазифа бирерләр иде, – ди танышы.

Шагыйрь, бер дә уйлап тормыйча, ихлас күңелдән әйтеп куя:

– Тамак туярлык, бер дәрәҗәдә мәгыйшәт итәрлек булгач, акчаның нигә кирәге бар? **Акчаның нигә кирәге бар**? Тукайдан гына чыгарга мөмкин шундый сүз!

Ләкин акчасыз да яшәп булмый. Акчаның нигә кирәге бар дисә дә, Тукай акча җиткерә алмаганга зарлангалый, нәширләргә, редакторларга акча сорап (үтенеп түгел, горурлык кушмый) язу җибәрә. Ә бит Тукай, Казанга килгәннән соң ике ел эчендә,

иң зур гонорар ала торган «өчлек»нең берсе була (шуның берсе – Ф. Әмирхан). Китап артыннан китап чыгара. Нәширләр Тукайның һәр язганын эләктереп алырга гына торалар. Мәсәлән, «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасын өлгер һәм җитез Гыйльметдин Шәрәф, бик тиз арада 5 меңле тираж белән бастырып та чыгара. Ул заман өчен 5 мең данә гаять күп! Шул тираж бер ай эчендә сатылып та беткән! Үзе салкын, дымлы, тараканлы һәм күселе 40 нчы бүлмәдә яшәгәнче, бер дигән йорт яки фатир сатып алып, муллыкта, рәхәттә яшәргә тулы мөмкинлеге булган, югыйсә, Тукайның. Гаилә карыйсы юк. Тормышка таләпләре дә зур түгел. Эшләп алганы артыгы белән җитәргә тиеш... Әмма Тукайның кесәсендәге акча торна булып кычкыра. Кергән тизлек белән үк чыгып та китә. Тирәсендә ялманып йөрүчеләр дә җитәрлек. Бурычка алалар, кире кайтаручы гына юк. Тукайның дусты шагыйрь С. Рәмиевнең акча сорау рәвеше: «Бер сум гына бирәсең инде. Кайтарып алырмын дип уйлама тагын!»

Тукай кием-салым, азык-төлек алганда да сатулашмый. Китапны да ташып кына тора. Алары да бик тиз генә кеше кулына күчеп бетә, әлбәттә, бушка!

Безнең татар шагыйрьләренең язмышы шундый, күрәсең! Үзләрен фәкать ижатка һәм халкына багышлаган шагыйрьләрнең кайсының тормышы бал да май булган соң! Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Акмулла, С. Рәмиев, Такташ, Җәлил, Ф. Кәрим, М. Әгъләмнәрне генә атау да җитә. Иң яхшы әсәрләрен я мохтаҗлыкта, я сугышта язганнар алар. Тукай да хезмәтчеләр тотып, яхшы йортларда, муллыкта, рәхәттә яшәсә, бөек Тукай дәрәҗәсенә ирешә алмаган булыр иде, мөгаен!

Кем кием, алтын-көмешләр,
Мал җыюдан ямь таба –
Алтын төсле бер чебен ул,
Чүп базыннан тәм таба.

15 гасырда яшәп ижат иткән
үзбәк шагыйре, фикер иясе,
дәүләт эшлеклесе ***Галишер Нәваи****.*

18. Ни әйтмәс бәндәләр, кермим бәхәскә, Яман-яхшымны бик беләм үзем дә

Гомәр Хәйям *– Иран шагыйре.*

Соңгы елларда, сөйләр сүз беткәнгәме, әллә сенсация ясау максатыннанмы, күп кенә шәхесләрнең шәхси тормышларында казынулар бара. Тукаебыз да бу җәһәттән игътибарсыз калмады. Тәмәке дә тарткан, аракы да эчкән, имеш, шикле урыннарга да йөргән һ.б., һ.б. Акчасын шуның ише нәрсәләргә туздыргач, ничек җитсен ул!

Дөрес, сәламәтлеге кушмаса да, Тукай тәмәке тарткан. Бу аның әле Уральскида яшәгәндә, шәкерт чагында ук өйрәнгән «һөнәре». Яшь кешенең нинди дә булса бер хикмәт ясап тирәюнендәгеләрне шаккаттырасы, егетләнәсе килгән чоры була. Бу – шул чорның җимеше булса кирәк.

Шигырьләре арасыннан күңел ачу, эчкеле мәҗлесләр турында язган бер-ике шигырен мисал итеп китерәләр дә, менә бит, үзе үк хәмердән баш тартмаганын яшерми, дип бәхәскә керәләр. 11–12 нче гасырларда яшәп иҗат иткән Иран шагыйре Гомәр Хәйям робагыйларының берсендә болай ди:

Миңа яшь кыз, шәраб, җыр булса җиткән,
Ә оҗмахларны калдыр үзеңә, Раббым.

Ягъни шагыйрь өчен илһам чыганагы – мәхәббәт, шәраб. Шулай булганда гына күңелдә шигырь-җыр туа. Бусы да шагыйрьләрнең бер сәер гадәтедер, бәлки!

Замандашларының фикерләренә күз салыйк әле. «Тукай өстендә торып кыстамыйча, бер рюмка аракы эчми. Мәҗлеснең ахрына кадәр утырып та, акылын җуяр хәлдә булмый. Аз сөйли, кешене күп тыңлый, кычкырып көлми».

«Мин бервакытта да Тукайның үзе теләп, үзе башлап эчкәнен күрмәдем».

Әйе, Тукай сыраханәләргә, арзанлы трактирларга да бара торган булган. Замандашлары аның бу гамәлен сүз тыңларга, кешеләрне күзәтергә, хәзергечә әйтсәк, тормышны өйрәнергә теләве белән аңлаталар. Бу фаразның дөреслектән ерак тормавы шагыйрьнең Сәгыйть Сүнчәләйгә язган бер хатыннан да күренә (1911, 1 январь). Юмор катыштырып, ул болай ди: «Кич

белән күрше мәйханәгә кереп, тиречеләр, извозчиклар, жуликлар белән катышам».

Тукай кая гына барса да, халык тормышын шулай җентекләп күзәткән, халык тормышын өйрәнгән, әсәрләренә тема һәм фикер туплаган.

«Чиле-пешле» кешеләр даирәсенең Тукайга зур уңайсызлыклар тудырганы турында әйткән идек инде. Ләкин болар, бер яктан, Тукай өчен информация чыганагы да булганнар. Бу егетләрнең күбесе газеталарда эшли. Утыра торгач, телләре чишелеп китеп, чын да, уйдырма да булган Казан гайбәтләрен сибепме-сипкәннәр. «Ә бит Тукай тирләп-пешеп чаба торган репортер түгел. Физик мәгънәдәге хәрәкәтчәнлек һәм җитезлек аңарда бик аз. Тормышы, тышкы вакыйгаларга шактый ярлы булып, редакция бүлмәләреннән һәм гостиница номерларыннан күп читкә чыкмый», – ди тукайчы И. Нуруллин. Тукайның тормыш юлын өйрәнүчеләр шагыйрьнең Казан хәлләреннән искиткеч хәбәрдар булуына таң калалар. «Чынлап та, аның халык җырларыннан файдаланып язылган сатирик куплетлары, эпиграммалары, сатирик шигырь һәм поэмалары, фельетоннары һәм сатирик парчалары бергә тупланган тәкъдирдә Казанның 1907–1913 нче еллардагы тормышын тулы чагылдырган энциклопедия хезмәтен үти алыр иде», – дип дәвам итә И. Нуруллин.

Бала-чагалар белән кызып-кызып кузна уйнаулар, Ташаяк ярминкәсенә барып карусельдә әйләнүләр, хатын-кыз таифәсеннән ераграк торырга тырышуы – болар да Тукайның иптәшләрен гаҗәпләндергән сыйфатлары.

Тукайның характеры да үзенчәлекле булган. Истәлекләрдә Тукайны аз сүзле, сүзен бик үлчәп кенә, яки вакыты белән үлчәп тә тормыйча сөйли торган төртмә холыклы итеп бирәләр. Ялган сөйләү, алдау гадәте юк. Һәрнәрсәне ачыктан-ачык сөйли. Турыдан әйтә, рияланмый, икейөзләнми. Яратмаган яки таныш булмаган кешеләр белән сөйләшү түгел, ачык йөз дә күрсәтми. Принцип һәм идея ягыннан һичкемне, хәтта дусларының да хәтерен саклап тормаган. Үзе бик әче телле. Ләкин үзенә әйткәнне бик авыр күтәрә. Ачуы килгән кешесе белән хәтта атналар буе сөйләшми. Ләкин үзе яраткан кешеләр белән еш кына ачылып китә, сөйләшә, сөйләнә, көлә-көлдерә.

Үзен белдеклегә санаган бушкуыкларны иллә дә яратмаган Тукай. Аның ишеләрдән ачы итеп көлә яки эпиграмма аша чеметә.

Тукай үзе, эчке дөньясы турында, бигрәк тә авыруы турында сөйләргә яратмаган. Ә бит аңарда көчле туберкулез, җитмәсә, соңга таба бизгәк чире дә өстәлә.

Язарга яки сөйләргә туры килгән очракта, авыруын мәзәкләштереп, юмор кушып сөйли. Менә аның бер язмасыннан өзек: «Бизгәк, мин иртәнге чәйне эчеп бетерер алдыннан (сәгать беренче яртыда), көтелгән кадерле кунак шикелле, миңа рәхим итеп, тәнемдә күпме тамыр бар исә, һәммәсен селкетеп, мине хәрәкәттәге поезд шикелле итә иде. Бу дерелдәү никадәр кәеф җибәргеч нәрсә булса да, мин аңар игътибар бирмичә, чәемне дерелдәгән кулым белән ясап эчә бирә идем». Бизгәктән учлап-учлап аспирин эчеп кенә бераз хәл алган. Гомумән, аспирин Тукайның соңгы гомерендә аерылмас юлдаш була. Тагын бер сыйфаты: доктор дисәләр, сырт йоннары тырпая; медицинага ышанмый, врачларны имче карчыкларга тиңли. Үзе авыруының барлыгын һәм җитди икәнен белгән, ләкин бу турыда врач авызыннан ишетеп, канын бозарга теләмәгән.

Мин кызыкмыйм һич кешенең малы, милке, бәхтенә,
Кайда ул, хәтта кызыкмыйм падишаһлар тәхтенә.
Көнче күз салмыйм кешенең йорт-җиренә, нигезенә.
Бер дә янмый күзләрем атлар, сыер һәм үгезенә.
Һич кызыктырмый мине шәп файтоны һәм арбасы.
Әйдә тик сөрсен сафа! – дим, иткәч ихсан Алласы!

Г. Тукай. *«Тәүбә вә истиғъфар».*

19. Г. Тукай иҗатында юмор һәм сатира

Җамал Вәлиди дигән галим Тукай турында болай ди: «Уральскида чагында ук берсе лирика, икенчесе, сатира дип атала торган ике канат үсеп чыкты да, Тукайны шигърият күгенә күтәрде».

Әгәр тапшыруларыбызда Тукай иҗатында юмор һәм сатира, аның роленә аерым тукталмасак, бик үк дөрес булмас.

Тукай – юморист һәм, барыннан да бигрәк, көчле сатирик. Тукай шигырьләре арасында җиңелчә юмор белән язылганнары

Уральск чорыннан ук күренә. Менә аның «Татар кызларына» шигыре (1906 ел). Шигырь исеменнән соң аска, җәяләр эченә (сөям дә, сөймим дә, яратам да, яратмыйм да) дип куйган.

Сөям сезнең сызылган кашыңызны,
Тузылган сачеңезне, башыңызны.
Сөям сезнең әдәп-инсафыңызны,
Егет кулы тиюдин сафыңызны.

Калфаклы татар кызларын хур кызларыннан да өстенрәк күрә шагыйрь.

Ишан хәзрәт билет бирсә бәңә гәр,
Аның ла җәннәткә керсәм бәрабәр.
Бәнем каршымда хур калфак кимәзсә,
Бәңа: – Җаным, исәнме? – димәсә, –
Диям: – Әстәгъфирулла, анда кермим!

Татар кызларының күркәм сыйфатларын санаганнан соң, үзе яратмаган якларын да әйтә. Шуларның берсе – наданлык. Алдарга оста остабикәләрне дә яратмыйм, ди. Алар, гыйлем бирәсе урында, сезне бозаулар, сарык бәрәннәре торган бүлмәдә укытып маташкан булалар, балаларын караталар, идәннәрен юдыралар. Сез җиһанда бер сатлык товар, хокуксыз. Болай хокуксыз булырга сез хайваннар түгел, хокукка хаклысыз, хәтта бик хаклы, ди. Юмор белән башланса да, шигырьнең ахры әрнү белән тәмамлана. Гомумән, Тукай шигырьләрендә юмор белән сатира җитәкләшеп йөри кебек. «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?», «Безне урынсызга яманлыйлар», «Тотса мәскәүләр якаң», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» һ.б. әсәрләре моңа мисал була ала.

«Авыл хатынының бала тибрәткәндәге өмидләре», «Авыл җырлары»ның биш көлтәсе дә, «Кәҗә белән Сарык», «Шүрәле», «Су анасы», «Алтын әтәч» әкиятләре җиңелчә юмор белән сугарылган. Гомумән, Тукайның балалар өчен язылган әсәрләренә юмор хас. Мәхәббәт шигырьләреннән «Утырышу», «Кызык гашыйк», шулай ук «Тешләре ямьсез матурга», «Сөбханалла», «Кәҗә тугрысында», «Өйләнү – түгел сөйләнү», «Егет илә кыз» кебек юмористик әсәрләре үзешчәннәр концертларында, шулай ук конферансьелар репертуарында озак еллар яңгырады.

«Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» (1908) поэмасы басылып чыкканчы, «Әдәбият-сәнгать түгәрәге»нең бер утырышын-

да Тукай бу поэмасын үзе укый. Поэманы беренче мәртәбә шагыйрьнең үз авызыннан ишетүче һәм беренче рецензенты буларак, Ф. Әмирхан: «Тукаевның бу әсәрен һәм «Яшен» журналында көлке шигырьләрен укый торгач, аңа татар галәменең иң оста юмористы диясем килә башлады», – ди.

«Кисекбаш»тан бер өзек.

20. Ни өчен Тукай иҗатында сатира зур урын ала?

Моның берничә сәбәбе бар.

1905 ел давылы шаулап узды. Ул кешенең куәтен, бердәм көрәшнең нәтиҗәсе барлыгын да күрсәтте. Ләкин әлегә кеше азатлык, бәхеткә ирешә алмады. Шулай да революция яшене халыкның дошманнарын ачыграк күрергә ярдәм итте. Аларның берсе – һәр яңалыкка, прогрессның һәр адымына каршы торучы феодализм калдыклары – иске фикерле руханилар, сәүдәгәрләр. Яңа заман фонында аларның яшәешләре, дәгъвалары комедиячел төс алды. Аяк чалып комачауламасыннар өчен, иң элек әнә шуларны көйдереп ташларга кирәк. Моның өчен әдәби коралның иң кулае – сатира. Яңа заман яңа көчле сатирикларны таләп итте. И. Нуруллин әйткәнчә, «үт сыекчасы белән яза торган каләмен» эшкә җигеп, Тукай сатирикларның алгы сафына баса.

Революциядән соң, кара реакция чоры башлана. Бу вакытта Тукай Казанда инде. Әле кичә генә «Хөррият өчен җан фида» дип шаулаган бик күпләр, бүген киргә йөгерәләр, посып калырга аулаграк җир эзлиләр, җылы оя табып, шунда посып калу ягын карыйлар. Күбесе я сәүдәгә ябыша, яисә эш хакы зуррак булган хәвеф-хәтәрсез урын эзли. Әзме-күпме каләм тибрәткәне баерак, хәллерәк газета-журналга сыенырга тырыша, я булмаса күбрәк акча китерә торган нәрсәләр язарга керешә.

Сатучылык итә бездә мөхәррир,
Әдип исеме аңа тагылыр-тагылмас.

Кайберәүләр исә, тук яшәргә мөмкинлек бирә торган итеп өйләнү ягын карыйлар.

Әгәр басса дөнья һәм муеннарда бурыч тулса,
Убырлы карчыгыңны да алырлар, акчасы булса.

Тукай бу хәлләргә аптырый, фикерләрен әнә шулай сатирик куплетлар, шигырьләр белән белдерә. Кемнәр-кемнәр, ә менә

Г. Камал, С. Рәмиев кебекләр дә демократик идеалга хыянәт итеп, берсе «Йолдыз», икенчесе, кибеттә әйбер төреп сатарга гына яраклы (Тукайның үз сүзләре) «Бәянелхак» газетасында секретарь. Якын дуслары Боһан Шәрәф, Кәбир Бәкер, алтынчы Рәмиевләрнең чакыруын кабул итеп, Оренбурга юл тоталар.

Безнең урам аркылы, ага суның салкыны,
Тарта Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны, –

дип аларны чагып ала Тукаебыз.

Тукайның көчле сатирик һәм юморист икәнлеген аның публицистик язмалары тагын бер кат раслый. Менә монда инде, Тукаебызның үзе әйткәндәй, «агызында чукмар кеби теле» булуына тәмам ышанасың. Аеруча, Казанда чыгып килүче «Яшен», «Ялт-йолт» кебек сатирик журналларда басылган фельетоннары, мәкаләләре Тукайның туры сүзле һәм әче телле булуын, принцип һәм идея мәсьәләсендә хәтта дусларының да хәтерен саклап тормаганын күрәсең.

«Яшен» журналы үзенең тууы һәм тиз арада «утлы вулканга» әверелүе белән Тукайга бурычлы. Тукай «Яшен» һәм алга таба аны алыштырган «Ялт-йолт» журналларында бик яратып эшли, аларга үзенеке кебек итеп карый, бик күп хезмәт куя. Татарстан китап нәшрияты тарафыннан 1985 елда чыгарылган биш томлыкның дүртенче томында Тукайның әлеге журналларда һәм «Әльислах»та дөнья күргән иң көчле публицистик язмалары һәм фельетоннары тупланган.

Яз язу, ләкин кызыкма шөһрәткә син;
Бик төренмә иртәгүк ертык булыр чүпрәккә син.
Тапмасам шөһрәт, сизәлмәсләр, димә күңелемдәген,
Зур тәрәзә бар, – дип аңла дөньяга күкрәктә син.

***(Г. Тукай.** «Шөһрәт».)*

21. Тукай – журналист һәм публицист

1905–1907 еллардагы революциядән соң татарлар яши торган барлык төбәкләрдә дә вакытлы матбугат барлыкка килә. Татар телендә беренче гәзит 1905 елның 2 сентябрендә Петербургта чыга. Ул – «Нур» дип атала. Шул ук елның 29 октябрендә Казан шәһәрендә «Казан мөхбире» («Казан хәбәрләре»), октябрь азагында Җаекта «Фикер» газетасы дөньяга чыга. Нәкъ бер ай-

дан Казан шәкертләре яшерен рәвештә «Әльислах» (реформа) гәзитен чыгара башлыйлар, ә 1907 елның сентябреннән аңа да рәсми төстә чыгу өчен рөхсәт бирелә. Казанда бер-бер артлы «Йолдыз», «Азат», «Азат халык» «Таң йолдызы» газеталары аваз сала. Оренбург, Җаек, Әстерхан кебек шәһәрләрдә яшәүче татарлар да газета-журналлар чыгаруда калышмый. Гомумән, якынча исәп белән генә дә 1917 елгы революциягә кадәр татарлар яшәгән төбәкләрдә 300дән артык төрдә газета-журнал чыккан.

1905–1907 елгы революция Тукайны да ирекле матбугат, ирекле фикер дөньясына алып керә. Әлеге елларда иҗат иткән күпчелек әсәрләрендә каләм, фикер, матбугат азатлыгына дан җырлый. Бу азатлык – милли культура һәм иҗат чәчәк ату өчен иң кирәкле, беренче шарт дип ышана.

«Революция башында ук Уральскида Камил Мотыйгый оештырган татар вакытлы матбугатын Тукай катнашлыгыннан башка күз алдына китереп булмас иде», – ди әдәбият галиме Гали Халит. «Уралец» типографиясен сатып алганнан соң, К. Мотыйгый шунда «Фикер», «Әлгасрел җәдит» (гасыр яңалыгы), «Уклар» дигән газета-журналлар чыгара башлый. Тукай бу органнарның – наборщигы, фальсовщигы, корректоры гына түгел, ә төп авторларының берсе һәм, хәтта, редакторы да. Бигрәк тә татарча беренче юмористик журнал булган «Уклар»ны тулысынча әзерли һәм редакцияләп килә. Шул журнал үрнәгендә ирекле матбугатның нинди булырга тиешлеген күрсәтергә тели. Шагыйрьне 1905 елгы революция идеяләренә ышанычта булган ирекле матбугат язмышы борчый. Шуңа күрә, социаллар юлын тоткан «Әльислах» газетасында җиң сызганып эшкә тотына. Ләкин газетаның кереме такы-токы.

68 номер чыккач, цензура кысу һәм акча кытлыгы сәбәпле, 1908 елның җәенә «Әльислах» яшәүдән туктый. Шуннан соң, күп тә үтми, Г. Тукай, Г. Камал белән берлектә, «Яшен» исемендәге көлке журналы чыгара башлый. «Тукай «Яшен»не бөтенләй үзенеке итеп карый, аңа байтак хезмәт куя иде», – ди Галимҗан Шәрәф истәлегендә. Тик унынчы санныннан соң, «Яшен» дә мәйданнан китә. Әмма Тукай һәм аның белән фикердәш яшьләр реакция алдында чигенергә теләмиләр. 1910 елның мартыннан «Яшен»нең дәвамы – «Ялт-йолт» журналы чыга башлый.

«Ялт-йолт» та, «Яшен» кебек үк, Тукай җитәкчелегендә чыккан һәм аның рухы белән сугарылган. Кыю фикерле бердәнбер татарча көлке журналы булып таныла «Ялт-йолт». Г. Тукай шулай ук 1912 елның көзендә чыга башлаган «Кояш» газетасында (фактик редакторы Ф. Әмирхан.), шул ук елда мәйданга килгән «Аң» журналы (редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәни) белән дә хезмәттәшлек итә.

Тукайның публицистик язмалары да, башлыча, югарыда исемнәре аталган газета-журналларда басыла. Шулай ук «Йолдыз», Әстерханда чыгып килгән «Идел» газеталарында да язмалары бирелә. Тукай шулкадәр күп яза ки, шактый язмаларын псевдоним белән бирә. Менә аларның берничәсе: Габдулла Тукаев, Г. Тукай, Г. Т., Шүрәле, Гөмберрт, Милләтче, Мин язмадым, Имзасыз да Яраретдинов, Фәйләсүф, Фәйләсүфләр, Шәп кеше, Мөхәррир мин түгел, Салам торхан, Счет төймәсе һ.б. Кайбер язмаларын бөтенләй имзасыз бастырган. Гомумән, Тукайның 50дән артык псевдоним белән язуы билгеле.

Тукайның публицистик язмалары белән танышканнан соң, нечкә юмор, үтергеч сатирага тап буласың. Аңардагы сүз байлыгы, аңардагы сүз уйнату осталыгы!

Тукай кулы, Тукай каләме уйнаган язмалар арасында ниндиләре генә юк! Әдәби-публицистик язмалар, мәкаләләр һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләр, рецензияләр, фельетоннар, памфлетлар... Аның инициативасы белән булдырылган белдерүгъланнар, сатирик сүзлекләр, мәзәкләр сәхифәләре.

Публицистик язмаларында ул беркемне дә аямый. Кемнәр генә эләкми аның каләм очына. Бер генә яңалык та, кимчелек тә Тукай күзеннән читтә калмый.

Тукай татар әдәбиятында тәнкыйть булырга тиеш, дип саный. 1907 елда бу турыда «Тәнкыйть – кирәкле шәйдер» дигән махсус мәкалә дә яза. Тәнкыйтьчегә зур таләпләр дә куя. Тәнкыйть итүченең кем очрады шул булуы ярамый, ди, «үзләре дә әдәбият галәмендә күп ат уйнаткан тәҗрибәле вә әхлаклы адәм булуы» таләп ителә, ди. Тәнкыйть гадел булырга тиеш, ди. Бөек шагыйребез үзенең замандашлары Г. Исхакый, Г. Камал, М. Гафури, С. Рәмиев, Н. Думави, Г. Ибраһимов иҗатларына карата да үз фикерләрен белдерә. Аларның әсәрләрендә үзен канәгатьләндергән яклар турында кинәнеп язса, кимчелекләрен

Тукайга хас булганча, кылычтан үткен тел белән ярып сала.

Гомумән, булачак каләм әһелләренә һәм бүгенге көндә каләм тибрәтүчеләргә, журналистларга шагыйрь С. Хәким әйткәндәй, «Тукайдан өйрән дә өйрән!»

22. Г. Тукай – мөгаллим

Тукаебыз дөньяда 27 ел гына яшәсә дә, үзеннән соң милләтенә гаять зур мирас калдырган. Үзенә гомернең аз бирелгәнен сизгәндәй, һәр өлкәдә үз сүзен әйтеп калырга ашыккан. Алдагы чыгышларның берсендә, Тукайның С. Рәмиевкә язган хатыннан бер өзек китергән идек: «Мин поэт (шагыйрь) генә түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә». Әйе, Г. Тукай шагыйрь, дипломат, җәмәгать эшлеклесе, журналист һәм публицист, тәнкыйтьче, фольклорчы гына түгел, мөгаллим-педагог та булган. Бүгенге чыгышыбызда, шагыйрьнең педагогик эшчәнлегенә дә бераз тукталып китәрбез.

Тукай тумыштан ук укытучы җанлы кеше була. Заман-дашларының истәлекләреннән күренгәнчә, 1903–1904 елларда Уральскида («Мотыйгыя» мәдрәсәсе) үзе дә дүрт ай балалар укытып ала. Тукай аерым шәкертләргә өйдә урысча өйрәтү дәресләре дә бирә. Шул вакытта мәдрәсәләрдә хакимлек иткән механик ятлау алымнарына каршы чыгып, шәкертләрнең уку материалларын аңлап үзләштерүләренә ирешә, аларның мөстәкыйль эшләрен оештыра.

Г. Тукай шулай ук берничә дәреслек авторы да.

Шагыйрь 1909 елда башлангыч мәктәпләр өчен «Яңа кыйраәт» («Яңа уку китабы») исеме белән дәреслек-хрестоматия төзи. Ә 1910 елда бөтенләй яңа тәртип белән эшләнеп, бик күп яңа фәнни вә әхлакый мәкаләләр вә шигырьләр кертелеп, камилләштерелгән икенче басмасын чыгара. 1913 елда укытучыларның Уфада җыелган киңәшмәсендә ул иң яхшы дәреслекләрнең берсе дип таныла һәм мәктәпләр өчен төп уку китабы итеп кабул ителә. Дәреслек 1918 елга кадәр ел саен бастырыла.

Беренче уңышы белән рухланып, Тукай 1910 елда икенче бер яңа дәреслек бастырып чыгара. Ул «Мәктәптә милли

әдәбият дәресләре» дип атала һәм татар мәдәнияты тарихында әдәбияттан беренче уку китабы була. Тукай яңа дәреслегенә дә сүз башы яза һәм укытучыларга методик киңәшләр бирә.

«Яңа кыйраәт» дәреслегенә кергән язмалар балалар аңларлык телдә язылган. Автор язмаларында белемгә омтылыш, кызыксыну тәрбияли, әдәп-әхлак мәсьәләләрен алгы планга куя.

«Баланың ата-анасын сөюе» хикәясендә баланың ата-анасына ихтирамы, кечкенәдән үк кайгыртучан булып үсүе кебек сыйфатлары сурәтләнә.

«Шәмсетдин исемле ун яшьлек малай бер байга көтүчелеккә яллана. Бай аны айга алты сум бәһа куеп эшкә ала. Ләкин бала байдан айлык хезмәт хакын атна саен бүлеп бирүен үтенә. Атасы авырып урын өстендә ята икән. «Шул сәбәпле һәр атна саен аңар ризыкланыр өчен акча алып кайтып бирәсем килә», – ди бала.

Бай кешегә бала Шәмсетдиннең атасына бу кадәр саф мәхәббәт кылуы бик ошый, акчасын атна саен биреп баруы өстенә, ул аның айлык хезмәт хакын да арттыра».

Дәреслектә табигать белеменә караган язмалар да урын алган. «Кояш», «Һава», «Су», «Җир» язмаларында гади һәм аңлаешлы итеп табигать күренешләренә аңлатма бирелә. «Елның дүрт фасылы» язмасында яз, җәй, көз, кышка үзенчәлекле тасвирламалар бирә.

Уральск шәһәрендәге «Мотыйгия» мәдрәсәсендә бергә укыган иптәше Гайнетдин Туприевка 1909 елда Казаннан Уральскига язган хатында мондый юллар бар: «Безнең яшь гомремезне бушка әрәм иткәне өчен мәдрәсәсенә, бөтен шундагы схоластикасына ләгънәт укыйм. Уйлап торам да: «Ну укытканнар икән безне!» – дип куям.

Имеш, без дә курс бетереп, студент булып чыкканбыз. Имеш, безне дә мәгыйшәт (тормыш, яшәеш дигән сүз) белән көрәшергә коралландырып чыгарганнар!» *(Г. Тукай. «Әсәрләр», 1986, 5 том, 92 нче бит).* Тукаебыз схоластикага корылган мәдрәсәләрне, андагы укытуны тәнкыйтьли. Яңача укыта, белем бирә торган мәктәпләр кирәклеген әйтә.

«Мәктәп» шигыре.

Мәкаль бардыр: «Урыс байса, авылында саладыр дәү чиркәү;
Татар байса, хатын асрый, була хатыны өчәү-дүртәү.
Гүзәл тәфсир кыйлынса, бу мәкальдән ушбудыр матлап (теләк):
«Урыс байса, сала чиркәү, вә ләкин әүвәле мәктәп», –
дип, татар байларына укларын кадап ала.

Җыеп кына әйткәндә, Тукаебызның милләтебезне белемле, зыялы, алдынгы итеп күрәсе килгән. Заман таләпләренә туры килә торган мәктәпләр, алдынгы карашлы белемле укытучылар, яхшы дәреслекләр һәм алдынгы методика белән генә боларга ирешеп булачагына басым ясаган.

23. Г. Тукай һәм Дәрдемәнд

Татар әдәбиятында Дәрдемәнд псевдонимы белән ижат иткән шагыйрь булган. Ул – Закир Рәмиев. «Үзенең искиткеч нечкә тойгылы, тирән мәгънәле шигырьләре белән танылган шагыйрь Дәрдемәнд Урал тауларында алтын казытучы бер промышленник, яхшы ук бай бер капиталист иде», – дигән язучы Фатих Кәрими. Агалы-энеле Шакир һәм Закир Рәмиевләрнең 20дән артык алтын приискалары булган. Анда яхшы йортлар салдырганнар, яхшы атлар җиккәннәр, байлыкта яшәгәннәр. Ф. Кәрими болай дип дәвам итә: «Ләкин алтынчы бай З. Рәмиев китап сөюче, күп укучы, белемнән тәм табучы, нечкә тойгылы, моңсу шигырьләр сөйләүче «Дәрдемәнд» булып калган. Ул башта ук үзенә Дәрдемәнд (кайгылы, моңлы, хәсрәт чигүче мәгънәсендә) дигән исем сайлап ала. Ахырга кадәр шул имза, шул исем белән яза».

Дәрдемәнд – үзенә аерым бер шәхес һәм талант. Бер үк вакытта зур байлык иясе һәм чып-чын шагыйрь. Ике тәлинкәле үлчәүне күз алдына китерик. «Бер тәлинкәсендә – Дәрдемәнд шигырьләре, икенче тәлинкәсендә – Дәрдемәнд-Закир Рәмиевнең алтыннары... Кайсы баса? Шигырьләре баса», – дип язган иде шагыйрь С. Хәким.

«Бездә, бер үк вакытта миллионнарча сум байлыкка һәм югары дәрәҗәдә шигъри талантка ия булган бүтән каләм әһеле юк», – ди әдәбият галиме Ф. Галимуллин. Бертуган Рәмиевләр матди байлыкларының шактый өлешен милләтебезне аң-белемле, мәдәниятле итүгә тоталар. Шушы ике туган берләшеп, 1902

елда ук Эчке Русиядә татар телендә гәзит чыгарырга ниятлиләр. Ләкин ул вакытта патша хөкүмәте моңа рөхсәт бирми. Алар максатларына 1906 елда гына ирешәләр. Шул елны Оренбургта «Вакыт» исемендә газета (редакторы исеме алда телгә алынган язучы Ф. Кәрими) һәм 1908 ел башыннан «Шура» журналы чыгара башлыйлар. Редакторы – Ризаэтдин Фәхретдин.

Рәмиевләр газета һәм журналны сыйфатлы итеп чыгаруга акчаны кызганмаганнар. Журналистларга, эшчеләргә акчаны яхшы түләгәннәр. Мәсәлән, «Шура» журналының редакторы булган Риза Фәхретдиннең, «Вакыт»ның редакторы Ф. Кәриминең айлык жалованьесы 130 сум булган. Моны күпләр министр жалованьесы дип йөртәләр. Ә Мәскәү, Петербург шәһәрләрендә чыга торган популяр рус газеталары редакторлары аена 70–80 сумнан артык жалованье алмыйлар. Үзләре белән язышучы авторларга да гонорарны яхшы түләгәннәр. «**Язучы, шагыйрьнең тормышы тәэмин ителми икән, аның иҗаты да тәэмин ителми», –** дия торган булган Дәрдемәнд.

Дәрдемәнд сирәк-сирәк кенә үзенең шигырьләрен «Шура» журналында, кайчакта «Вакыт» газетасында бастыра. Шул шигырьләре белән татар әдәбияты дөньясында таныла.

Дәрдемәнд белән Тукай – ике зур шагыйрь – бер-берсен күреп белмәгәннәр, очрашып сөйләшүләре турында хәбәрләр юк. Әмма бер-берсенең иҗаты белән газета-журналлар аша таныш булганнар.

1908 елны Тукайга Оренбургтан тәкъдим була. «Әле Оренбурдан да мине чакырып хат килде. «Вакыт» гәзитендә, «Шура «журналында эшләргә. 40 тәңкә айга жалуние бирәләр. Ләкин мин хәзергә анда бара алмыйм. Оренбур язучылары илә газета аркылы бераз чәкәләшеп алган идек». *(Апасы Газизәгә язган хатыннан, 27 март, 1908 ел).* Әйе, мондый чәкәләшү була. «Әлгасрелҗәдит»нең бер санында, Тукай әле Казанга килгәнче, «Гъ.Т.» имзасы белән «Мөтәшагыйрьгә» (ягъни шигырь язып маташучы) дигән шигырь басыла.

Тегермән әйләнә; әйләнсә дә тартылмыйдыр ярма;
Мәшәкатьләнмә бушка көчләнеп, юл уртасын ярма.
Һөнәрләр күп җиһанда, син дә моннан башка сәнгать тап;
Чабатаң берлә, нинди мәнфәгать бар соң, әдәп таптап?

Тырышма нафилә җиргә (**вакты)** гаҗизеңне икъраргa:
(тырышма бушка, кирәксезгә көчсезлегеңне, аптыравыңны
үзең үк икрар итәргә).
Сиңа соң сандугачча сайрамак мөмкинме, и карга!
Шагыйрь булып маташма, зинһар, кермә шагыйрь
битлегенә син,
Кисәрләр койрыгыңны, кермә былбыл читлегенә син.

Шигырьдә **вакыт** сүзе бар һәм ул сүз җәяләр эченә алынган була. «Вакыт» газетасы нәширләреннән берсе булган Дәрдемәнд бу шигырьне үзенә каршы язылган дип уйлый һәм «Вакыт»ка кушымта рәвешендә чыгарылган «Әдәбият капчыгы» исемле җыентыкта «Шагыйрьгә» шигырен бастыра. Дәрдемәнд искиткеч зыялы, белемле, сабыр, тактлы һәм акыллы кеше буларак, Тукайның ижатына зур бәя бирә. Аны **шагыйрь, яңа былбыл** дип атый. Вак-төяк такмаклар язып, ала каргалар рәтенә төшүдән кисәтә, талантына бәрабәр темаларга мөрәҗәгать итәргә киңәш бирә.

Ф. Кәрими фикеренчә, Дәрдемәнд һөҗү (сатира) итәргә, нидән дә булса көләргә яратмый. Һөҗүви шигырь язуны ул бер мутлык, гөнаһ эшләү дип карый. Моны әллә кайда бер сирәк кенә эшләп куйса да, соңыннан аның вөжданы газаплана. Хәтта, соңга да калмый, шигырьнең ахырында ук үзенең күңеле яхшылык теләгәнен аңлатып куя. Мәсәлән, Тукайга җавап итеп язган һөҗүенең ахырында ул:

Матур гөлләргә бул былбыл,
Нәзакәт багына сакчы, –

дип, аның шулай булырга теләвен белдерә.

«Шагыйрьгә» шигыренә каршы Тукай «Йолдыз» газетасында җавап сүзе белән чыга. «Аңлашу» дигән язмасында (1907, 12 июль) үзен хаксызга гаепләүләренә каршы килә. «Бәнем Мөтәшагыйрьгә» шигырен язуым асла «Вакыт» гәзитәсенә юнәлтеп түгелдер. Шул шигырьне язганда, «Вакыт» гәзитәсе минем хәтеремә дә килгәне юктыр. Миңа «Вакыт» гәзитәсен кимсетергә бер дә юл юктыр. Чөнки «Вакыт» гәзитәсе әшгарь мәҗмугасы (шигырь җыентыгы) түгел. «Үзенең кайбер газета-журналларда, аерым алганда «Борһане тәрәккый»дә чыгучы (Әстерханда 1906–1910 елларда чыккан татар газетасы) чилепешле шигырьләргә эче пошуын, бу шигырьнең шундый эч

пошулар сәбәпле ихтыярсыз язылган булуын әйтә. «Вакыт» гәзитәсе үз сүзен кире алсын!

Ни өчен Тукай «Вакыт» һәм «Шура»ның чакыруын кабул итмәгән, алар белән язышырга теләмәгән соң? Төп сәбәп – чәкәләшеп алу гынамы? И. Нуруллин болай ди: «Тукайны Оренбургка китүдән, башлыча, «Вакыт» белән «Шура»ның политик юнәлеше тыеп калган». Чөнки бу басмалар – либераль буржуазиянең төп органы. Тукай Уральскида чакта ук революцион-демократик байрак астына баскан иде».

«Монда «Әльислах» ходка китсә, көлке журналы да чыкса, үземнең кальбән сөйгән гәзитә вә идеямә хезмәт итәр идем», – ди Тукай Ф. Әмирханга язган бер хатында.

Реакция башлангач, «Урал», «Азат халык», «Таң йолдызы», «Тавыш», «Фикер» кебек революцион-демократик юнәлештәге газеталар бер-бер артлы ябыла башлый. Болар кулыннан төшкән революцион-демократик байракны күтәреп алган бердәнбер газета булып «Әльислах» кала. Шуңа күрә Тукай төп эш урыны итеп «Әльислах»ны сайлый. Үз идеяләренә, тоткан юлына тугрылык саклап, финанс ягыннан үтә фәкыйрь, жандарм идарәсе һәм цензура җентекләп күзәткән, җитмәсә, милләтнең үз эчендә реакцион көчләр төрлечә һөҗүм итеп торган газетада эшләүне хуп күрә шагыйрь. Менә бусы инде Тукайча!

Заман агышы ниләр бирсә дә ал син,
Җамың тот, шаһ кебек тәхетеңдә кал син.
Азат та, кол да бертигез Ходайга,
Яшәү җамын эчеп түнтәр дә сал син.

(Гомәр Хәйям)

23. Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан

Ялгыз булганмы Тукай? Юк, бәхеткә...
Казанда таянган Фатих, Сәгыйткә...
Гаязга дәшкән: «Кайтчы!» – дип. Сыйган бит
Берьюлы ничә арыслан тәхеткә!

Рәдиф Гаташ

«Тукай турында истәлекләр» дигән язмасында шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй болай ди: «Тукай бер кешене дә дус дип атамады. Иптәш дисә гаҗәп түгел. Күп кеше белән тыныша алмаган Тукай белән без иптәш идек (миңа биргән китапларында «иптәшем Сәгыйткә» дип яза иде)». С. Сүнчәләй шулай дисә дә, Тукаебыз Г. Кариев, С. Рәмиев, Кәбир Бәкер, Г. Камаллар белән якыннан аралашкан, аңар татар большевигы Х. Ямашевның идея йогынтысы көчле булган. Артык аралашу булмаса да, Тукай аны бик хөрмәт иткән. Ләкин барыннан да бигрәк Тукай өчен иң зур таяныч, тугрылык саклаучы, баш хәрефтән язылырлык ДУС дип әйтерлек кеше Фатих Әмирхан булган. Олуг мөхәррир, бөек язучы, классик әдип буларак татар әдәбиятында зур урын биләгән шәхес буларак та билгеле ул.

Ф. Әмирхан Тукай белән бер үк елда, ягъни 1886 елның 13 гыйнварында туган. Туган җире Казанның Яңа бистә дигән урыны, мулла гаиләсе. Балачагы Яңа бистәдә узган, Казанның атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый, шул ук вакытта рус классына йөреп, аны 1901 елда уңышлы тәмамлый. Тумыштан зирәк. «Мөхәммәдия»дә иң яхшы укучыларның берсе. Ярым-яшерен башкарыла торган эшләрнең, мәсәлән, кулъязма газета яисә журнал чыгару, әдәби кичәләр үткәрү, спектакльләр куюның үзәгендә. Әтисе Зариф хәзрәт – билгеле һәм дәрәҗәле кеше, Казанның атаклы муллаларыннан берсе. Ул Казанның могтәбәр байларыннан, дус-иш муллаларыннан, бигрәк тә «Мөхәммәдия» мөдире Галимҗан Барудидан сүз ишетеп тора: тый улыңны, хәзрәт, урыс булып бетте. Фетнәче, шәкертләрне аздыра. Патшага каршы бара торган студентлар шайкасына кергән һ.б. һ.б.

1905–1906 уку елында, мәдрәсә тәртипләренә протест йөзеннән, 100гә якын шәкерт «Мөхәммәдия»не ташлап чыга.

Алар арасында Фатих та бар. Олы улының ата-бабалары эшен дәвам иттерүен, ягъни дин юлыннан китүен теләгән ата, алга таба улының социалистлар мәсләген алга сөрүчеләр сафына кушылуын өнәми. Ата белән бала арасында зур конфликт барлыкка килә. Ахыр чиктә, ата, кызып китеп, улына ишек күрсәткән. Ул исә ишекне шапылдатып ябып чыгып киткән. Мөстәкыйль яши башлаган егеткә башта җиңел булмый. Әмма Фатих төшенкелеккә дә бирелми. Рус телен өйрәнүен дәвам итә. Әтисе Зариф хәзрәт улына бер тиен дә акча бирми. Фатих исә биш-алты баланы русча укытып алган акчасын репетиторга түли. Бераздан Фатихны Мәскәүгә «Тәрбиятель әтфаль» журналына секретарь итеп чакыралар. Шулай итеп ул Мәскәүгә китә.

Тукайдан аермалы буларак, Әмирхан югары даирәләрдән качмаган. «Москвадагы татар вә рус аристократларыннан, хәтта бюрократларыннан әллә ничаклы гаилә белән таныштым», – ди ул. Төс-кыяфәт, буй-сын бар, кыюлык һәм тапкырлык та җитәрлек. Зәвык белән киенә. Гардеробын еш алыштырып тора. Сүзгә дә оста. Йөремсәк, бик аралашучан.

1907 елның җәен ул Казанда үткәрә. Әтисе белән ике арадагы киртә дә әнисе Рабига абыстай тырышлыгы белән әкренләп юкка чыга. Яшьләр арасында элек тә игътибар үзәгендә булган Фатих бу җәйдә дә билгеле бер даирәнең төше, җаны була. Иптәшләре белән дачаларда, табигать кочагында ял итә, күңел ача.

Тукайдан аермалы буларак тагын бер сыйфаты – хатын-кызлар белән флиртовать итәргә ярата. Ул һәрвакыт матур кызлар чолганышында. Ләкин күңелле минутлар артында фаҗига посып торган икән. 1907 елның 15 августында трамвай юлын аркылы чыкканда, Фатихны паралич суга: аяк куллары йөрмәс, бер күзе күрмәс була.

Казанның татар төбәге шау-гөр килә. Аеруча Печән базары әһелләре тантана итә. «Зариф мулланың урыска сатылган чукынчыгын каһәр сукты!» «Кызыл авызга остаз бәддогасы төште!» – ди алар.

Дәваланулар нәтиҗәсез калмый... Куллар хәрәкәткә килә, күзе элекке хәленә кайта. Әмма аяклар йөрми. 21 яшьлек егет гомерлеккә гарип кала, гомер азагына кадәр коляска белән генә хәрәкәт итә.

Тиктормас, һәрвакыт игътибар үзәгендә булган, аралашучан шат күңелле Фатихка кояш сүнгән кебек тоела берара. Ләкин егет бу хәлдән чыгу юлын таба. Элек тә якыннары һәм дуслары арасында «теленә шайтан төкергән» дип бәяләнгән Фатих кулына каләм алып яза башлый. Җиң сызганып, «Әльислах» газетасы белән җитәкчелек итә. Һәр санның баш мәкаләсен яза, сан саен бер-ике фельетон, рецензия, сан аралаш диярлек хикәя... Җитмәсә, газетаның финанс ягын кайгырту да аның өстендә.

Тукаебыз Казанга килеп төшкән 1907 елның көзендә Фатих Әмирханның хәлләре менә шулайрак була. Ф. Әмирхан Тукай белән октябрьнең беренче атнасында Яңа бистәдәге үз өйләрендә танышкан. Әмирхан белән Тукай арасында дуслык чагыштырмача тиз урнаша һәм ул соң чиккәчә дәвам итә. Тукай Әмирханга ышана, аның сер сыйрдай кеше икәненә инана. Казанга килгәч, беренче күңел капчыгын да ул Әмирханга бушата. Үтә күзәтүчән зирәк Фатих Тукайда сирәк очрый торган зур талант күрә. Татар мәдәнияте һәм шигъриятендә тоткан урынын бүтән һәркемгә караганда да дөресрәк аңлый, тирәнрәк күрә.

«Әльислах»та бергә кайныйлар. Ф. Әмирхан Тукайны күтәреп ала, язганнарын тоткарлыксыз үткәрә, һәр китабына югары бәя биреп, рецензия яза. «Менә шул газета тирәсендә без Тукай белән тәмам танышып җиттек вә бик тиз арада бер-беребезгә шәхси ихтирам саклаша башладык», – ди Ф. Әмирхан.

Тормыш булгач төрле хәлләр була. Бу ике зур шәхес еш кына бәхәсләшәләр, кызып та китәләр. Үпкәләшүләр дә булып тора (күбрәк Тукай үпкәләгән), ара-тирә – кычкырышканнар да. Икесе дә көләргә оста. Берсенең тел энәсе гаять нечкә һәм нәфис, ә икенчесенеке юанрак һәм тупасрак. Ләкин Фатихның үпкә саклый торган гадәте юк. Ул Тукайның кырыс холкын аңлый. Беренче булып аңа кул суза.

Ф. Әмирхан Тукайның яклаучысы да, саклаучысы да була. Ул аңа рухи ярдәм, кирәк булганда матди ярдәм дә күрсәтә. Юкка гына, Әмирханны Тукайның Фурмановы (Д. Фурманов – В. И. Чапаевның комиссары) димәгәннәр.

Ф. Әмирхан негатив (тискәре) күренешләргә битараф булмаган. Шуларның берсе – татарның алдынгы карашлы дип

исәпләнгән яшьләре арасында эчкечелеккә каршы көрәш юлына басуы. 1905 елгы революциядән соң татарларда да алмашыну, европалашу процессы башлана. Яшьләр борынгылардан килгән гореф-гадәтләрне нәфрәтләнеп кире кагалар, Рус-Европа мәдәнияте казанышларыннан файдалана башлыйлар, хәтта аларны үзләренә үрнәк итеп куялар, тышкы яктан мәдәниләшүгә күбрәк игътибар бирәләр. Модалы кием-салым, озын итеп чәч үстерү... Атаклы рус язучысы Ф. Достоевскийның «красота спасет мир» гыйбарәсен үзләренә шигарь итеп алалар. Ә бит Достоевский «духовная красота» дигән, ягъни рухи матурлык, рухи байлык. Ә рухи яктан мәдәниләшү исә мәшәкатьле, күп вакыт, көч сорый. Эчке культурага ирешергә өлгермәгән бер төркем яшьләр, картларга үч итеп, артыграк «европалашып» китәләр: үзләрен кирәгеннән артык хөр тота башлыйлар, эчемлек белән дуслашалар. «Әльислах» яшьләре тирәсендә дә шундый бер круг оешып ала. Берничә байбәтчәдән тыш, бу кругка Солтан Рахманколый, Вәли Апанаев, Ибраһим Кулиев, Фәхрелислам Агиевлар керә. Алда әйтелгәнчә, бу компания Тукайны да үз эченә ала. Хәтта Тукай номеры кәеф-сафа кору урынына әйләнә.

Ф. Әмирхан исә гомере буе исерткечкә дошман була. Үзе эчмәү генә түгел, татар яшьләре арасында эчүчелекнең җәелә баруына каршы кулыннан килгәнчә көрәш тә алып бара. Сәләтле яшьләрнең, эш эшлисе вакытларын бушка уздырып, саулыкларына зарар китерүләре, Тукай кебек зур талантның алар арасына эләгеп харап булу куркынычы турында уйлау, энесе Ибраһимның да, Тукай әйтмешли, «чиле-пешле» кешеләр кругына кереп китүе эчкечелеккә каршы көрәшкә этәргәндер. Тукайны, энесе Ибраһимны ул бу төркемнән араларга тырышкан. «Әльислах»та басылган «Яшьләр колагына бер ләүхә (сүз)» мәкаләсендә: «...яшьләр – милләтнең, халыкның киләчәге. Шуңа күрә алар һәр җәһәттән, аерым алганда, әхлак ягыннан үрнәк булырга тиеш», – ди

«Әмма ни генә булса да, бу ике бөек шәхес бер үк идеал белән яшәгәннәр, шул идеал хакына кулга-кул тотынып барганнар, бер-берсенә хөрмәт саклаганнар. Олы дуслык булган ул. Бу дуслык Тукай өчен, аның иҗаты өчен рәхмәт яңгыры һәм кояш җылысы булган кебек, Әмирханга да аз файда китермәгәндер». (И.Н.)

1912 ел азагы һәм 1913 ел башларында Ф. Әмирхан һәм Тукай «Амур» номерларында күрше бүлмәләрдә яшиләр. Тукайның сәламәтлеге көннән-көн киребә тәгәри. Бик еш һәм озак ютәлли. Бер стена белән генә аерылып торган Әмирхан бүлмәсенә Тукайның һәр хәрәкәте, хәтта сулыш алуы да ишетелеп тора кебек. Газаплы авыру кочагында калып, үлем көтеп яткан Тукайны әрнүле бер кызгану белән кызгана ул. Дустының санаулы көннәр кичергәнен йөрәге һәм күңеле белән кабул итә алмый газаплана. «Мә, Тукай, ал минем таза үпкәләремнең берсен. Берәр үпкә белән дә дөньяда торырбыз әле», – дип кычкырасы килгән шикелле булды, ди истәлекләрендә. Иртәгә больницага китәсе дигән көннең кичендә (25 февраль) Тукай Фатих бүлмәсенә керә.

– Мин иртәгә Клячкинга керәм. Мин киткәндә син тормаган булырсың. Моннан соң күрешмәсәк... хуш инде.

Фатих Әмирхан, докторлардан ишетеп, шагыйрьнең ай, ай ярым гомере калганын яхшы белсә дә, гадәт буенча әйтелә торган сүзләр белән болай ди: «Тиз терелеп чык, тиз күрешик. Тукай ишеккә таба китә башлап, кинәт борыла да: «Юк, тиз күрешмик әле, син озаграк яшә!» – ди дә тиз генә чыгып китә.

1913 нче елның 2 апрелендә шагыйрьнең гомере өзелә. 4 апрельдә бөтен Казан халкы Тукайны соңгы юлга озата. Истәлекләрдән күренгәнчә, Ф. Әмирхан җеназаны капка төбеннән генә үкси-үкси озатып калган. Тукайдан соң калып ул 13 ел яши. Тукай кебек гомере буе ялгыз яшәп, өйләнмәгән килеш, 40 яшендә үпкә авыруыннан вафат була.

Чыгышымны әдәбиятчы-галим *И. Нуруллинның «Фатих Әмирхан» китабыннан (1988)* өзек белән тәмамлыйм.

«Һәр елны без 26 апрельдә шигырь бәйрәме үткәреп, Тукай каберен чәчәкләргә күмәбез. Ник шунда берочтан Фатих Әмирхан каберен дә бизәп китмәскә? Бу ике бөек шәхес аерылгысыз ич: «Тукай дидеңме – Әмирхан күңелгә килә, Әмирхан дидеңме, Тукай искә төшә. Чәчәкләр китерегез аңа, кешеләр! Үзенә һәм ижатына булган мәхәббәтнең билгесе булсын ул чәчәкләр. Халкыбызның күңеле киң, йөрәге олы. Китерегез аңа чәчәкләр! Фатих Әмирхан шунда лаеклы урын алсын».

24. Г. Тукай һәм Галимҗан Ибраһимов

Үз чорында ук Г. Тукай иҗатына битараф булмаганнар. Һәр әсәре, һәр китабы җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп иткән, аларны укыганнар. Язганнары белән килешкәннәр яки бәхәсләшкәннәр, аңар ачуланганнар, аның белән ызгышканнар. Менә бер тәнкыйтьче Тукайның һәр китабына дип әйтерлек, мактаудан битәр, тәнкыйтьләү өстенлек алган рецензияләр яза башлый. Бер күзәтү мәкаләсендә, Тукайның 1911 елгы иҗатын күздә тотып, шагыйрьне сүнгән шәмгә охшата. Тукай үлеп бер ай үткәч басылып чыккан китабында «Тукай шагыйрьме, түгелме?» дигән мәсьәлә күтәрә һәм бу сорауга кистереп җавап бирмәсә дә, Тукайны чын шагыйрь итеп танымавын сиздерә. Бу кеше – язучы Галимҗан Ибраһимов. «Татар шагыйрьләре» исемле күләмле язмасында (1913) Тукайны хәтта шагыйрь итеп таныйсы килмәвен әйтә. Тукай үлеменнән соң ук (бу вакытта язучы Киевтә) «Талант трагедиясе» дигән күләмле генә язмасында да Тукайга карата шактый тискәре фикерләр әйтә.

Г. Ибраһимовның Тукай хакындагы «Актык сәлам» исемле мәкаләсеннән күренгәнчә, 1910 елның ахырларына кадәр алар ярыйсы гына дус яшәгәннәр. Тукай аңа өмет белән караган, язучы да шагыйрьне ихтирам иткән. Менә бервакыт Г. Ибраһимов Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» китабына рецензия яза һәм «Йолдыз» газетасына илтә. Газета редакторы Һади Максуди шагыйрьнең ачулану ихтималын әйтеп кисәтү ясаса да, Г. Ибраһимов рецензияне бастыруны сорый. Мәкалә басыла. Шул көнне Г. Ибраһимов Тукай номерына барган. Тукай янында берничә каләм әһеле була. Рецензия турында да сүз була. Бәхәсләшеп алалар. Тукай дәшми генә тыңлап торганнан соң, «син»нән «сез»гә күчеп: «Сез бик инсафлы язгансыз. Сезнең ул фельетоныгыз (рецензиягез дими) – минем хакта первый отрицательный мәкалә», – ди. Алга таба Тукайның «Мияубикә» поэмасы басылуга ук, Г. Ибраһимов тагын тәнкыйть мәкаләсе белән чыга. Тукай белән аралар тәмам бозыла. Хис-тойгыларга бай булган, үзе дә романтик табигатьле 23 яшьлек Галимҗан Ибраһимов бу елларда күбрәк поэзия турында яза. Үзенең язмаларында, бер-ике чыгарылма белән татар поэзиясен бөтенләй диярлек бетереп ташлый. Баштагы язмаларда чыгарылма эчен-

дә Тукай бар әле. Ләкин яшь тәнкыйтьче алга таба күрә: матбугатта күбрәк Тукайга игътибар бирәләр. Ә кайда С. Рәмиев, кайда Дәрдемәнд? Кайда гаделлек? Бу хатаны кичекмәстән төзәтергә кирәк! Халыкка шигырьнең, поэзиянең нәрсә икәнен аңлатырга кирәк! Шулай итеп, Г. Ибраһимов агымга каршы ташлана һәм «Тукайны мактау хорын бераз сүрелдерергә карар итә» (И.Н.) В.Г. Белинский поэзияне икегә – идеаль поэзия һәм реаль поэзиягә бүлеп караган. Идеаль поэзия төшенчәсе эчендә романтизм беренче урынны тота. Русның атаклы тәнкыйтьчесе хезмәтләре белән таныш Г. Ибраһимов та (ул аны үзенең остазы итеп саный) татар әдәбиятын шулай ук икегә бүлеп ташлый. Лириканы бөтенләе белән идеаль поэзиягә, ә эпик әсәрләрне реаль поэзиягә калдыра. Аның поэзия дигәне – нәкъ менә романтизм лирикасы.

«Татар шагыйрьләре» дигән күләмле язмасында ул өч шагыйрь иҗатына туктала: С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Г. Тукай. Саф романтик С. Рәмиев, Дәрдемәндләргә ул бик югары бәя бирә, ә Тукайга аеруча зур таләпчәнлек күрсәтә. «Кем ул шагыйрь? – дигән сорауга, – ул – хиссият колы булырга тиеш», ди. Тукайның бары тик «хиссият колы» гына булмавы, аның мәхәббәт лирикасына азрак урын бирүен ошатмый. «Бу дөньяда шагыйрьнең игътибарын җәлеп итәрлек ике генә нәрсә бар: берсе – мәхәббәт, икенчесе – табигать. Һәр шагыйрь ямь вә матурлык каршында тез чүгеп, табигатьнең җамалын (матурлык) сайрый, һәр шагыйрьнең Зөләйхасы була, ул аңа табына, күбесе исә буны хәят чишмәсе итеп тота, шигырьләренә илһамны шуннан ала», – ди. Г. Ибраһимов хәтта **халык мәнфәгатьләре турында язуны** шагыйрьлеккә кимчелек китерә торган як дип карый.

Шулай итеп, Г. Ибраһимовның Тукайны хәтта шагыйрь итеп таныйсы да килми. «Әйе, баштагы иҗатында романтизмнан азат булмаса да, тулаем алганда, Тукай реалист иде. Иҗатының соңгы чорында аның реализмы, романтизмның уңай сыйфатларын үзенә сеңдереп, яңа баскычка күтәрелде», – ди әдәбият галиме И. Нуруллин.

Г. Ибраһимов бәясенә Тукайның замандашлары битараф калмый. Мәсәлән, Фәтхи Бурнаш, бу фикерләргә каршы чыга, Г. Тукайны шагыйрь буларак югары бәяли. Җамал Вәлиди «Та-

тар шагыйрьләре»нә язган рецензиясендә Тукайны яклап чыга. «Тукаев шигырьне Аполлон вә аның җирдәге табынучылары өчен сөйләми иде. Ул халык илә бергә, халык өчен, халык йөрәгеннән сөйли иде», – ди. Ләкин Г. Ибраһимов алга таба да, байтак еллардан соң да, үз фикерләреннән ваз кичми: «...моннан ун-унике ел элек ничек булса, әле дә шул көенчә калды», – дип бөек шагыйрьгә карата тискәре мөнәсәбәттә калуын белдерә.

Шагыйрь С. Хәким болай ди: «Галимҗан ашыккан, артык ашыккан... Икесе дә зур шәхес. Араларына кермим. Тукай да, Галимҗан да усал. Тукай җавапсыз кала торган кеше түгел. Шәхси яратып бетерәүләр язганнарыннан күренеп тора... Галимҗанның Тукай турындагы мәкаләләрен халык кабул итмәде. Халык Тукайга бөтенләй икенче төрле бәя бирде... Халыкка күбрәк ышанырга кирәк икән. Халык үз улын кимсетергә ирек бирми. Дөреслек – халык ягында».

25. «Очты дөнья читлегеннән...»

Язучы Р. Батулла «Нурга төренгән Тукай» язмасында татар шагыйрьләре һәм сәнгатьчеләре иҗатлары-тормышлары белән биш сыйфатка ия, дигән иде. Менә ул атаган сыйфатлар: илаһи куә, фәлсәфә, әүлиялык, фидаилык (каһарманлык, ватанпәрвәрлек, ил-халык өчен үзеңне корбан итәргә әзер булу, үзеңне корбан итү) һәм соңгы бишенчес – фаҗигале соң.

«Алдагы дүрт сыйфаты булган кешенең шәхси тормышы гаять катлаулы, кыен һәм, гадәттә, фаҗига белән тәмамлана. Аны җәберлиләр, кыерсыталар, үл түзми, үз-үзенә кул сала яки аны үтерәләр, яки үтертәләр; ул ялгызлыкта, юксыллыкта, чит-ят илдә, ватаныннан ераста, горбәттә үләргә мәҗбүр, – ди. Русларның Пушкины, Лермонтовы, татарның шул ук Кол Галие, Мөхәммәдъяры, Кол Шәрифе, Җәлилләре шушы язмышка дучар булмадылармы? Чит-ят илдә, Ватаныннан ераста ялгызлыкта үлмәсә дә, Тукай үз илендә үлде, дөресрәге, үләргә мәҗбүр ителде, ди. Моның белән килешми мөмкин түгел.

Якты дөньяның бөтен караңгы якларын күреп, азмы-күпме яктысыннан да өлеш алып, бик аз, бары 27 ел яши алды Тукай. Ләкин шагыйрь М. Җәлил әйткәндәй,

Билгеләми гомер озынлыгын
Еллар саны, картлык җитүе.

Шул 27 елның җиде елы тулы канлы иҗатка багышлана. Ул бит чиста шагыйрь генә түгел. Әдәбият-сәнгать, журналистика һәм публицистика өлкәсендә дә «ат уйнаткан» кеше. Һәм әле ничек кенә итеп! Күпләр гомере буе язып та Тукай дәрәҗәсенә җитә алмаска мөмкин. Әйе, Тукай кебек талантлар дөньяга пачкалап түгел, берәмләп кенә килә.

Моннан алдагы тапшыруларыбызда Тукайның 1912 еллар азагына кадәрге тормышы, иҗаты, эшчәнлеге белән танышкан идек. Менә тарих мәйданына 1913 ел аяк баса. Безнең бөек Тукаебызны мәңгелектән мәңгелеккә алып китәчәк ел.

Әле 1912 елның язында Тукай, Петербургка баргач, гомерендә икенче тапкыр докторга күренә. «Туберкулезның соңгы дәвере, бер үпкәсе череп беткән. Икенче үпкәсенең дә ярты сы гына калган. Тын ала торган әгъзаларының дүрттән бере белән генә тын алып тора», – ди доктор Тукай танышларының берсенә. Ә Тукайның үзенә өметләндергеч сүзләр әйтә. Докторның сүзләре Тукайга канатлар куйган кебек була. Сәламәтлеге соң дәрәҗәдә беткән булуга карамастан, 1912 елның көзеннән һәм 1913 ел башында ул күп эшли. «Кояш» газетасы, «Аң» журналының мәйданга килүе дә Тукайны эшкә, иҗатка рухландырган. Шигырь һәм публицистик язмаларын ул әлеге газета һәм журналда бастыра.

1912 елның җәендә Казанда «Амур» мөсафирханәсе ачыла. «Амур»ның ике кечкенә бүлмәсенә «Кояш» газетасы урнаша. Шагыйрьнең дусты Ф. Әмирхан да шунда яши һәм эшли башлый. Шул елның көзендә Тукаебыз да «Амур»га күчеп килә. «Болгар» номерларының суыгы тәмам желегенә үткәнлектән, яңа урында җылы бүлмәгә урнашып булмасмы дигән уй китергәндер аны монда. Аннан соң Ф. Әмирханга якынрак булырга тырыша.

Тукай «Җан азыклары» җыентыгын матбугатка әзерли. Язмыш шуклыгыдырмы, 1912 елның ноябрь башларында чыккан китапның тышлыгына «Габдулла Тукаев. «Җан азыклары». (соңгы шигырь мәҗмугасы). Нәшире «Мәгариф» китапханәсе. Казанда» дигән сүзләр языла.

1913 елның кышында Тукайның авыруы көчәя. Гомеренең

көннән-көн кими барганын Тукай сизгән. Нәширләрдән алачак 500 сум акчасын ике баланы стипендия биреп укыту өчен тотарга кушып телдән васыять тә әйтә. Кайбер кешеләрнең киңәшләре буенча, ул Кырымга бару фикеренә дә килә. Ә якын иптәшләре, һавалар рәтләнгәнче Кырымга баруны кичектереп торырга, анда барганчы берәр шифаханәгә кереп беркадәр хәл җыярга киңәш итәләр. Иптәшләре аны, 26 февральдә, Казанның иң яхшылардан саналган Клячкин шифаханәсенә, аена 150 сум хак түләп урнаштыралар. Тукай монда да тик ятмый: заманнан артта калмас өчен вакытлы матбугатны күзәтеп бара (читтә чыккан газета-журналларны да, рус телендәге вакытлы матбугатны да карап барганы билгеле). Каләмен дә ташламый. «Уянгач беренче эшем» дигән мәкаләсе дә больницада языла һәм 14 нче март санында «Кояш» газетасында басыла. Киләчәк буыннарга мирас итеп калдырачак шигырьләрен тазартып, чүп-чарлардан арындырып калырга ашыга. «Тиз арада үзем браковать итмәгән вә үзем яраткан шигырьләрдән җыеп, 400 сәхифәле зурлыгында рәсемле бер мәҗмуга чыгарырга карар бирдем», – ди әлеге мәкаләсендә. Газета-журнал редакцияләре белән бәйләнештә тора, записка-хатлар алыша. Гомеренең соңгы сәгатьләре якынлашканын күңеле белән сизсә дә, рухын төшерми. Нәшир, журналист һәм педагог Шиһап Әхмәров үзенең «Габдулла әфәнде Тукаевның авыруы» дигән истәлегендә болай яза: «...ул тән кешесе түгел, рух иясе иде; аның каршында җисмани авыру – авыру түгел, ул аңар илтифат итми; ул фәкать рух саулыгына, вөждан сафлыгына гына әһәмият бирә иде. Шуның өчен ул үзенең авыруын дәвалауга зур әһәмият бирми иде. Ул һаман тырыша, һаман яза. Ул үләргә ике көн калгач кына үзенең иң куәтле коралын – каләмен кулыннан ташларга мәҗбүр булды», – ди.

31 мартта шагыйрьнең хәле кинәт начарлана. Температурасы күтәрелә, пульсы ешая, тын алуы авырлаша. Иртәгесен дуслары Казанның танылган терапевты Лурияне алып киләләр.

– Хәле өметсез. Күп булса, өч көн торыр, хәтта алайга да бармас. Чиратлашып янында кунығыз, – ди доктор. 2 апрельгә каршы төндә хәле бераз яхшыргандай була. Әмма бу, мае беткән лампаның гөлт итеп бер яктырып алуы кебек кенә булып, төштән соң шагыйрьнең хәле авырая. Үләренә бер сәгать

калганда да, «Аң» журналына биргән шигырьләренең корректурасы белән кызыксына. 2 нче апрельдә кичке 8 сәгать 15 минутта Тукайның гомер кылы шартлап өзелә.

4 апрель көнне татар телендәге барлык газета-журналлар диярлек Тукайга багышлап чыгарыла. Бу көнне нәшриятлар, редакцияләр, китап кибетләре ябыла. Мәдрәсәләрдә укулар туктатыла.

4 апрельдә бөтен татар дөньясы шагыйрь белән саубуллаша. Тукайны соңгы юлга озатырга бөтен Казан җыела диярлек. Халык ташкыны урамнарга сыймый. Тукай һәм Сәйдәшне озаткандагы кебек халык ташкынын Казан хәтерләми. 5–6 мең кешенең озатып калуы – үлемсезлеккә илтә торган юл ул!

Тукай 20 нче йөз башында бездә иң күренекле сүз осталарының берсе булып танылды.

Тукайны татар халкы гына түгел, барлык төрки халыклар диярлек үз шагыйре итеп саный. «Тукайны фәкать татар халкының шагыйре дип кенә әйтү җитми. Тукай үзбәк халкы арасында да билгеле һәм танылган шагыйрь», – ди үзбәк поэзиясенең классигы Гафур Голәм. Казакъ әдибе Мохтар Ауэзов, үзбәк Хәмзә Хакимзадә, таҗик Садертдин Айни, азәрбайҗанлы Сөләйман Рәстәм, кыргыз Аали Токымбаев, төрекмән Берды Кербабаев, чуваш Педр Хузангай һ.б. каләм осталары Тукайны үзләренең остазлары дип саный. Тукай шигъриятенә югары бәя бирүчеләр арасында А. М. Горький, С. Есенин, Александр Фадеев, Луи Арагон, Павло Тычина да бар.

Безгә Тукайны өйрәнергә дә өйрәнергә әле. Без Тукай турында бик аз беләбез. Күп булса, мәктәп программасына кергән дистәдән артык шигырен, «Шүрәле» әкият-поэмасын, «Су анасы», «Кәҗә белән сарык» әкиятләрен... Тагын «Исемдә калганнар»ы. Ә бит Тукай турында шактый гына мәгълүматлар тупланган җыентыклар, галимнәребезнең хезмәтләре байтак. Тукай – татар дөньясында әсәрләре иң күп басылган шагыйрь. Аның шигырьләре рус теленә, төрки халыклар телләренә күпләп тәрҗемә ителгән, җыентыклары чыккан. Күренекле казакъ язучысы Сабит Муканов 1917 елда Тукай китабын кулга төшерә. 50 елдан артык, укып торырга да бирмичә, күз карасы кебек саклаган. Чөнки курка: китап кире кайтмас.

Татар халкы шагыйрь Тукаен алдагы 200, 300, 500 елдан соң да онытмасын, зурласын иде. Әнә бит үзбәкләр Галишер Навоиларын, әзәрбайҗаннар Низамиларын, иранлылар Гомәр Хәйямнарын, грузиннар Шота Руставелиларын гасырлар дәвамында укыйлар, өйрәнәләр, алар белән горурланалар. Балалары һәм оныкларына алар турында сөйлиләр, шигырьләрен дога урынына өйрәтәләр. Бу олуг шәхесләрнең исемнәрен үзләренең визит карточкасы урынына кулланалар. Безнең Тукаебыз да алардан ким булмаска тиеш!

Танылган театр тәнкыйтьчесе Габдрахман Кәрам болай дип язып калдырган: «Тукаев чын мәгънәсе белән шагыйрь һәм халык шагыйре булып калачактыр. Аның шигырьләре буыннан-буынга калып, миллионнарча балаларыбыз тарафыннан ятланачак вә аның шанлы исеме мәңгегә онытылмаячак». Амин, шулай булсын иде!

Файдаланылган әдәбият

«Тел дигән дәрья бар»

1. Абдуллина Р. С. «Сөйләм культурасы», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2012.
2. Батуллин Р. М. «Тузга язмаган хәлләр», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1997.
3. Галәветдин Идрис. «Сәлам бирә беләсеңме?», Яр Чаллы, «Тәүбә», 2010.
4. «Әдәбият белеме сүзлеге» (төзүчесе А.Г. Әхмәдуллин), Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1990.
5. «Әдәбият белеме, терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге», Казан. «Мәгариф» нәшрияты, 2007.
6. Әхмәтьянов Р.Г. «Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2003.
7. Батулла «Тузга язмаган хәлләр», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1997
8. Исәнбәт Н.С. «Балалар фольклоры», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1984.
9. Исәнбәт Н.С. «Татар халык мәкальләре», I–III томнар, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2010.
10. Кәримуллин Ә.Г. «Тел – милләтнең сакчысы», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1997.
11. Курбатов Х. «Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2002.
12. Мәхмүтов Х. «Язылмаган кануннар», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1995.
13. Сәрьян Х.С. «Уеңны уйдырып сал», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1977.
14. Саттаров Г. Ф. «Татар исемнәре сүзлеге», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1981.
15. Сафиуллина Ф.С. «Татар теленең лексикасы», 4–8 класслар өчен күнегүләр җыентыгы, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1975.
16. Сафиуллина Ф.С. «Тел дигән дәрья бар», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979.

17. Сафиуллина Ф.С., Ибраһимов Г.Б. «Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел», Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 1998.

18. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. «Хәзерге татар әдәби теле», Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2002.

19. Сафиуллина Ф.С. «Тел гыйлеменә кереш», Казан, «Тарих», 2001.

20. Хатипов Ф.М. «Әдәбият теориясе», Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2000.

21. Хәйруллин И. «Ислам дөньясында мең дә бер сорау», Уфа, 2009.

22. «Шатлыгым, кайгым минем....» Әдипләребез тел культурасы турында, Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2003.

23. Юсупов Р.А. «Икесен дә яхшы бел», Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2000.

24. «Язык – зеркало народа». «Тел – халыкның көзгесе», Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2009.

«Сабыйга» тапшыруы

1. «Балачак әдипләре», 1–3 китаплар, Казан, «Мәгариф «нәшрияты, 2006.

2. «Балачак энциклопедиясе», 1–4 китаплар, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2012 ел.

3. Дәрдемәнд. «Сайланма әсәрләр», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1959.

4. Исәнбәт. Н.С. «Балалар фольклоры», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1984.

5. «Совет Татарстаны язучылары» – библиографик белешмә, Казан, Татарстан китап нәшрияты. 1986.

6. «Татар совет әдәбияты» – IV том, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1986.

Тапшырулар әзерләгәндә, сәхифәгә исемнәре кергән барлык әдипләрнең әсәрләре, җыентыкларыннан файдаланылды.

«Кыйссадан хисса»

1. Батулла. «Тузга язмаган хәлләр», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1997.

2. Бикташи Җамалетдин «Фазаилеш шөһүр», Казан, 1996.
3. Җиһангирова Ш.Г. «Җирсү», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2001.
4. «Иманлы гаилә» – календарь, 2016.
5. Исәнбәт Н.С. «Татар халык мәкальләре», I–III томнар, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2010.
6. Насыйри К. «Китаб-әт-тәрбия», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1992.
7. Кәрим М.С. «Тормыш мизгелләре», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1996.
8. «Татарстан яшьләре» газетасы – «Замана кыйссасы» сәхифәсе, 2015.
9. Тукай Г.М. «Мәсәлләр», Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2002.
10. «Шура» дини альманахы, №7, 2015.

Тукай укулары

1. Батулла Р. «Урыннары җәннәттә булсын», Казан, «Рухият» нәшрияты, 2007.
2. «Бертуган Рәмиевләр» – фәнни биографик җыентык, Казан, «Рухият» нәшрияты, 2002.
3. «Дәрдемәнд» – фотоальбом, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2003.
4. Ибраһимов Г.Г. «Сайланма әсәрләр», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 5 том, 1978.
5. Нуруллин И.З. «Тукай» («Атаклы кешеләр тормышы» сериясе), Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979.
6. Нуруллин И.З. «Фатих Әмирхан» («Атаклы кешеләр тормышы» сериясе), Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1988.
7. Нуруллин И. З. «Тукай турында хикәяләр», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1966.
8. Нуруллин И.З. «XX йөз башы татар әдәбияты», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1982.
9. Расих А. «Ишан оныгы» романы, Татарстан китап нәшрияты, 1996.
10. Татар әдәбияты тарихы, III том, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1986.

11. Татар урта гомуми белем мәктәбенең 10 сыйныфы өчен дәреслек, Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2000.

12. «Тукай турында истәлекләр», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1986.

13. Г. Тукай. «Сайланма әсәрләр», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1968.

14. Г. Тукай. «Әсәрләр», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 5 томлы, 1986.

15. Г. Тукай. «Шигырьләр, поэмалар», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1990.

Эчтәлек

Дөнья сүзе – бер бүләк. *Автор*..... 3
Туган телебез – татар теле! *Мөслим муниципаль район башлыгы Рамил Муллин* 4
Туган тел сагында. *Мөҗәһит Әхмәтҗанов* 6
****Фоат Галимуллин* 9
Әссәләмәгәләйкүм, хөрмәтле милләттәшләр! *Ризәлә Исмәгыйлева*.....10

I б ү л е к

«ТЕЛ ДИГӘН ДӘРЬЯ БАР»

I кисәк

«Тел дигән дәрья бар».....9
1. «И газиз туган телем!»..... 9
2. Сүз көче. Сүз артын сүз ачар 12
3. Сүзләрнең дә тарихы бар... 16
4. Дөрес сөйлибезме? 19
5–6. Җырның һәм сүзнең «ертыгы» буламы? «Ертык» сүзләр һәм «ертык» җырлар 21
7. Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып..... 25
8. Катыштырма вә ләкин телгә телне.....31
9–10. Матурлык йөздә түгел – сүздә. Халык теле – чәчәкле болын 34
11. Ни башына ни кунган... 38
12–13. Кем син? Нәселең кем синең? *(Туганлык мөнәсәбәтен, нәсел-нәсәп, кардәш-ыруны белдерүче сүзләр)*..... *42*
14. Ни хәлең бар, кеше туганым? 45
(Исәнләшү, хәл белешү). 45
15. Алла боерса, хатын, ишек ач! (дәвамы). 48
16–17. Исемнәр бакчасына сәяхәт..... 50

II кисәк

Сүзләр һәм гыйбарәләр дөньясында..... 54
1. Маңкорт..... 54
2. Тели белсәң – теләк... 55
3. Хикмәтле гыйбарәләр. Сүзләрнең дә хикмәте бар..... 58
4. Үзеңнеке үзеңә кайтсын 60

5. Байлыгыңа масайма, дәрәҗәңә таянма,
саулыгыңа инанма! 62
6. Тырышлык бәхет китерер, ялкаулык ачтан үтерер..... 64
7. Хикмәт әйтә белүдә 66
8. Яхшы сүз – җан азыгы, яман сүз – баш казыгы..... 67
9. Алай димә! 69
10. «Үзеңә үлем теләмә!»..... 70
11. Көнче көне көенеч 71
12. Кешегә баз казыма... 73
13. Нәүширвандай гадел... 75
14. Тартасыңмы, саласыңмы? 76
15. Аллаһ ризалыгы өчен..... 78
16. Беләсем килгән иде... 80

III кисәк

Ни өчен болай әйтәбез? 83
2. Әгәр Дәүләт сукыр булмаса.... 85
3. Һәр сүзнең мәгънәсе була. Картның васыяте..... 87
4. Алтын канат атаң бар, көмеш садак анаң бар 88
5. Үз өемдә үз көем..... 89
6. Карама түшенә, кара эшенә..... 91
7. Авызын ачса, үпкәсе күренә 93
8. Атсыз авыруның аты корысын 94
9. Мифологик образларга бәйле мәкаль-әйтемнәр 95
10. «Йөзек кем кулында булса, шул – Сөләйман» 96
11. Аю хезмәте күрсәтү 98
12. Аты барның – канаты бар..... 98
13. Безнең дә атабыз кияү, анабыз килен булган 99
14. Язганны күрерсең, чәчкәнне урырсың 100
15. Колакка киртеп кую..... 102
16. Питрау күкесе.....103
17. Сафура буранналары..... 104
18. Грек, Рим мифлары буенча таралган мәкаль-әйтемнәр 105
19. Грек мифларыннан кергән әйтелмәләр 106
20. Дөньяны сүз бизәр 107

IV кисәк

Сөйләм культурасы 109
1. Тел, сөйләм – милләтнең визит карточкасы. Сөйли белү – сәнгать ул 109
2. Күп сүз – чүп сүз 111
3. Сөйләмең ипле булсын 112
4. Кешесенә карап сүз сөйлә 114
5. Сүзне әйт сыяр җиргә, яки сүз вакытында һәм урынында әйтелсә генә сүз 116
6. Ике тыңла – бер сөйлә 118
7. Кеше сөйләмдә ачыла 119
8. Кеше сүз пәрдәсе артында (сөйләүченең темпераменты сөйләмендә күренә) 121
9. Сөйли белү – һөнәр ул 122
10. Ораторлык сәнгате 124
11. Бергә булыйк, бердәм булыйк 131

II бүлек

«САБЫЙГА». РАДИОТАПШЫРУ

I кисәк

1. Кереш 136
2. Каюм баба сабаклары 138
3. Г. Тукай һәм татар балалар әдәбияты 140
4. Фатих Әмирхан һәм татар балалар әдәбияты 142
5. Дәрдемәнд һәм татар балалар әдәбияты 143
6. Дәрдемәнд. Балалар өчен кыска хикәяләр 146
7. Галимҗан Ибраһимов һәм балалар әдәбияты 148
8. Балалар язучысы Абдулла Алиш 151
9. Абдулла Алиш. «Куян кызы» 154
10. Балалар язучысы Дәрҗия Аппакова 157
11. Дәрҗия Аппакова. «Сөяк саплы пәке» (ахыры) 159
12. Гадел Кутуй. «Рөстәм маҗаралары» 160
13. Әмирхан Еники (1909–2000) 162
14. Әмирхан Еники. «Курай» хикәясе 166
15. Әминә Бикчәнтәева (1913–1986) 167

II кисәк

1. Бари Рәхмәт (1897–1957) 169
2. Әхмәт Фәйзи (1903–1958) 171
3. Әхмәт Фәйзи. «Тукай» романыннан өзек 174
4. Ләбибә Ихсанова (1923–2010)5
(әдәбиятыбызның Ак апасы) 175
5. Л. Ихсанова. «Җир астында җиде көн» 178
6. Роза Хафизова (1929–2005) 179
7. Р. Хафизова. «Кирлемән» 180
8. Татар балалар әдәбиятының әйдәманы –
Шәүкәт Галиев (1928–2011) 181
9. Ш. Галиев иҗаты. Шәвәли кем малае? 182
10. Резедә Вәлиева (1930) 184
11. Резеда Вәлиева (дәвамы). 186
12. Роберт Миңнуллин – балалар шагыйре 187
13. Р. Миңнуллин иҗаты (дәвамы) 189
14. Мөҗәһит (Мөҗәһит Әхмәтҗанов) иҗаты (1950) 191
15. Дания Гайнетдинова (1952) 193
16. Татарның Шолоховы – Фоат Садриев (1941) 195
17. «Таң җиле» романы – Аналарга мәдхия 197
18. Ф. Садриев «Аппакай». 200
19. Фантаст язучы Адлер Тимергалин (1931–1913). 201
20. Адлер Тимергалин. «Сәер планетада» (Өзек) 203
21. Рафис Корбан (1957) 205

III кисәк

«Сабыйга» – Балалар фольклоры 208
1. Балалар фольклорының әһәмияте 208
2. Бишек җырлары 209
3. Суы сарыксын, үзе калыксын! 210
4. Үс, үс, балам! 212
5. Топ-топ баса, туры китереп баса 213
6. Тел ачтыру, тел шомарту 214
7. Бала һәм әйләнә-тирә табигать 216
8. Чакырулар 218
9. Камка, ала карга 219
10. Санамышлар, хәрәкәтле уеннар 221
11. Тап, табышмак! 222

12. Җиләк җыям, как коям 224
13. Алдавыч әкиятләр 226
14. Имеш төбе – җимеш яки ни өчен алай? 226
15. Имеш төбе – җимеш 227

III бүлек

«КЫЙССАДАН ХИССА»

1. Югалмас байлык 228
2. Изге холыкларның күркәме – дошманны дус итү 230
3. Туган тел – иң бөек тел 231
4. Кереңнән элек, чыгарыңны уйла 233
5. Тәхет һәм бәхет 235
6. Нәрсә эшләсәң дә үзеңә әйләнеп кайта 236
7. Беркайчан да зарланма 238
8. Әйткән сүз – аткан ук 239
9. Изгелекнең кадерен бел! 241
10. Һөнәрле үлмәс 242
11. Яхшы гадәт – яхшы тәрбия җимеше 244
12. Саран булма, юмарт бул! 246
13. Комсызлык – угрылыкның да юлдашы 248
14. Күрмәгәннең күрәсе килә 250
15. Хәерлегә булсын! 251
16. Мәхәббәт сынаулары 252
17. Аналар мәхәббәте – иң көчле мәхәббәт 254
18. Нәфес – шайтан! 256
19. Кешесенә карап... 258
20. Сүз йөртүдән олы гөнаһ юк! 260

IV бүлек

«ТОРМЫШ ТӘРӘЗӘЛӘРЕ»

Ни өчен «тормыш тәрәзәләре?» 262
1. Сабыр төбе – сары алтын 263
3. Оҗмахта дип белгән 264
4. Болай да була 265
4. Сез һәм без турында 266
5. Без капчыкта ятмый 267
6. Хәлфә һәм аның шәкертләре 268

7. Бисмилласыз эш башланмас..... 268
8. Арадан берсе..... 269
9. Сабый бала өчен Ана – нинди булса да ана! 271
10. Үги үз булмый..... 272
11. Бер абынган ат 272
12. Бер горурлык хисе 273
13. «Беренчесе – гармун, икенчесе – скрипкә» 274
14. Бәхет ачкычы кем кулында? 275
15. Рәхмәт көне турында..... 276

V бүлек

ТУКАЙ УКУЛАРЫ

1. «Без – Тукайлы халык» 278
2. Тукай шагыйрьлек турында. Шагыйрь булу җиңелме? 279
3. Тукай иҗатында халык, аның язмышы, гражданлык лирикасы..... 283
4. Тукай иҗатында табигать, туган җир 286
5. Тукай һәм балалар әдәбияты 287
6. Тукай һәм балалар әдәбияты (дәвамы) 290
7. Тукай иҗатында дин..... 293
8. Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы... (Тукай иҗатында мәхәббәт)..... 296
9. И матур! Мин янмас идем – яндыручы булмасаң; Таммас иде җиргә яшьләр – тамдыручы булмасаң! 302
10. Г. Тукай – фәлсәфәче..... 306
11. Тукай – әүлия шагыйрь 311
12. «Җандай күрәм мин искеләрнең җырларын» .....314 (Тукай һәм җыр сәнгате).....314
13. Театр яктылыкка, нурга илтә (Г. Тукай һәм театр) 316
14. Г. Тукай – социаль контрастлар шагыйре.....318
15. Тукай мөтәрҗим (тәрҗемәче) шагыйрь генәме? 321
16. Шат яратса да җиһанга ят яраткан Раббысы!..... 324
17. Ваксынмау..... 328
18. Ни әйтмәс бәндәләр, кермим бәхәскә, Яман-яхшымны бик беләм үзем дә.....331
19. Г. Тукай иҗатында юмор һәм сатира 333
20. Ни өчен Тукай иҗатында сатира зур урын ала? 335
21. Тукай – журналист һәм публицист 336

22. Г. Тукай – мөгаллим 339
23. Г. Тукай һәм Дәрдемәнд.....341
23. Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан..... 345
24. Г. Тукай һәм Галимҗан Ибраһимов 350
25. «Очты дөнья читлегеннән...».....352

Файдаланылган әдәбият.....358

ISBN 978-5-905160-20-2



Мухамметгараева Гульфия Вагизовна

НАКАЗ ПРЕДКОВ
(на татарском языке)

Мөхәммәтгәрәева Гөлфия Вагыйз кызы

ДӨНЬЯ СҮЗЕ – БЕР БҮЛӘК

Корректоры: *Фирая Маликова*
Бизәлеш мөхәррире, техник мөхәррире,
компьютерда битләргә салучысы: *Азат Яшәр*

+10 Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. № 436-ФЗ

Басарга кул куелды 7.04.2021. Форматы 60×90 1/16.
«Times» гарнитурасы. Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 23,0.
Тиражы 1000 данә. Заказ

ООО «Халкыбыз мирасы» нәшрияты
Казан, Спортивный урамы, 33, офис 1
Тел. 8(843) 246-2-246, 89046-746-246
http://aksu.tatar
e-mail: 2959308@mail.ru